ISSN 0206-4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

3.2005



# КАЗАН ШӘҺӘРЕНӘ—1000 ЕЛ



*Хәзерге Тукай урамы, 14/19 йортта урнашкан Солтан мәчете*



*Казансу елгасы аркылы салынган күпер*

ХХ гасыр башында алынган фотосурәтләр.
*Абдулла Дубин коллекциясеннән.*

**Казан утлары**
**Qazan utları**

2005

# 3

(989)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркатип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
Факс — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Рәдиф ГАТАШ. *Шигырь.* ...... 5
Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Яңа шигырьләр. ...... 21
Зиннур ХӨСНИЯР. Кәҗә йөри кыектан. *Повесть.* ...... 28
Әхәт САФИУЛЛИН. Кешене өмет яшәтә. *Повесть.* ...... 71
Нәҗибә САФИНА. Күкләр тора—елап, көлеп, күкрәп. *Шигырьләр.* ...... 106

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Әгъдәс БОРҺАНОВ. Россияне танып белү. ...... 6

**ЯҢА ИСЕМНӘР**

Наилә МИҢНЕХАНОВА. Бәйрәм иртәсе. *Шигырьләр.* ...... 129

**ҖИҢҮНЕҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА**

Маннур САТТАРОВ. Окопташ дусларымның берсе. *Документаль повесть.* ...... 109

**ШАГЫЙРЬ ҖӘҮДӘТ СӨЛӘЙМАНГА 50 ЯШЬ**

Флүс ЛАТЫЙФИ. Шагыйрь күңеле дәрьядыр. ...... 64
СӨЛӘЙМАН. Өзелгәнем, җирдә эзләгәнем. *Шигырьләр.* ...... 68

**ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"**

Хатип ГАЙСИН. Гамәленә күрә әмәле. ...... 132

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Милли казаныш. ...... 136
Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. ...... 171

**ХӘТЕР**

Фәнис ЯРУЛЛИН. Сирәгәя бара аккошлар. ...... 154

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ**

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында. 166

**АБДУЛЛА ӘХМӘТНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ**

Флүс ЛАТЫЙПОВ. Балачак хатирәсе. ...... 178

**ӘДХӘТ СИНУГЫЛНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ**

Рәдиф ГАТАУЛЛИН. Сәйях шагыйрьнең сәйяр гомере. ...... 182

**ХӘНИФ ХӨСНУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ**

Үзгә бер тыйнаклык хас иде. ...... 183

Хатлардан юллар. ...... 176
Котлыйбыз! ......180-181
Latin imlasında uqu künekmələre ...... 184
"Казан утлары" архивыннан. ...... 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ...... 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

Указ Президента Республики Татарстан о Государственной премии им. Г. Тукая.
"Проза и поэзия": стихи Р. ГАТАША, Р. ФАЙЗУЛЛИНА, Н. САФИНОЙ, Н. МИНГАЗОВОЙ; повести З. ХУСНИЯРА "Ходила коза по карнизу", А. САФИУЛЛИНА "Надежда умирает последней".
"К 60-летию Победы": документальная повесть М. САТТАРОВА "Друзья-однополчане".
"К 50-летию Дж. Сулеймана" статья Ф. ЛАТЫФИ, подборка новых стихов поэта.
Дискуссия "Герой нашего времени": статья Х. ГАЙСИНА.
"Наука": статья А. ТИМЕРГАЛИНА "Национальное достижения"; "Словарь нации".
"Память": воспоминания Ф. ЯРУЛЛИНА о композиторе Ф. Ахметове.
К 100-летию А. Ахмета: статья Ф. ЛАТЫПОВА.
В номере отмечаются 70-летие А. Синугыла, Х. Хуснуллина.
Наши юбиляры.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: "Казанская красавица" – работа художника Н. ВАСИЛЬЕВОЙ; писательница – публицист Венера Якупова.

## IN THIS ISSUE:

*The magazin edits monthly*

Decree of the President of Republic of Tatarstan about the State premium of Tukai.
«Prose and poetry»: verses by R. GATASH, R. FAIZULLIN, N. SAFINA, N. MINGAZOVA; stories by Z.HUSNIYAR «Goat walking on eaves», A. SAFIULLINA «Hope dies last».
«To 60th anniversary of Victory»: documentary story by M. SATTAROV «Friends-comrades».
«To 50th anniversary of G. SULEIMAN» article by F. LATYFI; new verses of poet.
Discussion «Hero of our time»: article by H. GAISIN.
«Science»: article by A. TIMERGALIN «National achievements»; «Dictionary of nation».
«Memory»: memoirs by F. YARULLIN of composer F. Ahmetov.
To 100th anniversary of A. Ahmet: article by F. LATYPOV.
In his edition is celebrated 70th anniversary of A.Sinugyla, H.Husnullin.
People celebrating their jubilee.
From photoarchive of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Kazan beauty» work by artist N. VASILYEVA; writer-publicist Venera Yakupova.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 21.02.2005 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 7011. Заказ А–88.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2005 ел.

**Рәдиф Гаташ**

***

Шагыйрьләргә тик илһамчымы син,
Татар кызы?! Күпме ярасын
Бәйләдең бит илнең! Әле озак
Безгә бергә-бергә барасы,
Сине, ак калфаклы алиһәбез,
Сынауларның көтә яңасы...

Борынгының Афродитасымы?—
Син Тукайның, бәлки, Зәйтүнәсе—
Әрнүләрнең горур Музасы.
Тарих аша синең йөрәктә ул
Килә назның сабыр туташы—
Язмышларның тугры юлдашы!

Күпме шагыйрьне син алып килдең
Татар Парнасының тәхетенә.
"Зәукың" өчен түгел, хисең һаман
Тоташ ил җанына, бәхетенә:
Безнең тулпарда син таккан чуклар
Бәйгеләрдә барган чагында.
Гамь дибез еш—җәрәхәтле хәтер
Гасырлардан кайтып чагыла,
Ул синең дә тере—җаныңда...

Татар кызы, Муза, Алиһәбез,
Әле озак бергә барасы,
Ахыргача бул син моң туташы,
Ахыргача ил, җыр ярасын
Син ябарсың наз-яулыгың белән...
Чор, җир тетри...
Безгә—барасы!



Әгъдәс
Борһанов

# РОССИЯНЕ ТАНЫП БЕЛҮ

*"...камил булмаган һәм куркыныч теләсә нинди нәрсәләрне аңлауны үзеңнән башларга кирәк".*
Ю. Н. Афанасьев

Соңгы елларда безнең илдә торгынлык-күчеш-акыл җитеп бетмәү заманнарында танылган тарихчы галимнәрнең бик тәфсилле фундаменталь хезмәтләре дөнья күрде. Аларның максаты илнең, халкыбызның һәм дәүләтнең тарихын тирәнтен танып белү, аларны моңа кадәр чыгып килгән басмалардагы идеологик яктыртудан арындыру иде. Менә ул хезмәтләрнең кайберләре: Б. Миронов. Россиянең империя чорындагы социаль тарихы *(XVIII-XX гасырлар).* Шәхеснең, демократик гаиләнең, гражданнар җәмгыятенең һәм хокукый дәүләтнең җеназасы, I том. *(СПб. 1999)*; Ю. Афанасьев. Куркыныч Россия. Бүген самодержавие традицияләре *(Изд. Центр РГГУ. М., 2001)*; А. Яковлев. Энгер-меңгер. *("Материк". М., 2003).* Боларга өстәп бөтен дөньяга танылган әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренең Россиянең бүгенгесе һәм киләчәгенә бәһа бирү, әүлиялек сыйфатларына ия кайбер хезмәтләрен дә күрсәтергә мөмкин.

Минем бу тикшеренүем үземнең "Кайдан киләсең һәм кая барасың, Россия? Россияннарның Октябрьдән соңгы тарихын һәм киләчәген анларга тырышу тәҗрибәсе" *(М., "Инсан". 1996)* һәм "Милек философиясе һәм социологиясе: Россия чынбарлыгы" *(М., "Эльф-М., 2000)* дигән китапларымдагы идея-фикерләрне үстерү ниятеннән язылды. Мин өстә күрсәтелгән авторларның фикерләре белән килешеп, кайвакыт шулардан өзәреш алып яки бәхәсләшеп, әлеге мәсьәләне аңлауны тирәнәйтергә теләдем. Кешелек дөньясы илнең-дәүләтнең һәм халыкның яшәеше, төп үзәге мәгълүм бер табигый-тарихи яки ясалма принциплардан чыгып оештырыла торган милек мөнәсәбәтләренә таяна, турыдан-туры аның язмышын билгели.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, бу хезмәтләрнең барысы да рус телендә язылган.

"Россиядәге модернизациянең өч гасырлык тарихы, нигездә, уңышлы булган: Россиянең алга барышы вакыт-вакыт 15-25 елга сузылган кризислар, сугышлар, җәмгыятьтәге чуалышлар яки хәзерге кебек радикаль реформалар белән өзелгәләп торган. Андый кризислардан соң алга барыш яна көч белән дәвам итә. Барлык илләр өчен дә хәзерге заманда уртак булган, җәмгыять үсешендәге нормаль күренеш

Әгъдәс БОРҺАНОВ (1920) – *Россия дәүләт гуманитар университеты профессоры; Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы; тарих фәннәре докторы, дәүләтчелек һәм сәясәтнең актуаль темаларына күпсанлы монографияләр авторы. Мәскәүдә яши.*

кебек, россияннарның бүгенге авыр кризисы да вакытлыдыр, ул озакламый бетәр дигән өмет бар. Россиядәге тарихи процессның нормаль хәл икәнен дә әйтеп үтү кирәктер",—дип раслый Б. Миронов. Кыскасы, бездә хәлләр начар булса да, ул шулай булырга тиеш. Димәк, яңадан "велосипед уйлап табу" белән шөгыльләнмәскә кирәк. Хакимият башында утыручы түрәләр өчен бик уңайлы тезис-фикер бу.

Кайбер авторларның фикерләре башкачарак. "Ни өчен кешеләрнең көндәлек тормышын җиңеләйтү һәрвакыт Көнбатыштан килә? Ни өчен без бик тә ышанычсыз сәясәтчеләр белән бер арбада әле? Ни өчен табигый байлыклары, уңдырышлы җирләре булмаган илләр бездән яхшырак яши?"—Моңысы А. Яковлев сүзләре. Бу сорауларга җавапларны бары тик ярлылыгыбызны, ялкаулыгыбызны, башбаштаклыгыбызны русларның һаман аңлашылып бетмәгән күтәренке рухына сылтамасак кына таба алырбыз. Кызганыч ки, русларның бөтен тарихында ияреп килгән бәлаләрне аңламау, аңларга теләмәү, тынгы бирми торган бөеклек, мессианлык фикерләре, ул фикерләрне теләсә нинди чаралар белән тормышка ашырырга тырышу рус психологиясендәге иң тискәре сыйфатлардыр. Россиянең иң асыл патриоты Дмитрий Лихачев "безгә тәүбәгә килергә кирәк" дигән.Без аның бу сүзләрен васыять итеп алырга тиешбез. Юкса, без әле һаман да Дәүләт Думасы рәисе булган Г. Селезневның "безнең тәүбәгә килерлек гамәлләребез юк" дигән сүзләрен сокланып кабул итәбез. Кызганыч ки, үзебезгә дә, кешелек алдында да тәүбә итәрлек эш-гамәлләребез күп. Күренекле рус язучысы Борис Васильев: "Бездәге шикелле тарихи хәтере зәгыйфьләндерелгән башка берәр халык бармы икән? Бер нәрсәне дә хәтерләмибез, бер нәрсәгә дә өйрәнмибез..."—дип яза.

Алга таба йөгертебрәк булса да, Ю. Афанасьев китабына үз фикеребезне белдерергә кирәк табам. Ул китапка Б. Виттенберг бик бәхәсле бәя биргән. Ул аңа "Тарихи оптимизм һәм тарихи пессимизм" дип исем биргән. Аның фикеренчә, Ю. Афанасьев хезмәте тарихи пессимизм күзлегеннән чыгып язылган, димәк, тарихка дәүләтчә караш түгел бу. Дәүләтчә караш ура-патриотик рухта булырга тиеш, үлсәк тә, "җырлап үләчәкбез" димәкче автор. Рецензент белән килешергә мөмкин түгел. Оптимист начарны да яхшы дип мактаган кеше түгел. Оптимист начарны начар дияр, аны бетерергә тырышыр. Пессимизм белән дә шундыйрак хәл: акны кара дияр. Ю. Афанасьев Ватанының тирән җәрәхәтләрен ачып, аларны дәваларга тырышучы оптимист.

Виттенберг Ю. Афанасьевның "Гайдарча конфескацион акча реформасы үткәрелде, Чубайсча бандитларча приватизация ясалды, Ельцин кушуы белән парламент бинасын утка тоттылар, Чечняда сугыш башладылар. Путин исә хәзер асылда монархистик-большевистик, ә формасы белән демократик хакимиятне ныгытырга маташа. Хакимият һич тә үзгәрмәде",—дигән нәтиҗәләре белән килешми. Ул шулай ук Афанасьевның "Россия узган гасырның туксанынчы елларын оттырды..."—дигән фикеренә дә каршы чыга. Ул: "Россия ачык һәм ирекле илгә әверелде. Сәяси ирек, сүз ирегә бар, нормаль икътисадка да нигез салынды—икътисад сәясәтендә уңышсызлыклар булса да, эшмәкәрлек ирегә саклана. Ә туксанынчы еллардагы сәяси яулап алуларның язмышы аны хакимиятнең кысарга тырышуына гына бәйле түгел, ул Россия гражданнарының сәяси ирекне яклап калу сәләте булу-булмауга бәйле",—дип яза. Афанасьев хаклы: туксанынчы еллар тулысы белән оттырылды. Әйе, сәяси ирекнең күпмеседер сакланып калды, чөнки, беренчедән, туксанынчы еллардагы демократик хәрәкәтнең чәчәк аткан чорында Россия элек без таныргa теләмәгән кеше хокуклары турындагы кайбер килешүләргә кушылды, икенчедән, хакимияттәге түрәләрнең бик тә инде "европалылар" буласы килә, алар моны элегрәк үзләре Россиягә таккан иделәр, шуны хәзер яңадан кайтарып алмакчылар. Ә төп мәсьәләдә—нормаль икътисади үсешкә нигез салынмый калды. Алай гынамы соң: халыкны һәм дәүләтне оялмыйча талау өчен бөтен шартлар тудырылды. Бер генә мисал—1998 елның августында Халыкара валюта фонды безгә чираттагы заем биргән иде. Америка долларлары белән исәпләгәндә, аның 235 миллионы Ельцинның кызы Татьяна Дьяченко исеменә Сидней банкына (Австралия); 1 миллиард 400 миллионы Россиянең ул вакыттагы премьер-министры Черномырдин исеменә Нью-Йорк банкына; 780 миллионы "Кредит Сюисс"

(Швейцария) банкына А. Чубайс исеменә; 270 миллион доллар "Кредитанштальт-Банкферейн"га) (Швейцариянең Лозаннадагы бүлеге)—Б. Березовский исеменә; фунт стерлингка әйләндереп, Вестминстер Милли банкына (Лондон, Бөекбритания)—2 миллиард доллар Борис Ельцин исеменә күчерелделәр. Черномырдин, Чубайс, Березовский, Ельцин исемендәгеләре ябык исәптә, ягъни аларны беркем дә ала алмый. "Әгәр дә Россия ихтыяжларына нәрсә дә була калса, ул 100 миллион доллардан артмыйдыр",—дип яза Ю. Афанасьев. Бу "карак әфәнделәр" "россияннарның моңа түзеп торуларына өметләнәләрдер, бәлки. Моңысы беркайчан да булмас. Үзләрен җаваплылыкка тартмасалар, аларның бер гаепсез нәсел-нәсәпләренә шундый бәлаләр киләчәк әле—Ходай үзе күрсәтмәсен! Россия тарихында мондый вакыйгалар бер генә булмаган бит. Олигархик-монополистик капитал дәүләт белән үрелеп үскән чакта халык хуҗалыгының нормаль үсеше була алмаячак, дөнья тәҗрибәсе шуны күрсәтә: аның ким дигәндә ярты өлеше вак һәм урта бизнеска бирелергә тиеш. Ә ул бездә "күгәрчен борыны" хәтле генә: Афанасьев аны халыкның дүрт процентган да азрагында дип саный. "Альфа-Банк" президенты П. Авен: "Кече бизнес бездә 13-15 %тан артмый. Нормаль икътисадта ул 50%тан да артык булырга тиеш",—ди. Монополистик капитал, XX гасыр тәҗрибәсе күрсәткәнчә, фашизмга (коммунофашизмга) нигез ул, ул бөтендөнья сугышына әверелеп китәчәк империалистик сугышлар башлануга бер сәбәп кенә.

Безнең ил гражданнары туксанынчы елларда яулап алынган сәяси мөмкинлекләрне яклый алмый, аларның тавышларын бер шешә аракыга, бер кап шикәргә һәм башкаларга түрәләр (электорат) сатып ала, демократик электорат бары тик күпчелеге урта сыйныф милекчеләре булганда гына барлыкка килә. Безнең әдәбиятта вак һәм урта бизнесны еш кына икътисади мәсьәлә итеп кенә күрсәтәләр. *(А. Яковлев—"Энгер-менгер").* Бу проблема, иң беренче чиратта, социаль-сәяси проблема. Электоратның нигезен тәшкил итүче күпмиллионлы үсеш субъектлары оешмый торып, без, милләт буларак, яшәргә сәләтсезләр. Бары тик шул очракта гына социаль-сәяси тотрыклы дәүләт төзеп булачак. Халык бүген үз-үзен "талап җыелган байлыкны талап ал", дигән ысул белән генә яклый алмый, "реформалар" дигән булып, аны төбенә кадәр таладылар, ул хәзер оеша алмый. Аны оештыручы-туплаучылар да юк, булган очракта да аны көрәш барышында ашатып-яшәтеп торучылар да юк. Коммунизм төзергә хыялланган җитәкчеләр, бигрәк тә Сталин, бу катлаулы-четерекле проблеманы аңлаганнар. Яковлевның: "Беркемнеке дә булмаган (дәүләтнеке булган) милек мәсьәләсенең язмышын хәл итмичә, чын мәгънәсендә иҗтиһат итәрлек икътисади һәм сәяси тотрыклылык Россиядә булмаячак",—дип язганы бик берьяклы гына. Ул мәсьәләне чишүне кемгә һәм ничек хәл итәргә тапшырасың бит? Хакимият аны үзе тудырган олигархларга тапшырды да үзе мөшкел хәлгә төште. Дәүләт милке—халык милке ул, халык реаль милекче булырга тиеш. Җәмгыятьтәге барлык мөнәсәбәтләр бары тик илдә массакүләм милекчеләр оешканда гына туа ала. Ләкин ул дәүләт тарафыннан даими таланып килгән һәм асылда хәерчелеккә тарыган халык арасында үзеннән-үзе барлыкка да килә алмый. А. Яковлев тәкъдим иткән реформа чараларының берсе дә милекчеләр сыйныфын булдыруның мөмкинлекләрен ачып күрсәтми. Массакүләм милекчеләрне массакүләм кәсәбәчеләр белән дә бутарга кирәк түгел, янәсе, 1985 елда базар реформаларын шуннан башларга мөмкин булган. Массакүләм милекчеләр чынлыкта бөтен халык булырга тиеш, ә массакүләм кәсәбәчеләр, күп булса, халыкның 3-5% ын гына тәшкил итә. *(А. Зиновьев фикере).* Безнең уебызча, ул бар халыкның 1% ын гына били, аңысы да әле җәмгыятьтә массакүләм милекчеләр булган очракта гына.

Хакимиятне үзгәртү турында. Ул бары тик сәяси оешкан-тупланган халык массалары аны революция барышында алыштырганда гына була ала. Россиядә антифеодалистик революция йомшаграк булса да, халыкның социаль актив өлеше: крестьяннарның өчтән бер өлеше кулаклар һәм урта хәлләләр, шәһәр буржуазиясе булганга күрә мөмкин булган. Шул сәбәпле, ул объектив котылгысыз буржуаз эчтәлекле булып, барыбер буржуазиянең җиңеп чыгуына китермәгән. Шуңа да

аларның көчәнүе, җәмгыятьнең буржуаз-демократик максатларын чор таләп иткәнчә чишү мөмкинлеге булмагач, социаль-сәяси көчләр дә юклыктан көчәнү генә булып чыккан, революцияне дәвам итү коммунистлар җилкәсенә төшкән. Алар, әлбәттә, революциягә бик теләп кушылып киткәннәр, үз максатларына ярашлы вакыйгаларны үзләре үк оештырганнар, алар ясалма-ялган булганлыктан, бер максатка да ирешә алмаганнар. Крестьяннарның өчтән ике өлеше бик ярлы һәм шәһәрләшкән халык булган, алар шәһәр пролетариатына ярдәм итешеп, хакимияттә коммунистик диктатура урнаштырганнар. Нәтиҗәдә "шөшле биреп без алдым" килеп чыккан: самодержавно-бюрократик диктатураны коммунофашистик диктатурага алыштырганнар. Боларның аз гына да мәдәни социаль җирлеге булмагач, талау-юлбасарлык сыйфаты үсеп, бик күп тискәре күренешләр барлыкка килгән. Мәгълүм бер мәзәктә, иң хәерче Африка илләренең берсе өр-яңа ракеталар белән баштанаяк коралланган, дип сөйлиләр. Коммунистлар да иң начар сыйфатлы дәүләт капитализмы оештырып караганнар. Моны юлбашчы Ленин да бик тиз аңлап алган. Кайбер авторлар инде череп таркалган шул дәүләт системасын мактап, хәзерге түрәләрне яманлап, У.Черчилльнең шундый фикерен китерәләр: "Сталин сукалы Россияне житәкләгән, аны атом бомбалы итеп калдырган". Ләкин халык һаман да кытлыкта, тегесе житми, монысы житми, торыр куышлары да юк, ә дәүләт бюджеты тулысы белән шул атом бомбасын булдыруга, аның серләрен американнардан урлауга китеп бара.

1991 елның августында яңа тип хакимият урнаштыру максатын куйгач, халык арасыннан яңа хакимият төзергә сәләтле сыйныф та булдырырга кирәк иде. Ә андый сыйныф юк, халык, нигездә, тулаем ярлы пролетариат кына, аның милке-мөлкәте дә юк, димәк, үсеш-алгарышны күтәрерлек сыйныф та юк дигән сүз. Хакимиятне шул ук сыйныф булып житмәгән функционерлар, өлешчә хакимияттә утырган, әмма бер баскычка түбән дәрәҗәдәге икенче клан алыштырды да куйды. Хакимияткә килгәч, бу клан үзенә таяныч булырдай, үзеннән таләп тә итәргә сәләтле социаль нигезе булмаганлыктан, бюрократизм закончалыклары буенча "Җавапсыз демократия" булды, хәзер ул "идарә ителә торган демократия" дип йөртелә башлады. Үзе барысы белән дә идарә итәргә тиешле клан белән идарә итәргә тотындылар. Менә шундый әкәмәт...

А. Яковлев та башка сүзләр белән генә шул хакта ук фикер йөртә: "Без яңа сыйфатка ия дәүләт аппараты төзи алмадык. Ул саботажчылар һәм сатлыкҗаннар, эшлексезләр һәм һәртөрле законнарны сөймәүчеләр аппараты булып калды. Ул хәзер дә шул халәттә. Ул системаның үзе тарафыннан шулай "өйрәтелгән". Демократлар үзләре берничек тә чишә алмый торган бурыч куйдылар. Шуны аңлаган, дөресрәге, шуны инстинктив тойган демократларның беренче дулкыныннан "үзгәртеп коруны башлаган" кайбер күренеклеләре актив сәяси эшчәнлектән бөтенләй киттеләр, кайберләре исә шактый "икмәкле" урыннарыннан да отставкага чыктылар. Күпчелеге системага яраклашты да хәзер дәүләтне уңышлы гына "имеп ята". Алар бит һаман да бюрократик дәүләткә хезмәт итәләр, түрәләр ана нәрсәләрнедер тыю өчен, "үзенә йолку һәм башкаларга юл бирмәү" өчен, күзәтеп-буйсындырып тору өчен кирәк. Мондый дәүләттә "яңа" аппарат баш бюрократны алыштырып эшләнә, ләкин ул шәхес буларак кына "яңа" (әйтик, "мәскәүлеләр" урынына "питерныкылар"), ә сыйнфый асылы шул ук кала. Соңгы сыйфатта аппарат бары тик өстен сыйныфка гына хезмәт итә, ләкин җәмгыять хезмәт итә торган сыйныф булып үзе кала алмый. Мондый бюрократик системада түрәләрнең буйсынуы—хисап тотуы да вертикаль буенча гына була, горизонталь буенча хисап тоту булмагач, аппарат демократик та була алмый. Баш бюрократның төп кайгыртуы да әнә шунда.

Ю. Афанасьев үзенә максат куйган: "...ни өчен рус тарихының буеннан-буена безнең шул үткәннәрдән һаман да чыга алмавыбыз программага салынган?"—ди. Эш шунда ки, Россия җәмгыятендә аны үткәннәрдән чыгарырга сәләтле сыйныф күптән юк инде; хакимияттә утырган бюрократлар илне һәр хәлиткеч вакытта тупыйкка кертә дә, һәркемне туйдырып бетергән маразматизмы аркасында, ул яңа, яшьрәк клан белән алыштырыла, ләкин бу клан да шул ук иске клан казанында

кайнап үскән, жаны-тәне белән аңа береккән була. "Шул ук кәбестә шулпасы, тик бераз сыеграк кына". Ни өчен "сыеграк"? Чөнки искеләре аристократлашып өлгергән, алар тәҗрибәлерәк, "мәдәнирәкләр", алар, дөнья аристократлары белән аралашып, алардан яхшы манераларга өйрәнгәннәр, ә алмашка килгән яшьрәкләр әле "яшел", халык массаларын алдауның иң кирәкле сыйфатларын алар әле үзләштереп өлгермәгән, дәүләтне һәм халыкны талауның ялтыравык сүзләрен дә белмиләр. Бюрократиянең хакимияттә эзлекле рәвештә үз эшчәнлекләрен дәвам итүе, Мәскәү Русе заманыннан бирле бетмәс-төкәнмәс яулап алу сугышлары алып баруы хәзер дә һаман үрчеп торучы хәрби хезмәткәрләр һәм түрәләр өчен бик кирәкле шарт. "Алар бөтен Русь буенча киң таралган. Мәскәү хакимиятнең генезисын канга батырган—менә шул инде рус хакимияте",—дип яза Ю. Афанасьев.

Ю. Афанасьев: "Хакимият табышмак та, җавабы да үзендә,—дип күп мәгънәле нәтиҗә ясый. —Хакимияттә самодержавие сыйфатлары белән социалистик сыйфатлар, шәхси тормыш белән коммунитар тормыш, инициативалы иҗтиһат белән реакцион җимергеч көч тә бергә үрелгән. Ул ирек сөюче дә, аны кысучы да. Ул бөек тә һәм бик түбән дә". Әйе, хакимият кулында табышмак та, җавабы да. Мәскәү хакимияте Алтын Урданың теләктәшлеге аркасында ут һәм кылыч белән рус кенәзлекләрен яулап ала, бөтенроссия хакимияте булып әверелә. Ул руслар тормыш-көнкүрешен тәэмин итә. Үзен социаль нигезләр белән ныгытмый, ә көч һәм җәза кулланып, Урда хакимияте, ягъни тышкы көчләр ярдәмендә аякка баса. Мөгаен, рус хакимлегенең "тышкы" көчләр ярдәмендә килеп чыкканлыгын Рюриклар заманыннан ук башларга кирәктер. Нәтиҗәдә ул үзе дә халык өчен чит-ят, тышкы көч булып әверелә. Хакимият белән җәмгыятьнең мәңгелек капма-каршылыгы, аларның бер-берләреннән аерылуы шуннан киләдер. Хакимият асылда үз илендә үзе оккупант. Үз оккупантларының җәберләү-кысуларыннан тәмам туйган рус халкы самодержавно-тоталитар шартлардагы (ул патшаныкымы, "генсекныкымы") режимда яшәгәндә чит халыкларның оккупациясен бер дә кабул итә алмый, аларны куу һәм юк итүдә көрәштә бернинди чаралар куллануданда тартынып тормый, хәтта үз-үзен юк итүгә кадәр барып җитә.

Көнбатыш илләрендәге хакимиятләр халыкның, җәмгыятьнең ризалыгы белән килешеп оештырылган. Россиядә исә ул сыйныфларны, төрле төркемнәрне еш кына кол итеп барлыкка килгән, хәтта җәмгыятьне дә үзенә буйсындырган. Дәүләт хакимияте һәр нәрсәнең әтисе булган: тәртипнең дә, тәртипсезлекнең дә, революциянең дә, реакциянең дә. Рус хакимияте үзенең моносубъективлыгы белән аерылып тора, аның легитимлыгы, ягъни законлылыгы башка субъектлар белән килешүләр төзеп түгел, ә бәлки аларны көч белән бастырып эшләнгән. Ул формасы белән дә, табигате белән дә конституцион түгел, ә бары тик функциональ гына булган. "Рус хакимиятенең көнбатыш Европача сәяси дәүләт институтлары булмаганлыктан, аларны аерым катлам боярлар, дворяннар—үзенә күрә гадәттән тыш комиссияләр алыштырып торган, алар исә сыйныфлардан өстен генә түгел, тышкы сыйныфлар вазифасын да үтәгәннәр, еш кына алар хәтта күпмедер дәрәҗәдә җәмәгатьчелектән дә өстен булганнар, әйтик: опричнина яки Петр Беренченең гвардиясе яки "яңа типтагы" Ленин партиясе шикеллерәк.

Дәүләт азатлык хәрәкәтенә объектив рәвештә төп максат куйган: мине буйсындыр, мин бул (ягъни хакимият бул!) һәм син теләгән тәртипләр барысы да тормышка ашар. Ленин фикерен искә төшерик: "Һәр революциянең төп максаты—хакимиятне кулга төшерү". Димәк, шулай булгач, хакимият хакимият инде, ул аның башында торучы бюрократия кулында Россиядәге һәр түнтәрелеш хакимияткә бюрократларның яңа кланы килү белән башлана һәм тәмамлана, алар үзләре дә җәмгыятьтән аерылганнар. Мәсьәлә шунда ки, ни өчен бюрократиягә бу гамәлләр һәрвакыт унай килеп тора? Чөнки алар, милекчеләрнең көчле урта сыйныфына оешырга мөмкинлек бирмичә, халыкны мал-мөлкәтсез калдыру сәясәте алып барган. Кайчандыр язучы Андрей Платонов, большевикларның төп эшчәнлеге кычкыртып талау икәнлегенә басым ясап: "Алар халыкның җанын суырып алдылар"—дигән. Мал-мөлкәтсез халык—камыр, анардан самодержавиегә хезмәт итүче сүзсез-нисез мескеннәрне дә, теләсә кемне, хәтта үз-үзләрен дә җинел генә юк итәргә әзер

коммунофашистларны да әвәләп була. Менә сезгә җавабы табылган табышмак: теләсә кайсы халыкнымы, сыйныфнымы, аерым кешенеме ирексез калдыру һәрвакыт аның милкен тартып алудан башланган, аны кол иткәннәр. Аның ирекле булуы да тарихи рәвештә һәрвакыт милекле булуына барып тоташа. Башкача була да алмый. Азия, Африка һәм башка илләрнең халыкларын буйсындыру тарихы, хәзер исә элекке СССРның "союздаш" яки "автономияле" халыкларын "суверенлаштыру" тәҗрибәсе мона бик ачык мисал.

Үзлегеннән үсешкә ирешә алмаган кешеләрсез җәмгыятьнең киләчәге юк. Эчке каршылыкларсыз да тормыш юк, чөнки каршылыклар көрәш—үсеш чыганагы ул. Коммунистик җәмгыятьтә тиешле үсешне тәэмин итәрдәй эчке каршылыклар булмагач, партия аны уйлап чыгарырга, оештырырга (крестьяннардан "кулаклар"ны, "халык дошманнарын") мәҗбүр булган. Алар белән көрәш исә ясалма эшләнгән, ул табигый каршылыкларны алыштыра алмаган. Шуна күрә болай да көче бик чамалы, үле туган дәүләт бөтенләй хәлсезләнгән.

Россияне күптәннән инде (бигрәк тә Ленин үлгәч) хакимият башындагы бюрократиянең интеллектуаль зәгыйфьлеге ээрлекләп килә. Бүгенге көндә бу гаять куркыныч—инде менә ике дистә елга якын һаман "үзгәртеп корабыз", "реформалаштырабыз", ә иң өстә утыручы бюрократларның теләсә кайсысыннан: "Россияне кая өстерисең, әфәндем?"—дип сора, ышанам—җавап бирә алмаячак. Хәер, бөтен Россия дә җавап бирмәс. Моны әле Николай Васильевич Гоголь да яхшы белгән.

Идарә итүче элитаның күптәннән билгеле интеллектуаль зәгыйфьлеген ачып салырга кирәк. П. Чаадаев та Россия "интеллектуаль яктан төшеп калган" дигән бит. Менә шул сәбәпле, бу элита "сунын тирәнлеген белмичә, кереп китәргә" гадәтләнгән дә.

Илнең язмышы турында кайгыртучы күп кешеләрнең фикерләүләрендә әлеге кимчелекне бетерү өчен идарә итү эшенә әлегә бөтенләй диярлек җәлеп ителмәгән, алай гына да түгел—чит илләргә чыгып китәргә мәҗбүр булган зыялыларны тартырга кирәк дигән караш ята. Соңгы елларда бу мәсьәләне эзлекле рәвештә тирәннән каерып С. А. Магарил яктыртып килә. Аның төп фикерләре бергә тупланып "Милли үсеш һәм Россия зыялылары" дигән мәкаләсендә бирелгән *(2004)*. Ул: "Тарихи процесс барышында Россия интеллектуаль һәм әхлакый сыйфатлы милли элитаны кирәк кадәр үстерә алмады",—дип яза. Аның фикеренчә, илне заманча үзгәртеп кору ролен нәкъ шул милли элита үтәргә тиеш. Тиешле күләмдәге милли элита әлегә бездә булмаганлыктан, бурыч—аны үстерү: идарә итүче сыйныф аның эшчәнлегеннән файдаланырлык булсын. Әмма ул хәзерге еш алышынып торган, милли мәнфәгатьләрне кайгырта белмәгән хакимият тарафыннан андый эшчәнлеккә тартыла да алмый. Моның өчен җәмгыятьнең үзенең үзгәрүе кирәк.

Автор, үз-үзенә каршы килеп, болай яза: "Тотрыклы үсеш өчен халиткеч шарт, билгеле инде, милекне бүлгәләү юлы белән максатчан рәвештә массакүләм урта катламны булдырудыр". Сораштырулар шуны күрсәтә: безнең халыкның җитмешләп проценты үзләрен урта катлам кешеләре итеп саный. Ә бит юкса, аның өчтән бере ярлылыкның аргы ягында тора! Ә байлар кайда соң? Эш шунда ки, теләсә кайсы җәмгыять (дәүләт), ул хәтта бик артта калган булса да, бик ярлыларга һәм бик байларга бүленә—алар чагыштырмача алай күп түгел, калганнар шулар уртасында, боларның күпчелеге ярлылыктан ерак тормый. Бу катламны, автор әйткәнчә, милек бүлгәләп кенә коткарып булмый, чөнки ул "тартып ал һәм бүлгәлә" дигәнне китереп чыгарырга мөмкин, әмма ул әле милек сыйфатында кулланылачак дигән сүз дә түгел. "Тотрыклы үсеш" бары тик, үзен һәм якыннарын җигә-җигә булса да, үз мөлкәтеннән кергән керем хисабына яшәүче милекче урта сыйныфы булган гражданнар җәмгыятендә генә үсәчәк. Бу гаять эшчән сыйныф, зыялыларны гына буйсындырып калмыйча, үз араларыннан да аларны үстерә башлаячак. Кендеге белән шул сыйныфка береккән бу зыялылар, чынлыкта буржуазлаша барып, Ватанын да үз милке итеп караячаклар, аларда чын зыялылар психологиясе калмаячак та калмаячак. Хәзерге Россия бизнесменнары—тамырлары галимнәр, экономистлар, юристлар һ. б. булган зыялыларның бер өлеше үзен ничек тота? Базар аларга

кирәкмәгәнен, ә дәүләт аларга төкереп караганын тойган йөз меңнәрчә фән кандидатлары һәм докторлары үзләренә кулай шөгыльне чит илләрдә таптылар, анда исә аларга ихтыяж һәрвакыт бар. Ләкин алар—"гаепсез гаеплеләр", бер заман "кешелекнең пачпортсыз сукбайларына" әверелеп калырга да мөмкин ич. Безнең заманда шундый "йогышлы авыру" бар—ул ностальгия—жирсү дип атала. Бу "авыру" еракларга киткән эмигрантларның гына түгел, үз дәүләтендә кече ватаныннан—туган-үскән жиреннән аерылганнарның да җелекләренә үтә. "Кайда тусаң, шунда яшә" дигән гыйбарә бар. Кошлар булып кошлар да ел саен туган якларына меңәр чакрымнардан кайтып төшәләр!

Сүз дә юктыр, идарә итүче элитаның теоретик һәм сәяси җитлеккән булуына күп нәрсәләр бәйле. Интеллекты һәм белеме житәрлек булган затлар әледән-әле хөкүмәт даирәләрендәге эшчәнлеккә тартыла торалар. Ләкин алар анда күпмедер вакыт "ак карга" булып йөриләр дә, "ала каргалар" чукып бетермәсен дип, шулар төсенә керәләр, ә инде алай була алмаганы яки булырга теләмәгәннәре "ашата торган оядан" куке шикелле итеп кенә төртеп тә төшерелә. Монысы котылгысыз. Чөнки алар, беренчедән, һәртөрле "яхшырту" тәкъдимнәре белән түрәләрне бимазалап тора, ә түрәләргә болай да рәхәт!—икенчедән, кыяфәтләре, үзләрен тотышлары белән түрәләр арасында аерылып торалар, алар янында "аяк киемнәре кыса башлый", берәр ялгышрак сүз ычкындыруың да мөмкин, алар "чүпне өйдән чыгарырга да оста"—кыскасы, иш түгел булгач, иш түгелләр инде.

Зыялыларның актив катнашыннан башка алгарыш-модернизация булмаячак. Әмма үсеш субъекты оешкач, ул модернизация субъектына да әвереләчәк. Башка мөмкинлек юк. Гражданнар җәмгыяте булмаса, яңа вәзгыятькә кучәрдәй субъектлар да булмаячак. Шуңа күрә зыялыларны "...алар тегесен дә, монысын да эшләргә теләмиләр" дип битәрләү һавада гына эленеп кала. Нәкъ менә халык әйтемендәге шикелле: чибәр француз кызы булдыра алган кадәрен булдыра, әмма артыгын булдыра алмый! Аерым кешедән дә, сыйныфлар-төркемнәрдән дә, хәтта дәүләттән дә табигать биргәннән артыгын таләп итүдән мәгънә юк. Җәмгыятьнең үсешендә зыялыларның роле никадәр зур булса да, ул барыбер хәлиткеч түгел. Бурыч шуннан гыйбарәт ки, без зыялылар, ориентирларны үзгәртеп, гражданнар җәмгыяте нигезләрен салу өчен юл эзләрдәй социаль катлам табарга тиешбез. Зыялылар элек тә, хәзер дә андый булмаган, киләчәктә дә була алмас.

Югары мәдәниятле Көнбатыш тарихына мөрәҗәгать итсәк, кешелекнең күңелсез тарихын ача алганын күрербез. Кешелек бит әхлаклылыкны бар итүче—интеллектлы субъектлардан тора, алар күп газаплар чиккән бәхетсез кешелек өчен кирәк тә кирәк. Егерменче гасырның чама белән икенче яртысына кадәр Көнбатышта идарә итүче сыйныфларның үз мәнфәгате дөньяны үз кубызына биетеп килгән. Алар милли байлыкларны үз кулларына туплап, үзләре буйсындырган халыкларны мал-мөлкәтсез калдыргач, үз ихтыяжларын артыгы белән канәгатьләндереп килгәннәр, җәмгыятьнең күпчелегендәге иҗади-иҗтиһади башлангычны буып торганнар. Тарихны үзләре теләгәнчә язганнар һәм ул шундый булып оешкан да. Изеп торучы сыйныфларга каршы торырлык көч булмаган.

Милекнең кучеп йөрүе объектив процесс булганлыктан, ул кат-кат монопольләнә: колбиләүчелек чоры, феодаль чор, капиталистик (дәүләти капиталистик) чор. Соңгы чор кешелекне гомуми һәлакәт чигенә китереп житкерә—социаль һәлакәткә: ике бөтендөнья сугышы һәм экологик куркынычка. Көнбатыш дәүләтләрнең хаким сыйныфлары милекнең кучеп йөрүен 180 градуска борып жибәрә алган, үткән замандагы бөек буржуаз революцияләрнең тәжрибәсе буенча аны халыкка тараткан. Күпмиллионлы милекчеләргә үзләре әйбәт яшәү өчен, монополистлардан аермалы буларак, сугышсыз-нисез генә сыйныф—үсеш-алгарыш субъекты булган җәмгыять төзәргә мөмкинлек ачылган. Шулай итеп, алар, беренчедән, үзләрен һәлакәттән коткарып калганнар. Икенчедән, хәзер инде жир шарының калган өлешен үзгәртеп корырлык көч туплый алганнар. Иң әүвәл кешелек өчен бигрәк тә куркыныч илләр булган Югославия белән Гыйракта, чиратта Төньяк Корея тора, әгәр дә, һәртөрле Жириновский ишеләрдән ваз кичеп, үз тышкы сәясәтен тулысынча үзгәртмәсә, Россия дә шундый гамәлгә дучар ителергә мөмкин.

Көнбатышның кешелек тарихы табышмагын чишүе Россия язмышына карата да кулланылырга тиеш.

Әлегә шунысы кызганыч, илне үсеш-алгарышның унай эзенә төшерердәй көчләр, Афанасьев әйткәнчә, "акыллы көчләр һәм хәрәкәттәге механизмнар Россия мәйданында күренми". Чөнки, беренче чиратта, хакимият моны теләми, андый көчләрнең барлыкка килүенә һәртөрле киртәләр кора. Чөнки тоталитар сыйфатлы сәяси көчләрнең (коммунистлар, фашистлар, бюрократия) диктатурасы бары тик даими социаль киеренкелек шартларында гына мөмкин. Моның өчен кечкенә сугышлар, "яхшысы"—дөнья сугышлары ин кулае. Афанасьев, 1939 елны Гитлер белән килешү төзеп, Икенче бөтендөнья сугышына юл ачкан Сталин сүзләрен китерә, даһи юлбашчы болай дигән икән: "Соңгы егерме еллык тәҗрибә күрсәткәнчә, большевиклар партиясе хакимлекне кулына төшерә алу дәрәҗәсендәге көчкә ия булырлык коммунистик хәрәкәт тыныч чорда Европада була алмый. Бу партиянең диктатурасы бары тик зур сугыш нәтиҗәсендә генә мөмкин..." Шунысы игътибарга лаек, үзенең эчке каршылыклары белән үсүче җәмгыять тыныч чорда коммунизмны тудырмый. Димәк, коммунизм—тышкы каршылыклар җимеше. Ул, сыйнфый яки милли каршылыклар булып, начар идарә ителә торган, нормаль булмаган социаль-икътисади мөнәсәбәтләр нәтиҗәсе була. Коммунизм, "явызлык җимеше" буларак, шундый каршылыклардан туып, "җирдә оҗмах" төзү нияте белән дигән булып, ул явызлыкны геометрик прогрессиядә башкара. Гомер-гомердән мескен, ач-ялангач, рәнҗетелгән-кимсетелгән халык исә коммунистлар сүзенә ышана, Ельцин реформаларының тискәре нәтиҗәләрен күргәч, халыкның бер өлеше хәзер дә әле теге "тәти" вәгъдәләргә ышанып яши.

Биредә коммунизм белән фашизмның туганлыгы турында фикер йөртү урынлы булыр дип уйлыйм. Минемчә, беренчесе икенчесенең чишмә башы булган. СССР хөкүмәтенә Нобель бүләге лауреаты, галим Иван Петрович Павлов язган ("сезгә кадәр фашизм юк иде") мәгънәдә генә түгел, ә турыдан-туры мәгънәсендә... бер яктан, идея-теоретик, әһәмияте белән тоталитар тәгълимат буларак, икенче яктан, Советлар Россиясе мисалында фашизм идеяләрен тормышка ашыру, ягъни үрнәк буларак әйтелә. Аерым алганда, сүз "пролетариат" диктатурасы (чынлыкта исә коммунистик номенклатура һәм юлбашчылар диктатурасы), хезмәт армияләре, монополистик партия идеяләре, шул рухта пионер-комсомол-гитлерюгенд һ. б. тәрбияләү турында бара. Фашизмның (национал-социализмның), "өченче катлам", ягъни халык тарафыннан тудырылган буржуаз сыйныф өйрәнчегенең үзенчәлеге шунда гына—ул коммунизмның сыйнфый нәфрәт турындагы төп идеясен кабул итә алмаган, күрәсең, аның киләчәге юклыгын аңлагандыр. Шуңа күрә фашизм җиңел генә расачылык идеологиясенә шуып төшә. Монысы, бер яктан, дәүләти монополистик капитализмның империалистик характерда көчәюе белән билгеләнсә, икенче яктан, ак раса булган "арийчылар" өчен бу тарихи аклану шикеллерәк тә икән. Коммунофашизм белән национал-социалистик фашизмнарның нәфрәтләре арасындагы аерымлык коммунистларга җәмгыятьтә байларга һәм ярлыларга бүлену беткәнче социал-сәяси сәхнәдә уйнарга мөмкинлек бирә. Капитал хәзер югары цивилизацияле дәүләтләрдә һәркайда халыклаша барган саен ярлылар да кими бара. Алар арасында коммунистларның йогынтысы юкка чыга диярлек. Мондый хәл ярлылардан-ярлы безнең илдә дә күзәтелә, дөрес, сәбәбе башка, коммунистларның җинаятьләрен яхшы хәтерлибез әле, халыкларның коммунистик җирлектә ирекле берләшүләре, егерменче гасыр тәҗрибәсе күрсәткәнчә, тормышка ашмас гамәл булды, мифик "пролетар интернационализм" шигаре белән көчләп берләштерергә тырышу шулай ук яшәүгә сәләтсез икәнлеген күрсәтте. Якын киләчәктә национал-социализмның җитди сәяси көч булырлык мөмкинлеге юк. Моның сәбәбе—төрле тән төсендәге кешеләрне, Табигать (Аллаһы Тәгалә) һәм Тарих шулай яраткан ки, мәгълүм бер төрле тән төсендәгеләре (каралар)—коллар, ә икенче тән төсендәге кешеләр (аклар)—әфәнделәр, дигән тәгълиматны кабул итмәүләрендә. Милләтләрнең дә, кешеләрнең дә саны һич тә кимүгә бармый. Монысы—беренчедән. Икенчедән, халыкларның үзаны күрмәгәнчә үсә, хәтта әле кайчан гына "өлкән туганнар" дип йөртелгән милләтләр "үз кайгыртуларына" алган "кече туганнар" булган бик ярлы

халыклар да, бәйсезлек-суверенлык башлангычларын тоеп, кешелек дәрәҗәсенә сусаганлыкларын күрсәтәләр. Өченчедән, нәкъ шушы нигездә капма-каршы идеологияле, төрле динле, гореф-гадәтле төрле расадагы милләтләр дә берләшә хәзер (Евросоюз! НАТО!). Шуңа күрә гасырлар буе хөкем сөреп килгән славянофиллык, англосаксонлык h. б. сыйфатларга ия булучылар сәяси сәхнәдән төшеп калалар.

Генетик ук дип әйтмим, күрәсең, тарихи шулай килеп чыккандыр: славян халыкларының милли психологиясендә раса бердәмлеге хисе бик артык зурдан дип булмый. Бәлки, аларның иң көчле дәүләте Россиянең тышкы һәм эчке сәясәтендәге төп сыйфатлар нәтиҗәседер: Лев Николаевич Толстой әйтмешли, "өстенлек иткән наданлыкның көчләве"дер. Ничек кенә булмасын, безгә кул сузымы гына славян Украина, Польша, Болгария, арырак Чехия, Словения һәм башкалар, Россиягә кул селтәп, Евросоюз белән НАТО канаты астына сыендылар. Ә инде славян булмаган "кече туганнарның" күз кая караса, шул якка качулары турында сөйләп торасы да юк. Безгә бердәнбер сыланырга теләүчеләр—серблар. Туганрак җаннар бит: албаннарны һәм башка мөселманнарны кырган шагыйрь Караджич (Кара эч!) үз "батырлыклары" өчен безнең әдәби федераль берләшмәбез тарафыннан бүләк алды, сербларның төп җәллады коммунист Милошевичны халыкара суд тырнагыннан ничек тартып алырга белмибез. Халыклар хәзер "кешеләрне яхшырту өчен" дип үткәрелеп килгән коммунофашистик тәҗрибәләрдән туйды да туйды. Кешелеклелек чоры килә хәзер.

Күптәннән тоталитар булган Россия дәүләте, катгый рәвештә бары тик үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып, хосусый милек принцибын җәмәгатьчелекнең бик аз өлешенә генә булдыргач, XX йөз башына тулысынча диярлек милек-мөлкәтсез калдырылган ярымпролетарий крестьяннар (аның өчтән ике өлеше—ярлылар) һәм пролетарийлардан ялланып эшләүче халыкны бар итте. (Ягъни шәхес буларак кеше изеп ташланды).

Хәзер кешеләр массакүләм буйсынган хәлдә яши, алар башкача яши дә алмый. Алар—"корбан", чөнки алар "үсеш-алгарыш субъекты" түгел, алар эш булсын дип, капитал артсын дип эшләми, алар хезмәт хакын тартып-сузып кына житкерергә тырыша, хосусый милке булмаган ялланып эшләүче үз иркендә түгел, ул үзен яллаган кешенең колы гына. Коммунистик идеалның Россия аңына тәңгәл булуы да шуннан килә. Җавап бирә алмаган кешегә җаваплылык та өстәргә ярамый. Колга, кол булуын өчен үзең гаепле, үз язмышына үзең җаваплы, шулай булгач "корбан" да түгелсең, дип тукып тору аны мәсхәрәләү генә.

Узган гасырның туксанынчы еллары башында мин үзәк газеталарның берсендә "Безответственная демократия" дигән мәкалә белән чыккан идем, шунда демократларыбызның хакимияткә килгәч ни өчен әшәкеләнгәннәренең сәбәбен дә ачып бирдем. Чөнки алардан җаваплылык таләп итүче, намуслы эш таләп итүчеләр юк. Чын-чынлап таләп итүне исә оешкан халык кына булдыра ала, ә халыкны оештыру өчен акча кирәк. Большевикларга Морозов-Шмит кебек байлар ярдәм иткән, әмма ул гына житмәгәч, Сталин-Камо тибындагы кычкыртып талаучыларга ялынырга мәжбүр булганнар. Көнбатыштагы буржуазия талау юлына басмаган, аның үз байлыгы да житәрлек булган. Безнең "демократия" исә социаль жирлексез пролетариат, —ә без туксан процент пролетарийлар,—нигездә коммунофашизм жирлегендә яши. Икътисади бәйсез була алмау кешене кемгә булса да буйсынырга мәжбүр итә. Ул кан кардәшләренә, үз сыйныфына, милләтенә, Ватанына дошман булырга да мөмкин.

Большевистик режимның иң куркыныч мирасы—"совок", ул шул түзеп булмаслык режимга буйсынып яши, аның ихтыяр көче юк, ул кемнәндер, нәрсәдер көтеп, үз язмышын кемдер оештырып бирүгә өмет итеп яши. "Көчле, бөек дәүләт" халыкка бер яхшылык та эшләми, ул халыкка каршы гына эшли ала. Гомумән, дәүләт кемгәдер нәрсәдер бирү өчен төзелмәгән, ул, мәсәлән, салымнар җыя, аны тышкы һәм эчке тәртипләрне җайга салу өчен дип башкара. Әгәр дә инде ярлыларга ярдәм итә икән, аны шул ук халыктан тартып алып эшли. Кызганыч, халык моны аңламый. Алай гына да түгел, Россия халкы гипердәүләтчел, шуңа күрә аның аңына

"шөрепләрне борырга", "дәүләтне нығытырга" дигән фикерләр җинел үтеп керә, аны бюрократлар бик оста файдалана. Патша диктатурасы күпчелек халыкның теләктәшлеге белән большевистик диктатурага әверелгән. Бу бәладән чыгу юлы әлегә күренми дә. Хосусый мал-мөлкәте булмаганнар белән ярлылар арасындагы каршылык пычак өстендә йөрүгә тиң, ул көчләп тартып алуга әверелергә дә мөмкин. Ярлы халык аңында әкренләп күнелсез ризасызлык туа, ул эчкечелеккә, тупаслыкка, җинаятьләргә илтә, ярлы халык үзенең шулай начар яшәвен байлардан күрә.

1917 елгы вакыйгалар һич тә "социалистик революция" түгел. Ул вакытта җәмгыятьнең өчтән бере генә милек хуҗалары булган, әмма шул да ярлы халыкның ярдәме белән самодержавно-бюрократик дәүләткә каршы күтәрелергә һәм җиңеп чыгарга ярдәм иткән. Крестьяннарның алпавытларга каршы көрәше дулкынында хакимияткә даһи оештыручы, сәясәтче һәм теоретик Ленин җитәкләгән партия килгән. Социаль революциянең җирлеге-нигезе милекчеләрнең урта сыйныфы булган. Әйе-әйе, һич тә күпләр уйлаганча, зыялылар түгел, аларны өлешләп сатып алырга да мөмкин, алар кем күбрәк түли, шуңа сатыла да. Күбесенчә яланып эшләүчеләр җәмгыятенә әверелү дә ерак түгел. Ләкин дәүләт белән яхшы итеп бары тик милекчеләр сыйныфы гына идарә итә ала, әгәр дә ул бюрократияне үзенә хезмәт иттерсә, дип тә өстик. Бюрократия җәмгыятькә хезмәтче буларак кирәк, һич тә Россиядәге шикелле киресенчә түгел. Милекче хуҗа һәрвакыт булган һәм булачак, аның уңышлы эшләве-яшәве үзеннән тора, ул идарә итә белергә тиеш, ул үз милкенә тумыштан алып үлеменә кадәр кендеге белән бәйләнгән, чөнки милек аның яшәү чыганагы. Ялланып эшләүче ялчы исә бары тик кеше байлыгыннан, шул исәптән дәүләт байлыгыннан гына файдалана, шуны бүген үк алып калырга тырыша. Ялланып эшләүче, идарәчеме, гади хезмәтчеме—ул вакытлы гына кеше. Россиянең дәүләтчелеге шуңа һәрвакыт зыян күрә. Россиядәге реформалар һәм үзгәртеп коруларның берсе дә барып чыкмавы очраклы түгел.

1991 елгы демократик төзелеш чорындагы төп ялгышны һич аңлатып булмый, ул мәгарифкә һәм фәнгә, социаль өлкәләргә игътибарсызлыктан килә. Ул халыкта демократик идарә итүгә ышанычны какшатты, "яңа хәерчеләр"—галимнәр, укытучылар, табиблар, пенсионерларны тудырды, ул социаль демагогиягә, буш сүзгә уңдырышлы җирлек булды. Алай гына да түгел, ә хаклы рәвештә ачуны китерә башлады. "Мәгариф һәм фән—цивилизациянең нигезе",—дип яза А. Яковлев. Гасыр буена безгә тукып килделәр: "барысы да колхозныкы (советныкы), барысы да минеке". Законлы гомумхалык милкен башта ук бөтен халыкның хосусый милке итеп эшләргә кирәк иде, шунда гына хосусый милекчеләрнең гражданнар җәмгыятен төзүгә нигез салынган булыр иде. Ул инде күпчелекнең ярлылануына һәм азчылыкның баюына юл куймас, үз дәрәҗәсен белгән, үзенә үзе хуҗа гражданны тәрбияләр иде. Атаклы испан философы Ортега-и-Гассет: "Үткән белән көрәшеп булмый, аны йотарга гына кирәк, юкса бернинди революция дә уңышка ирешә алмаячак",—дигән. 1985 елгы март-апрель революцияләре, туксанынчы елларда дәвам итеп, халыклар аңына телдә генә булса да кертелгән фикерне сызып ташлады: ул илдәге бар нәрсә халыкныкы дигән фикер иде. "Реформаторлар" Октябрь контрреволюциясендә большевиклар кыланганны кабатладылар гына, гасырлар буе халык тормышында үткәндә булган төшенчәләрне сызып ташладылар. Нәтиҗәдә хакимияткә яңа вакытлылар килде...

Безнең бюрократларга вакытлылар сыйфаты тумыштан ук килә, моны аңламау нефтедолларлар булганда элитаның эленке-салынкы гына эшләве сатып та алына дигән уйга китерә. Аларны тәнкыйтьлә, карга, сүк, яхшы эшләргә кирәк дип өндә—файдасыз. Алар башкача эшли белмиләр. Алар бары тик үзләрен "халык дошманы" дип атаудан куркып кына эшлиләр. Ә нефтедолларлар кимү халыкның "шөрепләрен кысуга", "билбауларын да кысуга" китерәчәк. Бюрократларның эленке-салынкы гына эшләве мөмкин булган вариантларның иң яхшысы санала. Брежнев заманындагы торгынлык чорын А. Зиновьев ил тарихындагы иң яхшы вакыт дип саный.

Ю. Афанасьевча, бюрократик хакимият белән җәмгыять хезмәттәшлек итәргә теләгәндә халыкның мул-имин тормышы хәл ителәчәк, имеш. Теориядә бу мөмкин

эш. Президент В. Путин, дәүләт хакимиятен "вертикальләштерүдә" тәҗрибәләр үткәреп, аның округлардагы тулы хокуклы вәкилләрен булдыру һәм иҗтимагый-сәяси сәхнәдән хакимияткә ошамаган "партияләрне" кысрыклап чыгару һәм "бердәм Россия" түрәләре партиясен үзәкләштерү юлы белән тормышка ашырырга тырыша. Шул ук вакытта ул, бер яктан, урындагы җирле хакимиятләрне көчсезләндереп үзәк хакимиятне ныгыту юлын эзләсә, икенче яктан, халыкка төрле ташламалар ясый. Хакимиятне "вертикальләштерү" бюрократияне канцлер Карл Нессельроде фикерләренә кушылырга мәҗбүр итә. Ул исә: "Без патшаны гына беләбез, Россиядә безнең эшебез юк",—дигән. Килешеп-ризалашып яшәү дәүләт белән җәмгыятьнең горизонталь мөнәсәбәтләре булса гына була ала. Моның өчен яна хакимият, яңа җәмгыять булу сорала.

Чынлап та, демократик хокукый дәүләтләрдә XX гасырның икенче яртысыннан башлап шундый вәзгыять урнашкан, анда барлык мәсьәләләр компромисс, ягъни үзара килешү юлы белән хәл ителә. Компромисс һәм килешү ул дәүләтләрдәге халыкның өчтән ике өлеше чамасы хосусый милекчеләр булып әверелгәч кенә барлыкка килгән.

Россия үзе өчен дә, бөтен кешелек өчен дә куркыныч дәүләт. Моның төп сәбәбе—"төзәлмәс яра булган пролетариатлыкта", ул җәмгыятьне социаль тотрыксызлыклар белән эчтән кимерә, аның "яман шеш" авыруына дучар итеп яна революция һәм контрреволюцияләргә дә китерүе мөмкин. Монысы бик авыр проблемаларның берсе, аны чишә алмасак, кем әйтмешли, "безгә бәхет елмаймаячак".

Россиядә җәмгыять тә, дәүләт тә нормаль түгел, табигый тарихи түгел, ә ясалма тарихи гына. Рус рухының психологиясе дәүләт тарафыннан тәрбияләнгән түрәләр тарафыннан башка халыкларга каршы максатчан алып барыла ("басурманнар", "сортирда "мочить" итү, ягъни үтерү", "ваххабист" кебек төшенчәләр, сөннәткә утыртудан көлү һ. б.), болар барысы да рус халкын үзеннән ваз кичәргә мәҗбүр итә. Ә бит рус халкы үзенә-үзе генә дошман.

Сорау туа: рус рухындагы бу сыйфатлар кайдан туа, аның чыганагы кайда? Заманыбызның күренекле язучысы Борис Васильев төп сәбәпне русларның "чик буе халкы" булуында күрә. Россия тарихта шундый урын сайлаган—ул утрак тормышлы халыклар белән күчмә халыклар арасында, Европа белән төркиләр арасында калган. Ә "чик сакчысы"—ул профессия, ул һөнәр, аның психологиясе дә шундый, ул һәрвакыт үзенә дошман эзли. Тапмаса, үзе уйлап чыгара. Бу психология бүген үлем куркынычына тиң. Барлык уңышларына карамастан, русларның фикере-аңы артта калган, бөек фәне, бөек әдәбияты бар, ә уртача уйлау сәләте көнбатыш илләреннән нык артта. Европа берләшә бара, Россия аерылуга юл тота. Б. Васильев менә шулар турында ачынып сөйли. Философ Франк рус кешесен "шәрә кеше" дип атый, "аның шәхси хокуклары үз тәненә ия булу хокукыннан ары китми" ди. Рус кешесенең тормышын җайга салырдай милке юк. Милек исә үз-үзенне танып белергә, башкалар белән аралашырга, хакимияткә һәм Ватанга таянырга ярдәм итә, даими үсештә тота. Димәк, милек кешенең сәләтләрен ача, тормышында мөстәкыйль хуҗа булып яшәргә булыша. Үз Ватанында дәүләткә яки башкаларга кул сузып, хәер сорашып йөрү—оят, бик оят.

Руслар "гаепләләрне" читтән эзлиләр, барысы да "гаепле", тик алар үзләре түгел.Чынлап та, аларның шундый хәлгә төшүенә үзләре гаепле түгел. Кем гаепле—алары билгесез, аларны түрәләр шулай тәрбияли. Язучы В. Гроссман: "рус рухы ирексезлек белән сугарылган, ул мен еллык тарихы булган кол".

Руслар аңында тормыш шартларының мәңгелек кимчелекләре аркасында тормыштан рәхәтлек алу дәрәҗәсе бик түбән булып калган. Революциягә кадәрле рус крестьянында хезмәткә гомумән һәм аерым алганда байлыкка мөнәсәбәт гаҗәеп каршылыклы булган. Алар арасында рус крестьяны турыдан-туры бәйләнеш-бәгланыш барын да күрми. Ул байлыкның хакимлек, көч һәм матди иркенлек бирүен дә аңлый, әмма аны әхлаксызлык дип саный, чөнки байлык һәрвакыт намуссызлык аша, гаделсезлек аша килә, башкаларга рәнҗеш китерә дип уйлый. "Азга да канәгать бул, Ходай Тәгалә сине онытмас",—дип яши ул. Бәйрәмнәрдә эшләү—зур гонаһ, бәйрәмнәрдә дә эшләп йөрүчене авылдашлары каты җәзага да

тартканнар. Билгеле инде, бәйрәмнәр русларда күп булган, ул артык күп эчү белән дә башкарылган. Русларның эчкечелеккә бирелүе—тормыш рәвешенең бер дә яхшы сыйфаты түгел, әмма ул "шәрә" кешенең чарасызлыгыннан, гажизлегеннән килеп чыккан. Эчәргә яратса да, рус крестьяны иген игү чорында авызына бер тамчы да аракы алмаган, ә хәзерге колхозчылар елның дүрт фасылында көн дә эчә, төн дә эчә.

Рус крестьяны жиргә хосусый милек итеп карый белмәгән, ә бит жир—житештерү чарасы. Онытмыйк, россияннарның күпчелеге—кичәге крестьяннар ич. Статистлар раславынча, аларның ун проценты гына эшчән-тырыш трудоголиклар, янә ун проценты беркайчан да эшләргә теләмәгән. Теләсә кайсы алдынгы илдә сиксән процент халык үзенең ни өчен эшләгәнен аңлап эшли. Рус кешесе ялкау Емеля ул, ул гомере буе мич башыннан төшмәгән, аннары аның кулына могжиза белән чуртан килеп керә, кочагында бер чибәр пәйда була. Туйга да Емеля мичендә утырып кына бара. Бу әкият бик матур да, әмма, ни кызганыч, Емеля кебек яшәү җәмгыять үсешенең бүгенге таләпләренә туры килми шул. Ялкауларча гомер сөрү элекке Россия таләпләренә дә жавап бирмәгән, шуңа да ул башка алдынгы илләрдән бер гасырга, хәтта аннан да күпкә артта калган инде...

Русларның милли сыйфатларындагы әлеге кимчелекләр халык тормышының базар мөнәсәбәтләренә корылмаган булуыннан килеп чыккан. Үзенне дини идеяләр белән тыеп тору, намуслылыкның әхлакый нигезләре Россиядә булмаган да.

Минемчә, рус милләтен шундый итеп дәүләт үзе тәрбияләгән. Беренчедән, ул "бер диңгездән икенче диңгезгә кадәр" чит жирләрне сугышып ала барган, аны тиешенчә үзләштереп тә тормаган, икенчедән, әлеге яулап алынган жирләрдә үз кешеләренә күпчелек очракта милекче булу мөмкинлеген дә бирмәгән. Хосусый милек ул кемнеке булса да булырга тиеш, алай түгел икән, ул беркемнеке дә түгел. Рус кешесенең хосусый милекче булмавы анарда, гомумән, милеккә каршы психология тудырган, анысы үз чиратында халык массаларында милекчеләрнең урта сыйныфын булдыруны буып килгән. Ә бит шунсыз дәүләткә кирәк кадәр күләмдә һәм яхшы эшмәкәрләр дә туа алмаган. Шуның аркасында вәзгыять дәүләтнең үзен эре милекчелеккә этәргән, анысы да базар мөнәсәбәтләренә корылмаган, ул аны житештерү көчләре кирәк булганга һәм хәрби промышленность комплексы булсын өчен генә булдырган. XX йөзнең соңгы елларына таба Россия, гадәти буржуаз ил булырга да өлгермичә, вак һәм урта бизнес эшмәкәрләренең капиталын тупламыйча, турыдан-туры синдикатлар, картельләр, банклар аша дәүләт белән үрелеп үскән монополистик капитализмга сикергән. Дәүләтнең империалистик асылы көчәйгән. Россия, олигархия белән үрелеп үскән дәүләт капитализмын яңартырга тырышып, шуны хәзер дә кабатларга омтыла.Башка кимчелекләр дә юк түгел. Милекчелеккә каршы килү, бетмәс-төкәнмәс казна һәм кешеләр милкен урлашу, кеше кайгысына битарафлык, эчеп дулап йөрү, кеше тормышын бер тиенгә дә санамау—болар барысы да Ф. Достоевский әйткән "рус кешесе бик киң, аны бераз тарайту да гөнаһ булмас иде" дигән сүзләренә мисал була ала.Иван Бунинга бер мужик әйткән бит: "Мин әйбәт, ягымлы, әмма миңа ирек куймагыз. Ул чагында мин беренче разбойник, беренче талаучы, беренче карак, беренче исерекбаш булачакмын",—дигән. Бунин руслардагы мондый психологияне "тарихыбызның беренче бите" дип атаган. Россия немецы Альфред Кох Америка радиосына үзенең "Совет империясен сату" дигән китабы чыгу уңаеннан болай сөйләгән: "Күп газаплар чигүче рус халкы үз гаебе белән газап чигә. Аны беркем дә басып алмаган, беркем буйсындырмаган, беркем төрмәләргә куып кертмәгән. Алар үзләрен-үзләре чаккан, үзләрен-үзләре төрмәгә утырткан, үзләрен-үзләре атып үтергән. Шуңа күрә бу халык үзе чәчкәнне үзе ура." Бу сүзләр барысы да дөрес. Ачы хакыйкать.

"Россиянең мәңге төзәлмәс ярасы булып хәерчелек һәм хокуксызлык, хокуксызлык һәм хәерчелек кала. Хәерчелек изге һәм беркем кагылырга тиеш түгел хосусый милек булмаудан килә, хокуксызлык—дәүләтнең җәмгыять тормышында чиктән тыш зур әһәмият тотуында",—дип яза А. Яковлев.

Россия дөньяда зур урында торучы дәүләт булган һәм шулай булып кала бирә. Әмма ике бөтендөнья сугышлары аның язмышын үзгәрткән: беренче бөтендөнья

сугышы аны табигый-тарихи үсештән туктаткан,башка дәүләтләр арасыннан тартып алган, икенчесе үзенең нәтиҗәләре белән империяне таркаткан, "тисә—тиенгә, тимәсә—ботакка" дип яшәүгә китергән.

Нәрсәгә өмет итәргә соң? Рус халкының анына ниндидер могҗиза булыр дигән әкияти ышану ныклап кереп урнашкан.

Бәлки, чынлап та, нәкъ русча могҗиза булыр: президент Путин, мәсәлән, үз хакимиятенә кискен һәм эзлекле рәвештә каршы чыгар. Ул хакимияттән котылыр һәм Россия демократиягә, базар мөнәсәбәтләренә, хокукый дәүләт булуга юл тотар.

Үз заманында Гегель шундый сүзләр әйткән: "Ашкынып сәяси упкынга якынаеп килә торган халыкның язмышын берәр даһи гына тыеп-туктатып кала ала".

Дөнья андый тәҗрибәне дә белә. Узган гасырның утызынчы еллары башында Америка президенты Ф. Д. Рузвельт гаять авыр икътисади кризис кичергән АКШны үсеш-алгарышның якты юлына алып чыга, бу ил хәзер дә шул юлдан бара. Моңа ничек ирешелгән? Милекче урта сыйныфның күпмиллионлы санын тизләтелгән ысул белән булдырганнар. Шул ук узган йөзнең алтмышынчы еллары башында колониаль системаның таркалуы аркасында Франция искиткеч авыр сәяси кризис кичерә, хакимияткә ультрамилли реакцион көчләр килү куркынычы туа. Президент Шарль де Голль француз җәмәгатьчелегенең урта катламы белән уртак тел таба, экстремист көчләргә Алжирның милли азатлык фронты кабул итәрлек килешү юлын күрсәтә һәм илне упкыннан тартып ала.

Әһәмияте белән аларныкыннан да ким булмаган эшне бөек Ленин башкара: ул даһи, яңа икътисади сәясәт белән кооператив төзелешне берләштереп, илне һәлакәткә өстерәүче "социалистик" юлдан әлегәчә күрелмәгән "халык капитализмы" юлына алып чыга. Илдә "икътисади могҗиза" була: 1921-1927 елларда промышленностьның еллык үсеше 44 % тәшкил итә, эшләүчеләрнең доходлары өч мәртәбә, гомер озынлыгы биш елга арта, туучылар саны 16 % ка күтәрелә, җинаятьчелек ике мәртәбә кими. Урта сыйныфны тизләтелгән ысул белән булдыру илне упкынга төшүдән, халыкны һәлакәттән коткарып кала.

Ул чордагы Россияне мин бүреләр өере куркыткан атларның упкынга таба чабуы белән тиңләр идем. Атларны бары тик бер юл белән генә һәлакәттән алып калып була: көтүче үз атында чабып барып атлар алдындагы айгырны үз артыннан ияртергә, шул рәвешле упкыннан читкә алып китәргә тиеш. Ленин да нәкъ шуны эшли. Россия "көтүенең" упкынга таба чабуы—революция һәм гражданнар сугышы нәтиҗәсе, аларны оештыруга Ленин да турыдан-туры катнашканлыктан, аңа революция хәрәкәтен икенче юнәлешкә алып китү кулай була. Аннары, партия өчен гаять авыр бу психологик халәттән чыгуга бары тик Ленинның даһилыгына халык ышану да булышкан.

Даһи кирәк! Ул озак яшәргә, үзе башлаган эшне үзе төгәлләргә тиеш. Ниндидер юньле нәрсәгә ирешү өчен "Россиядә озак яшәргә кирәк" дигән үткен телле Корней Чуковский.

Ләкин даһилык даһилык белән. Табигать андыйларны сирәк тудыра. Могҗизалар да бик сирәк була. Бәлки, дәүләт үз халкын куып керткән тупыйктан чыгу юлын башкача эзләү кирәктер... Үзгәртеп коруларга—реформаларга без үзебез комачауламыйбыз. Үзебезне яхшыртырга кирәк. Тупыйктан чыгу юлын үзебез эзләп, бөтенхалыкның урта сыйныфын үзебез булдырырга тиешбез. Безнең яшәү рәвешебез бик алама-начар бит. Үзебез бертуктаусыз эчәбез, энкечеләрне яратмыйбыз. Мең ел буенча урлашабыз, ә каракларны хөрмәт итмибез. Туктаусыз ялганлыйбыз, ә алдакчыларны кешегә дә санамыйбыз. Байларны күрәлмибез, ә үзебез эшләргә теләмибез, кеше хисабына яшәргә яратабыз. Үзгәрешләр турында хыялланабыз, әмма реформаторларны кире кагабыз. Безнең хыялыбыз: бернәрсәне дә үзгәртмичә, барысын да үзгәртү".—А. Яковлев шулай яза. Үзебезне үзебез җинеп, "ятып калганчы, атып калырга кирәк". Ике бака турындагы бәянны хәтерлисездер. Алар каймак салган чүлмәккә төшкәннәр, имеш. Берсе кыл да кыймылдатмыйча, тончыгып үлгән, икенчесе, ничек тә чүлмәктән чыгарга теләп, сикеренә дә сикеренә икән. Шулай сикеренә торгач, каймакны майга әйләндергән бу. Шул май кисәгенә басып, чүлмәктән сикереп тә чыккан.

Истә тотыйк: ирекле кеше иң әүвәл—матди яктан тәэмин ителгән, бәйсез кеше! Ин башлангыч психологиябез—коллар психологиясе. Кем белә, бәлки шуннан котыла алырбыз әле.

Дәүләт бюрократиясе моны безгә эшләп бирмәс, ул кадәр юләр түгел ич, үзе утырган ботакны үзе нигә киссен, ди. Хәер, бу гамәл белән ул шөгыльләнә—дәүләт белән наданнарча идарә итә, диюем. Менә Россиянең бөтен тарихы шаһит—крепостнойлыкны бетереп, бөтендөнья цивилизациясе процессына катнашырга мәҗбүр булган бит. Моның нәтиҗәсе социаль-икътисади яктан, феодалларның хосусый милеккә монополиясен бетереп, милекне крестьяннарга тарату, шул рәвешле аларның күпчелеген милекчеләрнең урта сыйныф итү булган. Ләкин патша бюрократиясе крестьяннар реформасын шундый итеп үткәргән ки, күпмиллионлы милекчеләр сыйныфы тудыру урынына Россия егерменче гасыр башындагы революцияләргә тулысынча хәерчелеккә төшкән халык белән килеп кергән. Халне соңга калып кына башланган Столыпин реформасы да, аның антифеодал мәгънәдә эзлекле булмавы да төзәтә алмаган. Крестьяннарны хәерче хәленә төшереп, бөтенләй юкка чыгару сәясәте һәм шуны тормышка ашыру Сталин тарафыннан "коллективлаштыру" дип яманаты чыккан крепостнойлыкка янадан барып керү булган. Крестьяннар сыйныфы гына түгел, нэпманнар һәм кооператорларның күпмиллионлы урта сыйныфы да юк ителгән. 1998 елда дефолтка кереп батканнан соң, ана кадәр оеша башлаган урта сыйныф тамырыннан корытылган. Әгәр режим алышынмаса, мондый хәлләр һаман кабатланып торачак. Ә ул хакимиятнең "бирәнлектән шартлавы" белән генә алышыначак.

"Россиянең киләчәге бик авыр булыр дип күзаллыйм,—ди Нобель премиясе лауреаты язучы Александр Солженицын.—Ул бер дә тантаналы булмас. Житмеш ел тоталитар изүдән соң Россия милли байлыкны һәм халыкны талауның җимергеч давылына килеп эләкте. Халкыбыз аякка басып өлгерә алмый калды. Ул үзенең инициативасын, үзенең көчен үз язмышын хәл итү мөмкинлегенә дә өлгерә алмый калды". *(А. Солженицын. Без тарих кулында уенчык түгел. Интервью. Аиф, № 20 (1224). 2004., май).* Шуна күрә әхлагы сау-таза, эчкечелеккә бирелмәгән кешеләр инициативаны үз кулларына алырга, законга каршы килмичә генә төрле юллар белән баерга тырышырга тиеш. Иң әүвәл, булганын әрәм-шәрәм итмичә, кечкенә булса да, үз эшеңне башлап җибәрү хаҗәт: вак бизнеска тормышта, туклану, вак сәүдәгәрлек, һөнәр, кустарьлык өлкәләрендә очы-кырые күренмәгән мөмкинлекләр бар бит. Кем үз эшен яки гаилә эшен башлап җибәрә алмый, андыйлар, үз тиеннәрен гомуми бизнеска салып, кооперацияләр оештыра ала.

Шул уңай белән үзебезнең миллиардер байларыбызга да киңәш бирәсе килә. Сезнең бүгенге яшәү рәвешегез, эшчәнлегегезнең матур киләчәге юк. Әгәр дә бар капиталыгызны чит илләргә тулысынча чыгара алсагыз да, кайда гына булсагыз да, дәүләт сезне эзләп табачак, бюрократия белән бүлешергә мәҗбүр итәчәк, дәүләт, үзегезгә булмаса, балаларыгызга зыян салачак. Рус дәүләтенең бу өлкәдә 3-У-У-Р тәҗрибәсе бар, ул әле Петр I дән, ә бәлки, аннан да алданрак башланып, канлы эшләренең осталары большевиклар тарафыннан ныгытылган-үстерелгән, хәзерге яңа хакимият түрәләре дә читтә калмас. Мин сезнең байлыгыгызны бюрократлар белән бүлешүегезне теләмим. Юк, эре бизнес үзенә теләктәшләрне вак һәм урта бизнес вәкилләре арасыннан табарга тиештер. Халык сүзенә колак салыгыз, аны авыл укытучысы Тамара Бибикова бик әйбәт әйтеп биргән: "Безне бизнесменнар таламый—түрәләр талый. Бюрократия үзен тарихны алга этәрүче көч дип уйлаган. Янәсе, ул үзе дәүләт. Һич тә алай түгел. Дәүләт нәрсә турында булсада кайгырта алмаса, ул хакта бизнес уйлансын. Шуңа альтернатива тапсын. Бу дәүләт белән конфронтация булмас, ә ана сигнал, бер билге, мисал булыр". *(З. Ерошок. Тимрюк и Ходорковский. Новая газета, 26.04-287. 04.2004 г.)*

Кешелек бөтен җир шарында чорлар алышынган заманда яши. Дөньяда глобализация процессы бара. Россиягә бу очракта халыкның тормышын җайга салу кыен булган төбәкләрдәге табигый байлыкларны иң алга киткән дәүләтләр белән бергәләп үзләштерергә кирәктер, мөгаен. Төньякта, Себердә, Ерак Көнчыгышта якын елларда ныклап торып бу эшне башкарырга көчебез дә, кешеләребез дә

житмәячәк. Шул ук вакытта ул табигый байлыклар кешелеккә кирәк. Башка илләр ул жирләрне үзләштерү өчен үз өлеш чыгымнарын да кертсәләр, дөрес булыр иде. Төньяк районнарны кешесез калдыру тәжрибәбез шуны сөйли, анда халыкны даими яшәтергә тырышуның мәгънәсе юк, мөгаен, андагы эшчәнлекне вахта методы белән алып бару кулайрактыр. Бу исә үзебезнең генә көчебездән килмәс. Башка илләр белән бергә глобализация процессына кушылуның башы шул булыр.

Соңгы сүзем зыялыларыбыз, аларның бурычлары турында. Язучы В. Ерофеев, Россиядә рәхәт тормыш булмауны сурәтләп, шундый сорау куя: "Шулай да нәрсәдә соң русларның цивилизациягә сәләтле булмауларының сәбәбе?"—ди. Һәм үзе үк, бик дөрес җавап та бирә: "Мөгаен, урта сыйныфка ялгыш мөнәсәбәттә булуыбыздадыр",—ди. Мондый мөнәсәбәтнең башында, әлбәттә, дәүләт үзе, аның өстен сыйныфы бюрократия тора. Ләкин аны тормышлары һәм рухлары белән аристократлар: язучылар, сәнгать кешеләре, зыялылар ныгыткан. Чөнки җәмгыятьнең рухи тормышы эшчәнлегендә алар өстенлек иткән. Урта сыйныфка мыскыллап "мещанлык" дип караганнар. Рус әдәбияты һәм сәнгате мещанлыкны даими җәберләп килгән, аның яшәү нигезенең әхлакый мөмкинлегенә юл куймаган. Рус мәдәниятендә һәрвакыт мещан гаепле булган. Россиядә мәдәният белән цивилизация арасындагы тәңгәллек бозылган. Җәмәгатьчелекнең фикере шундый: бер үк вакытта колбасаны да, Андрей Рублевны да яратып булмый, янәсе. Яки-яки. Рус зыялылары беркайчан да халыкка колбаса бирү өчен көрәшмәгән, ул аны азат итү өчен көрәшкән. Зыялылар азатлык биреп халыкны коткарудан башкасына риза түгел, нәтиҗәдә Россиядә азатлык та, колбаса да булмаган.

Әгәр дә без заман таләбенә җавап бирергә теләсәк, милекчеләрнең урта сыйныфын булдыруны тизләтергә тиешбез. Зыялылар бу изге эшкә рухи да, фәнни дә, сәнгать һәм әдәбият белән дә булышырга бурычлы.

Безнең илдә үтерү бервакытта да оят эш булмаган, ә сату итү, сәүдә эше оят саналган. Без мещанлыкка каршы пропагандага чик куярга тиешбез, бу бигрәк тә театрларга карый. Киресенчә, милекчелек хисенең көчен күрсәтергә кирәк. Һәр кеше аларны хөрмәт итсә, начар булмас иде. Чөнки милекчеләр—дәүләтнең арка сөяге. Чит илләрдән килеп сатучыларга да ачык йөз күрсәтегез. Бүген грузиннар, әрмәннәр, әзәрбайҗаннар йөзәр меңәрләп Россия гражданлыгы ала. Бездә баю җиңелрәк, чөнки россияннар үзләре байлыкка артык кызыкмый, аның тир түгеп эшлисе дә килми. Ә Россия эшчән, тырыш кешеләр өчен алтынга тиң ил ул.

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)



# Равил Фәйзуллин

## ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

***

Шагыйрьләр алар картаймый.
Шагыйрьләр—ара гына.
Вакыт иңсәсенә басып
ял итеп ала гына...

Туксанда да ялганның ул
суга ала яңагына.
Шагыйрьләр пыскый алмыйлар.
Шагыйрьләр—яна гына!

### Яшәү

Озын гомер телисең син, әй, юләр!
Бер көнемдә күпме газап-тетрәү!
Өлгералмый иртә таңнан төнгәчә
Ышанычка куеп йөрим мин терәү...

Озын гомер телисең син, акыллым!
Көнем туса, җиргә сыймый шатлыгым!
Һәр мизгелдә тоеп яшим: бәхетемдә
Тудыручым—Бөек Көчнең хаклыгын.

Равил ФӘЙЗУЛЛИН (1943) – *Татарстанның халык шагыйре; биш томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

## Пенсионер

Гомер буе налог салынды...
“Үзең теләп” заем алынды...
Авыздан өзеп җыйганны
“реформа” суга салдырды—
бер көн эчендә яндырды!
...Юлларда бушлай йөрүне
татлы төш итеп калдырды.

...Пенсия акчасы, белмим,
фатир түләргә калырмы?
“Якты киләчәк”кә чаба-чаба,
үләргә соңга калынды...

***

“Бетсәң—бет, әмма тәңгәлләш!
Сула минемчә генә!
Юкса, тәрәзәңдә булыр
рәшәткә белән келә!
Үз өеңдә дә йөрерсең
билдән иелеп кенә!..”

Импер-интер кыланыштан
Күктәге Кояш көлә:
“Кеше ирегеи тыеп булмый,
ул—Табигатьтән килә!
Ул—Илаһ көчтән килә!”
Җир кирегә әйләнә алмый,
Пигмейлар әйтеп кенә...

...Тәңгәлләшеп буладыр ул
тик Мәхәббәттә генә!
Анда да әле азга гына—
назлы рәхәттә генә!

## Солдатка китү

Юатырга тырыштым,
Ә ул елап елышты.
Китеп бардык төялеп,
Ярым калды сөялеп.

Кая барам? Ник дип китәм?
Кемнән саклыйм кемнәрне?..
...Күздән яшьне җил киптерде,
кичеп чыккач үрләрне.

## Чарасыз юану

Беткән... Сөяк белән тире... Тиздән
бакыр акча ятар күзенә...
Юк!—бу якты яз, дәрте ташкан яз
мәет төсен алмас үзенә.

Кояш нуры өчен түгел, фәкать
туфрак кына йотар җәсәд бу.
Тән-кабыктан җаны чыгып очар—
Җир өстендә урын исәпле...

Ә шулай да кеше кадәр кеше
чыга алмыйдыр ул гел юкка.
Хәтер булып йолдызларга кунар,
рәшә булып иңәр офыкка.

***

*Мич башында ятса ятыр,*
*мылтыгы янда булыр.*

Ары лап-лап, бире лап-лап,
чит кавемнәр җирен таптап,
халыклар бәхетен "яклап",
вәхши гамәлләрен аклап,
энәгә салам саплап...

Глобаль затсызлык белән
тора таңымны каплап.

***

"Картлык—шатлык түгел". Хак сүз.
Ялгыз калсаң, һай, авыр!
Элек дару—агу иде,
хәзер агу да дару...

Яшьлектәге авырлыкны
дәртле куәт җиңә ала.
Сирәк кеше саклый көчен
Картлык дигән финалга.

## Шундый хәлләр...

Заманында урыс патша Зөясуда шәһәр-кирмән салдырды.
Безнең башлык тәре-сурәт иконаны Ватиканнан алдырды.
"Казан нуры" мәчетендә шушы хәлгә нинди вәгазь, белмибез.
Мәскәүдәге иң олы поп: "Вот басурман, һай, молодец!" ди, имеш.
Тырышсалар, тәре-икона Казанга да хуҗа кебек кайтыр әле!
Болай барса, һич шөбһә юк: милләтебез гөрләп "чәчәк атар" әле!..

***

Очкычлар ватылгач, җирдән
"кара тартма" эзлиләр...
Сер тулы "күңел төене"
бар ул һәммәбезнең дә!..

Күп серләр мәңге ачылмый.
Һәм кирәкмидер дә...
Алар, ахры, Күккә ашадыр
Җан рухы белән бергә.

Карагыз Күк гөмбәзенә!—
Йолдызлар—тоташ тылсым!
Уртак сер булмаса аларда,
ул берлек каян килсен?

## Бар иде...

(Түрәлектән төшкән бервү авызыннан)

*Таулар иелә иде...*

Балта үтми!..
Сүз үтми...

Бар иде!—
һәр әйткән сүз,
майга кергән пычак кебек,
кисә-кисә
үтә иде!
Яшенташтай
өтә иде!
Хәтта сүзсез
күз карашы
җитә иде!..

Ятлап йөрерләр иде!
Әйткән сүзләрнең көенә
атлап йөрерләр иде...

Кайрадым балтаны—
үтә!
Сайлыйм сүзләрнең шәбен—
үтми...

Бу дөньяга
ни җитми?
Ә?

## Айкалый—айкалый...

*Н.га*

Нәсарани да җаный!
Гыйбарани да җаный!..
Яшь чакта, бәлки, ярый...

Олыгайгач, картайгач,
Тарихи ген аваз салып,
Күңел сызлый, җан каный,
айкалый-айкалый...

Бабайлар рухы—аңда.
Интер балалар—алда.
Кяфер телен шәп беләбез,
оныклар аңламага!

Бәгыреңә тулган моңны
кем аңлый да, кем таный?
Күңел сызлый, җан каный
айкалый-айкалый...

## Пародокс такмаклар

(шаяру)

Ике әби күмер чаба
шахтада.
Ир егетләр чигү чигә
яктыда.

Ябалаклар чут-чут сайрый
гөлләрдә.
Сандугачлар тычкан тота
төннәрдә.

Кабан күле спирт булган
алкашка.
Галимнәргә надан килә
алмашка.

Кем мәйданда, чүлмәк итеп,
баш вата?
Колмак баткан дәрьяда
таш калка.

## Булмый ул...

Багар күгең аяз түгел икән,—
йолдызларны танып булмый ул.
Хәсрәт чиксәң, аерым-аерым торып,—
бер шатлыкта янып булмый ул.

Илаһ көчләр әгәр белдермәсә,—
җандашыңны табып булмый ул!

***

*Бер каламдәшкә*

Ходай аңа күпне биргән.
Иман гына бирмәгән.
Халыкныкын күпләп алган.
Кайтарыйм! димәгән.

...Күрәсең, рәхмәтле булу
Табигатьтән иңмәгән.

***

Альп тауларын да күрдем.
Альп тауларын да...
Илаһ бер Биек Чик—Үлем—
һәркем алларында.

***

Мәхәббәттән—Нәфрәт туа ала.
Нәфрәттән—
туса туар Үч кенә.
Ә Үчнең рейтингы кечкенә!

Пародокс:
Судан туа ала Ут!

... Кеше зирәгрәк булган саен,
күп чак
бәхете юк!..

## Хәл

*(бала тугач)*

Бер аптыраган елаган ди,
ике аптыраган көлгән...
...Аптыраулардан гаҗиз булып
уртак гөл шытты көлдә.

## Әй, ул шайтанны!..

*Шайтан Адәм баласының*
*кан тамырында йөри.*
(Хәдистән)

Моның шайтан күзендә үк!
Ку, ди, шайтанны!..

Төнге шашкын мәхәббәттән
югалткач аңны—
шатлык яше булып чыкты
кызның шайтаны!
Әллә яшь, әллә тир
идәнгә тамды...

Фәрештәләр кул чаптылар
каршылап таңны!

## Тормыш Кырында

Шатлык кына шытсын диеп,
чәчкән идем мул итеп мин
гел Өмет орлыклары...

Каян чыгып тулышып үскән
Үкенеч башаклары?

"Ур!", ди Язмыш!

Урак кебек бөкерәеп
аптырап торам.

***

Дулкын арты дулкын килә.

Берәүләр—илдән илгә күчә...
Берәүләр—ирдән иргә...
Берәүләр—диннән дингә күчә...

...Бүгенгә тау мәшәкатьләр алдында
кечкенә кала
кичә үткән кичә.

***

Алай итте,
болай итте...
Әле кайтты,
әле китте...

Әйтте Күкләр:
"Әй, балалар,
йәгез, җитте!"

Ачу туды,
үпкә туды...
Күңелләргә
рәнҗү тулды...

Әйтте Күкләр:
"Әй, балалар,
йәгез, булды!"

Инде менә
булынды да,
җителде дә!

Утырабыз
бәхетебез
китегендә...

***

Яшьлек, чыннан да, яшелдер.
Яз төсе бит—яшел.

"Саргаеп бөрешкәненңне
яшь күәләрдән яшер!"—
дип әйтүгә, Күк катында
яшьнәп алды яшен!

## Çəçmə əsərlər
## Чәчмә әсәрләр



**Зиннур Хөснияр**

# КӘҖӘ ЙӨРИ КЫЕКТАН

ПОВЕСТЬ

*Все бабы—дуры,*
*а мамы умные.*
Афоризм.

### "Мөгезсез үгез"...

"Ферма сыерларын урман арасындагы җәйләүгә җыеп киттеләр. Чит илдән нәселле сыерлар кайтарачаклар икән. Бу эшкә "Химполе" оешмасы үзе алынган.Колхоз да алар карамагында бит. "Квас" кына бирә торган сыерлар кайтартачакбыз диделәр, ни әйтсәң дә,"химиклар" бит—булыр, булыр, Алла боерса... Бер ай узды, ике ай. Өченче ай китте дигәндә дә, сөт урынына "квас" һәм "пепси-кола" бирә торган нәселле хайваннар күренмәде. Англиядә ящур икән, тоткарлык бары шуның аркасында гына дип шәрехләде әлеге хәлне Галәветдин Минтаһирович. Югарыда ни әйтсәләр, шуңа ышанырга күнектерелгән халык "пепси" бирә торган сыерларны әүвәл бернинди шик-шөбһәсез көтте. Районның баш "химигы" әйткәч, сөт урынына сыер хайваны ничекләр итеп "пепси" бирсен инде дигән сорау белән дә үзенең башын катырып азапланмады—көтүен белде.

Ә "Мишка" кушаматлы үгезне сыерлар белән ияртеп җибәрмәгәннәр иде. Чөнки хуҗалыктагы сыерларның бердәнбер карап торган "Мишка"сы иде ул. Халык белән бергә үгез дә көтте.

Ферма бушап калгач, шәхси хуҗалыктагы сыерларның да хәле кыенлашты, чөнки монарчы алар тагарагына да фермадан кайтып тора иде.

Көттеләр. Көтә торгач, иң беренче булып, үгезнең тәкате корыды.Житмәсә, хуҗалык сыерларының да аның янына тояк эзләре суынды; ни ашатырга аптыраган халык мөгезле эре терлекне сөт кәҗәләренә алыштыра башлады.

Бозаулар янындагы бер абзарда бәйдә торган үгез рәттән өч көн

---

Зиннур ХӨСНИЯР (1961) *—язучы;"Таң ата да кич була", "Тәгәри китте язмышлар", "Терсәк сугышы" һ. б. китаплар авторы; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

бертуктаусыз мөгрәде мөгрәде дә, ахыр чиктә, чылбырын өзде һәм бозаулар абзарын җимереп керде.Бу вакытта фермада акылга бераз җинелрәк, ләкин элек алдынгы савымчы булган Гайфә түти ялгызы гына иде. Үгезнең мөгрәвен өченче көн инде үзенчә башка нәрсәгә юрап йөргән Гайфә савымчы, тора-торып, ныклы фикергә килде: үгезнең "җиленнәре" тулган, савырга кирәк, юкса шартлап ярылачаклар! Әнә, шундый изге нияттән үгез абзарының ишеген ачып җибәргән иде Гайфә савымчы. Чылбырыннан ычкынган үгез бозаулар янына бәреп керде.

Сырт сөякләре шартлап сынган айлык бозауларны икенче көнне үк каядыр юкка чыгардылар. Шул ачудан фермага бер төркем элеккеге савымчы апалар җыелышып килеп, җинаятьче үгезнең ике мөгезен берьюлы тимер пычкысы белән кисеп аттылар. Ул таза гәүдәле, нәселле сыерга охшап калды. Гайфә савымчы аны бик кызганды, савып, хәлен җинеләйтү теләге—баш миендәге бер "шаригы" салам арасына төшеп югалган тилемсә хатынның—һаман сүнмәгән иде әле".

Кәрим фельетонның соңгы җөмләсенә нокта куйды да, мендәр астына яшерде. Бер ферма сыерларының юкка чыгуы турында ана элеккеге коллегасы—район газетасы журналисты Садыйк сөйләп киткән иде. Куллары исән-сау булган Кәрим, мендәренә сөялеп утырган килеш,бу вакыйга нигезендә фельетон язып атты. Тик әүвәл кемгә укытырга? Кызына күрсәтергә унайсызланды. Турыдан-туры район газетасына җибәрсә генә инде? Тик әүвәл... иң беренче хатыны Фәгыйләгә укытмыйча ярамас! Үпкәләве бар. Яраткан кешеңне үпкәләтү—гафу ителмәслек начар гамәлдер...

Бүген өйгә тагын соңлап кайтыр микән инде Фәгыйләсе?..Тагын төне буе хатынын көтеп ятармы икән Кәрим?..

## Минем әни бай хатын...

Кызның үз гомерендә беренче мәртәбә кибет киштәсенә тәртип белән тезелгән исәпсез-хисапсыз, төрледән-төрле уенчыкларны: буе ярты метрлап булган кызыл битле Кыш бабайны, алсу йөзле Кар кызын, бишектәге тере бәби чаклы курчакларны, гәүдәгә чын юлбарыс баласыннан чак кына кайтыш тагын әллә нинди җансыз җанварны, күз явын алырдай уенчык-муенчыкларны бер селтәнүдә идәнгә сибереп төшерәсе килде. Алар матур иде, ялтыравыклы, затлы бизәкле иде, әмма һәммәсе җансыз, ясалма иде. Аларны беренче карашка гына чын дип уйлыйсың, ясалма икәнлекләрен белгәч, шул алдануыңа хурланасың, бу дөньяның бар алдавыч ялтыравыгыннан үч аласы килә.

Кибеткә нидер алырга кергән кешеләр генә чын, тере. Кемгә нәрсә, кәҗәгә кәбестә дигәндәй, кибеттә бар да бар. Монда ашамлык-эчемлек тә, чүпрәк-чапрак та, тимер-томыр да сатыла. Бер түбә астына урнашкан бинаның икенче ишегендә саламнан коньяклы коктейль суырып утыру өчен кафе урнашкан, өченче ишек гап-гади ашханәгә алып керә.Арткы, аулагырак ягында, менә дигән кунакханәсе бар.

Кызның әнисе шушыларның барысының да хуҗасы. Ул әлегә кызын күрми, чүпрәк-чапрак бүлегендә таныш хатыны белән сөйләшеп торалар. Менә аны бер ир-ат кырыйга дәште дә, оятсыз рәвештә биленә кулын салып, колагына нидер пышылдады. Кыз үзе дә сизмәстән аларга якынайды. Әнисе әлеге ир-атны төртеп диярлек җибәрде дә: "Йөрмә монда",—дигәндәй, ачу белән кулын селтәде. Ләкин тегесе дә ниндидер үҗәт иде, һаман чыгып китми.

—Мине танымадың бугай син, Фәгыйлә? Казан кунагын сыйлаганда мин дә бар идем бит. Исеме ничек иде әле ул түрәнең?

Фәгыйләнең бит алмалары әүвәл Кыш бабайныкы кебек кып-кызыл булды, аннары әлеге төсне янәшә киштәдәге Кар кызы йөзендәге алсулык алыштырды. Ул, җәһәт кенә барып, ике шешә аракы алды да теге бәндәнең кулына тоттырды.

—Йөрмә монда бүтән!

—Мин тагын кергәләрмен әле, Фәгыйлә, яме!

Кызга бу адәмнең сүзе дә, үзе дә шыксыз булып күренде.

Әнисе белән сөйләшкән хатынның йөзен күрүгә кыз куырылып килде. Шул бит инде! Зарифә апа! Айратның әнисе ич! Бигрәк мөлаем апа инде ул! Ләкин шулай булса да, янына барып сүз кушасы, сөйләштерәсе килсә дә, ничектер шүрләтә. Усал хатын булмаса да кыз аннан уттан курыккандай курка. Үзе якын итә, үзе курка! Бигрәк кызык инде! Малае, Айраты, тагын да кызыграк аның. Алар Айрат белән ун ел буе бер мәктәптә укыдылар, икесе дә Казанга барып укырга керделәр.

* * *

Әнисенең эшенә юкка гына килмәде кыз. Әйтәсе сүзе бар... Әмма ничекләр генә итеп үгетләсә дә, файдасы булмас шикелле иде.

—Әни, синең урыныңа үзем генә барыймчы, ә!

—Юк, юк, балам. Анда әллә кемнәр киләсе ди. Берәр нәрсә булса, мине шул сәгатьтә үк эштән куачаклар. Үзең беләсең, кызым.

—Әни дим, әллә үзең дә бармыйсынмы соң? Кадалып китсеннәр!

—Кәримә дим, кызым! Бу юлы бик зур түрә киләсе, ди. Сәгыйть Сәетович әтиең турында да сөйләшеп карармын дигән иде.

...Әнисен ризалату файдасыз иде.

—Бар, кызым, өйгә кайт. Әтиеннең тамагы ачкандыр. Берәр нәрсә әзерләп ашат.

Әнисен тагын күндереп булмады. Аптыраганнан гына килде, әтисе бит... Йөрмәсен әле әниең шунда ди. Тагын казаннар килгән икән ди.

Алар яшәгән бистәгә Казан кунаклары еш килә. Әллә инде хуҗалары Сәгыйть Сәетович шулай бик кунакчылмы соң? Әллә кунакларга Сазлык елгасының суы ошый, әллә елга ярында ук салынган мунча-сауна күңелләренә хуш киләме икән? Әнисе шулай ди бит. Яртышар көн мунчада яталар, яталар да аннары ашап туя алмыйлар, ди. Хәер, әнисе әйтмешли, алар зур, укыган кешеләр инде. Казанда вакытта шулай мунчалар кереп йөрергә кайдан вакыт тапсыннар соң?

Анысы да монысы, Сәгыйть Сәетович бик юмарт кеше, көне-төне шуларны сыйларга булышкан өчен әнисе уч тутырып акча алып кайта. Акча капчыгының авызы казаннар кулында икән ди. Шуларның күңелен күрә алгач, Сәгыйть Сәетовичның да эшләре гөрләп бара, әнисе дә акча эшли. Ә акча Кәримәләргә бик кирәк. Урын өстендә яткан әтисе бар. Моннан өч ел элек, егылып, ике аягын, ике кулын сындырган иде—һаман рәткә килә алмый. Мәскәү хастаханәсенә алып барырга кирәк ди. Шуңа әнисе тырыша-тырыша акча җыя. Көне буе гел аягүрә кибеттә эшләгәннән соң, кунаклар килгәндә, кичләрен Сәгыйть Сәетовичка аларны сыйларга булыша.

Текә яр бистәсенең бер очыннан икенчесенә чыгып җиткәнче сәгать ярымлап вакыт кирәк диләр. Кәримәнең исәпләп караганы юк, чөнки бистәнең югары очыннан түбәненә автобус йөреп тора. Әнисе шулай дип сөйли торган иде. Текә яр, аларның гаиләсе монда күченеп килгәндә, Сазлык елгасы буенда ук урнашкан тугыз йортлы урыс авылы булган. Казан артындагы әлеге авыл нигезендә (урысча исеме—Собачьи горы) заманында зур төзелеш башлап җибәргәннәр. Төрле яктан һәм кырыкмаса кырык милләттән Текә ярга торыр җирсез юксыллар, эшсезләр җыелган. Тугыз йортлы салам түбәле Собачьи горы хәзер—шаулап-гөрләп торган Текә яр бистәсе. Хәер, урысча ул әле дә бөтен язуларда да Собачьи горы дип языла. Татарлар телендә “Текә яр”, урыс телләләр дә, вата-сындыра: “Текоярова” дип әйткәләп куя.

Кәримә, үз тукталышларына килеп җитәм дигәндә генә, ике кеше аша үзенә төбәлгән күз карашын тоеп, әллә нишләп китте. Үз яшьләрендәге бер егет бик кызыксынып аны күзәтә иде. Күз карашын оялып читкә алды алуын, тик тагын бер мәртәбә генә булса да, сиздермичә-белдермичә генә аңа караш ташлыйсы килде. Әлеге хис оялчан күңелдән көчлерәк булып

чыкты, тәки үзенекен итте: ул янә шул тарафка күз салды. Бер генә мизгелгә карашлары да очрашты әле һәм шундук бит алмаларына эссе ут капты. Пырхылдый-пырхылдый түбән очка көч-хәл белән тәгәрәгән "пазик",әйтерсең, очкычка әйләнде дә, болытлар өстеннән йөзә башлады, әледән-әле терсәкләре белән бер-берсенең кабыргасын санап барган ачы телле кешеләр гүя шул мизгелләрдә җәннәт фәрештәләренә әверелеп, былбыл кауреые белән аның борын очына кунган өч кенә бөртек тир тамчысын җилләтергә керештеләр, тукталыш саен: "Билеты, за билеты передавайте! Всё равно за эти деньги иномарку не купите!"—дип, юл буе теленә салынып барган шофер егет, көр тавышы белән сузып торып җырлап җибәрде сыман.

Кыз яңадан "җиргә төшкәндә", аның тукталышын шактый ара узып киткәннәр иде. Күңелендәге "этлек": "тагын бер мәртәбә генә карап ал инде шул егеткә!"—дип өстерсә дә, кыз бүтән җөрьәт итмәде. Курыкты. Монарчы беркайчан да татымаган татлы, әмма ниндидер сәер хисснең тагын кабатлануыннан курыкты. Сәерлеге түгел, артык ләззәтле булуы куркытты бугай.

Чираттагы тукталыштан соң автобус түбән очка таба кузгалды. Гадәти булмаган теге егет тә аның белән китте. Кызның әле генә җанын кайнаткан татлы кичерешләр автобус артыннан ияреп бардылар да, аллә "хәлләре бетеп", аллә кирәкмәгәнгә санап, үзенә кире әйләнеп кайттылар һәм күз ачып йомган арада күңеленә кереп бикләнделәр. Күңел дигән гаҗәеп дөньяда тагын бер буш урын кимеде...

Әтисе кызының кая барганлыгын белә иде, тел әйләндереп тормады, бары яткан җиреннән чак кына кымшангандай итте, әмма өйдә ята-ята тоныклана барган күзләрендә сораулы караш барыбер чагыла иде.

Бардыңмы, әниең нәрсә дип әйтте янәсе.

—Имтиханнарына әзерлән. Үзем барам диде.

—Алай икән.

Ата белән кызның әңгәмәсе шуның белән тәмам булды. Болай да тыныч холыклы әтисе, бигрәк тә бу соңгы ике ел эчендә тагын да азрак сүзлегә әйләнде. Күңелендәге соравын сүзсез әйтергә, җавабын да күз карашлары белән бирергә өйрәнде бугай инде ул.

—Әти, карының ачмадымы?.. Нәрсә пешереп ашатыйм?

—Су алып кил.

Кәримә суыткычтан шифалы су шешәсе алып ачты. Ул салкын иде. Җылытырга талпынган иде, теге бүлмәдән әтисенең:

—Кызым, салкын килеш әйбәтрәк була,—дигәне ишетелде.

Әти кеше, башын күтәрә төшеп, чәшкәне кулына алды.

—Әти җаным, бигрәк салкын. Чак кына җылытыйм инде, ә,—дия-дия Кәримә учлары белән ике яклап чәшкәне кысты.—Хәзер, әти, чак кына.

Әтисе су эчкән арада кыз күзләрен дә алмыйча яратып аңа карап утырды да, балачактан килгән гадәте буенча әти кешене көтмәгәндә битеннән үбеп тә алды.

Ул бала әтисен яки әнисен бик ярата дип әйтергә яраталар. Майга май дигән шикеллерәк килеп чыга инде бу. Ничекләр итеп әти-әнине яратмыйсың ди! Аллаһы боерса, әле менә аякларына да басып китсә, аның әтисе дөньяда бер кеше булачак әле! Хәер, болай да берәү генә инде ул!

Кәримә әтисенең битеннән тагын бер мәртәбә үбеп алды да беркавым никтер тынып торды. Автобустагы хәлне әтисенә сөйлисе килдеме соң? Хәер, нәрсә дип сөйләсен инде. Авыз тутырып сөйләрлек берни булмады ич. Кеше күплектән автобус эче тынчу булгандыр да, бәлкем, бер мизгелгә генә башы әйләнеп киткәндер әле. Теге егетнең монда ни катнашы бар ди!

—Кызым бүген ничектер аяклар кызыша кебек. Җан кергән шикелле булдымы шунда...

—Әти, озакламый аякка басасың әле син. Менә күреп торырсың. Мәскәүгә май аенда барасы бит әле, име.?

—Акча житсә инде.

—Нишләп житмәсен! Аңа хәтле айдан артык вакыт бар ич әле!

Әти кеше дәү учлары белән кызының башыннан сыйпады.

Аның бик тереләсе, тизрәк аякка басасы, сөйгән хатыны белән күз алмасыдай кызын соңгы елларда чуалыбрак киткән дөнья мохтажлыгыннан коткарасы, тормыш камытын яңадан үзенә аласы килә иде. Нәкъ аяк астыннан гына мондый бәла килеп чыкмасамы? Хатынын үзенең төп эшеннән соң, тилмертеп, кичке сменага калдырып эшләтә торган ир-ат идеме соң ул!

Кайгы агач башыннан йөрми диләр. Мондый гыйбарәләрне юкка гына, сүз булсын дип кенә әйтмәгәннәрдер, күрәсең. Үткән еллар, кайчак кайгылары белән ишелеп килгән, кайвакыт елмаеп-көлеп каршыңа чыга торган язмыш язусыз-сызусыз зур мәктәп ул. Аннары кайвакыт кайда сөртенәсеңне дә чамалап бетерә алмыйсың. "Кайда егыласымны белсәм—шунда ястык җәеп куяр идем",—дигән ди бит әнә берәү.

Хатынының әнисе—сиксән ике яшьлек карчык—алар кулында тәрбияләнә.

Ут карчык,булган кеше. Житмеш биш яшенә чаклы кәҗә мамыгыннан үзе шәл бәйләп базарда саттырды. Кызы Фәгыйлә күзлек кия башлаганда әби "эх" дигәнче, күзлексез-нисез энәгә җеп саплый, гарәп язуы белән язылган китаплар укый, Кәриманe чигү чигәргә өйрәтә иде. Әлбәттә, аны берәү дә шәл бәйләргә мәҗбүр итмәде, аңа эш кушмадылар, ләкин карчыкның йөрәге шундый иде, тынычсыз, тасырдык иде.

Картлачын җирләгәннән соң кияү йортына берданбер мамык кәҗәсен алып килде ул. Тора-бара хайваны картайды, әбинең картаясы килмәде, кәҗә бәрәнен асрады. Аның фәлсәфәсе болайрак иде. Бу кәҗә токымы аңа бик кадерле. Ул хайванның әбисен алар карты белән икәүләп Морки базарыннан алып кайталар. Кәҗә бик шәп, затлы мамыклы булып чыга. Аның мамыгыннан бәйләнгән шәлләр тирә-юньдә дан казана. Халык аның шәлләренә чиратка языла. Моңарчы тормышның тишек-тошыгын көч-хәл белән, аннан-моннан гына ямап барган гаилә кәҗә аркасында бөтәеп китә. Фәгыйләнең әтисе мактанып: "Кемнәрдер ат алып та мантый алмады, берәүләр кәҗәдән дә унды!"—дип сөйләргә ярата торган булган.

Әнә шул затлы кәҗә аркасында хәлләр булды да инде. Кияү Кәрим бер дә бер көнне эштән кайтып кереп капканы ачып җибәрсә, ни күрсен, әби белән кәҗә лапас түбәсендә утыралар.

Кәҗә, күрәсең, лапас түбәсеннән өскә үк менгән дә, кыек буйлап килә-килә, Кәримнең юнып кибәргә сөяп куйган озын-озын киштәлекләре арасына килеп кысылган. Әбинең исә кәҗәсен коткарырга менүе булгандыр, хәзер әнә кире төшәргә куркып түбәдә утыра.

Берәү булса, каенанасының мондый тилелеген күреп: "Чукын шунда, карт тәре!"—дип шатланыр гына иде. Ләкин Кәрим карчыкны үз әнисе урынына күрә. Гомумән, аларның мөнәсәбәтләре ана белән ул арасындагы кебек иде.

Әүвәл кияү кеше, бу хәлне күреп, кычкырып көлеп җибәрде. Чөнки мондый хәлне уйлап та чыгарып булмый иде. Бер генә кинода да күргәне юк, бер генә китапта да очратканы булмады. Әби лапас түбәсендә утыра! Кәҗәсен коткарырга менгән!

Кәрим кияү, ничек кенә тырышмасын, көлүеннән тыела алмады. Көлә-көлә менеп әбине алып төште ул, кәҗә бәтиен дә коткарды. Әбине алып төшкәндә, сөякләре таралып китә күрмәсен дигәндәй, ипләп, җайлап кына тоткан иде. Әби үзе дә чытырдап аның муенына ябышты. Каенанасының арык, әмма көчле куллары муенын шул хәтле иттереп кысканнар ки, әйтерсең, куллар түгел, тимерче келәшчәсе диярсең! Кәрим беравык муенын ни унга, ни сулга бора алмыйча азапланып торды. Каенанасы: "Нишләп торасың инде! Кәҗәмне коткар, кәҗәмне!"—дип, шираулап кычкырып җибәргәч кенә исенә килде.

Кәҗәне коткару тагын да кыенрак булып чыкты. Ул әби түгел, муенга

ябыша белми шул. Кәрим, кәҗәнен киштәлекләр арасына кысылган башын чыгарам дип азаплана торгач, үзе, тигезлеген югалтып, чак кына аска мәтәлмәде, кәҗәнен койрыгына тотынып калды. Койрыктан тарту житте— кәҗә бәтие, ямьсез итеп кычкырды да, лапас түбәсеннән уктай атылып төшеп, дүрт аягына да жиргә басты. Кәҗәсенен шактый биек түбәдән яшен ташыдай мәтәлгәнен күргән каенана әче тавыш белән чинап жибәрде: "Бетерден кәҗәмне, харап иттен! Бетерден, имансыз!" Кемдер килеп каенананда шундый тавыш бар дип әйтсә, мәнге ышанасы түгел иде. Үзе ишеткәч, беравык шаклар катып торды әле. Ишегалдына тавык бәрәнгесе урларга төшкән карга-чәукәләр, котлары алынып, һавага күтәрелде. Келәт буенда тычкан сагалап утырган кара мәче, томырылып, капка астыннан чыгып качты. Гәүдәсен яшен суккандай булды, буыннары йомшарды. Башы әйләнә башлавын да сизгәч, ул тизрәк жиргә төшәргә ашыкты. Әмма тотынып өлгерә алмады, дөбер-дөбер тәгәри-тәгәри аска мәтәлде.

Әби кеше лапас кырыенда гына өелеп торган таш өеме өстендә хәрәкәтсез яткан киявенә әүвәл игътибар да итмәде, бөтен игътибары кәҗә бәтиендә. Кәҗә бәтие Кәрим кебек ишегалдына түгел, яшелчә бакчасы ягына төшкән иде. Лапас түбәсеннән очуы шундук онытылды, ул, як-ягына карана-карана, кәбестә түтәлләренә һөҗүмгә әзерләнде.

Кәримнен авырту-сызлануы бик көчле булса да, эченнән аты-юлы белән үз гомерендә беренче мәртәбә карчыкны сүкте. Көчлерәк сүккән саен, авыртуы да шулчаклы тыйлыгып тора шикелле.

Кәҗә бәтиенә чиртым да булмады, аяк-куллары сынган Кәримне, кәҗә белән әбине коткарып калган кияү-балакайны, хастаханәгә озаттылар.

Аяк-куллар дөрес ялганмады, тагын сындырдылар, тагын нәрсәседер килеп бетмәде...

* * *

Әллә нинди көн булды бу бүген: әүвәл кибеттә нindидер түрә шоферынын әнисе белән сөйләшкәнен ишеткәч, кызнын йөрәге тасырдарга керешеп, бер хәерсез хис күнелнен бер читенә таш кебек кереп оялаган иде; хәзер исә шул күнеле, канат яргандай, очынасы итә, гәүдәсе мамык шикелле, очып китәр сыман, аяклары бер урында басып тора алмый. Әллә... әллә инде автобуста күргән егет булдымы сон монын сәбәпчесе?.. Айратнын әнисе белән күрешүме? Әтиенен: "Йөреп китәрмен күк тиздән, кызым!"— дип әйтеп, өмет белән тулган зур кара күзләрендәге якты мон, ышанычмы?.. Ни генә булса да, кызнын жанын нәрсәдер жилкендерә, тәүлек эчендә кырыкка төрләнә ала торган кыз бала күнеле, тынычлыгын тәмам югалткан иде.

Ярабби, яхшыга булсын! Мондый жилкенүләрнен ахыры, гадәттә, хәерлегә түгел. Ләкин нишлисен: күнел дигәнне тыеп торып булмый, андый чакларында ул акылга һич кенә дә буйсынырга теләми икән... теләми икән шул...

Әтисе: "Кызым, бу хәбәрне тизрәк әниенә дә житкерергә кирәк. Бүген эшеннән иртәрәк кайта алса яхшы булыр иде",—ди. "Әти, әни бүген дә вакытында кайта алмаячак. Кала кунаклары килгән, шуларны сыйлыйсы бар",—дип, ничек әйтәсен инде ана?

Кәримә аптырауга төште. Күнел жилкенүе дә сүрелде кебек. Ләкин жаны барыбер тыныч түгел, ул читлектәге сандугач баласыдай тыпырчына, бәргәләнә иде.

Әүвәл әнисенә телефоннан гына шылтыратмакчы булган иде. Күршеләрендә телефон бар, кайчан керсән дә якты йөз күрсәтеп, сөйләшергә рөхсәт бирәләр иде. Әмма... әллә хисләр кайнарлыгы зиһененә тәэсир кылып, гакылы тәмам сафланып, хәтер почмагындагы йокымсырый башлаган күзәнәкләре капылт кына уянып киттеләр! Булган иде бит инде бер мәртәбә! Булган иде! Нәкъ шундый хәл кабатланган иде: әтисе берзаман кинтән жинеләеп китеп, әнисен эштән чакырып кайтырга жибәрде аны. Әүвәл ул күршеләренә кереп, телефоннан сөйләште. Бу шатлыклы хәбәрне

ишетеп, әнисе бик сөенде, бүген иртәрәк кайтырмын, дип вәгъдә бирде. Көттеләр, кичкә чаклы, карангы булганчы әтисе белән икәүләшеп көттеләр аның кояштай балкып ишектән килеп керүен. Әни кеше эш сәгате беткәч тә кайтмады, вакыт шактый узып, караңгы төшкәч тә ишектә "кояш" күренмәде.

...Кәримә, әтисенә аны-моны әйтмичә генә, бистә үзәгенә китте, маршрут автобуслары йөреп тора иде әле.

Кибет бикле булгач, кафеның арткы ишегенә китте. Бар тәрәзәләрдә дә утлар яна, эчтә музыка уйный, кемнәрдер шау-гөр килә, тостлар әйтешәләр, тагын әллә нинди тавышлар ишетелә. "Сәет Сәгыйтовичның кала кунаклары!"—дип уйлап куйды кыз. Шул уйдан соң эченә жылы йөгерде, ул кыюланып, батыраеп китте, ашыга-ашыга, кафе ишегенә таба атлады. Һәм тәрәзә буеннан узганда, ирексездән кунакханә эченә күзе төште, житмәсә, пәрдәнең бер чаты ачылып та киткән иде. Кәримә егылып китә язды, бүлмәдә тәрәзәгә арты белән бер шәрә хатын-кыз басып тора. Почмактагы агач караватта зур бүксәле (аркасына ятуына да да карамастан корсагы түмгәк кебек булып күренә) бер ир-ат ята. Авызында тәмәке, ул бертуктаусыз сөйләнә, нииндидер сүзләр әйтә дә, аннан соң шаркылдап көлеп жибәрә, өстенә япкан одеал кырыеннан буйлы-буйлы трусик балагы чыгып тора. Менә ул шәрә хатынны үзенә тартып китерде дә өстенә одеал каплады. Кәримә телсез, өнсез калды, аяклары атламас булды. Шәрә хатынның сул як калак сөяге астында ике тиен акча зурлыгында миң бар иде. Бу аның... бу шәрә хатын... ике тиен акча зурлыгындагы минле хатын аның... аның әнисе түгелме соң? Ул ни кылганын, нәрсә эшләгәнен үзе дә белмичә янәшәдәге автобус тукталышына йөгерде һәм ишекләрен ябып кузгалып маташкан автобусның алгы борынына килеп бәрелде. Аны кемдер автобус эченә тартып алды, кемнәрдер шелтәләделәр, ачуландылар. Әмма әлеге мизгелләрдә фани дөнья мәсьәләләрендә аның эше юк иде. Өенә кайтып керүгә, бу халәтен әтисенә сиздерүдән куркып, тизрәк юрган астына чумды. Тынычлана алмыйча бик озак калтыранып, дерелдәп ятты; зиһене чуалган иде, анык кына ни хакында булса да уйлый алмады дисәң, дөреслеккә бигүк туры килеп бетмәстер дә, бәлкем, чөнки баш миен, әлегесен фани дөньяның әшәкелекләре турында нииндидер булса фикер йөртеп, акны карадан аерырга күнегеп житмәгән яшь гакылын һаман берүк төрле хәерсез, юньсез һәм ямьсез уйлар агач кәүсәсен чокыган әрсез тукран кебек өзлексез талый иделәр: "Әниең шул рәвешле акча эшли! Ә акча сезгә бик кирәк! Чөнки әтиенне аякка бастырасы бар!!!" Бу уйлар - котычкыч уйлар иде. Ул, алардан качарга теләп, башын юрганына да урап карады, мендәр астына да тыгып бакты, ләкин алар котылгысыз иде, үҗәт, усал һәм аяусыз уйлар иде!.. Әтисе янына килеп нәрсәдер әйтү хакында хыялланасы да юк, кыз, түземсезләнеп, әнисенең кайтып керүен көтеп ятты. Көтүен көтте, ләкин ишектән "кояш" керүен көтмәде. Бүген бусаганы тоныкк "ай", ярым китек моңсу "ай" атлап керер төсле кебек тоелды...

Кыз, юрганының читен чак кына ачып, тәрәзәгә карады. Инде төн житеп килә. Ә офыкта баеп бара торган тоныкк ай шәүләсе тирбәлә. Нәкъ үч иткәндәй бит, шайтан!..

Йоклап китү турында уйлыйсы да юк. Гәүдәсеннән хәерсез калтырау һаман китми дә китми. Шул рәвешле күпме яткандыр, берзаман кайтып керде әнисе. Кәримә башка вакытта аны аяк өсте каршы ала, алар юк-бар хакында гәпләшеп бик озак әтиләренең караватъ кырыенда утыралар, аннары, бергәләшеп урыннар жәеп, йокларга яталар да һәм тәмле-тәмле, матур-матур төшләр күрәләр иде. Бүген ул алай итмәде, башымны юрган астыннан чыгармыйм, дип уйлады. Уйлавын уйлады, ләкин барыбер юрган читен аз гына ачып, өй эчен күзәтте, әнисенең чишенгәнен карап ятты һәм шул чак кычкырып жибәрә язды:теге ике тиен акча зурлыгындагы миң, тәрәзә аша арты белән борылып торган шәрә хатынның калак сөяге астындагы хәерсез миң... Һе, менә сина мә!—ул миң әнисенең уң ягында икән бит! Кәримә тәгаен хәтерли,—бу очракта ялгышу, хаталану һич мөмкин хәл түгел иде,—

Сәет Сәгыйтович кунакханәсендәге шәрә хатынның мине сул як җилкәсендә иде ләбаса!

Кызның гәүдәсен янә калтырау алды. Әлбәттә, бу юлы сәбәбе бөтенләй башка иде! Хәерлегә булсын!..

Әнисе, әтисе яткан бүлмәгә кереп чыкты да (әти кеше йоклап киткән булгандыр, күрәсең) эчке күлмәген киеп, кызы янына килеп ятты.

—Кәримә, Кәримә, йоклыйсыңмы, кызым?

Җавап булмагач, ул үзенә аркасы белән борылып яткан кызын кочаклады... һәм кызының бизгәк тоткан кебек калтырануын тоеп, мышык-мышык еларга кереште. Ана белән бала арасындагы биокүзәнәкләр аша күңелсез әңгәмә башланды.

—Гафу ит, кызым! Мин күп итеп акча эшләп кайттым!

—Акча? Сина кем акча бирсен?! Синең минең уң як җилкәңдә бит?

—Менә тиздән әтиеңне больницага салырбыз.

—Әти үзе дә йөреп китәчәк әле ул!

—Түләүле операциягә дә акча җитәрлек хәзер.

—...

—Аннан соң бу эшемнән китәм. Әтиең аякка баскач дим... Ул акчаны күп итеп таба иде бит.

—...

Тәрәзәдән күренгән теге ярым китек ай көчәнә-көчәнә өй эченә, идәнгә, стенада эленеп торган сәгатькә үзенең тоныкь нурларын сипкән булган тагын... Ник азапланып маташа инде? Тулган чагы түгел бит барыбер...

* * *

Кәримәнең әнисен суд залыннан ук алып киттеләр.

Әүвәл җиде елдан да ким булмас дигәннәр иде. Анысы да "аванс" белән әле. Авыру ире, гаиләсе барлыгын исәпкә алып,соңыннан, ни хикмәттер, суд дүрт ел дигән карар чыгарды.

Күрештермәделәр, очраштырмадылар, сөйләштермәделәр.

Дигәннәр иде, сөйләгәннәр иде, юраганнар иде...

Авыру әтисе янында ялгыз башы калган студент кызны сыгылып төшәр, бу кайгыны күтәрә алмас дигәннәр иде. Киресенчә булды: әүвәл көне-төне бертуктаусыз елады-елады да... аннары, әтисе янында әбисен калдырып, укырга китеп барды. Әнисен уйлый-уйлый акылга җиңеләеп калыр бу кыз бала дип сөйләгәннәр иде. Күз яшьләре кибеп беткән идеме, әллә бәгыре каттымы—бүтән яшь түкмәде. Бер иш адәм баласы кайгы-хәсрәт һәм кыенлыкны күпме күберәк татыса—шулчаклы ныгый, үҗәтләнә генә икән. Кәримә шундыйлардан иде, күрәсең.

Әнисез калгач, укуын ташлар бу кыз бала дип юраганнар иде.

Әйе, элек, укуга алай бигүк битараф булмаса да, барыбер күңелен биреп бетерә алмый кебек, кирәк булганга гына укый шикеллерәк иде. Киресенчә булды, кышкы каникуллардан соң... хәер, әнисен, газиз әнкәсен төрмәгә алып киткәннән соң, аның фәннәргә дә мөнәсәбәте үзгәреп, ул һәр нәрсәдән мәгънә эзли башлады.

Ләкин тагын өстәмә бер акыл теше чыгу түгел иде бу. Нәрсә белән булса да кызыксынмаса, күңелендәге бу хәшәрәт дөньядагы бушлыкны шулай буш килеш калдырса, һич тә яшерен-батырын түгел, кызның үксеп-үксеп елыйсы, тулай торак идәнендә,—Алай гына да түгел!—Бауман урамы ташына ятып тәгәри-тәгәри елыйсы килер кебек иде шул... Акыллы иде кыз, төпле иде кыз. Шул аяз акылы аны төрле җүләрлекләрдән саклап килә әле, шөкер...

Ул укыган гуманитар факультетта фәлсәфә, социология, психология фәнен тирәнтен өйрәнәләр. Башлангыч курслардан ук. Ни гаҗәп, хәзер ул аны аңлый башлады сыман. Әлбәттә, күп нәрсәне кабул итеп бетерә алмаса да. Элегрәк кыз баланың күңеле башка дөнья яссылыгында яши, гакылы исә аерым юлда сыман иде. Гаҗәп һәм кызык: адәм баласын Кеше итеп тоткан әлеге ике төшенчә, шул төшенчәләр аңлаткан мәгънә вакыт-вакыт

кушыла башладылар, үзара якынайдылар. Күп гомерен чәчәкле болында үткәргән кайгысыз күбәләккә охшаш күнел, әледән-әле йолдызларга кунып алгалаган иләс күнел, берзаман жиргә кунды, фигыль-гамәлләре гакыл белән охшаша, килешә башладылар. Мондый үзгәреш сиздермичә генә килде. Һәм кызны үзгәртте. Ничек үзгәртте, юл-сукмагын кай якка борды—анысы әһәмиятле түгел, ләкин үзгәреш булуы хак иде.

Артык акыллы булунын беркайчан да хатын-кызны бәхетле иткәне юктыр. Хатын-кыз турында ир-ат ничә гасырлар буе фәлсәфә корган, бик акыллы булып, әлеге женестән үзен өстен куеп, анын гамәлләрен бала-чага холкына тинләгән. Хатын-кыз өчен ин якын дус ир-егетләрнен дуэльләрдә бер-берсен үтерешкәнен нишләптер фәлсәфи күзлектән карарга онытып жибәргән ул...

Кәримә кин, ялтыравык манкайлы, аксыл йөзле яшь профессорны тынлый. “Ир-атнын гакылы һәм рух дөньясы утыз яшькә якынлашканда гына камилләшә, хатын-кыз мондый югарылыкка унсигездә үк ирешә. Шуна күрә дә хатын-кыз гомере буе бала-чага булып кала, зур бала-чага... әйләнә-тирәсендәгесен генә күрә ул, вак-төяк белән шөгыльләнүне бик мөһим дип уйлый. Нәкъ менә гакыл аркасында кеше хайван кебек бүгенге белән генә яши алмый, үткәнне анализлый, киләчәкне фаразлый, шунын аркасында ул сак эш итә, кайгыра-кайгырта, борчыла, гакылынын сыеграк булуы сәбәпле хатын-кыз ир-аттан аерылып тора. Үзенен рухи күрә-карау булуы белән аерыла ул: анын интуитив (турыдан туры кабул итүче) акылы якындагын бик ачык күрә, ләкин күзкүреме чикләнгән, читтәгене күрү сәләтенә ия түгел.”

Ул әйткән фикерләрне дәфтәренә төшереп куя да кыштыр-кыштыр лекция язган группадаш кызларына күз салгалап ала. Гуманитар бүлектә егет-малайлар бармак белән генә санарлык. “Димәк, әле болар малайлар гына... утызга житмәгәннәр, димәк, өлгереп тә житмәгәннәр”,—дип уйлый кыз.

Профессор һаман сөйли, борынгы фәлсәфәчеләрдән мисаллар да китерә, үз сүзләре белән дә сөйли, инде күптән яттан белгән фикер-цитаталарны берниндн аңлатмасыз гына аудитория өстенә сибә.

“...Хатын-кызнын гәүдәсеннән үк анын гаять зур хезмәт өчен яратылмаганы күренеп тора. Физик яктан да, рухи нисбәттә дә. Ул үзенә язылган гомерне чынбарлык белән түгел, ә газап-мәшәкатьләр эчендә уздыра: бала табу газаплары, балалар турында кайгырту, иренә буйсыну... Бу зат югары кичерешләр, көчле шатлыклар өчен яратылмаган. Ир-атка караганда анын гомере талгын-тынычрак, мәгънәсезрәк, әһәмиятсезрәк уза һәм ул аннан гына бәхетле дә бәхетсез дә була алмый.

Моннан йөз илле ел элек әйтелгән фикерләр Кәримәне вакыт-вакыт сискәндереп жибәрә.

Адәм балалары кавемен дәвам иттерү, сүндерми саклау вазифасы табигать тарафыннан яшь, сәламәт һәм чибәр ир-егетләргә тапшырыла. Бу—табигатьнен какшамас ихтыяры һәм ул хатын-кызнын кайнар хисләрендә чагылыш таба. Бу бик борынгы канун, кануннарнын аннан да элгәресе юк. Кем дә кем үз хокуклары һәм мәнфгатьләрен шушы канун белән кисештерә—ул кеше ни генә дисә дә, ни генә кылса да—анын хокук һәм мәнфәгатьләре беренче житди каршылык туу белән аяк астына салып тапталачак. Чөнки хатын-кызда бик эчкәре яктан, яшерен, кычкырып әйтелми торган, хәтта азагына кадәр төшенеп тә бетелмәгән, тик тумышыннан ук бар булган бер гакыл болай дип тукып тора.”

Яшь профессор, сүзеннән бүленеп, тәрәзәгә карап алды.Әллә Бауман урамы буйлап дөбер-шатыр чапкан троллейбуснын узып китүен көтәме, әллә хәзер әйтәчәк фикеренен гаять әһәмиятле булуына шул рәвешчә искәртүеме сон? Бәлки, вакыт алай күп тә узмагандыр, ләкин студент халкына бу бик озак тоелды, урындык-өстәлләр шыгырдый башлагач, профессор сүзен дәвам иттерде: “Безне индивидуум буларак кайгыртып, безнен аша тереклекнен бер төре (species) саналырга хокуклы булдык дип

ышанучыларны алларга хакыбыз бар безнең. Безгә иң якын торган—бездән туган буынга нисбәтле рәвештә тапшырыла һәм без чын күңелдән ул игелекне булдырырга тырышабыз". Әмма хатын-кызның әлеге югары принципны һич тә abstracto түгел, ә in concreto гына аңлый һәм аны жае чыкканда үз гамәлләре аша чагылдырудан да кулай юл күрми; ә менә аларның вөжданы күпчелек очракта без уйлаганга караганда тыныч кала, чөнки алар индивидуум каршындагы бурычларына хилафлык китергән хәлдә, үзләре югарырак кимәлдә саналган нәрсәгә—тереклек төренә тугры калу хисен йөрәкләренең иң аулак почмакларына качырып саклыйлар.

Хатын-кыз, фәкать адәм балалары кавемен арттыру өчен генә кулланылуы һәм вазифасы шуның белән тәгәлләнү сәбәпле, индивидуумда яшәүдән бигрәк, кавем эчендә яши һәм аның өчен кавем тормышы индивидуаль тормыштан якынрак. Бу хәл аларның бар булмышларын, эш-гамәлләрен билгеле бер жилбәзәклек өрфиясе белән каплый һәм үзләрен ир-ат юлыннан үзгә юлга—бик еш һәм тиз генә жимерелә торган никахлар юлына алып китә.

Лекция тәмам булганнан соң маңгай чәче пеләшләнә башлаган кырык яшьләрдәге профессор сорау-жавап кебегрәк семинар оештыра.

Кызлар профессорга быел июль аенда кырык өч яшь туласын да беләләр, фамилиясенең Иштәков, исеме—Руслан, атасының исеме Дәүләт икәнлеге дә яхшы мәгълүм аларга. Тик яшьләр профессор хакында төп ике нәрсәне ачыклый алмыйча чып-чын газап утында яналар иде; өйләнгәнме ул, юкмы, яки хатын аерганмы, аерса, ничәнче хатыны белән тора һәм милләте белән кем? Татарныкына охшамаган фамилия, аннан соң үзен "Дәүләтович" дип түгел, Руслан Даулатович дип әйтергә кушты. Кыяфәте белән грузинга да охшаган, ләкин кара тутлы түгел, киресенчә, немецлар кебек аксыл. Грузин булса, болай лекция укып йөрмәс, базарда әфлисун сатуны кулайрак күрер иде, ә немец милләтенә фамилиясе туры килми. Кыяфәтендә яһүд чалымнары да бар—менә янә фамилиясенең Иштәк булуы каршы килә.

Профессорда хатын-кызны уштан яздыра торган ниндидер "мәхәббәт магниты" бар, фәлсәфә фәненә гашыйк булганы һәм хатын-кыз өммәте хакында юк-барны сөйләгәне өчен йөрми кызлар аның лекцияләренә, әнә шул сөйкемле сөяге, мәхәббәтле кыяфәте үзенә тарта. Әлбәттә, серле булуы. Хатын-кыз өчен ир-аттагы иң мөһим, әһәмиятле, әйтергә кирәк, иң бөек сер—өйләнгәнме—юкмы икәнлеген белү. Руслан Даулатович әле аларга лекцияләрне күптән түгел генә укый башлады, ана кадәр фәлсәфәне Козловский фамилияле карт профессор укыта иде—ул Израильгә китеп барды.

Өйләнгәнме бу, юкмы! Һай, беләсе килә бит, ә!

Бүгенге лекциясендә хатын-кызны эттән алып беткә салды. Ана да ачулары килә һәм яшь профессорның бу гамәле теге "бөек серне" тагын да катлауландыра иде: "Хатын-кызны шулай юкка чыгарасыз, димәк, Сез өйләнмәгән кеше?!."

Группада Аниль исемле бик чая Казан кызы бар. Мулла кушкан исеме "Әнил" ди. Ул зур кара күзләре белән тутырып бер караса, факультеттагы ир-ат студентлар гына түгел, сакаллы профессор абыйлар да атлаган жирләреннән сөртенеп-сөртенеп киталәр.Чибәр, курчак кебек матур кыз... Анасы кайдадыр зур урында, әтисе дә галим диләр. Кәримәнең кайгысын да беренче булып Әнил ишеткән иде, ул аны кочаклап алды да:

—Пессимизмга бирелмә, Кәримә. Бар кайгыларыңны онытырлык шөгыль табармын әле мин сиңа, менә күрерсең!—дип юатты.

Ләкин Кәримәнең хәле юатулардан узган инде. Ул һәрвакыт әнисен уйлый, аны төрле халәтләрдә күз алдына китереп, жаны сызлый, күңеле сыкрый. Әнә ул читлек эчендә, япа-ялгызы, хәтта читлекнең ишеге дә юк. Бер почмакта бөрешеп утыра. Менә ул караңгы, таш идәнле камерада ята. Янында күселәр йөгерешеп йөри... Кәримә тизрәк күзләрен ачып жибәрә, ямьсез уйлардан котылырга теләп, дерелдәгән кулларының юеш уч төпләре белән битен ышкый, чигәләрен уа. Ләкин бу гына ярдәм итәрлекме соң,

ахырда кыз барыбер үксеп-үксеп сыгылып төшә...

Руслан Даулатовичның лекцияләре генә Кәримәне фани дөнья уйларыннан аерып тора шикелле. Шулар аша кыз бу болгавыр тормышны аңларга, танырга һәм шуңарга таянып, үзе кереп адашкан "караңгы мәгарәдән чыгу юлын эзләргә азаплана. Нинди генә бикле ишек булса да барыбер кайдадыр, кемдәдер аның йозагын ача торган ачкыч, тылсымлы ачкыч булырга тиештер бит инде югыйсә! Шул ачкычны бик тә, бик тә кулга төшерәсе һәм... һәм әнисен якты дөньяга чыгарасы килә иде кыз баланың...

Әлеге авыр уйларны Әнилнең яңгыравыклы тавышы бүлә:

—Руслан Даулатович, Вы наверняка знаете, поговорку, которая гласит, что петух, может быть, хорошо кукарекает, но яйца все-таки сносит курица.

Руслан Даулатович студентларының кыю-кыю сорауларын, фикерләрен ярата, ләкин үзеннән дә акыллы булганны өнәп бетермәве дә күз карашыннан ук сизелеп тора. Ул моны сиздермәскә тырыша, тик барыбер күз карашында чагылып-чагылып алган усал чаткы-мизгелләргә хуҗа булып бетерә алмый, яшь профессор моны үзе дә белә, шуңа күрә андый вакытларда аңа акыл шәрифләрен икеләтә эшкә җигәргә, шома мангаен тагын да катырак җыерырга туры килә.

—Мин сезгә Шопенгауэрның тормышка карата булган фикерләрен китерәм!—ди ул.

Ырынбур егете Заһид андый чакларда, белдеклегә салынып, гел сүз кыстырырга ярата. Заһид килеш-кыяфәт белән кызларның ушын алырлык егет түгел. Ләкин ул белә: үзенең очкынланып торган зәңгәр күзләре кызларга ошамый түгел. Әмма ул күзләр сәер рәвештә төрле якка хәрәкәтләнгәндә (күз чокырына бик яхшылап майлап тыгып куйган зәңгәр шарлар кебек) аның йөзе таш сын кебек, ник бер җыерчык пәйда булсын, ник бер керфеге селкенсен. Заһид әгәр елан булса—бу җир йөзендә бер генә бака да калмас—һәммәсе Заһид авызында булырлар иде. Елан күзләренә капма-каршы буларак, алар гел хәрәкәтләнеп торса да ул күзләрнең сихри тарту көче бар. Заһид күп сөйләшә һәм үзенең бу гамәлен кызлар бик ярата дип уйлап нык ялгыша. Хатын-кыз күп сөйләшергә яраткан ир-ат белән бик теләп гәпләшсә дә, тыныч һәм аз сүзле ир-егетләр аңа күбрәк ошый. Үзе хатын-кыз булмагач, Заһид атлы студент бу кадәресен үк, әлбәттә, төшенеп бетерми торгандыр инде.

—Руслан Даулатович, Шопенгауэр, Ницше дисез. Ницше тәгълимате белән коралланып немецлар дөньяны һәлакәткә китерә яздылар бит инде!—ди Заһид.

Руслан Даулатович әлеге сүзләргә исе китмәгәндәй генә:

—"Алтын балык" әкиятен укып та әллә нинди фантазияләргә бирелеп булыр иде,—дип әйтеп куя да озын тырнакларын кайрап утырган Әнилгә таба борыла. Бар группа белә: профессор Әнилгә битараф түгел. Ул бу хакта турыдан-туры да сиздерми, аны имтихан бирергә бакчасына да чакырганы юк; әмма студент халкы усал эт кебек сизенә—Руслан Даулатович Әнил нинди генә кирле-мырлы яки дорфа сүз-фикер әйтсә дә аның шома мангаенда ике сызык пәйда булып, гадәттә, ул бу җайсыз холыклы кызга кире кагып булмаслык дәлилләр китерергә тырыша, хәтта азапланадыр да шикелле иде. Заһидның соравыннан соң профессорның маңгаенда бер генә сызык уелып алган иде.

Күренеп тора: бүгенге лекция һәм немец фәлсәфәчеләренең хатын-кыз хакындагы кискен фикерләре кызга бер дә ошап бетмәгән иде—тырнак матурларга керешүе дә шуның өчен генә булгандыр әле. Ләкин кызның игътибары барыбер аудиториядә барган бәхәсләрдә иде.

—Мужчина единственный самец, который бьет свою самку,—диде ул урысчалатып һәм аннан соң өстәп куйды,—Шорес Куртелин сүзләре.

—Шорес түгел, Шорж... Шорж Куртелин,—дип, бик итагатьле генә төзәтте аны профессор.

—Икенче хатыны аны күсе агуы биреп үтергән.

Монысы, әлбәттә, Заһид инде. Житди сөйләшү вакытында юк-бар сүз кыстырмаса ул Заһид Заһид буламы соң?!

Руслан Даулатовичның маңгаенда берьюлы өч сызык пәйда булды! Моңа кадәрле бу хәлнең булганы да, күренгәне дә юк иде әле! Бетте Заһид, профессор сытачак аны, бүген булмаса иртәгә, иртәгә булмаса язгы имтихан вакытында! Руслан Даулатович белән Әнил арасына кысылмаска иде дә бит кана! Телен тыя алмады. Үз башына булыр, мөгаен. Әмма шул тиктормас теле Заһидны күп очракта зур фажигалардан коткарып та кала тагын...

—Ир-ат нәкъ бала-чага кебек инде ул:кулыннан тотып йөргәнне ярата, әмма шул ук вакытта, үзен зур кеше итеп исәпләргә куша.

Руслан Даулатовичның маңгае шомарды: аудитория җинел сулап куйды, димәк, Заһид бу юлга исән-сау кала икән әле. Әлеге,—кемнәрдер әйткән,— тапкыр сүз коткарып калачак аны, тапкыр сүзләр ошаса Әнил дәшмичә калмаячак иде. Ә Руслан Даулатович исә күбрәк Әнил сөйләвен тели, шуңа күрә дә Заһид сүзләреннән соң сырт йоннарын кабарткан иде өйләнмәгән ни яшь, ни әлләни карт түгел профессор абыен.

—Я согласна жить в мире, которым правят мужчины, до тех пор, пока могу быть в этом мире женщиной,—диган Мэрилин Монро.Әлбәттә, мондый гыйбарәләрне урысча китерә Әнил.

Кыз шулай диде дә, бурлаттай кызарып, куллары белән ике чигәсенә ябышты. Ни булганын аңлар ара булмады—тәнәфескә чакырып кыңгырау чылтырарга кереште.

Кәримә Әнилнең иң башына кулын салып үзенә таба тартты.

—Ни булды, Аниль! Авырыйсыңмы әллә? Кит, бөтенләй йөзең үк качты бит?!

—Авырмыйм,—диде аңа каршы Әнил өзек-өзек тавыш белән.—Бу минем әнинең яраткан сүзләре,—диде ул.

Кызлар урыннарыннан тордылар. Артларыннан чыгып килүче Заһид, кызларны аерып, икесенең арасына керде дә:

—Бальзакны тыңлагыз сез кызлар, Бальзакны. Ул менә нәрсә дигән: "Если мужчина остроумен, хорош собою и общителен, женщины интересуется не тем, откуда они вышли, а тем, куда он хочет прийти!" Ха-ха!

Әнил сиздермичә генә терсәге белән лыгырдавык группадашының касыгына төртте. Егет мондый һөҗүмне көтмәгән иде һәм авыртуын да каты авырта иде бугай, ул сыгылып калды һәм ыңгырашып:

—У-у-у! Үтерәсең бит! Кинжал белән чәнечтеңме әллә син, җен! Ай, әчем, әчем!—дип зарланырга кереште. Әнил ачулы иде, сүзләре теш арасыннан гына кысылып чыкты:

—Бәдрәфкә йөгер. Тизрәк! Чират күптер!

* * *

Уку бинасының ишеген ачып урамга чыгуга, Әнил Кәримәгә эч серен ачып ташларга тиеш кебек иде. Һәрхәлдә, Кәримә, группадашының холкын аз-маз белгән Кәримә, үзе шулай дип уйлады. Тик алар сөйләшеп китә алмадылар—Кәримә янына бер үсмер йөгереп килде дә, каршысына ук килеп басты.

—Кәримәме? Каюмовамы?

Иске-москы киемле, озын пычрак чәчле таныш түгел үсмернең бу соравы кызны тетрәндереп җибәрде. Беравык ул югалып калды.

—Булса! Шуннан ни?—дип, аның өчен Әнил җавап бирде.

Кызның усал тавышы үсмернең чак кына ачуын да китерде бугай, ләкин аның телләшеп торырга һич тә исәбе юк иде, шулай да үпкәсен сиздергән тонда:

—Син әйтмәсәң дә беләм Кәримә Каюмова икәнең. Әнисе фотосын күрсәтте. Мә!—дип, ул Кәримәнең учына кәгазь кисәге салды да вокзал ягына таба китеп, күздән дә югалды.

"Иртәгә, 12се көнне, сәгать өченче яртыда Казан вокзалында булабыз. Әниең."

Язуны аның белән бергә үк Әнил дә укыган иде, ул, аптырап, иптәш кызына карады. Хәзер сытылачак, үксеп елап җибәрчәк иде.Әнил, шуны сизепме, аны култыклап алды да тиз-тиз ишек төбеннән ераккарак алып китте,аннан соң бу авыр халәтне йомшартырга теләп:

—Димәк, Себергә, этап белән,—дип куйды.

Кызлар Кремль урамына менеп, университет каршындагы утыргычка утырдылар. Кәримә юл буе тавышсыз-тынсыз, шыпырт кына елый, күз яшьләренең бер өлеше бите буйлап тәгәри, батыр кыз калганын эчәнә йота һәм алар аның күзәнәкләренә сеңә дә тамырлар буйлап аккан яшь канга килеп кушылалардыр төсле.

Әнил бәләкәй сумкасыннан кесә телефонын алды да ниндидер номер җыярга кереште. Кәримәнең баягы тыныч күз яшьләре мышкылдауга күчә башлаган иде инде, Әнил йә юатса, йә болай гына әнисе хакында берәр сүз әйткән булса, бая ук, Бауман урамында ук акырып җылап җибәрергә әзер иде.

—Мышкылдап утырма әле, яме!—дип, Әнил ана җинелчә генә төртеп алды. Кара!.. Юатасы урынга! Иптәш кызының муеныннан кочаклап, яшьле күзләреннән үбә-үбә юатасы урынга! Бигрәк тупас бу Әнил ! Таш йөрәк! Акыллы кешеләр әйткән цитаталарны ятлап кына кеше булып булмый шул әле! Аның өчен күкрәк читлегендә йөрәк дигән нәрсәнең дә тибүе кирәк!..

—Руслан Даулатович! Сезме!—дигән сүзләр Кәримәне әлеге уйларыннан аерып, айнытып җибәрде.—Руслан Даулатович! Бүген кич буш буласызмы! Күрешәсе иде...

Кәримәнең яшь тулы күзләре гаҗәпләнүеннән маңгаена менә яздылар. “Руслан Даулатович белән кич күрешәсе бар???”

Әнил телефонын сумкасына чумдырды да, Кәримәгә карап, күз кысып куйды. Ә тегесе карга баласы кебек авызын ачып тик аптырап утыра иде.Әүвәл Әнил үзе сүз башлады:

—Борчылма, Кәримә. Руслан Даулатовичның дусты шишка! Большая, большая шишка! Әниеңне спасут!

—Как спасут!—дип, урысчалатып сораганын Кәримә үзе дә сизми калды.

—Дело техники. Впрочем, нам результат важен, а им—процесс. Тут и процесс важен, и результат важен, подружка!..

“Әнил, Әнилә, Аниль... Мәңге аңлап булмаслык, чишеп, төшенеп бетеп булмаслык сер син, дустым!”

“Дөрес уйламыйсың, Кәримә. Бернинди сер түгел мин. Хәер, серен сердер. Ләкин бер дә катлаулы түгел, гади, бик гади. Әнә, теге, газондагы яшел чирәм өстендә аунап яткан пычрак таш кебек гади. Үзе пычрак... үзе таш”.

Күнелләр сөйләшә белә. Бер кешенең күнеле икенче кешенең “телен” аңларга сәләтле. Әгәр алар бер-берсенә якын ике кеше булсалар. Бигрәк тә аларны сытып, изеп торган берүк төрле кара кайгы булса...

Бер-берсен үлеп яраткан парлар күз карашлары белән дә аңлаша ала диләр... Юк, аңлаша алмыйлар. Ялган бу. Аңлашу түгел, алар хәтта борыннары белән сулый да алмыйлар... томау төшкән була, хисләр томавы. Күз карашлары да хисләр пәрдәсе белән капланган була. Аларга әнә, теге пычрак таш та хәтта бер зур алма кисәге булып күренәчәк. Дөресрәге, шулай шәйләнер иде.

“Йа, Ходам! Нигә шул чаклы катлаулы итеп яраттың соң син җиһанны, бәндәләреңне!”

“Мин?! Бәндәләремне? Җиһанны? Юк, бәндәләремнең адәм булганнары сез алай ялгышмагыз! Мин яраткан дөнья бик гади иде. Һәм ул табигать әнкәгез кануннары белән генә яшәргә тиешле иде”.

“Алайса нигә көчлерәк бөҗәгең көчсезен җәберли яисә тамагы ач икән, тотып ашый ук? Нигә бүреләрең куяннарны ботарлый?”

“Яшәү - көрәш ул! Ә көрәш кешелекнең бердәнбер энергия чыганагы.

Ул булмаса, хәтта кояш та сүнәр, ай да калыкмас иде. Ләкин ул көрәш гадел көрәш иде. Кагыйдәләре хак иде аның. Сез көрәш кагыйдәләрен үзегез боздыгыз. Әүвәл бер бәндә бозып җибәргән иде, аннан күреп икенчесе, өченчесе... хәзер исәбе-хисабы юк инде".

"Иң дөрес һәм тугры дин Ислам дине булыр. Без, мөселман бәндәләре, шулай дип инандык. Христиан, будда һәм башкалары нигә хаҗәт иде соң?"

"Куркыныч, каты яшеннән соң һавалар сафланып кала. Бәндәләр үпкәләрен тутырып, рәхәтләнеп сулый башлыйлар.

"Яшәү" көрәш дидем. Көрәшне сез уен дип тә атыйсыз. Һәр уенның да көрәшнеке кебек үк үз кагыйдәләре була. Дин, мин, син—башка мәсьәлә. Сез менә үзегез уйнаган уенның кагыйдәләрен генә бозмагыз!"

Ходай тәгалә үзеннән ерак булганга күрә адәм баласы язмышын һәрдаим алдаларга тырыша. Ләкин Ходайның фәрештәләре һәрвакыт адәми зат янында икәнлеген исеннән чыгара...

...Чал университет каршындагы мәйдан Казанның иң биек урыныдыр, мөгаен. Күккә иң якын нокта да шушында микән әллә?..Югыйсә, күкләр белән болай турыдан-туры сөйләшеп булыр идеме икән?..

Һай, пинжәген җилкәсенә салган таш сынны кешеләр теге чакта, узган гасыр уртасында, моны үзләре дә аңламыйча, бик хаклы рәвештә куйганнар! Ул элек һәйкәл булса... хәзер кара багана хезмәтен үти. Хаталанмагыз, адәмнәр! Менә бу бәндәгез кебек уенның кагыйдәсен, табигатьнең кануннарын боза күрмәгез, зинһар! В.И.Ульяновка һәйкәл түгел ул, Сабак-һәйкәл!

Ул һәрвакыт һәр адәмнең хата җибәрергә сәләтле икәнен күрсәтеп, исегезгә төшереп торсын.Бу үзгәртеп кору дигәннәрне үзенең билгеле бер ноктасына җиткәч, мавзолейдан ук чыгарып ташламасалар ярый ла!? Аның мәетен хәзер этләр дә ашамас инде...

...Фәлсәфә лекцияләреннән соң баш миләрен сәер фикер-микерләр тәмам шулпаландырып бетерә, билләхи!.. Әллә нинди бөек ачышлар ачылып ташлана шул чакларда! Йа, Хода! Үзең ярлыка инде син бу кыз балаларынны!!!Ә менә аларның бүген кич кылыначак гөнаһ-гамәлләрен кайчан да булса ярлыкый алырсыңмы соң?..

Хатын-кыз ике төрлегә бүленә: кайберләре тормыштан тәм табарга сәләтле, икенче бер төрлесенең бар белгәне гел зарлану, сукырану.

Уйлар ачык форточкадан өйгә бәреп кергән шарлы яшен кебек. Урамга кире чыгып китмәсә, яндырачак, шартлатачак. Тизрәк ишегенне, йә булмаса тәрәзәнне ачып куй әле син! Кайдан килсә—шунда китсен! Алайса шартлавын бар, бахыр...

Әнә, университет колонналары яныннан узып баручы көяз ханымга игътибар ит!

—Әнә, минем әни!—дип, терсәк очы белән төртеп алды Әнил.

—Ничек синең әни? Алайса нигә дәшмисең?! Әйдә, куып тотабыз.

—Хәзер куып тотабыз,—диде Әнил тыныч кына. Әмма үзе урыныннан да кузгалмады, киресенчә, эскәмиядән күтәрелә башлаган Кәримәне җиңеннән тартып кире утыртты. Ул кесә телефонын сумкасыннан янадан чыгарган иде, усал көлемсерәп, номер җыярга керешгә. Көяз ханым кул сумкасыннан телефон алып колагына куйды.

—Алло! Мам! Привет! Ты когда домой придешь?

Көяз ханым:

—Исәнме, кызым! Син нигә бу вакытта өйдә түгел әле? Сотовыйдан бит син?

—Әйе, өйдә түгел әле мин, мам! А ты когда придешь?

—Кызым, миленькая, я сегодня немного задержусь после работы, ладно, скажешь папе.

—Ты сейчас на работе?

—Да. А что?

—Ничего, мам. Так просто! Пока, мам!

—Пока, пока, дорогая!

—Хахаль янына бара,—диде Әнил тыныч кына.

—Ничек! Син нәрсә, Аниль?! Юләр сүзләр сөйләмә инде!

—Юләр сүзләр сөйләмим мин, подружка! Киләсе атнага этинен защита. Докторский. Ученый совет Мәскәүдә. Эти язган темага бары тик Мәскәүдә генә яклап була. Әни айлар буе Мәскәү юлын таптады инде. Блат имеет. Хәзер ул Мәскәү бабае янына бара. Гостиницага. И бүген төнлә генә кайтачак. В лучшем случае поздно вечером. Она умная, красивая. Смотри, какая походка красивая, правда, да?!

Әнил үзеннән көләдер дип уйлап, авызын турсайта башлаган иде, ләкин тегесе шундук аның баш миен сафландырып җибәрде:

—Ышанмасаң, әйдә артыннан барабыз. Мин хәтта кайсы номерда булачакларын да беләм. За то мой бедный папа удачно защитит свой докторский, возможно потом его поставят проректором. Если нет, мамочка поможет. Она у меня красивая! Ой, юк, подружка, безнең алар артыннан тикшереп йөрергә вакыт юк, безне Руслан Даулатович көтә. Киттек!

Кыз сикереп торды да Кәримәгә кулын сузды. Әнилнең куллары дерелди, күзләре дымлы иде. Кәримәнең аяк буыннары йомшарды, ул атлый алмас булды. Өстәвенә Әнилгә дә ачуы басылмаган иде әле.

—Син! Син! Ничек?! Ничек! Үз әниең турында шундый пычрак сүзләр сөйли аласын!!!—дип кычкырды ул, кулын кире тартып алып. Бу мизгелләрдә Әнилнең йөз-кыяфәте кара янган, сүзләре ачы, үтергеч иде.

—Ә синең әниең ничек шулай эшли алган соң?!!

—Этине... этине терелтергә акча кирәк булганга бит ул! Аптыраганнан, гаҗиз булганнан! Син! Син! Минем әниемә тел тидермә! Ул этиемне бик ярата минем.

Әнил аңа карап мыскыллы көлде дә:

—Успокойся, девочка! Минем әнием дә этиемне бик ярата! Эти докторскиен якласын дип тырышып йөрүе генә бит. Этигә докторскийны яклаттырмасалар, ул—бетәчәк!

Кәримә бераз тынычланган иде инде.

—Ничек бетәчәк?—дип сорады ул аннары.

—Эчеп... Минем эти голова! Он очень талантливый физик! Ләкин аңа үсәргә ирек бирмиләр! Хәтта әнинен кандидатскиен да эти язып бирде. Яклавын әни үзе яклады. Эти яза, әни яклый. Икесенә дә Ходай ике төрле талант биргән.

Әгәр бу докторскиен якламаса эти эчүгә сабышачак! Әни аны ярата. Зур кеше булуын тели. Йә, ярый, разболтались тут! Киттек! Вакыт юк! Руслан Даулатович көтә торгандыр.

"Мин Ходайдан һәм үз-үземнән генә куркам",—дип куйды кыз үзалдына.

Китсеннәр. Кызлар ашыга. Ә безнең вакыт бар. Без Әнилнен әнисе—колонналар яныннан узган чибәр ханым артыннан иярәсе иттек. Әнилнең ачулы чагы—телсез сөяк ни сөйләмәс?..Үзебез тикшереп карыйк...

Әдилә Кремль урамыннан "Сәфәр" кунакханәсенә чаклы машина тотты. Кунак аны түземсезләнеп көтеп тора иде инде. Ишектән килеп керүгә киемен салырга булышып, шкафка элде. Мәскәүдә чакта үзен бик иркен тота торган Козлов (Әдилә ханым профессорны фамилиясе белән атый) Казан жирендә үзен ничектер уңайсызрак сизә һәм, үзенең бу халәтен чибәр ханымга күрсәтмәс өчен, бертуктаусыз сөйли, киеренкелекне шул рәвешле йомшартмакчы була иде, күрәсен.

—Тәрәзәдән Казанга сокланып тордым әле. Гаҗәп күренешләр, гаҗәп! Казан искиткеч үзгәргән. Яшь чакта минем Казанны төсле открыткалардан күргәнем бар иде.

—Абрам Ильич, Сезнең Казанга беренче тапкыр гына килүегезме?—дип, гаҗәпләнгән булды Әдилә ханым, гәрчә Козловның Казанда яшәп алганын белсә дә. Сугыш вакытында этисе, ниндидер юлын табып, гаиләсе белән Казанга хәрби заводка кучүгә ирешә, аннары фәнни институтта эшли.

—Кырыгынчы-илленче елларда Сталин заманы Казаны иде ул. Минем аны искә төшерәсем килми,—дип җавап бирде Абрам Ильич ханымның соравына.

Абрам Ильичны Әдилә кунакханәгә үзе урнаштырган иде, аның килүенә ресторанннан ризыклар керттерде. Бүген өстәл төрле тәм-томнар белән тулган. Абрам Ильич аны җилкәсеннән кочып алды.

—Казанның кызлары матур була.

Әдилә карт яһүднең инбашы аша өстәл өстендәге тәгамгә күз салды һәм эсселе-суыклы булып китте—француз шәрабы юк иде, күрәсең, онытылгандыр. Бу очракта ул кунагы өчен түгел, күбрәк үзе өчен борчылды: димәк, коньяк эчәргә туры киләчәк. Коньяк каты, ул хәзер баш мие күзәнәкләрен чәчеп-таратып ташлый, икенче көнне көне буе шуларны җыеп, тәртипкә салу белән шөгыльләнәсе була. Бөтенләй эчмәсәң? Һе, бөтенләй эчмәсәң... ничекләр итеп бу карт профессорның гел сөяктән генә торган аркасына массаж ясыйсың!? Шулчак Әдиләнең башына кылт итеп бер шәп фикер килде һәм ул әлеге фикернең нәкъ менә аңа иң кирәкле вакытта ярдәмгә килүенә сөенеп бетә алмады.

Абрам Ильич диссертациянең шәп язылуы турында фикер әйтте һәм тиздән совет утырышын җыячакбыз диде. Әдилә өчен бу бик зур яңалык булып, ул шатланырга, куанырга тиеш иде һәм моны Абрам Ильичка да ачыктан-ачык сиздерергә бурычлы иде бу мизгелдә. Ләкин теге хәерсез уй һаман гакылын кимерә, "Ничекләр итеп коньяк эчәрмен?" Ул уйларының теленә чыкканын үзе дә сизми калды.

—Шәраб алып керергә әйтергә онытканмын. Мин ресторанга шылтыратып алыймчы, Абрам Ильич,—диде ул, итагатьле генә якланачак диссертация өчен рәхмәт әйткәннән соң. Ләкин бу вакытта Абрам Ильич, ике чәркәгә коньяк коеп, берсен Әдиләгә сузып маташа иде.

—Өлгерербез, Әдилә Мәннәфовна, өлгерербез. Иң яхшы закуска синең иреннәрдәге француз помадасы. Француз помадасы белән бергә кушылгач, бу француз коньягы затлы шәрабкә әйләнәчәк.

"Гафу ит, Фәнилем",—дип пышылдады ул шул мизгелдә нигәдер ирен күз алдына китереп. Белә иде хатын, алдан күрә: коньяк аны җебетеп ташлаячак!.. Эчкән хатын-кыз өчен иң беренче кабымлык—аның гакылы, беренче чәркәдән соң ул аның яртысын "югалтса", икенче-өченчесеннән соң кабымлык урынына, әнә, өстәлдә өелеп торган йөзем җимешләре, конфетлар гына калачак. Хәзер хатын-кыз иданне кулына чүпрәк тотып юмый... Тузан суырткыч... мәгәр чүпрәк тотып юса... бәлкем, идән чүпрәген күз алдына китерер иде, үзен шуның белән чагыштырып караса, күңеленең бер читендә булса гына да горурлык дигән хис уяныр иде дә...

Эттән тугандыр бу хатын-кыз өммәте... Югыйсә, шул мизгелдә үк котылу юлын таба алмас иде. Карт яһүд кесәсеннән кульяулык алып бик пөхтәләп ханымның иреннәрендәге помадасын сөртеп торган арада (помада кабымлыкка булыр дигән иде үзе!) шалт-мөхәмматҗан, аның түм-түгәрәк башкайларына янә бер шәп фикер килеп кунмасынмы!

—О-о-о!! Абрам Ильич, гафу итегез, мин онытып та торам икән ич. Мин Сезгә сюрприз әзерләдем бит әле!

Абрам Ильич чәркәсендәге эчемлекне чәй эчкән кебек шупырдатып чөмереп куйды да Әдиләгә текәлде.

—Сауна... Менә дигән сауна әзерләп куйдым бит мин сезгә. Шундый хөрмәтле кеше Казан чаклы Казанга килеп массаж алмыйча китмәстер инде шәт!

Ул тиз генә телефонга үрелде һәм кайсыдыр мунчага шылтыратты, икенче шылтыратуы таксига иде.

Абрам Ильич су ярата торган кеше булып чыкты. Казанда торганда аларның бакчалары да Казансу ярында ук булган икән, хәзер Яңа Савин районы җирендә, йөзмә күпер читендә үк. Анда Казансу аша яңа күпер салыначак.

Номер иркен иде. Чиста, пөхтә. Әдилә ханым бу номерга иптәш хатыннары белән еш йөри, һәм Казанның бар гайбәте шунда чәйнәлә-

чәйнәлә дә, тәмам мунчалага әйләнгәннең соңында, юылып, чистарынып, шулардан арынып чыга иде алар. Гайбәт чүлмәкләре тула башлагач, әлеге дус дүрт хатын янә җебенергә җыеналар. Люкс номерда бар нәрсә дә кеше өчен эшләнгән иде. Саунадагы такталарына кадәр сап-сары юкә... Такталардан тезелгән ләүкә,күн диван, душ кабиналары.

Әдилә ханым, ишекне эчтән бикләп алгач, массаж ясаучы кызга анадан тума чишенергә боерды. Унҗиде яшьлек чибәр чуваш кызы аның үзенә караганда да кыюрак булып чыкты: иң беренче чишенеп ташлап, массаж өстәле кырыена хуш исле төрле крем-майларын тезеп куйды да, душка кереп чыгып, иненә сөлге салды һәм Абрам Ильичның чишенгәнен көтеп тора башлады. Әдилә, плащын салып элде дә, телевизорлы бүлмәдәге күн кәнәфигә чумды.

Вакыт бик озак узадыр кебек тоелды аңа.Ниләр генә уйлап бетермәде шул арада Әдилә Мәннәфовна. Тиздән доктор булачак ире турында да, буйга җиткән студент кызы Аниль хакында да. Шунысы гаҗәп, үзенең кунакханәдәге баягы кыланышларын исенә төшереп, хәзер үз-үзеннән көлә иде ул. Ник фикере кинәт үзгәрде соң әле? Югыйсә, ул саунага да кермәде—фикерләре җебемәде, коньяк та эчмәде—баш шәрифләре чуалмады. Әллә... әллә... яшь кызның күкрәкләре арасына борынын төртеп күн диванда утырган ир сыныгы гаепләме моңа!?

Адәм баласы организмының нигезен табигый күзәнәкләр тәшкил итә. Алар гакыл биләмәсендә. Шул биләмәдән беркая да читкә чыга алмыйлар. Гакыл—сакчы. Ышанычлы, сау-сәламәт сакчы. Бер чәркә эчемлек гакылны җебетеп, хәлсезләндерәчәк, уяулыгын югалттырачак. Иренә бер хыянәт итеп караган хатын-кыз яшь, сусыл уҗым түмен татыган мәнсез сыер хайваны кебек. Улагына алтын башак салсаң да, аның "койрык очы" һәрвакыт уҗымга тартачак. Рухи көчне кыргый инстинкт таптап, сытып китә ала.

Әдилә ханым "әһ" дигәнче чишенеп атты да, рәттән ике чәркә коньяк эчеп, шоколад капкалады һәм каты эчемлек киндек турысына төшеп җитеп, кымырҗый, кыздыра башлагач, массаж бүлмәсенә чыкты һәм аның карт яһүденә сөлек булып ябышкан кызны, шәрә иңбашларыннан каптырып, куптарып алды да саунага куып кертеп җибәрде...

—Ты слишком красива!—диде Абрам Ильич баш бармаклары белән ханымның күкрәк башына орынып.

"...что бы быть нормальным человеком",—дип дәвам итте әлеге фикерне баш мие парланган Әдилә Мәннәфовна.

## Аклану

Мин түрә ханым белән карт яһүд турындагы бүлекне яздым да, автор буларак, үз-үземә ачуым килеп, каләмемне читкә тотып аттым. Ни хакым бар соң минем бар хатын- кызны да бер чыбыкка тезеп чыгарга! Ниндидер фәлсәфәчеләрнең фикерләренә таянам, имеш, әллә кайчан күзгә чалынып, хәтердә калган тапкыр сүзләрне файдаланып, геройларымның гамәлен пычәтләп барам, имеш!.

Минем кияүдә дүрт сеңлем бар.Шушыннан соң аларның күзләренә ничек күренермен?!Нигә мин, иҗат итә башланган романымнан бүленеп, әлеге бәян-кыйссага тотындым соң әле?

Әнә, шундый уйлар битәрләргә керешә мине. Һәм кульязмамны язу бүлмәсендәге шкафның бер караңгы почмагына тотып аттым.

Бу вакыйгадан соң берәр атна вакыт уздымы икән, урамда элеккеге сабакташым Ырынбур егете Заһидны очраттым. Ул миңа фаҗигале яңалык җиткерде. Безнең бүлек кызы Әнилне кичә кич ниндидер машинага утыртып алып киткәннәр дә... Әйе, әйе суынып беткән шәрә гәүдәсен Салмачы бистәсе янындагы урманнан табып алганнар...

Мин бик каты тетрәндем. Башыма күсәк белән суккан кебек булды. Берничә көн гел шул хакта гына уйлап йөрдем. Аңыма килгәндә минем өчен янә яңалык ачылган иде:әлеге кыйссада бер героемның прототибы да

нәкъ шул Әнил үзе иде бит инде һәм... Һәм төп образ аның туганнан туганы Камилә. Шул кызларның язмышларын сурәтләгәнмен бит мин!..

Бу әсәр хатын-кызның һәммәсен дә бер чыбыкка тезү максатыннан язылмый. Үзем дә хатын-кыз дөньяга тудырган җан иясе. Күп кызларның гөнаһсыз яшьләренең сәбәпчесе бит... үзем дә... Шуларның, берәрсенең, каргышлы күз яшьләре тоткандыр да әле мине?.. Юкса, яшем утыздан узып китте, һаман өйләнә алмыйча йөрим.

Бер караганда, Австралия феминисткаларының дозунг-чакыруы мина тач туры килеп тора инде:

"Әгәр ир атны тотсагыз, күтенә тибегез!.."

## Фагыйләтен–тайбәтен...

Руслан Даулатович янына барудан бик курка иде Кәримә. Лекция-семинарларда гына күрергә ияләшкән укытучына ничекләр итеп үз тормышыңны ачып салмак кирәк? Унайсыз бит, ояты ни тора?! Ләкин бармыйча чарасы да юк... Әнисе хакына бит...Бу көннәрдә ул газиз әнкәсе өчен ут-суларга керергә әзер. Әйе, ул аны әүвәл каргады, сүкте, күралмас дәрәҗәгә җиткән иде. Ул бит... ул бит акча эшлим дип... Сәгыйт Сәетович кап-корсакларының күнелен күргән ләбаса... әтисенә хыянәт иткән. Кәримәнең урын өстендәге әтисен коткарам, аякка бастырам дип... шул ук әти кешегә хыянәт иткән!?

Ул көнне... дөресрәге, ул хәерсез кичне... Аракы чөмерә-чөмерә дуңгыз хәленә килгән өч хайвани зат... өчесе берьюлы мыскыл итәргә уйлагач, Фәгыйлә, хурлыгына түзә алмыйча, хәер, бәлкем, үз-үзен белештермичәдер: кухнә пычагы белән бер кунакның корсагын тишеп агызган булган. Теге бәндә үлүен үлмәгән үзе—эчәкләрен кире җыеп алып өлгергәннәр. Алай гына булса, бәлкем, эшне зурга ук та җибәрмичә йомарлар иде. Ләкин үткен пычак түрә-бәндәнең "җан җирен" дә яртылаш кыеп төшерергә өлгергән икән шул.

Фәгыйләне утыртып куйдылар...

Менә хәзер шушы вакыйганы укытучы кешегә сөйләп бирергә туры килер микәнни, Ходаем!..

Ләкин янында атлаган Әнил аңа уй дөньясында алай озаклап хисләнергә ирек бирми.

—Акча кирәк булачак, күп акча!—дип куя Әнил Кәримәгә күтәрелеп карап.—А может кирәк тә булмас әле.

Кәримә аның әлеге сүзләреннән берни төшенми, шулай да шәрехләвен сорамый, Әнил барысын да үзе аңлатып бирәчәк.

—Синдә нинди эчке киемнәр?

Нинди мәгънәсез сорау бирә инде бу тагын?! Нәрсә булсын—трусик та лифчик инде!

—Нинди төстә дип сорыйм?

—Зәңгәр... нигә!?

—Кара булса, эффектлырак...и кара колготки...

—Син нәрсә, Руслан Даулатович белән постельгә ятырга кирәк булмаячактыр ич?!—дип сорады күзләре зур булып ачылган Кәримә.—Мине... кем беләндер постельгә салырга уйламыйсындыр ич!!! Тогда... пошла ты к черту, яме!

Кәримә атлавыннан капылт туктап калды. Аның аяк буыннары дерелдәргә керешеп, хәлсезләнгән, аягында көч-хәл белән генә басып тора, менә-менә—егылып китәр төсле иде.

—Әниең хакына дамы!?

—Причем монда минем әни?

—Аны коткару өчен,—дип шәрехләде Әнил гап-гади генә итеп, ләкин бик аңлашылырлык җөмләләр белән.

—Аниль! Син...син чынлаптамы?

Әнил, капылт туктап, группадашының йөзенә күтәрелеп карады да,

Кәриманең мәет тәсе кергән кыяфәтен күреп, кычкырып көлеп җибәрде, уз итеп, яратып аның җилкәсеннән кочып алды.Әллә шаярта, әллә чынлап сөйли иде Әнил, ул тагын Кәримәгә ят булган табышмакка күчте:

—Неужели, син... кыз кеше әле?! Бер дә ир-ат белән йоклап караганың юкмыни соң?—дип сорады ул, бу юлы җитдиләнеп.

Кәримә беренче сыйныф баласы укытучысының соравына уйламыйча-нитмичә җавап биргән кебек :

—Әйе... Нигә?—дип куйды.

—Девственницалар кыйммәт тора!

—Аниль!—дип кычкырып җибәрүен Кәримә үзе дә сизми калды. Бауман урамы буйлап ваемсыз агылган халык төркеменнән кемнәрдер аларга таба борылып карады. Шулчак каршыларына әзмәвердәй ике егет калыкты.

—Девчонки, хотите заработать? Пошлите с нами!—дип бәйләнде берсе, бакыр сыман оятсыз карашын әле Кәримәгә, әле Әнилгә күчереп. Кәримә курка калды, аяк буыннары капылт йомшарып, тез астының хәле киткәндәй булды. Әнилнең генә исе китмәде, ул каршысында басып торган әзмәвернең берсен юлыннан төртеп җибәрде де:

—Пошел вон!—дип, юлын дәвам итте, икенче кулы белән Кәриманең кулыннан эләктерде. Мондый кыюлыктан егет кисәкләре үзләре дә каушап калганнар иде бугай, бәйләнеп артларыннан иярмәделәр.

—Руслан Даулатовичка ошаячаксың син. Ул сиңа ярдәм итәчәк!

"Гөнаһсыз кыз бала булганым өченме?" дип сорарга Кәриманең батырлыгы җитмәде.

Руслан Даулатович кызларны институт ишеге янында урамда көтеп тора иде. Кәримә шундук игътибар итте: профессор киемнәрен алыштырып өлгергән, костюм-галстукларын салып, хәзер ул соңгы модалы киемнәрдән иде. Бу киемнәрдән ул хәйран яшәреп тә киткән, хәтта тавышында да көндезге таләпчән кырыслык калмаган төсле: әйтерсең, кызлар белән бергә укып өйрүче өлкән курс студенты гына...

Ни гаҗәп: килеп җитешкә, Әнил Руслан Даулатовичны култыклап алды, әйтерсең, кинога барырга чакырган егете!

Алар Кәриманe чак кына артта калдырып, алданрак атладылар: Кәриманең йомышын әйтү өчен Әнил махсус шулай иткән иде. Ул иптәш кызының кызу-кызу сөйләвеннән берни дә аңламады диярлек, дөресрәге аның ни әйтүе әһәмиятле дә түгел кебек иде. Руслан Даулатовичка хәлне сөйли торгандыр—инде катлаулы төенне чишү өчен аның тиктормас теле тагын нәрсәләрдер әйләндереп чыгара икән—берни кылып булмый: ул ана үзе риза булып иярде, гәрчә Әнилнең баягы юклы-барлы куркыныч сүзләре кара мәче кебек аның эчен тырнап тора, гәүдәсендәге калтырау бер кимегәндәй була, беравыктан тагын отыры көчәеп, тез буыннарын йомшарта, аякларын калтырата, бәлки шул сәбәпле артта кала, аларга ияреп бара алмый торгандыр да әле... Руслан Даулатовичның сүзләрен ачыгырак ишетәсе килә иде аның: "ярар" диярме икән яисә итагатьле итеп кенә кире кагармы? Андый хәл була калган очракта Кәримә үзе, Руслан Даулатовичның икенче ягыннан эләктереп алып: "Мин риза, Руслан Даулатович!"—дип, сүзгә кушылырга әзер торырга уйлады. Ничек итеп кенә булса да аны ризалатырга, ничекләр итеп кенә булса да "юк,булмый" дигән сүзне әйттермәскә иде бит канә!!! Чү, туктап тор әле.... "Мин риза" дип, сүзгә кушылырга әзерме соң мин?!Нәрсәгә риза икәнлегенне үзең дә белмәгән килеш...Әйе, нәрсәгә риза?..

Кәримә шул уйларын тагын бер кат күнеленнән кичерде дә башын түбән иде: нигә үз-үзен бимазалый - нәрсә икәне мәгълүм бит инде, көн кебек ачык...

Урам почмагында Руслан Даулатовичның машинасы тора иде. Алар шунда утырдылар.Арткы утыргычка кереп чумган мәет кыяфәтендәге Кәримәгә Әнил "Все нормально!" дип пышылдарга өлгерде. Шуна күрә ул бу минутларда үзе түгел, әледән-әле тәне эсселе-суыклы булып китә, йөрәге

лепер- лепер тибә, ул йөрәгенең тавышын ишетә, типкәнен ишетә, ләкин ни әйткәнен ишетми—йөрәк сөйләшә белми, белсә, ни дип әйтер иде икән? Ачуланырмы, әллә хуплармы бу гамәлләрен! Кая хупласын инде, хупласа, бу чаклы каты типмәс, күкрәк читлеген ватардай булып сикермәс иде. Каршы ул... Бәлкем, сөенеченнән шулай жилпенә торгандыр, ә? Әнисен уйлап борчылган чакларында йөрәге гел авыртып кысылып-кысылып куя торган иде бит... Бәлкем, хәзер тынычланыр, бар да әйбәт булгач, әнисе котылып ирекка чыккач, борчылырга бүтән сәбәп тә калмаячак бит, югыйсә? Йөрәге дә тынычланып калачак. Бәлкем, шуларны уйлап, алдан ук жилпенә торгандыр ул, бахыр?..

"Күп дигәндә тагын бер айдан!.." Әйе, әйе нәкъ шул вакыт эчендә Кәримәнең әнисе ирекка чыгачак! Һәрхәлдә ана шулай дип вәгъдә иттеләр...

Руслан Даулатовичның берүзенә өч бүлмәле фатир. Аның берсе китап киштәләре белән тулган, стенасында китап шкафы булмаган ярты метр да урын калмаган. Анысы профессорның эш бүлмәсе дә икән. Калган бүлмәләрнең берсе кунаклар кабул итү өчен, бәләкәйрәге йокы бүлмәсе.

Әнил, кесә телефоны шылтырауга, каядыр китеп барды. Тик өйгә кире кайтам дип әйтмәде.Алар Руслан Даулатович белән фатирда икесе генә калдылар, буйдак профессор һәм яшь студент кыз. Руслан Даулатович телефоннан хәбәр көтте. Ул хәбәр Кәримәнең әнисенә бәйле иде, шуңа күрә Әнилгә ияреп кайтып китү хакында ничектер уйламады студент кыз, әйтерсең, профессорына имтихан бирергә килгән; әллә ялган, әллә чын: чибәр студент кызлар зачет яки имтихан куйдырыга бакча-дачаларга йөри икән дип тә ишетеп белә иде. Юк, алай булмас!Менә укытучысы ана бик жинел генә сорауга жавап бирергә кушар да, ул тиз генә киенеп, рәхмәтләр укый-укый, үзенен шыксыз тулай торагына кайтып егылыр.Буйдак профессор болын чаклы фатирында япа-ялгыз башы торып калыр. Чөнки аның вакыты юк, профессорның үз фәнендә яна ачышлар ясыйсы бар...

## "Ахырзаман башы"

Яшь профессор студент кызның эчке калтыравын сизде булса кирәк, әллә Кәримәнең тышкы кыяфәте чынлап та куркак куянны хәтерләтә иде инде, жинелчә генә өстәл әзерләде, кофе кайнатты, кызга исә, буш утырмасын өчен, "теләсәң, китаплар белән таныша аласың" дип, ымлап, үзе бик озак кына кухня ягында югалып тора иде.

Тыш-кыяфәте белән генә түгел, хәтта бар халәте белән бу мизгелләрдә чынлап та бүре авызына керергә әзерләнгән куркак куянны хәтерләткән кыз, Руслан Даулатович аны бала-чагага саный һәм шуңа күрә юата, тынычландырырга тели дип уйлап, чак кына турсайды, үпкәләгән сыман да булды; үзенең куркак куян түгел икәнлеген расларга теләгәндәй— "Булышыйм!" дип, әүвәл кухня якка да кергән иде, профессор итагатьле генә кире какты—"Юк, юк, мин үзем. Син, әнә, китаплар караштыргалый тор!"

Руслан Даулатович, үзе кабатларга яратканча, шактый катлаулы язмышлы кеше иде.Аның әбисенең әнисе—карт әбисе,—узган гасыр башында Урта Азиягә могаллимәлеккә чыгып киткән яшь татар кызы,—шунда бер үзбәккә кияүгә чыгып, төпләнеп калган Казан арты татары. Бер-бер артлы дөньяга килгән уникe кызның язмышы һич кенә дә бер-берсенә охшамаган—кайсы шундагы үзбәк-казакъларга кияүгә чыгып, чит милләтләрнең дәвамчылары булып, сенеп-эреп беткәннәр. Руслан Даулатовичның әбисе исә үзбәк егетенә тап була. Шуннан соң аның нәселендә янә Кырым татары бар, соңгы буыннары тагын Гайнә татарлары белән кушылып киткән.

Руслан акыллы, чибәр егет булып үсте. Заманында Ленинградтагы югары уку йортларының берсендә фәнни коммунизм факультетын тәмамлаган егетне зур түрә булыр дип фаразладылар. Ләкин ул, барысын да шаккатырып, фән юлыннан китте һәм үзе мондый һөнәр сайлауга бер дә үкенми иде.

Гадәттә, төгәл фәннәрдә генә зур ачышлар ясап, дөньяга танылырга мөмкин. Әмма безнең Руслан Даулатович нәкъ менә гуманитар фән өлкәсендә дөньяви ачыш ясарга хыялланган бер исәр галим иде. Фәнни коммунизм факультетын тәмамлап, инде бу түрә булып китәр дигән өметләрне өзеп, укырга, янә белем эстәргә дип, икенче уку йортының биология факультетына барып кергәч алды ул "исәр" дигән исемне. Үзенә тагылып йөргән әлеге исәрлек егеткә бик охшый, чөнки белә, күреп тора бит: исәр булмаган адәм беркайчан да дөньяви ачыш ясый алмаячак!

Хәтта аның сөйгән кызы да бар иде. Хәтта ул сөйгән кызының зур урыннарда теш казып утырган түрә ата-аналары ярдәме белән тормыш дигән бу фани дөньяның иң бөек ноктасына менеп, шуннан гына бер кайгы хәсрәтсез дөньяның арт ягына тибеп яши ала, хәттә аңа дөньяви ачыш ясарга да комачаулык итмәячәкләр иде. Ләкин...лəкин.Тормышның шул "ләкин"нәре булмаса әгәр... Өйләнешеп ике-өч ай узмагандыр, аның сөекле хатыны бер дә бер көнне кайтып керде дә—"Руслан, мине факультетның деканы итеп сайларга (куярга иде дөресрәге) исәплиләр ",—диде. Бу вакытта алар икесе дә Петербургта бер югары уку йортында укытучы, фәннәр кандидатлары иделәр.Әлбәттә, хатынны зур урынга түрә итеп куюларына сөенергә генә кирәк булгандыр. Руслан әүвәл куанды да кебек. Ләкин яши торгач, бу сөенечләр яшь ир-атның күнелендә көенечләр белән алмашына барды. Хатынның эштәге түрәлек "холкы" өйгә дә ияреп кайта башлагач, ир кинәт кенә "тәртәгә типте"—Азия мохиты белән сеңгән "патриархатлык" галәмәте көнкүреш тормышының гап-гади мәсьәләләре белән дә килешергә теләмәде бугай—түрә хатын белән юллар, бер чатка җиткәч, икегә аерылып, төрле якка китеп бардылар.

Яшь, чибәр ир тора-бара докторлык дәрәҗәсе алды, профессор булды, тормышында төрле-төрле хатын-кызлар да очрамады түгел. Ләкин ул яши-яши һаман бер нәрсәгә гаҗәпләнә бара: җәмгыять эт җамаягы кебек әйләнгән, асты-өскә килгән, кайчандыр үз җаена гына тәгәрәгән тәгәрмәчне кемдер таудан этеп төшереп җибәргән һәм ул бер түмгәккә туры килеп, хәзер туры юлын үзгәрткән дә, упкынга таба барып маташа кебек иде.

Кәримә исемле иде Руслан Даулатовичның беренче хатыны... Беренче хатыны гына түгел, күңелен, бәгырь телемнәрен уеп алган мәхәббәте дә! Яшь егетнең җанында туган иң тәүге, иң садә хисләр шул кыз белән бәйләнгән иде. Ул аны акылы белән түгел, күңеленең иң-иң нечкә хисләрен кушып яратты. Алар тагын кушылдылар, әмма бәби табуга кадәр барып җитә алмадылар—Кәримә, докторлыгын яклап, шул араларда аны проректор итеп куясылар иде—бәби алып кайту арткырак планга күчеп торды. Тагын икесе ике якка киттеләр. Әмма бер шәһәрдә яшәделәр, төрле уку йортларында эшләделәр. Сирәк-мирәк кенә булса да күрешәләр дә иде. Туган көннәр, бәйрәмнәр гел бергә узды. Икесе дә нәкъ печән өстендәге эт кебек иделәр: ерагаеп та китмәделәр, кушыла да алмадылар. Һәм мондый хәл озакка да сузыла алмас, кайчан да булса барыбер бер чиге чыгар дип уйладылар күнелләреннән генә.

Андый чик булды, бер дә көтмәгәндә һәм бик сәер, гайре табигый рәвештә. Бердән бер көнне Русланга докторлык дессертациясен яклау турында читтән тәкъдим ясалды, ул әле аны-моны уйлап житкергәнче, тәкъдим артыннан бик тиз генә яклау да булып узды. Дөрес, аның бу вакытта үз темасына монографиясе дә,саллы гына фәнни мәкаләләре дә бар иде. Фәнни җитәкчесе Аркадий Ильич—үтә итагатьле яһүд карты—Русланның мондый тизлегенә үзе дә аптырап калды. Чөнки шәкерте, бер караганда, алай тиз генә якларга ашыкмый, һаман эзләнә, винегрет кебек буталып беткән бүгенге фәлсәфә фәнен үзенчә тәртипкә салырга азаплана кебек тоелган иде.

Бу эштә Кәриманең каты кулы уйнаганын бер Руслан Даулатович үзе генә сизде. Һәм, шуны белүгә, шәһәрне үк ташлап, ерак әбисенең туган якларына китеп барды...

Дөрестән дә, сәер гамәл кебек иде бу бер караганда. Бер яктан караганда да шулай, икенче яктан караганда да...

Ир-атнын үз горурлыгы була. Ул горурлык аны ир итә, чүпрәк булудан гына түгел, хәтта чүпрәк-чапраклар арасында да буталып калырга ирек бирми... Дөнья яшь галимнең әнә шул горурлыгына тиде булса кирәк... Дөнья шайтаннар, фәрештәләр белән тулган гаҗәеп серле һәм шул ук вакытта бик буталчык, яктылы-яктысыз мәгарә сыман...

Руслан Даулатович җәмгыятьтә шау-шу куптарырга тиешле хезмәтенең исемен әүвәл—"Ахырзаман ахыры" дип куймакчы иде. Ләкин уйлый торгач, әлеге исемне үзе үк килештермәде—гап-гади мәкалә исемен хәтерләтә шикелле. Шәп фикер үзеннән-үзе килде: "Яна Манифест"... Әйе, чынлап та дошманга үз күсәге белән орсаң, үтемлерәк булачак бит! Руслан Даулатович дошман дип, эченнән генә көлеп, Маркс белән Энгельсны атый. Аларның тулаем хезмәтләрендә аның эше юк. Иң куркынычы - алар җәмгыятьтәге ике җенес арасында шактый буталчыклар китереп чыгарып, җәмгыятьне астан кимерә торган "кортлар" уйлап тапканнар. Шул демогоглар аркасында эксперимент буларак житмеш кенә ел яшәп алган Советлар илендә адәмнәр өстенә коточкыч бәла-казалар, бәхетсезлекләр килгән!..

Ир-ат белән хатын-кыз тигезлеге хакында иң беренче сафсата сатучылар да шулар бит! Маркс белән Энгельсның "Манифест Коммунистической партии" әсәрендә һәм Энгельсның "Происхождение семьи, частной собственности и государства" хезмәтләрендә үк гаилә мөнәсәбәтләрен бутау башлана. Имеш, балалар гаиләдә түгел, ә җәмгыятьтә тәрбияләнергә тиеш. Имеш, хатын-кызның төп көче гаиләдә түгел, ә иҗтимагый хезмәт, эш урынында файдаланылырга тиешле!.. Аларча, гаилә хатын-кыз өчен төп хезмәтләре белән чагыштырганда вак-төяк шөгыль генә булып калырга тиешле...

Табигать хатын-кызны хатын кыз итеп, ир-атны нәкъ менә ир-ат итеп яраткан да инде. Әлеге ике җенесне берүк төрле яссылыкка кую, ирләр генә башкарырга тиешле хезмәтне үтәүне, ул да тигез хокуклы ич дип, хатын- кыздан да таләп итү—ахмаклыкның һәм алай гына түгел, хатын-кыз бәхетсезлегенең иң биек ноктасы! Нәкъ шул ахмаклыкның гади генә, ләкин тормышчан мисалы итеп кулларындагы ломнар белән, трамвай юлларын ремонтлаган апаларны, химия заводларында сәламәтлеген какшаткан хатын- кызларыбызны китерергә булмыймыни!

Хатын-кыз ул Илаһи зат!!! Хатын-кыз беренче чиратта бәби табу сөенечен кичереп, гаилә учагының иң якты Уты булырга тиеш! Иҗтимагый хезмәттә катнашу яки катнашмау (нинди микъдарда катнашу) беренче чиратта хатын-кызның үз ихтыярыннан гына торырга тиеш! Ул яши торган җәмгыять исә аннан шуннан артыгын таләп итәргә тиеш түгел!Ир-ат белән рәттән дүрт сәгать эшләгәне сигез сәгатькә исәпләнергә тиеш! Ә теге демагог яһүдләрнең тәгълимате нигезендә корылган ялган, алдавыч фикерләр исә әүвәл җәмгыятьнең табигый үсешенә зыян салды, шуның белән беррәттән хатын-кызны бәхетсез итте! Алардан ир-ат ясады, ир-атны чүпрәк итте!!!

Хатын-кыз сөяр, һәм сөелеп яшәр өчен яратылган Зат! Ул беренче чиратта ир-атның илһамчысы, рухландыручысы булырга тиешле Зат!

Ана теләге баланы диңгез төбеннән чыгарыр ди! Шәхестә, индивидта бары тик ана мәхәббәте генә кешелек күзәнәкләрен тәрбияли ала, ул аны үзенең баласына булган Мәхәббәтенең илаһи көче тәэсирендә тормышка ашыра!

Җәннәт аналарның аяк баскан урынында!!!

Ир-ат әгәр дә бөек җиңүләргә ирешә икән яки зур гамәлләр кылырга сәләтле икән, беренче чиратта, ул моның өчен хатын-кызга, бары тик хатын-кызга гына бурычлы!!!

Әнә шул аксиоманың, тормыш, яшәеш аксиомасының кайчандыр "муены сындырылды", барлык бәлаләрнең башы тик шуннан гына!!!

Ул демагогларның ялган тәгълимате Руслан Даулатовичны бәхетсез итте—сөйгән хатынынннан аерды...

Аның тамырларында гына да бит әллә ничә төрле милләтнең каны ага! Кем аркасында! Хатын-кыз аркасында!!! "Ирек" хатын-кызга теләсә кемгә кияүгә чыгарга мөмкинлек бирде! Һәм шуның белән ул кавемне дә бәхетсез итте!

Цивилизация куркыныч алдында! Аны коткарып калу өчен хатын-кызны үз урынына, ир-атны үз урынына утыртырга кирәк!..

"Хатын-кызга яңадан пәрәнҗә ябындырып, аны үз ихтыярыннан башка яратмаган кешесенә кияүгә бирү синең черегән цивилизацияңне коткарып калырмы соң?!"

"Хәзер берничә буын яшьләр гарип буын буларак тәрбияләнеп килә.Гаиләдә ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәт—бала тәрбиясендә, аның шәхес булып формалашуында төп этәргеч!

Гаиләләрдә хөкем сөрергә тиешле гади генә табигый баланс бозылды. "Патриархат" та түгел, тулысынча "матриархат" та юк.

"Мат-Пат" дип аталган яңа төр винегрет. Ә ул нәкь менә балаларның ашказаннарын боза да инде, черт побери!"

*Я научила женщин говорить...*
*Но, боже, как их замолчать заставить?*

Бу юлларны хатын-кыз шагыйрә язган.

Руслан Даулатовичның әлеге мәсьәләгә булган карашы шактый четерекле, катлаулы иде. Чөнки Марксны тәнкыйтьләп кенә хакыйкатьне ачып-аңлатып биреп булмаячагы сукыр күзгә дә күренә. Каннар бозылу галәмәте—төрле милләтләрнең буталуы—аның хезмәтендә, дөресрәге, бөек ачышларында шулай ук әһәмиятле фактор буларак өйрәнелергә тиеш ләбаса дип фикер йөртте инкыйлабчы галим. Җәмгыять беренче нәүбәттә ныклы гаиләдән торырыга тиеш, тагын да төгәлрәк әйтсәк, милли гаиләдә тәрбияләнеп үсәргә тиеш яшь буын.

Әлеге ачышларны ясау өчен теория белән гамәлне кушу мәҗбүри микән дигән мәсьәлә-сорау исә үзеннән-үзе хәл ителде—фәнни институттан югары уку йортына күчкәч, имтихан бирә алмый интегеп йөргән чибәр студент кызлар яшь профессорның тәмам башын әйләндереп бетерә яздылар.

Тол профессорның өендә телефон шылтырады.

—Бәхетле йолдыз астында тугансың икән...—Руслан Даулатович китап киштәсе янында тынсыз калып, аннан түземсезләнеп нинди дә булса хәбәр көткән кызга карап торды да:—Әниең Казанда гына калачак. Һәм... ким дигәндә бер айдан ул иректә булачак!

Бу мизгелдә кызның гәүдәсе генә түгел, бөтен барлыгы—гакыл-хисләре, җаны һәм бар рухы—пружина кебек киерелгән иде. Хис-пружина кинәт бушады һәм ул, үз-үзен белештермичә, каршысында басып торган, үзе өчен әлеге минутларда дөньядагы иң изге кеше булган ир-атка таба атылды да аны кочып алды.

Әлеге "шатлык йолдызы" һич көтелмәгәндә атылды ки, Руслан Даулатович, аягында басып кала алмыйча, артындагы диванга ауды.Кыз аны шашына-шашына битеннән, маңгаеннан үбә, аның җир җиләге сыман сусыл һәм өстәвенә кап-кайнар иреннәре тол ирнең кытыгын китереп, гакылын томалап куйды да, калган гамәлләрен бары тик хисләр иркендә калдырып, тәмам каушатты, уянырга өлгергән күзәнәкләре ары-бире чабулый башлады, аннары, тәмам буталышып бетеп, юлларыннан ук яздылар һәм аны да үз артларыннан иярергә чакырдылар.Менә аның кулы ирексездән кызның тыгыз күкрәкләренә орынып китте, шуннан соң инде яшь ир тәмам хисләр иркендә генә калырга әзерләнде. Ләкин нindидер көч, иңбашларыннан тотып диярлек, кызны диваннан тартып торгызды, ул әле нәрсә булганын да һәм алди ни булачагын да аңларлык хәлдә түгел, тәне әле яңа гына салкын суга чумып чыккан кебек калтырана, йөзе генә

түгел, жиләк кебек кызарышып, тулып торган иреннәре дә ап- ак булды, әмма ул, үзендә көч табып:

—Рәхмәт Сезгә, Руслан Даулатович!—дип әйтә алды шикелле.

Чыннан да, рәхмәт Руслан Даулатовичка, рәхмәтнен дә иң зурысы! Ул бер сүз дә әйтмәде, бары матур итеп елмайды һәм кызны юатып:—Борчылма, Кәримә, бар да яхшы булыр!—дип юатыр сүзләр дә тапты әле. Әлбәттә, аның бөтен эчен жинелчә генә калтырау алып, йөрәге, нәрсә булса да көткән шикелле, дөп-дөп тибәргә керешкән һәм тамырларындагы канны да гадәттәгедән көчлерәк, тизрәк куа, шул сәбәпле кан басымы күтәрелеп, аны сугышчан халәткә китереп житкерә язган иде инде.

Бераз суына төшкәч ул: "Шөкер!" дип куанып куйды. Бу кыз аның диванында аунаган башка студент кызлар кебек түгел, аларга охшамаган! Мәсьәлә исеменең беренче хатыныныкы кебек "Кәримә" булуында гына түгелдер инде, әлбәттә.

Руслан Даулатович яшь, чибәр һәм кагыйдә буларак, шактый надан кызларның, имтихан бирә алмауларыннан файдаланып, аларны үз ястыгына салучылардан түгел, тол ирнең андый максаты юк. Ул чытлак кызлар һәрвакыт ана үзләре жәтмә коралар, очраклы, көтелмәгән әллә нинди очрашулар оештыралар. Дүртенче дистәне жыюына карамастан, Руслан Даулатович яшьләр булган кичәләргә йөрергә ярата, турыдан-туры катнашмаса да шул мохитнын һавасын ярата тол ир, шул рәвешле ул үзенең яшьлеген эзли, яшьлегендә өзелеп яраткан Кәримәсен янадан эзли. Бу заманда кырык яшь ир-атның чәчәк аткан еллары булса да, кем әйтмешли "яшем житте кырыкка, эшем китте шырыкка" дигән әйтем куркыта аны.Нәкъ менә шул "шырык" аркасында аның күңеленә мең төрле шикшөбһә кереп оялый да рухын басып, сытып тора. Фәнни эш белән шөгыльләнсә дә, Руслан Даулатович фәнни институтлардан урын эзләп йөрмәде, укытасы, яшьләр арасында буласы килде аның. Китап, лекцияләргә ябышып ятарга яратмаган чибәр кызлар аны, тол профессорны, Казанның мең төрле почмагының көтелмәгән борылышында очраклы рәвештә генә очратып, ялгыз ир-атның кытыгын китерәләр, бу эшнең ахыры Руслан Даулатовичның өч бүлмәле фатирында шәм яктысында тәмам кылына иде гадәттә. Студентларның наданлыгын яки фәнне төшенеп, аңлап бетермәүләрен файдаланамы ул?! Әүвәл Руслан Даулатович үзен зур жинаятьче итеп хис итә иде. Тора-бара бу авыр хис үзгәрде. Ярый, хуш, надан студент кызга, бер мәртәбә аның фатирында очрашып, яхшырак аңлашканнан соң, ул аның зачеткасына шәп билге дә "утыртты" ди һәм шуның белән моңа нокта да куелырга тиеш бит инде. Юк... теге кыз өч көннәнме, берәр атнаданмы, нинди дөньяда булмаган ахмак сәбәп тапкан булып, юлына тагын килеп чыга яки батыраеп фатир ишеген шакый. Югыйсә, аның фәненнән имтихан да бирәсе юк бит инде канә!..

Бу кыз балаларның әтиләре алып биргән чит ил машиналарында жил куып йөргәннәрен белсә дә, мескен, хәерче стипендияләргә мохтаж түгел икәнлекләрен белсә дә (аларга шәп билге кую өчен аталарының телефон трубкасын күтәреп куюлары да житә, югыйсә) баштарак аларның бу жилбәзәк гамәлләрен башына сыйдыра алмыйча азапланып, интегеп йөрде. Ниһаять, үзенә кунакка килгән бер тау ягы кызы бик ачык итеп аңлатып бирде ана мәсьәләнең серен. Бу чибәр кызны үз лекцияләрендә сирәк күрә иде ул. Шулай да фатирына турыдан-туры килеп кергәч таныды—өченче курстан.

Зур түрә дәрәжәсенә ирешкән авыл малаеның мантыйгы бик гади: үзе нәкъ менә үз акылы белән шундый зур дәрәжәгә ирешә алгач, аннан туган балалар тагын да акыллырак, талантлырак булырга тиешләр.Аларны тормышның вак-төяк мәшәкатьләреннән азат итәргә кирәк, ул ашау-эчү турында, матур кием-салым хакында яки затлы чит ил машинасы турында уйлап һәм, ахыр чиктә, Казан тулай торакларының берәрсендә таракан санап яшәргә тиеш түгел, атасыннан күчкән сәләтен, гакылын ул малай яки кыз бала фәнгә багышларга тиеш, максаты яхшы билгеләргә генә укып, кесәсенә диплом салу булырга тиеш. Югары уку йортында укыган чакта

билгеләре бик шәптән булмый икән, аның өчен дә борчылып торасы түгел: бала әлегесен ачылып житмәгән! Килер бер көн, аның ефәккә төрелгән баласы зур кеше булып өлгереп житәр, ин юк дигәндә, ахыр чиктә, атасы эшенең дәвамчысы булыр. Монысы малайларга кагыла. Кызларга килгәндә исә... Монда да үз мантыйгы бар. Берәр зур житәкченең асыл малаена тап булып, алдагы тормышын муллыкта, рәхәттә уздырыр, шөкер!.. Чөнки аның тормышыннан бик канәгать булган үз хатыны көне-төне колагына шул хакта тукып тора лабаса! Колагына гына түгел, бу нәрсә аның инде һәр күзәнәгенә кереп сеңгән!

Әлеге кызлар үзләренең алар өчен әти-әниләре махсус уйлап тапкан алтын бөжра эчендә икәнлекләрен беләләр. Тик, алтын булса да, барыбер аның бөжра икәнлеген аңлыйлар. Кайсы яшь күнелнең "ябылуда" яшисе килсен! Аларның күңелләре бу гамәлләргә, кырыс мантыйкларга карата үзләренең ризасызлыгын белдерә һәм менә шул эчке ризасызлык белән сугарылган каннары аларны "читкә" каерып тора, әти-әнисенең теләкләренә каршы килеп, төрле җүнсез гамәлләргә чакыра. Ничек телибез—шулай яшибез, ди, ул кызлар. Ничек телибез—шулай кыланабыз дип фикер йөртә бу чибәр кызлар һәм чәчәкле болындагы бәйсез күбәләкләр сымак теләгән тарафларына очып киткәлиләр дә...Аларның бик гади генә бер теләкләре бар, ул да булса, үз язмышларына үзләренең хуҗа буласылары килү.

Аларның берсе дә, малае да, кызы да, әти-әниләре теләгән югары баскычларга күтәрелә алмый.Чөнки—тормыш көрәш ул.Ә боларда көрәш иммунитеты бала чакта ук ата-аналары тарафыннан үтерелгән, юкка чыгарылган була. Тормыш әзергә бәзер генә яшәргә өйрәнгән балаларына карата нишләптер бигрәк аяусыз шул...

Бер мәртәбә имтихан биргәннән соң студент кызларның аның янына үз теләкләре белән бернинди сәбәпсез икенче, өченче тапкыр килүләре—Руслан Даулатович өчен бердәнбер һәм ныклы аклану. Аннан соң... аннары ул тикшеренүче-галим, хатын-кыз холкын никадәр якыннанрак өйрәнә икән, димәк, аның фәнни ачышлары шулчаклы тормышчан һәм кире каккысыз булачак! Фән өчен галим кеше, шагыйрьләр читтән илһам эзләгән кебек, әхлак кануннарына сыешмаган гамәлләр кыла икән, бу, һичшиксез, табигый күренеш итеп кабул ителеп, аны гаепләргә урын калдырырга тиеш түгелдер ләбаса!

Кәримә атлы бүгенге студент кыз исә билге куйдырырга килмәгән. Бу самими карашлы кыздан чынлап торып курка Руслан Даулатович. Дөресрәге, әлеге кызның үзен юлдан яздырудан, башы-аягы белән хиссият дөньясына алып кереп китеп, башын, акылын югалтудан курка иде. Кырлап-сырлап торасы да юк: Руслан Даулатович үзенең бу кызга карата битараф түгел икәнлеген сизә башлады бугай. Ходай сакласын, ул бөтән гашыйк булып, салкын акылын жебетергә теләми, йөрәгендә беренче Кәримәдән соң калган жәрәхәттән һаман кан саркый, ул аны төшләрендә күреп уяна, кайбер төннәрне таңга чаклы беренче хатынының "куеныңда" уздырып чыга, төне буе ләззәт, мәхәббәт тәмен татыганнан соң, уянып киткәч, хак чынбарлык аның башына күсәк белән китереп органдай була. Тол ирнең яшисе килми башлый, ул төшкә чаклы төшенкелектә йөри. Шул рәвешле акылдан язуың да бар. Менә тагын... бу кыз да, дөресрәге, бу кызга да күңеле битараф түгел шикелле, нилектәндер ымсына, кытыклана. Күңелен бер "бәйдән" ычкынса, аны бернинди фәлсәфә кануннары белән дә урынына утыртып булмаячагын аңламый мыни ул?!

Борынгы грек фәлсәфәчеләре үк моңа игътибар иткәннәр. Бу нисбәттән Платон Софоклның сүзләрен мисал итеп китерә. Өлкән яшьтәге Софоклдан сораганнар икән: "Мәхәббәт ләззәтенә мөнәсәбәтең ничек? Хатын-кыз сине һаман кызыксындырамы әле?"—дип. Тегесе җавап биргән: "Мин бу нәрсәләрдән үзенең кырыс әфәндесеннән йөгерә-йөгерә качкан кол кебек шатлана-шатлана арындым, качтым инде".

Руслан Даулатовичның Кәримә иреннәре тигән ике бите бик рәхәт булып һәм бик озак янды...

Буласы нәрсә булмый калды. Көтелеп тә булмый калган нәрсәләрне, җил үзе белән эзен дә калдырмыйча очыртып алып китә.Тормыш безнең уй-фикерләрдән үрелгән. Шуна күрә кайбер авырлыкларны адәм баласы кичереп, үткәреп җибәрергә тиеш. Чөнки Ходай шулай тели.Ә ахыры хәерле булыр кебек...

...Кәримә көтте, үзе белән якын арада булачак зур үзгәрешкә алдан ук әзерләнде. Әлбәттә, анлы рәвештә һәм махсус түгел, бу әзерлек кызның акылыннан гайре рәвештә барды шикелле. Әйтерсең, ул бик текә ярның читенә үк килеп житкән дә... юк, ул инде шул текә ярда аякларын ук салындырып утыра, чак кына кузгалса, яисә талпынып алса—аста кайнаган дингез дулкыннары арасында булачак. Ул Дингез аны төпкә алып китмәячәк, үзенең акулаларына ризык итеп тә бирмәячәк, ул дингез аны йомшак дулкыннары өстендә уйнатачак, иркәләячәк, бишектә тибрәткән кебек тибрәтә-тибрәтә, соныннан гәрәбәдәй комлы ярына чыгарып бастырып куячак—яшә, рәхәтлән, тормышның тәмен таты, син хәзер инде үзең бая гына аягыңны салындырган текә яр өстендә түгел, син кичәге кебек болыннан чәчәкләр жыеп йөри аласың. Хуш исләр белән хозурлана аласың. Син хәзер гөнаһсыз кыз бала түгел. Ләкин шуны бел, син инде самими кызчык кебек ул матур чәчәкле, хуш исле болында бер кайгысыз очып уйнаган күбәләкләр артыннан дөньяңны онытып куып йөри алмаячаксың, дөресрәге, синдә бүтән андый теләк уянмаячак, беркайчан да... Син хәзер хатын-кыз, син хәзер ул күбәләкнең очынып уйнавына соклана-соклана күзәтә генә аласың...

Нигә?! Аерма шунда гынамы икәнни соң?.. Юк, аерма анда гына түгел. Син кайчан да булса үзең охшаткан кешегә кияүгә чыгарсың. Зәфаф кичендә, бәлкем, хатын-кызга хас мәкерлегенне файдаланып, үз кешеңне алдый да алырсың. Ләкин син гомерең буе яшерен сереңнән котыла алмаячаксың, ул сине каберенә чаклы озата барачак. Ул сине фани дөньяда да адым саен эзәрлекләп, ирең белән ястык бүлешкән мизгелләреңдә, бигрәк тә—битәрләп, жаныңны өшетеп торачак!.. Син үзең тудырган газиз балаларыңның күзенә дә тутырып карый алмаячаксың! Син инде буй житкән кызыңа тәүфыйклы бул балам дип әйтәсең, кисәтәсе килгән чакларында, теге мәкерле серең күсәк сыман башыңа тондырачак, син аңгыраеп калып, кызыңа бирәсе киңәшләрең дә табигый һәм самими булмаячак, кызың, бәгырь кисәгең, ул киңәш, теләкләреңне колагы, аңы белән кабул итсә дә, ул аның жанына үтеп кереп, кызыңны бәлаләрдән коткарып калу көченә ия булмаячак инде...

Син кулыңда искиткеч матур һәм бик хуш исле чәчәк тотып торырсың, ләкин син инде чәчәкнең хуш исе белән матурлыгын бергә, икесен дә берьюлы тоя алу ләззәтеннән мәхрүм ителгән хатын-кыз буларак, йә матурлыкны гына күрә алырсың, йә борыныңа хуш исе генә килер...

Бу сүзләрне кемдер Кәримә атлы гыйффәтле кызның колагына пышылдый иде. Кем шулай кисәтә аны, хәтта... ул кемдер аны өркетә, куркыта шикелле. Тулай торагына кайтып пружиналы тимер караватына аугач та әлеге "кемдер" пышылдавыннан туктамады.

*"Минем әнием ирекка чыгачак! мина иң беренче нәүбәттә шунысы кадерле"*

Кызны йокы алмады. Алар сабакташ кызлары белән күптән түгел генә жыелышып, кача-поса бер фахишәнең көндәлеген укыганнар иде. Кәримә яшергән жиреннән тиз генә шуны тартып чыгарды һәм китапның үзенә кирәкле битен эзләп тапты.

*"Шундый карар кабул иткән мизгелдән кала, мин ул төннең һәр минутын аерымачык хәтерлим. Кызык—үземне бер тамчы да гаепле итеп сизмим. Элек мин үз тәнен сатып көн итүче хатын-кызларга тормыш бүтән юл калдырмагандыр дип уйлый идем,—хәзер моның алай түгел икәнлеген күрәм. Мин бит "юк" дип, кире кага ала идем, "әйе" дип ризалашырга да була иде..*

*Һәммәсе дә мин алдан фаразлаганча булды: гарәп белән аның кунакханәдәге номерына кердек, шампан эчтек, мизгел эчендә бик каты исердем, анадан тума чишенеп, урынга барып яттым һәм тыныч кына аның кәефе булганын көттем (үземә дә рәхәт булганлыгын күрсәтеп кыланып та тормадым). Душка кердем, гарәптән акчасын алдым да, такси тотып, өйгә кайттым. Таңга чаклы бернәрсә белмичә йоклаганмын.*

*Мин урамнан барам. Кешеләрнең йөзләренә текәлеп карыйм һәм белергә тырышам: бу кешеләр барысы да язмышларын үзләре сайлады микән? Әллә минем кебек язмыш тарафыннан ирексез рәвештә сайландылар микән?*

*Мин үз-үземне тамчы да кызганмыйм. Корбан итеп тә хис итмим, чөнки гыйффәтле булып калган хәлдә, буш кошелегымны кыстырып, рестораннан ук чыгып китә ала идем бит. Мин ул гарәп каршында әллә кем булып та кылана ала идем. Ала идем... Ләкин күпчелек кебек үз-үземне тулысынча язмыш кулына тапшыруны кулайрак күрдем."*

"Без күпме теләсәк, шулчаклы хыяллана алабыз, ләкин реаль тормыш бик кырыс. Моның белән син нәрсә әйтмәкче буласың? Сине кайчан да булса гаепләячәкләр дипме? Ләкин бу хакта беркем дә белмәячәк бит һәм бу шөгыль вакытлыча гына бит..."

Кәримә үзенә таныш булмаган фахишә кыз белән килеште дип тә, килешмәде дип тә әйтеп булмый... һич әйтеп булмый. Ул бары тик аның көндәлеген укыды, укыган саен укыйсы килде. Чит кешенең эч серләрен белергә омтылу теләге идеме бу, әллә үзе дә мондый гамәл кылырга мәҗбүр булган очракта, тырыша-тырыша котылу өчен " салам" эзләү идеме?..

Кәримә йотлыга-йотлыга укыды.

*"Мин шуны аңладым—ир кеше хатын-кызга түли—бәхетле булыр өчен түли...*

*Табигый хисләрен канәгатьләндерү өчен генә шулчаклы акчаны чыгарып салмас бит инде ул. Бәхетле буласы килә аның. Җир йөзендәге башка кешеләр кебек үк минем дә бәхетле буласым килә, ләкин моңа беркем дә ирешә генә алмый. Әгәр дә төптән уйлап карасаң, нәрсә югалтам соң әле мин?*

*Намус. Горурлык. Үз-үземә хөрмәт. Әгәр дә төптәнрәк уйлап карасаң, боларның берсенең дә миндә булганы юк. Мин бу дөньяга туарга атлыкмадым, мин үземнең мәхәббәтемне очратмадым, мин һәрвакыт ялгыш гамәлләр кылдым һәм минем тормышым да үз тарафымнан ук җимерелгән..."*

Кәримә әлеге мескен кызны ирексездән үзе белән чагыштырып куйды. Аның да монарчы чын мәхәббәтен тапканы юк бит әле, аны да, әнисен коткарып калу хакына, бүгенме, иртәгәме... нәкъ шул язмыш көтәргә мөмкин бит? Ул бүтән бу хакта уйларга теләмәде, тизрәк китапка капланды.

*"Яратышуга килгәндә, әлеге нисбәттә берни дә үзгәрмәде. Чишенеп ятасы, ыңгырашкан булып кыланысы (әлеге ыңгырашулар кайчак артык акча алып килә), соңыннан душка керәсе—су астында торган чакта тәнең генә түгел, җаныңның бер өлеше дә чистара кебек. Әллә үзең шулай булуын теләгәнгә генә микән? Клиент белән бернинди үбешү юк. Иптәш кызым әйтә,үбешүне киләчәккә, үзеннең чын мәхәббәтенне очратканчы сакларга кирәк, ди. Әйе, әйе, кайчан булса да ул Үбү киләчәк, һәм синең бар дөньяңны аллы-гөлле төсләргә күмеп, сине мәңгегә бәхетле итәчәк!.. Шул Үбү Синдә гүзәл хатын-кыз уятачак!!!"*

Чү, туктале, ул Руслан Даулатовичны битеннән үпте бит!? Юк ла, үз-үзенне газаплама инде, шатлыктан гына, рәхмәт әйтәсе килгәннән генә ләбаса ул...

*"Минем янга килгән барлык ир-ат та,—озын буйлымы ул, кыскамы, тынычмы, яки тел бистәсеме,—һәммәсе дә үзләренең куркуларын җиңеп киләләр. Тәҗрибәлерәкләре бу куркуны басар өчен кычкырып сөйләшкән була, кайберләре үзенең әлеге халәтеннән качу өчен хәмер эчә. Курку хисе кичермәгән ир-атны минем әле моңарчы күргәнем юк. Әлбәттә, алар хатыннарына ишетелүдән яки кеше теленә керүдән куркалар.*

*Ләкин нигә? Алар түгел, киресенчә, мин куркырга тиеш бит әле монда! Һәр кичне үземә таныш булмаган кешеләр белән кунакханәгә мин керәм бит. Мин керәм, көчсез хатын-кыз башым белән, үзем белән хәтта коралым да юк?! Гомумән, бу ир-атлар кызык кавем. Минем белән кунганнары гына түгел, минем юлымда очраган һәммәсе дә... Әйе, алар куркытырга мөмкиннәр, кычкырырга, суккалап та алырга күп сорамаслар, әмма барысы да хатын-кыздан куркуларыннан акылларыннан язарга мөмкиннәр. Бу курку үзләре башларын итәкләре астына тыккан хатыннарыннан гына да түгел. Мәсәлән, туган әнисеннән курку...*

*...Өстәвенә, әгәр, артык салган баштан, булдыра алмасалар, алар оялалар да. Югыйсә, уята алмаганым өчен мин оялырга тиеш бит, алар түгел..."*

Кәримә китапны читкә тотып атты. Нииндидер бер фахишәнең эч серләре ана нәрсәгә кирәк булды соң әле? Кадалып китсен шунда! Житмәсә, Кәримә укырга да оялган жөмләләрне ул ачыктан-ачык яза да бит әле? Әнил булса, "какой ужас!" дип, бу көндәлекне күптән чүплеккә тондырган булыр иде инде...

Кыз үзе шулай дип уйлады, ләкин бик яхшы белә ләбаса—әлеге уйларында хилафлык та юк түгел, үз-үзен чак кына алдый да бит ул... Чөнки яхшы белә, күптән укыды инде, соң чиктә әлеге фахишә кыз чын мәхәббәтен таба һәм аны тапканчы ук шул хакта, ягъни чын хисләр хакында уйлана башлый. Көндәлекнең ул өлеше Кәримәгә аеруча ошый. *"Мин бүген шөгыльләнгән һөнәрме, кәсепме ул, ни булса да—аның бик борынгы булуына төкердем мин. Шунысы хак: мин бу кәсебемне куралмыйм!!! Ул минем жанымны ашый, бәгыремне кимерә, ул мина акчаның бар нәрсәдән дә өстен икәнлеген аңлатмакчы була!*

*Минем тирәмдә бәхетләләр юк. Ул ир-атлар яхшы белә: бушка да ирешеп була торган нәрсәгә алар учлап акча түлиләр, шул нәрсә аларны кимсетә, ачуларын китерә. Иркәләү, сөюләр хакына бушка да бирелергә әзер булганымны белә торып, сатылырга, акча таләп итәргә мәжбүр ителгәнем өчен минем жаным кыйнала. Берәр атнага гына түзәм дә... Аннан нишлим? Нокта куяммы? Әйе, куям. Һәм мин боларның барысын да киләчәк тормышымда онытырга, нинди оныту гына, бәлки тормышымнан ук сызып ташларга тырышачакмын! Минем күңелем дә бит мәхәббәткә сусаган! Минем дә яратасым, сөеләсем килә!*

*Тормыш артык кыска... Ул кыска тормышны бары тик чын мәхәббәт мизгелләре генә озынайта алачак... Мин шуны аңлый башладым. Ниһаять... Бар адәмнәр өчен дә уртак булган "ахырзаман" белән берргәттән һәр кешенең үзенең генә дә "ахырзаманы" була торган булса, кыз бала өчен ул мин кылган гамәлләрдер... Аның да беренчесе үктер, Ходаем.*

*Үзең ярлыкый күр, Ходаем! Муеннан гөнаһларга батабыз да... аннары, авыз күтәреп, гафу итүеңне үтенәбез,тәүбәгә килмәкче булабыз, сине искә төшерәбез"...*

* * *

... Ул төнне Руслан Даулатовичның фатирында таңга чаклы ут сүнмәде. Кан тамырларын шартлатырдай булып гәүдәсендә тупланган көч-гайрәт ана йоклап китергә ирек бирмәде. Ул язу өстәле янына килеп утырды.

...Борын-борыннан ук күршеләр булып гомер итсәләр дә, холык-кыяфәтләре белән бер-берсеннән жир белән күк кебек аерылып торган милләтләр, тарихның кайсыдыр мизгелләрендә, үзара буталышып, каннарын бозганнар... Басып алынган халыкның каймак кебек кызлары коллыкка алынган. Әлеге чуалыш-кушылулар нәтижәсендә жир йөзенә йөзләгән-меңләгән "безобразияләр" туа торган. Гибрид грейфрукталар ничек тәмсез булса, боларның каннары кушылу нәтижәсендә дөньяга килгән "жимешләр дә" шундый ук чиле-пешле була торгандыр. Йа, Ходай! Әгәр синең изге китапларың булмаган булса, адәм балаларын жирдән атлап түгел, күптән агач башыннан йөрерләр һәм бер-берсенә нарат күркәсе атып уйнап, тәннәреннән бет чүпләп утырырлар иде... Син—тудыручы, Син—

коткаручы!.. Шулай булгач, Синең тәгълиматең күкләрдән инмәгәндер дип, кем авыз күтәреп әйтә ала?!

Тарих белән "тарих" кына бит дип шаярмагыз, ул хакта җинел генә фикер йөртмәгез! Халыкның тарихы аның кичәге язмышы гына түгел, ул аның туачак таңы, офыктан күтәреләчәк кояшы. Син кичә нинди идең, бүген дә шулай син, иртәгә дә, алдагы көннәрдә дә шулай булачаксың! Кабыгың гына алмашынырга мөмкин, тик асылың үзгәрмәячәк. Белеп тор моны!..

Руслан Даулатович студентларына да шул ук фикерләрне тукый тора. Дөресен әйтергә кирәк, әгәр ул аларны үзе, ягъни булачак монографик хезмәте өчен генә теркәп барган очракта, күнеле һич канәгатьлек тапмас иде. Уйлаганнарын студентлары белән уртаклашасы... юк, дөресрәге, ул аларга шәкертләреннән, чит кешеләрдән тагын бер кат раслатып, күңел тынычлыгы табарга омтыла шикелле.

—Милләтләрнең каннары буталып беткән. Кан кузәнәкләре бертөрле генә түгел. Кайда кайсы милләт күзәнәкләре өстенлек итә—индивид үзен шул милләт "бишегендә" унайрак хис кыла.

Яңа исәп-хисаптан башланган бүгенге дөньяның берничә йөз елы милләт каннары кушылу-буталудан гына тора. Аңарчы ул чагыштырмача тотрыклы булган. Һәр милләтнең үзенә генә хас холкы, фигыль-гамәле аеруча көчле чагылган.

Ул шулай диюгә, арадан берәр кыюрак студенты сикереп торып:

—Руслан Даулатович, мин Сезнең белән һич килешә алмыйм! Каннар буталу революциядән соң гына башланган ич!—дип, каршы да төшмәкче була. Шулчак профессор абзагыз, дөньясын онытып, тарихка кереп китә. Әлбәттә, үзенә каршы килгән студентны гаепләми ул. Хәтта аның сүзләрен куәтли дә. Мисал итеп урыс ельязмачыларының сүзләрен китерә.

955 нче елның җәендә князь Игорьның хатыны Ольга греклар янына Патша шәһәренә килә. Ул заманда патша булып Левның улы Бөек Константин хакимлек итә. Ольга менә шуның катына бара. Патша гүзәл Ольганы күреп соклана һәм" безгә бергәләшеп патшалык итәргә язгандыр" ди. Ольга үзен саклап калу өчен шундук хәйләгә керешә, дөресрәге, чын максатын әйтә. "Мин мәҗүси бит, христиан кеше мәҗүси хатынны хатынлыкка ала алмый, мине чукындырасың килсә, тик үзең генә чукындыр, югыйсә, мин чукынудан баш тартачакмын", ди. Һәм патша аны патриарх белән бергәләп чукындыра. Патриарх хатынга христиан диненең тәгълиматләрен өйрәтә. Чукынганнан соң Ольгага Елена дигән яңа исем бирәләр.

Үз диненә күчкәннән соң Константин патша Ольгага хатыны булырга тәкъдим ясый. Ләкин Ольга аңа шундук каршы төшеп:

"Ничек итеп син мине үзенә хатынлыкка алмакчы буласың?! Син бит мине үзең чукындырдың һәм кызым дип атадың! Ә христиан кануннары буенча ата кеше үз кызына өйләнә алмый".

"Хәйләләдең син мине, Ольга" дип, патша аның фикере белән килешергә мәҗбүр була. Шуннан соң ул аңа күп мал-мөлкәт, алтын-көмеш биреп кайтарып җибәрә. Ольганың халкы да христиан диненә күчә. Ләкин аның улы Святослав христиан диненә күчүдән баш тартып, мәҗүси булып калса да, алар бик тату һәм матур гомер кичерәләр.

—Сезгә билгеле мәгълүматлар нигездә әнә шулар,—дип, никтер авыр итеп көрсенеп куйды Руслан Даулатович.

—Борынгы ельязмада язылганча бит инде!

—Аларда чын хаклык бар дип уйлыйсызмы? Алдый алар...

—Ничек инде?..

—Монастырьларда утырган ельязмачылар хуҗаларына нәрсә кирәк, нинди данлы тарих кирәк—шуны язганнар да. Мәсәлән, Святослав кенәз Игорь малае түгел! Ул Ольгага өйләнгәндә шәлперәйгән карт була инде. Тоткынлыкка төшкән Ольганың гыйффәтен хазар башлыгы ала, малай, ягъни урыс кенәзе Святослав шуның баласы! Менә каннар буталуның ачык мисалы сезгә!

Ельязмаларда ялган күп дидем. Дөрестән дә шулай бу. Мәсәлән, шул ук Святославның малае Владимир үзе кенәз булып алгач, Выдубицкий монастыре монахы Сильвестерны дәштерә дә, беренче урыс ельязмасын юкка чыгарып, яңаны язарга куша. Чөнки анда Русьны берләштерүдә Владимирның роле кечерәйтеп күрсәтелгән була. Шуннан бирле тарихчыларның башы әйләнеп беткән инде. Княгина Ольганың кайчан Константинопольгә килгәне дә, урыс илен төгәл чукындыру датасын да тәгаен белгән кеше юк. Дөреслекне бары тик патша Констанинның сәркәтибе язмаларыннан гына эзләргә кирәк. Порфирогинетның бу хакта аерым хезмәтендә тәфсилләп языла. “De ceremoniis Auiae” дип атала әлеге хезмәт һәм сәркәтип Ольганы скандинав исем белән Елга дип атый. Константинопольгә, Сильвестер язганча, 955 елда түгел, ә 957 елның 9 сентябренда килә Ольга. Мондый мисалларны күпләп китереп булыр иде. Шунда туктапып торыйк әлегә. Ләкин мин бу урында тагын бер әһәмиятле фактны искә алып китәргә уйлыйм, ул да булса, кенәз Владимир, атасы кебек үк, законлы никахтан тумаган, ул “ ключница” Малуша малае.

Рухи яктан шактый тотрыксыз бөек урыс кенәзе Владимир исә, барлык ир туганнарын үтереп бетереп, Киев тәхетенә утыруга абыйсының көмәнле хатыны грек кызы Юлияне көчли, аның белән генә дә чикләнеп калмый бу бозык җан. Шуннан соң византияле принцесса Аннага өйләнү бәрабәренә бөтен Русьны чукындырып ташлый. Әбисе Ольганың максаты әнә шул рәвешчә тормышка аша. Ольга әби исә үз чиратында, җеп очын яшерү өчен Владимирның әнисе Малушаны Киевтан куып ук җибәрә.

Әйткәнемчә, Святослав—хазар патшасы яһүди Песах малае.

Каннар буталу белән бергә, әлбәттә, гореф-гадәтләр, яшәеш рәвеше дә үзгәрә. Мәсәлән, Ибн Фазлан шул дәвердә яшәгән урыслар хакында менә ничек язып калдырган. Шунысына игътибар итегез: халыклар гадәтләре белән бер-берсеннән ул вакытта нык кына аерылып торганнар. “Көннәрдән бер көнне мин Итил ярында сәүдә эшләре белән бирегә килеп чыккан русларны күрдем. Мондый камил гәүдәле адәмнәрне минем әле күргәнем юк иде. Алар кыяфәтләре белән пальма агачларын хәтерләтә, чәчләре сары; йөзләре алсу, тәннәре ап-ак. Аларда җилән, кафтан киеп йөрү гадәте юк, ир-атлары “киса” дип аталган тукыма кисәге белән ярты тәннәрен генә каплап йөри, бер куллары тышта кала.

Руслар тәһарәт алмый, җенси якынлыктан соң пакьләнми, ашар алдыннан кулларын юмый.

...Һәркемнең өй эчендә озын урындык бар, анда хуҗа үзе һәм сатып җибәрү өчен алып килнгән гүзәл кызлар-жарияләр дә тезелешеп утыра. Кайчакта русларның берәрсе жария белән якынлык кылырга тотына, ә иптәше шуны карап тора. Кайвакыт әлеге оят эшне бер төркем кеше дә күзәтә...

...Алар көн дә дөньядагы иң пычрак су белән юыналар. Бу менә ничек эшләнә: иртән хезмәтче кызларның берәрсе хуҗасына зур кисмәк белән су китерә. Теге анда кулын юа, битен, чәч үскән бөтен урыннарын юарга тотына, тарак белән чәчләрен тарап, аларны кисмәккә ташлый бара. Аннан шул кисмәккә борынын сеңгерә, төкерә, кыскасы, су пычрансын өчен барысын да эшли. Хуҗасы юынып бетергәч, хезмәтче кыз кисмәкне урындыкта көтеп утырган икенче берәү алдына китереп куя. Бусы да хуҗа кеше кебек бөтен эшен башкара—шул ук суда юына, чәчләрен тарый, какыра-төкерә. Кисмәк шул рәвешле өйдәге бар кеше юынып беткәнче берсеннән-берсенә йөри. Һәркайсы аңа төкерә-какыра, битләрен, чәчләрен юа.

Аудитория һәр сүздән дерт итеп сискәнеп киткәндәй була. Студентлар, аптырашып, бер-берсенә карашалар. Ләкин ни хәл итмәк кирәк, Фазлан үзе күргәннәрен ташка язып калдырган шул.

...Минә шулай ук берәр башлык үлгәннән соң аны ничек күмүләре хакында да еш ишетергә туры килде. Бу очракта йоланың иң гадие—мәетне

яндыру икән. Шуңа карамастан минем бу йоланы үз күзләрем белән күрәсем килә иде. Шулай бер көнне нindидер башлыкның үлеме турында хәбәр таралды.

Үлгәннән соң алар мәетне ун көнгә кабергә төшереп куеп, өстен ябып тоттылар, шул вакыт эчендә мәрхүмгә яңа киемнәр тегелде.

Берәр фәкыйрь кеше үлеп китсә, алар кечкенә генә көймә әмәлләп, мәетне шунда куялар да, көймәсе-ние белән яндыралар.

Бай, мал-мөлкәтле кеше үлгәндә аның бөтен байлыгын өч тигез өлешкә бүләләр: бер өлеше гаиләсенә кала, икенче өлеше жирләү, йолалар үткәрү һәм киемнәр тегүгә тотыла, ә өченчесе—исерткеч эчемлек әзерләүгә китә. Алар бу эчемлекне мәрхүмнең жариясе, үз-үзен үтерергә риза булып, хуҗасы белән бергә корабта яндырылган көнгә чаклы эчәләр. Набыз дип аталган бу эчемлекне алар артык күп эчәләр, көнен-төнен шушы эш белән шөгыльләнеп, кайберләре хәтта савыт тоткан килеш үлеп тә китә.

Мәет озату әзерлеге барган ун көн эчендә алар хатын-кызлар белән якынлык кылалар һәм сазда уйныйлар. Корбан булырга ризалык биреп, тиздән яндырылырга тиешле жария кыз исә шушы ун көн дәвамында набыз эчү һәм күңел ачу белән шөгыльләнә, ул матур итеп киенә, чәчләрен, күлмәкләрен бик матур итеп бизи һәм теләгән кешесе белән якынлык кыла.

Әгәр дә берәр башлык үлеп китсә, аның гаиләсе мәрхүмнең жарияләреннән, хезмәтче егетләрдән: “Кем аның белән теге дөньяга китәргә тели?”—дип сорый. Гадәттә арадан берәрсе ризалыгын бирә. Шушы сүзен әйткән кешегә сүзен кире алу тыела. Ул кире уйлаган очракта да бу аңа рөхсәт ителми. Бу эшкә нигездә жария кызлар ризалык бирә.

Шулай итеп, арадан бер башлык үлеп китте дә жария кызлардан: “Кем аның белән теге дөньяга китәргә тели?”—дип сорадылар. Кызларның берсе “мин” дип җавап бирде. Шушы сүз әйтелгәч, аны ике кыз карамагына тапшырдылар. Алар жарияне сакларга, ул кая барса да, гел аның белән булырга тиешләр иде. Әлеге кызлар хәтта жариянең аягына хәтле юалар иде.

Мәрхүмнең туган-тумачасы аны озату хәстәрен күрде—яңа кием-салым тектереп, кирәкле бөтен эшләрне башкарды. Ә корбан ителергә тиешле жария бу вакыт кәеф-сафа кылып, күңел ачып йөрде, шат йөз белән булачак тантаналы йола турында хыялланды.

Менә башлыкның үзен, аның белән бергә корбан ителәчәк кызны да яндыру көне килеп житте. Бу көнне мин мәрхүмнең Ител ярында торган корабы янына төштем. Менә корабны судан сөйрәп чыгардылар, алдан әзерләп куелган дүрт махсус җайланма өстенә урнаштырдылар. Аның як-якларына күтәрмә-баскычлар куелды. Шулай ук корабка сак та билгеләнде, алар арлы-бирле йөренгәндә нindидер сүзләр әйтәләр, нәрсәдер укыйлар иде. Бу эшләр башкарылганда мәрхүм вакытлы каберендә ята бирде, аны әле чыгармаганнар иде.

Корабның урта бер төшендә колгалардан тирмә сыман бер куыш урын ясалды, өстендә төрле төстәге тукымалар ябылды. Аннан озын урындык алып киленде дә корабка куелды. Шуннан соң аларда “үлем фәрештәсе” дип аталып йөртелгән бер карчык килде. Аның житәкчелегендә корабтагы урындык өстенә калын киезләр түшәлде, алар рум парчасы белән капланды, шундый ук парча тышлы мендәрләр куелды. Алардан мәрхүмне соңгы юлга озату эшләренә әлеге карчык житәкчелек итә, ул мәеткә киемнәр тектерә, аны кендерә, корбан буласы жарияне дә ул үзе үтерә икән. Мин бу карчыкның алыптай таза һәм караңгы йөзле булуына игътибар иттем.

Аннан соң чират мәрхүмнең үзенә килеп житте. Иң элек аның вакытлы кабере өстендәге туфрак катламы алынды, аннан түшәме сүтелде һәм өстенә жәймә капланган мәет көн яктысына чыгарылды. Мин аның суык кабердә ятып карасу-зәңгәр төскә керүенә игътибар иттем. Мәетне кабергә салганчы ук, руслар анда исерткеч эчемлек, нидидер жимеш һәм лютнага охшаган уен коралы төшереп куйганнар иде. Бу әйберләр барысы да кабердән чыгарылды...

...Бу йоланың бик күп халык җыелган җирдә үткәрелүен әйтергә кирәк... Корбан ителәсе җария, бизәнеп-ясанып, мәрхүмнең туганнары урнашкан куышлар борынча йөрде, анда һәрберсе белән якынлык кылды, куыш хуҗасы ана кешегә ишетелерлек каты тавыш белән:

—Анда баргач, хуҗана тапшырырсың: бу эшне ул сине яратып һәм хөрмәт итеп башкарды диярсең,—дип әйтә иде.

Җария кыз шулай, куыштан куышка йөреп, мәрхүмнең барлык туганнары белән якынлык кылып чыкты.

Фазланның язганнары уйдырма-әкият түгел, ул үз күзләре белән күргән манзараларны тасвирлаган. Милләтләрнең, халыкларның холкы бүген генә формалашмаган, аның башлангычы—гасырлар төпкелендә.

Тагын шул ук Фазлан язганнарга мөрәҗәгать итик.

“Башкортлар сакалларын кырып йөриләр һәм бет ашыйлар. Берсенең курткасын салып, аның җөйләрендәге бетләрне теше белән сыткалавын үз күзләрем белән күрдем. Безнең арада бер хезмәтче башкорт бар иде. Бервакыт ул киеменнән бет тотып алды да, аны тырнагында изгәч, теле белән ялап куйды.

Аларның һәрберсе таяктан ирләрнең җенес әгъзаларын юнып ясый, аны бау белән муенына асып куя. Берәр сәфәргә җыенганда яисә дошман белән очрашканда шушы таякны үбә, аңа сәҗдә кыла.

Йа Тәнрем, ярдәмеңнән ташлама!—ди.

Бу хәл мина кызык тоелды һәм мин тылмачтан:

—Берәрсеннән бел әле, алар ни өчен болай эшлиләр, ана нинди мәгънә салалар?—дип сорадым.—Ни өчен тәнреләре итеп ирләрнең җенес әгъзасын сайлаганнар?

Башкорт безгә:

—Ни өчен дисезме? Чөнки мин якты дөньяга шушы нәрсә аркасында килгәнмен, башка тудыручыны белмим,—дип җавап бирде.”

Болгарлар турында да яза Ибне Фазлан: “Аларда ир-атлар белән хатын-кызлар, елгага төшеп, ят җирләрен каплап тормыйча, шәп-шәрә килеш бергәләшеп коеналар, әмма бу халыкта бернинди зина-фәлән кылу юк. Берәрсе шуны эшләсә—кем булуына да карамастан җәзасын ала: моның өчен башта җиргә дүрт сука тимере кагып куела, зиначының ике кулы белән ике аягы аларга ныгытып бәйләнә, аннан соң гаепле кеше муеннан бот төбенә чаклы балта белән икегә чабыла. Гаепле хатын-кыз да шундый ук җәзага тартыла. Шуннан соң зиначыларның һәр саны агачка бәйләп куела...Аларда карак-угрылар да зиначылар кебек җәзалана.”[1]

Әгәр дә болгарлар укымышлылыгы белән аерылып торган берәр кешене очратсалар:“ Бу кеше башкаларга караганда Тәнрегә хезмәт итәргә лаеклырак!”—диләр дә, муенына элмәк салып, аны агач ботагына асып куялар.

Йа, Хода! Мин моны белгәч шаклар каттым! Бүгенге болгар-татарларның холкында да бар бит шул нәрсә: кем акыллырак, талантлырак, укымышлырак, ул кешене хәзер батырырга, юк итәргә торалар. Бу нәрсә татарларның иң кабахәт милли үзенчәлеге!!! Нәкъ менә шуның аркасында кол хәлендә яшисең дә инде син, милләтем!..

Гасырлар узып, тора-бара бу халыклар үзара тагын да якынлашып, ахыр чиктә кушылып-катнашып беткәннәр. Әмма тарих уеп салган горефгадәтләрне вакыт җилләре дә, үзара буталышу-кушылу да юкка чыгара алмый, әлбәттә. Алар кан-күзәнәкләрдә яши. Алар бүген дә милләт әхлагының төп нигезен тәшкил итә.

## Түләү

Кәримәнең әнисе озакламый ireккә чыгарга тиеш. Бу мәсьәлә хәл ителгән, очы тәмам чишелер өчен бераз вакыт кына кирәк иде.

[1] “Әхмәд Ибне Фазланның Итил елгасына сәяхәте”. Солтан Шәмси тәрҗемәсе.– Казан:Тат.кит.нәшр., 1999.

Бер караганда кызның җилкәсеннән тау төшкәндәй булды, шулай да тынычланырга иртәрәк—моның өчен түлисе бар иде бит әле...

Йа, Хода! Бу Дөньяны коткаруны тагын хатын-кыз кулына калдырырсың микәнни!?

Ни булса да, тормыш алга китте кебек. Әнисе иреккә чыга, әтисенең "Мөгезсез" үгез дигән мәкаләсе район газетасында дөнья күреп, бик зур шау-шу куптарды. Әтисенә туктаусыз шылтыраталар, өйгә килүчеләр дә бар. Чөнки мондый кыю мәкалә барысының ушын алган, күпләрнең күзен ачкан, тагын да күбрәкләрнең отыры ачуын китергән иде. Район матбугатында җирле җитәкчелекне тәнкыйтьләп кара әле син! Бу кыюлык кына түгел, бу зур батырлык һәм тәвәккәллек тә иде. Дөрес, газета редакторын икенче көнне үк эштән алдылар алуын. Ләкин болай да пенсия яшендәге Мохтаров абыйның моңа әллә ни исе китмәде. Ул элегрәк елларда байтак вакыт районның партия комитетында эшләгән җаваплы хезмәткәр, пенсия яше җиткәч, газетага күчкән иде. "Безнең заманнарда фермадагы бер бозау үлсә дә колхоз председателенең теңкәсенә тияләр иде, ә хәзер колхозларның малларын фермалары-ние белән сатып җибәрсәләр дә бернәрсә юк!.."—дип, кереш сүз язган иде Мохтаров "Мөгезсез сыер" фельетонына.

Барыннан да бигрәк, әтисенең йөзенә нур кунды, күңеленә яшәү дәрте кереп оялады.

Алда тагын бер чишелмәгән төен тора иде әле. Шул турыда уйласа, Кәримәнең күз аллары караңгыланып, аягында басып тора алмый башлый, тиктомалдан хәле китә һәм борып-борып эче авыртырга керешә иде. Әйе, чишелмәгән төен... Әнилгә нәрсә, ул көлә генә, Кәримәнең халәтен анлап көлә.Әмма көлүе бик серле, нидер әйтеп бетермәгән төсле иптәш кызы. Ләкин әйтелмәгән сүзне кеше авызыннан тимер келәшчә белән генә тартып алып булмый. Кәримә ике ут эчендә. Соңгы араларда Руслан Даулатовичның күзенә дә күренергә ояла, качып йөри. Әлбәттә, бу яхшы гамәл түгел. Рәхмәт әйтергә кирәк, алдына тезләнеп, әнисен коткарганы өчен мең-мең рәхмәт укырга, бәлки: "Сезнең бу яхшылыгыгызны гомер онытмам!" дияргә дә кирәктер, тагын әллә ничаклы матур сүзләр өстәп әйтергә кирәк һәм тагын, тагын...

Әнил төрттерә: "Руслан Даулатовичны отблагодари инде син",—ди. Моны үзе дә яхшы белә Кәримә. Тик ничекләр итеп үз-үзен җинәсе соң?! Ничекләр итеп... бәллүр пыяла кебек чәлпәрәмә килергә торган күңелкәен, күкрәк читлеге эчендә бәргәләнгән йөрәккәен күндереп, андый адымга җөрьәт итәсе ?

Әниенне коточкыч бәладән йолып калу бәһасез нәрсә! Андый бәхетне дөньядагы бернинди кыйммәтләр белән дә бәяләп булмый торгандыр әле, бәлки?.. Ни булса—шул булыр?

Дөнья кыз алдында коточкыч авыр мәсьәлә китереп куйды. Монысы хак...

Кәримә аптырагач, фахишә кызның көндәлеген тагын кулына алып карады. Үзе ясаячак адымнарга, кылыначак гамәлләренә аклану эзләргә, күңеленә ышаныч индерергә иде исәбе... Берни булмагандай ятасың да... аннары душка кереп, тәненне генә түгел, җаныңны чистартасың. Әйтерсең, дөньяда бернинди үзгәреш тә булмаган. Әнә, кояш та нәкь вакытында һәм элеккеге урыннан чыкты, кичен ай да үз вакытында калыкты...

Мондый икеле-микеле халәткә, ниһаять, бер дә бер көнне чик куелды. Тагын Әнил ярдәмгә килде, ул аны кичке якта Руслан Даулатовичның фатирына алып китте. Алдан сөйләшмәгәннәр иде, ничектер бик кинәт кенә килеп чыкты кебек. Әмма юлда барганда Кәримә дулкынланудан чак кына һушыннан язмый калды, тик ни галәмәт, профессорның ишеген ачып керүгә, кызга каяндыр һәм нинди дер кыюлык ингән сыман булды, кыяфәтенә нур кунып, йөзләре ачылып китте.

Руслан Даулатович кызларны бик ачык йөз белән каршы алып, өчесенә дә кофе кайнатып алып чыкты. Аны-моны сөйләшкәләп утырдылар да,

беркавымнан тол профессор житди тонга күчеп, кызларга үзенен эше, диссертация хакында сөйләп алды.Әнил сумкасыннан компьютерда жыелган шактый калын кульязма алып, профессор алдына куйды.

—Сезнен кинәшләрне искә алып, өр-яңадан карап чыктым, Руслан Даулатович.

—Яхшы, яхшы, булдыргансын! Иртәгә фикеремне житкерермен.

Кәримә берни анламыйча тик аптырап карап утыра иде. Ләкин профессор ана да сүз кушып, мәсьләнен нидә икәнлеген тәфсилләп төшендерергә кереште. Баксан, бер караганда, мәсьәлә бик гади икән ләбаса. Ул Кәримәгә курс эше тәкьдим итә. Ләкин темасы гайре сәер "Яна манифест". Тезис-фикерләре дә сәер генә, ләкин кызык. Әнил исә бу эш белән бер елга якынлап кызыксына икән, шактый өлешен язып та бетергән инде. Кыскасы, Руслан Даулатовичнын студентлары шул хезмәтләре белән зур фәнни конференциядә чыгыш ясарга тиешләр. Әле тиз генә түгел, вакыт бар. Руслан Даулатович бу эшкә аларнын группадашлары Заһидны да тартырга уйлый икән, ләкин егеткә капылт кына үзе башлап әйтәсе килми. Заһидны кызлар әзерләргә һәм үз чиратында аны да ризалатырга тиешләр иде. Бу темалар әлегә сер, курс эшләре әзерләнеп беткәч тә анын хакында кешеләргә белдеререгә ярамый. Вакыты житкәч кенә, фәнни конференция вакытында, барысынын да маңгайларына бәреп, өчесе дә рәттән чыгыш ясыйлар, ноктаны профессор үзе куярга тиеш иде.

Кызлар, саубуллашып, чыгып киттеләр, тол профессор Әнилнең кульязмасын укый калды. Ләкин Кәримәнен күнеле барыбер нинди дә булса чишелеш көтә иде. Ул ишек янында басып торган Руслан Даулатовичны кочаклап битеннән үбеп алды да: "Рәхмәт Сезгә әнием өчен! Мин моны беркайчан да онытмам, Руслан Даулатович!"—дип әйтергә үзендә кыюлык таба алды.

Ишек ябылгач, Әнил үз алдына гына сөйләнгән кебек әйтеп куйды:

—Әни белән барыбер ачыктын-ачык сөйләшәчәкмен әле мин!

—Ни турында сөйләшәсен?

Әнил ана турсаеп карады да:

—Беләсен ич инде !—дип төрттереп куйды.

—Әйе, әйе, беләм шул...

—Әүвәл менә курс эшемне яхшылап язып бетерәм дә... фәнни конференциягә әнине дә чакырам...Аннан сон ачыктан-ачык сөйләшергә жинелрәк булачак.

Кәримәгә өн кергән иде инде, ул Әнилнең кулыннан кысып тотты да:

—Бу Руслан Даулатович... таякны артык бөкми микән? Хатын-кызны чүпкә санамыймы? Син ничек уйлыйсын?

Әнил ачу белән кулын тартып алды да нindидер ят тавыш белән:

—Әгәр... әгәр чүпкә санасамы?! Ул очракта ул сине, дустым, кылган яхшылыклары өчен, анадан-тума чишендереп, постеленә төртеп еккан булыр иде! Алай итмәде бит! Итмәячәк тә! Мин анын фатирында йоклап та калганым бар... кристальный чиста кеше! Төне буе үзенен хатыны турында, аны ничек яратканлыгы хакында сөйләп чыкты ул мина... Вот мәхәббәт булган!

Кәримә үзе дә сизмичә сорау биреп куйды:

—Булган?

—Әгәр мәхәббәт ике яклы булмаса, ул барыбер сүнүгә дучар...

Әнил хаклы дип уйлап куйды Кәримә... Рәхмәт Әнилгә! Әгәр ул, ул булмасамы?..

Йә ярый, ул да дустына бурычлы булып калмас әле, Алла боерса...

Коммунистларнын ин котырган чагы.Маркска, Энгельска һәм Ленинга, аларнын дистә еллар буе бик күп халыкларны шашындырган, юлдан яздырган тәгълиматләренә кизәнергә курыкмыйсынмы? дип сораячак әле бер дә бер көнне Руслан Даулатович Кәримәдән. Шул чакта Кәримәнен күз алдына әнисе, Сәгыйть Сәетович кунакханәсендә яткан буй-буй трусик кигән кап-корсак күз алдына килер дә ул: "Юк! Курыкмыйм!" диячәк.

* * *

Руслан Даулатовичның хатын-кызны "чүпкә" санамавы чынлап та хак иде. Ул моны бер лекциясендә студентларына да исбатлап күрсәтте. Кайсыдыр утырган жиреннән генә:

—Казан хатын-кыз кулында булмаса, Иван Грозный шәһәрне ала алмаган булыр иде. Казанны хатын-кыз саткан, Сөембикә саткан урысларга!—дигән сүзләр ычкындырган иде. Профессор әүвәл әлеге студент егетне эттән алып эткә салырга, наданлыкта гаепләргә уйлаган иде, ахыр чиктә, Сөембикә хакындагы чын тарихны сөйләп бирүне кулайрак күрде бугай.

—Минем өчен Сөембикә гомергә якты шәхес образы булып яши. Ул гүзәл, батыр, кыю хатын, көчле хатын. Башка Казан бәкләре чүпрәк-чапрак яки акча өчен урыска ата-анасын да сатып жибәргән шул дәһшәтле чорда Сөембикә алардан ун башка өстенрәк тора! Язмыш аны Сафагәрәйдән аерып, тол калдыра.

Үзен, ирексезләп, Мәскәүгә алып китәр алдыннан Сөембикә ире Сафагәрәй кабере белән хушлашканда сөйләгән сүзләренә игътибар итегез сез! Чәчләрен үрә торырлык! Бу ельязмаларда теркәлеп калган.[1] "Сөембикә кабер янына житкәч, башындагы алтын башлыгын алып ташлады. Моңлы тавыш илә еглап: "Әй, минем сөекле падишаһым Сафагәрәй! Күрәсеңме бөтен хатыннарыңнан артык яраткан хатыныңны! Хәзерендә мин сөекле угълың илә урыс йортына тоткын булып китәмен.Синең илә озак ханлык итмәдем...күп яши алмадым.Син ник миннән вакытсыз аерылдың? Ни өчен мине тол, сөекле угълыңны үксез калдырып, кара жир астына киттең? Син кайда торасың? Мин дә синең яныңа барыймчы, икәүләп бергә торыйкчы! Ни өчен син мине монда калдырып киттең? Күрмисеңме, синең бикәң үзебезнең мәңгелек дошманыбыз булган Мәскәү падишаһы кулына биреләдер. Мин ялгызым гына аңа каршы тора алмадым, үземә ярдәм итүче кеше таба алмаенча, ирексез аңа биреләмен. Әгәр дә тел һәм динебез бер булган падишаһ кулына тоткын ителгән булсам иде, мин һич кайгырмаган булыр, шатланып кына барыр идем. Сөекле падишаһым! Минем ачы еглауларымны ишетсәнә! Үзеңнең караңгы ләхетеңне ачып, мине үзең яныңа алсана! Синең ләхетең миңа һәм сиңа хан урындыгы, якты сарай булсыннар, әй сөйкемле падишаһым! Кайсы чакта мин рәнжеп, сиңа "үлүчеләр илә тугьмаучыларга куаныч булыр", дия идем түгелме? Шул мин әйткәнчә булмадымы? Син шуларны белмәдең, менә безгә хәзерендә тере көенчә кайгы һәм рәнжү килде. Сөйкемле падишаһым, үзеңнең яшь һәм матур бикәңне кабул итсәнә! Мине харап итмәсәнә! Минем матурлыгым илә дошманнар файдаланмасыннар иде. Мин синнән аерылмыйм, көлке һәм мыскыл ителер өчен, телләре һәм диннәре башка булган ят жиргә китмим. Сөекле падишаһым! Кем анда килеп минем еглавымны басылдырыр, кем минем ачы яшьләремне туктатыр, кем минем жанымның кайгыларын таратыр, кем минем яныма килер? Миңа һичкем юк... Мин кайгымны кемгә сөйлим: угълыма сөйлимме, ул сөттән аерылмаган, атама сөйлимме, ул моннан бик ерак, казанлыларга сөйлимме, алар бит үз ирекләре илә ант итеп мине урысларга бирделәр. Әй, сөекле падишаһым Сафагәрәй! Ник син миңа жавап бирмисең, ни өчен үзеңнең сөекле бикәңнең ачы яшьләрен ишетмисең? Менә монда, ишек төбендә, мәрхәмәтсез гаскәрләр торалар, алар мине, ерткычлар кыр кәжәсен алып киткән кебек, синең яныңнан алып китмәкче булалар. Бер чагында синең хатының булган, бөтен Казан падишаһлыгының бикәсе саналган кеше хәзерендә кызганыч тоткын, ярлы һәм арык кол булып калды. Борынгыдагы куанычлар, андагы кәеф-сафалар өчен хәзерендә еглаулар, ачы күз яшьләре килде. Электәге ханлык шатлыклары урынына мине рәнжүләр, кайгылар, бәлаләр чорнады. Мин хәзерендә еглый да алмыйм, күземнән яшьләрем дә чыкмый. Бетми торган ачы яшьләр илә минем күзләр сукырайды. Күп кычкырудан тавышларым кысылды!"—диде.

---

[1] Атласи. Себер тарихы. Сөенбикә. Казан ханлыгы. —Казан: Тат.кит.нәшр., 1993 ел.

Аудитория тулы яшьләр әлеге хәлне тынсыз калып тыңладылар. Кызларның күзләрендә яшь, егетләр исә авыз ачып сүз әйтерлек дәрәҗәдә түгелләр иде. Авыр тынлыкны Руслан Даулатович үзе бозды:

—Күрәсезме, Сөембикә ничек итеп иренә сыгына, үзенең хатын-кыз язмышы ирә кулында булган чакларны сагынып, ачы күз яшьләре белән искә ала! Сүз дә юк, гүзәл хатын, сокланырлык хатын, кыю, батыр ханбикә! Ләкин шуңа да карамастан, Сафагәрәй атлы иренең канаты астына сыенып яшәүне артыграк күргән сөйкемле, чын хатын-кыз!

Заһид кызык булсын өчен:

—Ә хәзерге кызлар чит милләт кешесенә кияүгә чыгарга атлыгып торалар, алучы гына булсын!—дип, сүз кыстырып караса да, авызын ерып көләргә атлыгып торучы булмады. Чөнки бу бер дә көлке түгел иде...

Руслан Даулатович фикерен:

—Моны борынгы тарих дип кенә карамагыз.Тарих гасырлар буена кабатланып тора ул...—дигән сүзләр белән тәгәлләде.

### Тагын... шул үгез..

Әнисе ireккә чыгу әтисенә бик тә шифалы дәва булды—аякларына җан керә башлады, бармаклары кыймылдарга керешге. Йа, Ходаем! Иң үтемле дәва яки җылы сүз, яки яхшы тәэссорат икән ләбаса!..

Ләкин бу бәхетле көннәрнең гомере кыска булып чыкты. Абруйлы кешеләргә нахак бәла яккан дип, "Химик" Кәримне судка бирде һәм бик зур суммада акча таләп итте. "Химик" белән судлашып торуның файдасы юклыгы һәркемгә дә көн кебек ачык иде, ул җинеп чыгачак иде һәм акчасын да каерып алачак иде. Бөтен бәла дә шунда—аларның андый акчалары юк иде.Гаилә янә хафага төште. Әнисе тагын Сәгыйть Сәетович кебегрәк бирәр шома кешенең кооперативына эшкә урнашырга йөри башлады.

Кәримә бу юлы озак уйлап тормады—туп-туры Сәгыйть Сәетович янына үзе китте.

Сәгыйть Сәетович кызны бик теләп кабул итте, нигәдер аның әнисенә дә ачу итми һәм кем кызы булуыннан да курыкмый иде, күрәсең. Әллә үзен гаепле сизә инде, чучка танау, дип уйлап куйды кыз. Әнә бит, шампан шәрабенә чаклы алып килергә кушты, өстәл өстен төрле нигъмәтләр белән тутырдылар.

Тик шампан шәрабенә бөкесе аша гына шприц белән аракы кушылганын, шуңа йокы даруы да өстәлгәнен каян белсен инде ул гөнаһсыз кыз бала?!.

Сәгыйть Сәетович, аның гозерен ишетүгә, алдан ук әйтеп куйды, акча белән үзем ярдәм итәрмен, әниеннең дә бездән алачак акчалары шактый әле, бүген үк исәпләтермен диде бит, рәхмәт төшкерe. Күрәсең, ул теге вакыттагы хәл өчен бик нык үкенә һәм гаебен әнә шул рәвешле юмакчы, гөнаһларыннан котылмакчы була иде ахырысы, бахыр...

Бу урыс президенты Борис Ельцинның исерек баштан Мәскәү күперennән сикергән бер матур, җылы кич иде...

*2004 ел.*

✱

# ШАГЫЙРЬ КҮҢЕЛЕ ДӘРЬЯДЫР...

ШАГЫЙРЬ ҖӘҮДӘТ СӨЛӘЙМАНГА 50 ЯШЬ

Соңгы елларда татар әдәбиятында кызыклы гына бер күренеш пәйда булып килә. Шигъриятта ниндидер яңа аһәң, яңача сүз, яңача фикерләү, заманча ритмнарга тәңгәл килерлек ритм көтеп зарыккан күңелләребезгә ямь һәм өмет өстәүче күренеш ул. Бәлки өметләнгәнебезчә, артык куәтле агым да түгелдер, әмма таш астыннан саркып чыккан чишмә кебек, ул үз юлын таба һәм акрынлап-акрынлап татар әдәби мохитына яңа яңгыраш, яна төсмер бирә шикелле. Мин биредә белемнәре буенча математик, физик, кибернетик, юрист, тарихчы вә гайре төгәл фәннәр буенча өлгереп җиткәннән соң, кинәт кенә әдәби таланты ачылып киткән каләм ияләрен күздә тотам. Элегрәк әдәбият дәрьясына, нигездә, филологлар килеп кушыла торган иде, ә хәзер әнә... нинди генә һөнәр ияләре юк. Һәм алар арасында инде җитлеккән поэзиясе белән күпләрне җәлеп иткән Җәүдәт Сөләйман аерым урын тота.

мин – диңгез дулкыны,
                  түз, елга!
түзегез, сугылган ярлар да.
үзем дә кыйналам ярларда,
үзем дә сыкранган елгада.

ни кылыйм – сыймыйм ла елгага...

ни кылыйм – сыймыйм ла елгага...
төшкәнмен җил куган болыттан.
мин – дәрья айкарга яратам,
диңгезгә, дәрьяга юл тотам.

гаеп юк сездә дә, миндә дә...

1997 елда "Идел" журналы китапханәсе" сериясендә чыккан "Күләгәләр" исемле китапта шагыйрь шулай дип яза. Ирексездән уйлап куясың, чыннан да шулайдыр. Чөнки Җәүдәт Сөләйман кылган гамәлләрне җиренә җиткереп башкару өчен өч кеше гомере дә җитмәс иде.

Иң беренчедән, ул—бүгенге фән дөньясында күренекле галим булып җитешкән шәхес. Татарстан Фәннәр Академиясенең мохбир әгъзасы, техник фәннәр докторы, Татарстан Фәннәр Академиясенең һәм Казан дәүләт университетының "Ясалма акыл проблемалары" исемле уртак лабораториясе мөдире. Бер үк вакытта Казан университетының гамәли математика һәм кибернетика факультеты деканы урынбасары, шул ук уку йортынын Информатика институты директоры урынбасары вазифаларын башкара. Аның фәнни тикшеренүләре ясалма акыл һәм педагогика яссылыгында алып барыла, аерым алганда, сәләтле балаларның социаль-психологик

адаптациясе, компьютер технологиясе һәм математик лингвистика өлкәләренә карый. Нәкъ менә шушы өлкәләрдә ул фундаменталь һәм гамәли кулланышка кердәй ачышлар ясады да инде. Аның тарафыннан йөзләрчә гыйльми хезмәтләр, мәкаләләр язылып, аларның гомуми күләме 190 басма табактан артып китә.

Икенчедән, ул—республикада гына түгел, инде Рәсәй күләмендә танылып өлгергән "Сәләт" хәрәкәтен оештырып җибәрүче һәм аның даими җитәкчесе. 1994 елдан бирле "Сәләт" лагерьларында фәннен теге яки бу өлкәсендә үзләрен күрсәтеп өлгергән меңнәрчә бала ял итте, белемен чарлады, иҗат оеткысын үстерү мөмкинлеге алды.

Өченчедән, ул—Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, җиде шигырь китабы авторы. Аз түгел бит!

Бу исемлекне дүртенчедән, бишенчедән, дип, әле байтак дәвам иттереп булыр иде. Чөнки каләмдәшебез Җәүдәтне без инде байтак аспирантларның, университет тәмамлаучы яшьләрнең диплом проектлары җитәкчесе буларак та, Россия Ясалма акыл ассоциациясе вице президенты буларак та, спорт һәм җәмәгать эшлеклесе буларак та беләбез. Бер карыйсың, ул Казанда, университет аудиторияләрендә мәш килә, икенче карыйсың, яңып-көеп сәләтле татар балаларының фестивален үткәреп йөри, өченче көнне кайдалыгы белән кызыксынсаң, ул Мәскәүгә китеп барган булып чыга, тагын берничә көннән йомышың төшеп шылтыратасың, Италиягә йә башка берәр илгә фәнни конференциягә китте, дип җавап бирәләр. Кайчагында барысына да ничек өлгерә икән ул, дип баш чайкап шаккатырга гына кала. Хәер, артык шаккатасы юктыр да, чөнки максатчан һәм үз-үзенә таләпчән кеше күп нәрсәне булдыра ул. Теләгең һәм анык максат-ориентирларың, алны-ялны белми, көнне төнгә ялгап эшләү сәләтең генә булсын. Ә Җәүдәт Сөләйман исә нәкъ шундыйлардан.

Аның белән танышканчы, дуслашканчы, математиклар һәм физиклар, гомумән, техник фәннәр дөньясындагы кешеләр белән якыннан аралашкан булмаганлыктанмы, мин аларны, дөресен әйтим, ничектер башкачарак итеп күз алдына китерә идем. Фикер йөртү рәвеше тимер мантыйк кысаларына кертеп утыртылгандыр, чынбарлыкны күзаллаулары тимер-бетон субайлар сыман артык турыдыр, хис-тойгы, элпәдәй юка кичереш вә хыял дөньясы, мәхәббәт һәм нәфрәт чигендә тирбәлеп торучы хиссияте рухия да алар өчен ят бер нәрсәдер сыман тоела иде. Алар өчен барысы да анык, ачык һәм алар барысын да ниндидер гыйльми вә фәнни аксиомалар, теоремалар, гипотезалар белән аңлата алалардыр дип белә идем шикелле. Дөрес, ул дөнья кешеләренә кызыгу һәм соклану кебегрәк нәрсә дә бар-барын, әмма барыбер алар миңа кайсы яклары беләндер урман кочагында үсеп утырган, таралмаган табигыйлеге белән матур куакны янсә ялгыз агачны түгел, ә яхшылап шомартылган, ышкыланган борысны хәтерләтә иде. Шулай иде... Гуманитарийлар хисчәнрәктер, табигыйрәктер, кайнарракты сыман тоела иде миңа.

Әмма 1996 елның җәендә булган бер вакыйга минем дәреслектән шактый ерак торган шушы сәер күзаллавымны пыран-заран китерде дә ташлады. Түбән Кама шәһәреннән ерак түгел урнашкан нарат урманында "Сәләт"нең чираттагы җәйге лагере эшләгән көннәр иде ул. Татарстанның барлык районнарыннан, күрше-тирә республикалардан һәм өлкәләрдән җыелган балаларга һәм яшьләргә белем бирергә Казан университетының яшь галимнәре: математиклар, кибернетиклар, татар филологиясе факультеты белгечләре килгән иде. Үзе белән ике улын алып килгән композитор Мәсгудә Шәмсетдинова "сәлкеш"ләргә татар легендалары, риваятьләре һәм ырымнары, музыка серләре турында сөйли, мин исә татар әдәбияты һәм гомумән татар дөньясы, ягъни "Татарика" дәресләре алып барам. "Сәлкеш" сүзен дә аңлатып китим әле, лагерьда балалар уйлап чыгарган бу яңа сүз "сәләтле кеше" дигәнне аңлата. Кыскасы, балалар белән үзебез дә бала-чага булып бетә яздык, алар белән аралашу һәр кешедә була торган ниндидер комплексларны кул белән алып ташлагандай юк итә икән. Мәсгудә белән без төшкә хәтле дәресләр бирәбез дә, өйләдән соң бүлмәләребезгә кереп бикләнәбез. Минем "Ишелеп төшкән бәхет" романын яза башлаган чак, һәр минут кадерле, һәр буш сәгатем яңа геройларымның язмышын тәфсилләп, уйланып үтә. Белгәнемчә, Мәсгудә дә тик ятмый, лагерь клубының рояль куелган бүлмәсеннән көне буе диярлек әллә нинди таныш булмаган аккордлар

янгырый. Димәк, ул да яза, иҗат итә. Рәхәт! Табигать кочагында яраткан кешеләрең арасында, яраткан эшең, күңеленә якын шөгылең белән булаша алудан да кадерлерәк мизгелләр бар микән?! Көннәр уза, язып тутырылган битләр арта бара... Безнең ни эшләп утыруыбыз балаларга әйтелгән, бимазалаучы, борчучы юк. Хәер, аларның үз дөньясы, үз мәшәкатьләре, өлкәннәрдә артык гамьнәре юк та.

Язып утырам шулай, кинәт бүлмә ишегенә кемдер килеп бәрелде, таләпчән шакый башлады. Кем булыр икән? Ризасызлыгымны сиздермәскә тырышып ишекне ачып җибәрсәм, каршымда еш-еш сулап Мәсгудә басып тора. Минем авыз ачып ниндидер сүз әйтүемне дә көтеп тормастан, һич кенә дә каршы төшмәслек итеп ярып салды бу:

—Флүс, әйдә тизрәк, яңа көй тыңлатам, яңа көй яздым...

Гомер бакый сабыр, һәр сүз вә ымнан үзенә бер мәгънә таба белүче, тыныч холыклы Мәсгудәне алыштырып куйганнар диярлек иде. Иҗат кешесенең мондый халәтен аңлатып булмый, бары сизенеп кенә була торгандыр да. Сүзсез ана иярдем.

...Рояль янына килеп утыруга композиторның күзләрендә нур кабынды, нечкә озын бармаклары салмак кына клавишалар өстендә бии башлады. Залны әле моңарчы беркайчан да ишетмәгән, киң янгырашлы, бәгыреннең үзәгенә кереп бөтәрләп алучы моңлы аһәң күмеп китте. Дулкынланудан карлыга төшкән тавыш белән Мәсгудә җырлый башлады:

Дәрьяларда ай-кояш бар, ай-кояш,
“Дөньяларда ниләр бар?” — дип, кил, сораш.
Дөньяларда таптым сагыш, таптым моң,
Әти, җаным, киңәшергә инде соң...

Белмим, әллә нишләп бала йоннарым кабарды, ирексездән күзләремә яшь тыгылды. Бу көйдә, бу сүзләрдә әллә нинди бетмәс бер моң, яшь аралаш кемгәдер эндәшергә омтылу, үкенү һәм чарасызлык ята иде кебек. Әнә шул моң бөтен кан тамырларыңа кереп тула да йөрәгеңне музыка белән бергә сулкылдарга мәҗбүр итә. Мин үземнең нарат урманы ешлыгына чумган ниндидер лагерьның клубында утыруымны да, янымда кемнәр, нәрсәләр барлыгын да онyттым, күңелем күптән вафат әтием белән сөйләшә, аңлаша, аннан киңәш сорый иде кебек.

Бу сәер халәттән Мәсгудәнең сүзләре аерды:

—Ничек? Ошадымы? Җәүдәт шигыренә бу,—диде ул ниндидер ят бер тавыш белән. Күрәсең, ул үзе дә мин кичергән хисләр дөньясыннан чыгып җитә алмаган иде әле.

Җавапка нәрсә әйткәнемне төгәл генә хәтерләмим, чөнки яңа көй авторының да күзләрендә җемелдәгән яшь бөртекләре тәмам тетрәндергән иде. Ә ул исә яна сорау бирде:

—Әллә елагансың инде?—диде.—Чынлапмы!..

—Ирләр юри елый алмый...

Сүзсез дә аңлашып була торган шушы халәттә күпме утыргандыр, белмим, залга Җәүдәт Сөләйман килеп керде һәм сәерсенеп безгә карап тора башлады.

Мәсгудә бер сүз дә әйтмәде, рояльгә иелде һәм инде миңа таныш, тетрәндергеч аккордлар тагын залны күмде, Мәсгудәбез исә безнең барлыгыбызны бөтенләй оныткандай җырлады да җырлады:

Минем янып-көюләрне ни басар?
Безнең алда көрешүләр ни гасыр?
Чишмә-судыр дигән идем бу дөнья,
Юк, түгелдер көмеш агым, бу — дәрья.

Соңгы аккордлар яңгырады. Исемне җыеп залга яңадан күз салганда Җәүдәт стенага капланган һәм куллары белән таш стенаны төя-төя үкси иде. Җилкәләре калтырана. Мәсгудә белән без дә сүзсез идек. Олы ир кешене тетрәндергән көйнең аһәннәре әле һаман күңелебезне сулкылдата иде бугай.

“Әй, дәрья, дәрья” дигән бу шигырьне Җәүдәт туган ягында, Чувашиянең Батыр районы Кызыл Чишмә авыл мәктәбендә озак еллар укытучы булып эшләгән, әле күптән түгел генә вафат булган кадерле әтисе истәлегенә язган иде.

Сонрак ул жырны мәшһүр жырчыбыз Хәйдәр Бигичев жырлап караган, радиостудиядә яздырырга да теләк белдергән иде, әмма ин соңгы мизгелдә баш тартты.

—"Әти, жаным, кинәшергә инде соң..."—дип жырлый алмыйм, минем әтием исән бит әле. Аңламас ул мине,—диде ул.

Ни кызганыч, халкыбызның Илһамнан кала икенче сандугачы булып танылган талантлы жырчы озак яши алмады, берничә елдан үзе дә бакый дөньяга күчте. Жырлаган, әмма яздырырга өлгермәгән жыры исә балаларына истәлек булып калды. Хәзер ул "Сәләт" лагерьларында жырлана, шул жырны искә төшергән саен мин кеше күнеленең төпсез дәрья икәненә ныграк ышана барам. Ул дәрьяга математик та, кибернетик та, шагыйрь дә, политик та, табиб та һәм... дөньядагы меннәрчә-меннәрчә башка һөнәр кешеләренең жан жылысы, кичерешләре, шатлык вә кайгылары сыйган. Кеше күнеле—төпсез дәрья шул!

..."Сәләт" лагерьларында кулга-кул тотынып эшләү, әдәбият мәйданында фикердәш вә аркадаш булу белән бергә, язмыш шаяруымы, безнең Аккош күлендәге дача йортларыбыз да Жәүдәт Сөләйман белән күршедә булып чыкты. Табигый, байтак кеше дачага ял итәргә, вакыт уздырырга килә. Атна буе тормыш мәшәкатьләреннән, эштәге ыгы-зыгыдан туйган кешенең бер бушанып аласы килү табигый хәл. Ә Жәүдәт Сөләйман дигән иптәшебез исә, дачага да эшләргә, ижат итәргә, фәнни мәкаләләренең асылы хакында ялгыз калып уйланырга килә, дисәм, ялгышмамдыр кебек. Ничә тапкыр шаһит булганым бар, аның тәрәзәсендә төнге өчләргә кадәр ут сүнми. "Бераз язгалап, сызгалап утырдым әле",—ди ул икенче көнне очрашкач гадәти бер нәрсә турында сөйләгәндәй иттереп. Баксаң, үз-үзенне аямый эшләү, куйган максатына үзенне тулаем багышлый белү дә аның өчен гадәти бер хәл икән. Моны күпләр булдыра алмый, дип беләм.

Шагыйрьләр турында язу ифрат авыр эш. Чөнки кайчагында ике-өч юллык строфага да шагыйрь кешелек мең еллар буе уйланган, баш ваткан ниндидер бер проблеманың өстәмә төсмерен күзалларлык тирән мәгънә сала белә. Шагыйрь Сөләйманның тарих төпкелләренә чумарга омтылуы да юктан түгелдер. "Сөләйман әсәрләрендә ерак тарих—әкият түгел, ә бүгенге катлаулы нәрсәләрнең гасырлар-дәверләр катламы астында калган сукмакларын бүгенге шагыйрь күз нурлары белән капшап карау. Ул татар халкының Алтай якларына тоташкан тамырларында кан булып ага, уйлана, борчыла", дип яза Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис Сөләйманның "Казык" исемле шигырь китабына язган кереш мәкаләсендә. Моның белән килешергә генә кала. Чөнки Жәүдәт Сөләйман бүгенге заман фәненең иң актуаль проблемаларын хәл итүдә үз юлын эзләү белән бергә, шигърияттә бүгенгенә чал тарих белән тоташтыручы, онытылган, инде күздән югалган жепләрне табарга омтылучы диңгез гаувасы* да.

Ниндидер бер тантанада Татарстанның халык язучысы Гариф ага Ахунов юбилярны котлап бик мәгънәле сүзләр әйткән иде. Ялгышмасам, алар болайрак янгырый:

Егерме яшендә егеткә көч кирә,
Утыз яшендә егетнең кулыннан эш килә,
Кырык яшендә егеткә аң кирә,
Илле яшендә егеткә дан килә.

Бу шигырьне искә төшерүем юктан түгел. Каләмдәшебез, үзенчәлекле язу эслүбенә ия шагыйрь, житлеккән галим һәм эзләнүчән педагог Жәүдәт Сөләйманга март аенда илле яшь тула. Ул инде кеше тормышындагы барлык бу стадияләрне үтеп, житлегү, жигелеп эшләү чорына кергән икән. Ә хезмәтең булса дан һәм мактау, замандашларыңның тануы да озак көттермәс. Хәер, ул бу танылуга инде бүген үк лаек булган сирәкләребезнең берседер дә.

**Флүс ЛАТЫЙФИ**

*Гаувас* – чумып диңгездән энже-маржан эзләүче.



**Сөләйман**

# ӨЗЕЛГӘНЕМ, ҖИРДӘ ЭЗЛӘГӘНЕМ...

## Казык

**Казык кактым.**
**Сагынуларым,**
**Шатлыкларым,**
**Уй-хисләрем туплап**
**бер казыкка.**
**Бәйлә шунда**
**Хис-тойгыңны,**
**Моңнарыңны.**
**Казык тирәли бит**
**җирләр мул азыкка...**

***

**Үз Рухыма кулай итеп,**
**Койдым шигырь калыпларын.**
**Минем кылган гамәлләргә**
**Мөһер сугар оныкларым.**

**Үзем—зиһен,**
**Бер мизгелгә тәнгә ия**
**фани фәкыйрь,**
**Әллә канат, әллә йөгән—**
**Миңа тынгы бирмәс фикер.**

**Ошбу тәнсез—**
**фикер өнсез,**
**Ошбу тәндә—**
**үзем теләп...**

**Җиһан-дәрья гизеп йөреш**
**Өнсез өннең өнен өнәп.**

***

**Ап-ачык,**
**ап-ак,**
**яп-якты—**
**...әҗәл.**
**Буталчык,**
**кап-кара,**
**караңгы—**
**...яшәү.**

Гомер бакый тартылабыз—
ачыклыкка,
аклыкка,
яктылыкка...

* * *

Аллы-гөлле
чигү чигә сылу—

...күңелендә
чәчкә-гөлле болын.

Әби-карчык
салмак кына
йон эрли—

ә орчыкка
күңелдәге
эңгер
үрли.

* * *

Өзелгәнем, җирдә эзләгәнем—
язлар сыйдырырлык бөреләр,
кояш сыенырлык күңелләр.

...Җирдә сөрү, көзге сөрү бара,
җем-җем уҗым—язга ялгама.
Уҗым кырын күреп, урап кайтсам,
өзелеп килгән өмет ялгана...

Һәр тамчыда
    чагылмыйдыр
умырзая елмаюлы яз-бикә...
Һәр тамчыда
    күзләмә кояшны...
Шыбыр-шыбыр коя тамчы-яңгыр—
тып-тып иткәннәре—кояшлы...

Язлар бит ул күктән күккә ята,
офыкларны этеп як-якка,
тамчы сыйдырмый, дип
    килми каламыни язлар,
сыенырлык бөре бар чакта.

* * *

Рәссамнарга өлге булыр төсләр—җиде күктә,
Елкы-йөрәк кирәк—күрим әле, сайлыйм, дисәң.
Нинди нурлар кушылуы мәгъкуль, нинди моңнар,
Ашып күккә, өстәп төсләр кушыйм, салыйм дисәң.
Тәңре юлы—мәхәббәттән мәхәббәткә имди,
Хәятыңның һәр мизгеле түгелме сөюдән?
Ак-караның кушылмасы—олы бер сер имди,
Рәсем-кыйссаң шул серләрне таныптыр чигелгән.

Иңнәреңдә гомер бакый—татар күге-аты,
Син күтәргән күкләр биек—булырмы очкан кош?
Канатлары талмасмы дип, төшсенме күк каты?
Айны узып яши күрсен Шагыйрь элгән балкыш…

## Үлән арасында имән

Синең җаның, синең егәрлек,
сыямыни фани гомергә!
Җиде буын китеп карау кирәк,
җиде буын җыйган моң-җан кирәк,
синең җанны тулай күрергә…

…Үлән арасында
чак-чак күренерлек,
үсә сыек чыбык,—
җилдән өзелерлек…
…Шушы нечкә сыннан
үсәр диеп имән
кайдан белсен үлән—
үлән җанлы үлән.

***

…И талпына
йорт казлары
күккә—
киерелә каурый кочак
…юкка.
Ярый әле киек казлар күктә…
Каз оча дип,
кем ышаныр иде,
юкса…

…Адәм бии, оча сәхнәдә.
Аяк түгел, хәтер этәрә.

…Атлантида
күге
хәтердә…

*1995-2002*



## Әхәт Сафиуллин

# КЕШЕНЕ ӨМЕТ ЯШӘТӘ

ПОВЕСТЬ

“Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә”,—дип юкка гына әйтмәгәндер адәм баласы. Бу сүзләр кайгы-сагыштан ут йотып йөргән, бик борчулы вакытта гына әйтеләдер.

Чыннан да шулай бит. Тормыш үз җае белән тәгәри дә тәгәри. Дөнья әйләнә-тулгана. Кояш чыга да байый, көн артыннан көн үтә. Җир үз күчәре тирәсендә зыр килә. Буыннарны буыннар алыштыра. Ә кешеләр, боларны бөтенләй сизмәгәндәй, гел үз эшләре белән мәшгуль: гаилә коралар, бала табалар, киләчәгенә зур өметләр баглый-баглый аны үстерәләр; эшлиләр, кавышалар, аерылышалар, каядыр чабалар, ашыгалар. Кыскасы, адәми затның бөтен уен, бөтен эчен-тышын дөнья мәшәкатьләре чолгап алган. Аның күңелендә—якты өметләр, берсеннән-берсе матур уй-хыяллар. Хәзергедәй авыр заманда менә шушы өмет, хыяллар булыша аңа. Тормышның күп кенә ачысы-төчесеннән аны шулар йолып кала.

Катлаулы нәрсә бу тормыш дигәнең! Җылы-җылы өметләре дә, якты-якты хыяллары да, ачы кайгы-сагышлары да никадәр аның! Борынгы бабаларыбыз әйтмешли, барысы да адәм баласының аяк астында йөри.

Дөресе дә шулай. Әле атна-ун көн генә элек Мәрзия әби дә үзенең сөякләре тырпаеп торган ябык иңбашларына кинәт кенә менә шундый авыр кайгы ишелеп төшәр дип күз алдына да китермәгән иде. Күз алдына китерү түгел, мондый нәрсәнең ике ятып бер төшенә дә кергәне юк иде. Кеше ышанмаслык хәл бит: аттай томырылып йөргән җиреннән тап-таза картың төн эчендә үлеп китсен әле!

Кичен эштән кайтты, көндәгечә, бергә сөйләшә-сөйләшә ашап-эчтеләр. Аннары Мәрзия әби үзе аш бүлмәсендә табак-савыт юа калды, ә карты Нургата, сабына резин шнур бәйләгән күзлеген киеп, телевизор каршысына килеп утырды. Ярата иде шул Нургатасы бу хикмәтле тартманы. Күз керфекләренә йокы кунганчы карап утырыр иде шуны.

Эшләрен бетергәч, Мәрзия әби үзе дә түр якка чыкты. Бергәләп “Шинель” дигән кино карарга утырдылар. Менә шул киноны карап бетергәнче, гомердә булмаганны, Нургатасы ике мәртәбә тәмәке тартып керде.

—Ни булды сиңа бүген, атасы?! Нишләп тыз-быз йөрисең?!—дип гаҗәпләнде Мәрзия әби бу хәлгә.

---

Әхәт САФИУЛЛИН (1936) *—язучы; «Онытылган вәгъдә», «Сер бирмәдек», «Тулгана дөнья» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

—Үзем дә белмим, эч поша әллә нигә...—диде моңа каршы карты.

—Берәр җирең-мазар авыртмыйдыр ич? Сызланасың мәллә?

—Минем кайчан авыртканым бар?! Аллага шөкер, сызланган җирем дә юк,—диде Нургатасы.

—Күз тимәсен, диген! Авыру ерак йөрми ул,—дип, аның мактануын ошатмагандай, Мәрзия әби аңа кырын күзе белән карап алды.

—Авырырга исәбем юк әле, анасы. Әйтәм бит, күңел урынында түгел... Күңел уйный...—диде Нургата карчыгына.

—Хәерлегә булсын, атасы. Үтәр, Алла боерса, үтәр. Әллә, дим, лимон белән чәй эчеп карыйсыңмы? Ясыеммы?

—Кирәкми, кирәкми! Әле генә тордык бит чәй янынннан,—дип кулын селтәде Нургатасы.—Борчылма юкка! Карале, кара, хәзер салдыра бит болар Акакийның шинелен! Валлаһи, салдыра! Ул заманнарда да булган кеше чишендерүче азгыннар, ә! Их, явызлар! Их, адәм актыклары! Кеше тырыша-тырмаша кием җиткерде мескен, ә болар... әзергә бәзер...

Менә шулай гадәттәгечә үткән иде аларның соңгы кичләре. Ә иртән: "Гомер бу вакытка кадәр ятканы югые, нишләп тормый соң бу карт",—дип янына килсә, тәненә тикле суынып беткән иде Нургатасының.

Кинәт кенә иңенә ишелеп төшкән тау хәтле кайгысыннан нишләргә дә белмичә, Мәрзия әби тәмам катып калды. Еларга да, кычкырырга да белмәде, мескен. Салкын тәне җылынсын, дип картының өстендәге юрганын рәтләп маташа бит әле! Һай, мондый кайгыдан, хатын-кыз түгел, дөньяның ачысын-төчесен татыган ир-атың да акылдан язар.

Мәрзия әби нәрсәгә тотынырга, кая бәрелергә белмичә, бүлмәләре буенча әрле-бирле йөренде-йөренде дә, альяпкыч итәге белән битен каплап, үксеп елап җибәрде. Нишләргә? Кайсы якка йөгерергә? Кемне чакырырга? Кемгә кычкырырга? Нишләсә дә, япа-ялгызы иде.

Аннары ул, айнып киткәндәй, абына-сөртенә ишеккә таба ашыкты. Чыгып, уң як күршеләре ишеген төяргә тотынды.

—Исмәгыйль улым! Люда кызым! Ачыгыз әле, ачыгыз, Исмәгыйль улым! Люда-а!

Шулай бераз суккалый-төя торгач, кинәт ишек ачылып, аннан күршеләре Исмәгыйльнең гаҗәпләнүле тавышы ишетелде:

—Син нәрсә, Мәрзия әби?! Янгынмы әллә?!

—"Скурый"га шалтырат сана, Исмәгыйль улым! Нургата бабаң үлде. Үлде Нургата... Харап булды, мескен! Тиз чакырта күр, улым!—дип өзгәләнде карчык, ярым ачылган ишеккә өмет белән карап. Әйтерсең әле соң түгел, Нургатасын коткарып була иде.

—Үз акылыңдамы син, Мәрзия әби?! Белешеп сөйләшүеңме бу?—диде күршесе, ачылып җитмәгән күзләрен уа-уа.—Ни булды?

—Үлде... Нургата бабаң үлде, улым! "Скурый" чакырта күр тизрәк!—дип такмаклады карчык.

Шулчак тавышка Исмәгыйльнең хатыны Людмила да чыкты.

—Ни бар? Ни булган?—дип сорады ул, иснәнеп.

—Әнә, Мәрзия әби әлләни сөйли анда, диде аңа ире.—Нургата бабай үлгән, ди... Әллә белеп сөйли, әллә белешмичә...

—Йокы бүлеп йөриләр шунда,—дип мыгырданды Людмила. Тик аннары, Мәрзия әбине күреп, уңайсызланып калды. Һәм, ишекне киңрәк ача төшеп, аңа дәште:

—Ни булды, әби? Коля бабай авырыймыни?

—Үлгән, ди. Ишеттеңме? Үлгән!..

—Чакыр инде, улым, чакыр тизрәк! Килегез, диген. Әй, Ходаем, әй, Аллам! Ниләр генә булды соң бу Нургатага, ниләр булды?! Кичен генә сау-таза ие бит...

Инде Исмәгыйль дә, йокысыннан тәмам арынып, Мәрзия әбинең юкка гына хафаланмавына ышанып җитте. Шундук милициягә дә шалтыратты, "Ашыгыч ярдәм" машинасын да чакырды.

Озак та үтмәде, әбинең ишеген шакыдылар. Кабалана-кабалана барып ачты. Анда ике милиционер басып тора иде. Аларны күргәч, Мәрзия әби, гәрчә хәзер киләселәрен белеп торса да, коелып төште. Әйтерсең картының үлемендә гаепле, хәзер аны кулга

алачаклар. Хәтта бу уйдан күз аллары караңгыланып китте, кинәт ниндидер тирән упкынга егылып төшкән сыман булды. Калганын төшендә күргән кебек кенә хәтерли. Аннан кабат-кабат ни турындадыр сораштылар, нидер яздылар. Бераздан табиб та килеп житте. Ул килгәч, бергәләшеп, әйләндерә-әйләндерә Нургатасын карадылар.

Милиционерлар табиб белән ярым пышылдап ни турындадыр сөйләштеләр дә, Нургатасын носилкага салып, алып чыгарга жыендылар.

—Кая алып барасыз аны?!—дип илерде Мәрзия апа.—Бирмим мин аны сезгә, юк, бирмим!—Ул, аны гәүдәсе белән каплагандай, өстенә иелде.—Бирмим дигәч, бирмим!

***

—Бәлки, булышырга кирәк булгандыр?—диде Людмила, ире барасы жиренә жыенып йөргәндә.—Ялгызы бит, нишләсен?..

—Син нәрсә?!—диде аңа Исмәгыйль, күзләрен зур ачып.—Күп булыр монда ялгызлар! Әйткәч тә, күрше генә ич алар безгә. Ә күршелек: "Исәнмесез!"—дип баш кагудан узмады.

—Ә Коля бабай безнең кухня кранын ничек яхшы итеп рәтләде!—диде Людмиласы, үз сүзен сүз итәргә тырышкандай.—Кран шыбырдап ага башлагач, нишләргә белмәдек. Ә ул:—Кая, нәрсә булды анда сезнең?—дип керде дә унбиш-егерме минут эчендә төзәтеп тә куйды! Икенче елы, ник тамчы су аксын!

—Әллә нәрсәләр хәтерлисең син...—дип йөзен жыерды Исмәгыйль.—Соң, мин дә, булышмады, димим бит. Яхшы кеше иде Нургата бабай. Әйе, ярдәме дә тигәне бар. Ә нишләргә кушасың миңа хәзер? Кая жыенганымны беләсең ич! Сөйләшенгән, килешенгән, ничек бармый каласың?

—Беләм, беләм. Ярар, алайса, үз жаеңны кара!

—Белгәч! Бүген генә димәгән, йә көмешергә туры килер...

—Үзеңә кара. Үзеңнекен үзең беләсеңдер,—дип сөйләшүләренә нәтиҗә ясагандай итте хатыны.

Әйе, бүген юлына таш яуса да барырга тиешле жире бар иде Исмәгыйльнең. Шәһәр читендәге гүзәл табигать кочагында, урманда дача урыны карарга, үзе әйтмешли, бер "солидный" кеше белән сүз куешканнар иде. Әле анда барып житәсе дә бар.

"Тапкан үләр вакыт!—дип уйлап алды Исмәгыйль, күңеленнән Нургата бабасына шелтә белдереп.—Монда кеше дачага урын алырга йөри, ә ул... яткан жәелеп! Кышын үлсә ни булган?.."

Исмәгыйль ашыга-ашыга баскычтан төшеп барганда Нургата бабайны моргка алып китүчеләрне куып житте һәм бу очрашудан эсселе-суыклы булып китте.

"Ниткән күңелсез көн соң бүген?!—дип куйды ул үз-үзенә.—Ачы таңнан, үлде, дип уяттылар, хәзер, әнә, юлны мәет кисеп чыкты".

Күңелендә тагын шик-шөбһә уянды. Әллә бүген юлы уңмаячакмы? Юк, юк, бу шулай очраклы гына килеп чыкты. Моны начарга юрарга ярамый.

Ул бераз тынычлана төште. Кесәсеннән ачкычлар бәйләме чыгарып, шулар арасыннан гаражныкын эзләде. Гаражын ачып керде дә, канына сеңгән гадәте буенча, машинасының тәрәзәләрен сөрткәләп алды. Аннары машинасын чыгарып, гараж ишеген дүрт йозагы белән шартлатып бикләп куйды да юлга кузгалды.

Ниһаять, аның тагын бер хыялы тормышка ашачак! Әйе, шулай булырга тиеш. Инде төгәл сөйләшенгән ич.

Исмәгыйль машинасының көзгесенә карап алды. Аннан үзенең чиста, шома итеп кырылган кара тутлы түгәрәк, чибәр йөзен, елкылдап торган озын, кара чәчләрен, кызларныкыдай нечкә кара кашларын күреп, менә бит без нинди, дигәндәй, елмаеп, көзгедәге Исмәгыйльгә соры күзен кысты. Сәлам, янәсе!

"Урыны ни тора бит, урыны!—дип үзе дә сизмәстән башын чайкап куйды ул.—Боровое Матюшино инде ул Васильево яисә Атлашкино түгел! Юкка гына Татарстан корабының рулендә утыручы абзаларың ял итә торган урын димиләр аны! Димәк, республикабызның патша-падишаһлары белән бер юлдан йөриячәк Исмәгыйль абзагыз!—Ул, алтын тешләрен күрсәтеп, үзалдына елмаеп куйды һәм, шул елмаюын күрергә теләгәндәй, янадан көзгегә карады.—Менә шулай безнең эшләр, агайне! Бу эш тә уйлаганча барып чыкса, кешеләрнең күзләре машина фарасы шикелле булыр иде! Көнләшүдән нишләргә белмәсләр иде. Әле болай да: "Ничек шулай жайлы бара

синең эшләр!"—дип гаҗәпләнәләр. Ә квартира алгач? Таныш-белешләрнең күзләре шар булды, гаҗәпләнмәгән кеше калмады.

Тормышның җаен тоя белергә кирәк! Агымсудай аккан тормыш агышын өйрәнергә, шуннан файдаланырга кирәк!"

***

Ул, солдат хезмәтен тутыргач, туп-туры Казанга, әнисе ягыннан туган тиешле Хәдичә апаларына кайтып төште. Кечкенәдән үзен шәһәр кешесе итеп күрергә тели иде ул, чөнки авыл тормышы үзенең язгы-көзге пычраклары, авырлыгы, шыксызлыгы һәм тынычсызлыгы белән аның бала күңелендә үк ниндидер сөйкемсезлек уятып өлгергән иде. Әти-әниләрен генә кара! Эшлиләр, эшлиләр, ләкин башкалар кебек үк, бер дә алга киткән җирләре күренми. Ә бит бер караңгыдан икенчесенә кадәр эшлиләр түгелме?!

Ә шәһәр тормышы исә бөтенләй башкача төсмерләнә иде аңа. Һәр ел саен, бигрәк тә җәйге айларда, туган авылларына күпме кеше кунакка кайта! Күз явын алырдай итеп киенеп-ясанып! Ә монда? Хәер, ниен сөйләп торырга инде аның! Авыл тормышын шәһәрнеке белән чагыштырып буламы соң?!

Исмәгыйль, һәр авыл баласы шикелле үк, кечкенәдән олылар кулы арасына кереп эшкә өйрәнгән кеше буларак, армиядән кайтуга ук эшкә урнашу турында уйлый башлады. Әле ул чагында бернинди хыялый уйлары булмаса да, исәбе кеше шикелле яшәү иде. Шәһәрчә киенергә, шәһәрчә ашарга, гомумән, шәһәрчә яшәргә! Шуңа күрә эшкә дә юк-бар җиргә урнашасы килмәде. Эштән курка торганнардан түгел, эше авыр булса булсын, тик акчасын уч тутырып алырлык булсын. Хәзер аңа акча, күп акча кирәк, чөнки бераз кеше рәтле киеним дисәң, ай-яй, күпме чыгарып салырга тиешсең. Ә үзенә кием-салым җиткергәннән соң бераз әти-әнисенә дә ярдәм итәсе килә. Шунсыз ярамый—ул алар алдында бурычлы. "Әнә, Фәрхенурның Казандагы малае күпме акча салган!"—дип әйтерлек булсын.

Күп кенә яшьләр, гадәттә, унны бетергәч, югары уку йортына керергә хыяллана. Дөрес, мондый уйның Исмәгыйль күңеленә дә килгәне булды. Тик ул аны шундук кире куды—уку аны бер дә кызыксындырмый иде. Күңеле ятмый иде укуга. Ун классын әти-әнисенә тел-теш тидермәсеннәр, үзен ялкаулыкта гаепләмәсеннәр өчен генә тартып-тырышып тәмамлады. Һич тә укуга чын күңелен салып түгел. Хәтта югары уку йортына керергә өндәүче белдерүләргә күз дә атмады.

Шулай эзләнеп йөри торгач, Исмәгыйль бер мәлгә аптырап калды: һөнәр ияләре кирәк тә, һөнәр ияләре кирәк! Ә һөнәре булмаганнарга нишләргә? Дөрес, аларны да күп җирләргә чакыралар, тик түләү ягы гына аз шул. Андый акча белән ничек яшәргә, ничек өс-баш җиткезергә кирәк?! Әйе, тормыш дигәнең, ул уйлаганча, шәһәрдә дә бик җиңел түгел икән бит! Ләкин, нишләмәк кирәк, болай бушка вакыт уздырып йөргәнче, тизрәк эшли башлыйсы иде. Ул бу турыда Хәдичә апасы белән киңәшләшеп алды.

—Минемчә-ә,—дип сузды туган тиешле апасы, Исмәгыйльнең уй-фикерен тыңлаганнан соң,—минемчә-ә, кибет тирәсенә елышсаң, хәзерге заманда бер дә начар булмас, улым. Дәлнийшем укырга теләмәгән кешегә менә дигән урын, минемчә...—Уку мәсьәләсен телгә алуы, үзенчә, ир туганының кабыргасына төрттерүе булды бугай, чөнки ул аны югары уку йортында күрергә теләгән иде. Юрфакка керергә кыстап аптыратканы да бар. Тик ахырда, уеннан аны бернинди сүз дә, бернинди үгет тә кире кайтара алмасына ышангач кына, үгет-нәсихәтеннән туктарга мәҗбүр булды.—Хәзерге заманда менә дигән урын, минемчә. Сәүдә тирәсенә елышканнар дөньясы хәзер. Кемнең кулында, шуның авызында, дигән борынгылар.

Хәдичә апасы да шулай дип торгач, Исмәгыйль икенче көнне үк туп-туры "йөкче кирәк" дип белдерү язган азык-төлек кибетенә китте. Керде, директорны сорады. Шунда бер сатучы, прилавка ишеген ачып, аны эчкә кертте дә, алар, әллә ниткән капчыклар, каплар, әрҗәләр белән тулы коридор буйлап бара торгач, бер бүлмә янына килеп туктадылар. Сатучы хатын ишек шакып алды, аннары аны бик саклык белән генә яртылаш ачып:

—Сезгә килгәннәр, Елизавета Сергеевна!—диде дә, җиңелчә генә Исмәгыйльнең җилкәсенә төртеп алды: бар, янәсе, кер!

—Исәнмесез! Мин ни... белдерү буенча. Грузчик мин...—диде Исмәгыйль, ишек бусагасын атлап. Һәм, инде канына сеңгән солдат гадәте буенча, куллары белән гимнастерка итәген рәтләп куйды.

—Узыгыз, уз! Утырыгыз!—Елизавета Сергеевна дигәннәре нидер язып утырган жиреннән зәңгәрсу чәчле башын күтәреп елмая төште һәм зур булмаган шушы кабинетына бик ятышып бетмәгән диванга таба күрсәтте.—Тыңлыйм сезне, тыңлыйм.

—Эш турында мин. Белдерү буенча... Эшләргә телим...—диде ул.

—Бик яхшы,—диде директор, янәдән бик мөлаем елмаеп. Аның бу елмаюы Исмәгыйльгә шулкадәр эчкерсез, шулкадәр самими булып тоелды, ул ирексездән тагын гимнастерка итәген тарткалап куйды. Күрер күзгә бик тә чибәр, яшь иде бу хатын.—Кирәк безгә бер грузчик, бик кирәк.

"Шундый яшь, ә инде үзе кибет директоры!—дип сокланды Исмәгыйль, аңа карап.—Утыз яшьләр тирәсе генәдер әле бу чибәр хатынга! Югары уку йортын бетергәндер инде бу..."

—Утырыгыз!—диде директор, нинди дер тирәннән килгән кискен тавыш белән. Үзенә карышуны өнәмәгән, таләпчән тавыш иде бу.

Исмәгыйль, таләпчән боеруга буйсынып, күрсәткән урынга килеп утырды.

—Күрәм, син әле генә солдаттан кайткансың,—диде Елизавета Сергеевна, кинәт "сез"дән "син"гә күчеп.—Шуңа күрә әле бозылырга өлгермәгәнсеңдер, дип уйлыйм. Ярар, алам мин сине эшкә. Иртәгәдән башларсың. Исемең ничек дисең? Исмәгыйль? Яхшы. Ә хәзергә документларыңны торгның кадрлар бүлегенә илтеп тапшырырсың...

Ул энжедәй тигез, ап-ак тешләрен күрсәтеп, көлемсерәп куйды. Шулчак аның ияге астында кечкенә генә нинди дер матур чокыр барлыкка килеп, аның алсу бите тагын да нурланып киткәндәй булды. Кара карандаш белән ак кәгазьгә сызган сызыктай нечкә кашлары бер югары күтәрелеп, бер түбән төшеп, биешеп алды. Кибет директоры, чыннан да, хәтсез чибәр иде. Көлгәндә нинди дер бер яктылык белән кабынып-ялтырап китә торган коңгырт күзләре генә дә ни тора! Буяткан зәңгәрсу чәчләрен әйт тагын. Димәк, үз-үзен карап йөри торган зат.

—Калганы эш дәверендә... Бездә сиңа ошар дип уйлыйм,—дип тәмамлады директор сүзен.

Ләкин бер атна үтте, ике, өч атна эшләде Исмәгыйль, тик Чибәр хатын (аны беренче күрүдә үк ул аңа шундый кушамат таккан иде) ник бер мәртәбә сүз кушсын! Очрашканда да сүзләре "Исәнмесез!—Исәнмесез"дән ары узмады.

Алай да бер көнне, җомга көн иде бугай, ул берүзе генә директор кабинетыннан ерак түгел бер складта яңа гына бушатылган төрле кап-тартмаларны урнаштырып ятканда, кинәт кенә Чибәр хатын килеп керде.

—Буламы, Исмәгыйль? Йә, ничек соң бездә? Бик арытмыймы?—диде ул, ишек бусагасына баскан килеш бераз аның эшләвен карап торгач.—Кайчак авырга да киләдер, әйеме?—Директор, аның тирдән ялтырап торган ялангач тәненә ишарә ясап, коңгырт күзләрен очкынландырып, елмаеп куйды.—Тирләгәнсең, әнә...

—Зарар юк, Елизавета Сергеевна, ияләшеп җиттем инде,—диде Исмәгыйль, битен сөртеп.—Эштән курыкмыйм мин. Кечкенәдән эшләп үстем...

—Ярый, алайса, ярый...—дип Чибәр хатын тагын да елмая төште.—Күнекмәгән килеш авырдыр әле. Дөресен генә әйткәндә, эшеңнән канәгатьмен. Сатучылар да мактый үзеңне: товарны вакытында китерә, бушаган кап-әрҗәләрне дә вакытында алып китә, диләр. Молодец!

—Эшем шул бит минем, Елизавета Сергеевна,—диде моңа каршы Исмәгыйль, шулай кинәт кенә килеп чыккан директорның күзенә бәреп мактавыннан уңайсызланып.—Минем вазыйфама керә ич алар...

—Бурычыңны дөрес аңлыйсың,—дип Чибәр хатын ишектән чыгу ягына атлады. Тик бер-ике адым атламагандыр, кинәт янәдән килеп, куллары белән ишек яңагына таянды.—Эшеңне бетергәч, миңа кереп чыгарсың әле...

Бу сүзләрдән соң Исмәгыйль аптырап калды: нигә чакыра икән аны директор? Һәрхәлдә, хәзер генә әйтүе дөрес булса, ачуланыр өчен түгел бугай. Ул әясе-куясы әйберләрен урнаштырып алганнан соң кулларын юып, үзенә бертөрле эчке кызыксыну белән директор кабинетына таба атлады. Чибәр хатын ялгызы гына иде. Исмәгыйль кыяр-кыймас кына ишекне ачкач, ул шундук:

—Кер, әйдә, кер, Исмәгыйль!—дип аңа бик үз итеп дәште.

—Урнаштырып бетердем мин анда. Керергә кушкан идегез...—дип төртелеп калды егет.

—Булдыргансың. Молодец!—дип утырган урыныннан күтәрелә төште директор.—Тиз тотасың син эшне, күңел биреп эшлисең. Хәзер бит күбесе алай-болай гына китерергә ярата. Син андыйлардан түгел икән. Мин бит ялкау белән тырышны гына аера беләм!—Ул кинәт көлемсерәп куйды.—Йә, нишләп басып торасың? Утыр диванга! Аякларың кәҗүнний түгелдер бит?

—Мин нәрсә... Мин басып та торам, борчылмагыз юкка, Елизавета Сергеевна,—диде Исмәгыйль.—Тыңлыйм мин сезне...

—Ярар, алайса,—дип янәдән елмайды директор.—Күрәм, үзсүзле кеше син, үзеңнекен итә торган кеше... Алайса, менә нәрсә, Исмәгыйль... Сиңа бер сүзем бар...—Ул көндезге ут яктылыгында дистәләгән нурлар белән ялтыраган зур алтын йөзекле нәфис бармагы белән аңа таба ишарә ясады.—Әгәр дә мәгәр шуны тыңласаң, кеше булырсың... Әгәр дә мәгәр сүземне аяк астында калдырсаң, мин сиңа бик каты үпкәләячәкмен. Ишеттеңме? Тик моны ялгыш аңлый күрмә! Үтенечем бу минем...

Чибәр хатынның бу сүзләре егеткә ошамады. "Нигә шулай читтән урап йөрергә?—дип куйды ул үзалдына.—Йомышың бар икән, әйт тә сал ярып!"

Шуны сизгәндәй, кинәт Чибәр хатын сүзен йомгакларга ашыкты:

—Кыскача гына әйткәндә, мин сине берсекөнгә туган көнемә чакырам, Исмәгыйль. Курыкма, курыкма, зурдан кубып ясалган мәҗлес түгел. Анда берничә генә кеше булачак...

Кинәт кенә гомерендә дә көтмәгән бу сүзләрне ишеткән Исмәгыйль моңа ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Шулай булмыйча, әле монда эшли башлавына да өч атна чамасы гына бит! Җитмәсә, кем чакыра диген! Шундый чибәр, сөйкемле хатын үзе! Их, биргән дә соң моңа Ходай чибәрлекне! Багалмасыдай алсуланып, түгәрәкләнеп торган йөзенә карарга кыймассың, валлаһи!

—Рәхмәт, Елизавета Сергеевна...—дип тотлыкты Исмәгыйль, аның күзенә карарга кыймыйча.—Мин мондый чакыруга... гафу итәсез, бара алмыйм. Андый җирләрдә булганым да юк... Рәхмәт чакыруыгызга...

—Кара аны, Исмәгыйль, егет кешегә артык тыйнаклык та килешеп бетми,—дип көлде директор.—Ничек диләр әле: "Егет булса, шундый булсын, ике күзе ут булсын",—диләрме? Дөресен генә әйткәндә, мин сине хуҗам белән таныштырырмын, дип уйлаган идем. Ничектер бер сөйләшеп утырганда, аңа, шулай, шулай, бездә солдаттан яңа гына кайткан бик тыйнак кына егет эшли, дигән идем. Ә ул шуннан соң: "Күрсәт тә, күрсәт аны миңа! Шуны чакырмасаң, туган көнеңә дә килмим",—диде. Йә, әйт яшермичә генә, син бит үзем чакыра дип белдең. Дөресме? Янәсе, менә нинди хатын безнең директор!.. Дөрес әйтәмме?

Бу сораулардан соң Исмәгыйль тагын да уңайсызланып калды.

—Ни сөйлисез, Елизавета Сергеевна? Сезнең турыда алай уйларга ни хакым бар?..—диде ул, үзенең аяк очына карап. Һәм сүзне тизрәк икенчегә борырга тырышты.—Ә нигә кирәк мин ул ир-атка?! Мин зоопарктагы җанвар түгел бит... миңа карарга...

—Безнең торг директоры—хатын-кыз, Исмәгыйль. Ишеттеңме? Хатын-кыз!—дип юка иреннәре белән серле елмаеп куйды Чибәр хатын.—Курыкма, ашамас ул сине. Мин белмим, бәлки, ул сиңа башка берәр эш тәкъдим итмәкчедер?..

—Мин эшемнән канәгать,—диде моңа каршы Исмәгыйль.—Хәзергә миңа башка бернинди эш тә кирәкми.

Әйе, эшкә килгәндә, ул хәзерге эшеннән риза иде. Төп азык-төлек продуктларының барысына да талон системасы кертелгән, ә башка төрләренең кибет киштәләреннән югалган шушы авыр заманда бу мәсьәлә буенча бернинди кытлык та сизми иде монда эшләүчеләр. Теләгән вакытында теләгән кадәр ит-маен да, шикәрен дә юнәтәләр. Сирәк-мирәк кенә булса да, башкаларның төшенә генә керә торганнары да эләгә иде әле үзләренә! Тормышның катлаулы нәрсә икәнлеген менә шушында атлаган беренче адымнарыннан ук сизә башлады Исмәгыйль. Чыннан да, катлаулы дими ни дисең инде аны? Кайсы гына кибеткә кермә, берни дә юк диярлек—киштәләр буш, буш һәм буш. Шул ук вакытта кибет складларынданиләр генә юк икән ләбаса! Әгәр гап-гади сатып алучыны алып кереп: "Кирәк нәрсәңне сайлап ал!"—дип шундагы ашамлыкларны күрсәтсәң, ул, мөгаен, һушыннан язар иде. Чөнки хәтта күпләр үз

гомере буена исен дә исни алмаган нәрсәләр дә бар икән анда! Ничәмә-ничә төрле балык консервалары, кара, кызыл уылдыклар, кофе, куертылган сөт, һинд чәйләре дисеңме, егермегә якын төрдәге ысланган казылыкларны, кыскасы, ни генә юк ул гади генә почмакларда! Хәтта Исмәгыйльгә яңа гына тотылган мәрсин, чөгә балыкларына тикле бушатырга туры килгәне бар. Дөрес, бик күп булмый алар һәм шул ук көнне "йөзеп" тә китәләр. Тора-бара гына аңлады: андый нәрсәләрнең кемгә икәнлеген директор гына белә икән.

Әйе, тормыш катлаулылыгын ул шушы кибеттә эшләгәндә аңлый башлады. Чыннан да, бик катлаулы икән бит безнең тормыш. Юк, авырлыгы мәсьәләсендә түгел, ә катлам-катлам булган кишттәләре белән катлаулы икән ул. Анда төрле дәрәҗәдәге кешеләр өчен үз кишттә-катламы икән. Иң аскысында, әлбәттә, минтай балыгы белән килосы илле тиенлек килька булыр. Аларның кемгә икәнлеген барыбыз да беләː кер дә ал, халык массасы! Складлар эчендәге башка, югарырак кишттә-катламнарың—үз клиентлары. Алар артык күп түгел: директорның, аның хуҗаларының танышбелешләре, туган-тумачалары һәм дә җирле власть әһелләре. Тәртип саклаучылары да шушында, закон сагында торучылары да...

Исмәгыйль тормышны аңлый барган саен гаҗәпләнде: үзенә кирәкне теләгәнчә алган ОБХСС хезмәткәре бу кибеттәге товар яшерү, халыкны алдау кебек тискәре яклар белән ничек көрәшә алсын, Ходаем?! Ә бит "көрәшәләр". Йөзләре җитди, кыяфәтләре эшлекле. Гаҗәпләнмәслек тә түгел—кибетләрнең эчке ягында бөтенләй башка тормыш кайный икән ләбаса! Ул бу тормышка охшамаган гына түгел, аңа якын да килми. Шушы нәрсәләр белән чагыштырганда, күз алдындагысы чынына пародия генә икән бит: сөйләвебез—бер, эшебез бөтенләй икенче төрле...

—Мин кистереп кенә әйтә алмыйм,—дип куйды Чибәр хатын.—Начальствоның уй-фикерен белергә язмаган безгә. Бәлки, аның менә шушындый, бөтен җирле килгән, әле яңа гына солдаттан кайткан егетне болай гына күрәсе киләдер? Андый теләге булса да нишлисең?.. Начальство есть начальство. Начальству надо подчиняться!—дип көлде директор.—Боларын шаярып кына әйтәм, әлбәттә. Тик котәм мин сине, Исмәгыйль. Ярыймы? Менә адресым...—Ул аңа сумкасыннан визит карточкасын алып бирде.—Әллә... Юк, юк... Мин болай гына... Бәлки, сине кием мәсьәләсе борчыйдыр? Әйт, син армиядән генә кайткан кеше. Әйтсәң, берәр нәрсә уйлашырбыз...

Исмәгыйльнең йөзенә кызыллык йөгерде. "Нишләп җанымны ашый соң бу Чибәр хатын?—дип уйлап алды ул.—Нишләп авырткан җирне каезлый? Бәлки, тотарга да, минем кияр киемем юк шул, диярга? Шуннан соң кыстап та тормас, башыма төшкән бәладән котылырмын!"

—Дөресен генә әйткәндә, эш шулайрак тора, Елизавета Сергеевна,—дип ярып салды Исмәгыйль, беткән баш беткән, дигән сыман.—Тиздән алачакмын, әлбәттә...

—Күптән шулай диләр аны, җүләр!—дип ачылып китте директор. Хәтта Исмәгыйль: "Нигә шатлана бу?!"—дип уйлап алды.—Башта ук шулай дисәң! Табабыз сиңа костюм-чалбар. Әлбәттә, табабыз!

Һәм ул шундук телефон трубкасына үрелде. Тиз-тиз генә кирәкле номерын җыеп, сөйләшергә дә тотынды:

—Әминә Кәримулловна! Хәерле көн! Әйе, мин әле бу—Лиза. Бүген кызыл балык алдык. Тукта, мин әйтәм, Әминә Кәримулловнага да кирәктер. Биш кило? Пожалуста, хет унны, Әминә Кәримулловна! Бер кечкенә генә йомышым бар иде сиңа, Әминә Кәримулловна... Сездә яхшырак ир-ат костюмнары бармы? Импортный, әлбәттә! Финскийлар? Ничәнче размер?—Елизавета Сергеевна трубкасын кулы белән каплады да тиз генә Исмәгыйльдән: "Ничәнче размер киясең?"—дип сорап алды. Бу сөйләшүне зур кызыксыну белән тыңлап торган егет аңа размерын әйтте. Директор трубканы куйды да бик зур канәгатьлек белән үзалдына елмаеп алды.

—Ишеттеңме?—диде ул Исмәгыйльгә һәм сумкасына үрелде.—Менә сиңа әҗәткә бераз акча, барып ал костюмыңны! Ашыкма, киеп-карап ал! Кыскасы, яңа костюмың белән котлыйм сине! С тебя причитается!

Исмәгыйль исә катты да калды, ни әйтергә дә белми. Өнемме бу, төнемме, ди бугай. Ниһаять, телгә килде:

—Сез нәрсә, Елизавета Сергеевна?! Мин бит үзем... Үзем мин!..—дип мыгырданды ул.—Кирәкми миңа болай... Үзем алам мин аннары...

—Әлбәттә, үзең,—дип көлде Чибәр хатын, ашыкмыйча гына.—Синең костюмың

артыннан мин бармам бит инде! Әйдә, берочтан Әминә Кәримулловнаның балыгын да алып барырсың. Калганын үзе белә ул…

—Әллә ничек була бит әле бу, Елизавета Сергеевна,—диде Исмәгыйль, инде кибеттән чыгарга җыенганда.—Сезне дә борчыйм… Минем гомердә дә кешедән әҗәткә акча алганым юк…

—Ярар, ярар, күп сөйләшмә! Димәк, тормышны белмисең әле син,—диде директор бу юлы нindидер кырысрак сыман тоелган тавыш белән.—Бигрәк беркатлы шул әле син... Бала-чага шикелле. Зарар юк, шәһәр авылга караганда тизрәк өйрәтә ул. Бар, әйдә, бар!

Китте Исмәгыйль. Барып керде, әйтелгән катка менде, директор урынбасары кабинетын сорады. Аны ишек төбенә хәтле үк озаттылар.

"Әһә, монда бу хатын-кызны яхшы беләләр икән,—дип нәтиҗә ясады ул.—Беләләр һәм хөрмәт итәләр. Бәлки, хөрмәт итмиләр, ә куркалардыр! Алар икенче законнар буенча яшиләр бугай. Гаҗәп, бер тиен дә түләмичә биш килограмм нинди балык җибәрделәр бит шуңа! Димәк, кирәкле кеше. Әнә бит, костюм турында да телефон аша сөйләшү белән үк килештеләр. Финский, диме? Бар, табып кара син аны кибетләрдән! Әле өченче көн генә Хәдичә апасы кибеттән сөмсере коелып, буш кул белән кайтып керде ич. Кредитка пальто алырга йөргәндә, белешмәң дөрес түгел, дип борганнар. Биш-алты ай туры китерә алмыйча йөгереп йөргән иде бит кибетләр буенча! Инде эләктердем дигәндә генә... Мине дә бормасыннар тагын..."

Әминә Кәримулловна үзе генә иде. Исмәгыйль, Елизавета Сергеевнадан икәнлеген әйтеп, аңа кулындагы төргәген сузды. Ләкин, гаҗәпләнүенә каршы, ул төргәкне кулына да алып карамады, бары тик:

—Хәзер,—диде һәм уң ягындагы селектор төймәсенә басты.—Кер әле монда, Мәдинә!

Шул ук мизгелдә олырак яшьтәге эре генә гәүдәле бер хатын килеп керде.

—Алып куй әле шуны, Мәдинә!—диде дә аңа урынбасар, Исмәгыйль кулындагы төргәккә күрсәтте.—Менә тагын нәрсә: Наиләгә төшеп әйт, шушы егеткә финский костюм сайлап бирсен, аннары шуны кредитка оформить итегез! Белүемчә, аның эш урыныннан белешмәсе юк. Алай да эшләп бирегез!—һәм Исмәгыйльгә карап:—Барыгыз, кирәгенчә эшләрләр,—диде.

Ул, аның белән хушлашып, Мәдинә артыннан иярде. Киемнәр эленеп торган бүлекләр буенча үттеләр, нindидер коридорга килеп чыктылар. Шул коридор буенча бара торгач, бер ачык ишек янына килеп эчкә керделәр. Андагы кечкенә генә бүлмәдә бер яшь хатын-кыз нәрсәдер язып утыра иде.

—Наилә, Әминә Кәримулловна бу егеткә финский костюм сайлап бирергә кушты. Аннары шуны кредитка рәтләп бирәбез,—диде аңа Мәдинә.

Наилә исә, ток суккандай, шундук сикереп торды да, кызыксынучан кара күзләре белән Исмәгыйльгә карап алды.

—Аңладым, Мәдинә Ибраһимовна, хәзер үк эшлибез аны,—диде ул инде чыгарга җыенган хатынга.

Наилә, өстәле тартмасыннан ачкычлар алып, уң яктагы пәрдәне ачып җибәрде. Аның артында ишек икән, эчкә керделәр. Наилә бер сүз дә әйтмичә, аны түргә таба алып китте.

—Сезгә нинди төс кирәк?—диде Наилә.—Карамы, зәңгәрсумы, әллә көрәнме?

—Зәңгәрсу төслесе,—диде Исмәгыйль, кыяр-кыймас кына.

Наилә шундук элгечтән бер костюм-чалбар алып аңа сузды һәм көзгегә таба ишарә ясады.—Киеп карагыз! Монысы ярамаса, башкасын карарбыз...

Яңа костюм-чалбар киеп көзге алдына баскан Исмәгыйль башта үз-үзен танымады диярлек. Килешсә дә килешер икән! Үзенә үлчәп теккәннәр диярсең—сыланып тора!

—Бик тә килешә бу сезгә. Бик таман да,—диде Наилә, аны як-якка боргалап.

Исмәгыйль кибеттән, бала-чага шикелле, очынып килеп чыкты. Авызы колагына җиткән! Ниһаять, шәһәр кешесе булырга омтылу юлында беренче адымын атлады түгелме?! Хәзер аңа кем: "Авыл малае",—дияр?

Аның мондый зур нәрсә сатып алуына Хәдичә апасы да сөенде. Һәм гаҗәпләнде дә. Хәзер моның ише затлы нәрсәләрне көндез ут яндырып эзләсәң дә табып булмый ич! Бәясе дә бик юнь.

"Барыргамы, бармаскамы?—дип тинтерәде Исмәгыйль, директорының чакыруы

турында уйлап.—Бер караганда, инде хәзер бармасаң да яхшы түгел—мине шундый костюм-чалбарлы итте. Ә бармасам ни булыр? Хәер, бу кадәресен күз алдына китерүе авыр түгел. Икенче көнне үк, кая, егет, әҗәтеңне кайтарып бир әле, дип әйтүе бик мөмкин. Ул бит туган апаң түгел. Димәк, бармыйча ярамый. Дөресен генә әйткәндә, үзенең дә барасы килә анысы. Чакырып торганда нигә бармаска ди? Кызык та бит: нигә чакыралар?.."

Исмәгыйль бер мәл икеләнеп йөрде-йөрде дә, бармыйча яхшы түгел дигән уйга килде. Һәм күрсәтелгән көндә Чибәр хатынның ишеге төбенә килеп басты. Аны Елизавета Сергеевна үзе ачып, бик җылы каршылады.

—Менә Исмәгыйль дә килде!—диде ул бик гади-гадәти генә һәм елмая төште.—Әйдә, уз! Бик көттереп кенә йөрисең...

Зур гына бер бүлмәгә килеп керделәр. Анда бик мул итеп әзерләнгән өстәл тирәли унга якын кунак утыра иде инде. Хуҗабикә аларны үзара таныштырып тормады, бары тик:

—Исмәгыйль дигән егетебез була бу, иптәшләр. Бездә эшли,—диде.

"Ярый әле, кем булып эшләвемне әйтмәде. Кунаклар алдында уңайсыз булыр иде,—дип уйлап алды Исмәгыйль, аларны күздән кичереп.—Күркәләр кебек күперенеп утыруларына караганда, монда минем шикелле грузчиклар булырга охшамаган. Боларның кайсысы торг директоры икән?"

Ул мондагы кунакларны танымый да, белми дә иде. Тик менә монысы Әминә Кәримулловна түгелме соң?! Юк, ул түгел икән. Ул кара чәчле иде, ә бу—алтын сыман сары чәчле. Алай дисәң, сөйләшүе аныкына охшаган. Шул ич, шул! Башына парик кигән! Шуны раслагандай, иңбашына тиеп торырлык зур алкалар таккан Әминә Кәримулловна:

—Таныш безгә бу егет, таныш!—дип елмайды.

Исмәгыйль дә утырды. Мәҗлес дәвам итте. Хуҗабикә хөрмәтенә берсеннән-берсе купшы сүзләр әйтелде, алар рюмка-бокал чыңнары белән хупланылды, күп кенә мәзәкләр сөйләнелде, уен-көлке янгырады.

Өстәл бик мулдан әзерләнгән, нәрсәләр генә юк! Телисең икән, балык уылдыгын кашыклап аша! Карасын да, кызылын да. Мандарины да табын тулы, әфлисуны да. Хет бәрәңге урынына аша! Казылыкларның да ниндиләре генә юк! Эчемлекләрен күр тагын: безнең ил аракылары гына да биш-алты төрле! Ә күпме чит илнекеләре елмаештып утыра! Кыскасы, табынга күз төшерү белән: "Кемнең кулында, шуның авызында", дигән әйтем искә төшә.

"Менә яши болар!—дип гаҗәпләнде Исмәгыйль эченнән генә.—Коммунизм икән монда! Менә бу тормыш, ичмаса!"

Исмәгыйльнең моңа кадәр мондый фатирга кергәне дә, шушындый байлыкны күргәне дә юк иде. Кайда күрсен ул аларны? Хәдичә апасының ике кеше дә иркенләп йөри алмаслык кечкенә, фәкыйрь бүлмәсеннән башка тагын кемнәргә кергәне бар соң? Бәлки, моның ише бай фатир бер Чибәр хатында гына түгелдер? Шушындый мул тормыш күпләрдәдер? Юкка гына: "Шәһәр тормышы!"—димиләр аны!

Аның кыюсыз гына утыруын күреп, Чибәр хатын рюмкасын тотып янына килде дә:

—Нишләп болай кара көеп утырасың син, Исмәгыйль?!—дип чиста, матур тавышы белән гаҗәпләнүдән кашларын сикертеп, үпкә белдерде.—Әйдә, күтәр әле берне туган көнем хөрмәтенә!

Бу сүзләр уен-көлке белән тәрелеп, ләкин шул вакытта каршы килү мөмкин булмаган ниндидер катгыйлык белән әйтелде ки, Исмәгыйль кулына рюмкасын алырга мәҗбүр булды.

—Бетереп куй!—диде Чибәр хатын, аның белән чәкештереп алгач.—Күрсәт егетлегеңне!

Нишлисең, янында шундый гүзәл хуҗабикә үзе басып торганда эчмичә дә булмый. Җитмәсә, аны хуплап, кунаклар да: "Сорыйбыз! Елизавета Сергеевна хөрмәтенә!"—дип шаулашып алдылар. Эчеп җибәрергә туры килде. Башта аракы авызын, аннары тамагын, соңыннан ашказанын, юк, бөтен эчен өтеп алгандай булды. Күздән яшь атылып чыкты. Әмма ул сер бирмәскә тырышты.

—Молодец! Күптән шулай кирәк иде!—диештеләр.

Бераздан тәненә ниндидер җылылык йөгерде, оялу, кыенсыну юкка чыкты, ара-

тирә җырларга да, сүзгә дә кушылгалый башлады. Хәтта солдатлар тормышыннан берничә мәзәк сөйләп, кунакларны көлдереп тә алды. Моңарчы оялып, уңайсызланып кына утырган Исмәгыйль күз алдында ачылып китте.

Бик кыстагач, сакланып кына булса да, тагын бер-ике рюмка күтәрергә туры килде. Ә иртә белән... иртә белән кемнеңдер аны кысып-кысып кочаклавына, чәчләреннән сыйпавына, бертуктаусыз үбүенә уянып китте ул. Уянып китте дә, төшемме соң бу, өнемме, дип гаҗәпләнде. Иртәнге эңгер-меңгер. Башы—ялангач хатын-кыз күкрәгендә. Тукта, үзе дә анадан тума түгелме соң?! Йа Хода, кайда ул? Бертуктаусыз үзен кочаклаучы, бер кулы белән аның әллә кайсы җирләрендә капшанучы бу хатын-кыз кем? Әллә Чибәр хатын үземе?! Алай булса, мондый бәхеткә ничек шулай ансат кына тарган соң әле ул?! Димәк, кунаклар таралышып беткәннәр дә алар Елизавета Сергеевна белән икесе генә калганнар?! Менә шулай көтмәгәндә генә килер икән бәхет дигәнең!.. Дөрес, яше буенча олырак—кичә егерме сигез тулды. Хәер, моның ни әһәмияте бар? Ике ел хатын-кыз заты күрмәгән егет өчен барыбер түгелмени? Өйләнәсе хатын түгел лә! Карале, үзе дә ничек угалана! Менә сиңа тыйнак Чибәр хатын, менә сиңа бөтен сатучылар каршы сүз әйтергә курыккан директор! Тымызык күлгә шайтан ияләшә, дип юкка гына әйтмиләр, ахрысы. Их, булмаса булган икән... Исмәгыйль дә хатынны кочып назларга кереште...

—Үтерәсең бит, Исмәгыйль! Төн буе туйдырмадымы?—диде янындагы кайнар сулыш, аны үзенә сеңдереп.

—Юк, туйдырмады,—дип җавап кайтарды ул, кызып.—Сездән һич туярга мөмкин түгел! Сез—фәрештә, сез—гүзәлләрнең гүзәле!

—Хатын-кызга бик сусаган син, Исмәгыйль...

Туктале, бу Чибәр хатын тавышы түгелме әллә соң?! Хәер, нинди тавыш ди, кайнар пышылдау гына ич бу...

Ул бераздан тагын изрәп йокыга талды. Ачкыч белән ишекне ачкан тавышка дерт итеп уянып китте. Кемдер керде, аякларыннан салды, аннары әкрен генә алар яткан бүлмәдә ут яндырды. Исмәгыйль башын юрган астына яшерде.

—Сез торырга уйлыйсызмы бүген, юкмы?—дигән тавыш ишетелде.

Чү, бу Елизавета Сергеевна тавышы бит! Ә монда, аның янында, кем мышнап йоклап ята, алайса?! Ток суккандай, аның бөтен тәне, бөтен буыннары калтыранып куйды. Йа Хода! Ул бу төнне кем белән үткәргән? Ничек болай килеп чыккан? Туктале, Исмәгыйль бу караватта үзе генә ята иде түгелме? "Менә шушында ятып йокла рәхәтләнеп"—дип аны монда Чибәр хатын үзе җитәкләп чыгарды ич! Димәк, аннары аның янына кемдер килеп яткан?! Ә кем икән соң ул?

—Торырга вакыт, чәй әзерлим,—диде Елизавета Сергеевна. Бу юлы тавышның аныкы икәнлегенә бернинди шиге дә калмады.

Исмәгыйль әкрен генә башын юрган астыннан чыгарды. Тавыш иясе бүлмәдән чыгып бара иде. Әйе, Чибәр хатын иде ул. Шунда аның янында яткан хатын—ул Елизавета Сергеевнаның ут яндырганын да тойган, сүзләрен дә ишетеп торган бугай—юрганын ача төшеп:

—Хәерле иртә, Исмәгыйль! Уяндыңмы?—дип куйды һәм ап-ак куллары белән муеныннан кочып, аны үзенә таба тартты.—Йә, канәгатьме син?

Исмәгыйль, корт чаккандай, сискәнеп китте һәм ирексездән янындагы хатын кочагыннан ычкынырга маташты. Кем бу? Торг директоры?! Аны күрергә теләгән хатын-кыз?! Менә хәллә-ә-әр... Ул кичәге кунакларның һәркайсы: "Эльза Константиновна! Эльза Константиновна!" дип бер алдына, бер артына төшкән торг директоры белән төн чыккан лабаса! Район тикле район сәүдә дилбегәсен кулында тоткан хатын белән! Кеше ышанмаслык хәл бит бу! Ә бит әле кичә генә шушы хатынның янына да килергә мөмкин түгелдер кебек тоелган иде!.. Беренче карашка әлләни тәкәббер, үзен зурга куючан кешегә охшамаса да, аның белән башка кунаклар арасында шактый гына аерма, ниндидер өстенлек барлыгы сизелеп тора иде. Монысы аңлашыла да, әлбәттә. Чөнки, ни әйтсәң дә, кунакларның күбесе шушы мөлаем хатын кул астында эшләүче, аңа буйсынучы кешеләр бит.

—Нигә уйга калдың, Исмәгыйль? Ник дәшмисең?—дип сорады Эльза Константиновна, аны кочагыннан җибәреп.—Төн буе теләгәнен алды-алды да, хәзер сөйләшәсе дә килмиме, ә?

Ул шулай ярым шаяру белән сөйләнә-сөйләнә юрганын каерып ачты да, анадан

тума булуына чак кына да оялмыйча, идәнгә төшеп басты һәм ашыкмыйча гына караватӨ янындагы урындыкта яткан киемнәрен кия башлады. "Карале, моның бер дә килмәгән жире юк икән бит, шайтан алгыры! Чибәрлеге дә бар, буй-сыны да килешле, кем әйтмешли, бөтен жире үз урынында". Аңа карап торган Исмәгыйль ирексездән шундый нәтиҗә ясады.

Аннан соң үз тормышында шактый зур роль уйнаган Эльза Константиновна белән танышлыгы менә шулай көтмәгәндә-уйламаганда башланып киткән иде. Нәкъ әкияттәгечә килеп чыкты. Юк, танышлыклары шуның белән генә бетмәде. Исмәгыйль аңлавынча, утыз биш яшьләр чамасындагы бу хатын яшь ир-атларга карата битараф кала алмый торганнар затыннан иде бугай. Әйтүе дә кыен, үзенә күрә бер авырумы бу, әллә табигатеннән, тумышыннан килгән йомшаклыгымы, әллә тормыштан мөмкин булганның барысын да алырга тырышуымы? Инде шушы беренче төннән соң ничәмә-ничә дистә тапкырлар очрашып-күрешеп йөрделәр, шулай да Исмәгыйль шуны ачыклый алмады. Бары шунысын гына әйтә ала: ул Эльза Константиновнаның күңеленә хуш килде. Шулай булмаса, бу кадәр үз итмәс иде. Ике елга якын очрашып тордылар бит! Бергә үткәргән беренче төннән соң ун-унбиш көн дә үтмәде, гап-гади кибетнең гап-гади йөкчесе булган Исмәгыйль сәүдә базасының яшелчә складыӨ мөдире итеп билгеләнде! Бу эшнең ни-нәрсә икәнен дә белмәгән килеш! Бу турыда Елизавета Сергеевнадан ишеткәч, моңа ышанырга да, ышанмаска да белмәде.

—Кайгырма, Хуҗа үзе билгеләгәч, өйрәтүчеләре дә, булышучылары да табылыр,—диде аңа Чибәр хатын.—Мондый бәхет безнең системада уннарча ел эшләгәннәргә дә тәтеми. Эльза Константиновна белән дуслыгыңны дәвам итсәң, киләчәктә бал белән майда гына йөзәрсең. Сер итеп кенә әйтәм, бик ошаткан ул сине...—Ул җиңелчә генә елмаеп куйды.—Бик тырышасың бугай... Тырыш ирләрне бик ярата шул...

Аңламассың бу хатын-кызны. Исмәгыйль тора-бара гына төшенде: аның Эльза Константиновна белән танышлыгының башы иң элек Елизавета Сергеевнаның үзенә барып тоташа. Соң, бер мәртәбә дә күрмәгән Эльза (утыз алтынчы яше белән барган хатын икесе генә калган чакларда үзенә шулай дип дәшәргә куша иде) аның турында кайдан, ничек белсен?! Димәк, миндә армиядән генә кайткан бик чибәр, бөтен жире килгән, көче-куәте ташып торган егет эшли, дип аңа Чибәр хатын әйткән булып чыга! Кем белә, бәлки Исмәгыйль Чибәр хатынның үз башлыгына бер бүләге шикеллерәк нәрсә булгандыр?..

Эльза Константиновна белән бәйләнеп-аралашып киткәч, Исмәгыйль әле үзенә яше һәм җәмгыяви дәрәҗәсе буенча да тиешле булмаган өске божрада әйләнә башлады. Аның, кечкенә авыл малаеның, кечкенә солдатның үзенә югары дәрәҗәле кунаклар белән бергә рестораннарда, йөзү бассейннарында, сауналарда, дачаларда йөрергә туры килер дип уйлаганы булдымыни?! Һич юк! Бу турыда уйлау түгел, хыяллана да алмады. Дөрес, ресторанга да, бассейн-сауналарга да, шуның ише бүтән җирләргә башкалар да керә ала. Тик ул бит боларның бик дәрәҗәле кешеләр өчен генә каралган эчке як ишекләрен дә ачып керде. Ресторан дигәч тә, анда теләгән һәр кеше керә ала торган гомуми заллардан тыш, катлы-катлы ишекләр артында нинди затлы бүлмәләр булуын күз алдына да китергәне юк иде. Баксаң, бар икән андый оҗмах почмаклары, бар! Телисең икән, көн буе утыр—беркем күрми дә, белми дә. Анда официант та чакыру буенча гына керә. Ул сукыр да, чукрак та—берни күрми, берни ишетми: курыкмыйча утыр, ләззәтләнеп кенә аша-эч, ял ит, мәхәббәт белән шөгыльлән! Барысы да лаеклылар өчен монда!

Шундый ук затлы бүлмәләр йөзү бассейннарында, мунча-сауналарда да бар икән ләбаса! Чит-ят күзләрдән саклар өчен ишекләре дә аерым. Тик бу кадәресен шул ишекләрне ачып керү хокукы бирә торган дәрәҗәле баскычка менгән затлар гына белә...

Әлбәттә, ул бу югары баскыч идәннәренә Эльза Константиновна аркасында гына аяк басты. Ә ул хатын үзе, мөгаен, вакытында башка берәүнең, халык әйтмешли, кемнеңдер йонлач кулы ярдәмендә күтәрелгәндер. Әйткәч тә, башта аның да район күләмендәге сәүдә эшен тартырлык көче дә, тәҗрибәсе дә булмаган бит. Унны тәмамлагач, төзелеш оешмасында секретарь-машинистка булып эшләгән, аннары, үзе әйтүенчә, көтмәгәндә генә "үсеп" киткән. Партия җыелышы үткәрергә килгән райком вәкиле аны ("бик ошадым бугай мин аңа",—дип сөйләде Эльза Константиновна) икенче көнне үк райкомга эшкә алган. Башта анда секретарь-

машинистка булып эшләгән, аннары, тиз генә партиягә кергәч, инструктор булып киткән. Ә партия җимерелеп, райкомнар бетерелгәч, инде бу вакытка "номенклатурный работник" булып саналган кызны кибет директоры итеп куйганнар. Аннары читтән торып Сәүдә институтын "ерып" чыга. Шул ук райком бинасындагы элеккеге "райком" дигән язуны "район хакимияте" дигәненә алыштырган кечкенә коммунистлар—бүгенге демократлар аны гел күз уңында тота, һәм күп тә үтми, ул кибет директоры кәнәфиеннән район сәүдә идарәсенекенә сикерә.

Исмәгыйль бүгенгедәй бу тормышта белем дигән нәрсәнең әллә ни зур роль уйнамавын тора-бара үзе дә яхшы аңлады. Кемгәдер ошадыңмы, яклаучы кешең бармы, син әллә ниткән дәрәҗәле урыннарга да үрмәлисең. Хәтта өч тиенлек белемең булмаса да! Ә инде кемгәдер ошамадың яисә кемнеңдер юлын аркылы чыктың икән, ике институт, өч университет тәмамласаң да урам себерүче булып йөрүең ихтимал. Без яшәгән илнең язылмаган, ләкин шулай да Президент Указлары, Хөкүмәт карарларыннан да төгәлрәк үтәлә торган законы шулай. Эшне белү-белмәвең, аны тарта алу-алмавың беркемне дә кызыксындырмый—кирәк кеше югарыдагы урынга куела. Бу эшне тәмам таркатканчы шунда "эшли" бирә. Шуңа күрә бездә кечкенә агроном зур төзелеш оешмасын җитәкләргә, кечкенә ветеринар финанс министры, ә кечкенә көнкүреш хезмәткәре исә бүген мәдәният министры булырга мөмкин...

Исмәгыйльнең гомердә дә башына китермәгән яңа эше өчен куркуы юкка гына булып чыкты: булышчылары да, өйрәтүчеләре дә табылды. Иң башта шушы яшелчә складының элеккеге хуҗасы, "завсклад" булып эшләгән Әнвәр Бариевич Шәмсетдинов (нишләптер аны барысы да Александр Борисович дип йөриләр иде) бер айга аның урынбасары итеп калдырылды. Аңлавынча, бу Эльза Константиновна теләге белән шулай эшләнде. Аңа яңа эшенең серләрен шушы кеше төшендерде, бөтен нечкәлегенә хәтле ачып бирергә тырышты. Ә ул нечкәлекләр шактый икән. Яшелчә складлары дигәч тә, монда кәбестә, кишер, чөгендер, помидор, кыяр ише нәрсәләр генә сакланмый, ул алма, йөзем, әфлисун, мандарин, хөрмә, банан һәм башка бик күп төрле җылы як җиләк-җимешләре белән дә шыплап тулган бит әле.

Йөзем дигәннән, яңа гына эшли башлаган көннәрендә бу җимеш салынган әрҗәләрнең еш ачылып-ябылып торган капка янына куелганнарын күргәч—инде салкыннар башланган чак!—Исмәгыйль хәтта кабынып китте. Күрә торып черетәсез, янәсе. Тик аннары, әнә шул бер айлык "стажировка" вакытында, Александр Борисович ашыкмыйча гына аңа монысын да төшендерде. Баксаң, аңлы рәвештә шулай эшләнә һәм шулай эшләнергә тиеш икән бу. Әйтик, бер тонна яшелчә яисә җиләк-җимешне гамәлдән чыгару, урыслар әйтмешли, "списать" итү җәһәтеннән төзелгән актка кул куярга тиешле кешеләргә: "Менә ул яраксызга чыккан нәрсәләр" дип күрсәтү өчен беразын юри черетергә кирәк икән. Бу үзе генә дә бер фәнни өлкә диярлек була: склад мөдире һәр яшелчә, һәр җиләк-җимешнең кайчан, нинди шартларда бозылырга мөмкин икәнлеген дә белергә тиеш.

Алай гына да түгел. Ярый, ике-өч йөз килограмм нәрсәне черетеп, тоннага якынын гамәлдән чыгардың да, күпмедер "артык" нәрсә барлыкка килде ди. Аны складта тотудан беркемгә дә файда юк—тизрәк сатып акчага әйләндерергә кирәк. Ә аның өчен, миндә сул товар бар, алмыйсызмы, дип кычкырып йөреп булмый. Кибетләренә әйбер алучы директорлар белән эш итәргә кирәк, моның өчен аларны яхшы белү шарт. Беренчедән, склад кибет түгел, аннан турыдан-туры яшелчә дә, җиләк-җимеш тә сатып ята алмыйсың, икенчедән, бу эшне бик ышанычлы кешеләр аша гына майтарырга була... Александр Борисович аны бу нечкәлекләргә дә өйрәтте, бик ышанычлы булган берничә кибет директоры белән таныштырып калдырды. Аннары, бераз шомаргач, кирәкле кешеләрне үзе дә таба торган булды. Күп тә үтмәде, кечкенә солдат, кечкенә "грузчик" Исмәгыйль—Исмәгыйль Габдрахмановичка әйләнеп китте бит, әй!..

***

Фатыйма йокысыннан уянганда кыйгачлап төшкән кояш нурлары тәрәзә пәрдәләренең челтәрле-челтәрле бизәкләрен стенага төшереп куйганнар иде инде. Ул, бу күренешне әле беренче мәртәбә генә күргәндәй, бер пәрдәгә, бер аның стенадагы күләгәсенә караштыргалап торды. Ачык форточкадан кергән җиләс һава тәрәзә пәрдәсен беленер-беленмәс кенә селкетеп куя, шунда аның стенадагы челтәрле

күләгәсе дә сизелер-сизелмәс кенә хәрәкәтләнеп ала, челтәрле бизәкләр әле сулга, әле унга таба авыша, әйтерсең, экрандагы кино күренеше.

Фатыйма үзалдына елмаеп куйды: ул бу тәрәзә пәрдәсен үз куллары белән бәйләде бит! Менә хәзер аның иртәнге йомшак җилдә хәрәкәтләнүен, аның стенадагы күләгәсен күңелендә ниндидер канәгатьләнү хисе белән тудыргандай булды. Хәер, аның кулларыннан бер шушы тәрәзә пәрдәсе генә чыктымы?! Әнә, хәзер урындык башында эленеп торган, урын-җирне җыеп куйгач мендәрләре өстенә ябып куелачак зур гына челтәрне күр тагын! Һәр көн эштән кайтканнан соң ашап-эчеп алуга шуңа тотына иде. Шушы мендәрләр челтәрен бәйләүгә генә дә ай ярым чамасы вакыты китте! Аның каруы, карап туймаслык, күз явын алырлык нәрсә килеп чыкты! Мондый бизәк-рәсемле челтәрне кибетләрдә дә очрата алмыйсың.

—Ничек түземлегең җитә синең шундый вак-төяк эш белән бетәшеп утырырга?!—дип гаҗәпләнделәр ул чакта бүлмәдәш кызлары.—Күзеңне бетерәсең бит, җүләр!

—Әй-й, сез бу эшнең тәмен белмисез әле, тәмен!—диде ул аларга, челтәренең бәйләгән кадәре өлешен үзенең ак, матур куллары белән сыйпап.—Киресенчә, түземлелек, ихтыяр көче тәрбияләргә булыша бит ул! Бер мавыгып киткәч, ташлап булмый икән аны! Теләсәң дә ташлый алмыйсың...

Анысы дөрес тә бит. Һәркемнең җаны сөйгән, күңеленә яткан ниндидер үз шөгыле була: кемдер шырпы каплары, кемдер яраткан артист, җырчыларның рәсемнәрен, кемдер почта маркалары җыя, хәтта иске үтүк, иске самавыр җыючылар бар, ә Фатыйманың яраткан шөгыле исә челтәр бәйләү. Бу аңа—әнисеннән, әнисенә әбисеннән күчкән шөгыль. Хәер, ул тегү эшен дә бик ярата, үзе үк рәсемен ясап, үзе сызып-кисеп әллә ниткән фасонлы күлмәкләр дә тегә бит әле!

Урта мәктәпне тәмамлагач та, укырга кая керергә, дип баш ватып тормады. Казанга килеп, туп-туры тегүчеләр әзерләүче техник училищега барып керде ул. Инде аны тәмамлавына да ике елга якын, хәзер тегү фабрикасында эшли. Дөрес, әллә ни күп акча түләмиләр түләвен, тик аның өчен җаны яраткан эше булуы үзе зур бәхет.

Фатыйма стенада эленеп торган сәгатькә күз төшереп алды. Шушы бүлмәдә яшәүче иптәшләре белән җыелышып алганнар иде. Алтын йөгерткәндәй ялык-йолык килүче сәгать сигезенче ун минутны күрсәтә иде. Әлбәттә, әгәр эш көне булса, инде ул күптән аяк өстендә булыр иде. Ә бүген ял көне, урын-җирдә бераз иркәләнеп ятсаң да була, чөнки ял атнага ике генә көн бит ул. Еш кына шимбә көннәрендә дә эшләргә туры килә әле.

Ул өстендәге җәймәсен иягенә хәтле күтәрде дә күзләрен йомды. Их, рәхәт тә соң ял көннәрендә күзеңне йомып менә шулай ятуы—беркая ашыгасы юк, соңга калмыйммы, дип борчыласы юк. Ята бир шунда рәхәтләнеп, иркәләнеп, ял көненең тәмен тоеп!

Менә хәзер дә аның коңгырт күзләрен нәкъ менә шушы татлы уйлар йомдырды бугай. Ә күзен йомдымы, күз алдына шундук Габделбәре килә дә баса. Һәрвакыт чиста итеп кырынган түгәрәк йөзендә гадәттәге оялчанрак елмаюы белән килеп баса. Аның артка таралган куе кара чәчләре бераз гына дулкынланып тора, кызларныкы кебек сызылып киткән кара кашлары астыннан чем-кара күзләре ниндидер күренмәс якты нурлар сибеп тора сыман. Хәер, чынында ул нурлар юктыр да инде, ләкин Фатыймага нишләптер нәкъ менә шулай тоела. Аңа карап торганда ул бу нурларны күрә дә шикелле. Шундый нурлы күзләр, шундый матур, чиста йөз—ник бер мин, янсә сөял кебек нәрсә булсын!—бары тик аның Габделбәрендә генә кебек. Инде тиздән танышканнарына да ике ел тула, күз тимәсен, әле бер тапкыр да сүзгә килгәннәре, ачуланышканнары юк.

...Ә танышулары болай булды. Фатыйманың икенче сменадан кайтып килеше иде. Җәйге матур, җылы төн. Урам тып-тын. Инде төн тынлыгын бозып бик сирәк кенә үтеп-сүтеп йөргән трамвай да, Достоевский тукталышында берничә кешене төшереп калдырып, үзен менә шушындый матур җәй төнендә дә эшләтүләренә ачуы килгәндәй, рельс башларында ачу белән тыкырдый-тыкырдый борылышта күздән югалды. Аннан төшкән берничә кеше дә бераздан, аны урамда үзен генә калдырып, кайсы кая, төрле тыкрык һәм урамнарда эреп юкка чыкты.

Фатыймага куркыныч булып китте. Мондый чакта күңелне төннең май кебек җылылыгы да, соңарган кошларның ара-тирә сайраган тавышлары да тынычландыра алмый—аны ниндидер билгесез шомлы шикләнү хисе биләп ала. Шуңа күрә ул икенче

сменада эшләүне сөйми. Юк, эшен дә авырыксынмый, менә шушы төнге урамы куркыта иде. Җитмәсә, җәяү үтәсе ара да шактый әле.

Менә шундый төннәрнең берендә курка-курка урам уртасыннан атлаган Фатыйма янында әллә ниткән чыелдаган тавышлар чыгарып—тормоз тавышы иде бугай бу—кинәт "Жигули" машинасы туктады. Кыз ирексездән тротуарга таба тайпылып куйды.

—Курыкмагыз! Утырыгыз, әйдә, кая кирәк, шунда кайтарып куям,—диде аңа ир-ат тавышы татарчалатып.

—Рәхмәт, кайтып җиттем диярлек инде мин...—Фатыйма, тротуарга чыгып, шуннан бара бирде.

—Утырыгыз, диләр сезгә! Нәрсә, әллә куркасызмы?

—Менә тагын!.. Курыккан ди!—диде кыз, шикләнүен сиздермәскә тырышып.—Курыксам, төнлә йөрмим дә мин!

—Йә, батырайган булып маташмагыз,—диде шофер, машинасын яхшы ук яктыртылган ут баганасы янында туктатып.—Ни әйтсәң дә, төнге урам кыз кешене шикләндерәдер.

Шулчак Фатыйма да ирексездән адымын әкренәйтте һәм ирексездән елмаеп машина тәрәзәсеннән башын чыгарып карап торган шоферга күз төшереп алды. Аңа яшь кенә егет елмая иде. Кыз бераз тынычлана төшкәндәй булды, ләкин шулай да сер бирәсе килмичә:

—Мин өйрәнгән инде. Кайгыртуыгыз өчен рәхмәт,—диде һәм шундук адымнарын тизләтте.

—Ярар, алайса... Шикләнәсез икән, утырмагыз. Мин сезне болай гына озатып куям. Тулай торагыгызга хәтле...

—Минем тулай торакка кайтуымны каян беләсез?!—дип гаҗәпләнде Фатыйма.

—Беләм. Шушы вакытта кичә шунда кереп киттегез сез,—диде шофер, машинасы белән әкрен генә янәшә барып.

—Азмыни тулай торакка кереп китүче кызлар!—дип көлеп куйды Фатыйма, бераз ачыла төшеп.

—Мин сезне йөрешегездән үк таныдым. Күлмәгегез дә шушы иде...

—Бик күзәтүчән кеше, ахры, сез,—дип тагын көлде кыз, адымын бераз әкренәйтә төште.—Ләкин мин кичә бу вакытта йоклый идем инде.—Әлбәттә, ул монысын болай гына әйтте, чөнки ул эштән кичә дә нәкъ шушы вакытта кайтты. Бер атна—беренче, бер атна икенче сменада эшли ул.

Ләкин егет бик үзсүзле булып чыкты: инде тәрәзәсеннән башын чыгарып бер сүз дә әйтмичә, машинасын Фатыйма белән янәшә алып баруын белде. Бары тик тегүче кызлар яши торган тулай торак ишеге төбенә җитәрәк кенә:

—Сез өченче фабрикада эшлисезме?—дип сорады һәм көлемсерәп:—Рөхсәт итсәгез, мин сезне иртәгә дә менә шушылай гына булса да "озатып" куяр идем.

—Үзем дә яхшы озаям мин, борчылмагыз,—диде аңа Фатыйма, кулын ишек тоткасына куеп.—Хушыгыз!

Икенче көнне егет аны машинасы белән Достоевкий тукталышыннан бераз китүгә үк куып җитте һәм "Жигули"ен туктатты да, ишеген ачып:

—Хәерле төн, кыргый кызый!—дип елмайды.—Утырыгыз, "ә" дигәнче кайтарып куйыйм әле үзегезне!

—Бу тагын сезмени әле?!—дип чын-чынлап гаҗәпләнде Фатыйма.—Тик юкка борчыласыз—барыбер утырмыйм! Аякларым сау булсын...

—Нинди киребеткән кыз соң сез?!—диде егет. Тавышыннан бик аңлашылып та җитмәде: кызның бу кирелеген хуплый идеме ул, әллә шуның өчен ачулануы идеме?—Валлаһи дип ант итәм, мин сезгә бер начарлык та эшләргә җыенмыйм бит...

—Мин дә, җыенасыз, димим. Тик таныш булмаган кеше машинасына утырырга мине кем дип беләсез?—диде кыз төксе генә һәм тиз-тиз атлавында булды.

Егетнең "озатуы" бүген дә нәкъ кичәгечә килеп чыкты: тротуардан кыз атлый, ә аның белән янәшә, юлдан машина бара. Фатыйма тәмам тулай торак ишегеннән кереп югалганчы...

—Бу кадәр дә үҗәт булырсыз икән,—диде ул кыз инде ишек төбенә җитәрәк.—Тик мин сездән дә үҗәтрәк. Белегез аны!

Бу "озату" атна буе, тәмам икенче сменада эшләве беткәнче һәм нәкъ элеккечә дәвам итте: егет ничек кенә үгетләп карамасын, Фатыйманы машинасына утырырга

күндерә алмады. Бер караганда, бу шофер егетнең йомшак тавышыннан ниндидер эчкерсезлек, үзенә җәлеп итә торган ышанычлылык та яңгырый, аңа ышанырга да була кебек, ләкин шул ук вакытта кыз күңелендә гадәттә авыл кызларына гына хас нииндидер курку хисе, юк, курку хисе дә түгел, ә үз-үзеңне көтелмәгән рәнҗетүдән, көтелмәгән ояттан саклану хисе дә сиздерә иде. Хәер, моны аңлавы да авыр, бу, мөгаен, хатын-кызга кыз туганнарыннан—әбиләреннән, әнисеннән буыннар аша күчә торган нииндидер саклану чарасы иде бугай.

Бу атна бетеп, Фатыйма беренче сменада эшли башлады. Хәзер эштән дә вакытында чыга, беркемнән дә шикләнмичә көпә-көндез кайта. Рәхәт, урам тулы халык. Шул ук вакытта ул моңа ... шатланмый да кебек: менә шушы шау-шулы урамда нидер җитеп бетми бугай. Әллә ул бу урамда үзе артык, әллә бу шау-шулы көндезге урамга аның җаны теләгән тынлык җитми,—аңламассың... Ул икенче сменада эшләгәндә шушы Достоевкий урамы буйлап курка-курка атлагандагы төнге тынлык җитми, ахрысы. Әллә шул тынлыкны бозып тормозлары белән чыкырдап, чыелдап кинәт кенә килеп туктаган машина тавышы җитмиме? Әллә шул машина тәрәзәсеннән инде берничә төн рәттән ишетелгән ягымлы тавыш юксындырамы? Әйе, шулай бугай, Фатыйманың колаклары һәм, әлбәттә, күңеле дә теге егетнең колакка ятышлы, ягымлы тавышын юксына бугай. Шулай булмыйча! Бик тә ягымлы, бик тә эчкерсезгә охшаган тавыш иде бит ул, каһәр!

Фатыйманың бу атнасы әнә шундый юксыну, икеле-микеле, хәтта нииндидер үкенечле хисләр белән узды. Дөресен генә әйткәндә, ул, үзенең гаҗәпләнүенә каршы, тизрәк икенче, төнге сменасы килеп житүен теләде. Әйе, теләде шул, бик теләде. Хәзер аның башына: "Ә бәлки..." дигән нииндидер өмет сарган уй килгәли иде.

Курыкканың буш, юраганың юш булсын, дигәндәй, ниһаять, Фатыйманың беренче сменалы атнасы үтеп тә китте һәм төнге сменасындагы беренче көнендә "Жигули" машинасы аны туктадышта, трамвайдан төшеп бераз китүгә үк диярлек куып җитте. Кыскасы, барысы да күңеленнән үзе теләгәнчә килеп чыкты: егет машинасын туктатты да, ишеген ачып:

—Утырыгыз, үҗәт кыз! Бу юлы үтенеп сорыйм,—диде һәм елмаеп куйды. Хәер, кем белә, бәлки елмаймагандыр да ул, ләкин кызга шулай тоелды.—Сездән дә үҗәтрәк, дип әйткән идем бит мин. Әгәр дә хәзер үк килеп утырмасагыз, белегез аны, каравыл кычкыртып үзем утыртам!..

—Тагын сезмени әле бу?!—гаҗәпләнгән булды Фатыйма, мөмкин кадәр ваемсызрак булырга тырышып. Ә бит үзе яшертен генә көткән иде бу минутны!—Үҗәт кенә түгел, үҗәтнең дә үҗәте икән сез!..

—Шулай шул. Дөрес әйтәсез,—диде егет, бөтен йөзе белән балкып.—Утырыгыз инде, әйдә, ялындырмагыз!

Нишләтәсең, шулай ялындырып булса да утырды Фатыйма. Менә шушы кичтә танышып китте алар. Хәер, танышып китте дигәч тә, ул чакта, егетнең машинасына кереп утырган шушы беренче көнне, дөресрәге, төнне, Фатыйма үзен эзәрлекләүче бу егетнең исемен генә белеп калды бугай, чөнки тулай торак янына минут эчендә килеп җиттеләр. Егет Габделбәр исемле икән, үзе әйтмешли, бер начальникне йөртә икән. Беренче танышу-белешүләре менә шул булды. Дөрес, инде тулай торак янына килеп туктагач, Габделбәр Фатыйма белән бераз сөйләшеп утырырга теләгән иде дә, тик кыз үз дәрәҗәсен белеп кенә, инде соң икәнлеген сылтау итеп, аның бу тәкъдимен кире какты. Үзе күңеленнән: "Беренче көнне үк алай ачылып китү килешеп бетмәс",—дип уйлап куйды.

Ничек кенә булмасын, гәрчә озаклап сөйләшеп тормасалар да, Фатыйманың күңелендә нәкъ менә шушы беренче көннәре (төннәре!) матур хатирә булып сакланып калды. Әлбәттә, аннан соңгы ике ел эчендә йөзләрчә озатулар да булды, кинотеатрларга барулар да шактый булды, үбешү-кочаклашулар да күп булды. Ә менә беренче мәртәбә үзара танышулары нииндидер матур, якты һәм башка мәңге кабатланмас җыр булып калды

Габделбәрнең үҗәт кыз Фатыйманы төнге эзәрлекләүләре әнә шулай тәмамланды. Инде танышып шактый гына вакыт узгач, ул аны нәкъ менә шул үҗәтлеге өчен ныграк яратуын әйтте...

Җәйнең бер матур кичендә "Мир" кинотеатрында кино караганнан соң кайтып килешләре иде.

—Хәтерлисеңме, Фатыйма, мин беренче мәртәбә сине утыртырга дип машинамны менә шушы йорт янында туктаткан идем,—диде Габделбәр, бер кулы белән кызны биленнән үзенә таба тартып.

—Куркытып бетердең син мине ул чакта. Шайтан хәтерләгән аның кайсы төштә икәнен,—дип көлде Фатыйма, кулын биленнән алып.—Төн уртасында ялгыз кыз бер дә белмәгән-күрмәгән кеше машинасына утырамы инде?!

—Әй, ничек кенә утыралар әле!—дип елмайды егет. Аннары бу сүзләр Фатыймада начар уй тудыруы мөмкинлеген сизеп бугай, сүзен башкача, йомшаграк итеп очлап куйды:—Төрле кеше бар инде... Беләсеңме, нәрсә...—Ул, кирәкле сүзен эзләгәндәй, бер мәлгә генә тирә-ягына каранып алды.—Әгәр дә шул бер әйтүдә килеп утырган булсаң, бәлки мин синең яныңа башка килеп тә йөрмәс идем...

—Ә нигә?

—Миңа синең әнә шул үҗәтлегең ошады: мин аны татар кызларына хас тыйнаклык дип аңладым. Бу акыллы кыз икән, дип уйладым.—Егет көлеп куйды.—Шуннан соң үзем дә үҗәтләнеп киттем. Сине кулдан ычкындырасым килмәде...

—Шулай диген инде... Ә мин, киресенчә, бу ир-ат төнлә менә шулай хатын-кызларны аулап йөри икән, дип уйладым,—диде Фатыйма елмаеп.—Минем куркуымны күрсә-ә-ә-ң!

—Бер дә сиздермәдең әле үзең...

—Тырышкан булдым инде, үземчә. Сер бирәсем килмәде!

Икесе дә көлеп куйдылар.

...Менә хәзер боларның барысы да юрганын иягенә хәтле ябынып татлы уйларга талган Фатыйманың күз алдыннан кино кадрлары сыман берничә секунд эчендә узып китте. Аның алсу иреннәренә елмаю кунган иде. Рәхәт иде аңа бу минутларда. Рәхәт иде, чөнки, Аллага шөкер, үзе сау-сәламәт, җир җимереп эшләп йөри, күңеленә хуш килгән эше бар, җаны яраткан, дөньяда бердәнбере дип санаган кешесе бар. Инде бу мәсьәләдә эшләр өйләнешүгә таба бара, дип тә шикләнмичә әйтергә була. Бәхет өчен кыз балага ни кирәк тагын?!

***

—Әллә бүген син мине үтертергә җыенасыңмы?—диде Исмәгыйль, үзенең зур итеп ачылган соры күзләрен Габделбәргә ачу белән төбәп.—Теге чатта чак кына "Вольво"га бәрелми калдың, монысында мөгезсез сыер шикелле кызыл утка килеп кердең. Ни булды сиңа бүген?

Үз уйларына чумып тәмам дөньясыннан онытылып барган Габделбәр шефының бу сорауларыннан соң гына бер мәлгә айнып киткәндәй булды. Юк, айнып та җитмәде, ә арткы урыннарның берсендә утырып барган хуҗасының нидер әйткәнен генә ишетте бугай.

—Нәрсә дидегез?—дип сорады ул, аңа таба борылып.

—Син нәрсә, бүген ишетмисең дәме әллә? Сәер син бүген, дим. Үзең руль артында утырасың, ә уйларың бөтенләй башка җирдә кебек. Бәрдерә күрмә, иманыңны укытам, дим.

—Беренче көн генә йөртмим бит инде мин машинаны! Курыкмагыз, Исмәгыйль Габдрахманович, бер кино герое әйтмешли, "усю будет в порядке, без шуму и пылинки",—дип тапкырлыгыннан канәгать булып, шофер үзенең ап-ак һәм энҗедәй тигез тешләрен күрсәтеп елмаеп куйды.—Бәрелмибез дә, бәрдермибез дә, Алла боерса!

—Карап йөрмәсәң, боерыр ул сиңа! Беләсең килсә, сакланганны саклармын, дигән ул. Ишеткәнең бармы шуны?

—Булмыйча! Шуңа күрә бик аккуратно гына йөрим дә мин!..

—Ярар, ярар, шапырынма! Җүләр үзен мактар ди... Әйдә, алдыңа гына карап бар! Әле яшисем килә минем...

—Кемнең дә яшисе килә инде ул, Исмәгыйль Габдрахманович. Бер җырда әйтелгәнчә: "Габделбарый, карале, алда тормыш бар әле"...

—Яшәрсең, яшәрсең. Барысы да алда әле синең... Мине харап итә күрмә, дим...

—Курыкмагыз, барыбыз да яшибез әле, Алла боерса...

Икесе дә үз уйларына чумды бугай, шактый вакыт дәшмичә генә бардылар.

"Барысы да алда әле синең, имеш,—дип Габделбәр, кемгәдер ачулангандай,

күңеленнән шефының сүзләрен кабатлап куйды.—Монда хәлләр "алла"дан да алдарак килеп тора әле..."

Дөресен генә әйткәндә, бүген аның кәефе бик начар иде. Хәер, кистереп, бик начар иде, дип тә, яхшы дип тә әйтә алмый иде бүгенге аңлаешсыз халәтен. Күңелен ниндидер кәтелмәгән билгесезлек биләп алган иде. Бер караганда, әле кичә генә Фатыймасыннан ишеткән хәбәргә шатланырга, сөенеченнән аны кулларына күтәреп алырга, шул күтәргән килеш тәмам башы әйләнгәнче бөтерелергә-әйләнергә тиеш иде кебек югыйсә. Тик нишләптер алай килеп чыкмады...

Бүлмәләренә Габделбәр килеп кергәндә, Фатыйма анда бергә яши торган Фәридә исемле кыз белән икесе генә иде. Ул кергәч, үзенә ниндидер йомыш тапкан булып, кайчан гына килсәң дә гел китап өстенә иелгән Фәридә каядыр чыгып китте. Икәүдән-икәү генә калдылар.

—Өйдән хат алдым, сиңа да күп сәлам әйтергә кушканнар,—диде Габделбәр, костюмын элгечкә элеп. Хәзер ул бу бүлмәдә үзен шактый иркен тота иде.

—Рәхмәт. Миннән дә сәлам юлларсың. Йә, ничек анда синекеләр: авырмыйлармы?

—Барыбыз да исән-саулар, дип язалар. Авырырга да вакытлары юк инде аларның авыл җирендә—эш тә эш! Ә синекеләрдән хат-хәбәр бармы? Алар ничек?

—Яшәп яталар бер көе. Казанга килгән чакларында әти үзе дә кагылгалый. Болай исән-саулар...

—Алайса, ярый. Сагынып беттем инде сине, Фатыйма!—диде Габделбәр, аның биленнән кысып.

—И-и, җүләр, ике-өч көндә сагынып бетәләрме инде?!—Фатыйма, күзләрен шаян ялтыратып, үзенең бәрхеттәй йомшак тавышы белән бүлмәне яңгыратып иркенләп көлеп алды.

—Сиңа көлке. Сиңа гел көлке. Яратам, дим—көлке, өйләнешик, дим—тагын көлке,—диде егет, кызның ике чигәсенә бөдрәләнеп төшкән чәчләрен колак артларына кыстырып.—Җитди генә сөйләшеп тә булмый синең белән...

—Нишләп булмасын,—диде Фатыйма, кинәт көлүеннән туктап.—Ләкин өйләнү—сөйләнү генә түгел бит ул, Габделбәр. Кочаклашып яту гына да түгел...

—Әйттең сүз! Минем кайчан: "Өйләнү—кочаклашып яту", дигәнем бар?—дип сорады Габделбәр.—Мин дә, син дә бала-чага түгел. Йөрүебезгә дә ике елдан артып китте. Бер-беребезне беләбез. Күптән өйләнергә вакыт...

—Сине яхшы белмәсәм, йөрмәгән дә булыр идем. Ә өйләнешү мәсьәләсендә...—Фатыйма кинәт чигәсеннән аның кулын алды.—Миңа син һаман, өйләнешик тә өйләнешик, дисең, Ә мин синнән һаман: "Кайда яшәрбез: син бер тулай торакта, мин монда шушындамы?"—дип сорыйм.

—Сораган саен мин сиңа:—Берәр бүлмә булса да алып торырбыз,—дим түгелме? Яшиләр бит әле шулай...—Габделбәр тавышында бераз ачулануны, ниндидер ризасызлыкмы чагылып китте.—Кешеләр яшиләр бит әле шулай,—дип, бу юлы басым ясап, ниндидер кискенлек белән кабатлады ул тагын. Синеңчә, "Сөйгәнең белән шалашта да җәннәт", дигән әби-бабайлар хаклы булмаганмыни?

—Кеше өстендә тору—кеше өстендә тору инде ул! Кечкенә генә булса да, үз куышың булу яхшыдыр, минемчә.

—Куышыбыз юк, дип хәзер миңа шулай аерым-аерым яшикме һаман? Бер-беребезне яратышабыз бит без, Фатыйма. Нигә һаман киресен сукалыйсың?

—Димәк, куыш турында уйларга кирәк. Бу турыда беренче генә әйтүем түгел бит. Кеше өстендә торучылардан түгел, үзләре аерым яшәүчеләрдән үрнәк алырга кирәктер, Габделбәр...

—Әйтүе генә ансат. Фатир алу җиңел эш түгел шул хәзер...

—Беркем дә җиңел, дими. Мәсәлән, хәзер син эшли торган ул шәхси предприятиедә аны гомердә дә алып булмый бит...—Фатыйма үзенең зур, коңгырт күзләрен тутырып аңа карады. Аннары ике кулы белән аның кулын тотып үз битенә тидерде.—Бәлки, фатир алып була торган җиргә керергәдер? Кешеләр, шул фатир-фатир дип, авыр булса да, төзелештә эшләп чиләнә. Кайсыбере хәтта дворник булып та эшли әле...

—Син дә кулыма себерке тотып ишегаллары себереп йөрүемне телисеңме әллә, Фатыйма?!—дип гаҗәпләнде Габделбәр.—Шофер бит мин, шофер! Иң яраткан эшем бит бу минем! Миңа шуны аңлыйсыңмы син?

—Аңлыйм мин, бик аңлыйм. Ул шоферлар төзелешкә дә кирәктер?

—Эшләдем мин анда армиягә хәтле. Акчасы аз аның анда. Ә монда миңа өч мәртәбә артык кереп бара,—диде Габделбәр һәм өстәл янына килеп утырды.—Аннан соң монда машинасы да үз кулымда… Төннәрен сине каршы алырга. Карале, Фатыйма, капкаларга берәр нәрсә бармы? Тамак ачты…

Фатыйма өстәл әзерләргә кереште: казылык белән ипи, күмәч кисеп куйды, тиз генә кухняга чыгып чәй җылытып алып керде. Аннарыияген бер кулына куеп, ниндидер бер самимилек белән Габделбәрнең ашавын күзәтеп утырды. Егетнең кайчакларда менә шулай үзендә ашап утыруын карап торырга ярата иде ул. Тиз генә хәстәрләп алган шушы табын булачак гаилә тормышларының кечкенә генә бер мизгелен күзалларга мөмкинлек бирә шикелле. Менә шушы мизгелләр аны үзен Габделбәрнең хатыны, шушы өстәлнең, шушы бүлмәнең хуҗабикәсе итеп тоярга булыша иде сыман.

—Ничек булса да, башта фатир ягын җайларга кирәк, Габделбәр,—диде Фатыйма, өзелгән сөйләшүләрен дәвам итеп.—Син зур акча эшләп, аны сатып алып булыр дисеңме?

—Булыр сиңа! Беләсеңме, күпме тора ул хәзер?!—диде егет, хәтта бер мәлгә ашавыннан туктап.

—Алайса, моны ничек хәл итмәкче соң син?—Фатыйма туп-туры аның күзләренә карады.—Өйләнештек ди. Шуннан?

—Шуннан, шуннан,—дип кабатлады Габделбәр ачу белән.—Утырган да шуган шуннан!—Ул, кулындагы ипи телемен өстәлгә куеп, торып басты.—Әле генә сөйләшкәннәрне яңадан башлыйбызмы? Гафу ит, кайчакта синең миңа чыгасың килми шикелле...

—Вәт җүләр! Әйттең сүз!—дип көлде Фатыйма һәм, урыныннан торып, кулы белән аның кара чәчләрен сыйпап куйды.—Синнән башка кемгә чыгыйм ди мин?! Утыр, аша! Ачуланма!

—Яшиләр бит әле... Башта берәр кешедән бүлмә-фәлән алып торырбыз... Аннары күз күрер... Йә әйт, бүлмә турында белешә башлыйммы? Синен миңа "әйе" дигән бер сүзең җитә, атна-ун көн эчендә табам мин берәр бүлмә. Йә, ничек?

—Карале, Габделбәр,—диде кинәт Фатыйма, егетенең әле генә әйткән сүзләрен ишетмәгәндәй. Аның менә хәзер бик зур яңалык әйтергә җыенганын раслаган шикелле, хәтта күзләре ниндидер серлелек белән очкынланып-янып куйды.—Берүк шатлыгыңнан идәнгә ава күрмә! Әйтимме?

—Сузма, Фатыйма, сузма, әйтсәң әйт тизрәк! Идәнгә үк егылып китәрлек нинди яңалык икән ул?

Фатыйма, су астына чумарга җыенган кеше шикелле бик тирән итеп сулыш алды да, ике кулы белән урындыкта утырган Габделбәрнең муеныннан кочаклап, аның колагына әкрен генә:

—Безнең бәбиебез булачак, Габделбәр!—дип пышылдады.—Кечкенә Габделбәребез булачак...

—Нәрсә, нәрсә?!—диде егет, әле генә ишеткәненә ышанырга да, ышанмаска да белмичә.—Кабатла әле, Фатыйма, тагын кабатла!

—Кечкенә малаебыз булачак!—диде Фатыйма бу юлы ачык һәм шактый ук көчле итеп.—Бөтен билгеләре шулай...—дип өстәде ул аннары әкрен генә.

—Бу дөресме соң инде, ә, Фатыйма?!—диде бу яңалыктан соң бераз вакыт ни әйтергә дә белмичә сүзсез торган Габделбәр.—Бу шундый шатлык... шатлык дияргә була... Чыннан да, аркан авып китүең дә бар моңа...

—Әйтәм бит, билгеләре шулай... Хатын-кызлардан ишеткәнем бар...

—Сакланырга кирәк иде безгә...—дип куйды шунда егет, ни турындадыр уйлангандай. Ниндидер үкенү яисә Фатыймасын кызгану хисе ята идеме бу сүзләрдә, аңлашылмады.—Синекеләр белсә дә уңайсыз, безнекеләргә ишетелсә дә...

—Анламадым, син бу хәбәргә шатмы, әллә мине гаепләп маташуыңмы?—диде Фатыйма, кинәт кулларын аның муеныннан алып.

—Мин шат... Шат, әлбәттә. Бигрәк ни... көтелмәгән яңалык бит... Нишләп гаеплим ди мин сине? Ничектер вакытсызрак шикелле, дим... Бәлки, дөрес тә түгелдер әле, ә, Фатыйма? Үзең әйтмешли, монда әле куыш та юк, ә ни... бәби, дисең... Ни әйтергә дә белмәссең монда... Алай да табибларга күрен әле син, Фатыйма, күрен... Бәлки, нидер... дөрес түгелдер...

—Күрәм: бу хәбәр сөендерү түгел, пошаманга төшерде бугай сине,—диде Фатыйма, үз-үзе белән сөйләшкәндәй, уйчан гына. Һәм әкрен генә елап җибәрде.—Шатланырсың дип уйлаган идем мин. Ә син...

—Мин шат... Шат, дидем бит... Синең өчен генә бит мин. Әтиең-әниең ишетсәбелсә, дим... Ярар, елама, башта табибка күрен, тикшерт... Дөрес икән, хәзер елап ни файда? Бүлмә мәсьәләсендә белешкәләп йөрермен... Менә шулай. Ярый, киттем мин, Фатыйма...

—Без бүген театрга барырга дип сөйләшкән идек түгелме?!—дип гаҗәпләнде кыз, күзләрен түгәрәкләндереп.—Ни булды? Кая ашыгасың шулай?

—Гафу ит, Фатыйма, мин сиңа килүгә әйтмәкче идем... Бүген бер көтелмәгән эш килеп чыкты. Бер иптәшем машина ремонтларга булышырга сораган иде. Бик сораган иде... Дус кеше... Бармасаң, уңайсыз...

—Кем ул?—дип сорады кинәт Габделбәренең күз алдында үзгәреп калганын күрепсизеп торган Фатыйма.—Синең дусларыңны беләм бит мин...

—Юк, монысын белмисең,—диде Габделбәр.—Белмисең монысын. Көтә ул мине. Ярый, Фатыйма, ачуланма! Театрга башка вакытта...

Ул саубуллашып чыгып китте. Ялганлады Габделбәр—аны бернинди дусты да көтеп тормый иде. Ул шул минутта кинәт кенә башына килгән сәбәп иде. Дөресен генә әйткәндә, бүген Фатыймасы янына килүе дә, үзара алдан сөйләшенгәнчә, театрга бару өчен иде. Камал театрына "Ай булмаса, йолдыз бар..." дигән спектакльгә барасылар иде. Ләкин бер дә уйламаганда гына барысы да үзгәрде дә куйды. Хәер, кинәт кенә дә түгел инде, бер караганда. Башта Фатыймасы фатир турындагы сүзләре белән күңелен тырнап куйды. Әйтерсең ул үз фатирыңның яхшы икәнлеген аңламый торган аңгыра. Ләкин кайда соң ул үз фатирың? Юк бит ул, юк! Аны элек тә алулар җиңел түгел иде. Ләкин чиратка баскан кеше берничә еллардан соң барыбер яңа фатирга ия була ала иде. Ә хәзер, элек тырыша-тырмаша коммунизм төзеп яткан ил капитализмга йөз тота башлагач, ул элеккеге чиратлар күп җирдә гомумән юкка чыкты, хәзер үз көненне үзең күрәсең, хәзер бар нәрсә дә акчага гына корылган. Фатир мәсьәләсендә дә шулай: фатирлы буласың килә икән—сатып ал! Ә бәяләре—ай-яйяй! Буең җитәрлек түгел. Менә шушы хәлләргә Габделбәрнең болай да ачуы килеп чарасыз булып йөри иде. Мөмкинлеге булса, илне таратып аны шушындый көнгә калдырган кешеләрне, үзе әйтмешли, тотып асар иде ул.

Ә монда сүз тагын болай да күңелен һаман борчып килгән шул фатир турында... Кешеләр аның өчен ишегалларын себерүчеләр булып та эшлиләр, янәсе. Кем әйтә диген әле шушы сүзләрне! Фатыймасы, сөеп-яратып йөргән, инде язмышын бергә бәйләргә йөргән кешесе! Кемгә әйтә бит әле! Тормышын машинадан башка күз алдына да китерә алмаган шофер кешегә, Габделбәренә! "Димәк, аның өчен мин кулыма себерке тотып ишегалды себереп йөрсәм дә барыбер?!—дип ачынып уйлап алды ул, ниндидер эчке ярсыну белән.—Юк инде, Фатыймакай, булмас монысы: Габделбәр асфальт себереп, кышын кар көрәп йөрмәс!" Ул менә хәзер уйлаганын шактый ук үтемле итеп, хәтта бераз тупасрак рәвештә, икесе генә фатир турында сөйләшеп утырганда ук әйтмәкче иде дә, ярар, телен тешләп булса да түзде инде, араларын салкынайтасы килмәде. Яхшы итеп әйтәсе килгән иде килүен. Әллә кем булып, мыскыл итеп утырганы өчен...

Анысы гына җитмәгән, бәби турындагы хәбәрне әйт тагын. Бу турыда уйлап та караганы булмаган вакытта, искә дә килмәгән чакта. Шуңа күрә бу көтелмәгән хәбәрне ничек кабул итәргә дә белмәде ул. Әйе, әйе, шатланырга идеме аңа, әллә уйламаганда башка килеп төшкән зур кайгы итеп кабул итәргә идеме? Югалып та калырсың, аяз көнне яшен суккандай яңгырады бит ул яңалык. Алай гына да түгел, ул, бер караганда, гәрчә бу икесенең дә уртак гөнаһысы булса да, икенче яктан, ул нигәдер Габделбәрнең күңеле тарафыннан ни өчендер Фатыймасының хыянәте итеп кабул ителде бугай. Моның алай түгел икәнен дә аңлый, белә, ләкин, ничек кенә булмасын, күңеле аны нәкъ менә шулай итеп кабул итте. Шул мизгелдә моңарчы яратып йөргән, инде өйләнергә җыенган иң якын кешесенә күңелендә ниндидер күралмаучанлык очкыны чәчрәп киткәндәй булды. Алай булырга тиеш түгеллеген дә аңлый, ләкин, нишләтәсең аны, нәкъ араларыннан кара мәче йөгереп узгандай булды. Әйтерсең, Фатыймасы аңа бала турындагы хәбәрне җиткермәде, ә Габделбәргә кемдер, бөтенләй башка берәү Фатыймасының—аның Фатыймасының!—аңа хыянәт итеп йөрүе турында йөзенә

бәреп әйтте... Шуңа күрә кинәт әллә нәрсә булды: аның бүген, менә хәзер, Фатыймасы янында каласы килмәде...

Төнге йокысы да рәтле булмады: әллә йоклады, әллә юк шунда... Әллә гел ни турындадыр уйланып яттымы?

Икенче көнне эштә дә кәефе начар иде. Күңелендә һаман Фатыймасы белән булган кичәге сөйләшүләре тынгы бирмәде...

—Алай да ни булды сиңа, Габделбәр, балтасы суга төшкән кеше шикелле син бүген,—диде Исмәгыйль, шулай шактый гына сөйләшмичә бара торгач, авыр тынлыкны бозып.—Гаиләңдә берәр нәрсә килеп чыктымы әллә, дияр идем, син өйләнмәгән...

—Күңелсезлек өйләнгәнме, юкмы дип сорап тормый шул, Исмәгыйль Габдрахманович...—Шоферның әллә ни сөйләшәсе дә килми иде бугай, ул, үзенең уйларын бүлдергәнгә ачуы килгәндәй, ниндидер ризасызлык белән тиз генә шефына карап алды.—Аның үз эше... Көтмәгәндә килә дә тәрәзә кага ул...

Габделбәрнең бу сүзләре машинаның арткы утыргычында баручы Исмәгыйльне кызыксындырып җибәрде. "Нинди кайгы төшкән соң әле бу егет башына?—дип уйлап алды ул эченнән генә.—Әле моңарчы бер вакытта да бүгенгедәй кәефсез чагы юк иде бит..."

—Әйт, ни булды? Җиңеләеп китәрсең,—диде ул, аның хәленә керергә теләгәндәй.—Шикләндереп җибәрдең син мине...

—Нәрсәсен сөйлисең аның?.. Гадәти хәл...—дип куйды шофер теләр-теләмәс кенә һәм шактый вакытка тынып калды. Күрәсең, сөйләргәме, юкмы, дип икеләнә иде. Тик бераздан гына кемнедер гаепләгәндәй, уң кулы белән рульгә сукты да дәвам итте.—Яшәргә урының булмасын, тормышмыни бу?! Күптән өйләнергә вакыт, ә кайда торырга?

—Аңладым. Торак—проблемаларның проблемасы шул хәзер.

—Проблема шул менә! Җитмәсә, йөргән кызым авырга узган... Кая алып кайтыйм мин аны хәзер?!

—Хәлләр мөшкел икән синең, дускай,—дип башын чайкады Исмәгыйль.—Әйтәм аны, әллә ничек син бүген...

—Булырсың монда әллә ничек,—диде Габделбәр төрпә генә, әйтерсең шушындый хәлгә начальнигы гаепле.—Нишләргә дә белгән юк...

—Ашыккансыз бала белән.

—Кем белгән бит аны... Көтмәгәндәрәк килеп чыкты шул.

—Ярар, кайгырма! Берәр җае чыгар әле. Җан биргәнгә җүн бирми калмас.

—Белмим, белмим. Хәзергә җүн бирер урыны күренми шул әле,—дип көрсенде шофер.—Башка кайгы төште, нишләргә дә белгән юк. Төшерергә кирәктер, мөгаен, ул баланы. Аны тапса, хатынны тулай торактан куып чыгарулары да бар...

Бүгенге көн Габделбәргә ай булып тоелды бугай.

***

Бәхетне һәр кеше үзенчә аңлыйдыр, шуңа күрә һәркем үзенчә бәхетледер. Аның ниндидер чикләре, аны фәнни билгеләү ысуллары да, чаралары да юк. Кемдер бүген ашарына кара ипие, бәрәңгесе булса да үзен чиксез бәхетле дип саный, ә кайберәүләр бәхетне зур, иркен фатирында акча кытлыгы сизмичә яшәүдә, шуның өстенә тагын шәһәрдән читтә, матур табигать кочагында заманча, башкаларныкыннан биегрәк тә, зуррак та итеп салынган коттеджы булуында, кыйммәтле чит ил машинасында йөрүдә күрә.

Хәзер "Исмагфрукт" фирмасының генераль директоры булып эшләүче Исмәгыйль Газизуллин бәхетлеләрнең шушы категориясенә керә. Ул үзен гел бәхетле кеше дип саный килде. Дөресе дә шулай. Солдат хезмәтеннән соң Казанга кайтып кибеткә йөкче булып кына кергән иде, ниндидер биш-алты ел эчендә шәхси фирма хуҗасына әйләнде дә куйды! Әгәр дә мәгәр язмыш аны Чибәр хатын һәм аның хуҗасы Эльза Константиновна белән очраштырмаган булса, аның тормыш сукмаклары кайсы тирәләрдә бөтерелер дә, кайларга алып чыгар иде. Кем белә, бәлки әле һаман кибетләрдә капчык-каплар ташып йөрер иде. Моны очраклылык димичә, ни дисең? Әлбәттә, Исмәгыйль уенча, монда аның ул чакта яшь, солдаттан кайткан гына вакыты булуы да, төскә-биткә чибәрлеге дә зур роль уйнады. Хатын-кызга ир-ат буларак ошадыңмы, ул

сине патша итәргә әзер! Тора-бара, тормыш уртасында һәм дәрәҗәле кешеләр арасында кайный башлагач, ул моның дөреслегенә кырыкмаса кырык тапкырлар инанды.

Әйе, кайчак тормыш катлаулы да, кайчак үтә гади дә икән. Шуңа күрә аны аңлавы да авыр. Язмыш сукмаклары йөртәме анда кешене, әллә очраклылыкмы, әллә бәхетме? Әллә алар барысы да бер төенгә төйнәлгәннәрме? Моңа җавапны абруйлы исем-дәрәҗәләр йөртүче галимнәр дә белмидер.

Үзгәреш җилләре Исмәгыйльне дә әйләнеп үтмәде. Башта аукционга "куелган" бер зур кибетне, аннары тагын икене һәм офисы өчен бер конторане сатып алды. Юк кына бәяләргә. Андый нәрсәләрнең аукционга куелуы исә күз буяу, дөресрәге, шундый алыш-бирешләргә законлылык төсмере бирү өчен генә булды. Аларны кем сатып аласылары әллә кайчан билгеле, сөйләшенеп куелган иде.

Монда да Эльза Константиновна булышты. Дөрес, сәүдә, финанс мәсьәләләрендә инде Исмәгыйль үзе дә күп нәрсәне, үзе әйтмешли, күп нәмәстәкәйне, иң мөһиме— илнең кайсы сукмакка борылуын ачык аңлап алган иде. Инде ул читтән торып финанс-экономика институтын да тәмамлады. Анда да шул Эльза Константиновна киңәше һәм булышлыгы белән керде ул. Шунысы кызык: хәтта имтихан биреп тормыйча студент булып китте! Күрәсең, һәр җирдә сүзе үтә торган бу хатын мәсьәләне тиешле кеше белән үзе хәл иткән. Ул аңа бер очрашуларында:

—Сиңа бу институтны, һичшиксез, тәмамларга кирәк, Исмәгыйль! Әйдә, быел читтән торып булса да укырга кер!—дип кире каккысыз итеп әйткән иде.

Керде, укыды. Бер кергәч, кеше көлдерәсе килмәде—тырышты. Менә инде бер ел чамасы ул югары белемле гендиректор! Заманча җиһазланган үз офисы, өч зур кибете бар. Алар кайчандыр дәүләтнеке иде.

Кыскасы, матди яктан Исмәгыйльне дөньяда бәхетле кешеләрнең бәхетлесе диярга була. Дүрт бүлмәле фатиры, Боровое Матюшинода дача-коттеджы бар, яраткан хатыны янында. Дөрес, хатыны Людмила рус милләтеннән. Яшелчә базасында бухгалтер булып эшли иде, шунда таныштылар. Хәзер ул—үз фирмаларының баш бухгалтеры. Чын мәгънәсендә зур хәрефтән "Бәхетлеләр" дип әйтү өчен бу гаиләгә ни кирәк тә ни җитми тагын? Юк шул, тормыш дигән нәрсәнә юкка гына катлаулы димиләр, анда һәр яктан да бәхетле булган кеше юктыр, булырга мөмкин дә түгелдер, чөнки галәм чиксез булган кебек, кешенең ихтыяҗлары да иксез-чиксез бит аның. Бар, канәгатьләндереп кара син аны!

Ә менә бу гаиләгә бәхет дигән нәрсәнең иң гадие, ләкин үзләрен бик бәхетсез дип санаган бик күп гаиләләрдә дә була торганы җитенкерәми: Ходай аларны баладан мәхрүм иткән иде. Ә баласыз ана чәчәк атмаган гөл яисә чәчәк атып та җимеш бирмәгән агач инде ул. Ата кеше дә үзен шул хәлдә сизәдер. Ә бала кирәк иде, икесе дә көтәләр иде аны. Өйләнешеп бергә яши башлауларына да дүрт елдан артып китте, ләкин өзелеп көткән йөрәк парәләре юк та юк. Баштарак өметләрен өзмәделәр әле— көттеләр. Бер ел, ике ел өметләнделәр. Шуннан соң икесе дә табибларга күренде, шунда Людмиланың бала тудырырга сәләтсез булуы ачыкланды. Нишләтәсең: "Балагыз булмаячак",—дип кистереп, күзгә карап әйттеләр. Әлбәттә, икесе өчен дә үзәк өзгеч карар иде бу. Юкса хатынының нәселләрендә булмаган нәрсә. Табиблар ниндидер өмет чаткысы калдырсалар да бер хәл: бернинди акча да кызганмыйча, хәтта бу өлкәдә иң абруйлы саналган теләсә нинди чит ил клиникаларында да дәваланып карарлар иде. Юк шул, юк, булмый, дип күзләренә бәреп әйттеләр.

Шулай итеп, бөтен яктан да бәхетле буласы Исмәгыйль белән Людмила һәр ата-ана кичерергә тиешле шул зур бәхеттән мәхрүмнәр иде. Бөтен яктан мул булган шушы тормышларында да иң бәхетсез кешеләр иде алар. Үзара яратышалар, тату яшиләр, ләкин аларны тагын да якынайта, тагын да сөйкемлеләндерә, тагын да ныграк бәйләп тора торган уртак җепләре юк. Иркен, мул тормышлы өйләрендә бала тавышы ишетелми... Ләкин кеше бар нәрсәгә дә күнегә, язмышы белән килешергә мәҗбүр була. Бу гаилә дә буйсынды үз язмышына. Бала турында, гомумән, бала-чага турында сөйләшү түгел, хәтта ялгыш та искә алмаска тырыштылар. Хәтта: "Бәлки, бер баланы балалар йортыннан алып тәрбияләргәдер?" дигән уйны да һәр икесе дә үз күңелләрендә аерым-аерым гына йөрттеләр, бер-берсе белән уртаклашырга кыймадылар, бу аларның даими рәвештә сызлап аптыраткан йөрәк яраларына тоз сибү, дип санадылар. Бу мәсьәләдә онытылып яшәргә тырыштылар.

Ә менә Габделбәрнең йөргән кызы, дөресрәге, аның балага узуы турындагы хәбәре

Исмәгыйль күңелендә бала хакындагы бу четерекле, үзләре өчен бик тә йөрәк өзгеч мәсьәләне бөтен ачысы, бөтен барлыгы белән күңелендә яңартып, чираттагы ничәнче мәртәбә исенә төшереп үзәге өзелеп, йөрәге сызлап куйды. Әйтерсең йөрәгенә пычак белән кадап, юк, кадап кына түгел, ә айкап, боргалап алды.

Бу хәбәргә күңелендә туган иң беренче җавап көнләшү хисе иде. "Бар бит дөньяда бәхетле кешеләр!—диде ул, яралы күңелен тынычландырырга теләгәндәй.—Кызык бу тормыш дигән нәмәстә: кайбер кеше бәхетсез килеш бәхетле, кайберләре бәхетле килеш бәхетсез...—Бу очракта Исмәгыйль "кайберләре" дигәндә хатыны белән үзләрен истә тота иде.—Бу егетнең өйләнешеп яши башлар өчен безнең кухня хәтле бүлмәсе дә юк, ә өйләнмәс борын балалы булырга торалар! Бала—бәхетнең иң зурысы бит. Ә ул иңенә ишелеп төшәргә торган шул зур бәхетеннән баш тартмакчы, төшерергә кирәк булыр, имеш. Җүләр, тилебәрән орлыгы ашаган нәмәстә..." Тик Исмәгыйль бу уйларын Габделбәргә әйтмәде. Кешегә үз фикерен шундый кискен рәвештә җиткерергә ни хакы бар? Тора-бара үзләре уртак бер карарга килерләр, аңлашырлар. Аларның үз эшләре ич бу.

Тик шулай да, бу турыда атна буе уйланып, дөресрәге, көнләшеп йөри торгач, күңелендә әллә ниткән ымсындырулы, өметле бер нәрсә чагылып киткәндәй булды. Башта әле ул шушы уй-чаткының ни рәвешлерәк икәнен дә чамалый, ачык итеп күз алдына китерә дә алмый торды, чөнки ул уй: "Ә бәлки..." рәвешендә, бары тик менә шушы ике сүз калыбына сыеп кына, анда да яшен яшьнәгәндәй бик тиз генә ялтырап китте. Ә шушы ике сүз артында нинди уй-фикер ята, әле ул монысын үзе дә ачыклап җиткермәгән иде шикелле. Әллә инде күңелендә ачыклап куйса да, аның бөтен мәгънәсен, бөтен тирәнлеген үз-үзеннән дә яшереп маташуымы? Ничек кенә булмасын, "Ә бәлки..." дигән бу ике сүз аның күңелен торган саен ачыграк били барды, хәтта ул бераздан нindider бер өмет рәвешенә кереп, баш миенең күзәнәкләренә үк урнашты. "Ә нигә тора-бара күзгә күренергә торган баланы харап итәргә?!—дип фикер йөртте ул.—Медицина беренче баланы төшерергә дә кушмый бугай бит әле. Аннан соң хатын-кызның кайберсе бала табарга сәләтсез булып кала, диләр. Болай эшләгәндә, бу яктан да куркыныч нәмәстә юк. Алар яшьләр, әллә ничә бәбиләре булыр..."

Инде Исмәгыйльнең "болай эшләгәндә" дигән сүзләре артында авыр уйлану, фикер каршылыкларыннан соң күңелендә туган, барлыкка килгән нindider төгәл ачыклык ята шикелле иде. Өмет рәвешенә кергән ачыклык иде бу. Ләкин ул кинәт кенә юкка чыккалады, кинәт-кинәт күңелен: "Бәлки, кызының балага узуы дөрес тә түгелдер әле?!"—дигән шик биләп алгалады. Ачыкларга кирәк иде дә, тик бу араларда Габделбәр дә сүз кузгатмый, үзе һаман балтасы суга төшкән кешедәй йөрүен дәвам итә. Әллә нәрсә булды егеткә: шатланып-очынып йөрисе урынга, көн саен үз-үзенә бикләнә бара, бөтенләй аз сүзләнде, үзең сүз башламасаң, көннәр буе авызын ачып берни әйтмәс. Исмәгыйль аның бу халәтен фатир мәсьәләсендә уйга батуыдыр дип юрады. Чыннан да, уйланырлык бит хәзерге хәле: өйләнергә кирәк, ә фатир юк!.. "Әгәр дә мәгәр бу эш мин уйлаганча барып чыкса, аларга фатир мәсьәләсен чишәргә ярдәм итәр идем,—дип уйлый Исмәгыйль.—Хәтта җиң сызганып ярдәм итәр идем. Акчасыннан да тормыйм! Тик минемчә генә барып чыксын..." Тик уен тормышка ашырырга керешкәнче, кызыйның балага узу-узмавын ачыкларга кирәк иде.

Шуңа күрә, көннәрдән бер көнне ул бу турыда үзе сүз башлады. Боровое Матюшинодагы дачасыннан кайтып килешләре иде. Юл шактый озын, көн кояшлы, матур, кәефе дә яхшы иде—әле кичә генә Молдова вәкиле белән фирма кибетләренә шактый гына җүн бәягә берничә тонна йөзем китертү турында килешү төзеделәр. Ә ул исә шактый зур керем вәгъдә итә иде.

—Йә, мәхәббәт фронтында хәлләр ничек, Габделбәр?—диде ул шаярулы тон белән.—Малай: "Эти!" дип тибенмиме соң әле? Әллә кызың алдаган гынамы? Кайчак алар, кияүгә чыгасылары килеп, әллә ниткән нәмәстәкәйләр уйлап чыгарырга да мөмкин!

Егетнең бу темага бер дә сөйләшәсе килми иде бугай, хуҗасы әйткәннәрне ишетмәгәндәй, бераз дәшмичә генә барды. Тик аннан соң гына чыраен сытып:

—Алдамаган шул... Табиб та раслаган,—дип куйды.—Мәхәббәт фронтындагы хәлләр көннән-көн катлаулана бара әле монда, Исмәгыйль Габдрахманович. Мин иртә әле балага, дим, ә ул шатлыгыннан күбәләктәй очынып йөри, табам, ди. Әйткәнне

исенә дә аласы килми. Тавыш-гаугa, кыскасы, сугыш кырындагы шикелле—туплар шартлый...—Габделбәр нииндидер ачыну белән кулын селтәде.—Бер караганда, шатлык та кебек, икенче яктан—вакыты ул түгел...

Шактый гына сөйләшмичә бардылар: икесе дә үз уйларына чумган иде. Габделбәр Фатыймасы белән кичәге очрашуларын исенә төшерде. Араларында күңелсез сөйләшү булып алды.

Ул килеп керүгә Фатыймасы, лотерея билетына ярты дөньяны откан кешедәй, йөгереп килде дә аның күкрәгенә башын куеп:

—Малаебыз булачак безнең, Габделбәр! Доктор әйтте!—диде. Күзләрендә шатлык нурлары балкый. Шушы хәбәрне раслап куйганнан соң гына исенә килгәндәй, сүзен дәвам итте.—Нишләп атна буе күренмәдең?! Исәнме! Исәнләшергә дә онытып торам...

—Котлыйм, Фатыйма. Димәк, дөрес булып чыкты?

—Нишләп күренмәдең, Габделбәр?—дип кабатлап сорады Фатыйма.—Әллә нәрсәләр уйлап бетердем... Әллә бала турындагы сүздән курыктымы икән, мин әйтәм...

—Бигрәк инде син... Нишләп куркыйм ди мин ул хәбәрдән? Гаҗәп, күпме йөреп тә мине һаман аңлап бетерә алмадыңмы әле?!—диде егет, үпкәләгән сыман иреннәрен турсайтып.—Их син!.. Вакыт булмады, шуңа килә алмадым. Мин шат, бик шат, Фатыйма. Тик менә нәрсә...

—Нәрсә?—дип бүлдерде аны Фатыйма, кинәт аның тавышында ниндидер икеләнү сиземләп.—Берәр нәрсә булмагандыр бит?

—Юк, юк, берни булмады, борчылма,—диде егет, аны тынычландырырга ашыгып.—Барысы да әйбәт, яхшы...—Габделбәр әйтәсе килгән фикерен ничек йомшаграк итеп җиткерергә дип уйланып, туктап калды.—Бала булдыру иртәрәк түгел микән, дип әйтмәкче идем...

—Моны ничек аңларга, Габделбәр?!—дип гаҗәпләнде Фатыйма, аның кочагыннан чыгып.—Син, булачак әти кеше, фикереңне ачык итеп әйтә аласыңмы? Ә?

—Беренчедән, Фатыйма, әлегә син—ана, мин әти кеше булмаган. Чокырны сикереп чыкмас борын "һоп" дияргә ашыкма! Икенчедән, мин бик ачык һәм аңлаешлы итеп әйттем: яшәр урыныбыз да юк килеш бала булдыру иртәрәк әле!—Ул, Фатыйманың гаҗәпләнүдән түгәрәкләнеп, зур булып ачылган күзләрен, балавыз сыгарга җыенган иреннәрен күреп, өстәп куярга ашыкты.—Аңла, Фатыйма, бу сүзләрне әйтү җиңел түгел. Синең турында кайгыртып кына әйтүем...—Габделбәр, бу сүзләренең ничек тәэсир итүен чамаларга теләп бугай, Фатыйманың күзләренә карады, аннары аның ике кулын да күкрәгенә кысты.—Беренчедән, балага узуыңны сизсәләр, әти-әниең күзеңне дә ачырмас... Туган-тумачаларың тагын... Авылдашларың... Икенчедән, синең турында кайгыртуым бу, Фатыйма: бала табам дип саулыгыңны какшатуың бар... Өлгерербез... тормыш башлана гына ич әле...

—"Беренчедән", "икенчедән", "икенчедән", "беренчедән",—дип кабатлады Фатыйма, аны үчекләп һәм кулларын аның кулларыннан тартып алды.—Кайтыртуың өчен рәхмәт инде. Димәк, баланы төшерергә кушасың? Дөрес аңладыммы мин сине?

—Нишләп... нишләп шулай тупас итеп сөйләшәсең син, Фатыйма? Мин сиңа берни дә кушмыйм... Киңәшәбез генә ич без,—диде Габделбәр, уңайсызлана төшеп.—Киңәш тотабыз... Синнән.... бездән кеше көләрлек булмасын... Бары шул гына.

—Шундый акыллы киңәшең өчен зур рәхмәт сиңа,—дип кыз кырт кына борылды да караватына барып капланды һәм сулкылдап елап җибәрде.—Мин сине бөтен җаным белән яратып... үз күреп... Ә син мине яратмыйсың икән... Болай, үзеңнекен алырга гына йөрисең икән...

Габделбәрнең Фатыймасы белән булган сөйләшүе шулай күңелсез тәмамланды. Ул аны хәзер яңадан күңеленнән кабат кичереп алды да, кәефе тагын төште. "Ике ел ярым йөреп бервакытта да сүзгә килгәнебез юк иде, бала мәсьәләсе калкып чыгуга, әйтерсең арабыздан кара мәче узып китте,—дип уйлады ул эченнән.—Тизрәк бүлмәфәлән табарга да, өйләнергә кирәк! Ямьсез хәбәрләр тарала башлаганчы бергә укмашу хәерле. Чыннан да, нишләп югалтырга ди ул күзгә күренергә торган баланы? Әйткәч тә, Фатыйма гаебе генә түгел бит бу. Үз бәхете белән тусын!"

Ә Исмәгыйльнең исә үз уйлары. Шушы көннәрдә башында туып өлгергән фикерен бу егеткә ничегрәк җиткерү турында уйланып бара. Четерекле мәсьәлә бит, монда бик оста дипломат булу кирәк. Дөрес, әлегә ул уй-ниятләре хакында Людмиласы

белән сөйләшмәгән иде. Чөнки бу Людмиласының авырткан җиренә кагылу, ярасына тоз салу булачак... Шуңа күрә хатынының йөрәк ярасына аны төзәтерлек, һич тә булмаса ниндидер шифасы булырлык, җиңеллек китерерлек итеп кагылырга кирәк. Мәсьәлә уңай чишелеш ягына таба борылмыйча торып, аның белән бу турыда сөйләшү мөмкин түгел. Кирәк тә түгел!

Башта Габделбәрне күндерергә кирәк. Ә Фатыймасы белән ул, бары тик ул гына сөйләшергә тиеш. Кызның авырга узуы расланган. Монысы бик яхшы. Габделбәр аның бала табарга җыенуына каршы. Монысы да бик яхшы. Каршы булмас иде—торыр җирләре юк. Монысы үтә дә яхшы. Бәлки, үз уен тормышка ашыру юлында нәкъ менә монысы хәлиткеч нәмәстәкәйдер. Сөйгәнең белән бер түбә астында яшәр өчен кайбер югалту-корбаннарга бармыйча булдыра алмаслар...

Ләкин сөйләшүне ничегрәк башлап җибәрергә соң? Шик-шөбһә тудырмыйча гына, шушы юлның бердәнбер икәнен ничегрәк төшендерергә?

—Аңлыйм мин сине, Габделбәр, яхшы аңлыйм,—дип башлады ул сүзен, үз-үзе белән сөйләшкәндәй әкрен генә.—Өйләнешеп, бер-берең белән сөешеп туймыйча яшәр урыныгыз да юк. Ә монда, җитмәсә, бала мәсьәләсе килеп чыкты. Шактый четерекле синең хәл. Җитмәсә, тиз генә өйләнешмәсәгез, кызың турында яман сүзләр дә таралып өлгерергә мөмкин... Бер теленә кердеме, безнең халык өзми дә, куймый да бит ул! Авыр синең хәл, авыр...—Исмәгыйль әле генә әйткәннәреннең егет күңеленә барып җитүен көткәндәй, беразга тынып калды.—Ярдәм кулы да сузасы килә сиңа...—Ул, үз уйларына чумган кеше сыман, авыр гына көрсенеп алды да тагын сүзсез калды. Бу юлы шактый вакыт сөйләшмичә барды. Әйтерсең, башлаган сүзен дә, янында Габделбәр утыруын да онытты. Сүзен, уйларыннан айнып киткәндәй, бераздан гына дәвам итте.—Тик мөмкинчелек юк... Аннан соң син миндә нибары ярты ел гына эшлисең. Ә кешене белү өчен бер пот тоз ашарга кирәк, дигән безнең бабайлар...

—Мин нәрсә, начар эшлимме, Исмәгыйль Габдрахманович?—дип бүлдерде аны Габделбәр.—Әгәр булыша алсагыз, мин көнен дә, төнен дә...

—Ышанам мин, ышанам. Начар эшлисең дип әйтә алмыйм, молодец, тырышасың. Мөмкинлек юк бит, мөмкинлек. Фатир зур проблема ул хәзер.—Син шуны аңлыйсыңмы соң, егет, дигән шикелле, Исмәгыйль Габделбәргә карап алды. Йөзе караңгы иде.—Ләкин дөньяда хәл итеп булмаган нәмәстәкәй юк. Теләк булганда, әлбәттә...

—"Теләк", "теләк..." дип кабатлады Габделбәр.—Теләк белән генә эш майтарып булса икән, Исмәгыйль Габдрахманович. Дәрт бар, дәрман юк, дигән шикелле, хәзер ул теләк дигән нәрсәдән бигрәк, кыштырдый торганы кирәк. Алдан акча йөри торган замана бит хәзер! Аның белән теләсә нинди теләкне дә тормышка ашырып була.

—Дөрес, замана шундый. Ләкин теләк булмаса, анысы да күктән төшми ич аның...

—Акчасы булуын теләмәгән кеше юктыр дөньяда. Ләкин аңа карап кына керми шул ул. Менә шунысы начар.

—Әлбәттә!—диде Исмәгыйль, тик аңлашылмады: "әлбәттә"се акча теләмәгән кеше юктыр дигәннеме, әллә аңа карап кына керми дигәнне раславы идеме?—Теләк кенә аз, әлбәттә. Ярар, монысы аңлашыла инде аның. Син хәзер бүлмә-фәлән эзләп йөрисеңме соң?

—Берничә җирдә булдым инде. Әй, кыйммәт тә сорыйлар, Исмәгыйль Габдрахманович! Юк кына бүлмәләр дә ат бәясе тора. Әле кайберсенең кешечә яшәрлеге дә юк.

—Шулайдыр, шулайдыр,—дип раслап куйды Исмәгыйль.—Ихтыяҗ зур, шуңа каералар бәяне. Ләкин сезгә вакытлы торак түгел, ә үз куышыгыз кирәк, Габделбәр. Үз куышыгыз!

—Әллә сез минем кыз белән сүз куештыгыз инде?!—дип көлде Габделбәр.—Ул да, үз куышыбыз кирәк, дип колак итен ашый...

—Дөрес әйтә ул. Кеше почмагында яшәгәнче, кечкенә булса да, үз почмагың яхшы,—диде Исмәгыйль һәм эченнән генә сүзне һаман төп мәсьәләгә юнәлтә алмавына үз-үзен ачуланып куйды.—Хатын-кыз гел хаклы ул. Менә син, хәзергә бала кирәкми, әле иртәрәк, дисең, ә кызың хаклы бит. Юк, юк, мин сине дә аңлыйм, син дә хаклы. Ләкин докторлар беренче баланы төшерергә кушмый. Аннан соң бала булмаска мөмкин. Шуңа күрә табарга кирәк аны, табарга! Табалар бит шулай... Яшь-яшь кенә кызлар таба... Аннары калдырып чыгалар...—Исмәгыйль Габделбәргә карап

алды.—Бала җанын да кыймыйлар, үзләре дә сау-сәламәт, тора-бара, әйтик, тормышлары җайланып киткәч, теләгән чакта бала табарга дә сәләтле булып калалар.

—Димәк, хатын да, баласын табып, шунда калдырып чыксын? Шулаймы, Исмәгыйль Габдрахманович?

—Мин, шулай эшлиләр, дидем. Ә менә әлегә син теләмәгән ул балагыз мәсьәләсендә—әгәр дә ул исән-сау булса, әлбәттә!—башкачарак эшләп булыр иде... Шунын хакына сезнең ике бүлмәле фатирга хуҗа булу мөмкинлегегез бар... Хәлегезгә кереп, шушы нәмәстәкәйне башкарып чыгуны үз өстемә ала алам...

—Минем башка менеп җитмәде әле бу нәрсә. Тел төбегезне аңлый алмыйм, ничек фатирлы була алабыз соң без, ә, Исмәгыйль Габдрахманович?

—Моның нәрсәсен аңламыйсың инде?—дип гаҗәпләнгән булды Исмәгыйль.—Фатыйман баланы таба да, безгә, минем хатынга бирә... Аңлашылдымы? Бала тудыру йортында калдырып чыкканчы, ул бала, яхшы, ышанычлы кулга эләгә... Балалар йортында каңгырап йөрми. Әгәр дә мәгәр хатыныңны менә шушы нәмәстәкәйгә күндерә алсаң, бер ай дигәндә ике бүлмәле фатирга керәсез дә утырасыз!..

—Чынмы?—дип бөтен йөзе белән балкыды Габделбәр.—Чынлап та үз куышыбыз булачакмы, Исмәгыйль Габдрахманович?!

—Әйттем бит: хатыныңны шушыңа күндерә алсаң, шушы ай эчендә өйләнешеп, шунда яши башлыйсыз.—Ул бераз тынып калды да һәр сүзенә басым ясап дәвам итте.—Тик туачак бала безнеке булырга тиеш! Бу каләресе аңлашылгандыр.

—Соң... әлбәттә инде,—диде Габделбәр һәм кинәт кенә сагаеп калгандай булды.—Ә ни... хатынны күндереп булырмы икән соң бу эшкә?

—Күндерә алмыйсың икән, күндермисең генә... Анысы синең эш. Мин сиңа фатир мәсьәләсен чишәргә ярдәм итәргә телим. Шуның иң кулай, иң ансат, иң очсыз юлын тәкъдим итәм. Теләмәсәң, ирексезләмим ич мин сине...

—Уйланырга кирәк монда, Исмәгыйль Габдрахманович...

—Уйла, әйдә, уйла! Әгәр шундый гарантия бирә алсагыз—әйтерсең. Шундук сезгә фатир хәстәренә керешәм. Ул минем кесәдә йөрми, аны табасы бар әле...

* * *

Трамвай йөртүченең "Достоевский тукталышы" дигән тавышы Фатыйманы уйларыннан арындырып җибәрде һәм ул ашыга-ашыга вагоннан төште. Тормыш турындагы уйлары да шунда өзелгәндәй булды. Юк, өзелмәгән икән. Соңгы көннәрдә уйлар кочагында яши дияргә була аны. Башына әллә ниткән уйлар килә. Башта күңелен балага узу шатлыгы биләп алды. Белмим, нигә шатлангандыр ул бу хәлгә? Булачак баланың әтисе, сөйгән егете Габделбәр белән әлегә бер түбә астында яшәмиләр ләбаса! Әйе, кияүдә түгел ич әле ул. Шуңа күрә бу хәл нинди шатлык булсын ди, җүләр! Киресенчә, ирсез килеш корсак күтәрү безнең халыкта элек-электән зур гөнаһ саналган, җүнсезлек, оятсызлык билгесе дип йөртелгән. Менә корсагың күз-караш төшәрлек булып түгәрәкләнә башлагач, үзең дә сизәрсең әле моны. Җир ярылса, җир тишегенә керердәй чакларың булыр.

Фатыйманың башына кырыкмаса кырык төрле уй килә. Ул үзе кинәт берничә Фатыймага әйләнеп калды бугай. Шуларның фикерләре төрле: берсе болай дисә, икенчесе алай түгел ди, берсе нәрсәгәдер сөенсә, икенчесе көенә, шуңа сәбәпләр эзли, җанын тырный. Булган шатлыгын да көенечкә әйләндерергә тырыша. "Кыз бала үзенең сафлыгын кияүгә чыкканчы сакларга тиеш!" Бу әби-бабаларыбыздан килгән, татар кызларына балачактан ук сеңдерелә торган борынгы гадәт. Ә "Син аны боздың. Саклый алмадың син... Ашыктың! Мизгелдә йомшаклык күрсәттең..."

Әнә Габделбәр дә үзгәреп китте шикелле. Юк, качып йөрми, алай да сирәгрәк күренә башлады. Әллә шулай тоела гынамы? Хәер, аны да гаепләп булмый—эш кешесе. Алай гына да түгел, кеше кешесе, начальнигы җибәрмичә, шактый соңарган көннәре бар.

Карале, озын гомерле булыр, әнә, үзе дә тулай торак янында басып тора түгелме? Аны көтүедер. Фатыйма чаттан борылуга аңа таба килә башлады. Авызы колагына житкән, сөенечле хәбәре булганга охшый.

—Исәнме, Фатыйма!—дип елмайды ул.

—Сәлам, Габделбәр! Нигә балкыйсың бу хәтле?—диде Фатыйма, күрешеп.—Шатлыгың эченә сыймаган кеше кебек син бүген.

—Мин гел шулай ич, Фатыйма. Бүген генәмени? Нигә кара көеп, кайгырып йөрергә? Муеннан бурычка баткан юк бит әлегә!

Алар сөйләшә-сөйләшә Фатыймалар бүлмәсенә керделәр. Иптәш кызлары өйдә юк: бүген ял көне, кайсы кая таралышып беткәннәр. Фатыйма сумкасыннан әле генә "Колхоз базары"ннан алып кайткан итне, яшелчәләрне суыткычка алып куйды да кухняга чәй куярга чыгып китте.

—Йә, дөньяда ниләр бар, Габделбәр?—дип әйләнеп керде ул бераздан һәм табын әзерләргә кереште.—Эшләп йөрисеңме?

—Дөньяда үзгәрешләр юк, таң ата да кич була,— дип көлде егет.—Эшли-эшли вакыт үткәне сизелми дә. Ә мин һаман буйдак булып йөрим! Кайберәүләр буйдак егеткә ничек авыр икәнен аңларга теләми...

—Аһ, аларны! Шелтә белдерергә кирәк аларга! Аңларлык итеп!—дип көлде Фатыйма.

—Хәзер кешене шелтә белән генә җиңеп буламыни?! Усал заман бит хәзер. Колакларын борырга кирәк, дисәң бер хәл...—Габделбәр кызның колагыннан тотты.—Менә шулай итеп.

—Карале, авырттырасың ич, җүләр. Җибәр!

—Ничек анда, малай үсәме?—дип елмаеп сорады Габделбәр, табын әзерләп маташкан Фатыймасының корсагына башын куярга тырышып.—Беләсеңме, нәрсә... Табарга кирәк булыр аны. Һичшиксез, табарга!..

—Аңламассың сине. Шушы көннәрдә генә, бала иртәрәк әле безгә, дидең, ә бүген киресенчә сөйлисең...

—Мин хәзер дә: "иртәрәк",—дим. Ләкин ни... беренче баланы төшерергә ярамый икән. Бала булмый ди аннары... Димәк, табарга кирәк...—Габделбәр инде иң мөһимен ничек әйтергә соң, дигәндәй,уйланып, туктап калды, тирән генә сулап куйды.—Аннары больницада калдырырга да була... Әгәр теләмәсәк, дим... Ни бит... Шулай эшлиләр бит...

—Ни сөйләвең бу, Габделбәр?!—диде Фатыйма, гаҗәпләнүдән күзләрен түгәрәкләндереп.—Ничек калдырырга?! Нигә калдырырга?! Үз балаңнымы?! Өйләнмәс борын акылдан язасыңмы әллә син?!

—Туктале син, тукта, Фатыйма. Син үзең дә әллә нишләдең соңгы вакытларда. Сүз әйтергә ярамый, кабынырга гына торасың. Башта төшенеп җитәргә кирәк... Тыңларга... Әйтеп бетермәдем бит әле мин...

—Әйткәнең дә җиткән. Артыгы белән аңлашылды. Син мине яратмыйсың икән... Йә, нәрсә әйтмәкче идең тагын?

—Тик ни... аңларга тырыш син мине, Фатыйма! Һәм... бүлдермә... әйтеп бетергәнче...—Габделбәр тирән итеп сулап алды да, күлмәк якасы төймәсен чишеп җибәрде.—Беренчедән, сөймәсәм, яратмасам, мин синең белән йөрмәс идем. Икенчедән, икенчедән яратам мин сине. Өченчедән, минем синең саулыгың турында кайгыртуым. Дүртенчедән, безнең ике бүлмәле үз фатирыбыз булачак, Фатыйма! Ишетәсеңме? Ике бүлмәле! Син әйтмешли, үз куышыбыз булачак безнең, Фатыйма! Тик ни... бала тугач... исән-сау туса, дип әйтүем... аның өчен баланы бирергә кирәк... Төшергәнче шулай яхшырак булыр бит...

—Нәрсә-ә?! Балаңны фатирга алыштырыргамы?! Мондый уй ничек башыңа килде синең, ә? Җирбит! Оятсыз! Моннан соң мин сине ничек кешегә санап йөрергә тиеш ди, ә?! Бар, чыгып кит! Күземә күренәсе булма!—Фатыйма сулкылдап елый башлады.—Иң якын кешемә санап йөрим бит шуны!..

—Туктале, Фатыйма, тукта! Ашыкма, кызма! Син аңлап җиткермәдең, ахры, сүз үз фатирыбыз турында бара ич, җүләр булмасаң... Ике бүлмәле турында! Күктән төшәргә торган бүләк бит бу! Уйлап кара, башка мондый мөмкинлек беркайчан да булмаячак! Үзе кулга керергә торган бәхет...

—Бар, чыгып кит!—дип Фатыйма Габделбәрне ишеккә таба төрткәли үк башлады.—Бәхетең дә кирәкми, үзең дә! Балаңны сатып алган бәхет кирәкми миңа. Бар, башка күземә дә күренәсе булма!

Хәзер сүзне дәвам итәргә тырышу ахмаклык иде, шуңа күрә Габделбәр үзе дә чыгып китү ягын карады. Алай гына да түгел, бу сүзне башлавына да үкенде. Фатыймасының ни әйтерен, бала мәсьәләсендәге фикерен белә иде ич инде югыйсә. Белә торып бит, белә торып...

Чыннан да, нык ялгышты Габделбәр. Югыйсә Фатыймасын борчуга салмыйча, үзе уйлап йөргәнчә генә эшләсә ни була иде? Хуҗа Насретдин шикелле. Ул бер патшаның ишәген укырга өйрәтергә алынган ич, аптырап тормаган. Ун ел эчендә әллә патша, әллә ишәк үлә, дигән. Әлбәттә, алар очрагында эш катлаулырак тора. Хәер, шуннан ни булган? Иң мөһиме—Фатыйма гына сизмәсен, бала үле туды, дигәнгә ышансын. Ә врачлар белән Исмәгыйль Габдрахманович үзе сөйләшер. Акчасы күп, теләсә нинди эшне әйләндереп чыга алырлык. Тик хәзер аңа, бу эшкә хатын риза түгел, дип ничек әйтергә? Туктале, нигә дөресен әйтмәскә ди? Дөресен әйтергә дә планнарына бераз үзгәреш кенә кертергә. Бары шул гына. Хәзерге вакытта максат—тиз генә өйләнеп, үз фатирыңа кереп утыру! Моны Фатыйманың йөкле икәнлеге кеше күзенә чалына башланганчы эшләргә кирәк. Бер караганда, күңелсез сөйләшүдән соң монысы да җиңел булмас әле аның. Килешүе авыр булыр, авыр. Куып ук чыгарды бит. Нишләтәсең, Габделбәр үзе гаепле. Ярар, бераздан тынычланыр әле...

Ә Фатыйманың һич тә килешергә исәбе юк иде. Габделбәр белән булган шушы сөйләшүләреннән соң бу кешегә карата ачуы шул дәрәҗәгә җитте, аны ул сүз белән генә аңлатып та бирә алмый иде. "Ничек мина шундый шакшы тәкъдим ясый алды ул?!—дип нәфрәтләнде Фатыйма, әле һаман елавыннан туктый алмыйча.—Моны иң якын дип йөргән кеше түгел, иң кара эчле дошман да эшләмәс! Адәм актыгы ул моннан соң... Мондый кеше белән яшәгәнче, гомер буе ялгыз яшәвең мең мәртәбә артык! Моннан соң килмәсен дә, йөрмәсен дә! Бетте, ара өзелде!.."

Фатыйманы әллә ниткән үкенечле уйлар биләп алды. Габделбәр белән танышкан көнен каһәрләде, үзенең кызлыгын югалткан көнендәге саксызлыгы, мизгел эчендәге йомшаклыгы, хискә бирелүе өчен үз-үзен иң шакшы сүзләр белән ачуланды.

Ә бит Габделбәре көчләмәде аны, үзе әллә нишләде... Башы әйләнеп киттеме, әллә аның иркәләвеннән, назыннан хушсыз калдымы? Бик тә гади, бик тә көтмәгәндә килеп чыкты бит ул...

Бергә эшли торган иптәш кызы фатирына Яңа елны каршыларга барганнар иде. Габделбәр белән. Матур гына утырдылар. Музыка, бию... Шәрабны да татып кына карады анда Фатыйма, чөнки моның ише нәрсәне кабып та караганы юк иде. Ләкин танцы вакытында, ничек шулай килеп чыккандыр, Габделбәр белән икесе, кунаклардан аерылып, вальс әйләнә-әйләнә, башка бүлмәгә килеп керделәр. Габделбәр шунда аны кысып-кысып кочакларга тотынды, колагына берсеннән-берсе матур, ягымлы сүзләр пышылдады, шашынып-шашынып үпте. Әйтерсең ел буе күрешмәгәннәр. Югыйсә моңарчы да үпкәне дә, кочаклаганы да, хисле, ягымлы сүзләр әйткәне дә бар иде. Ә монда нишләптер аның кочуы да, үбүе дә, сүзләре дә—барысы-барысы да бөтенләй үзгә иде, исерткеч иде. Нindидер сихер көченә ия иде бугай алар. Фатыйма әнә шул минутларда үзен әкият дөньясында, бәхет диңгезендә итеп тойды. Аңа рәхәт иде, ул бәхетле иде... Ул егеткә берниндн каршылык та күрсәтә алмады. Дөресрәге, каршылык күрсәтер халәттә түгел иде...

Аннан соң ул күңеленнән шушы мизгелне, шундагы йомшаклыгын, хисләр ташкынында эрүен үкенеп-үкенеп искә алса да, шул көннән башлап Габделбәре теләгенә беркайчан да каршы килә алмады. Менә хәзер шунын җимешен татый—балага узды. Тик хәзер үкенүдән, ялгыш адымың өчен үзеңне-үзең битәрләүдән, Габделбәрне каһәрләүдән ни файда? Аны гаепләп тә булмый бит. Гаепләргә кирәкми дә—ул, Фатыйма, үзе гаепле ләбаса! Гаепле? Нишләп гаепле булсын ди ул?! Җилдән барлыкка килгән бала түгел, сөйгән кешесенең баласы... Уртак җимешләре...

Сөйгән кеше? Сөйгән кеше шулай эшли диме? Сөйгән кеше үз баласын фатирга алыштырырга да әзер була димени?!

Уйлар, уйлар... Хәзер алар Фатыйманың бөтен барлыгын биләп алды. Нәрсә генә эшләсә дә, кайда гына йөрсә дә, шул уйлар диңгезендә йөзә. Берсеннән-берсе күңелсез бит әле алар! Менә шушы очрашуларына хәтле ничек бәхетле булган икән ул! Ә Фатыйма үзе әнә шул бәхетен сизми, шуның кадерен белмичә яшәгән. Шул бәхетенең кадерен белеп, Габделбәренә: "Ярар, алайса, тизрәк бер почмак тап та шунда яши башларбыз",—дип кенә әйтәсе иде аңа. Аннан соң, тора-бара, җае чыгар, барыбер урамда калмаслар иде. Яши бит әле кешеләр. Әнә, үзләренең тулай торакларындагы кечкенә генә бүлмәләрдә икешәр бала үстереп ятучы гаиләләр бар. Әлбәттә, моның рәхәт тормыш дип әйтерлеге юктыр. Ләкин нишлисең, кая барасың? Аның каруы бергә яшиләр, бер-берсен яратышкач—түзәләр. Аларга да җиңел түгелдер...

Ә син, әле кияүгә дә чыкмаган килеш, Габделбәрең алдына кулдан килмәстәй эшләр кушасың. Үз куышың булу яхшы, имеш! Бу яңалыкмы? Моны Габделбәр үзе белмиме? Ләкин кайдан аласың ди ул куышны? Кем әзерләп куйган ди аны сезгә?! Бетте ул хәзер чират торып фатир алулар! Бетте, юк ул, юк! Ә син "куыш" та "куыш"..." Менә шул куышны эзләп йөреше бит инде Габделбәрнең... Ә син, матур гына, җайлап кына аңлашасы, мәсьәләне уртага салып тыныч кына сөйләшәсе урынга, аны куып ук чыгардың. Кеше түгел, имеш. Җүләрләнүең бу синең, җүләр сатуың. Ярар, куып чыгардың ди. Шуннан нәрсә? Шуннан сиңа ни файда? Аны куып чыгарып фатирлы булдыңмы? Минутлык ачуыңны гына бастың, бары шул гына. Ә ул башка килмәсә, нишлисең, кая барасың? Әлегә ярый, корсагың беленми, ә беленә башласа?! Әйтик, әниең яисә әтиең сизсә, күрсә? Син монда, шәһәргә, рәхәтләнеп зина кылып йөрергә дип килдеңмени, диеп җаныңны ашый башласалар, ни дисең? Яраткан егетемнән ул, без тиздән кавышабыз, дисеңме? Кайда соң ул элек безгә сәламнәр җибәреп торган Габделбәрең, нишләп күренми, дип күзеңә карап сорасалар? Ул чагында икенче көнне үк зинһарлап аборт ясатырга чабачаксың бит! Үзең чабачаксың! Ул чагында, синеңчә фикер йөртсәк, үзеңне дә кеше дип атап булмый ич! Шулай түгелмени? Алайса, нишләп дәшмисең, нишләп башыңны түбән иясең? Ә?

Фатыйманың башында кырыкмаса кырык төрле уй бөтерелә, кырыкмаса кырык төрле фикер сугыша. Хәер, ул хәзер үзе дә ике-өч Фатыймага әйләнде бугай. Һәрберенең үз фикере, үз уе. Аларны тыңлый-тыңлый акылдан шашарсың...

***

Габделбәр, Исмәгыйль Габдрахмановичка хәлнең дөресен сөйләп, мәсьәләне чак кына башкачарак чишәргә туры киләчәге турында үз планын җиткерде. Аның асылы шунда: Фатыйма баланы таба, ләкин аның өчен ул "үле" туа, Исмәгыйль табиблар белән эшне үзе хәл итә, ә шул ук докторлар белән сөйләшеп-килешеп Фатыйма белән бер үк көнне бала тудыру йортына кергән хатыны аннан бала белән кайта. Үз баласы белән.

—Йә, ничек, шулай барамы, Исмәгыйль Габдрахманович?—дип сорады Габделбәр, мәсьәлә чишелешен кыскача гына аңлатып биргәч.—Фатыйма берничә көн кайгырыр, уңайсызланыр, әлбәттә. Ләкин башка юл юк: үлсә үлә, ләкин болай бирми ул аны!..

—Бермә-бер катлауландырдың син бу эшне. Болайга калса, мин аны күптән эшли идем инде. Ике бүлмәле фатир чыгарып салмыйча да,—диде Исмәгыйль, уйга калып.—Докторлар белән сөйләшеп, ташлап калдырылган бирәр баланы алырга була иде. Яисә балалар йортыннан... Тик безгә баланың үз анасы исән булуы шарт, чөнки аны имидән аерганчы үз анасының имезүе кирәк. Менә эш нәмәстәкәйдә... Димәк, без килешмәдек, Габделбәр. Сине фатирлы итмәкче идем, барып чыкмады инде алайса...

Бу сүзләр шоферны өнсез итте, хәтта бер мәлгә күз аллары караңгыланып киткәндәй булды. Сүзсез калды, зиһене таралды. Таралыр да! Үз фатирыбыз була дигәндә, шул якты өметне төбе-тамыры белән йолкып атсыннар әле! Өнсез калырсың да калырсың моңа! Бу айда ук кереп утыра аласыз, дигән иде бит. Ә менә хәзер... Юк, юк, нәрсәдер эшләргә кирәк—фатир дигән татлы кисәк кулдан ычкынып бара лабаса! Мондый мөмкинлек башка беркайчан да булмаячак!..

—Фатыйма үзе имезер, Исмәгыйль Габдрахманович!—дип кычкырды Габделбәр, әле генә башыннан яшен тизлегедәй чәчрәп киткән уен ахыргача үзе дә аңышып бетмичә.—Әйе, үзе имезер! Әнисе бала тапканда үлде, диярләр дә... имезергә аңа бирерләр...—Тик Габделбәр шундук кулын селкеп куйды.—Юк, юк... алай түгел, алай түгел. Әнисенең сөте юк, диярләр... Йә ничек, Исмәгыйль Габдрахманович?

—Мөмкин шикелле дә...

—Ничек кенә әле!—диде Габделбәр, шатлыгыннан балкып.—Больницадан чыккач та барып имезер...

—Белмим инде, белмим... Ләкин кисәтеп куям: ул баланың кемнеке икәнлеге турында бер генә сүз ычкындырсаң да...—Исмәгыйль, ни буласын башына китерергә тырышкандай, туктап калды.—Кемгә булса да тишсәң, дөньяда яшәмисең! Икенче көнне үк, юк, шул ук көнне теге дөньяга олагасың... Юк, үзем бармак белән дә чиертмәм, чөнки тавык суйганда да карап тора алмыйм—кан күрергә ярамый... Ә менә кан яраткан кешесен табармын...

—Сез нәрсә инде, Исмәгыйль Габдрахманович?! Мин ни... теләсә нинди йомышыгызны... Барысы да әйбәт булыр... сөйләшкәнчә...

Килешенде. Инде алда торган бу эш турында шушы көнне кич белән үк Исмәгыйль хатыны Людмила белән дә сөйләшеп алды. Дөресен әйткәндә, бу әңгәмәне башларга курыккан да иде, чөнки аның авырткан ярасына кагылганын белә ич ул. Ләкин, ни гаҗәп, Людмила бала мәсьәләсендәге бу сөйләшүне тыныч кабул итте. Исмәгыйльнең аңлавынча, ул бу турыда үзе дә уйланып йөргән. Шуңа күрә сөйләшүләре кайчандыр башлаган сүзләрен дәвам итү кебегрәк кенә килеп чыкты.

—Кирәк шул безгә бала, бик кирәк!—Людмила, ике кулы белән иренең муенын кочып, иреннәрен аның иреннәренә тидерде.—Сиңа әйтергә кыймыйча гына йөрдем. Болай кимсенеп яшәү бик авыр... Канатсыз кош шикелле...

Исмәгыйль шулай тиз аңлаша алуларына шатланып куйды. Әлбәттә, хатынына барысын да сөйләп-әйтеп бетермәде. Баласы безнеке булачак хатын аннан баш тартырга җыена икән, дип кенә аңлатты. Ә бала өчен ике бүлмәле фатир бирергә вәгъдә итүе турында ләм-мим сүз дә әйтмәде. Гомумән, Исмәгыйль хатын-кызга бик ачылып китмәү ягында иде. “Хатын-кызга үзең кирәк санаганны гына җиткерү хәерле,—дип әйтә торган иде аңа мәрхүм әтисе.—Артык әйтеп ташласаң, аннары ул синең җаныңны ашарга мөмкин...”

Хәзер вәгъдә ителгән фатирны табарга кирәк иде инде. Ул Габделбәргә андый вәгъдә биргәндә элеккеге күршеләре Мәрзия әби фатирын күздә тоткан иде. Ике ай чамасы элек базарда күргән иде, бик бетәшкән, мескен. Күрәсең, Нургата бабай үлгәннән соң яшәве күпкә авырайган. Аннан соң кешене уй белән ялгызлык та бик бетерә бит. Бигрәк тату яшәделәр. Нургата бабай, карт булса да, җир җимертеп йөри иде бит әле. Тиктормас кеше иде, мәрхүм. Мәрзия әбине ипигә дә җибәрми иде... Ә менә хәзер, нишләсен, бар нәрсәгә дә үзенә йөгерергә туры килә. Барлы-юклы саулыгы белән.

Мәрзия әби базарда ите казылыкка юнып алынган сөяккә чират тора иде. Килеп күрешкәч, башта Исмәгыйльне танымыйча торды. Танып алгач, үз туганын очраткан кеше шикелле, сөйләшеп сүзе бетмәде, бөтенләй ачылып китте карчык. Тормышыннан зарлана, яшәве авыр, ди, пенсия акчасы бернигә дә җитми, ди, бик еш авырыйм, ди. Шул чакта Мәрзия әбисе Исмәгыйльгә шулкадәр кызганыч булып тоелды, аңа өч килограмм менә дигән ит сатып алып бирде. Шунда карчыкның күзләреннән яшьләр бәреп чыкты. Людмила турында да сорашты, күп итеп сәлам тапшырырга кушты, кунакка чакырды.

—Менә бүген Исмәгыйльнең Мәрзия әби янына җыенуы, фатир мәсьәләсендә карчыкның кылларын тартып карау иде исәбе. Бәлки ике бүлмәледә каңгырып яшәп ятадыр, бәлки аның үзен карап-тәрбияләп торырга кеше кертергә кирәктер? Ул күп кенә күчтәнәчләр сатып алды. Карчык өйдә иде. Исмәгыйльнең килеп чыгуына бик тә сөенде, нишләтергә, кая утыртырга белмәде.

—Людмиладан сиңа күп сәламнәр, Мәрзия әби,—диде Исмәгыйль, алып килгән күчтәнәчләрен өстәлгә бушата-бушата.—Менә бераз күчтәнәчләр җибәрде әле үзенә...

—Рәхмәт, улым, рәхмәт, миннән дә сәлам җиткерерсең. И-и бу тамаша әйбер җибәрәләрме инде, ә! Расхутланып йөрисез...

—Ниткән расход ди, Мәрзия әби?! Аллага шөкер, икебез дә эшлибез,—диде Исмәгыйль һәм урындыкка утырды да бүлмәгә күз салды.—Йә, ничегрәк яшәп ятасың, Мәрзия әби? Берүзеңә генә күңелсез түгелме?

—Әй, улым, ялгыз кешенең тормышын әйтмә инде син аның,—диде карчык, зәңгәрсу тамырлары бүртеп торган, коры сөяккә калган кулын селтәп.—Картлык—түгел шатлык, димәсләрие аны... Бер көн кыштыр-мыштыр йөргән булсаң, ике-өч көн урын өстендә... Ялгызлык бит читен икән, улым, ялгызлык...—Ул башындагы яулык чите белән авызын каплап, елап җибәрде.—Нургата бабаң исән чакта оҗмахта яшәгәнмен икән...

—Ярар, елама инде, Мәрзия әби. Нишләтәсең инде аны...—диде Исмәгыйль, карчыкны тынычландырырга тырышып.—Бернишләп тә булмый... Тормыш дигән нәмәстәкәй шулай инде ул. Барыбыз да шунда буласы, тик һәркемнең үз вакыты...

—Шулай анысы, улым, шулай. Кем белә, бәлки бүген вакыт җиткәндер. Барысы да Ходай кулында. Үлемнән калган кеше юк...—Карчык яулыгы белән күз яшьләрен

сөртеп алды.—Мөмкин булса, патшалар калырые аннан...

—Хәзер ничә белән барасың син, Мәрзия әби?—дип сорады Исмәгыйль.—Ничә яшь сиңа, дим.

—Күп инде, улым, бик күп. Ходайның биргәненә шөкер, җитмеш алтынчыга китте.

—Сөбханалла, шактый икән шул. Ялгызлыктан котылырга кирәк сиңа, Мәрзия әби. Әле менә шушы көннәрдә генә укыдым, синең кебек өлкән яшьтәге берәү үлеп киткән шулай... Ул да ялгыз булган. Шуның үлгәнен беркем дә белмәгән! Шакшы искә чыдый алмыйча ишеген ватып керсәләр, кортлап беткән ди, мескен...

—Алла сакласын, Алла сакласын! Булыр, улым, булыр. Хәзер һәркемнең үз кайгысы, кешедә кешенең эше юк. Андый көннәргә калдыра күрмәсен инде Ходай!..

—Андый хәлләр адым саен бит хәзер. Дөнья хәлен белеп булмый, мин әйтәм, күршеләр дә белми калыр,—дип дәвам итте Исмәгыйль сүзен.—Үтереп чыгулары да бар. Хәзер кешене чебен урынына да күрмиләр. Әле менә шушы арада гына радиодан сөйләделәр... Бер бабайны үтереп, тураклап бетергәннәр ди. Фатирын алыр өчен ди. Ул да ялгыз яшәгән. Әллә, дим, Мәрзия әби, картлар йортына керәсеңме? Ашаталар-эчертәләр, авырсаң—карыйлар. Кеше арасында җиңелрәк булмасмы, дим.

—Әй, улым, андый көннәргә калдырмасыные инде Ходай. Яхшы җир түгел.

Исмәгыйль эченнән генә борчылып куйды: димәк, карчык анда барырга атлыгып тормый.

—Анда әләгүе дә ансат түгел, Мәрзия әби,—диде ул.—Мин бит элеккеге күрше булганга күрә генә. Тукта, мин әйтәм, ялгыз кеше белән ни булмас... Карале, Мәрзия әби, сораганым юк: бер балагыз да булмадымыни соң сезнең?!

Карчык озак вакыт бер сүз дә дәшмичә торды. Әйтерсең, соравын ишетмәде. Тик бераздан гына тирән итеп көрсенеп куйды, хәтта кулындагы чәе түгелә язды һәм калтыранган тавыш белән:

—Барые, улым, барые безнең бер малаебыз,—диде. Кайчандыр кара булган, ләкин тора-бара инде вакыт төссезләндергән-уңдырган күзләреннән берәр бөртек яшь чыгып, җыерчыклар баскан, бөрешеп беткән ике бите буенча тәгәрәде.—Марҗага өйләнде дә, әтисе, күземә күренмә, дигәч, Чиләбе шәһәренә китеп барганнарые... Нургата бабаң бу якка бик кырысые, мәрхүм. Динебезне, денебезне саттың, дип күзен дә ачырмады шул. Шунда үлеп калды улыбыз. Марҗасы белән дә тынышмадылар... Язмыштыр инде, үзенә кул салган...

—Гафу ит, Мәрзия әби, әллә нәрсәләрне исеңә төшерттердем. Белмәгән идем...

Карчык дәшмәде. Шул малайлары турында уйлый иде бугай. Ә Исмәгыйльнең, килгән-килгән, мәсьәләне ачыклап китәсе килә иде. Барып чыгарлыкмы бу эш, әллә башка вариант эзләргә туры килерме? Әлбәттә, болай очсызга төшәчәк иде.

—Пенсия дигәннәре җитеп барамы соң, Мәрзия әби?—дип сорады ул.

—И-и, улым, кая инде ул?! Хәзер бит аның квартирына да күпме түләргә кирәк! Җитмәсә, газ, ут бәясе дә артып кына тора. Эшләр бөтенләй харап булырые, ярый әле ыльгута дигәннәре бар.

—Ичмаса, яныңа квартирантлар да кертмисең, Мәрзия әби... Картлык көнендә карап торырлар, бераз акчасы да булыр иде шунда,—диде Исмәгыйль, бөтен барлыгы белән аның хәленә керергә тырышкандай.—Акылдан шашарсың монда берүзең!..

—И-и, улы-ы-ым,—дип сузды карчык һәм кулларына күз салды.—Үземнең дә уйлаганым бар бу турыда... Ләкин халык начар бит хәзер, улым. Кеше бер-берен күралмый. Хәтта мал бүлешеп, туганнар белән туганнар суд юлларында йөри... Кертерсең дә... тора-бара үзеңне куып чыгарырлар... җә үтереп ташларлар... Үзең әле генә әйттең бит. Менә аның кай ягы бар, улым... Кеше белән җиңелрәк булырые да...

Әбинең бу сүзләреннән Исмәгыйльгә бераз җан кереп киткәндәй булды. Димәк, карчык болай үзе кеше кертергә каршы түгел.

—Дөрес, Мәрзия әби, замана бозылды, заманасы белән кешесе дә бозылды... Теләсә кемне фатирга кертә торган вакыт түгел.—Ул бераз пауза ясап алды.—Менә нәрсә, Мәрзия әби... әле яңа гына өйләнешкән бер гаиләгә торырга урын кирәк. Бик тәртипле яшьләр, авыл балалары... Егет үзе мине йөртүче шофер. Алар сине соңгы көннәреңә хәтле үз әниләре шикелле карый торган кешеләр...—Исмәгыйльнең үз сүзләрен тагын да көчәйтәсе, ышандырырлык итәсе килде. Шуңа күрә булмаганны да өстәп куйды:—Хәзер синең яшьләр тирәсендәге бер марҗа әби янына күченергә

торалар. Әби фатирын аларга калдырачак икән. Үлгәч... Кичә шуны ишеттем дә, туктале, мондый яхшы кешеләр Мәрзия әби янына керсәләр әйбәтрәк булмас микән, дип уйлап куйдым... Беркөн базарда күргәч, җәлләп куйдым үзенне...

—Шулай дисеңме?—диде карчык, ничектер җанлана төшеп.—Белгән, яхшы бәндәләр булса, анысы ни инде... Минем фатир да калырые аларга... Тик әнә шул фатир өчен генә йөри торганнардан түгел микән соң алар, улым? Миңа җылы карарлар микән, дим...

—Бу турыда үзем килгәләп-белешкәләп торырмын. Әгәр дә мәгәр алар тарафыннан сиңа бер генә яман нәмәстәкәй сизелә икән, үзем пыр туздырып куып чыгарачакмын мин аларны, Мәрзия әби! Әйткән иде диярсең!

Исмәгыйльнең бу сүзләре карчык күңеленә хуш килде бугай, ул тешсез авызын кулы белән каплап, күңелле генә итеп кеткелдәп алды.

—Шулай дисеңме, улым? Ышанычлы бәндәләр дисеңме?

—Мин сине алдыйммы инде, Мәрзия әби?! Әйтеп торам бит: менә дигән кешеләр! Алып килермен мин сиңа аларны, бер күрүдә үк күңелгә ятышлы яшьләр.

—Ярар, улым, ашыгыч эш түгел, мин бераз уйланыйм әле бу турыда. Берәр атнадан килеп чыгарсың, шунда сөйләшербез калганын...

Атна дигәне сизелмичә үтеп тә китте. Карчык яшьләрнең үзенә күченеп килүләренә ризалыгын бирде. Карчыкка Габделбәр белән Фатыйманы алып килеп күрсәтергә, таныштырырга да вакыт җитте. Башта, әлбәттә, бу турыда Габделбәргә әйтергә кирәк иде. Беренче очракта, аның фатир мәсьәләсе чишелде дигән сүз бит бу.

—Иң беренче бурычыгыз—карчыкны карау!—диде Исмәгыйль аңа.—Үз әниегез шикеле итеп! Йомшак мөгамәлә, җылы сүз, вакытында ашарына-эчәренә дигәндәй... Шунсыз фатир сезгә калмаячак. Әгәр дә мәгәр аннан бер генә зарлану сүзе ишетелә икән,—белегез аны!—шул ук көнне үзем куып чыгарам! Һәм тиешле акчасын да вакытында биреп барасыз. Боларны хатыныңа да сеңдереп куй! Аннан соң тагын менә нәрсә...—Исмәгыйль әйтәсе фикерен ачыклап бетерергә теләгәндәй, бераз тынып калды.—Хатыныңның корсаклы икәнен баштарак сиздермәскә тырышыгыз... Кире уйлап куюы бар... Аннары анысы, пропискага кергәч...

—Барысы да аңлашылды. Бик зур рәхмәт инде сезгә, Исмәгыйль Габдрахманович. Ләкин ни... Фатыйма белән ара бозылган бит әле...

—Сезнең араның ничеклеге кызыксындырмый мине. Анысы синең проблема. Мин хәзер бер генә нәрсәне беләм: бала безнеке булырга тиеш! Сөйләшенгәнчә, килешенгәнчә. Бу турыда башка сөйләшәсем дә килми. Ә арагызны бүген үк җайлагыз да, карчык янына кереп утырырга әзерләнегез!

—Тырышам инде мин, тырышам,—диде Габделбәр.—Мине куып чыгарганнан соң ике мәртәбә бардым инде янына, тик ни... һаман ачылып китәсе килми...

—Ачылыр. Ачылмыйча кая барсын ул хәзер?! Тик син балагыз булачагына сөенеп йөргән бул. Ышансын, тынычлансын... Бу фатирны үзем таптым, диген...

***

Вакыт уза, кием туза, дигәндәй, көннәр, атналар үтә торды. Инде менә Габделбәр белән Фатыйманың өйләнешеп яши башлауларына да ай чамасы булды. Туйны Габделбәр авылында үткәрделәр. Әлләни зурлап булмаса да, матур, мул итеп. Кавышуларына икесе дә чиксез шатлар. Иң мөһиме—яшәр урыннары бар, киләчәктә фатир бөтенләй үзләренә калачак! Мәрзия әбине бик хөрмәтләп-зурлап торалар, дөресен генә әйткәндә, аңа хәзер яшәве күпкә җиңеләйде: кибетләргә дә, базарга да, даруханәгә дә йөргәне юк—кирәк нәрсәне Габделбәр, йә Фатыйма алып кайта. Ашау-эчү бергә дигәндәй, Мәрзия әбине хәзер аларның әниләре дияргә була. Кыскасы, чөкердәшеп, бер гаиләдәй яшиләр!

Юк вакытын бар итеп, карчык янына Исмәгыйль дә кагылгалап тора. Килеп чыккан вакытларында яшьләр белән ничек яшәве турында кызыксынмый калмый.

—Йә, Мәрзия әби, хәлләр ничек? Квартирантларың турында нинди зарларың бар?—дип сорады ул менә бүген килеп чыккач та.—Кыерсытмыйлармы? Авыр сүз әйткәннәре юкмы?

—И-и, улым, аларны квартирант диярга дә тел әйләнми,—диде авызы колагына җитәрлек итеп елмайган карчык.—Үз балаларым шикелле алар... Кайберәүләр үз балаларыннан да күрми мондый яхшылыкны!

—Син яшермә, Мәрзия әби, андый-мондый берәр нәрсә килеп чыкса, турысын әйт! Мин аларның эзен тиз суытырмын!..

—Юк, юк, улым, берсе хакында да кыек сүз әйтә алмыйм. Бер симия шикелле яшибез, Аллага шөкер! Авыл балалары бит, тәртипле булып үскәннәр. Эш сөеп. Кулыма бер эш тә тими хәзер. Күз тимәсен, бик пар килгәннәр...—Шунда карчык, гәрчә бүлмәдә икесе генә булсалар да, кеше-кара ишетмиме дигәндәй, як-ягына каранып алды да тавышын әкеренәйтә төште.—Тагын берничә айдан дүртәү булырга торабыз бит әле, Исмәгыйль улым!—Ул моны ниндидер күңел күтәренкелеге, сөенеч белән әйтте ки, гүя әби үзе бәбиләргә җыена иде.—Фатыймабыз йөкле! Кичә үзе әйтте... сөенә балакай!

—Баланы әйтәм, Мәрзия әби... Ул дөньяга килгәч, тынычлыгыңны бозмасмы икән соң? Бала тавышы, елавы...

—И-и, улым, бала комачаулыймы инде?!—диде карчык, елмаеп.—Бала өйгә бәхет алып килә ул. Бәхете белән туа!

—Шулай анысы...—диде Исмәгыйль, бер яктан, сөенеп, икенче яктан, көенеп. Сөенече шул: Мәрзия әби яшьләрне куып чыгармаячак. Көенече шул: бу сөйләшү, үзләренең балалары булмавын хәтерләтеп, йөрәген әллә кайдан, тирәннән чеметтереп алды.

Хәзер Габделбәр дә бөтенләй икенче кешегә әйләнде: шат, очынып йөри, сөйгән кешесе—хатыны да янында. Монысы бигрәк тә яхшы, чөнки теге чакта бозылып киткән араларын яңадан җайлавы бер дә җиңел булмады. Ничәмә-ничә тапкыр килсә дә, Фатыймасының сүзе бер булды: “Күрәсем дә килми—мин яратып йөргән кешем булып чыкмадың”. Тәмам үзәкне өзде шул сүзләре белән. Ярый әле, узган эшкә салават дигәндәй, тора-бара барысы да җайланды тагын... Ниһаять, алар бергә! Аллага шөкер, торыр урыннары да бар, бәхетләренә, әби-карчык та бик күркәм кеше булып чыкты. Фатыйманың йөклелеге турында да беркем белми калды. Гомумән, барысы да яхшы. Җан биргәнгә җүн бирә, дигәннәре дөрес икән бит!

“Исмәгыйль Габрахмановичка рәхмәт,—диде үз-үзенә әбинең янган үтүген рәтләп маташкан Габделбәр.—Ул ярдәм кулын сузмаган булса, һаман да шул уртак торак почмакларында иза чигеп ятар идек...”

Бүген ял көне. Фатыймасы, әнә, нидер тегеп утыра. Аның җенләнгән нәрсәсе инде ул тегү-чигү дигәннәре. Хәер, тагын челтәр бәйләү дигәне дә бар ич әле. Кара, әби мендәрләре өстенә ябарга дип әле шушы көннәрдә генә нинди матур челтәр бәйләп бетерде!

Габделбәр хатыны белән карчыкның якын итеп, бер-беренә “кызым”, “әби” дип сөйләшүләрен тыңлап утырырга ярата. Күңеленә ниндидер җылылык иңә. “Әтерсең, бер гаилә әгъзалары”,—дигән уй туа, җаны рәхәтләнеп китә. Тормыш ваклыклары онытылгандай була.

—Син нәрсә тегеп утырасың анда?—дип сорады Габделбәр тегү машинасы янында мәш килгән Фатыймасыннан.—Эшеңдәгесе генә туйдырмадымы әле сине?!

—Фабрикада тегү—бер нәрсә, ә өйдә—бөтенләй икенче,—диде Фатыйма, башын күтәреп.—Йә, әйтеп кара әле: нәрсә тегеп ятам мин?—Ул бөтен йөзе белән балкып-елмаеп куйды.—Үлсәң дә белә алмыйсың!

—Әбигә берәр нәрсә тегеп утырасыңдыр әле. Шулаймы?

—Юк, белмәдең! Белмәдең!—Фатыйманың күзләрендә ниндидер хәйләкәр очкыннар уйнады, үсмер кыз дип белерсең.—Йә, тагын әйтеп кара! Үлсәң дә белмисең!

—Белмим шул...

—Их, син! Малаебызга күлмәкләр тегәм мин! Шуны да белмисең!..

—Нәрсә?!—дип корт чаккандай сискәнеп китте Габделбәр һәм гаҗәпләнеп хатынына карады. Әле генә ишеткәне шундый көтелмәгән хәбәр иде, хәтта кулындагы үтүге идәнгә төшеп китте. Хәтерләми дә калды: әллә ул аны үзе тотып аттымы? Шунысын гына белә, бөтен тәне бизгәк тоткандай калтыранып китте, шул ук мизгелдә кемдер хәнҗәрен сабына кадәр йөрәгенә батырган шикелле тоелды. Йөрәге башта сулкылдап алды, аннары ничектер тартышып куйды, аннары, үлем ачысы белән көрәшкәндәй, күкрәк читлегеннән чыгарга теләгән сыман, әле моңарчы беркайчан да булмаган тизлек белән шашынып-шашынып тибәргә кереште. Хәтта маңгаена тир бәреп чыкты.—Нәрсә дидең, Фатыйма?!

—Ни булды сиңа Габделбәр?!—диде хатыны, аннан да күбрәк гаҗәпләнеп.—Нигә калтыранасың?

Габделбәр шактый вакытка сүзсез калды. Күңеле айкалган-чайкалган иде. Бала турында әнә шулай көтмәгәндә искәргәне, хәтеренә төшергәне өчен шушы мизгелдә ул аны өзгәләп ташларга әзер иде. Ләкин моны эшләргә ярамый, ярамый гына да түгел, ачуы килгәнне дә сиздермәскә кирәк! Телне тешләп булса да түзәргә кирәк!

—Берни булмады,—диде, ниһаять, Габделбәр, әле яңа гына аңына килгәндәй. Алай да ачуын баса алмаган иде әле.—Утырасың шунда, шашкан кеше шикелле... Эрләмәгән-сукмаган, Гали, менә сиңа ыштанлык, дигән ди берәү... Әле күзгә күренмәгән бала белән баш катырасың...

—Нишләп алай дисең инде, Габделбә-ә-әр?—Фатыйма, үпкәләвен белдереп, иреннәрен турсайтты.—Әлегә күзгә күренмәгән икән, күренмәс дигән сүз түгел. Вакыт житкәч күренер, Алла боерса...

—Күренсә, икенче эш... Шул вакытта да тегеп була ич аны...—диде Габделбәр. Аннары ачуы килүен сиздерүеннән үзе дә уңайсызланып, Фатыймасына юктан гына кычкыруын аңлап, бу хәлне йомшартырга кирәк тапты.—Күзеңне бетереп утырма, диюем... Хәзер кибетләрдә бала киеме буа буарлык! Тусын гына, мин аңа кочагы белән алып кайтам!

Аның бу сүзләреннән соң Фатыйма тынычлана төште.

—Ә минем үзем теккәнне кидерәсем килә,—дип елмайды ул.—Мин сиңа комачауламыйммдыр ич?

—Ярар, ярар, тек, алайса, тек,—диде Габделбәр.—Мин бит болай гына... күзең дип кенә...

Шөкер, кисәктән генә кабынган ялкын тиз сүнде, дөрләп китә алмады. Ә бит бераз түземлелек күрсәтмәсә, шактый ук дөрләп китүе дә мөмкин иде. Чөнки ул бала турындагы күңелсез уйлар хатынының корсагы зурая барган саен болай да тынгылык бирми инде аңа. Бу турыда уйламаска да тырыша, ләкин—нишләтәсең аны!—уйланыла шул. Ирексездән уйланыла. Күңелендә әллә ниткән үкенечле уйлар уята-уята аптыратып бетерә. Шул чакларда Габделбәрнең бәгыре телгәләнеп-телгәләнеп китә, аны үтмәс пычак белән сызып җибәрәләр шикелле тоела.

Беренче карашка менә хәзер тормышлары да җайга салынды, торыр җирләре дә бар—кеше почмакларында иза чигеп йөрмиләр, сөйгәне дә янында, ә җан тынычлыгы барыбер юк. Юк җан тынычлыгы! Дөрес, Фатыймасы тыныч, бәхетле. Аның иң зур бәхете—туачак баласы, юк, туачак балалары. Аларның уртак балалары! Шуңа күрә ул якты өмет белән яши, аны һәр яңа туган көн сөендерә, чөнки һәр туган яңа көн балаларының дөньяга килү бәхетен якынайта ич! Тормышлары ямьле, тигез, ә бала аны тагын да бизәп җибәрәчәк. Моңа ничек шатланмыйсың!..

Баксаң, билгесезлек тә бәхет чыганагы була ала икән, чөнки ул һәр кешедә яшәп килә, яши һәм яшәячәк! Өметне сүндермичә саклап килә ул. Кешедә өмет сүндеме, ул кеше булудан, яшәүдән туктый. Шуңа күрә дә Ходай кешегә бик зур байлык—Өмет бүләк иткән дә. Өмет яшәтә кешене, өмет! Фатыйма да зур Өмет кочагында яши һәм ул—бәхетле... Ул дөреслекне белми...

Ә Габделбәр? Нишләтәсең, менә аның хәзерге тормышында, Фатыймасыннан аермалы буларак, кешене өмет белән яшәтә торган билгесезлек дигән нәрсә юкка чыкты. Ул билгесезлекне һәм шуның белән бергә өметен дә Исмәгыйль белән булган фатир турындагы үзара килешү алып ташлады. Хәзер Габделбәрнең өмете юк—ул булачак балаларының язмышын белеп тора. Белеп тә, шуны иң якын кешесеннән яшерергә мәҗбүр. Нәрсә хакына, ни өчен? Үзләренең гаилә тынычлыгы, бергә яшәү мөмкинлеге хакына. Бу җавапның, бу мәкернең асылына төшенеп уйлансаң, бик тә кызык, хәтта кеше гакылына сыймастай нәрсә килеп чыга: киләчәктә хатыны белән бергә-бергә тигез, бәхетле яшәүләре өчен бала мәсьәләсендә бәхетсез булырга тиешләр!.. Моннан да коточкыч, мәгънәсез җавапның, җавапның гына түгел, ә чынбарлыкның булуы мөмкинме?! Юктыр, мөгаен, юктыр. Җан газабы тудырырлык сәбәп түгелмени бу? Әлбәттә! Ә менә шул чынбарлыкны алдан ук белеп тору Габделбәр өчен икеләтә газап...

Үзеннән дә яшерергә, бөтен барлыгы белән исенә төшермәскә, онытырга тырышкан җан газабы ул аның...

Ә монда—күлмәкләр... Аларныкы булмаячак балага... Ничек түзмәк кирәк бу

газапка?!. Габделбәрнең җаны айкалып китте, бу турыда берни дә белмичә яшәгән Фатыймасын кызганып үзәге өзелеп куйды, аның алдында үзен бик гаепле, хәтта зур җинаятьче итеп сизде. Аның алдына егылып, башын идәнгә бәрә-бәрә, үзенең күңелендә йөрткән шушы газабын иркенләп, тамчысына кадәр тышка чыгарып бетерерлек итеп елый-елый гафу үтенәсе, чәчләрен үбә-үбә, битләреннән сөя-сөя эчен бушатасы килде. Ләкин ярамый бит! Ярамый! Үз бәхетләре хакына ярамый!..

***

И-и, бу тормыш... Дөньяда аннан да катлаулы, аннан да аңлаешсыз нәрсә бармы икән?..

И-и, бу өмет... Дөньяда аннан да татлы, аннан да алдагыч нәрсә бармы икән?..

И-и, кеше... Киләчәк тормышыңдагы хәлләрне алдан белеп торсаң, син, мөгаен, дөньяда яши алмас идең... Акылыңнан шашар идең син! Һәм дөнья тоташ җүләрләр җыенына әйләнер иде...

***

Барысы да килешенгәнчә килеп чыкты. Элеккеге вакытта, тырыша-тырмаша социализмның соңгы фазасын төзеп маташканда, бу хәл коточкыч вакыйга, юк, коточкыч җинаять саналыр иде.

Ә хәзер... Хәзер илдә—дөресрәге, аның җимерелгәннән калган бер өлешендә—максатлар да, юнәлеш тә башка, кыйбла да бөтенләй икенче якта. Ил коммунизм түгел, капитализм төзеп маташа... Бөтенесен ватып-җимереп, әхлак вә намусны "демократия"нең пычрак итеге белән таптый-таптый, "кеше кешегә дус һәм туган" дигән гыйбарәне тырыша-тырыша сөртеп, аның урынына пычрак, начар исле кара буяу белән шушы аңлашылмас һәм бозык заман рухына туры килергә тиешлесен—"Кеше—кешегә бүре" дигәнен яза-яза, пычрак гамәлләр, явызлыклар, миһербансызлык белән шуны раслый-раслый, төзеп маташа. Илне талауның Бөек чоры, бары тик бездә—Россиядә генә булырга мөмкин Кешелексезлек, Зур Тәртипсезлек чоры, һәр кыңгыр эшнең башында алдан Акча йөри торган заман иде бу...

Монда да нәкъ алдан планлаштырылганча килеп чыкты. Бала тудыру йортына кергән Фатыйма "үле" ир бала тапты. Бала тудыру йортына шул ук көнне кереп аерым палатада "саклау" өчен яткан, бала табарга сәләтсез булган Людмила ир бала "тапты".

Исмәгыйль белән Габделбәрнең үзара килешүләре буенча ул баланы балалар тудыру йортыннан чыккач та имчәктән аерганчы, килеп-китеп, шул ук Фатыйма имезергә тиеш иде. Ләкин монысы кемнедер шикләндерде бугай, бер дә бер көнне, инде бер ай чамасы имезгәч, Людмила Фатыймага:

—Сезгә башка бала имезергә килеп йөрергә кирәкми. Монда күршедә яшәүче хатын имезәчәк,—диде.—Бик зур рәхмәт сиңа, Фатыйма.

Нишлисең? Килеште. Әлбәттә, ул бу балага бик тартылган, тәмам ияләнеп өлгергән иде. Ул аңа, баласының, чыннан да, үле тууына ышанган Фатыймага, бу авыр югалтуын онытырга булышкан иде. Чынында үз баласы икәнен белмичә үз иткән иде аны яшь хатын. Менә хәзер аның сабыйны имезеп йөрүе әллә Людмиланы, әллә Исмәгыйльне шикләндереп куйды...

***

Тирә-якта тормыш кайный: урамнар ыгы-зыгы килүче кеше һәм машиналар белән тулы, дөбер-шатыр килеп, дугаларыннан ут көлтәләре чәчә-чәчә трамвай, троллейбуслар уза, күктә, артларыннан озын ак юллар сызып реактив самолетлар оча... Кемдер туа, кемдер үлә... Кемнәрдәдер—туй, кемнәрдәдер—матәм мәҗлесе... Кайдадыр шатланалар, кайдадыр елыйлар...

Ишек-тәрәзәләре тимер рәшәткәләр белән уратып алынган менә бу йортта да кайный тормыш дигәннәре. Ләкин мондагы тормыш бөтенләй үзгә, йортны әйләндереп алган биек, чәнечкеле тимерчыбыклы койма тышындагысына бөтенләй охшамаган... Хәер, анда яшәүчеләрне койма ягындагы ул тормыш кызыксындырмый да бугай. Алар, гәрчә инде күптән бала-чага булмасалар да, һаман балалар булып кала бирәләр... Хәтта сакал-мыеклы килеш тә... Беренче карашка алар да безнең шикелле үк кешеләр сыман. Ләкин алай түгел шул: акылга сай алар, акылга! Ходай аларны дөньяга акыллы итеп тудырган, тик тормыш дигән катлаулы һәм аңлаешсыз

машина моның белән килешмичә, аларны үзенең тупас тәгәрмәч-шестерня, аларны тоташтыручы чылбыр вә каешлары арасында бөтерә-бөтерә, әвәли-әвәли гакылларыннан мәхрүм иткән... Хәер, үзләренчә, алар да бәхетле: кайсы үзен—Ленин, кайсы—Сталин, кайсы Наполеон дип йөртә, үзләре шикелле үк җүләр иптәшләре белән шулар булып, өстән торып сөйләшә...

Ә менә караваты янында авызыннан селәгәйләрен, борыннарыннан маңкасын агыза-агыза машина тавышы чыгарып кечкенә үзбушаткыч машина белән уйнаучы, күрер күзгә егерме биш-егерме алты яшьләр тирәсендәге кара тутлы, йөзен сакалмыек баскан бу ир-атның гаме исә бөтенләй башкада.

—Минем малаемның машинасы бу!—ди ул үзе янына җыелышып карап торган җүләр иптәшләренә.—Ул менә шушындый зу-ур машинада эшли...

—Яхшы машина! Зур машина!—дип шатланыша аның иптәшләре.—Аның руле дә бармы?

—Ничек руле булмасын инде?!—дип гаҗәпләнеп башын күтәрә ир-ат.—Тик бүген аны ремонтка калдырганнар... Мае аккан аның... Бүген бу машина рульсез генә чыккан...

—Яхшы машина! Зу-ур машина!—дип сөенә-сөенә кабатлый янындагы җүләрләр.—Рульсез булгач, аны гаишниклар туктатмасмы соң?..

—Ничек туктатсын?!—дип кашларын җыерып гаҗәпләнә ир-ат.—Ул бит җирдән йөрми! Ул бит һавада оча. Ком ташый...

Аның белән килешәләр.

—Яхшы машина! Зу-ур машина!—диеп елмаешалар. Аларның күзләре очкынланган, йөзләре балкый. Бу минутларда алар да бәхетле иде...

Әйе, халык телендә "Сары йорт" дип йөртелә торган тиләләр йортында да тормыш кайный. Үзенчәлекле тормыш...

Кечкенә машина белән караваты янында авызыннан-борыныннан селәгәен, маңкасын агызып, дөньясын онытып уйнап ятучы бу бәндә Габделбәр иде...

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**



## Нәҗибә Сафина

## КҮКЛӘР ТОРА—ЕЛАП, КӨЛЕП, КҮКРӘП...

***

Үз-үземә—хөррият мин,
Үз-үземә—Хуҗа дип,
Ялгыз утырам өемдә,
Сагыш күлмәгем киеп.

Табигать гел хәрәкәттә,—
Җил исә, ява яңгыр...
Күбәләкләр гөл имәләр,—
Аһ, шифалары бардыр.

Ә минем кулымда каләм,—
Һаман өемдә калам...
Өн ишетәм, дәшә әнкәм:
"Сәхраларга чык, балам".

Бары шул өн мине тартып
Чыгара урамнарга.
Сәер халәтләргә калып
Адашам бураннарда.

Коеп яуган яңгырларда
Йөримен сулар ерып...
Карурманнар кочагында
Калам төннәрдә кунып.

Шул караңгылык эченнән
Гүя әллә кем килә.—
Әллә кеменнән алда ук
Бер гаҗәеп өн килә:

---

Нәҗибә САФИНА — *шагыйрә, публицист; «Таң кошы», «Әгәр дә уйлаганда», «Без — шигырь, тормыш — проза» һ. б. шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

"...Үз-үзеңә кол була бел,
Үз-үзеңә хуҗа син—
Татыганга бу дөньяның
Сәгадәтен, нуҗасын.

Шушы халәтеңнән китми,
Яза-яза җырыңны—
Илтеп ялгарга тиешсең
Киләчәккә чорыңны!"

Һәм...шушы өн тагын мине
Каләмгә бәйләп куя.
Җаныма шагыйрьлек дигән
Тылсымлы мөһер уя.

Җилләр артыннан йөгерәм,
Юлыгам ташкыннарга...—
Канатсыз килеш кояшка
Җитәргә ашкынганга.

Һәм тагын да әнкәм өне:
"Кил, балам, сагындым ла.
Чү! Балам, чү, бик ашыкма,
Тигездә абындың ла".

...Бәлки яшәү рәвешемдер:
Табынып... абынып...
Үз-үзеңә хуҗа да бул,
Бул хуҗаның—колы да.

## Ычкынасым килә...

Дөньясына бер нәгърә орып,
"Яратам!"—дип килә кычкырасым.
Һаман саен нигә кабатлыйсың:
"Сөю-мәхәббәт дип, ычкынасың"...

Бар хикмәт тә шунда, әйтсәм әйтим:
Ычкынасым килә минем... Җирдән!—
Канат җәеп бер очасым килә.
Шатлыгымнан шашып көлә-көлә.

Кайтавазы булып көлүемнең
Күкләр күкрәп, яшен уйнар иде.
Канат җилләремнән чайпалыр да
Ак болытлар иңгә кунар иде.

Шигырь каурыйларым арасыннан
Салават күпере бер салынып да,
Син килерсең миңа Акбүз атта,—
Вакыт булды инде сагынырга.

Нур-тәхеттә очрашырбыз шулай.
Мәхәббәткә җир-күк шаһит булыр.
Бары сөю канатында гына
Җирнең тартуыннан качып булыр.

Җир әйләнә шундый сөю эзләп,
Күкләр елап, көлеп, күкрәп тора.
Ышанмасаң, шундый хикмәт барга,
Мәңге сөю көткән айдан сора...

Ай бит үзе җирдән ычкынган зат—
Гашыйк җаннар табына торган нокта...
Ычкынабыз бугай, сөю эзләп,
Ялгызлыктан—тагы ялгызлыкка...

## Үзгәрми үзгәртәләр...

Мәхәббәтне алтын димә,
алтын шундый салкын.—
Үзе үзгәрми үзгәртә
ләкин адәм затын.

Чын мәхәббәт тә үзгәрми,
тик үзгәртә җанны;
алтын салкынын тойдымы,
ташлап китә аны.

Үзгәрми үзгәрткәннәрне
таный алмадыңмы,
үзең дә сизмәячәксең
җансыз калганыңны...

## Шул халәттә

Мәхәббәттән кояш кебек
әгәр янмаса,
Хис язынннан ташкын булып
ташый алмаса,
талпынмаса кош шикелле
очарга күккә,
Йөрәк дигән "ит кисәген"
ташла чүплеккә.

Әгәр янса, әгәр ташса,
әгәр талпынса,
ут булып та өермәдәй
керсә ялкынга,
ул йөрәккә бәдән—оҗмах,
җаным да фида.
Шул халәттә бары яшәү
һәм яшьнәү—уйда!

## Югалган таңны эзләү

Әллә ничә укталдым,
Укталдым да туктaлдым.
Мин бит синең йөрәктән дә
Сорамыйча ут алдым.

Ул ут кабаттан уятты
Йоклап яткан вулканны.
Җанга кертеп калдырдым мин
Вулкан уяткан таңны.

Һәм... менә таңнарда йөрим
Саташкан күке сыман.
Күке телсез, үзем илсез,
Киләчәгем күк тoман...

Өзгәләнәм, кычкырамын—
Мин йокысыз таңнарда...
Бикле читлектә бәргәлән—
Минем хәлне аңларга...

***

Мин сине бары дөньядан
Киткәч кенә онытырмын...
Оныталмам, йөрәгемне
Синең өчен он итермен...

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр

*Җиңүнең 60 еллыгына*



## Маннур Саттаров

# ОКОПТАШ ДУСЛАРЫМНЫҢ БЕРСЕ...

ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ

1944 елның көзендә Висла елгасының аръягындагы плацдармда оборонада ята идек. Минем күзәтү пунктыма килеп, гаубица батареясының разведка отделениесе командиры, гвардия өлкән сержанты Юлдаш Азимов полк командиры исеменә рапорт язарга булышуымны үтенде:

—Үзбәкстанга кайтып килергә кирәк миңа...

—Ни булды, дустым, өйдән берәр күңелсез хәбәр алдың мәллә?—дип сорадым мин.—Фронттан берәүне дә җибәрмиләр бит, жанкисәгем! Эш нидә?

Юлдаш берничә секунд сүзен әйтә алмый торгач:

—Сөйгән кызымны кияүгә бирәләр,—диде.

—Кемне, Хәбибәнеме?

—Әйе,—диде Юлдаш. Аның аскы иреннәре дерелдәп алды.

Икәүләп язган рапортыбыз инстанция дип аталган баскычлардан узып, полк командирының кулына изге сәгатьтә килеп керде булса кирәк. Бер почмагына: "Бер айга җибәрергә" дип язып, кул куймасынмы!

Ул көннәрдә безнең Беренче Белоруссия фронты белән маршал Рокоссовский командалык итә иде. Одер—Берлин операциясе алдыннан безгә маршал Жуковны җибәрделәр. Һөҗүм 1945 елның 14 гыйнварында "катюша"лар залпы белән башланды.

Бу көнгә инде Юлдаш ерак сәфәреннән әйләнеп кайткан, үзенең сөйгән кызына өйләнеп, туйлар уздырып килгән иде. Дошман оборонасын өзеп, һөҗүмнең дүртенче көнендә 40 километр алга киткәч, мин, яраланып, госпитальгә эләктем. Юлдаш үзенең сугышчан юлын дәвам итте.

Яралануыма өч ай узып, госпитальдән чыгар алдыннан гына сугышчан дусларымнан хат алдым. Кемнәрнең әле исән, кемнәрнең һәлак булуын язганнар. Юлдаш Азимов Берлин өчен барган сугышларда, үзенә туп-туры килеп төшкән дошман снарядыннан һәлак булган. Бу, әлбәттә, минем өчен бик тә авыр хәбәр булды.

* * *

Сугыштан соң безнең адресларыбыз үзгәреп бетте. Сугыш аркасында өзелгән укуыбызны дәвам итү, эшкә урнашу, торак кайгылары туды. "Вакытлы кыенлыклар"ны

Маннур САТТАРОВ (1920) — *шагыйрь; шаян шигырьләре, язмалары матбугат битләрендә даими басыла. «Мылтыклы шүрәле», «Уйна дустым гармуныңны» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

жиңә-жиңә, ел артыннан ел уза барды. "Кайда соң сез, полкташ дусларым?" кебек җырлар җырларга гына калдык.

Бөек җиңүнең 20 еллыгы да килеп җитте. Дивизияләрнең ветераннар Советы оеша башлады. Исән калганнар бер-берен эзләп табалар. Мин дә төрле өлкәләргә хатлар язып, берничә сугышчан дустымны эзләп таптым. Ә менә сугышны башыннан ахырына кадәр узып, Берлин сугышларында һәләк булган Юлдаш дустымның гаиләсен ничек табарга?

Адрес өстәле аша эзләтер өчен, эзли торган кешеңнең исем-фамилиясен, әтисенең исемен, кайчан һәм кайда туган икәнен язарга кирәк. Мин Юлдашның әти-әнисенең дә, туганнарының да исемнәрен белмим. Озак уйлагач, баласын эзләргә булдым. Малай булса—Азимов Юлдаш улы, кыз булса—Азимова Юлдаш кызы. Туган елы 1945. Шушы белешмәгә таянып, Үзбәкстанның барлык унбер өлкәсенә һәм бер автоном республикасына хат язып салдым. Ике ай эчендә барысыннан да җавап килеп җитте: "исемлектә юк", "табылмады". Шуннан соң фронт дустымны газета аша эзләп карарга булдым. Бөтен Үзбәкстан территориясенә тарала торган "Совет Үзбәкстаны" газетасына Юлдаш турында мәкалә язып җибәрдем. Бер ай көтәм, өч ай көтәм, ярты ел көтәм, җавап юк. Тагын өч хат язып салдым. Ник бер хатыма җавап бирсен редакция! Сигез ай узгач кына, газета укучыларыннан минем мәкалә астында күрсәтелгән адресыма хатлар килә башлады. Беренче хат Кашкадәрья өлкәсеннән иде:

"Ассолому алайкум, хөрмәтле атахан!

Сезгә һәм барлык гаилә әгъзаларыгызга бәхет һәм тынычлык телибез. Таныш булмаган кешедән хат алып, гаҗәпкә калмагыз. Бу хатны ерак юлга чыгарып җибәрүче Юлдаш Азимовның кызы булыр.

Кадерле атахан! "Совет Үзбәкистони" газетасында сезнең "Кайтиш" дигән мәкаләгезне укып, бик тә дулкынландым. Сез коралдаш иптәшегез Юлдаш Азимов һәлак булды дип язгансыз. Ул бит исән!

Әтиебез каты яраланганнан соң, өч көннән аңына килгән. Сезнең дә исән калганыгызны белгәч, шатлыгыннан үзен кая куярга белмәде. Хәтта елап та җибәрде. Ул елагач, әниебез дә еларга тотынды. Сугыш елларында кара хат алуын исенә төшерде. Әтиебезне һәлак булды дип язган булганнар.

Кадерле атахан! Сез язганнарның барысы да—орденнары да, Белоруссия, Польша җирләрендә сугышулары да туры килә, тик институт бетерде дигәнегез генә дөрес түгел. Әтиебезнең андый укымышы юк. Бусын оныткансыздыр бәлки, аннан бирле күп еллар узды бит.

...Хәтта язган адрес белән сезләрнең кунакка килешен түземсезлек белән көтәбез. Үзегез килгәч, барын да аңлашырбыз.

*Сәлам белән, РӘҖӘП АЗИМОВА. 23 июль, 1984 ел."*

Каракалпак республикасында яшәүче Юлдаш Азимовтан килгән хатта: "Мин ике Саттаровны беләм: берсе белән Ленинградта госпитальдә яттык, икенчесе белән пехотада бергә сугыштык. Син аларның кайсысы буласың?"—диелгән иде. Ул да мине кунакка чакырган. Нукус шәһәренә килеп төшкәч, аның өен ничек табарга икәнен кәгазьгә дә сызып аңлаткан.

Ферганә өлкәсеннән килгән хат мондый:

"Саломнома.

Минем саломым Казан шәһәренә давыл җиле булып, диңгез штормысы булып барып җитсен, кадерле амаки Саттаров! Мине кем дип сорасагыз, Коканд шәһәрендә яшәүче белмәгән кызыгыз Лобар булырмын. Быел 9 нчы класска күчтем.

"Совет Үзбәкстони" газетасында басылган мәкаләгезне укыдым. Сугышта һәлак булган дустыгыз Юлдаш Азимовның туганнарын эзләүдә сезгә ярдәм итәргә телим. Үзем белгән, үзем күргән бөтен кешеләрдән сорашырмын. Мәкаләгез чыкканнан соң нинди яңа хәбәрләр алуыгызны миңа язып торыгыз. Моны мин сездән бик үтенеп сорыйм. Мин дә үзем белгәнне кичекмәстән язып җибәрермен...

*ХАЙИТОВА ЛОБАР. 30 июль, 1984 ел."*

Газетаның редакциядән сорап-сорап та ала алмаган санын миңа бөтенләй белмәгән кешеләр—Сырдәрья өлкәсеннән Булатов, Хорезм өлкәсеннән китапханәче Дилбәр

Морадова, Каракалпак АССРда яшәүче Жанабай Ишановлар жибәргән. Юлдаш дустымны эзләп табуда чын күңелдән ярдәм итәргә теләүчеләр шактый булып чыкты. Берсенең дә хатын җавапсыз калдырмадым. Рәхмәтләремне әйттем. "Кызганыч, мин эзли торган Юлдаш Азимов ул Сез түгел",—дип яздым дустымның барлык адашларына.

Озакламый тагын бер хат килеп төште. Кыскача эчтәлеге болайрак:

"Хөрмәтле Маннур әкә!

Мин, Кулдаш Азимов.

...Сүзнең минем бертуган абыем Юлдаш Азимов турында барганлыгына төшендем. Без, Юлдашның әнисе, сеңлесе һәм мин, аның кай җирдә һәлак булганын да, кайда күмелгәнен дә белмибез.

Абыем фронттан ялга кайткан иде. Өйләнеп унбиш көн торгач, янадан сугышка китте. Аның күкрәгендә орденнары һәм медальләре күп иде. Нинди икәнлекләрен әйтә алмыйм. Мин ул чакта 13 яшемдә, ә сеңлем 10 яшьтә иде. Без, абыебызны күргән һәм аның турында сөйләп бирә алырлык кеше барын белеп, бик шатландык.

Җиңгәбез, Юлдаш абыйны берничә ел көткәннән соң, бүтән берәүгә тормышка чыкты. Сез мәкаләгездә язганча, абыем педагогия институтын тәмамлаган иде. Берничә ай гына укытучы һәм мәктәп директоры булып эшләгәннән соң, армиягә алынды. Без аның фронттан язган хатларын, документларын һәм фоторәсемнәрен саклыйбыз".



*М. Саттаров хәрби хезмәткә китәчәк егетләр белән. Октябрь, 1984 ел.*

Телеграмма сугып, Юлдашның берәр фотосын җибәрүләрен үтендем. Юлга чыкканчы, мин эзләгән Юлдаш икәненә тәгаен ышанасым килде.

* * *

Кулдаштан килгән икенче хатны ашыга-ашыга ачтым. Эчендә каты кәгазь барлыгы сизелде. Бу—мин сораган фотокарточка булырга тиеш... Рәсемне күрү белән, ике күземнән яшь атылып чыкты. Бу бит—син, ут астында күпме сугыш юлларын бергә узган, мәңгелек яшь булып калган окопташ дустым! Юлдаш, автоматын тоткан килеш, полк байрагы янында төшкән. Өстендә гимнастерка, билендә киң каеш, башында кояшта уңган, яңгырлар юган, җилләр киптергән пилотка. 21 нче Мәскәү ополчен дивизиясе төзелүгә өч ел тулу уңаеннан, сугышта аеруча батырлык күрсәткән солдатларны һәм кече командирларны 1944 елның җәендә полк байрагы янында төшереп, рәсем артына әти-әнисенә Командование исеменнән рәхмәт язып җибәргән булганнар.

Август башында миңа инде Юлдашның кайларда укыганлыгы, институтны бетергәч кайсы мәктәптә эшләве мәгълүм булды.

Үзбәкстанга "частное лицо" булып түгел, берәр авторитетлы, сүзе үтә торган оешма вәкиле булып барырга тиешмен дип санадым. Ферганә комсомол обкомының беренче секретаре исеменә хат язып салдым һәм миңа чакыру язып җибәрүләрен үтендем. Юлдашның туганнары юл хакын үзебез күтәрербез дип язсалар да, сәфәремнең чыгымнарын һәлак булган дустымның якыннарына йөкләргә теләмәдем. Үзем пенсиядәге укытучы, ай саен ала торган 120 сумнан тыш җыйган акчам юк. Сәфәрем Татарстан эчендә генә булмагач, Казанда бер оешма да миңа командировка бирә алмый.

Ферганәгә язган хатыма җавап бирүче булмады.

Татарстан комсомолының Өлкә комитеты секретаре иптәш Шәяхмәтов Ферганә белән

бәйләнешкә керде. Болай булгач, эш җайга салынды дип шатландым... Ләкин Фәрганәдәге беренче секретарь үзенең Шәяхмәтовка биргән вәгъдәсен үтәмәде—миңа бернинди чакыру җибәрмәде.

Ике атна узгач, ип. Шәяхмәтов тагын Фәрганәгә шылтыратты. Бу юлы төребкәне икенче секретарь алды. Беренче секретарь мамык кырына чыгып киткән. Аның белән булган әңгәмә турында икенче секретарь берни дә белми икән. Анысы да телеграмма белән чакыру җибәрергә вәгъдә итте.

Тагын ике атна узгач, ип. Шәяхмәтов Ферганә комсомолына өченче кат шылтыратты. Трубканы өченче секретарь алды. Бусы да алдагы ике сөйләшү турында берни белми. Шулай да чакыру җибәрү чарасын күрергә сүз бирде.

Кулдаш борчыла: "Кайчан юлга чыгасың?"—дип, миңа хат артыннан хат җибәрә. Хатлары—бер үз исеменнән, бер әнисе, бер сеңлесе исеменнән зарыгулы һәм үпкәле.

Ферганә комсомол обкомы белән ике ай буе телефоннан сөйләшкән дәвердә мин Кулдашның әнисенә бүләкләремне дә әзерләп бетердем.

Юлдаш укыган Хуҗакурган мәктәбе, Ферганә педагогия институты, ул укыткан Миндан мәктәбенең хәрби дан музейларына бүләк итәр өчен, һәм әнисенә дип, бер дивизионда сугышкан иптәшләрнең—Юлдашның дуслары, командирларының фотокопияләрен әллә ничә данә ясатып алдым. Фотобүләкләрем бер чемодан булды.

Үзбәкстаннан чакыру киләсенә өметемне өзеп, көне килеп житкән самолет билетымны илтеп тапшырдым. Тапшыруым булды—телеграмма да килеп житте:

"Ферганский обком комсомола не возражает против приезда Саттарова ферганскую область своим родителям—Будет оказано всякое содействие".

Бу телеграмманы укыгач, Шәяхмәтов көлеп җибәрде: "Безне шушы филькина грамота өчен ике ай буе җәфаладылармы болар?"

Дөрестән дә минем мондый телеграммага һич тә мохтаҗлыгым юк иде.

Ниһаять, Татобкомол Ферганә ЛКСМ обкомы секретарена адреслап, миңа ярдәм күрсәтүләрен сорап, рәсми үтенеч язып бирде. Бу документ кулга кергәч, мин инде үземне "частное лицо" түгел, Татарстан вәкиле итеп санадым.

Туп-туры авиакассага киттем. Бер үзбәк Ташкентка алган билетын тапшырып тора иде. Шуны сатып алгач та, Кулдашка телеграмма суктым. Әмма Казанда миңа нинди сюрприз әзерләнгәнен белми идем әле. Үзем изге дип санаган эшләргә гомерем буенча аяк чалып килгән бер бюрократ бар. Аның исеме—Акча. Үзбәкстанга барырга җыенганда да теңкәмә тиде бит ул кире беткән, үз сүзле нәмәстә. Үзем дә, хатыным да укытучы буларак пенсиягә чыктык.

Халыкта бер мәкаль бар: яман сыер ярда бозаулый диләр. Минем чираттагы пенсиям белән дә шундый ук хәл килеп чыкты: Райсобес сентябрь пенсиямне тоткарлаган. Ноябрьдә ике ай өчен берьюлы бирергә телиләр.

Ул чакта һәр пенсионер үзенең әле бу дөньядан китмәгәнлеге турында йортлар идарәсеннән белешмә китерергә тиеш иде. Мин аны, әлбәттә, вакытында илтеп биргән идем, райсобес хезмәткәре бер яшь ханым, пыяла астына тыгып куйган иде.

Белешмә югалган, шунлыктан миңа пенсия язмаганнар булып чыкты. Начальницаларына кереп, поезд билетымны да күрсәттем. Хәлемне аңлый аңлавын, пенсиямне генә бирә алмый: белешмә кәгазе булуы шарт!

—Менә мин, тере кеше, сезнең каршыгызда басып торам. Менә паспортым!—дип тә карадым. Маяковскийның шигырь юллары исеме төште. Мин ул юлларны татарчага болай тәрҗемә иттем:

Тиздән Кәгазь хуҗа булып
Утырыр өй түрендә,
Йомарлап ташланган кеше
Ятар чүп кәрзинендә.

Ике айлык пенсиямне, вәгъдә ителгәнчә соңыннан гына бирделәр. Әмма бу акча миңа бигрәк тә Үзбәкстанда кирәк иде. Юлдаш дустымның күпсанлы кунакчыл туган-тумачалары миннән берни өмет итмәсәләр дә, бүләккә каршы бүләк бирергә тиеш идем бит мин. "Казанский сирота" булып барасым килмәсә дә, "Юл кешесенең юлда булуы яхшы",—дип, фоторәсемнәр тутырган чемоданымны күтәреп, аэропортка юл тоттым.

Мин инде географик картада ике шәһәрне тоташтырып, линейка һәм карандаш белән

туры сызык сызып куйган идем. Казан күген жиргә тиеп торган яңгыр болытлары каплаган иде. Безнең "ТУ-154" самолеты ул болытлар өстенә бик тиз калкып чыкты. Октябрь кояшының иртәнге нурлары түгәрәк тәрәзәләргә төшеп, бөтен салон эчен яктыртты. Тиздән стюардесса унбер мең метр биеклектә очуыбызны хәбәр итте. Үземне әкият дөньясына килеп кергәндәй хис иттем. Түбәндә "текә ярлар" да, "төпсез упкыннар" да бар. Ләкин алар чын түгел, болытлардан гына укмашкан алдавыч күренешләр.

Картамның кирәге дә булмады: җир өстенең аерым кисәкләре генә күренеп-күренеп кала. Арал дингезе минем туры сызыктан 200—300 километр уң якта ятса да, бер урында киң су өстеннән очып уздык. Самолетның үз юлы бар, димәк.

Ике сәгать ярым дигәндә, Ташкентка да килеп җиттек. Анда мин "Як-40" самолетына күчеп утырдым. Менә инде Фергана үзәне өстеннән очабыз. Офыкта түбәләрен ап-ак кар каплаган чын таулар тезелеп киткән. Ә түбәндә, самолет канаты астында, топографик картадагы кебек юл челтәрләре, кышлакларның һәм поселокларның яшеллеккә чумган кварталлары, яшькелт сулары ялтырап торган тар каналлар әкрен генә артка йөзә. "Очу вакыты 45 минут",—ди стюардесса. Ә мин моннан кырык ел элек, Юлдаш дустыма сугыш барган көннәрдә Польшадагы Пулавы станциясеннән ерак Ферганәгә кайтып җитәргә ничә көн кирәк булды икән, дип уйлап барам.

Самолет миңа бөтен Ферганәне югарыдан күрсәтергә теләгәндәй, шәһәр өстеннән әйләнеп очты... Менә ул Юлдаш дустымның үсмер һәм студент еллары узган, бөтен сугыш дәвамында күз алларыннан китмәгән, ерак җирләрдән язган хатларын да сагынып телгә алган шәһәре... Кырык дүртенче елның язында сөйгән кызына Көнбатыш Украина җиреннән җибәргән хатларының берсендә ул: *"Мондагы көне-төне сайрый торган сандугачлар гүзәл Үзбәкстанымны исемә төшереп, йөрәгемне чеметеп, чәнчеп-чәнчеп алыр өчен юри тырышалар булса кирәк"*,—дип язган булган.

"...Ут яңгыры астында канлы сугышның дүртенче җәе дә узып китте. Безнең гаскәрләр көнбатышка таба ерак юл узды, 77 гвардияче дивизиябез Висла елгасын да кичеп чыкты. Баш исән калса, тиздән кайтырбыз. Инде озак көтәргә калмады, бәгърем. Кавышу сәгатьләребез киләсе 45 нче елның язында йә җәендә сугар..."

Өчпочмаклы конверт итеп бизәкләнгән бу хатны җибәргәндә Юлдаш үзенең сөйгән кызын 1944 елның көзендә үк кочагына аласын һәм аннары яңадан фронтка, яраланган ерткычны үз оясында дөмектерергә китәсен уйламагандыр да бәлки. Очрашу бәхете бер дә көтмәгәндә килеп чыга. Кавышу сәгатьләренең якын булуын егет тә, кыз да белми әле. Юлдашның әнисе генә: "Тиз көннән кайтып төшәсеңне алдан ук белдем, күз нурым: төшемдә станция юлыннан кайтып килгәнеңне күрдем",—ди.

Юлдаш дөрестән дә станция юлыннан кайта. Өстендә гимнастерка, күкрәге тулы орденнары һәм медальләре. Беренче Кызыл Йолдыз орденын ул Сталинград сугышларында күрсәткән батырлыклары өчен алган. Икенче Кызыл Йолдыз орденын аңа Белоруссиянең Калинковичи шәһәрен азат иткәндәге батырлыклары өчен биргәннәр. Дошман оборонасын өзеп, үтә әһәмиятле тимер юл узелын алган Беренче Белоруссия фронты хөрмәтенә илебезнең башкаласы Мәскәү ике йөз егерме дүрт туптан утыз залп белән салют биргән иде. Егерме бер дивизиягә һәм полкка "Калинковичский" дигән исем бирелү дә бу операциянең масштабын әйтеп тора.

Юлдаш ике кулын парадтагыча киң итеп селкеп һәм күкрәгендәге тәңкәләрен зыңгылдатып, станция юлыннан атлый бирсен. Ә без тугыз айга артка китеп, шул Калинковичи өчен барган сугышка күз чите белән генә булса да карап алыйк әле.

156 ичы гвардияче полкның 2 нче дивизионы өчен бу көннәр иң кыен көннәрдән булды: өч батареяның да командирлары, дивизион командиры һәм аның ярдәмчесе дә яраланып сафтан чыкты. Фашист танклары бер көн эчендә ун тапкыр контратака ясадылар.

Батарея командиры Соколов авыр яраланды. Азимов аны медпунктка озатып, гаубицалар батареясының уты белән дошман һөҗүменә каршы торды. Фашист танклары һәм пехотасы күзәтү пунктына якынайган саен, Азимов командасы өстенә яуган снарядлар да якындарак шартлый башлый. Сай окопларда яткан разведчикларның үз снарядларыннан һәлак булу куркынычы туа. Сазлы җир окопларны тирәнрәк итеп казырга мөмкинлек бирми—су чыга. Юлдашның инде болай да киемнәре лачма су. Прицелны тагын да киметсә, снарядлар үзебезнең исән калган укчылар башына һәм күзәтү пунктына төшеп ярылачаклар. Гвардия разведчиклары моңа да әзер, дошман гына узмасын алар торган участоктан. Хәрби терминда бу "огонь на себя" дип атала.

Нәкъ шул минутта дошман чыдамый: артка чигенә башлый. Азимов яңа контратаканы каршыларга әзерләнә. Тик көн ахырына кадәр уңышка ирешә алмаган гитлерчылар һөҗүмнәрен туктатырга мәҗбүр булалар.

1983 елда Николай Соколовны мин Киров шәһәреннән эзләп таптым һәм үзебезгә кунакка чакырдым. Ул Казанга килгәч сугыш көннәрен искә алдык. Соколов авыр яралангач та күзәтү пунктыннан китәргә теләмәгән. Дошман уты окоптан баш калкытырга ирек бирмәгәч Юлдашның приказын үтәп, аны медпунктка илтәчәк разведчикларның гомере өчен борчылган. Кискен рәвештә:

—Караңгы төшмичә, мине кузгатасы булмагыз!—дигән ул.

Ләкин Азимов үзенең командирына:

—Иптәш комбат! Бу юлы миңа сезне тыңламаска рөхсәт итегез!—дигән дә, Абдурасулов белән Еловиковка кан эчендә яткан командирларын сугыш кырыннан чыгарырга приказ биргән.

1944 елда, "Знамя" дигән фронт газетасында, "Үз командирларына мәхәббәт" дигән баш астында минем зур булмаган мәкаләм басылып чыккан иде. Анда мин ике кыю гвардияче разведчикның снарядлар ясаган чокырлардан файдаланып, дошман пулеметларының ике яклап аткан уты астында авыр яраланган командирларын сугыш кырыннан алып чыгулары турында язылган иде.

"Ул чакта мин үземнең исән калуым белән плащ-палаткага салып сөйрәгән ике разведчикка гына түгел, Азимовка да бурычлымын",—дигән иде Соколов.

Бу авыр ярадан соң Соколов Ерак Көнчыгыштагы госпитальгә барып эләгеп, озак кына дәваланып чыккач, аны шунда урнашкан запастагы полкка җибәрәсе булганнар. Ләкин ул, төрле сәбәпләр табып, үзен яңадан фронтка җибәрүләренә ирешә һәм сугышчан дуслары янына, алгы сызыкка әйләнеп кайта. Бу хәл Азимовны тәгәрмәчләр фронттан еракта яткан Үзбәкстанга ялга алып кайткан көннәрдә була.

Юлдашның поезддан төшкәнен күргән бер якташы велосипедына атланып, биш километр араны җан-фәрманга чаптырып уза да туганнарыннан сөенче ала. Ул гына да түгел, бөтен Хуҗакурган кышлагын аякка бастыра.

Борынгы үзбәк гадәте буенча, ерак юлдан кайтучы Юлдашны басу капкасы төбендә учак ягып каршы алалар. Үз аяклары белән ике кулын селкеп кайтып килүен күреп, гаҗәпкә калалар. Чөнки әле моңа кадәр бу юлдан аксап-туксап яралы фронтовиклар гына кайта торган булганнар. Ә Юлдаш аксамый да, туксамый да: ышансаң ышан, ышанмасаң, юк! Бер аксакал хәтта аның аякларын капшап карый: үзенекеме, түгелме, янәсе?!.

Ферганә аэропортында мине Кулдаш белән сеңлесенең улы Таҗихуҗа каршылады. "Ташкенттан салган телеграммамны көтегез" дип Казаннан ук хәбәр итүемә карамастан, аэропортка алар кичтән үк килгәннәр һәм Ташкенттан килгән һәр самолетны каршылаганнар.

Алар мине туп-туры Алтыарыкка алып кайтырга исәп тотсалар да, минем әле Ферганәдә эшләрем бар иде. Комсомол оешмасына кереп, кайларда очрашулар уздырырга теләгәнемне әйттем. Алар миңа үзләренең бер хезмәткәрләрен бирделәр. Очрашуларның графигын төзер, барлык мәсьәләләр белән аңа мөрәҗәгать итегез,— диделәр.

—Танышыйк, кем буласыз инде сез?

—Бахтийор буламын,—диде ул. Безнеңчә Бахтыяр инде.

—Ә фамилиягез ничек?

—Сезгә фамилия кирәкмәс. Бахтийор дисәгез, монда мине һәркем белә.

Телефонын язып алдым. Өч көннән Алтыарык комсомол райкомына үзе шалтыратып, очрашулар графигын үзе хәбәр итәргә булды. Ярты эш эшләнде, дип уйладым мин. Бу малай мине төп башына утыртыр дип башыма да килмәде.

—Инде өйгә кайтабызмы?—дип сорады Таҗихуҗа.

—Юк әле. Мине өлкә газетасына илтегез.

"Ферганская правда"ның баш редакторы мине җылы кабул итте. Кайдан, нинди максат белән килүемне әйткәч, шул ук бинада урнашкан үзбәк телендә чыга торган "Коммуна" өлкә газетасының баш редакторын да чакырып кертте. Ул кергәндә мин инде алып килгән бүләкләремне күрсәтә идем. Булачак очрашулар турында газетагызда хәбәр бирергә кирәк тапсагыз, берәр хәбәрчегезне җибәрә аласыз",—дидем.

—Редакция өчен сез үзегез дә бик кызыклы шәхес булып чыктыгыз әле,—диде баш редактор.—Сезгә бернинди корреспондент кирәкми. Очрашулар турында материалны үзегез язып җибәрегез, күләмен чикләмибез. Бер полосалык булса, бер полоса, ике полосалык булса, ике полоса бирербез.

"Коммуна"ның баш редакторы мин җибәргән материалны үзбәк теленә тәрҗемә иттереп, үз газетасында бастырырга булды.

Редакциядә эшне бетереп чыккач, Кулдаш: "Инде өйгә кайтабыздыр?"—диде. "Юк әле,—дидем мин,—Ферганәнең өлкә радиосына илтегез."

Анда да мине бик җылы каршы алдылар:

—Чыгышыгыз ун минуттан артмасын. Текстын язып китерегез. Магнит тасмасына язарга сезне үзебез чакырып алырбыз,—диделәр.

Ниһаять, яшеллеккә чумган Ферганәнең шахмат тактасындагы квадратлар кебек тигез кварталлары арасыннан узып, район үзәге—Алтыарык юлына чыктык.

Утыз километр ара—тоташ асфальт юл. Хәрәкәт ике яклап. Уртада киң яшел полоса. Икесенең дә киңлекләре биш машина янәшә барырлык. Бу юл белән чагыштырганда, бездәге Казан—Мәскәү юлы да юл түгел, юлга пародия, мыскыл гына.

Ферганәдән чыгып, ун-унбиш километр чамасы узгач, Тажихуҗа үзенең "Жигули"ен ачык һавада шашлык пешерелгән җиргә борып туктатты. Тирәк төбендә зур өстәл. Кем шашлык, кем пылау ашый, кем җимеш белән чәй эчә. Кулдаш әйткән "тамак ялгап алу" гына булмады бу, бәйрәм сыеннан бер дә ким җире юк! Мондый шашлыкханәләр Алтыарыкка җиткәнче тагын берничә урында төтен чыгара калды.

Ниһаять, без инде район үзәге белән тоташкан Хуҗакурган кышлагына килеп җиттек. Юлдаш яшәгән Тынычлык урамы урамга түгел, борма тыкрыкка охшаган. Без экраннарда күргән Әфганстан авылларының урамнарын хәтерләтә. Менә мин моннан кырык ел элек чыгып китеп, шул китүеннән әйләнеп кайтмаган Юлдаш дустымның бусагасыннан атлап кердем.

Юлдашның әнисе Бувиниса Солиева яши торган өй өч көн буе кунак кабул итте. Туганнары, кардәшләре җәяү дә, машиналарга, мотоциклларга, велосипедларга утырып та, берәмләп тә, парлашып та, төркем-төркем булып та килә тордылар. Һәркайсы "орышта Юлдаш белән бергә булган адәмне" үз күзләре белән күрергә, үз колаклары белән ишетергә тели иде.

Окопташ дустым турында мин кат-кат сөйләдем, үзем белән алып килгән рәсемнәрне күрсәттем. Ул рәсемнәр арасында Юлдашның сугышчан дуслары—батырлыгы белән дивизиядә легендаларга кергән чечен егете разведчик Солтан Җамалдаев, кыю разведчиклар Коля Еловиков, Таня Гордюшина, үзбәк егете Сәйдерәсүл Әбдерәсүлев, дивизион командиры Василий Дронов, аның ярдәмчесе Петр Баринов, батарея командирлары Николай Соколов, Андрей Пилипенко һәм башка "дроновчылар" бар иде. Кунакларның яңа төркеме ишектән кереп, идәнгә җәелгән келәмгә аякларын бөкләп утырган саен, мин үземнең истәлекләремне яңадан сөйли башлыйм, сорауларына җавап бирәм.

Алтыарыкның үзендә урысчадан булсын, татарчадан булсын, үзбәкчәгә бик яхшы тәрҗемә итәрлек татар кешесе, үзбәк мәктәпләрендә озак еллар тарих фәнен укыткан пенсиядәге укытучы һәм сугыш ветераны, 1945 ел Мәскәүдә булган Җиңү парадында катнашкан татар кешесе Мөхәммәт Хәбибуллин да яши икән. Кызганыч, Кулдашлар өенә кунаклар җыелган көннәрдә мин бу турыда белмәдем. Тәрҗемәче кирәклеге ничектер уема килмәгән.

Тыңлаучылар мине аңлап җиткермәсәләр, Кулдаш ярдәмгә килә иде. Тик аның үзеннән кушып җибәрә торган гадәте бар. Мәсәлән, мин батарея командиры капитан Бариновның Юлдаш турында ни әйткәнен сөйлим: "Әгәр дә мин Азимовка берәр эш кушсам, җаным тыныч, чөнки ул бирелгән заданиене төгәл һәм вакытында үти". Кулдаш минем бу сүзләремне үзбәкчәгә болай тәрҗемә итте: "Капитан Баринов иң куркынычлы заданиене Азимовка йөкли торган булган, чөнки бүтәннәрнең берсенең дә моңа йөрәге җитми, тез аслары калтырый". Андый чакта мин Кулдашны төзәтергә мәҗбүр булам.

Кулдаш үз абыйсына әкияттәге батыр сыйфатларын бирә. Бигрәк тә, бераз төшереп тә алган булса, чаманы югалтып җибәрә. Мин "Юлдаш артиллерия полкында сугышты",—дигәч, Кулдаш үзеннән өстәп: "...чөнки артиллериягә көчле егетләрне сайлап алганнар. Ә минем Юлдаш абыем көчлеләрнең дә көчлесе булган. Бүтәннәр

җыйнаулашып кыймылдата да алмаган авыр пушкаларны сыңар кулы белән генә әле бер, әле икенче позициягә күчереп, дошман өстенә ут яудыра торган булган"..." дип тезеп китә. Сүз пулемет турында бара диярсең!

Кайберәүләр минем Кулдаш тәрҗемәсендәге фронт истәлекләремне авызларын ачып тыңласалар, кайбер ирләр әледән-әле мыек асларыннан елмаеп куялар иде.

Кулдаш үзенең абыйсы турында минем ничек сөйләвемнән канәгать түгел.

—Иртәгә безгә кунакларның яңалары килә. Бүгенгедән дә күбрәк булачак. Син Юлдашның орденнары бик күп иде дип сөйлә! Ул Советлар Союзы Герое иде, диген. Сугышның иң соңгы минутында Берлинда һәлак булды, дип әйт!

—Юлдаш абыеңның кылган батырлыклары болай да җитәрлек ич! Арттырып сөйләүгә мохтаҗ түгел бит ул,—дидем аңа.

Иртәгесен дөрестән дә кунаклар тагын да күбрәк килде. Аларның берсе мондый сорау бирде:

—Менә бу рәсемдәге байрак чын байракмы, әллә аны художник кына ясап куйганмы?

—Чын байрак,—дидем мин,—художник ясамаган. Бу безнең 156 гвардияче артполк байрагы. 1944 елның июль аенда 77 гвардияче дивизиянең төзелүенә өч ел тулу уңае белән, сугышта аеруча батырлык күрсәткән солдатларны һәм кече командирларны полк байрагы янында төшереп, артына Командование исеменнән әти-әнисенә рәхмәт әйтеп язып җибәргәннәр. Күргәнегезчә, Юлдаш та байрак фонында төшкән.

Кулдаш минем җавабымны болай тәрҗемә итте:

—Бу Юлдаш абыемның Рейхстаг түбәсенә менгереп кадаган байрагы!

—Рейхстаг өстенә Җиңү байрагын Егоров белән Кантария менгергән бит,—диде бер ветеран.

Кулдаш югалып калмады:

—Дөрес сөйлисең. Юлдаш абыемны дошман пулясы аяктан еккач, аның кулыннан бу байракны Егор Кантаров алып, Рейхстагның түбә башына беркетеп куйган.

"Төшереп алган" дигәннән, үзбәкләрдә мәҗлестә бирәр аксакал булса хәмер эчү тыела. Беренче көнне мине башта сарык суйган җиргә чакырып чыгардылар. Пычак белән сызгач, бугазыннан кан агып чыкканын кунак үз күзләре белән күрергә тиеш икән. Сарыкны чалганнан соң да минем әле басып торуымны күргәч: "Сезгә инде моннан китәргә мөмкин",—диделәр. Бер аулак почмакка алып китеп, аракы тәкъдим иттеләр. Яшь ирләр шулай картлардан качып кына бераз салалар икән. Күп салырга ярамый: сизәчәкләр. Мин аларга аракы эчмәвемне әйткәч, бераз аптырап калдылар: әдәп саклап кына бер йотымнан баш тартаммы, әллә бу Казан татары чыннан да эчми торган адәмме? "Кыстамагыз, рәхмәт, эчәр өчен мине бүтән чакырып тормагыз",—дигәч, үземнән гафу үтенделәр.

Ит, пылау, табикмәк, гомумән, аш-су пешерү белән гел ирләр генә шөгыльләнә. Пылау ашар алдыннан кунакларга идәндә утырган килеш кенә кулларын юу өчен, сулы комган, сабын, таз һәм сөлге китерүне дә ирләр башкара. Пылауны табынның берничә җиренә куелган зур тәлинкә-табаклардан бармаклары белән алып ашыйлар. Миңа, Казаннан килгән почетлы кунакка, аерым савытка салып, кашык йә чәнечке белән бирәләр.

Хатын-кызлар өчен аерым табын җәяләр. Анда инде кул юдыру, чәй һәм бүтән сыйларны китертү эшләрен хатын-кызлар үти, ә пешерү барыбер ирләр өстендә.

Юлдаш яңадан фронтка әйләнеп кайткач, "туебызда кышлакның барлык адәме булды" дип сөйләгән иде. Без ул чакта шул кадәр халыкны өйләре ничек сыйдырган икән дип гаҗәпкә калган идек. Хәзер менә үзбәк өенең күпме кунак кабул итә алуын үз күзләрем белән күреп белдем. Кунаклар бездәге кебек сәгатьләр буенча ашап-эчеп утырмыйлар, ярты сәгать сыйлангач, рәхмәт әйтеп, табынны үзләрен алыштыручылар өчен бушаталар.

Юлдашның хатыны Хәбибәхан беренче көннәрдә килмәде. Мине күрергә абыйсы килгән иде. Пәһлеван гәүдәле Мәмәтхуҗа абзый бүләк итеп алып килгән чапанын шунда ук өстемә киертте, башыма чиккән кәләпүш кидереп куйды, билемә яулык будырды. "Чын үзбәк булдың хәзер",—дип көлешеп алдылар.

Чапан, кәләпүш һәм ефәк яулык Хәбибәхан бүләге булган икән. Аны миңа соңыннан гына әйттеләр. Мине күрергә үзе киләсе булган, алдан ук әзерләнгән, тик качып килергә җаен таба алмаган. Абыйсы Мәмәтхуҗа юл расходларымны каплар өчен "үз өлешен" миңа Таҗихуҗа аркылы тапшырды. Рәхмәт әйтеп, акчасыннан баш тарттым. Ләкин "алай ярамый, Мәмәтхуҗа ага бик тә үпкәләячәк", дигәч, алырга туры килде.

* * *

Икенче көнне мин партия райкомына керергә булдым. Кулдаш бу фикеремне бер дә хупламады.

Ул райком бинасының баскычына аяк та басмаска тәүбә иткән булган икән. Бинага якын да килмәде. Тешләрен шыкырдатып, кем адресынадыр яман сүзләр җибәрде. Мин өй алды баскычыннан үзем генә менеп киттем.

Парад ишеген ачып кергәч тә, мине ике милиционер каршы алды. Кем булуым белән кызыксынып, документларымны тикшергәч, нинди йомыш белән килүемне сорадылар. Пропаганда секретарен күрергә теләвемне әйттем.

—Сез аны ни өчен күрергә телисез?

—Анысын инде мин үзенә сөйләрмен.

Ике милиционер бер-берсенә карашып, кертергәме, әллә борып чыгарыргамы дигәндәй сүзсез торгач, берсе эчке телефоннан ике генә сан алып, кемгәдер шылтыратты.

Бирeдә бүтән тәртипләр икән. Казанда райкомга эшең төшсә, вахтердан синә кирәкле секретарьның бүлмә номерын гына сорыйсың. Фәләненче бүлмә дип әйтеп, ничек табарга икәнен дә өйрәтеп җибәрә. Вахтер урынында булмаса, ишекләрдәге язуны үзең укып, кирәкле кабинетны табасың.

Милиционер телефон трубкасын куйгач: "Барыгыз, фәлән бүлмәгә керегез",—дип әйтерме дисәм, ул: "Хәзер үзе биргә төшә",—диде.

Артык озак көтәргә туры килмәде. Икенче кат баскычыннан төскә чибәр һәм ачык чырайлы бер яшь ир кеше төшеп, мине үзенә ияртеп алып менеп китте.

—Райкомның пропаганда буенча секретаре Эргашев булам,—диде ул.

Моңа кадәр комсомол райкомы секретаре булуын, бу эшкә яңа гына күчеп килгәнен дә әйтеп салды.

Алтыарык районының гаскәри хезмәткә чакырыла торган егетләре белән тантаналы очрашуда дивизиянең Мәскәүдәге ветераннар Советы исеменнән Юлдашның әнисенә "77 гвардияче дивизия ветераны" дигән, улына тиешле булган знакны һәм дивизиянең сугышчан дан юлы схемасын тапшырдым. Аннары дуслары исеменнән улының портретын бирдем. Үз исемемнән "Юлдаш дустыма" дигән музыкага салынган шигыремне тапшырдым. Гәүдәсе кечерәеп калган һәм бөкрәя төшкән сиксән биш яшьлек Бувиниса ана бүләкләрне алгач елап җибәрде һәм улының портретын үбәргә тотынды. Әмма аңа сүз бирелгәч, үзен тиз генә кулга алды, бу тантаналы митингта чыгыш ясарга да көч тапты. Призывникларга мөрәҗәгать итеп: "Ходай сезгә саулык-сәламәтлек бирсен, ватаныгызга тугрылыклы хезмәт кылыгыз!"—диде. Җавап сүзе белән гаскәргә алынучылар исеменнән бер үзбәк, бер урыс егете чыкты. Алар Бувиниса ана, президиум өстәле артында утырган партия һәм совет җитәкчеләре, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм барлык җыелган халык алдында хәрби белемнәрне үзләштерү өчен бөтен көчләрен куячакларын, кирәге чыкса, туган илләрен үзләренең якташлары Юлдаш Азимов кебек соңгы тамчы каннарына кадәр яклаячакларын әйттеләр.

Лейтенант чинындагы яшь кенә хәрби комиссар минем колагыма:

—Бу егетләр Әфганстанга китә инде,—дип пышылдады.

Чит дәүләт җиренә басып кергән гаскәрләрнең бу яшь сугышчыларына Юлдашның батырлыгы үрнәк булыр микән? Ул фашист баскынчыларына каршы көрәшеп, изге сугышта корбан булды, ә бүгенге үзбәк егетләренә Әфган җирендә ни калган?

Шул ук көнне "Пахтакор" совхозының кыр станында мамык җыючылар белән очрашу узды.

Юлдаш турындагы истәлекләремне тыңлаган хатын-кызларның әле берсе, әле икенчесе елый башлагач, тәрҗемәчем Эргашев та елап җибәрде. Күз яшьләрен тыя алмавына бик тә оялып, миннән гафу үтенде. Әмма мин дә үземне тар басмадан чыккандагыдай хис итеп, "ычкынып китмәскә" тырыша идем. Җитмәсә, район газетасының ике фотографының, әле берсе, әле икенчесе, аппаратларын чикелдәтеп кенә тора каршымда. "Елак большевик" яки "елак фронтовик" булып газета битләренә эләгәсем килми. Әле үземне муеныма капчык астырып, мамык җыючы яшь кызларның урталарына бастырып та төшерделәр. Мин мамык җыям, имеш!

Алтыарыкка килеп төшкәнемә инде биш тәүлек тулып узды, ә Ферганә комсомол обкомының эшлеклесе Бахтийорның әле һаман да хәбәре юк. Шәһәрара телефоннан ул

биргән номер белән шылтыратып карасам да, трубканы алучы булмады.

Хәбибәхан үзенең Юлдашын алты ел буе көткән. Юлдаштан баласы булмаган. Каен анасы белән каен атасы: "Инде, кызым, улыбызның һәлак булуы хактыр. Исән булса, бер хәбәре килер иде. Без сине үз кызыбыз кебек күрдек. Син әле яшь, гомер буе болай тол яшәвеңә Алла да, бәндә дә риза булмас. Инде үз кызыбыз итеп, кияүгә сине үзебез бирәбез",—дигәннәр.

Хәбибәханның икенче ире: "Миңа кадәр ирдә булуыңны балаларыбыз белергә тиеш түгел",—дигән. Балалар белмәсен өчен, зурлар да белмәскә тиеш. Шуңа күрә яңа гаиләдә сугышта башын куйган Юлдаш турында сүз сөйләү булмаган. Хәбибә инде җиде бала үстергән: дүрт кыз, өч угыл. Дүрт кызы да кияүдә, өч улы да өйләнгән. Аларның өй тулы үз балалары бар.

Хәбибә унсигез километр җирдән, иренә "туганнарым янына барып кайтам",—дип хәйлә корып, машинага утырып кына килгән иде. Өйдән ычкына алачагына бик ышанып җитмәгән, шуңа күрә бүләген дә абыйсы аша гына җибәргән булган. Хатын-кызлар мәҗлесендә өч сәгать буе бер сүз сөйләмичә, ике күзеннән яшь агызып утырды. Инде кунаклар өйдән чыгып киткәч кенә, үзе белән бергә-бер калып, бераз сөйләшеп алдык.

—Әтиегез-әниегез сезне кемгә бирмәкчеләр иде?—дип сорадым мин.

—Сөйгән егетемне калдырып, ул адәмгә үлсәм дә чыкмый идем,—дип җавап бирде Хәбибә.

Истәлек итеп, мин аңа үземнең яңа язган "Үзбәк кызларына" дигән шигыремне һәм ул шигырьнең юлга-юл тәрҗемәсен бүләк иттем. Ә ул тәрҗемәне миңа Мөхәммәт Хәбибуллинның хатыны—үзбәк мәктәбендә үзбәк теле һәм әдәбияты укытучы Нәзирә ханым ясап биргән иде. Үзбәкчәсен бәлки Фергана өлкә газетасы басып чыгарыр, дидем.

Юлдашның әтисе Азымбай Солиев Бохара әмирен төшерүдә катнашкан. Басмачылар, үзе өйдә булмагач, хатынын үтереп киткәннәр. Аннары ул үзеннән егерме яшькә яшьрәк булган Бувинисага өйләнгән. Бувиниса-ана җиде бала тапкан: алты угыл, җиденчесе кыз бала—Кулфихан исемле.

Кулфиханның йорты бүтән урамда, шулай ук таш стеналы участок эчендә. Ире белән аерылган ялгызак хатын. Бердән-бер улы Таҗихуҗа, шул ук курада үзенә аерым өй салган. Кулфихан үзе дә, улы һәм килене дә "Пахтакор" совхозында эшлиләр.

Юлдашның сеңлесе әле иллегә җитмәгән, тәскә чибәр хатын иде. Үзбәк кызыннан бигрәк, татар кызына охшаган. Үзбәкстанда мин хатын-кызлардан да, ирләрдән дә йөзен карап һич тә татардан аерып булмый торган үзбәк милләте кешеләрен күп очраттым.

Мәңгегә яшь булып калган Юлдаш дустымның иллегә җитеп килә торган сеңлесе булуы күңелемә сәер тоела. Абыйсы фронттан ялга кайтканда, Кулфиханга бит әле нибары ун гына яшь булган. Юлдаш абыемны күз алдыма китерсәм, үземне бала иттереп күрәм, ди ул.

Фронттан кунакка кайтканын яхшы хәтерли. Ул чакта да менә хәзерге кебек, алар өенә бик күп кеше килгән булган. Үз кышлакларыннан гына түгел, чит кышлаклардан да агылган халык. Юлдаш абыйсына нинди сораулар биргәннәрен дә хәтерли әле. Чөнки барысы да бер үк сорау:

"Син анда, сугышта, минем иремне күрмәдеңме?", "Улымны очратмадыңмы?", "Әтием, абыем очрамадымы?", "Өчпочмаклы итеп бөкләнгән кәгазьләр тотып киләләр: "Бу улымнан (әтиемнән, иремнән, абыемнан) килгән соңгы хат". Юлдаш абыйсыннан укытып, ни өчен хат язудан туктауларының сәбәбен сорыйлар. Абыйсы берәүне дә җавап бирмичә борып җибәрми. Бөтен хатларны әле бер, әле икенче ягын әйләндереп, укып чыга. Ак кәгазьгә язылган булса да, "кара хат" дип аталганнарын да тотып киләләр: "Бу хатны безгә ялгыш салмадылар микән?"—дип сорыйлар. Юлдаш абыйсы: "Сугышта төрле хәлләр була, ялгыш салган булулары да бик мөмкин",—ди. Ләкин бер генә хатын да, бер генә карчык та еламыйча гына чыгып китми.

* * *

Кулдашка "Совет Үзбәкстаны" газетасының "Кайтиш" дигән мәкаләм басылган санын ул больницада ятканда китереп биргәннәр. Бу якшәмбе көнне булган. Шәфкать туташлары врачтан башка сине чыгара алмыйбыз, дигәч, рөхсәтсез генә чыгып китеп, кулына шул газетаны тоткан килеш, өенә больница халатыннан кайтып кергән. Бердән, абыйсы турындагы хәбәрне тизрәк өйдәгеләргә җиткерәсе килсә, икенчедән, мәкалә авторына берәр кешедән хат яздырып салырга ашыккан. Үзе болай укый-яза белсә дә,

хатны бит әле яза белеп язарга да кирәк. Ул хатны алгач та, "Маннур әкә" юлга чыгарлык булсын.

Кулдаш та, сеңлесе Кулфихон да: "Юлдаш абыебыз исән кайткан булса, без болай надан калмаган булыр идек",—дип, миңа ничә кат әйтте. Әтиләре Азимбай агага сугыш беткәндә 65 яшь булган, сәламәтлеккә дә туймаган. Каравылчы хезмәте балаларын Ферганәгә җибәреп укытырга мөмкинлек бирмәгән.

Кулдаш күкрәге чәнчүенә зарлана. Табибларның нинди диагноз куйганын белми. Ул шулай әледән-әле дәваланырга кереп ята икән. Бер көнне ул миңа үзенең елан ите ашаганын әйтте. Мин бик гаҗәпләнеп сорагач:

—Чи килеш ашадым, миңа "Багучылар шулай кушты",—диде. Алар арасында күз тиюдән дә, сихердән дә дәвалаучылар бар икән. Кулдашка: "Сине хатын-кыз бозган",—дигәннәр.

—Елан ите ашагач, хәлең яхшырдымы соң?

—Юк шул,—диде Кулдаш,—әлегә файдасын сизмәдем. Менә шушы җирдә кадый,—дип, күкрәгенең урта бер җиренә төртеп күрсәтте.

Мин врач түгел, авыруга ярдәм итә алмыйм. Бердәнбер киңәшем—аракы эчмәскә һәм елан ите ашамаска, ә иң кирәклесе—багучылар киңәшен түгел, табиблар киңәшен тотарга.

Кулдаш "Пахтакор" совхозында "су складында" эшли икән. Ягъни, сусаклагычтан агып килгән суны мамык участокларына нормалап бүлеп бирә.

Бер көнне, шәһәрара телефоннан Ферганә комсомол обкомына чыга алмадым.

Икенче көнне яңадан шылтыраттым. Бу юлы трубканы алдылар.

—Миңа Бахтийор кирәк иде!

—Фамилиясен әйтегез!

—Ул үзен Бахтийор дип сорарга кушты!

—Бездә алар өчәү. Сезгә кайсысы кирәк?

—Казаннан килгән сугыш ветераны белән эш итә торганы кирәк иде миңа.

—Белмим, аларның кайсысыдыр бит!

—Алай булса, өчесен дә чакырыгыз!

Сүземне әйтеп тә бетермәдем, телефоннан еш гудок ишетелде.

Үземә Ферганәгә бармый булмас. Таҗихуҗаны яңадан борчыйсым килмәде. Ул инде болай да эшеннән соралып, миңа ничә көнен багышлады. Юлда берәр машинага утырып, барып житәрмен әле.

Ферганә юлларының нинди икәнен яздым инде. Утыз километр нәрсә ул! Фронтның карлы юлларыннан да ничәшәр йөз километр юл узганым бар!

Фронт тәҗрибәмне Ферганә өлкәсендә файдалана алмадым. Дөрес, кулымны күтәрә-күтәрә озак басып торырга туры килмәде. Бер йөк машинасын туктатып, кузовына менеп утырдым. Машина тулы үзбәк хатын-кызлары һәм араларында берничә ир дә бар. Алар үзләренең тулы кәрзиннәре һәм төеннәре белән Ферганә базарына, үзләре үстергән җиләк-җимеш, яшелчә, сөт, май кебек азыкларын сатарга баралар. Элдерәбез генә бит, малай, асфальт юлдан! Ләкин бик ерак китә алмадык. ГАИчылар безне туктатып, шоферның правасын алдылар һәм юл буендагы кырдан фәлән кадәр мамык җыярга задание бирделәр. Утырып баручылар, әлбәттә, ризасызлык белдерде: "Хакыгыз юк!" "Без болай да базарга соңга калдык!"

—Заданиене үтәмәсәгез, үзегезне үзегез тоткарлыйсыз, дип, нык тордылар ГАИныкылар. Нишләсен юлчылар—тотындылар мамык җыярга! Мин дә алардан калышмаска тырыштым. Бу эш өч сәгатькә сузылды.

Яңадан шул машинага утырып ун километр да китмәдек, яңа ГАИ посты туктатты. "Бездән әле генә бер кат җыйдырдылар инде!"—дип әйтеп карасак та, тыңларга теләмәделәр. Мин үземнең ерак Казаннан килгән адәм икәнлегемне, кичектергесез бөтән эшләрем барын әйтеп карасам да, колакларына да элмәделәр. Мин дә җыештым мамыкны. Ярый әле, Ломоносовны тотып алып, Фридрих II гаскәренең солдаты ясаган кебек, үзбәкләр мине бөтенләй мамык җыючыга әйләндермәделәр.

Биредә мамык җыю—бездәге урак өсте кебек инде. Бездә дә бит эш өстендә колхозчы апаларның базарга катык сатарга йөрүләрен хуҗалар бик яратып житкермиләр иде.

Үзбәкстан—мамык патшалыгы дип әйтеп үткән идем мин. Кайда нинди "буш" җир бар, анда мамык чәчкәннәр. Мамык кыры Таҗихуҗаның өенә үк килеп терәлгән.

Хужакурган кышлагында көтү чыгарырга да җир калдырмаганнар. Кулдашның һәм Таҗихуҗаның сыерлары һәм сарыклары көне-төне абзарда асрала. Аларга азыкны каян гына юнәтәләрдер?!.

ГАИ безне мамык җыюдан азат иткәндә кич җитеп килә иде. Комсомол обкомында эш көне беткәч янә Алтыарыкка борылып кайттым. Хәлләрне сөйләгәч, Кулдаш мине орышты. "Үзегез генә бер адым да атламагыз!"

Икенче көнне Ферганәгә мине Таҗихуҗа үз машинасы белән алып китте. Бахтийорны комсомол йортының ишек алдыннан эзләп таптым.

—Сез миңа очрашулар графигын төзедегезме?

—Юк. Бүген генә командировкадан кайттым.

Бахтийор инде бу вазифаны үз өстеннән төшкән дип саный иде. Үзенең фамилиясен һәм кем булып эшләвен дә әйтергә кирәк дип санамаган бу малайга ничек ышандым икән?

Бәхеткә, өченче секретарь Атаҗанов үз урынында утыра икән. Килеп төшүемә атна узгач, эшне аның белән яңа баштан башларга туры килде.

—Сезгә беренче очрашуны кайда оештырыйк?

—Бәлки педагогия институтыннан башларгадыр?

—Бүген соң инде. Әйдәгез, иртәгә уздырабыз.

Шулай итеп, юкка гына машина кудык.

Иртәгесен Таҗихуҗаның хатыны Халисон ике кечкенә баласы белән мамык җыярга китте, ә Таҗихуҗа мине тагын Ферганәгә алып китте. Инде октябрь аеның икенче яртысы булса да, көн эссе иде. Термометр күләгәдә егерме җиде градус күрсәтә. Без тирләп-пешеп чыктык.

Менә без яңадан комсомол бинасының ишек алдына килеп туктадык. Баскычтан менеп, Атаҗанов кабинетына кердем.

—Беләсезме нәрсә,—диде ул миңа,—әйдәгез, очрашуны педагогия институтында түгел, авыл хуҗалыгы институтында уздырыйк.

—Азимов анда укымаган бит. Менә мин бу бүләкләрне ул тәмамлаган институт өчен алып килдем.

—Мин сезнең белән рәхәтләнеп килешер идем. Ләкин бит ФГПИ студентлары шәһәрдә юк. Алар мамык кырында.

—Эш шунда гына калдымы? Без мамык кырына барыйк.

—Ул бит моннан еракта.

—Үзбәкстан җирендәдер бит?

—Әйе, Язъяван районында. Моннан алтмыш километрлар булыр.

—Шулай гына мыни? Әлбәттә барабыз!

—Бүген безнең транспортыбыз юк.

—Ә иртәгә булырмы?

—Иртәгә дә булмый.

—Транспортны мин үзем табам!

Без тагын бер көнебезне югалтып, бушка машина куып кайттык.

* * *

Транспорт сорап, Алтыарыкның партия райкомына мөрәҗәгать иттем. Минем өчен бер җиңел машина таптылар. Рульдә РОНО мөдире Мәһдиев. Бу кешене мин әле дә булса тирән ихтирам белән искә төшерәм.

Комсомол обкомында миңа "Ферганә үзәне буйлап" дигән, төсле рәсемнәр белән иллюстрацияләнгән, Мәскәүдә басылган истәлекле буклет бүләк иттеләр. Битләрен ачып карый башлагач, мин Хәмзәабадтагы Хәмзә Хәкимзадә Ниази мавзолеен күреп өлгердем. Таҗихуҗа мине шунда алып барачак иде бит. Ләкин без алтын көннәребезне Алтыарык белән Ферганә арасында мәгънәсез һәм җавапсыз кешеләргә ышанып, әрәм иттек. Таҗихуҗа әле мине Коканд шәһәренә дә алып барам дигән иде...

Тиздән җиңел машинасына утырып Пулатов та килеп җитте. Без инде юлга чыгып китәргә әзер идек. Әмма мине сугыш ветераннары вәкиленең күрәсе килгән икән.

—Моны бүтән вакытка калдырып булмыймы?—дип сорадым.

—Юк, юк! Бүген үк күрергә тиеш. Ул сезне бер минуттан артык тоткарламас,—диделәр.

Ветераннар комитеты вәкиле кемнедер эзләп, бүлмәдән бүлмәгә, этаждан этажга

бер менеп, бер төшеп йөргәндә, мин Пулатов белән сөйләшеп алырга булдым. Иң әүвәле минем Казаннан язган хатымны җавапсыз калдырмаганы өчен рәхмәт әйттем. Ул рәхмәт ишетергә лаек кеше иде. Чөнки Үзбәкстанның төрле дәүләт оешмаларына язып салган ун хатымның берсенә генә—анардан гына җавап килде. Калганнарын моннан кырык ел һәлак булган нindидер Азимовның язмышы кызыксындырмый булып чыкты.

—Сез Азимовны институт бетермәгән килеш документларын кире алган, дип язгансыз миңа.

—Әйе, бу шулай.

—Әйе, Сез архивлардан эзләп тапкан дата дөрес: 1940 елның 3 июле. Ләкин диплом аңа институтны тәмамлагач—1940 елның 1 июлендә бирелгән.

—Ни сөйлисез сез? Каян алдыгыз моны?

Мин Пулатовка Юлдашның әнисе сандыгында ефәк яулыкка төрелгән килеш, әле кичә генә бирелгән кебек сакланган диплом тоттырдым. "Приложение к диплому" дигән битләрен дә бирдем. Анда Юлдашның барлык фәннәрдән, шул хисаптан дәүләт имтиханнарыннан куелган тамгалары да бар иде.

Пулатов башын кашып:

—Һич тә аңлый алмыйм, бу ничек болай булып чыкты соң әле?—дип куйды.

Ниһаять, Ветераннар комитеты рәисе кулына зур гына бер бизәкле кәгазь тотып керде. Ул Үзбәкстан ЛКСМы исеменнән Ферганә обкомы тутырган Почет грамотасы икән. Анда: "за активную работу по военно-патриотическому воспитанию молодежи, участие во Всесоюзной экспедиции "Летописи Великой Отечественной" дип язылган иде.

Миңа шуны тапшыргач, комитет рәисе: "Иптәш Холбеков сезгә шуны әйтергә кушты: комсомол обкомы юлыгызны түли алмый, сметада каралмаган, диде"...

Студентлар янына бару гаҗәеп бер сәяхәт булды. Бу якта да асфальт җәйгән киң юл. РОНО мөдире Мәһдиев бик оста йөртүче икән. Мин аның сорауларына җавап биреп барам. Сөйләшеп бару аңа машина йөртергә һич тә комачауламый ахры. Элекке Үзбәкстан Югары Советы Президиумы рәисе Юлдаш Ахунбабаев исемендәге совхоз җирләреннән узганда сугышка кадәр үк таралган мәзәкне дә искә төшердек. Калининның: "Ничек, иптәш Ахунбабаев, Мәскәү сезгә охшадымы?"—дигән соравына ул: "Мәскәү—зур кышлак, әмма чәйханәсе юк бит!"—дип җавап биргән, имеш. Шуннан соң Мәскәүдә беренче чәйханә ачылган, ди.

Маргилан шәһәренең дә бер читен эләктереп уздык һәм Ахунбабаев районы җиренә килеп кердек. Район үзеге Язъяван дигән поселок булгангамы, Язъяван районы дип сөйлиләр. Инде Усман Юсупов исемендәге Зур Ферганә каналын да кичеп чыктык. Мамык җыючы бригадаларның саны-хисабы юк. Алар әллә ничә йөз квадрат километрларга сибелгәннәр. Без әле берсенә, әле икенчесенә килеп карыйбыз, тик берсе дә без эзләгәне түгел. ФГПИ студентларының кайсы кырда эшләгәнен белүче дә юк. Эзләп-эзләп таба алмыйча кайтсак, бик тә аяныч булачак. Бигрәк тә минем өчен. Мин бит бу эшне башлап йөрүче!

Ниһаять, Язъяван районындагы студент бригадаларының эше белән идарә итүче үзәккә килеп юлыктык. Юл күрсәтүчеләрен үзебез белән алып, ФГПИның математика факультеты студентларын эзләп таптык. Аларның да мамык җыйган чагы иде. Егетләрдән һәм кызлардан торган бу бригадада кырык кеше икән.

Очрашу гадәттән тыш җылы узды. Мин разведчикларның курку белмәс командиры Юлдаш дустым турындагы сугыш истәлекләремне сөйләдем. Ә яшьләрне аеруча мәхәббәт темасы кызыксындырды. Миңа бирелгән сорауларның да күбесе шул турыда булды. Студентлар Азимовның үзләре укыган институтның физмат факультетын тәмамлаганны белгәч, кызыксынулары икеләтә артты. Безнең белән килгән Кулдаш та абыйсының ничек фронттан ялга кайтып, өйләнеп китүе турындагы үзенең малай чак истәлекләрен сөйләде. Безгә кыр чәчәкләре җыеп бүләк иттеләр. Мондый җылы очрашу өчен Үзбәкстанның иң ерак кырына да очынып барырсың!

Язъяван районының мамык кырыннан без Ферганәгә кермичә генә туры юлдан кайттык. Очрашудан Мәһдиев тә бик тәэсирләнгән иде. Алтыарыкта салыначак яңа урта мәктәпкә Юлдаш Азимов исемен бирү мәсьәләсен күтәрәчәген әйтеп, мине гаять шатландырды. Барып кына чыкса ярар иде бу эш. Үзбәкстанга килүем турында газеталар бер язарлар да Юлдашны яңадан онытырлар. Мәктәпкә исемен бирсәләр, якты истәлеге мәңгеләшер иде.

Иртәгесен Миндан мәктәбенә берәүнең дә хәбәр итмәгәнен белгәч, мин яңадан

Ферганәгә юл тоттым. Очрашу уздыру турында кайгыртучы кеше булмаган. Атаҗановның кабинеты бикле, аның кая киткәнен белүче юк. Инде Ферганәгә килгәнемә ун көн булды, ә эшләрем бик әкрен бара. Әйтерсң лә, Азимов истәлеге белән бәйләнгән очрашулар батырның якташларына түгел, миңа гына кирәк…

Комсомол обкомының бусагасын күпме таптарга мөмкин? Мин Үзбәкстанда яшәп калырга дип килмәдем ич. Холбеков имзасы белән Казанга сугылган телеграммадагы “будет оказано всякое содействие” дигән сүз шушы булдымы?

Ярдәм сорап Ферганәнең партия обкомына мөрәҗәгать итәргә булдым. Мине пропаганда бүлеге мөдире Үлмәс ханым Әкрамова кабул итте. Эше болай да бик тыгыз булуга карамастан, мине ашыктырмый гына тыңлады, фотоларым һәм Азимов документларының копияләре белән танышты. Өлкә музее директоры Валентина Никитина белән дә телефоннан сөйләшеп, Казаннан сугыш ветераны килүеннән файдаланып, музейны Азимов турындагы материаллар белән баетырга киңәш итте. Аннары өлкә радиосы белән сөйләшеп, Казан кунагы белән бәйләнешкә керергә кушты. Аннан: “Без аны югалттык”,—дип җавап биргәннәр. Көтәбез, килсен, дигәннәр. Әзерләгән текстымны үзем дә инде бүген тапшырырмын дип тора идем. Үлмәс ханым үземне мактап та куйды. Аннары мин алып килгән фотоларны һәм Азимов документларының күчермәләрен ясатуның ничә сумга төшүен сорады. Минем аны санаганым да юк иде. Чамалап кына: “Йөз сум тирәсе булыр”,—дидем.

—Ә сезгә аны кем түли соң?

—Мин аларны бүләк итеп алып килдем.

Аннары Үлмәс ханым юлым өчен нинди оешма түләве белән кызыксынды.

—Ферганә комсомолы түләү мәсьәләсен үзегез килгәч хәл итәрбез дигән иде. Килгәч: “Түли алмыйбыз”,—дип җавап бирделәр.

—Гарантияле чакыру килми торып, сезгә Казаннан чыкмаска кирәк иде.

Юкка гына партия обкомына эшкә алмаганнар икән бу эшлекле ханымны! Холбеков, Атаҗанов кебекләр энергияле һәм акыллы яшь Үлмәс ханым Әкрамовага олтанга да ярамыйлар дип уйлап куйдым мин эчемнән генә... Хәзер дә шулай уйлыйм. Инде обкомнар таратылгач, кайда, кем булып эшли икән минем тирән ихтирамымны яулап алган бу ханым? Алтын тәңкә җирдә ятмыйдыр дип беләм…

Ферганәдә эшлисе эшем—радиога кереп, язылып чыгу иде.

—Башлагыз!—дигәч текстымны укырга тотындым. Юк-юк та, операторлар ягына күз салып алам. Юлдашның сөйгән кызына фронттан язган хатларыннан өзекләр китергәндә, башта берсе, аннары икенчесе еларга кереште. Ә мин үзем өчен курка башладым: тавышым калтыранмаса ярар иде! Бу ханымнар ягына карамаска тырыштым.

Мин үземнең ни өчен Казаннан ук Ферганә партия обкомы белән бәйләнешкә кермәвемә үкендем. Анда ике ай буена чакыру көтеп интегүләр дә, Ферганәгә килеп төшкәннән соң буш суса белән киндер сугулар да булмаган булыр иде. Татарның акылы төштән соң, диләр шул.

Ни өчен моңа башым җитмәве—Мәскәү үрнәге аркасында булгандыр. Безнең дивизиянең сугыш ветераннары белән очрашу Мәскәүдә партия райкомы түгел, комсомолның Кунцев райкомы ярдәме белән оештырыла килде. Дивизиябез башкаланың шул районында яшәүче ополченнарыннан төзелгән. Әлбәттә, минем Үзбәкстандагы очрашуларым Мәскәүдәге очрашулар белән чагыштыра торган да түгел. Башкалага Союзның бөтен почмакларыннан дивизиябезнең ничәмә йөз ветераны килә. Аларны кунак өйләренә урнаштыру, тантаналы кичәләр өчен бина табу, укучылар һәм хезмәт ияләре коллективларында чыгышлар ясау, Мәскәү предприятиеләренә һәм истәлекле урыннарга экскурсия оештыру, Билгесез солдат каберенә чәчәк кую, кунакларның Мәскәүдән тоткарлыксыз билет алып, кайтып китүләрен тәэмин итү һәм башкалар.

Партия обкомына мөрәҗәгать иткәннән соң, минем эшләремдә кискен борылыш булды. Хәзер очрашу оештыручыларны мин түгел, алар мине эзләп йөри башлады.

Моннан берничә ел элек радиодан мин бер тапшыру тыңлаган идем. Безнең илдән Кушма Штатларга барган бер кыз, белеме белән металлург, үз һөнәре буенча эш эзләп, ике йөздән артык адреска хат язып салган. Барысыннан да: “Сезнең профиль буенча бездә эш юк шул”,—дип, гафу үтенеп, хатлар килгән. Берсе генә дә җавап бирмичә калдырмаган. Аларда җаваплылык хисе кешеләргә ана сөте белән керә күрәсең. Ә бездә?..

Көндезге дүрттә мине Миндан мәктәбенә алып килделәр. Менә мин мәктәп директоры Абдукаюм Нурматов кабинетында.

—Моннан ике ай элек сезнең адреска Казаннан хат язып салган идем, җавап килмәде,—дидем мин.

—Беләсезме, иптәш Сатдоров, сез бит Юлдаш Азимовның кайсы кышлакта туганын язмагансыз. Шуның өчен без аны таба алмадык.

—Бу турыда миңа хат белән хәбәр иткән булсагыз, туган кышлагын да әйтеп язган булыр идем. Мин аны Казаннан торып, хат аша эзләп таптым. Ләкин бит Азимов—сезнең мәктәпнең укытучысы. Мин бу турыда хатымда да яздым. Инде эзләп табу турында сөйләсәгез, мин Миндан урамыннан беренче кат узуымда ук Азимовны белгән ике кешене очраттым. "Хәтерлибез: ул бит безгә математика укытты",—диләр. Карточкасын күрсәткәч:—Шул, шул, нәкъ үзе!—дип, шикләнергә урын калдырмадылар.

Дөрес сүзгә җавап юк. Нәрсә әйтсен миңа бу директор? Мин елмаерга тырышып:

—Укучыларга хәрби-патриотик тәрбия бирергә теләп, сез геройларны читтән эзлисез булыр. Ә бит сезнең коллективның үз кешесе сугыш герое!—дидем.

Мәктәпнең актлар залы укучылар һәм укытучылар белән шыгрым тулы. Бүтән очрашулардан аермалы буларак, залдагы дүрт йөздән артык укучының барысының да кулларында кыр чәчәкләре бәйләме. Бу аларның моннан кырык ел элек сугыш кырында башын куйган укытучылары Юлдаш Азимовка китергән бүләкләре. Кабере еракта, Бранденбург җирендә. Бүген аның туган иленә кайткан данын каршыларга җыелганнар бирегә. Китмәскә кайткан. Чөнки исеме мәктәпнең пионер дружинасына бирелде. Ә бергә сугышкан дустының бүләк итеп китергән истәлекле рәсемнәре, фотодокументлары, газета мәкаләләре дан музее бүлмәсен бизәр.

Бу залда Бөек Ватан сугышы кырларында ятып калган миндандыларның оныклары да утыра. Бабаларының изге каберләре Россия, Украина, Белоруссия, Польша, Германия җирләренә сибелгән. Чәчәкләр алар хөрмәтенә дә. Исән калып, илләренә әйләнеп кайтканнарының берничәсе, әнә, президиум өстәле артында утыра. Укучылар биргән көлтә-көлтә чәчәкләр аларның кочагына сыймады. Президиум өстәле чын мәгънәсендә чәчәкләргә күмелде.

Миндан мәктәбе Юлдаш дустымның биографиясе белән бәйләнгән, очрашу уздырмый калырга ярамый дип санаган урыннарның соңгысы иде.

Бик күп сораулар бирделәр. Аеруча кызыксынган темалары Юлдаш белән Хәбибәхонның мәхәббәте булды. Ике гашыйкның дулкынландыргыч мәхәббәте турында минем элек белгәннәрем бирегә, Алтыарыкка килгәч, яңа мәгълүматлар белән тулылана төшкән иде.

Мәсәлән, Юлдаш сөйгән кызына өйләнеп, кабат фронтка әйләнеп кайткач, безгә, окопташ дусларына, туй картиналарын берникадәр бизәбрәк күрсәткән. Кәләшне пар кыңгыраулы трантаска утыртып, пар атның ялларына ал тасмалар тагып, аларны җилләрдә җилфердәтеп алып кайттым, дип сөйләгән иде. Чынында башкачарак булган. Колхоз рәисе ат бирмәгәч, кияү үзенең иптәш егетләрен ияртеп, Алтыарыктан унсигез километр ераклыгындагы поселокка җәяү киткән. Нефтьчеләр поселогында машина тапмагач, бер тракторчыны көчкә күндереп, кәләшен трактор арбасына утыртып алып кайткан.

Ә колхоз рәисенең Юлдашка ат бирдермәскә бик тә "уважительный" сәбәбе булган. Юлдаш үзе белән бер класста укыган, картлар кыяфәтенә кереп, хәрби хезмәттән качып яткан берәүне танып, сакалыннан сөйрәп алып чыккан да, кышлак Советына китергән. Ә ул адәм колхоз рәисенең кардәше икән. Рәис ничек итеп Юлдашка ат бирсен ди?

Мин, әлбәттә, укучыларга сөйләргә тиешлесен генә сөйләдем, бөтен серне ачмадым. Аннан бирле инде кырык ел үткән булса да, кем белсен! Оныклары арасына да дошманлык чәчүдән сак булырга кирәк.

Училище фотографлары безне кат-кат сурәткә төшерделәр.

"Очрашу кичәсе шуның белән тәмам",—дигәч тә таралмыйлар. Мине урап алып, һаман да сораулар бирәләр. Автографымны алырга да теләкләре зур. Кем блокнотын, кем дәреслеген, кем дәфтәрен суза. Этешәләр, төртешәләр. Кыюрак кызлар, имзам куйгач, битемнән дә үбеп китәләр. Казанда йә Татарстан районнарында шигырь китабымны бүләк иткәч, яшьрәк чагымда да шатлыкларыннан битемнән үбеп алганнарын хәтерләмим. Авторучкамны кесәмә салып куярга да ирек бирмичә, мине капка төбенә кадәр озата чыктылар. Кайберләре капкадан чыккач та артымнан калмады. Ялгышмасам, инде залда ук автографымны алган елтыр күзле бер кыз, мин машинага кереп утыргач, ярым караңгыда муеныннан кочаклап, иреннәремне яндырып үбеп алды. Халык алдында

үбәргә оялган булса кирәк. Үзбәкләрдә дә бар икән бит чая кызлар!

Мин бу сылуга:

—Бер генә минутка сабыр итегез әле,—дидем.

Машинада калган плащымның күкрәк кесәсендә бер данә шигырь китабым бар иде. Елтыр күзле, нурлы йөзле бу яшь кызга ак бәхетләр теләп, автографымны язып бирдем. Шатлыгыннан нишләргә белмәде. Юкка гына бөтен кешедән азакка калып, озата бармаган икән үземне.

Кем инициативасы белән булгандыр, анысын хәтерләмим. Мине сугыш һәм хезмәт ветераннары дәвалана торган санаторийга очрашу уздырырга чакырдылар. Бу санаторий Алтыарык районы җирендәме, әллә күрше райондамы, исемнән чыккан. Тик мине Алтыарык район газетасы машинасы килеп алып китте. Редакциянең фотографы Сангинов та безнең белән барды.

Биредә дәваланучылар Үзбәкстанның төрле өлкәләреннән җыелган иде. Казаннан чыгар алдыннан гына Мәскәүдән, минем соравым буенча, 77 гвардияче дивизиядә сугышкан Үзбәкстанда яшәүче ветераннар исемлеген җибәргәннәр иде. Алар бездә күп булган, исән калганнарның гына саны билгеле түгел. Ветераннар Советы исемлегендә унбер кеше. Алар арасында Бохара өлкәсендә яшәүче Советлар Союзы Герое Азим Рәхимов, Хорезм өлкәсеннән “Дан” орденының тулы кавалеры Рәхим Авазморатов та бар иде. Сырдәрья өлкәсендә яшәүче, Азимов отделениесендә сугышкан Сәйдерәсүл Абдурасуловны мин “Совет Үзбәкстаны” газетасы аша эзләп тапкан идем. Ветераннар Советы миңа бу исемлек белән бергә бер истәлекле фото да җибәргән. Уртада Советның рәисе, сугыш елларында политотдел начальнигы булып хезмәт иткән отставкадагы полковник Медеников. Рәсем артына: “77 гв. дивизия ветераннары Кашкадәрья өлкәсендә” дип язылган. Елы куелмаган.

Мәскәү ополченнарыннан оешкан дивизиягә үзбәкләр ничек барып эләккән дисәгез, гаҗәпләнер әйбер юк. Дивизиянең составы сугышта яңара тора. Һәлак булганнар, яраланып сафтан чыкканнар, укырга җибәрелгәннәр, зуррак хезмәткә бүтән частьләргә күчерелгәннәр урынына яңалар килә. Дивизия оешкач та, 1941 елның июль башында Мәскәүдән унбер мең дүрт йөз кеше чыккан. Шуларның кырык алтысы гына Берлинга барып җиткән.

Улы сугышта һәлак булган Бувиниса ананың яшәү шартларын яхшыртырга кирәклеген бусагасыннан атлап кергән минуттан ук аңласам да, бу эш белән шөгыльләнергә һаман кул тими иде әле. Ниһаять, очрашулар тәмамланды һәм мин җиң сызганып шушы эшкә керештем.

Өйнең ул яши торган яртысы түшәмсез. Элек чолан гына булган ахрысы. Ә түбәсе яңгыр һәм кар суларыннан саргаеп, калҗаеп беткән фанерадан гыйбарәт. Ул фанераның өстенә балчык салынган. Мин төзүче булмасам да, салам түбәле йортның өй кыегы, такта һәм калай түбәленеке ничә градус итеп ясалырга тиешлеген беләм... Балчык түбә өй эченә ишелеп төшмәсен өчен, бүлмәнең нәкъ уртасында матчаны терәткән багана тора. Идәне җир, ишеге мәче сыярлык ябылып бетми.

Сугыш батырының анасына кешечә яшәү шартлары тудыру өчен, аңа яңа өй салып бирергә кирәк. Яңа өй салып бирә калсалар дип, урыны турында да сөйләштек. 14 сутый тәшкил иткән участокта, әлбәттә, урын җитәрлек. Бувиниса ана элекке өенең урынын да күрсәтте. Бу балаганга капиталь ремонт ясатырга мөмкинме, юкмы икәнен чамалар өчен, баскыч куеп, өй түбәсенә мендем. Астагылар куркышып:

—Анда бассагыз, ишелеп төшәсез бит!—дигәч, балчык түбәнең стенаны каплап торган җиренә баскан килеш кенә күзәттем.

Югарыдан әйләнә-тирәдәге йортлар әйбәт күренә. Алар барысы төзек, биек, калай түбәләре кызыл, зәңгәр, яшел буяуларга буялган. Гаражлары гына түгел, терлек абзарлары да йә калай, йә шифер. Стеналары таш белән балчыктан түгел, кызыл йә ак кирпечтән салынган бу мәһабәт өйләр, әлбәттә, сугыштан соң калкып чыкканнар. Бувиниса ананың бердәнбер балчык түбәле өе “сугышка кадәр үзбәкләр менә шушындый өйләрдә яшәгән” дигән кебек, музей экспонаттай сакланып калган. Шул ук вакытта: “Менә бездә, Алтыарык район үзәгендә, сугыш кырында башын куйган батырларның гаиләләре турында шулай кайгырталар инде”, ди кебек бу контрастлы күренеш.

Шуннан соң, “Пахтакор” совхозының директорына Бувиниса ана исеменнән “пешереп” гариза яздым, редакциядә аны машинкадан бастырып, директорга кертеп бирдем:

—Бу данәсе сезгә, ә менә бу күчермәләрен үзем белән Мәскәүгә алып китәм,—дидем.

* * *

Дөньяның төрле илләрендә кайчандыр гөрләп торган, гасырлар узу белән җир өстендә эзе дә калмаган шәһәрләр булганын беләбез. Ул шәһәрләрнең хәрабәләрен йә тарихчылар эзләп таба, йә алар бүтән бер максат белән җир казыганда килеп чыга. Кай чагында аерым кешеләрнең язмышы да шул борынгы шәһәрләрнең язмышын хәтерләтә.

Юлдаш Азимовның исеме дә сугыш елларында Хуҗакурганда яңгырап торган. Энгельс исемендәге колхоз "Пахтакор" совхозы составына кергәнче, аның рәисе Юлдаш исеме белән колхозчыларны хезмәт батырлыкларына рухландырган. Юлдаш өйгә салган хатында: үзенең "Батырлык өчен" медале белән бүләкләнүен язгач, колхоз рәисе шул хатны Бувиниса анадан сорап алып, колхозчылар җыелышында укыган.

—Хуҗакурган ирләре фронтта батырларча сугыша. Без аларга лаек булыйк, хезмәт батырлыгы күрсәтик! Нормадан тыш икешәр бураэна мамык түтәле казыйк!

Карты-яше оешкан рәвештә кырга чыгып, өстәмә икешәр бураэна җир йомшарта. Мамык өлгерер алдыннан килгән хатында Юлдаш үзенең "Кызыл Йолдыз" ордены белән бүләкләнгәнен яза. Колхоз рәисе Юлдашның бу хатын да җыелышта укый.

—Хуҗакурганлылар фронтта батырларча сугышалар. Без дә алардан калышмыйк. Нормадан тыш мамык җыйнау—безнең изге бурыч!

Мамык кибәннәре өстәмә "Азимов тонналары" белән биегәя.

Бер көнне колхоз рәисе тагын Бувиниса ананың өенә килә.

—Юлдаштан яңа хат килмәдеме әле?

—Килде, килде,—ди Бувиниса ана һәм сандык өстенә өелгән мендәрләр арасыннан улының яңа хатын чыгарып бирә. Анда Сталин портреты төшерелгән һәм имзасы куелган, типография хәрефләре белән басылган кәгазь дә бар. "Сугыш герое гвардия өлкән сержанты Азимов Юлдашка" дип язылган.

—Юлдаш—герой!

Бу хатны да рәис колхозчылар җыелышына алып китә.

—Юлдаш Азимовка герой исеме бирелгән! Менә Верховныйның приказы. Якташыбызның батырлыгына лаек булыйк!..

Бу юлы мамык эскертләре өстәмә "Азимов тонналары" хисабына тагын да зурая төшә.

Шатлыклы хәбәр район җитәкчеләренә дә барып җитә. Район үзәгендә митинг җыялар. Ялкынлы нотыклар сөйләнә. Азимбай әкә белән Бувиниса ананы котлыйлар. Район башлыгы аларга яңа өй салып бирергә вәгъдә итә.

Азимбай ага инде картайган, сәламәтлеге дә какшаган. Юлдаш уллары исән-сау кайтса, гаиләнең терәге булыр иде дә бит, әле сугыш бетмәгән. Сугыш беткән көнне Бувиниса ананың "кара хат" алганын укучы белә инде. Ләкин ул әле улын кайтыр дип көтә. Кайтмагач, хөкүмәтнең югары орденнары белән бүләкләнүе турында хатлары килеп тормагач, даны да әкренләп тына бара... Ул инде исем-фамилиясез генә "фәлән кадәр якташыбыз сугыштан кайтмады" дигән статистикага кертелә башлый.

Тора-бара "Пахтакор" совхозында уздырылган тантаналы җыелышларда һәлак булганнарны аягүрә басып, бер минут тын калып искә алганда, алар арасында сугыш елларында якташларын хезмәт батырлыгына рухландырган ничәмә орден һәм медаль кавалеры Юлдаш Азимов та бардыр дип, туганнарыннан башка берәр кеше уйлады микән?

Кырык ел эчендә сугыштан соң туган икенче буын үсеп җитә. Сугыш батырын ул укыган Хуҗакурган мәктәбе дә, сугышка кадәр тәмамлаган Фергана институты да, шул институт биргән диплом белән килеп, математика укыткан Миндан мәктәбе дә бөтенләйгә оныта. Бу истәлекләрне укып барган газета укучылары югарыда язылган күңелсез хакыйкать белән таныш инде.

Район башлыклары вәгъдәләр бирергә бераз ашыкканнар икән шул. "Сугыш герое" белән "Советлар Союзы Герое" икесе бер түгел икән бит! Яңа өй салып бирү түгел, тузган өйләрен ремонтларга ник бер кирпеч, ник бер такта бирсеннәр! Бирмибез димиләр әлбәттә. Вәгъдәгә саранлашмыйлар. Ул вәгъдәләр еллар буе сүздә генә кала килгәч, мәхәллә бусагаларыннан аяк атлап керми башлыйлар. Хәрби комиссариат таныклыгы нигезендә Юлдаш өчен билгеләнгән кырык бер сум пенсиясе генә айдан-айга килеп тора. Аны кая гына җиткереп бетерәсең?

Ярдәм итүче табылмаса да, ананың бәхетсезлегеннән файдаланып, аның азлап-азлап калдыра барган шул пенсия акчасын алып китүче табылган. Бу турыда Кулдаш миңа болай сөйләде.

"Илле дүртенче ел түгел иде микән. Мин өйдә юк чакта безгә бер адәм кергән. "Кайгырма, әби, улың исән, мин аны табып бирәм. Син миңа документларын бир, эзләтергә акча бир",—дигән. Әнием сөенеченнән еглап җибәргән, рәхмәтләр әйтеп Юлдашның документларын, җыйган акчасын биргән. "Бу аз, тагын бир",—дигән әфирис. "Бүтән юк, углым, актыгын бирдем",—дигән әни.

Бер көнне шулай урамнан барам. Каршыма әлеге адәм килеп чыкмасынмы! Якасыннан тотып алдым мин моның: "Эләктеңме, сабакы!"

Бер суктым—борыныннан кан китте, икенче суктым—колагыннан кан китте. Өченче тапкыр сугарга кизәнгән идем—берәү кулымнан китереп тотты. Карасам—нәчәлник милиция!

—Ник кыйныйсың аны?—ди.

—Иптәш нәчәлник милиция! Ничек аны кыйнамыйсың? Ул—проходимис! Әниемне алдаган, Юлдаш абыемның фронттан язган хатларын алып киткән, иптәш Сталинның лично үзе кул куеп биргән былгадарностларын алып киткән, әнинең үлемтек акчасын алган!

—Син аңа җәзасын бирдең инде, бүтән кыйнама, иди домой!—ди.—Югыйсә, үзеңне утыртып куябыз!

—Иптәш нәчәлник милиция! Бу ни дигән сүзең синең? Ул бит сабакы такой. Хуже сабакы! Юлдаш абыемның наградной документларын алып киткән, фронттан язган хатларын алган, әниемнең үлемтеккә җыйган акчасын алган! Синеңчә, мошенник һәм әфирис ыслабуда гуләйт кылып йөрсен, ә мин каталашкага мыни? Хитрый будешь! Аны убить мало! Дай миңа последний раз бер сугарга! Аннары мине үзеңнең каталашкаңа утырт, бер сүзем юк!—дидем.

Өченче сугуда үтерәсе идем, нәчәлник милиция сугарга гына бирмәде".

—Ә син аның шул кеше икәнен каян белдең?—дип сорадым мин Кулдаштан.—Ялгышып, бүтән берәүне тотып кыйнамадыңмы?

Бу соравыма Кулдашның бераз хәтере дә калды:

—Белмәгән адәмне тотып кыйнарга, башыма ат типмәгән ич минем! Капкабыздан чыгып килгәндә каршы очрады бит ул миңа. Әни сразы әйткән булса, артыннан куып җитеп, шунда ук бәреп үтергән булыр идем!

—Акчасын ник алганы аңлашыла, ә хатлары, документлары ник кирәк булды икән аңа?

—Дизәртир бит ул,—диде Кулдаш.—Андыйлар бездә тагын бар. Орыш елларында кайда булдың дип сорасалар, фәлән дивизиядә воевал дип әйтергә кирәк ич аларга!

Алтыарыкта "кызыл партизан" дип аталган бер аксакал, минем Азимов белән "орышта бергә булган адәм" икәнемне белгәч, үзе кызыксынган хәлләр турында сорашты. "Башы кайтмады шул мескеннең",—дип, Юлдашны да, аның әти-әнисен дә кызганды. "Без инде кулыбыздан килгән ярдәмне кылдык. Азимовларга угылларының кырыгын уздыру өчен ике капчык бодай оны, бер капчык дөге бирдек",—диде.

—"Без" дигәнегез кем була инде ул?

—Колхоз идарәсе. Мин анда бухгалтер булып эшли идем.

Мин бу турыда Бувиниса анага кайтып сөйләдем.

—Нинди бодай, нинди дөге?—дип гаҗәпләнде ул.

—Юлдашның кырыгын уздырырга бирдек, ди.

—Әстәгъфирулла балам! Биргәннәре юк!

—Бәлки оныткансыздыр, кырыгына булмаса, елын уздырырга биргәннәрдер?

—Юк, юк, беркайчан да биргәннәре юк, тешем сынсын әгәр!..

Кулдашның сөйләве буенча, бу он белән дөгене Азимовлар исеменә яздырып, Азимбеков дигән, беркемнәре дә сугышта һәлак булмаган адәмгә китереп биргәннәр. Бу турыда Юлдашның әти-әнисе белми дә калган.

Беркөнне почтальон, үсмер малай, ниндидер Азимбековка адресланган хатны, ялгышып, Азимовларга биреп китте. Кулдаш хатны ачып карады да, укып та тормыйча, сандык өстенә бөкләп өелгән юрганнар арасына кыстырып куйды. "Бу хат сезгә түгел бит, ник кире биреп җибәрмәдең?"—дип сорагач: "Почтальон аны миңа китерде",—диде Кулдаш һәм Азимбековлар адресына яман сүгенеп куйды. Икенче юлы да, өченче

юлы да Кулдаш Азимбековка дигән хатларны почтальонга кире бирел жибәрмәде. Җавабы һаман шул: "Миңа китерделәр бит".

Азимбековларның өйләре Азимовлардан бер-ике йорт аркылы гына икән. Башыма шундый ук килде: Азимовларга илтәсе "ике капчык он, бер капчык дөге" төялгән арбага шушы хат ташучы малай кебек берәүне утыртып жибәргән булсалар, Кызыл партизанның сөйләгәне дөрестер дә бәлки. Кызганыч, миңа ул бухгалтер белән кабат очрашып сөйләшергә туры килмәде.

Юлдашның фронтка әйләнеп кайткач безгә сөйләмәгәннәрен туган йортына килгәч белдем. Әти-әнисенең дә, кәләше Хәбибәнең дә жан-бәгырьләрен кабат сугышка жибәрәселәре килмәгән. Укытучылар житешмәү сәбәпле, мәктәпләр ябылыр хәлгә житкән. Укытучыларга хәрби хезмәттән бронь бирәләр, хәтта фронттан кире кайтаралар дигән хәбәр таралган булган. РОНО да аны ике куллап эшкә алырга әзер. Син бит укытучы кеше, кал, барысын да үзебез жайлыйбыз, ризалыгыңны гына бир, дигәннәр. Күндерә алмагач, калдыруның бүтән юлларын эзләгәннәр. 1944 елның көзендә Үзбәкстанда әллә милли полк, әллә милли бригада оештырырга керешкәннәр. Командирлар житешми дип, Юлдашны шунда кодалаучылар табылган. Сине күчерүне үзебез эшлибез, киреләнмә, дигәннәр. Юлдаш: "Минем утны-суны кичкән үземнең данлыклы дивизия бар. Әле сугыш дәвам иткәндә, урыным шунда, алгы сызыкта, гвардияче дусларым янында",—дип җавап биргән аларга.

Аерылганда әти-әнисенең, Хәбибәсенең күз яшьләрен күрмәс өчен, "Ферганәгә барып кайтам", дип, хәйләләп чыгып китеп, тимер юл станциясенә юл тоткан. "Китәсен әйткән булса, юлына азык пешергән булыр идем бит",—дип ачынып сөйләде әнисе. Өйдә калганнарга беренче хатны 1944 елның 20 декабрендә язып салган.

"Миһербанлы ата-анам, сөекле Хәбибәм, кадерле энеләрем һәм сеңлем! Мин саусәламәт. Хәзерге көн юлдамын. Менә Белоруссиягә дә килеп җиттем... Без күп кыенлыклар кичердек, барысына да чыдадык. Әле сугыш барган чакта, минем урыным фронтта, аның иң алдынгы сызыгында. Сез аңлыйсыз бит моны, кадерлеләрем..."

Унжиде яшьлек Хәбибәсе күңел төшенкелегенә бирелмәсен өчен аны юатуларын үтенә. Ике энесенең һәм сеңлесенең өс-башы, аяк киемнәре һәм саулыклары өчен борчылып яза.

* * *

Ферганәдән мин туп-туры Мәскәүгә очтым. "Ферганская правда"ның баш редакторы миңа самолетта урын бронировать итеп куйган иде. Үлмәс ханым Әкрамова тәкъдиме белән Алтыарык партия райкомы, үз мөмкинлекләреннән чыгып, кайтыр юлыма житәрлек кенә акча бирде.

Мәскәүгә кайткач, дивизиябезнең ветераннар Советына Үзбәкстанга сәяхәтем турында машинкадан биш битлек отчет язып бирдем. Сугыш герое анасының торак шартларын яхшыртуларын үтенеп, партиянең Ферганә обкомы һәм Алтыарык райкомының беренче секретарьлары исеменә хат әзерләргә киңәш иттеләр. Ветераннар Советы дәүләттән бер тиен дә акча алмый, бөтен эшләре инициатива нигезендә генә алып барыла иде.

Мәскәүдә эшләремне бетереп, Казан каласына ноябрь башында кайтып төштем. Монда мине шатлыклы хәбәр көтә иде. СССР Оборона министрлыгына моннан берничә ай элек Азимовның кайчан, нинди орденнар белән бүләкләнгәнлеген сорап язган хатыма җавап килгән. Ике Кызыл Йолдыз орденыннан тыш, ул әле икенче дәрәҗә Ватан сугышы һәм Кызыл Байрак орденнары белән бүләкләнгән булган. Бу турыда район хәрби комиссариаты да, әти-әнисе дә, хәтта Юлдаш үзе дә белми калган. Чөнки бүләкләнүе турындагы приказларга ул һәлак булганнан соң бер ай узгач кына кул куелган.

Мин шул ук сәгатьтә Алтыарык район газетасы редакциясенә бу хакта телеграмма суктым. Баш редактор үзе әзерләгән репортаж әле басылмаган. Телеграммам газетаның шул санын җыйганда килеп житкән. Мин жибәргән хәбәрне репортаж астына "Редакциядән" дигән өстәмә белән урнаштырганнар.

Тиздән бандероль итеп салынган "Пахта учун" ("Мамык өчен") газетасы да килеп житте. Минем Алтыарык районына сәяхәтем турындагы мәкалә тулы ике битне алган. Калын, ялтыравыклы ап-ак кәгазьдә басылган бу санын миңа егерме биш данә жибәргәннәр.

* * *

Дивизиябез ветераннары Советының Ферганә җитәкчеләренә язган хатлары игътибарсыз калмаган. Яңа 1985 ел алдыннан Азимовлар капкасы төбенә җиңел машина килеп туктый. Эченнән Алтыарык партия райкомының беренче секретаре һәм "Пахтакор" совхозының директоры килеп чыга. Алар Бувиниса ананы Яңа ел белән котлыйлар, үзләре белән алып килгән бүләкләрен бирәләр. Ике катлы йорттан үзенә бер бүлмә тәкъдим итәләр. Ошатса, ордерын да язып бирәчәкләр. Карап кайтырга теләсә, машиналарына утыртып алып барып күрсәтәчәкләр.

Бувиниса ана шатлыгыннан елап җибәрә. "Мин шушы йортта гомер иттем, калган гомеремне дә шушы йортта уздырырга телим, балакайларым,—ди.—Үземә бер кечкенә йорт салып бирә алсагыз, курабызда урын җитәрлек".

Иртәгесен совхозның баш инженеры биш кешелек комиссия белән килә. Бувиниса ананың йортын эчтән дә, тыштан да, астан да, өстән дә карыйлар. "Риза булсагыз, капиталь ремонт ясап бирәбез. Идән дә җәябез, түшәм дә түшибез, түбәсен дә эшлибез, Җиңүнең 40 еллыгына өлгертәбез, өегез яңадан да яхшы булыр",—диләр. Бувиниса ана үзенең Кулдаш улы белән киңәшеп алгач, ризалаша.

Икенче көнне үк зур бер машина белән төзү материаллары китереп бушаталар. Кызу эш башлана. Берничә көннән Бувиниса ана яңа түшәлгән идәндә келәмгә утырып чәй эчә. Ходай кушса, өенең түшәмен дә, түбәсен дә эшләп бетерерләр. Бервакыт стена аркылы гына яши торган Кулдаш улы килеп керә. "Әнием йоклап киткән икән",—дип уйлый ул. Иплә6рәк караса—әнисе мәңгелек йокыга талган икән...

Бу хәбәрне алгач, мин үземне кая куярга белмәдем. Нигә мин Юлдаш дустымның анасын, туганнарын элегрәк эзли башламадым икән? Берничә ел элек эзләп тапкан булсам да, кешечә шартларда азмы-күпме яшәп калган булыр иде бит! Терсәк якын—тешләп булмый, диләр, шул.

Бувиниса ана вафат булгач, совхоз машинасы килеп, төзү материалларын яңадан төяп алып киткән: фронтта һәлак булган сугышчының энесенә йорт ремонтлау каралмаган, дигәннәр. Аларга каршы нәрсә әйтәсең?

... Бер көнне шулай өйдә телевизор карап утырабыз. Бөек Ватан сугышы темасына документаль фильм күрсәтәләр. Бөтен экранга таныш йөз килеп чыкты. Мин: "Бу бит Юлдаш!—дип кычкырып җибәрдем. Җәмәгатем Гөлфия:—Ул түгелдер ул, аңа охшаган берәр казах егетедер,—диде.

—Ул, ул!—мин әйтәм.—Берниндн шигем юк.

Кем икәнен әйтмәделәр, рәсем астында язу да юк. Тик экранда күрсәтелгән фотоларның Совет Армиясенең Мәскәүдәге Үзәк музее фондында саклануын гына әйттеләр.

Киттем Мәскәүгә. Эштән сораласы юк—лаеклы ялда. Ул чакта Мәскәүгә барып кайту берни түгел иде әле. Үзәк музейдан эзләп таптым бит бу фотоны. Окоптан башы да күкрәге генә чыгып тора. Өстендә гимнастерка, башында пилотка, кулында бинокль. Фронтта төшереп алган булганнар. Бәхеткә ул Юлдаш дустымның анда саклана торган бердәнбер рәсеме түгел икән.

Төркем белән төшкән фотода безнең дивизиянең командиры Советлар Союзы Герое генерал Аскалепов хәрбиләр белән сөйләшеп тора. Рәсем астындагы язудан бу хәрбиләрнең соңгы операциядә аеруча батырлык күрсәткән солдатлар һәм кече командирлар икәнен аңладым.

Юлдаш Азимов генералның нәкъ каршысында басып тора иде...

*Яңа исемнәр*



## Наилә Миңнеханова

# СӨЮ ТАШЫ, НАЗ СҮРӘСЕ...

*Бу санда бер бәйләм шигырьләре тәкъдим ителә торган Наилә Миңнеханова—журналыбыз укучылары өчен яңа исем. Башкортстанның Туймазы шәһәрендә яшәүче Наилә ханым инде шактыйдан Уфада чыккан газета-журналларда күренеп килде. Алай гына да түгел, туксанынчы еллар ахырыннан Бәләбәй шәһәрендә уза торган "Илһам чишмәләре" исемле шигърият фестивалендә катнашып, шигырьләре хуплау табып, фестиваль лауреаты исеменә дә лаек булды ул. Фестивальдә катнашучылар иҗатын туплаган "Җәйгор" исемле күмәк җыентыкларда да күренде аның шәлкемнәре. 2003 елда исә Әхмәт Гадел кереш сүзе белән Яр Чаллыда "Сөю ташы" исемле мөстәкыйль китабы басылды. Аннары Туймазыда—"Күркә җиләк" исемле нәниләр өчен китабы дөнья күрде. Татарстан Язучылар берлеге каршындагы шигърият остаханәсендә дә аның иҗаты турында җитди сөйләшү булып узды.*

*Менә, ниһаять, бу үзенчәлекле, кызыклы шигъри дөньяга ия булган шагыйрә безнең журнал сәхифәләреннән дә укучылар күңеленә юл башлый. Хәерле сәгатьтә!—дибез.*

### Бәйрәм иртәсе...

Мичтә чатыр-чотыр утын яна,
Коймак туглый әни иртәдә.
Күзләремне йомып ятам әле,
Кояш нурын учлап сипсә дә.
Коймак майлый әни, җиз самавыр
Өйнең эчен кумгән буына.
—Бүген бәйрәм, Корбан-бәйрәм, кызым,
Тор инде, тор, чәем суына...
Хәтеремнән сайлап алыр идем
Коймак пешкән шушы иртәне.
Ак яулыгын чөеп бәйләп куйган
Әни булгач, өйләр бик ямьле!
...Әни табагачы миңа күчте.
Коймак белән сыйлыйм улымны.
Үткәннәрдән татлы хатирәләр
Килеп-килеп бүлә уемны.

***

Юләрләнәм инде әллә, Ходай,
Яшь кызмыни? Сөюемне яздым.
Сер тотмас дип азак йөрәгемне
Юри генә телгәләп тә алдым.

Канатланып сөюемне яздым.
Канат чәчә тышта гомер язым.
Ак көрт сырган яшьлек тыкрыгын.
Көрткә тагын бата-чума яздым.
Гашыйкмы мин? Акылымнанмы яздым?

## Сер йомгагым

Серле йомгак эчендә йомгак—сер.
Серле сандык эчендә сандык—сер.
Күңел охшаш матрешка курчакка,
Чишенеп төшә кайчак кыз чакка.
Бикле күңеленә күз йөгерттем,
Тылсымчыдай кулларым йөреттем.
Кулда Ачкыч... сер йомгагың сүттем.

## Ашыкмагыз әле...

Ашыкмагыз әле коелырга,
Яшьлегемнең шиңмәс гөлләре!
...Һәр тарафтан көлә миннән алар,
Уттай янгач һәрчак үзләре.
Ашыкмагыз әле үзгәрергә
Хыялымның зәңгәр күкләре!
...Җем-җем итеп елмая йолдызлар
Уттай янгач һәрчак үзләре.
Ашыкмагыз әле яңарырга,
Сагышларым, сынмам, түзәрмен.
Яшь аралаш елмая күзләрем,
Бәхет көтеп талган үзләре.

***

Уңмас юлга чыккан юлчы кебек
Тарала да тора йөгем дә...
Авыш-тәвеш атлый яшәү атым,
Синең кулда уем-дилбегәм.
Син дигәнем—Зур Сер, бергенәм!

## Ак ефәккә роза төшерәм...

Котлап синең туган көнеңне
Ак ефәккә роза төшерәм.
Яшьлегемнең татлы бер мизгелен
Бүген кабат искә төшерәм.
Язгы кичтә булган шул очрашу
Ташыта ла хисләр ташкынын...
Назлы елмаюың күрер өчен
Яшьлегемә кайтам ашкынып!..
Хәтеремдә әле бүгенгедәй,
Синең белән вальс биегән...

Әйтерсең лә, бар дөньяның яме
Синең белән миңа бирелгән!..
Хисләр ташты... Күзләр күзгә бакты —
Сөю уты капты йөрәккә!..
Пышылдады кайнар иреннәрең:
—Сандугач бул минем тирәктә!
Тирәгең синең мин булмадым...
Язмыш җиле илтте еракка—
Урау булды кайтыр юлларым...
...Котлап синең туган көнеңә
Ак ефәккә роза төшерәм.
Гүзәл кичнең татлы мизгелен
Кабат-кабат искә төшерәм...

## Яңа гасыр каршылаганда...

Җил—тегермән,
Кояш—сәгать булган,
Үлчәү булган Адым-күләгә...
Яңа гасыр килә ядрә төшле,
Компьютерлы камил галәмгә.

Тузан бөртегеннән әвәләнгән
Адәм күзли йолдыз галәмдә.
Йолдызларда Мәңгелекнең гаме,
Адәм гаме—төшке күләгә.

...Җил-гарасат, куба давыллар,
Гасыр белән гасыр алышына...
Атылалар җанда ук уйлар.

***

"Аласым да, бирәсем дә бетте"! —
Тынычланып йомдым күземне.
Бурычларым, төне буе, кармап
Чыкты—нәзек билем, тезем не...
Билдән аска ышанмаска өндәп,
Шайтан юатып йөрде үземне...

## Наз сүрәсе

Сөюнең текә катында
Ай-таганда атынам.
Һава ярып, Айга үрли —
Җил тагылган артымнан.
Йолдызлар җиргә атыла —
Хыяллары җирдәдер.
Учта сикерткән сабыйдай
Башым күккә тиядер.
Дөньям буялган ал төскә,
"Юк гамем һичбер эштә" —
Ашамыйм да, эчмим дә... —
Гүя мин бер фәрештә.

...Сөюем Наз сүрәседәй.
Мизгеле Вакыт кулында
Ак дисбе төймәседәй...

*Дискуссия: "Безнең заман герое"*

## ГАМӘЛЕНӘ КҮРӘ ӘМӘЛЕ

Үткән гасырның икенче яртысы башында үзәк газеталарның берсендә идеаль геройның нинди булырга тиешлеге турында дискуссия алып барганнар иде. Әйе, кешеләрне дә, яшәешне дә идеаль итеп күрергә теләгән вакыт иде әле. Әмма кешелек яшәеше, гореф-гадәтләре, күңел ачуга хаҗәт-омтылышы, азак килеп нәфесе күзлегеннән караганда бу абсурд—ирешеп булмастай мәгънәсез фаразлау булып чыкты.

Шуңа карамастан, әсәрләрдә идеальләштерелгән геройлар әвәләнде. Әлбәттә, сирәк булса да тормышта да идеальлек югарылыгына күтәрелергә тырышучылар да булмады түгел. (Аларның язмышлары турында фәлсәфә куертып тормыйк, үкенечкә таруыбыз ихтимал).

Вакытына күрә бу ярый һәм ярлы-ябагай, ярым надан килеш якты киләчәккә, коммунизм төзүгә исәп тотып алдынгылыкка омтылган яшьләргә мәсләккә ярашлы тәрбия бирү өчен бу шәп үрнәк иде.

Әмма вакыт үтү, халыкның аң дәрәҗәсе үсү, яман җилләрнең каян исүен аерачлый башлау белән идеальләштерелгән геройларга ышаныч кими, бетә башлады: алар катып калдылар, сүзләре үтми, эшчәнлекләре ышандырмый торганга әверелде.

Ничек, нишләп, дип гаҗәпләнәсе юк. Балык башыннан кортлады: илдәге эшчәнлек политикасы халыкны бушка эшләтүгә, хезмәтенә тиешенчә түләмәүгә; тирен генә түгел, канын сыгуга корылды. Законнар гадел таләп куючы гади халыкны якламады, аны юк кына гөнаһы өчен дә каты хөкем иттеләр, ә шаккатмалы гөнаһ кылучы идарә рычагы башында торучыларга җил дә, яңгыр да тимәде диярлек. Дөресе генә: аларны балдан алып майга күчерделәр. Закон сагында торучылар да аны ничек теләсәләр һәм түрәләр күрсәтмәләре буенча әвеш-тәвеш китерделәр. Мондый гамәлләр өстенлекләр белән файдаланучылар интересына эшләнсә, намуслы хезмәт ияләрен, дөреслекне яклап көрәшүче, тырыш эшчеләрне каралту, пычрату һәм хәтта юкка чыгару өчен коточкыч яла-ялган уйлап таптылар.

Факил Сафинның шушындый хәл-вакыйгаларны тирән һәм реаль ачып язган "Саташып аткан таң" романын ана рәхмәтләр әйтеп укыдым. Журналны укып баручылар роман эчтәлеген хәтерлиләрдер. Социалистик һәм коммунистик реализмның нигез ташы, халыкка мөнәсәбәте әнә шундый аянычлы кысуга, куркыту, изү, сыту, юкка чыгару алымына корылган иде.

Минем үзем кичергән бер хәл мондый гамәлләрнең бик яшәүчән икәнен раслаучы шаһит була ала. Колхозыбыз идарәсенең киңәйтелгән утырышы бара иде. Чыгыш ясаучы рәисебез Вәсфи Әкбәров дуңгызчылык фермасында эшнең начар булуы, үрчемнең күпләп үлүендә, мине—авыл клубы мөдире буларак—агитацион эшне нәтиҗәле алып бармауда гаепләде, бөтен житешсезлек шуннан килеп чыга дип раслады. Ә шуны КПСС райкомының идеология секретаре Мәснәви Камалов канәгать төс белән тыңлап утырды. Утырды һәм мәсьәләгә кискен ачыклык кертәсе урында бер авыз сүз катмый торып та калды. Бу хәленә эчтән генә булса да ояла яки гарьләнә белгәндерме-юкмы, анысын аңлау мөмкин түгел иде.

Сүздә исә: "Партия халык өчен яши", "Партия һәм халык бердәм" диделәр. Яшәешнең асылын гына яшерделәр. Чөнки яшәү рәхәтен КПСС райкомы, район

Советы башкарма комитетының эреле-ваклы пост биләүчеләреннән башлап югарыга таба барысының да ожмахка тиңләштерүгә корылган иде.

Ачның хәлен тук белми—алар әнә шулай байлык тудыручы гади эшчәннәрнен ничек яшәве белән чын күнелдән кызыксынмадылар, моны риясыз кайгыртмадылар диярлек. Үзләренә каршы исә авыз да ачтырмау дәрәҗәсенә күтәрелделәр, бер җөмлә тәнкыйть өчен кемсәне кешелектән чыгарып ташладылар, эшеннән кудылар. Моны ничек эшләү, тормышка ашыру алымнарын алар яхшы беләләр иде.

Мина, авыл хәбәрчесе булудан башлап, бер район редакциясендә егерме бер ел, шуның күпчелеген редактор урынбасары буларак эшләргә туры килде. Вазифам буенча райкомның бюро утырышларында да катнашылды. Шунда сафына компартияне гаделлекле, кешелекле дип кергән кеше буларак, секретарьларның оятсызлыгына, башбаштаклыгына, колхоз, предприятие житәкчеләре гаебе өчен белгечләргә, урта звено кадрларына, гади коммунистларга чыркылдатып җәза биргәннәрен, бер кадерләрен калдырмый суккәннәрен күреп, аз тетрәнергә туры килмәде.

Мондый оятсызлык халык контроленен район комитеты утырышларында дәвам иттерелде. Анда инде хөкемгә КПСС әгъзасы булмаганнар да җәлеп ителде, аларның кесәләренә үк кереллде. Болар менәрләгән намуслы һәм йөзеп эшләүче коммунистлар тәшкил иткән партия исеменнән башкарылды. "Халык өчен яшәү" асылы әнә шуннан гыйбарәт иде. Әлеге көнгә кадәр бит халык тормышы, хезмәт, яшәү шартларын яхшырту турында сайлаулар алдыннан һәм сайланганчы гына тиреләреннән чыгарга житешеп "кайгырталар". Сайлангач кына ничек тә ярыйга әверелә.

Ярый әле хәзер бу турыда әйтеп, күнелне бушатып була. Газета хезмәткәре буларак элек райком секретарьлары, райбашкарма комитеты, аның органнары хезмәткәрләренең гаделсезлекләрен ачынып искә алып: "Нигә болай ул, нигә шул тиклем оятсызланалар, нигә аларга закон юк?" дип мөрәҗәгать итәләр иде мина зур ышаныч белән яшерен рәвештә. Бик унайсыз була иде...

Әйе. Халык барлык этлекләрне, әшәкелекләрне белеп-күреп яшәде һәм мона каршы бер нәрсә дә эшли алмагач, кулын селтәде, проблемаларны хәл итүдән читләште, тыныч яшәүне кулай күрә башлады. Әнә шулай битарафлык туды, бик тиз гыйфрит дәрәҗәсенә күтәрелде.

Битарафлык гыйфритенең берсен әсәрләре яратып укыла, гыйбрәтлелеге белән күнелгә сенеп кала торган авторларның берсе Камил Кәримов "Сакау күке" романында ("Казан утлары", 7, 8, 9 саннар, 2003 ел) бөтен фажигасе-аянычлыгы белән ачып күрсәткән. Битарафлык—кансызлык һәм кешелексезлек туганы да икән әле. Моның шулай икәнен раслау өчен әсәрдән отышлы тасвирланган кыска гына эпизодка күз салу да житә.

"Яр өстеннән физкультура укытучысы узып бара иде.

—Рәкыйп абый! Марсель батты...

—Ул ташбаш батканчы әле...

—Житмешкә хәтлек санадык инде, чыкмый.

—Сездән качып йөзеп киткәндер, яхшылабрак эзләгез!

Рәкыйп абый китте. Малайлар шомнан арына алмады..."

Ә бит Марсель баткан тугай күз алдында, су аслап качып йөзеп китү мөмкинлеге дә юк!

Битарафлык чире йокмаса, Рәкыйп малайның чумган жиреннән житмешкә кадәр санаганчы чыкмавы турында ишетү-белү белән киемен йолкыштырып атып, тугайга ташланыр, аны алып чыгып, ясалма сулыш алдырып карау чарасын күрер иде...

Кем-кем, малайлар белән әвәрә килүче, аларның аталарына тин тәрбияче әле генә баткан баланы үлемнән коткарырга тырышу урнына, ни жаны беләндер: "Ул ташбаш батканчы әле..." дип, берни булмаган сыман китеп бара. Мондый бәндәне кеше дияргә тел бармый) битарафлык гыйфрите дими, кем диярсен? Их, андыйлар йөзгә бер дә, менгә бер генә булса икән?!

Чикләнмәгән законга яки законсызлыкка ия булу, властьтан үзләре теләгәнчә файдалана алу мөмкинлеге сонга таба привелигияле идарәче катламның нәфесе азуына, туемлыгы ертылуга китерде. Бер бажабыз дуамалланып, обком каравылы начальнигы булып бик яхшы эшләгән жиреннән, артта сөйрәлгән туган колхозын торгызырга исәп тотып, үзе теләп рәис булып кайткан иде. Ул бервакыт:

—Райкомнан узып берни эшләп тә, майтарып та булмый икән. Алай гынамы! Күптән түгел генә "первый", югарыга бирергә кирәк дип, шактый гына акча сорап алып китте. (Кемнәрдән ә?!). Бухгалтерыбыз бу сумманы кая куярга, нишләтергә дә белми изалана, дип зарланды.

Авыл хуҗалыгы тармагына кураторлык итүче икенче секретарь колхозларның берәрсеннән һәр елны бик зур сыер алып кайта (ничек, нинди суммага алганын белмим, бу яктан гонаһына керер хәлем юк), күзгә кадәр йортта ашатып симерткәч, "зыянлап" аны суялар, итен кыйммәт бәядән ресторанга илтеп сата иде. Колхозчыларның барлы-юклы малы—бозавын—исә очсыз бәягә мәҗбүри-ихтыяри рәвештә колхозларга җыялар иде.

Аппетит ашаганда барлыкка килә. Хәзерләүләр конторасының куәтле заманы, болай да сәүдә органнарының арткы ишекләренең хутлы заманы иде әле. Дәүләткә халыктан авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү өчен дефицит әйберләр кайту белән аларны "икенче" барып карамый, үзләренә файда китерердәйләрен аерып алып куярга сайламый торып, беркая җибәрергә рөхсәт ителмәгән. Аерып куелган товарны бәясен арттырып сату өчен республиканың башкаласына озата торган булганнар. Өченче секретарь белән оештыру бүлеге мөдире район китапханәсе фондына кайтарылган сайланма томнарны үзләштерергә тырышканда фаш ителделәр.

Көч түкми, җинел кәсеп белән байлык тупларга һәвәсләр өчен дә, авызын ачса үпкәсе күренергә торганнарга да отышлы һәм менә дигән үрнәк булды болар. Әнә шулай ришвәт алуны да, спекуляцияне дә, талауны да идарә органнарында эшләүче, боларны булдырмау өчен көрәшергә тиешле шәхесләр үзләре башлап һәм күпертеп җибәрделәр. Китте кода-кодагыйлык, эчкечелек. Кем ничек булдыра шулай таларга, йолкырга керештеләр! Ә зур калҗа өчен көрәш көндәшләрен, комачаулаучыларны, дәүләт байлыгы сагында намуслы торучыларны үтерү-үтерттерүдән дә тартынмауга китереп җиткерде.

Мондый хәлгә мөмкинлек закон, тәртип сагында торучыларның үзләренен коррупциягә тартылулары, җинаятьләргә битараф караулары, җинаятьчел юлга басулары, моңа булышлык итүләре нәтиҗәсендә барлыкка килде.

Камил Кәримовның югарыда искә алынган романында моңа да мисаллар бар. Утыз ел буена артезиан чишмәләре бораулап, бу эшнен рәте беткәндә аңа мирас итеп бирелгән, кучергәндә тягач машинаның суы кайнап, юл буенда калдырылган вагонында йоклаганда уятып кереп ГАИшниклар тикшергәндә, күптән ташлап киткән әтисе Фазыл Шәмсетдинов белән лейтенант Салих очраштылар. Командиры эшнең нәрсәдә икәнен абайлап алгач, тикшерүне тупас алып баручы юл-патруль хезмәте инспекторына болай ди: "—Шабаев! Бар, машинаны сакла, селектордан берәр хәбәр килмәгәе, җомга бүген—аварияләр көне!..

...

—Мин соң нәрсә, бик теләсәгез, икегезне генә калдырам...

Һәм ул Фазыл алдында мескен булып күренмәс өчен өстәп куйды,—бу зимагурны бер йөз граммлык кына исерек иде, дип, акт яза торыйммы?.."

Икенче очрак тагын да кәттәрәк. Салихның дәү әтисе Әмир төнлә эш урынын—ярга ныгытып беркетеп куелган баржаны—кузәтүчесез калдырып сөяркәсе фатирына барып куна. Ул аннан килгәндә төнлә ташыган Идел баржаны "йоткан" була. Әмир бу хурлыктан качып, сөяркәсе Фирая фатирында качып яши башлый. Аны баржа белән бергә һәлак булган дип уйлап инде "өчесен" дә уздыралар. Әмма Фирая телефон аша Салихны табып дәү әтисенең исән һәм аның янында икәнен хәбәр итә. Оныгының бабасы белән күрешкәч ике арада булган сөйләшүнең безнең игътибарга лаеклы түбәндәгедән гыйбарәт:

—Балакаем, бу хурлыктан исән-имин котыла алмам шул.

—Ялган җәрәхәтне ялган шифа белән төзәтергә була. Телевидение белән сөйләшүне үз өстемә алам. Минем эштә мондый хәлләргә беркемнең исе китми. Кеше исән калган икән—сөенерләр генә...

Дөньяны шаккатырып һәм калтыратып торткан заман геройлары искә алынган персонажлардан гыйбарәт түгелме? Әгәр К. Кәримов соңгы очракта Салихны уңай герой итеп тасвирласа моңа ышанучылар табылыр иде микән? Ышанган очракта да ясалма геройларга кызыгу, охшарга тырышу заманы үтте шул. Чөнки бу отышлы да, уңай да түгел. Кыргый капитализм, алдауга корылган базар безгә үз таләпләрен куя, яшәү өчен башкача җайлашырга мәҗбүр итә. Тормышның бит юньле, ныклы юлга төшеп житә алганы юк әле. Шушы максатта үткәрелгән реформалар да карт аю сыман бик акрын кыймылдыйлар. Аннары нинди дәүләттә, нинди стройда яшәгәнне дә өзеп кенә әйтә алмыйсыз. Шуңа күрә дә күбрәге нотасы чуалган кичәге музыкага биергә туры килә.

Радик Фәизов дискуссиягә катнашып "Алар безнен арада" дигән мәкаләсендә *(Казан утлары, 2 сан, 2004)* бер тәнкыйтьченен "бездә бүгенге көн татар әдәбияты

юк, ул үткәннәрне хәтерләүдән генә тора" дигән фикерне әйтте" дип язган.

Шулай, "Юк" дип мөһер сугу җинел бит ул! Өстәвенә бик белдекле булып, бер ялтырап та аласың. Эзләнәсе, чокынасы да юк... Ә менә булдыруы, заман вәзгыятен бик сизгер компас та тәгаен генә күрсәтә алмастай заманда язучыларга кыйбланы билгеләү бер дә җинел түгелдер. Җитмәсә ул вәзгыять көзге кәефсез көннәрдәге сыман еш алмашынып торганда.

Үткәннәр турында язу исә, гыйбрәт бирү, хаталарны, җитешсезлекләрне кабатламау, кисәтү өчен кирәк. Әдәбият тормыш-яшәешне реаль чагылдыруы белән игътибарга күбрәк лаек иң. Хәзерге кешеләр белән акча галиҗәнәпләре кайчандагыдан булса да дәһшәтлерәк идарә иткәндә (бу бер дә яхшы фал түгел) тормышның җилеге, эзенә төшенеп кара син?! Бүгенге офыкта менә дигән һәм искитмәле мактаулы затлар калкып чыгалар... Карыйсың, күп тә үтми, алар хөкем алдына баскан була!

Коммунизм төзү стадиясенең беренче баскычы дип аталган социалистик формациянең яшәешебез нигезен какшаткан ике зур җитешсезлеге булды. Аның беренчесе әхлагыбыз сагында торган динне тыю булса, икенчесе—күмәк хуҗалыкларның хуҗасызлык, таркаулыкларга юл ачуы булды. Хуҗа юк икән, конкрет җавап тотучы да булмый. Мона мисаллар җитәрлек.

Район буенча техниканың кышкы сакка ничек куелуын тикшерергә булгач, мине авыл хуҗалыгы идарәсенең баш инженеры белән бергә Калинин исемендәге колхозга билгеләгәннәр иде. (Элекке тракторчы, белемем буенча агрофакны бетергән кеше буларак авыл хуҗалыгы эшләре белән яхшы таныш идем).

Журналист буларак бер көн алдан шалтыратып, колхоз рәисеннән техниканың сакка куелуы ниндиерәк хәлдә дип белештем. "Нормада" диде ул көр күңел белән. Ә парктa? Анда комбайннарның яртысына диярлек басудан кайткач, кул да тимәгән булып чыкты. Тикшерүче коллегам үз кимчелеген, гөнаһын да йомып калдыру максатында булса кирәк, нәтиҗәләрне барлаганда җитешсезлекләргә җинелчә генә кагылып, беркемнең дә кәефен зурлап кырмау позициясенә басты. Бүгенге көнгә дә хас күренеш түгелмени бу? Сирәкләп булса да андыйлар турында газеталарда язып та, телеэкраннардан күрсәтеп тә торалар әнә.

Колхоз рәисе бик якыннан таныш, бик гарьчел кеше булса да, мин алай эшләргә тиеш түгел һәм алай эшли дә алмый идем. Борычлап-тозлап чыгыш ясадым. Күпме шлангның шартлап, сегментлары тутыгып күпме ургыч пычагының юкка чыгачагын чутлап, аларны алу өчен савучыларның тубыктан дигәндәй пычрак ярып, абзарда тизәктә йөзеп никадәр сөт саварга тиешлекләрен, моның өчен кемнәрнең гаепле икәнен атап күрсәттем. Дөрес сүзгә җавап юк, берсе дә үпкә-сапка белдермәделәр. Аның каравы, икенче тапкыр баруыбызга комбайннарны чистартып, тулысы белән тәртипкә китереп куйганнар иде. Әнә шундый кыймылдый алучанлык, кыймыллату җитеп бетми әле булса шактый урыннарда, өлкәләрдә. Кода-кодагыйлык һәм кәефне бозмаска тырышулар исә начарлык һәм җитешсезлекләрне бетерүгә ярдәм итмиләр.

Соңгы вакытлардагы яшәешнең чәчәк атучы төп критерийлары нидән гыйбарәт, оптимизмга урын бармы? Перспективалар өметлеме? Мина калса: "Алга—гомуми әхлаксызлыкка! Алга—берәүләрнең баюы, күпчелекнең хәерчеләнүенә, ятимлек, бомжлыкка! Алга—үлем-кырылуны тизләтүче эчкечелеккә, алкоголизмга, наркоманлыкка, никахсыз ирекле мәхәббәтне тырышып пропагандалап, дәвалап булмый торган СПИД авыруын кызурак темплар белән таратуга!"—кебек лозунглар күтәреп чыгасыбыз гына калып бара түгелме? Әнә нинди зур һәм күпме геройлыклар эшләү мөмкинлекләребез файдаланып җиткерелми тора?! Чөнки заманыбызның санап үтелгән яңалыклары, геройлары турында тулы канлы һәм модага кергән шаккатырмалы әсәрләр чыннан да юк диярлек бит. Бу унайдан сынаталар язучыларыбыз. Жал, бик жал! Хәер, аларны язып мәшәкатьләнмәскә дә ярыйдыр. Эшләр шулай барса, барыбер аларны укучы булмаска да, укыр кеше калмаска да мөмкин иң!

Ямьсез яңгырый, ә? Булса-була инде! Күләгәннән качып булмаган кебек, боларны да яшереп булмый һәм яшерергә кирәкми дә. Юкса, элек яшереп караганнар иде дә, бу аларның яңгырдан соң калыккан гөмбәләр сыман үрчүенә шартлар тудыру булып чыкты, каһәрең.

**Хатип ГАЙСИН**

**Адлер Тимергалин**

# МИЛЛИ КАЗАНЫШ

## МИЛЛИ ҺӘЙКӘЛЕБЕЗ— "ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯ СҮЗЛЕГЕ" БАСЫЛЫП ЧЫГУ УҢАЕННАН

Моннан ун ел элек Татарстан республикасы Фәннәр Академиясе каршында төзелгән Татар энциклопедиясе институты, ниһаять, бөтен татар җәмәгатьчелеге зарыгып көткән тәүге җимешен бирде. (Мин бертомлык "Татар энциклопедия сүзлеге"нең татарчасын күздә тотам, анын русчасы 1999 елда ук басылып чыккан иде.)

Милләтпәрвәрләребез мине аңлар, шуңа күрә шәхси шатлык-куанычларыбызны тәфсилләп торуны кирәксенмим. Китап белән танышканчы ук мин аны иң түргә, "Коръән" һәм "Библия" белән янәшә куйдым. Хозурланып карап тордым. Танышканнан соң да ул дәрәҗәле урынында калды.




Рәхмәтлебез, энциклопедияче әфәнделәр! Милләтебез йөз ел көткән бүләк бу.

Шөбһәсез, "Татар энциклопедия сүзлеге" соңгы елларда татарча басылган китапларның иң асылы, иң затлысыдыр. Татар җанлыклы һәркем өчен ул бәйрәм игълан итте. Чөнки без шуны яхшы беләбез: Энциклопедиябез яшәгәндә, без дә яшибез дигән сүз. Горурланып: "Тарихта эзле без, әсәрле без",—дибез.

Энциклопедик сүзлек—ул безнең Янарыш билгесе, татар Ренессансының күркәм бер дәлиле, инкыйраз дигән афәткә каршы саллы бер корал.

Үзенең фәнни принциплары һәм эшләнеше ягыннан Сүзлек безнең бүгенге күпчелек ихтыяҗларыбызга җавап бирә. Һәр укучы монда үзен кызыксындырган мәсьәлә яки тема буенча ризык табачак яисә алга таба эзләнү өчен төпле күрсәтмә, юнәлеш алачак. Энциклопедияләргә гомумән хас булганча, бу күркәм китапны актарып утыру гына да ләззәт бирә, уйландыра һәм ышандыра, куандыра һәм хәтта борынгыны, үткәннәрне сагыну хисе уята...

Минә гомеремдә байтак энциклопедияләр актарырга туры килгәне бар һәм мин үзебезнең бу Сүзлегебезне аларның берсеннән дә кайтыш дип санамыйм.

Аның теле аңлаешлы, төзек әдәби тел. Күләменә нисбәтән, сирәк-мирәк күренгән кимчелекләрне исәпкә алмаганда, зәвыклы тел дияр идем.

**Сүзлекнең бүгенге елгыр газитчеләр чиренә бирелеп, төрле—"Алманияләр", "Аурупалар", "санаклар" кебек соңгый төрекчелек шаукымыннан, корама ясалмалыктан табигый миллият калканы белән саклануы, ләкин түбәтәй өстеннән кәләпүш киеп кыланчыкланмавы да күңелгә хуш килә.**

**"Татар энциклопедия сүзлеге" кайберәүләр өчен объективлык үрнәге дә булырлык. Мәсәлән, безнең Сүзлегебез, "Башкортостан. Краткая энциклопедия"дән үзгә буларак, башка халыкларга ихтирамлы һәм игътибарлы булуы белән аерылып тора. Кайчагында хәтта болай ук тыйнак булу да әйбәт сыйфат түгелдер, ахры, бу заманда, дисең. Хәттин ашкан милләтчелеккә бирелеп, ертлач рус кенәзләре үрнәгендә: "се мое, а то мое же" дигән оятсыз принципны тотучы "ут күршеләребез"нең уйдырмалары белән көрәшүдән дә тайчанмасын иде Сүзлегебез, дисең. Әйе, кайчагында ана галәл усаллык җитми шикелле.**

Хәер, гаепләп маташмыйк, Сүзлегебезнең алтын сабырлыгы, тулаем алганда тыныч стиле һәм гомуми культурасы белән горурланыйк кына.

Минем бу мәкаләм "Татар энциклопедия сүзлеге"н күкләргә чөеп мактауны да һәм, әлбәттә, сагынып көтеп алынган изге китапны тора салып яманлауны да күздә тотмый. Мин фәкать Сүзлек белән танышканда үземдә туган фикерләр һәм тәкъдимнәр белән бүлешмәкче булам. Сүзлек-энциклопедияләр белән гомерем буе кызыксынганга, әйткәнемчә, мин бу өлкәдә җитәрлек тәҗрибәм бар дип уйларга җөрьәт итәм.

Фикерләремнең шактый җитдиләре, русча версиясенә кагыла торганнары да бар, бәхәслеләре дә очрар. Әмма бу фикерләр киләчәктә чыгачак энциклопедия томнарын тагы да яхшыртырга ярдәм итәр дип өметләнәм. "Тәнкыйть—кирәкле шәйдер". Кулыбызга кергән бертомлык та кат-кат басылыр әле, димәк, аны да камилләштерергә мөмкинлек туар...

Энциклопедик сүзлекнең фәннилек дәрәҗәсе һәм тирәнлеге һәм колачы да телнең камиллегенә, җитлеккәнлегенә турыдан-туры бәйле, әлбәттә.

"Татар теле гүзәл вә бөек тел" дибез. Ләкин бу сүзләр аюның да баласын "аппагым" дип, ә керпенең "йомшагым" дип сөйгәнен хәтерләтә бит. Чуаш теле—чуашка, башкорт теле башкортка гүзәл һәм әһәмле тоелмаса гаҗәп булыр иде.

Берләшкән Милләтләр Оешмасының тел комиссиясе татар телен дөньяның теләсә кайсы почмагында аңлашып була торган 14 телнең берсе дип игълан итте. Чыннан да, әйтик, төрек теле төрки телләр арасында иң күп таралганы булса да, ул гомумтөрки типтан ераграк тора, ә татар телендә тугандаш телләр белән уртак тамыр сүзләр проценты күбрәк. Гарәп һәм фарсы алынмалары татар телендә гамәли лексиканың өчтән берен алып тора, Көнбатыш Европа һәм рус сүзләре исә 10-15 процент тәшкил итә. Соңгы вакытларда рус алынмаларын гарәп-фарсы сүзләре һәм гомумтөрки тамырлы сүзләр кысрыклавы сизелә. Бу процесс тагы да дәвам иткән очракта, уртаклык индексы тагы да югарырак булыр дип көтәргә мөмкин. Әмма яңа сүзләр уйлап чыгару белән мавыкмаска, төрек теленең XX гасырда ясалма сүзләр хисабына сикерешле үзгәрүе аркасында килеп чыккан катлауlануларны булдырмау, өлкән буынның яшь буынны аңламый башлавын кисәтү чарасын күрергә һәм уртаклык индексын киметмәскә тырышырга кирәк, чөнки татар телен әлеге 14 тел исәбенә керткән күрсәткеч—нәкъ менә шушы уртаклык.

Гаяз Исхакый "Бүген үзен төрек дип йөргән госманлы төрекләреннән, Төркестан вә Кавказ төрекләреннән төреклек каны һәммәсеннән бездә артыграк",—дип яза. Аның кул астында булган мәгълүматлардан Идел буендагы халыкларда туран каны 96%, Төркестанда 56-60%, Төркиядә 16%, Кавказ төркиләрендә 50% тан түбән икәнлеге күренә (Гаяз Исхакыйның 1954 елның апрелендә язган хатыннан). Татар теленең гомумтөрки типка аеруча якынлыгы бу фактлар белән бик әйбәт аңлаша.

Болары шулай.

Әмма төп мәсьәлә шунда: без, кардәшләр, ана телебезне көчле, гайрәтле һәм җитлеккән тел дип әйтә алабызмы соң? Ана үлү, бетү, югалу куркынычы янамыймы? (Галимнәр дөньядагы 6000 телнең фәкать 600 енә генә үлем куркынычы янамый диләр.) Соравымны кабатлыйм: без ана телебезне һәртөрле агрессиядән саклана алырлык гайрәтле тел дип әйтә алабызмы?

Юк, без әлегә күкрәк сугып моны әйтә алмыйбыз. Татар теле колачлы һәм тотрыклы фәнни терминологиягә ия булмаганга, без еш кына бичара хәлдә калгалыйбыз һәм, аптырагач, әлеге дә баягы рус теленә ("үги ана" телебезгә дип әйтимме?) мөрәҗәгать итәргә мәҗбүрбез.

Энциклопедик сүзлектәге мәгънә төгәлсезлекләре күп очракта татар фәнни терминологиясендәге житешсезлек бәласе бит. Әле кайчагында энциклопедия редакторларының ифрат кыен очракларда да, бик специфик темаларны татар теле чаралары белән ача алуларына сокланасың. Моңа мисаллар күп, бу Китапта сүзлекчеләребез әйләнешкә кертеп жибәргән унышлы неологизмнар турында диссертация якларлык материал бар. Тел белгечләре өлгермәсә, мин үзем бу хакта бер күзәтү мәкаләсе язаргамы әллә дип кызыгып куям.

Энциклопедик сүзлекнен лөгатьлеге, фикер алышу өчен, элегрәк бастырып җәмәгатьчелеккә таратылган иде. Әгәр нәшер ителгән Сүзлекнең эчтәлеген шул лөгатьлек белән чагыштырсак, без аның нык кына киңәйгәнен күрәбез. Әлбәттә, Сүзлек русча версиясеннән дә баерак һәм калынрак булып чыккан.

Рәхәтләнеп танышканнан соң, мин, әйткәнемчә, Сүзлекне киләчәктә тагын да киңәйтергә, үстерергә мөмкин дигән нәтиҗәгә килдем һәм Энциклопедиябез 5 том гына түгел, кимендә 6 том булырга тиеш дип уйлыйм.

Бүген без үткән көннәребезгә яңа күз белән карап, кичә булган вакыйгаларның эчке механизмын, сәбәп-нәтиҗәләр чылбырын белгән хәлдә, тарихыбызга тирәнрәк үтеп керә алабыз. Кичәге "шома" бәяләмәләр бүген капма-каршысы белән алмашынса да гаҗәп түгел. Чыннан да Сүзлекнең лөгатьлеген төзүгә 90 еллар башында ук керешелгән иде, ә соңгы ун ел эчендә күпме үзгәрешләр булып өлгерде. Без үзебезнең галәмебезгә, мәдәниятебезгә, шул исәптән әдәбиятыбызга да яңача карый башладык. Кичәге түрәләр инде мотлакый авторитет түгел, күбәүләр "тәхеттән төшерелде", кара ягылган зыялы милләттәшләребез акланды һәм реабилитацияләнде. Димәк, сүзлекчеләргә тормыштан калышмаска тырышырга кирәк булган, ләкин Энциклопедия кебек гаять зур һәм четерекле эштә соңгарак калсалар да гаеп түгел.

Коллык, мескенлек тойгысыннан арыну бик читен. Антон Чехов үзенең күнелендә сеңгән коллык хисен гомере буе тамчылап сытып чыгарырга мәҗбүр булуы турында яза... Табигый, совет чоры шаукымы энциклопедик сүзлегебездә дә шактый сизелә әле. Анда теркәлгән шәхесләргә игътибар итсәк, персоналияләрнең байтагы совет чоры түрәләре, "урындагы кешеләр"—өлкә комитеты секретарьлары, югары дәрәҗәле чиновниклар, түшләренә калай таккан эреле-ваклы функционерлар һәм аларның куштаннары, ягъни сөрсеп беткән бюрократлар икәнен күрәбез. Өстәвенә биографияләре шактый бизәкләп бирелгәнгә, алар эшләгән дәвердә ирешелгән уныш-казанышлар гел аларныкы сыман булып кала. Ә бит совет чоры экономикасының төп кануны "ике икең—дүрт" кебек гади, примитив, аны, халык сүзе белән, "итәкне кисеп җиң ялгау" дип әйтергә була. Әгәр совет чорында халык хуҗалыгының берәр тармагында уныш казанылган икән, һичшиксез, икенче өлкәсендә торгынлык яки хәтта чигенү күзәтелмичә калмый. Без әле бүген дә шул чирдән арына алмый интегәбез, чөнки идарәчеләребез әүвәлге парт-школярлар яки аларның шәкертләре бит.

Сүзлектә шундый хаталарга күп урын бирелгәнен күргәч, хәтта моның объектив сәбәпләрен белгән килеш тә, күнелдә ризасызлык тумыйча калмый.

Советлар Союзы Коммунистлар партиясе турындагы белешмә тешкә тияр дәрәҗәдә озын һәм партбилетын секретерена яшереп кенә куйган большевик каләме белән язылганга ошый. Артык сүз ычкындырмагаем, ул-бу булмагае дибрәк язылганмы?

Юк, җинаятьчел КПСС турында гәп куертып торасым килми. Аңа карата "Долой!" дигән сүз генә урынлы.

"Татар энциклопедия сүзлеге"нә теркәлгән "Рабфак"лар турында берничә сүз.

Ликбезлар, рабфаклар, партшколлар ("партмәктәпләр"!), кызыл профессура—болар бер үк чылбыр буыннары һәм аларны, әлбәттә, "нужа тудырган". Заманында генсек Иосиф Сталин, илдәге чын зыялыларны, интеллигенцияне планлы рәвештә кырып бетергәч, "Кадрлар барын да хәл итәләр" дигән "канатлы" лозунгысын әйтеп ташлаган иде. Шуннан кадрлар житештерү буенча большевистик конвейер бөтен көченә эшли башлады. "Пырлитар" язучысы Мәхмүт Максуд "Матур әдәбиятта эшчеләрдән кадрлар житештерү турында" кебек мәкалә язып, "даһи юлбашчының" идеясен хуплап күтәреп алды. Шунысын да әйтеп китик, бу мәкалә

зыянсыз бер нәрсә булып чыкмаган. Автор монда халык дошманнарының исемлеген дә төзеп бирә (Ф. Бурнаш, М. Бөдәйли, Ф. Агиев, Г. Касыймов...)

Ильич әйткән "кухаркалар"дан ашык-пошык әзерләнгән ачкүзле кадрлар, илнең дилбегәсенә чытырдатып ябышып, кул-аякларыбызга зынжыр богау салгач, чыннан да барын да хәл иттеләр—70 ел эчендә "барын да һәлак иттеләр" дип әйтсәк дөрес булыр. Бүгенгесе көндә дә шушы рабфакчы, партшколяр һәм "кызыл профессура" оныклары илне, рухиятебезне, иманыбызны җимерү эшен дәвам итәләр.

Рабфак һәм партшколаларның файдасыннан бигрәк зыяны күп булды. Әйткәнемчә, Рәсәйне шушы җаһил карьеристлар идарә итә башлады. Партия чәчеп үстергәнгә күрә, алар ана эт шикелле тугрылыклы булдылар. Гаепләре ачыла калса, аларны кайчагында тагын да җаваплырак икенче постка гына күчерделәр, кайчагында берәр чит илгә илче итеп җибәрделәр, чөнки гомер-бакыйга билгеле иҗ: "карга күзен карга чукымый". Черек күлнең ин хәйләкәр һәм нечкә сексотлары да шулардан чыкты. Сөекле Такташыбызның—"үзе болай бер дә усал түгел кебек шикелле" рабфак студенткасы да, "көчлеләр", хакимиятләр ягына басып, ахырда шагыйрьнең зәңгәр күзләренә төкерде...

Иксез-чиксез Рәсәй матди һәм рухи бөлгенлеккә төште... Ялган экономика, ялган фән һәм ялган сәнгать, ялган матбугат тудырган аянычлы нәтиҗәләрдән менә ничәнче ел инде арына алмыйбыз.

Әлифбабызны кат-кат югалтып, мәдәният гыймаранын кабат "нуль кимәленнән башлап" торгызырга мәҗбүр итүчеләр дә нигездә әлеге кызыл профессорлар.

Генетиканың бөек ачышларын кире кагып, советчыл Мичурин—Лысенко биологиясе уйлап чыгаручылар, бөтен дөньяны ипи белән тәэмин итә алырлык илне ачтан тилмертүчеләр дә шулар.

Ә хәзер? Ә бүген?

Тәгәлләнми калган революциядән дә яманрак нәрсә юк.

Болгавыр чорга хас булганча, "кызыл профессура" урынына яна профессура килеп маташа. Әрсезләр, ерткычлар.

Моннан дүрт-биш ел гына элек бер күптәнге танышым, голәмәләр дөньясында академиклар ишәя башлагач, 20-30 еллардагы "кызыл профессура" белән, үзе әйтмешли, бүгенге "агач академиклар"ны чагыштырып маташкан иде. Бу чагыштыру әлеге күренешнең беренчел сәбәпләре һәм котылгысыз нәтиҗәләре турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә дә шикелле. Чыннан да, галим-голәмә арасында Тукай әйткән "тиле ярыш" башланды түгелме? Мин әлеге танышым белән килешә язган идем ул чакта. Менә бүген аның үзенең дә "тиле ярышка" кушылып, академик дәрәҗәсе алганлыгын ишеттек. Йогышлы чир, яман кизү намус иясен дә аямаган... Хәерлегә булсын. Мәскәүдә дә шул ук хәл дип тынычланырга ашыкмыйк, чөнки анда капма-каршы (гадел) көчләр дә хәрәкәт итә, алар исәннәр. Менә икенче ел инде, яна академиклар сайлауга мәскәүләр житдирәк якын килә башладылар.

Якын тарихыбыздан мисал китерим әле.

Әйтик, бер өлкә комитеты секретаре Гаяз Исхакый турында: "Мин барында Исхакый басылмаячак!" дип кистереп әйткән. Әлләни күптән дә түгел, шушы номенклатур зимагурның, җирсенеп: "Татарстаныма кайтып килер идем" дигән теләге бар дип ишеттек. Сүзлегебез шушы бәндәгә: "Юк инде, брамат, "Татарстаным" дип әйтергә хокукы булган кешенең илендә Исхакыйны да булырга тиеш!"—дигән хакыйкатьне аңлатсын иде.

Мин мондый әтрәк-әләмнәрне Сүзлеккә теркәмәскә димим. Калсыннар әлегә. Ләкин җирле һәм үзәктәге комсомол, КПСС һәм профсоюз "эшлексезләре", халыкның җелеген суырган совет функционерлары һәм тоталитар режимның башка ялчылары турында бирелгән мәгълүмат житәрлек каләр кыска, саран һәм һич югында "салкынчарак" булсын. Хәзергә шул житә. Киләчәк аларны үзе сызып ташлар. Тенденция шундый. Мәскәүдә чыгачак яна 30 томлык "Русская энциклопедия"дә мондый эшлексез эшлеклеләр"гә урын бермә-бер азрак биреләчәк дип хәбәр иттеләр. Мәскәүләрдән, шәт, калышмабыздыр.

Менә шушы парт-совет функционерлары биографияләрен бер-ике җөмләгә яки абзацка кыскарту хисабына Фараби, Әбугалисина кебек йөзләгән гомумтөрки һәм гомуммөселман бөекләренең тормышын, иҗатын һәм бөтен кешелек дөньясы өчен дә мөһим карашларын киңрәк яктыртырга мөмкин булыр иде.

Аннары Сүзлектә гуманитар юнәлеш өстенлек иткәне сизелә, төгәл һәм әсасый фән әһелләренә игътибар йомшаграк төсле. Әйтик, математик һәм мәдәният эшлеклесе, Сталин репрессияләре корбаны Максудов Гаяз Гисамович (1831—1942) Сүзлегебезгә керми калган, ә менисклы телескопны уйлап табучы Дмитрий Дмитриевич Максутовның "Татар энциклопедиясе сүзлеге"нә ни өчен теркәлүе аныксыз.

Конкретикага күчәм.

Әүвәлгеләрчә бисмиллаһ әйтеп, сүзне Пәйгамбәрдән башлыйм әле.

Сүзлектә Мөхәммәд Пәйгамбәр турында 9 юллык бөлешмә бар. Ул "Мөхәммәд Әхмәт бине Абду Аллаһ (Мөхәммәд пәйгамбәр)" рәвешендә теркәлгән. Монда байтак кына нигезле сораулар туа. Иң беренчедән—бирегә Әхмәт исеме каян килеп кергән? Чынлыкта Әхмәд (Әхмәт) Мөхәммәд Пәйгамбәрнең икенче исеме генә (хәдисләрдә Пәйгамбәр үзен Мөхәммәд дип тә, Әхмәд дип тә, Мәхмүд һәм Хәмид дип тә атый, ә бер хәдистә үзенең биш исеме бар икәнен аермачык әйтә, болар: *Мөхәммәд, Әхмәд, әл-Махи, әл-Хашир һәм әл-Гакыйб*).

Вариант буларак, Әхмәд исеме Мөхәммәд исеме янында җәя эчендә генә күрсәтелергә тиеш иде. Шунысын да әйтеп китик, Сүзлекнең русчасында ул "(Мухаммад) Ахмад" дип бирелгән. Алай да ярап бетми, әмма монысы ялгыш ук түгел. Икенчедән, "Мөхәммәд" дип язгач, янәшәдә, әлбәттә, "Әхмәд" язылышы таләп ителә (тамыр шул ук—хмд). Аннары татарча чыганакларда без Мөхәммәднең атасын Габдулла дип атауга күнеккәнбез, монда да шулай кирәк иде.

Пәйгамбәрнең исемен Мөхәммәд бине Габдулла Әл-Һашим дип тутырыбрак язу иң яхшысы булыр иде.

Мөхәммәд Пәйгамбәрнең туган елына карата фикер төрлелеге күзәтелсә дә, аның вафат булган елы берәүдә дә шик уятмый, чөнки ул, кем әйтмешли, сәгате-минуты белән билгеле (Исламда кешенең үлеме мәңгелек өчен туу дип карала). Шуңа күрә Энциклопедик сүзлектә Рәсүлнең вафат булган елы "632 тирәсе" дип язылганны күргәч, аптырашта каласың (ә русчасы мондый хатаны "ычкындырмый").

Югарыда әйткәнебезчә, 9 юллык кына мәгълүматлар арасында "Гарәбстанда беренче мөселман җәмгыятенә ... нигез салучы" дигән сүзләр бар. Минемчә, ул заманнарда (һәм хәзер дә) бу очракта "җәмгыять" сүзе түгел, "өммәт" сүзе кулланылган һәм кулланыла.

Инсаният тарихында иң күренекле, абсолют реаль шәхес булган гали зат турында язганда аеруча игътибарлы булу зарур.

"Сөләйман" дигән мәкалә дә бераз сәерсендерә. Анда Сөйләман "инсафлы һәм акыллы патша" дип атала, ягъни Библиядәге Соломон белән генә тәңгәлләштерелә. Ә Коръәннән без аның пәйгамбәр булганлыгын беләбез, ягъни Сүзлектә Сөләйман турында, бигрәк тә мөселман күзлегеннән караганда, иң мөһим нәрсә әйтелмичә калган. Гомумән, күп кенә коръәни һәм библияви шәхесләр арасында параллель үткәрергә мөмкин, чөнки алар турындагы риваятьләр Борынгы Гарәбстанда туганнар. Әмма Коръәндә һәм Библиядә сурәтләнгән бер үк шәхесләр арасында мөһим аермалар да күзәтелә. Коръәни Сөләйман белән библияви Соломон арасында да андый аермалар байтак. Мәсәлән, Коръәндә Бәлкыйс (Библиядәге "царица савская") турында яһүдиләр дә, христианнар да белмәгән мәгълүматларга тап булабыз. Мондый очракларда безгә игътибарны ислами чыганакларга юнәлтү тиеш.

Мәрьям-ана турындагы мәкаләне, асрауларны атаган кебегрәк, "Мәрьям" дип кенә бирмәскә иде, чөнки Мәрьям шәхесе христианнарда гына түгел, исламда да изге санала. Аннары керәшеннәребезнен Мәрьям (Мәрйәм) анасы "Ару Кыз Мария" ("Пречистая Дева Мария") һәм кайбер сөйләшләрендә "Ана-кәбә" ("Пресвятая богородица") дип атауларын да искәрткәндә комачау итмәс иде. Борынгы хәзәр телендә Марияне "Тәнре анасы" ("Матерь божья") дип олылаганнар, монысын да әйтеп китәргә мөмкин булыр иде.

Дини төшенчәләрне аңлатканда булган кимчелекләрнең күбесе гомумән бөтен татар матбугатына хас. Мондый хаталар махсус дини әдәбиятта да гел очрап тора.

Әйтик, Адәм галәйһиссәлам нәрсәдән яратылган? Энциклопедик сүзлектә "җан өрелгән балчыктан яратылган" диелә. Мәгълүм ки, Адәмгә җан соңыннан гына өрелгән (риваять буенча, Адәм сиксән ел шәкелсез, йөз егерме ел үзле балчык хәлендә җансыз ята). Сүзлекнең русчасын карадым. Анда "звучащая глина" телгә алына. Дини (ислами) чыганакларда "янган кирпеч кебек кипкән", "шыңгырдап торган каткан балчыктан" яратылган дигән сүзләргә дә тап булабыз. Энциклопедик сүзлектә исә—"туфрактан һәм...балчыктан", ягъни туфрак катыш балчыктан булып чыга. Электә туфракта (русча "почва") һәм балчыкка ("глина") бүлү булмаган әле, җир, туфрак, балчык сүзләре бер мәгънәдәрәк йөргән. Шуңа күрә сүзлектәге аңлатма үзе аңлатуга мохтаҗ.

Шушы ук мәкаләдә "хәлифә" диясе урында "хәлиф" киткән. Әлләни зур бәла түгел, ләкин бу ялгышны күбәүләр җибәрә, шуңа күрә генә телгә алуым. Сүзлеккә хәлифә сүзенең үзен дә теркәргә иде, әлбәттә. Ислам хәлифәте (Ислам хилафәте) төшенчәсе турында да шуны ук әйтергә була.

Ибраһим пәйгамбәрнең кәнизәге Һаҗәрнең исеме Сүзлектә Хаҗәр дип теркәлгән. Һаҗәр сүзенең хаҗга һәм хаҗи-хаҗияләргә катнашы юк; "һҗр" тамыры күрсәтеп торганча, ул "һиҗрәт", "мөһаҗир" сүзләре белән кардәш. Хаҗәр исеме "Татар исемнәре сүзлеге"нә дә кермәгән, Һаҗәр генә теркәлгән. Ибраһим пәйгамбәрнең хатыны Сара тарафыннан өйдән куылгач, Һаҗәр баласы Исмәгыйльне күтәреп чүлдә адашып, каңгырап йөри, хәтта аның Һаҗәр исеме дә соңрак бирелмәдеме икән дип уйларга мөмкин *(ил гизү, сәяхәт итү, һиҗрәт итү мәгънәсендә).* "Гарәпчә—татарча—русча алынмалар" сүзлеге"ндә теркәлгән һәҗәр сүзенең бер мәгънәсе—"хатынны ташлап китү", Һаҗәр исеменең ана бәйле булуы да ихтимал. Һаҗәрнең библияви тәңгәле *Агарьның* да исеме борынгы гыйбрани телдә "качып китү" мәгънәсендә ("Библейская энциклопедия").

Хәзәр патшасы Иосифның исеме Сүзлектә Йосыф рәвешендә бирелә *(278 бит).* Ләкин ул яһүд динен тоткан һәм 954—961 елларда яһүд дөньясы белән хат алышкан идарәче (каган, каһан) бит. Шуңа күрә бу затны Йосыф дип атау нигезләнеп җитми. Иосифка буйсынган болгарларның аны үзләренчә Йосыф дип йөрткән булулары мөмкин хәл, әлбәттә.

Еш кына татарча текстларда "Библия" сүзе урынына "Тәүрат" сүзен кулланырга яраталар. Бу дөресме? Нечкәләбрәк карасаң—дөрес түгел, чөнки "Тәүрат" ("Тора") "Библия"нең бер өлеше генә ул, аны башкача "Бишкитап" дип тә йөртәләр ("Зәбур" белән "Инҗил" дә "Библия"гә керә, соңгысы—"Яңа Гаһеднамә", "Новый Завет"). "Тәүрат"—яһүдиләрдә Моисей/Муса пәйгамбәр китабы, дигән билгеләмә дә очрый. Гомумән, "Библия" һәм "Тәүрат" сүзләрен бутау татарча чыганакларда еш күзәтелә, хәер "Әдәби сүзлек"тә (2001) "Тәүрат" яһүди "Талмуд"ка тәңгәлләштерелгән,—монысы инде бигрәк тә килешми.

"Нечкәләбрәк карасаң" дидек. Ә энциклопедия нәкъ менә нечкәләп карарга тиеш тә. Шуңа күрә, әйтик, Рабгузи турындагы белешмәдә *(512 бит)* "Коръәндәге һәм Тәүраттагы сюжетлар" дип язу төгәл түгел.

Энциклопедиячеләр сөнниләрнең хәдисләре белән шигыйларның (Сүзлек "шигыйләр" дип яза) әхбарлары арасында тигезлек билгесе куялар шикелле. Халбуки, шигыйлар беренче, алгы планга Мөхәммәд Пәйгамбәрнең кияве Галинең шәхесен чыгарырга тырышалар, хәтта бу турыда Коръәнгә 115 нче сүрәне дә өстәп җибәргәннәр. Хәдисләр исә нигездә Мөхәммәд Пәйгамбәргә нисбәтле була. Бу—принципиаль аерма.

Кәшфеләсрар Ваһаб (1858 —1957?) турындагы белешмәдә аның Голҗада имам-хатыйб булып торуы, мәктәп (соңрак мәдрәсә) оештыруы турында әйтелә. Минем кул астымдагы материалларга караганда, Голҗада 1900 елда башта мәдрәсә ачылган, аннары, 1914 елда, бу мәдрәсә Габдулла Бубый тарафыннан "Нур" мәктәбе итеп үзгәртелгән. Белмим, бәлки хаталанамдыр. Аннары мине Ваһаб хәзрәтнең, Сүзлектә күрсәтелгәнчә, 1957 елга кадәр яшәгәнлеге дә шикләндерә. Кара акыл белән генә уйлаганда да, Ваһаб хәзрәт Голҗа мәхәлләсендә имам һәм бер үк вакытта казый

булып торган хәлдә, "килмешәк" Габдулла Бубыйга җәдид мәктәбе ачарга юл куяр идеме икән? дигән сорау да туа бит әле.

Дәүләтша ишан (1787—1832) "язучы" дип аталган *(197 бит)*. Баксаң, аның динидидактик эчтәлекле бер рисаләсе генә билгеле икән ("Рисаләте нәҗатийә", кульязма хәлендә). Әгәр мондый юл белән барсак, без бик күп дин әһелләрен язучы, әдип дип атарга тиеш булабыз, хәлбуки аларны фәлән-фәлән хезмәтләрнең авторы дип атау да бик җиткән. Өстәвенә бу хезмәтләр әүвәлгеләрдән күчереп яки аларга ияреп кенә язылган була.

Кемгә ничектер, ләкин Сүзлектәге Камил Мотыйгый турында бирелгән белешмә *(440 бит)* мине канәгатьләндереп җиткермәде. Күп кенә каләм ияләренең тәрҗемә эше белән дә шөгыльләнүенә Сүзлектә басым ясап әйтелүгә дә карамастан, Мотыйгыйның бу өлкәдәге мөһим эше игътибардан читтә калган. Чыннан да, 1914 елда Казанда Мөхәмммәткамил Мотыйгый Төхфәтуллинның "Татарча Коръәни тәфсир" китабы нәшер ителә. Бу китапта гарәп тексты белән янәшә аның татарчага тәрҗемәсе дә бирелгән. Гомумән, киләчәктә Коръәннең фәнни нигезгә корылган татарча тәрҗемәсен эшләгәндә Мотыйгыйның бу хезмәте дә азмы-күпме ярдәм итәр иде. Әлбәттә, бу китабын төзегәндә ул әтисе Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллин (вафаты 1920 елда) хезмәтләренә таянган булыр, әмма китапның дөнья күрүендә аның үзенең дә роле бәхәссез...

Камил Мотыйгыйның үзен-үзе "татар Шаляпины" дип атап шапырынуы, Тукай белән араларының киселүе, 1915 елда мөфти Солтанов вафат булганнан соң үз кандидатурасын мөфтилеккә тәкъдим итеп шамакайланып йөрүе кебек тискәре фактлар да Сүзлектә ачылмаган, ягъни Мотыйгыйның фаҗигале тормышы берьяклы гына яктыртылган.

Казандагы мәшһүр "Милләт" басмаханәсен 1908 елда кем ачкан? Сүзлектә әйтелгәнчә, М. И. Идрисевме, әллә ширкәт хуҗаларының берсе Идрисев Ибраһим Сөләйман улымы? Шулай да соңгысы булырга охшаган, чөнки бу вакытларда аның улы Мөхәммәд Идрисев (1882—1948) төрле шәһәрләрдә һәм төрле илләрдә (Петербургта, Истанбулда, Ливанда, Мисырда һәм Германиядә) укып, китап басу эшен һәм рәссамлык һөнәрен өйрәнеп кенә йөри. Сонрак график һәм хәреф кисүче буларак танылa һәм ахырда басмаханәнең хуҗасы булып кала.

Рухи дөньябызга Гаяз Исхакый әйләнеп кайтканнан соң Исхакый турында татар кешесе аңында шактый четерекле бер сорау да туды. Сүзлектә ул "татар драматургиясенә һәм театрына нигез салучыларның берсе" дип бәяләнә. Болай дию генә аз бит. Асылда Гаяз Исхакый татар драматургиясенә нигез салучыларның беренчесе, дөресрәге—татар драматургиясенең чишмә башы. Бу гап-гади хакыйкать күбәүләрнең башына килә, театр белгечләренең аерым мәкаләләрендә дә сизелеп куя, ләкин алар аны, шушы төпле фикерне, куанып җибәрергә тырышалар, хакыйкатьне чатнатып әйтергә базмыйлар.

Чыннан да: ул чагында Галиәсгар Камалыбызны кая куйыйк?

Мин моны белмим. Шунысын гына беләм: тормыш барын да үз урынына урнаштырып куяр.

Теге яки бу шәхес турында бирелгән мәгълүматлар берьяклырак булган очракларны Сүзлектә тагын күрсәтергә мөмкин. Әйтик, замандаш шагыйребез Наис Гамбәрнең поэзиясе турында гомуми сүзләр генә әйтелә, Нечкәләп торылмый, аның каравы Наис Гамбәрнең берәр юбилей унае белән язган "дежур" мәкаләләре санап кителә. Шагыйрьгә шагыйрьчә бәя бирелсен, ә Наис Гамбәр—чын шагыйрь.

Казан галиме Н. И Воробьевның (1889—1967) фәнни хезмәтләре атап күрсәтелмәгән. Югыйсә, аның "Казанские татары" китабы бүген дә үзенең әһәмиятен югалтмады бит, ул хезмәт, әйтик, бүгенге кирпеч калынлыгын коллектив хезмәтләрдән үзенең төзеклеге, бөтенлеге һәм мәгънә тыгызлыгы белән аерылып тора.

Петр патша заманында әсир төшкән швед кешесе—Филипп Иоганн Страленберг безнең бу Сүзлегебезгә теркәлергә лаек түгелмени? Россиядә вакытында Страленберг җирле төбәкнең тарихы, географиясе, этнографиясе, археологиясе буенча бай материал туплаган. "Россиядә, Сибириядә һәм Бөек Татариядә сәяхәтләрем тарихы"

диган хезмәтендә ул Томск һәм Тубылда мөселман татарлар белән аралашуы турында яза, аларның тормыш-көнкүрешен тасвир итә. Мәсәлән, Страленберг бер татар мулласының мәет күмү йоласы турында сөйләгәннәрен язып алган. 1730 елда немец телендә чыккан "Россиянең төньяк һәм көнчыгыш өлеше" диган хезмәтендә Страленберг Казан татарлары турында да мәгълүмат бирә. Бу шәхеснең халык хәтерендә абруйлы бер галим һәм остаз "Филип бәй" рәвешендә сакланып, "Бәләбәй" сүзенә әйләнгән булу ихтималы турында да сүз куертырга мөмкин. Безнең яклардагы элекке гади, хәтта кырыс өслүбтәге мәчетләрнең тышкы яктан Балтыйк буе һәм Скандинавиядәге христиан гыйбадәтханәләренә тартымлыгы да аңлатуны сорый бит. Шуны да искәртим, мондый гипотеза өр-яңа түгел (дөрес, башкаларында бүтән Филипп яки хәтта Филипплар күздә тотыла).

Ә илгизәр һәм тылмач Гобәйдулла Әмиров? Бу татар сәяхәтчесе 1777 еллар тирәсендә, "Пугачау фетнәсе" бастырылганнан соң, туган туфрагын ташлап китәргә мәҗбүр була, бер ялгызы бөтен Шәрыкны әйләнеп чыга, утыз еллап гомерен горбәттә үткәргәннән соң гына Рәсәйгә әйләнеп кайтып, үзенең күргән-белгәннәре турында рус хакимиятләре өчен бик кыйммәтле хатирәләрен калдыра (рус телендә). Сәяхәтче һәм күзәтүчән шаһит буларак, ул мәшһүр Исмәгыйль агадан да һәм, әгәр инде руслар белән чагыштырыйк дисәк, атаклы Афанасий Никитиннан да югары тора. Тик шунысы күңелгә тия, Шәрык турында Гобәйдулла Әмиров туплаган мәгълүматлар рус империясенә генә хезмәт иткәннәр, ә татар җәмәгатьчелегенә нәмәгълүм булып калганнар. Хәер... Пржевальский белән Арсеньев кебек галим-сәяхәтчеләр дә, үзләре дә аңышмастан, ахыргы исәптә, империализм диган иблис арбасын тартканнар бит. Исмәгыйль ага катнашкан сәяхәт исә патша хакимиятләре тарафыннан оештырылган һәм ул, хәзергечә әйтсәк, "тышкы разведка" максатларын күздә тоткан булса кирәк. Исмәгыйль ага Гобәйдулла Әмировның "Татар энциклопедиясе сүзлеге"нә керми калуы миңа аңлашылмаячак.

Патша флотында контр-адмирал дәрәҗәсенә күтәрелә алган Исхак Ибраһим улы Исламов (1865—1923) биографиясенә караганда, Сүзлектән ул бер тапкыр гына дөнья тирәли сәяхәт иткән сыман булып аңлашыла. Хәлбуки, Исламовка Җир планетасын дүрт тапкыр әйләнеп чыгарга насыйп булган һәм беренче сәяхәте вакытында ук Ерак Көнчыгыштагы бер борынгы "кече штурман офицеры" Исламов исеме бирелгән. Тик шунысы кызык, соңыннан "кызыл"ларга каршы сугышкан һәм чит илгә чыгып китәргә мәҗбүр булган контр-адмирал исеме совет диңгез карталарында сакланды микән? Ай-һай... Гомумән, Исламовның тәрҗемәи хәлендә татар һәм мөселман кешесе сабак алырлык гыйбрәтле мизгелләр байтак, галим буларак та ул гадәттән тыш күпкырлы зат булган. Аның тормышындагы билгесез сәхифәләрне Төркиядә эзләүче энтузиаст бармы икән?

Ә Күчүм ханның хатыны Сүзге бикә? Бу бикә шәхесе тарихта һәм сәнгатьтә Сөембикә белән тиңләшерлек эз калдырган лабаса. Риваятьләрдән беләбез, ачкүзле рус казаклары кулына төшмәс өчен ул үзен-үзе чәнчеп үтерә... Мин Сүзлектә ирдәр табигатьле Сүзге бикә турында аерым мәгълүмат тапмадым.

Укучы Энциклопедик сүзлектә тарихыбызның борынгы сәхифәләрен аңлау өчен гадәттән тыш әһәмиятле хезмәтләр авторы А. П. Ковалевский турында да мәгълүмат таба алмаячак. Мин монда Сталин культы чорында сәяси тоткынлыкта яткан украин галименең Ибне Фазланның Идел буена сәяхәте турындагы хезмәтләрен һәм борынгы сәяхәтченең кульязмаларын тәрҗемә итүен күздә тотам.

Күп кенә чын бөекләрдән үзгә буларак, Фикрәт Табиев шәхесенә Сүзлегебездә 17 юл бирелгән, ә Виктор Черномырдин тагы да югарырак "бәяләнә". Өлеш чыгарганда мондый юмартлык совет чоры яки Мәскәү түрәләре турындагы белешмәләрдә аерымачык күзгә ташлана. Ә инде "нәфис сүз остасы" Черномырдин әфәнде урынына XIX гасырда Болгар хәрабәләрен, Идел буйларын, Казан, Зөя күренешләрен рәсемгә алып йөргән бертуган Г. Г. һәм Н. Г. Чернецовлар турында мәгълүмат бирелгән булса күпкә файдалырак булыр иде.

Соңгы елларда Чиркәү күленең сулышы әледән-әле өркетеп куя. Кичәге сексотлар һәм парт-совет функционерлары кабат ияргә менде. Өлкән яшьтәгеләре, әүвәлге

привилегияләрен саклаган хәлдә, гади халыкның чыраена төкереп яши бирәләр. "Ач үлемнең куркусыннан ил жылаган" бер мәлдә кичәге большевик тел бистәләренең оньк-туруннары бүген череп байый. Хәерле фал түгел. Сексотлар арасында шушы калын энциклопедик сүзлеккә теркәлгәннәре дә бар. Барын-бар, тик аларның сексот булганлыгын исбат итеп кара ди син! "Яшерен хезмәттәшләр" турындагы мәгълүмат жиде йозак белән бикләнүле. Заманында жаныбызга тигән вульгар тәнкыйтьче Мөсәгыйтьләрне сүгеп бушансаң гына инде (Сүзлектә аның турында да кыскача белешмә бирүне кирәк тапканнар, 1990 елда вафат булган икән—заманаларның алмашынуын белебрәк киткән мәрхүм).

Ярар, бу теманы да калдырып торыйк.

Ераграк тарихтан берничә мисал.

Сүзлектә Казан ханлыгы чоры даругаларының исемлеге генә түгел, картасы да бирелгән булса әйбәт булыр иде. Чөнки кайбер даругалар укучы аңында бутала (төрле сәбәпләр, шул исәптән язылышның тотрыклы булмавы аркасында). Гомумән, оригиналь карталар һәм схемалар теманы ачу өчен бик яхшы хезмәт итәләр бит. Мин, мәсәлән, Сүзлектә татар тарихына караган ядкяр-истәлекләр картасы булмасмы дип тә көткән идем.

"Арча даругасы"на бирелгән аңлатмадан Казан ханлыгы XVII гасырга кадәр яшәгән булып аңлашыла. Ә менә "Жөри даругасы"ның шул ук калыптагы аңлатмасында мондый хата юк.

Борынгы Казандагы "Отыч мәчете" кайда урнашкан булган? Энциклопедик сүзлектә (русча версиясендә дә) бу мәчетнең Болак суының уң ярында (?) Көрәеш бистәсенең урта бер жирендә, Печән базары тирәсендә булганлыгы аерымачык әйтелә *(татарча Сүзлектә 356, 485 битләр).* Ә Печән базары Сульяк Болак урамы тарафында булмаганмыни? Миңа, мәсәлән, түләүле поликлиниканың Унъяк Болак урамында (Бауман урамына якынрак якта) урнашкан булуы мәгълүм. Татарча китаплардан без, әйтик, Иске бистәнең Болакның сул тарафында икәнлеген укып белә идек. Димәк, Отыч мәчете Болак суының сул ягында булган диярге кирәк иде. Әгәр дә мәгәр электә Болак суы Кабанга агып керә торган булса, аның уң як ярын халык фәһеме, әлбәттә, хәзерге Киров урамы ягына "урнаштырган" булыр иде. Хәлбуки, Болак Казансуга коя торган булган, язгы ташу вакытында гына су кирегә агып, Кабан күленә кергән. Хәтерегездә булса, Иске Казандагы Сульяк Кабан урамы да Бистә ягында иде, 1998 елга кадәр ул *Комсомол урамы* дип аталды, хәзер *Шиһабетдин Мәржани* исемен йөртә. Турысын әйткәндә, мин бу элементар фактларны бер дә язасым килмичә генә язам.

Аннары. Татарча чыганакларда әлеге мәчет *Утыз мәчете, Утәч/Үтәш мәчете, Әтүч мәчете, Отыч/Отуч* мәчете дип кырыкмаса-кырык төрле атап йөртелә. Адашып, буталып каласың. Шуна күрә мәкаләдә татар укучысын бу хакта кисәтеп куйганда да яраган булыр иде.

Яманаты чыккан Черек күл... Энциклопедик сүзлектә "Казанның яулап алынуы" дигән мәкаләдәге картада Кремль астында "Кара күл" дип күрсәтелгән кечерәк кенә бер шартлы объект бар (русчасында—"Черное озеро"). Казан руслар кулына күчкәннән соң да әле гасырлар буена биредә күлләр системасы (тезмәсе) Казансуга кадәр сузылган була. Казан ханлыгы чорында Сасы күл яки Черек күл ("Гнилое озеро") дип Казан суының язларын шәһәр эчендәге башка күлләр белән тоташа торган култыгын атап йөрткәннәр. Н. А. Спасскийның "Очерки по родиноведению" китабында Шакшы күлнең югаргысы Мунча бакчасында, түбәнгесе Кремль астында Засыпкина урамы очында булган диелә. Аннары *Кара күл,* Ак яки *Чиста күл, Николаевский күле,* Театр күле тезелеп киткән булган. "XV—XVI гасырларда төп су чыганагы булып Черек Күл түбәнлегендәге Ак һәм Кара мунча күлләре системасы хезмәт иткән, күмәччеләр дә суны шуннан алганнар. Соңга таба бу күлләр суының сыйфаты начарлана, аларны акрынлап күмә баралар" *(Жаббаров А.Н., Гаделшин А. Б. "Казан сууткәргече. "Фән һәм тел". 2002, 2 сан).* Н. Ф. Калининның "Казан" дигән китабында *(Казан, 1957)* күлләрнең исемнәре түбәндәгечә: *Ак күл, Черек күл, Мунча күле, Пычрак күл.* Кайчандыр язгы ташулар вакытында Казан суы да шушы күлләр системасы һәм хәзерге Пушкин урамы буйлап "Божра"дагы балыклы

күлгә һәм Кабаннын үзенә үк агып кергән шикелле.

Тарихи картада бу күлләр системасы, әлбәттә, күрсәтелергә тиеш, шунсыз Казан каласын алунын, хәрби күзлектән караганда, ни дәрәҗәдә катлаулы эш булуы анлашылып бетми. Казаннын кальга өлеше (кирмәне), вакыт-вакыт, утрау шикелләрәк, су эчендә утырган. Кайчагында бу манзара мина Пушкин әкиятендәге "Буян утравы"н хәтерләтә.

Күргәнебезчә, әлеге күлләрнең исемнәре дә булган.

Картага язу өчен исем эзләргә туры килсә, хәтта "Җәгъфәр тарихы" кебек бәхәсле нәрсәләрне дә искә төшерергә ярый. Анда язылганча, шул тирәдә үк Карга күле, Акби күле һәм Бакча күле дә булган. "Черное озеро" атамасының этимологиясен түбәндәгечә реконструкцияләргә мөмкин шикелле: Карга күле—Кара күл ("Черное озеро"). Бу—гипотеза гына, әлбәттә...

Казандагы "Кара күл" гидронимы Сүзлектә аерым мәкалә булып теркәлмәгән, хәер, анда Казандагы тарихи "Черек күл" дә кермәгән.

19 биттә "Ай календаре" дигән мәкаләдә "Ай елы (һиҗри ел) Кояш елыннан 11 тәүлеккә кыскарак" дип кистереп әйтелә. Хәлбуки, Ай һәм Кояш календарьларында, елларның гади яки кәбисә ел булуына карап, ел озынлыгындагы аерма да үзгәрә. Кояш календаре елы гади, ә Ай календаре елы кәбисә ел булганда аерма 10 көн тәшкил итсә, Кояш календаре (шәмсия) елы һәм Ай календаре (камәрия) елы икесе дә гади яки икесе дә кәбисә ел булганда—11 көн, шәмсия елы кәбисә ел булып, камәрия елы гади булганда исә аерма 12 көнгә житә. Күрәбез ки, Сүзлектә төгәлсезлек киткән. Гомумән, календарьлар мәсьәләсендә күбәүләр буталалар. Һиҗри календарьдагы гади һәм кәбисә елларның үзенчәлекле чиратлашуы турында, мәсәлән, хажи Абдулла Дубин күп кенә мәкаләләрендә бер үк ялгышны кабатлый. "Чамасы чамага туры килсә ярый безгә—каткан тезгә" дигән кол философиясеннән үк килә торган ачы хакыйкать бу.

Сүзлек фарсы календаренда нәүрүз (яна ел) бәйрәменең 20-21 мартларга туры килүен искәртә, хәлбуки кайбер чыганакларда моның 21-22 мартларда булуы әйтелгән. Боларның кайсына ышанырга? Мәгълүм булганча, нәүрүз бәйрәме язгы сәвия вакытында, ягъни язын көн белән төн озынлыклары тигезләшкән мизгелдә үткәрелә. Тикшеребрәк карасак, язгы сәвиянең гадәттә 21 мартка төшүен, сирәк кенә 22 мартка һәм тагын да сирәгрәк 20 мартка туры килүен ачыкларга мөмкин. Шуна күрә югарыда күрсәтелгән вариантларның икенчесе дөреслеккә якынрак дип әйтә алабыз.

Энциклопедик сүзлектә Казандагы "Казаков мәчете 1975 елда сүтелде" диелә. Юк, сүтелмәде, эвфемизмнарсыз" гына әйтсәк, җимертелде ул. Хәзерге вакытта без анын нигезләрен таптап йөрибез. Шундагы татар зираты да киң Татарстан урамына түшәгән асфальт астында калды... Мондый зиратлар Казанда әллә ничәү. Ихтимал, киләчәк заман археологлары алардагы газиз сөякләрне казып чыгарыр әле.

Архитектура истәлекләренең адресы (урамы—искечә һәм яңача исеме белән, аннары бүгенге йорт номеры) күрсәтелгән булса яхшы булыр иде. Мәсәлән, Сүзлектә Казандагы ике катлы Муллин йортының татар сәүдәгәрләре өчен гадәти план буенча төзелгәнлеге әйтелә, ә күпчелек укучыга ул истәлекнең кайдалыгы нәмәгълүм булып кала. Йортның адресы сәүдәгәр Б. Ф. Муллин турындагы белешмәдә дә әйтелмәгән.

Абруйлы белешмәдә татар күңеленә бик якын булган "Ослан тавы" ("Аслан тавы") турында мәгълүмат эзләдем. Югары Ослан, Түбән Ослан авылларыннан башка нәрсә күзгә чалынмады. Ә Ослан безнең өчен бик күренекле һәм күркәле нәрсә бит. Бу тау башыннан караганда, бөтен Казан уч төбендәгедәй җәелеп ята диләр. 1918 елның көзендә Кызыл гаскәр артиллериясе аклар кулында калган Казанны шушы таудан утка тота. Тупка тотканда Ульянов Ленин күрсәтмәсе нигезендә эш итәләр, ә анын исеменнән сугылган яшерен телеграммада "Шәһәрне кызганмаска" ("Город не жалеть") дип язылган була. Ленин бабай бу телеграмманың оригиналын юк итәргә боерган булса да, тарих мөһим документны казанлылар хәтерләсен өчен саклап калган... Ослан тавы турында игътибарга лаек башка фактлар да житәрлек. Хәтта анын атамасының килеп чыгышы турында да сүз кузгатырга

мөмкин булыр иде. Русча чыганакларда мин "Ослан (яки Услон) тавы" дигән атама очратмадым (дөрес, Афанасий Никитин сәяхәтнамәсендә "Услан" дигән атама телгә алына, ләкин комментаторлар аны Әстерханнан төньяктарак Идел дельтасында урнашкан торак пункт дип фараз итәләр), ә русларда Ослан тавы "Соколиная гора" дип аталган бугай. Монысы да тарих өчен кызыклы, чөнки борынгыда Казанда шонкарчылар да булган, ә шонкар биек тауларда оялый... Электә рус патшаларына хезмәт иткән шонкарчыларның татардан булуы да расланган факт.

Сүзлектә терминологиягә багышланган кыска гына белешмә һәм "Терминологик сүзлекләр" турында махсус мәкалә бар. Беренчесендә терминологиягә билгеләмә бирелә дә, русча-татарча терминологик сүзлекләрнең кайберләре санап чыгыла (әмма төзүчеләре телгә алынмый), аннары терминологиягә кагылышлы хезмәт авторлары күрсәтелә. Алар арасында К. Насыйри, Г. Ибраһимов кебек бик могътәбәр исемнәр дә бар. Бүгенге терминология мәсьәләләре, мәсәлән, Ф. Фәсиев, И. Низамов һәм бигрәк тә тирәнгә төшкән Р. Әхмәтьянов хезмәтләрендә яктыртыла. Аерым хезмәтләр һөнәрчелек терминнарын туплауга карый. Болар барысы да бик мөһим, әлбәттә. Ләкин "практик терминологлар" нигә онытылган? Химия терминологиясен эшләүгә һәм гамәлгә куюга зур өлеш керткән Гыйлем Камайлар, Галимҗан Дистановлар, физика терминологиясен фәнни нигезгә корган Мөхәммәд һәм Мәхмүд Галиевләр, география терминологиясен эшләгән З. С. Дусаевлар һ. б.лар нигә онытыла? Асылда без менә шул могътәбәр затлар төзеп биргән фәнни телдә сөйләшәбез, мәктәпләрдә белем алабыз бит. Аларның бу өлкәдәге хезмәте регистраторларныкыннан югары бәяләнергә тиеш. Галиевләрнең һәм Дусаевның исә сүзлеккә аерым теркәлергә дә хокуклары җитәрлек.

Тагын бер нәрсәне искәртәсем килә. Энциклопедик сүзлек бер үк фән тармагына караган һәм төрле елларда нәшер ителгән терминологик сүзлекләрне гадәттә беренче, икенче, өченче... басмасы дип күрсәтә. Ә бит аларның кайберләре бөтенләй башка авторлар тарафыннан, тулаем бүтән принципларга нигезләнеп төзелгәннәр, шуңа күрә аларны бер үк китапның төрле басмалары дип санау белән килешеп булмый. Күптомлы энциклопедиядә моңа махсус игътибар ителсен иде.

Заманында үзем тәкъдим иткән бер төркем терминнарны "Татар энциклопедия сүзлеге"ндә күргәч икеләтә куандым. Беренче чиратта мин фарсы телендә юклыкны белдерүче "на", "нә" алкушымчасы ялганган берничә терминны күздә тотам. Татарстан китап нәшриятында фән-техника әдәбияты редакторы булып эшләү дәверемдә мин әйләнешкә төрле фән тармакларына (физика, астрономия, химия, биология, география һ. б.) караган йөздән артык мөһим термин, шул исәптән дистәләрчә үсемлек атамалары кертеп җибәрә алдым. Бүген менә шуларның байтагы энциклопедик сүзлегебезгә теркәлгәнен күрәм.

Чыннан да "нәевклид геометриясе", "нәорганик химия", "нәсызыкча" (нелинейный, -ная, -ное) кебек терминнарны уйлап чыгаруым һәм беренче тапкыр практикада куллануым белән горурланам да кебек. Бу терминнар очраклы табыш түгел, шактый уйланулар, эзләнүләр нәтиҗәсе иде. Ә "Татар энциклопедия сүзлеге"нә алар энциклопедияне редакцияләүдә катнашкан тел һәм борынгы әдәбият белгече Ф. Фәсиев үтенече белән мин төзеп биргән терминнар исемлегеннән барып кергәннәр дип аңлыйм. Ни кызганыч, принципта яңа терминнарның авторы энциклопедиячеләрнең күбесенә билгесез булып калган (бу хакта минем энциклопедиянең җаваплы мөхәррире Г. Сабирҗанов әфәнде белән дә телефоннан сөйләшкәнем булды). Моны кайдадыр язып та чыккан идем. Ә менә "нәсызыкча" терминына килгәндә, Ф. Фәсиев белән сөйләшкәндә монда басымны күрсәтү зарурлыгы турында да сүз булган иде. Бу очракта "нәсызыкча" сүзендә басым өченче иҗеккә төшә ("Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"нә теркәлгән "сызыкча" сүзендәге кебек!). Кызганычка каршы, "Татар энциклопедия сүзлеге"ндә басым ялгыш күрсәтелгән булып чыкты (соңгы иҗеккә төшкән итеп бирелә). Шул ук аңлатмалы сүзлеккә кергән сызыкча сүзенең мәгънәсе бөтенләй башка—ул кыска сызыкны, дефисны белдерә; ягъни, сүз төркеме буларак, исемнәргә карый. Мондый пөхтәсезлекне аклап булмый (нәмөмкин!), аны аңлатып кына була.

Соңгы терминнның мәгънәсе зиһенгә тиз генә барып ук җитмәгәнен күргәч,

шикләнеп тә куя башладым. Электән килгән "сызыкча" терминыннан баш тартып, "сызыкчыл" һәм "нәсызыкчыл" сүзләрен тәкъдим итсәм, ничегрәк карарлар микән дим. Аларны кабул иткән очракта укучының буталу ихтималы юкка чыга, басым белән баш катырасы да булмаячак. Гомумән, "чыл" суффиксының потенциалы, ягъни мөмкинлекләре шактый (беренчел, икенчел, ... һәм хәтта "ленинчыл", "сталинчыл", "советчыл", "партиячел" сүзләре моның өчен безгә унай жирлек әзерләгән диярге була). Мәсәлән, "квадратичный" сүзе катнашкан бер дистә русча математик терминны "квадратчыл (программалаштыру, функция, хата һ. б.)" рәвешендә биреп булыр иде сыман.

Хәтерлим, Ф. Фәсиевкә биргән исемлеккә русча "обтекание" терминына тәнгәл итеп "ягалау" сүзен дә язып куйган идем. Анысын сүзлекчеләр ошатканнардырмы-юктырмы—белмим. Әйбәт, халыкчан сүз үзе, эш практикамда (аэродинамика турында сүз барганда) мин аны кулланганадым.

Сүзлектә Казандагы яна "Мәдинә" мәчетенең манарасы ике балконлы диелгән. Балконың балкон инде, ләкин ул шәрәфә һәм мәәззәнә балконы, яки мәәззәнә дип атала бит. Аннары Мәржани мәчетенен мәәззәнәсе "челтәрле металл койма белән әйләндереп алынганлыгы" турында укыйбыз. Бу очракта "койма" сүзе ярап бетмәс, аны "тимер рәшәткә" дип алу дөрес булыр ("тимер" сүзе метал мәгънәсендә дә йөри). Мондый рәшәткәне (парапетны) тагы пәнжәрә дип тә атарга мөмкин бугай, ә татар диалектында аны бик матур сүз белән "керфек" диләр.

Байтак кына үлән-үсемлек исемнәренен татарчасы Сүзлектә искиткеч күркәм шәхес Р. Г. Иванованың "Словарь-справочник по флоре Татарии" китабы буенча бирелә. Хәтерлим, бу китапны матбугатка әзерләгәндә үлән-үсемлекләрнен татарча исемнәрен табу жиңел эш булмаган иде. Автор ярдәмендә бик күп чыганакларны табып актарырга, төрле халыкларда йөри торган үсемлек атамаларын чагыштырырга туры килде. Монда беренче чиратта география укытучысы М. Х. Галиәкбәровның язмаларын, Р. Г. Иванова кебек үк тырыш галимәбез Н. Б. Борһанованың хезмәтләрен искә аласым килә. Энциклопедик сүзлектәге "Терминология" мәкаләсендә аларның фамилиясе телгә алынырга тиеш иде дип уйлыйм, чөнки алар гади регистратор гына булып калмыйча, терминнарны системага салу һәм аеруча кулайларын кулланылышка тәкъдим итү белән шөгыльләнгән практиклар да әле. Фәнни терминологияне аякка бастыруда нәкъ менә шундый фидакарь эзләнүчеләрнен роле зур. Соң булса да, аларга тиешле бәяне бирә белсәк иде. Аларны санлау һәм олылау тиеш.

Күптән түгел Мәскәүдә А. П. Дьяченконың "Словарь авторских терминов, понятий и названий" дигән белешмәсе дөнья күрде *(М., ИКЦ "Академкнига", 2003)*. Бу китапта авторлары тәгаен ачыкланган яки хәтта якынча гына билгеле булган 3700 дән артык термин, төшенчә һәм атамалар тупланып, аларга кыскача аңлатма бирелгән. Китаптан фән теленен тарихы буенча кызыклы мәгълүмат аласын. Бәлки киләчәктә бездә дә бу тема белән шөгыльләнүчеләр табылыр? Аларга татар дөньясында да материал житәрлек дип уйлыйм. Бер унайдан "ут күршеләребез" башкортларның фәнни терминологиясен күзәтеп бару файдалы булыр иде. Мин, мәсәлән, башкорт дусларның ничә еллар буена татар терминологиясендәге табышларны дәшми-тынмый гына үзләштереп баруларына ышандым. Әзер бит—кап та йот.

Энциклопедик сүзлегебез кулланылышка тәкъдим иткән термин һәм атамалар күп, мин аларның барысын да күреп бетердем дип тә әйтә алмыйм. Яна терминнарның ошаганнары, күңелгә хуш килгәннәре уңышсызларына караганда күбрәк. Мәсәлән, шәһәрлек сүзе өлгесе буенча ясалган авыллык сүзен зарури ихтыяж аркасында туган дип санарга кирәктер. Дөрес, русча "стоянка" мәгънәсендәге торулык сүзе колакны сагайта. Өстәвенә энциклопедик сүзлек үзе дә аны тотрыклы кулланмый, мәсәлән, "Красная глинка туктаулыгы" дигән неологизм да очрый *(360 бит)*. Хәзинәбездә электән үк булган торлак һәм утрак сүзләрен эшкә жигеп булмыймы?

Сүзлек редакторлары каршында һич тә көтелмәгән проблемалар да килеп баскан очраклар күзгә чалынды. Менә шуларның берсе.

Сүзлекнең русча версиясендә, 432 биттә "Первый всероссийский мусульманский съезд" һәм "Первый всероссийский съезд мусульман" дигән ике аерым мәкалә бар. Бу корылтайларның беренчесе (легаль булганы) 1917 елга карый, икенчесе (легаль булмаганы) 1905 елда ук булып үткән. Боларны татарчада ничек бирергә? Бер-берсеннән ничек аерырга?

"Татар энциклопедия сүзлеге" болай эшләгән: 1917 елгысын "Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтае" дип, ә икенчесе "Бөтенроссия мөселманнарының беренче съезды" дип атаган *(122 бит).*

Әгәр алар, бу корылтайлар, үз заманнарында татар тарафыннан шулай исемләнгән булсалар бер хәл булыр иде. Ләкин мин, әйтик, 1905 елгы корылтайның татар матбугатында һәм татарча документларда "съезд" дип аталганына ышанып бетә алмыйм. Дөрес, бу хакта махсус эзләнергә мөмкинлегем булмады, ләкин минем Йосыф Акчураның "Гаяз әфәнде" дип исемләнгән мәкаләсендә "Русия мөселманнары иттифакының өченче җыены" дигән атамага тап булганым бар. Мәкаләдә "Бөтен Русия мөселманнары иттифакы"ның 1906 ел 16-20 августында Мәкәрҗәдә (асылда Нижний Новгородта, Нижгарда) үткәрелгән өченче корылтае телгә алына. Ихтимал, ул заманнарда съезд ише нәрсәләрне җыен дип атаганнардыр. Объективлык хакына түбәндәгеләрне дә өстәп әйтмичә булмый: 1914 елның гыйнвар башында чыккан "Ил" гәзитендә 1913 елның 23 декабрендә Петербургта Русия мөселманнарының беренче съезды ачылуы хәбәр ителгән. Күрәбез ки, татар матбугатына ул заманнарда русча съезд сүзе инде ят булмаган икән...

Мәгълүм ки, безнең күпчелек тарихчыларыбыз рус телендә яза, хәтта татарча чыккан китаплары да еш кына аноним тәрҗемәчеләр тарафыннан ана телебезгә күчерелгән була. Кызганыч, әлбәттә, ләкин бу шулай. Революциягә кадәрге татар һәм гомумән мөселман корылтайларын һәм җыеннарын съезд дип атау шулардан киләдер сыман. Әгәр диссертацияләрен ана телендә язып, татар телендә яклап гыйльми дәрәҗә алган булсалар, бу галимнәребез татар терминологиясенә дә өлеш керткән булырлар иде югыйсә.

Кыскасы, минем фикерем болай. Нигә әлеге атамаларны "Мөселманнарның беренче бөтенрусия корылтае" һәм "Беренче бөтенрусия мөселманнары корылтае" (яки җыены) дип аермаска? Искәртеп китик: сүзлектә "Беренче бөтендөнья татар конгрессы" дигән мәкалә бар, ягъни мин принципта яңа "өлге" тәкъдим итмим, бүген кулланылышта йөргән "калып"ны гына искә төшерәм.

Һәрхәлдә, конкрет бу очракта "корылтай" һәм "съезд" сүзләре белән фокус-покус ясауның кирәге юк иде. Тип-тигез җирдә дә абынмыйк инде.

"Казан утарлары" мәкаләсендә "Казан сарае идарәханәсе" дигән атама очратабыз. Беренчедән, "Казан утарлары" сүзенең "Казан дачалары" мәгънәсендә кулланылганлыгын әйтеп китик. Дачалар Казан воеводасы тарафыннан дәүләт хезмәтендәге кешеләргә бүлеп бирелгән (биләмә, җир-утарлар).

Мондый тәртип Казан ханлыгы чорында да булган, аларны "бүләк" (русча чыганакларда "беляк") дип атаганнар. Рус дәүләтендә гадәткә кергән "дача"ларның мәгънәсе өлешчә шушы "бүләк" терминына туры килә шикелле. Р. Әхмәтьянов "бүләк" сүзен "бүлеп бирелгән җир" мәгънәсендә дип аңлый.

"Утар" сүзе "хутор", "усадьба", "имение", "двор" сүзләренә күбрәк тарта шикелле. Казанның үзендә дә утарлар булган ("Шакир солдат утары", "Апанаев утары", архиепископ Гурий утары һ. б.). Аларның кайберләре чыннан да бүләк итеп бирелгән, һәм бу очракта, ихтимал, аларны "дача" дип тә атап була торгандыр.

Ә "Казан сарае идарәханәсе" дигәне "Казанская приказная палата" булып чыкты. Казан ханы сарае белән бутамас өчен, бу очракта атаманы төгәлрәк, саграк тәрҗемә итәргә тырышырга кирәк иде. Ничегрәк? Мәсәлән: "Казан боерыклар палатасы". "Боерык" сүзе шушы мәгънәдә "Древнетюркский словарь"га да теркәлгән, татарча чыганакларда "боерчы" (приказный), "боерчы бәк", "боерык иясе" кебек сүзләрнең актив булганлыгын күрәбез. Татар теленә "палата" сүзе дә ят түгел, Сүзлекнең үзендә үк "Казан хөкем палатасы" дигән атама бар ("пулат" сүзен искә төшергәндә дә ярый). Чыганакларда бу палатаны "Казанская изба", "Казанский приказ" дип

атау да очрый, ягъни тәржемә итү өчен мәйдан шактый кин, вариантларны иркенләп сайлап алырга була.

Кайбер билгеләмәләр татар телендә гадәттән тыш катлаулы яңгыраганга, алар зиһенгә барып та житми. Мәсәлән, Сүзлектә музыка өлкәсеннән "пентатоника"га түбәндәге билгеләмә бирелә *(494 бит)*: "Биш баскычны үз эченә алган октава кысалыгындагы тавыш югарылыгы системасы". Кычкырып укып караганда, жөмләнең колакка ятышсызлыгы аермачык сизелә, чөнки ул "музыкаль" түгел, аһәңсез. Русчасын эзләп табыйк әле ("Татарский энциклопедический словарь"да 430 бит): звуковысотная система, содержащая 5 ступеней в пределах октавы". Монда иң элек "кысалыгындагы" кебек мәзәгрәк сүздән котыласы бар. Моның өчен аны "чикләрендәге" сүзе белән алмаштыру да житә. Әмма әле барыбер татар укучысы өчен аңлаешлы билгеләмә килеп чыкмый. "Октава чикләрендә биш баскыч авазны эченә алган төрле югарылыктагы тавышлар тезмәсе" дигәндә ничек?

Тәржемәдә алга таба да чатаклыкка юлыгабыз. Русча текстта сүз башка төрле тавыш югарылыгы системасы куллану турында бара, ә татарчада "башка тавыш югарылыгын файдалану" диелгән.

Сүз дә юк, бу—шактый авыр очрак һәм мондый хәлләрдә музыка белгечләренә мөрәжәгать итеп, гадирәк аңлатма сорарга да мөмкин булыр иде дип саныйм. Нигә русча текстка ябышып ятарга?

Сүзлектә русча "потомственный почетный гражданин" термины озын һәм катлаулы иттереп, "нәселдән күчкән шәрәфле граждан" дип алына (мәсәлән, 174 биттә, "Ишморатов Габрахман Әхмәт улы" турындагы мәкаләдә). Татарча китапларда күптән очрый торган алынманы исебезгә төшерик: "нәселдән килгән шәйх" мәгънәсендә шәйх-и мирасы сүзе кулланылган. Бу очракта да шәйх статусы генетик туганлык буенча, мәсәлән, атадан угылга күчкән була. Димәк, әгәр дә без "мираси шәрәфле граждан" сүзен куллансак, Америка-мазар ачмыйбыз, хәзинәбездә булганны гына эшкә жигәбез.

"Гасыр" яки "йөз" сүзләрен ничек һәм кайда, кайчан кулану турында бәхәс куертасым килмәсә дә, бер-ике сүз әйтми булмастыр. Әлбәттә, "йөз" сүзен, исемләштереп, "гасыр" мәгънәсендә куллану татар телендә электә дә булган. Башта ул сөйләм телендә очрый башлагандыр сыман. Мәсәлән, Каюм Насыйри архивында сакланган иске ельязмада мондый сүзләрне укыйбыз: "Мең сигез йөзнең ун икенче елында паспортның пушнәсе (ягъни пошлинасы) алты сум булды". Тик шулай да "йөз" сүзе артык күп мәгънәле һәм фәнни текстта "гасыр" сүзен алмаштырып бетерә дә алмый. "Урта йөзләрдә казакъларда урта йөз (жүз) кабиләләр берләшмәсе булган" дип сөйләргә һәм язарга? Яки, фараз иттек, киләчәктәге яки хәтта милядига кадәрге туксан тугызынчы, йөзенче гасырларны телгә алырга туры килсә, ошбу әдәбиятчылар аларын ничек дип атарлар иде икән? "Туксан тугызынчы йөз"? "Йөзенче йөз"? Менә шушында Г. Тукайның яшь аралаш: "Шул гажәп: ник бу егерменче гасырда йөз дә юк!" дип сүз уйнатуын искә төшерсән дә ярый. Шагыйрь күңеле егерменче гасырыбызның чырайсыз һәм кимчелекле булачагын сизенгән...

Сүзлек редакторлары "гасыр" дигән сүздән котылырга бик-бик тырышсалар да, аерым очракларда аны чүпләп, текстны "чистартып" ук бетерә алмаганнар: Миннегулов Хатыйп турындагы белешмәдә "урта гасыр татар әдәбияты" киткән. Хәер, болар "вактин вак" нәрсә, мондый факт психологик яктан гына мәзәгрәк тоела—бу очракта без үзенә бер төрле "әдәби жаргон"ның чын, конкрет, төгәл мәгънәле термины туры килгән саен кысрыклавын, рәнжетүен күзәтәбез...

"Мөселман-сөнниләр"ме, әллә "сөнни мөселманнармы?" Икенчесе дөресрәк, чөнки сөнниләр, урыс әйтмешли, "по определению" мөселман инде. Ә мишәрләр турындагы мәкаләдә алар "мөселман-сөнниләр" дип язылган, Әстерхан татарларына да шундый ук характеристика бирелә. Бу—русчага иярү генә түгел, гомумән, башка дин тотучылар күзлегеннән карау бәласе. Татарча текстта әлеге этник төркемнәрне сөнниләр дип атау да житә.

"Нүкәр" сүзенең теркәлүе бик аңлашыла *(473)*. Ләкин жәя эченә аның язылыш вариантларын (нөгер, нукер) бирү генә житмәстер, аларын да аерым теркәп, Сүзлектә кабул ителгән төп формага юнәлтергә кирәк иде, чөнки тарихи текстларда әлеге вариантлар ешрак та очрый шикелле.

Мондый юнәлтү алымы Сүзлектә, әлбәттә, кулланылган (мәсәлән, "Плано Карпини" да, "Карпини" да бар һәм беренчесе икенчесенә юнәлтә). Бу алымны күбрәк кулланганда ярар иде.

Татар фамилияләренең азагында –ев яки –ов кушымчасы язу мәсьәләсе әлегәчә ныклап хәл ителмәгән килеш. Мәсәлән, 1999 елда басылып чыккан "Татарский энциклопедический словарь"да М. И. Махмутов фамилиясе җәя эчендә, татарчалаштырылып, "Мәхмүтов" дип бирелгән булса да, "Татар энциклопедия сүзлеге"ндә (2003) инде Мәхмүтев дип теркәлгән. Галимә Л. Т. Мәхмүтованың фамилиясе дә шундый ук эволюция кичергән. Бәлки алар, бу шәхесләр, паспортларын яңартканда фамилияләренең татарча язылышын шулай үзгәрткән булганнардыр—монысын белмим. Миңа калса, -ев ялганды ни дә, -ов ялганды ни—икесе дә рус кушымчасы бит. Хәер, бәлки, -ев ялгауга да ияләнер идек, чөнки гасырдан гасырга кыен ашаган татар бәндәсе күнекмәгән нәрсә дөньяда юктыр шикелле. Әмма һәр татар баласына диярлек кагыла торган мондый кагыйдәне рәсмиләштерергә, гавәмгә игълан итәргә кирәк бит. Янә шунысы ачык: бу мәсьәлә бер селтәнүдә генә хәл ителмәячәк.

Казанда тарихи "Адмиралтейская слобода" булган (совет чоры елларында ул берара "Кызыл Армия бистәсе" булып та йөри). Сүзлекнең татарча вариантында аның төп атамасы итеп "Бишбалта" алынган. Соңгы вакытларда чыганакларда "Адмиралтия бистәсе" дигән атама очрый башлады. Шунысы кулай булыр төсле, чөнки, термин буларак, "Адмиралтия конторасы" кебек төшенчә дә очрый, аны "Бишбалта конторасы" дип алып булмаса кирәк. Гомумән, "Бишбалта" төшенчәсе күңелгә бик якын тоелса да, топографик төгәллек хакына, фәнни текстта аны "Адмиралтия бистәсе" белән бутамаска кирәк дип уйлыйм. Бишбалта—шул тирәдә булган борынгы татар авылының исеме, карталарда ул Адмиралтия бистәсенең кечерәк кенә бер өлешен алып тора. (Ул тирәнең картасы, мәсәлән, М. С. Глуховның "Казанский ретро-лексикон"ында бирелгән, 2002). Кыскасы, бу очракта "Бишбалта" атамасы тарихи чынбарлыкны чагылдырмый, атамадагы төп информация югала.

Мәскәүдәге "Тылмачлар бистәсе" энциклопедик сүзлеккә теркәлгән-теркәлүен. Ләкин "тылмач" сүзенең үзен аерым да теркәргә һәм тарихта эз калдырган мәшһүр тылмачларыбызны атап күрсәтергә кирәк иде дип уйлыйм. Ни өчен дисезме? Чөнки Европа телләренә дә үтеп кергән борынгы "тылмач" сүзе "тәрҗемәче"/"тәрҗеман" (переводчик) сүзеннән үзгә. XVIII гасыр юридик документларында бу терминнар мәгънә ягыннан аерыла. Мәсәлән, 1770 елда Уфа провинциясе канцеляриясенә коллежский регистратор дәрәҗәсендә елына 80 сум хезмәт хакы белән бер тәрҗемәче (переводчик) һәм елга 25 сум хезмәт хакы белән өч тылмач билгеләнгән. Тылмачлар сөйләшүләр вакытында телдән тәрҗемә итсәләр, тәрҗемәчеләр исә язма текстларны тәрҗемә кылганнар. "Тылмач" сүзе шушы мәгънәсендә немец теленә дә кергән, венгр теленә дә алынган.

Рус патшаларының ярлык-грамоталарын татар теленә Мәскәүдәге Илчелек приказында (канцелярисендә? диванында? боерыкханәсендә?) эшләүче татарлар тәрҗемә иткәннәр. Алар гадәттә Касыйм, Темников (Төмән) һәм Романов өязе татарлары булган. 1689 елда илчелек приказы штатында исәпләнгән татарчадан тәрҗемә итүче тылмачлардан дистәләрчә кешенең исем-фамилияләре билгеле. 1723 елда Петр патша әмере буенча Казан татарларыннан 23 кешене Иранга (хәзерге Әзәрбайҗанга) тылмач итеп җибәргәннәр *(Татар әдәбияты тарихы, I том, 1984)*.

Тылмач булып эшләүчеләр арасында тарихыбызда эз калдырган шәхесләр дә аз түгел. Күренекле галим һәм педагог Хәлфин Сәгыйть Хәсән улы Казанда адмиралтия конторасында тылмач булган. Болгар кабертašларындагы язуларны русчага тылмач Йосыф Ишбулатов һәм Сүнчәләев Кадермөхәммәд тәрҗемә иткәннәр (1722). Шәрыкка сәяхәт итүе белән мәшһүр Гобәйдулла Әмиров та Оренбург чик буе комиссиясендә тылмач булган. Мәхмүтов Идеркәй—Емельян Пугачевның тылмачы. Мәгърифәтче, рәссам һәм нашир Әмирханов Рәхмәтулла Казанның татар ратушасында тылмач булып торган. Бикчурин Мирсалих Мирсәлим улы 1865—1873 елларда рус армиясенең Урта Азиягә походларында тылмач сыйфатында катнаша. Тылмач Бикчурин Миндиярның (1740—1821) коллежский советник

дәрәҗәсенә тикле күтәрелгәнлеге мәгълүм. Бу исемлекне әле тагын дәвам итеп булыр иде.

Мин боларны энциклопедик сүзлектә, татар урысчаны су кебек эчкән бер заманда, бүгенге уртакул тәрҗемәчеләргә игътибар ителеп тә, әүвәлге тәрҗемәче-тылмачларга әһәмият бирелмәгәнгә күрә генә язам.

"Сөрән" сүзенең *(578 бит)* борынгы төркичәдәге беренчел мәгънәсен теркәгәндә дә яхшы булыр иде ("сугышка өндәп кычкыру").

Сүзлектә "Диния нәзарәте"нә *(202 бит)* аңлатма юк, авторлар укучыны "Милли Идарә" мәкаләсенә генә юнәлтәләр. Ә анысына күз салсак, ул да әлеге төшенчәне ачмый, нәзарәтнең Милли Идарә составына кергәнлеге генә күренә. Ихтимал, башка мәкаләләргә юнәлтү кирәк булгандыр.

XIV—XV гасырларда Наручатта (хәзерге Пенза өлкәсе, Наровчат авылы исеменнән) сугылган бик үзенчәлекле һәм халыкта "нурчат" дип аталган озынча акчалар һәм бизәнү әйберләре турында мәгълүмат Сүзлектә күзгә чалынмады, югыйсә бик кызыклы факт бит, ә "нурчат" сүзе, мәләкәсләр, писмәннәр, минзәләләр шикелле, әллә ничек колакны назлаган кебек... Кырыкмаса кырык хәлаектан оешкан татар бу сихри сүзләрнең яшерен мәгънәсен тоемлый да кебек, аңлатып кына бирә алмый...

XV гасыр урталарында Әстерханда, Кырымда сугылган озынча формалы акчаларны халык әҗгәрәй дип атап йөрткән (Хаҗи Гәрәй исеменнән бозып ясалган сүз). Кайбер чыганакларда Болгарда сугылган озынча акчаларның да әзгәри *(әзгари)* дип аталуы искәртелә. Сүзлектә болары турында да аерым мәкалә күрмәдем.

Хәзерге химия терминологиясендә "оксид" термины кабул ителгән *(окись түгел, 475 бит)*. "Закись", недоокись", "перекись" кебек сүзләр дә фәнни хезмәтләрдә бик очрамый бугай инде.

Гайса (Гайсә, Иса) турындагы белешмәдә "Троица" ("Триада") мәгънәсендә "Өчлелек" термины кулланылган. Искәртеп китик: татарчага күптән тәрҗемә кылынган "Инҗил"дә "Изге Өчле" сүзе кабул ителгән, ә керәшеннәр үзләре аны "Тройсын" да диләр.

"Кәнсәләр" сүзенә карата *(560 биттә очрый)*. Әйе, гади сөйләм телендә андый сүз бар (иде). Ул—"канцелярия" сүзен имгәтү" нәтиҗәсе. Бу "инвалид" сүз, сөйләм теленнән икәнлеге искәртелеп, "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"нә теркәлгән-теркәлүен, ә "Татар теленең диалектологик сүзлеге"ндә аның үзенә күрә "берлек формасы"—"кәнсә" сүзе дә "елмаеп тора". Әмма Энциклопедик сүзлек талымсызлык күрсәтмәскә, гади, түбәнрәк сөйләм алдында "йөгенмәскә", тез чүкмәскә, вакланмаска тиеш, анар затлылык, аристократизм гына килешә.

"Шәрекъ" дип язу да яна нәрсә түгел, күп еллар буена ул "шәрык" язылышы белән тынычлы-тынычсыз яшәп килә, ләкин асылда "шәрекъ" язылышы транскрипциянең бер төре генә бит. Әйтик, кайчагында "Мөхәммәд" урынына, гарәпчә яңгырашка якынлаштырып, "Мухәммәд" дип тә язгалыйлар. Анысы да татарча язу түгел, фәкать транскрипцияләргә омтылыш кына. Кызганыч, каләм әһелләре транскрипция алымын милли язылыш дип еш буталалар. (Русча да, әгәр "заяц" сүзен транскрипцияли башласаң, пыцт итеп "заецъ" килә дә чыга.)

Сүзлектә Н. Ильминский турындагы "тешсезрәк" мәкаләдә "шәрекыятьче" дип язуга да тап булдым. Монысы инде артыкка җибәрү, валлаһи! Татарны чукындырсаң (Ильминскийлар әйтмешли, "чумылдырсаң") да уртадагы "е" авазын йотып калдырачак лабаса. Бу очракта "шәркыйәтче" дип язу искиткеч әйбәт буласы.

Латин графикасына күчә алсак, тешкә тия торган "шәрек"ләрдән дә, шәрыкләрдән дә, шәт, котылыр идек.

Сүзлектә "крәстиян" язылышы кабул ителгән. Мина калса, татарча "ә" белән русча "я" бу сүздә үзара сыеша алмыйлар. "Крәстиән" дип язарга һәм вәссәләм. Укылышта барыбер "й" авазы ишетелә.

"Олугъ" дип язу да сәер тоела. Калын "у" сузыгыннан соң татар калын "гъ" авазын әйтәчәк. "Угълы" дип язганда да русның калынлык билгесе артык, безнеңчә.

Сүзлектә "водная растительность"—су үсемлекләре, ә "водросли"—суүсемнәр. Татарчада болар бераз бутала, әлбәттә. Бу—кыен очрак һәм кичәге терминологлар

мондый "су асты ташларын" алдан күреп бетерә алмаганнар, югыйсә гарәпчәдән кергән нәбат/нәбатат сүзен, шәт, читкә тибәрмәгән булырлар иде (нәбате маи—су үземлекләре). Бәлки хәзергә кыен очракларда жәя эченә "флора" сүзен өстәү ярдәм итеп торыр? Ә бәлки монда "үсенте" сүзен кулланырга ярар? (Аның "заросль" мәгънәсе 1931 елгы "Татарча—урысча сүзлек"кә дә теркәлгән.) Бер унайдан шуны да әйтеп китик: "үсемлек" сүзе, термин буларак, узган гасырда гына әйләнешкә кергән, "сүүсем" турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Ә русча "растение" терминына килгәндә, әле XIX гасыр урталарында да, "растение" сүзе белән бер үк вакытта "прозябаемое" сүзе дә кулланылышта булган.

"Сүрә" терминына артык гомуми аңлатма бирелә һәм ул төшенчәне ачып бетерми. Сүрәләрнең формаль рәвештә озын, уртача һәм кыска сүрәләргә бүлеп йөртелгәнен әйтү белән чикләнмичә, аларны Мәккә һәм Мәдинә чорларына караганнары булуы, шигыйларда, мәсәлән, өстәмә 115 нче сүрә дә гамәлдә йөргәнлеге турында мәгълүмат бирергә кирәк иде. Соңгысы татар өчен аеруча кызыклы. Мәсәлән, бер кульязма ривайәттә Казан ханына Корьәндәге ниндидер "Алла Гали" сүрәсе булуы турында хәбәр китерәләр. Куфи язуы белән язылган хәбәр сөнни мәзжәбтәге Казан ханының ачуын чыгара. Бу ривайәттә ниндидер реаль вакыйга чагылса кирәк. Ихтимал, тарихчыларыбыз ул вакыйганың кайсы хан заманында булуын да ачыклый алырлар иде.

Сүзлекчеләр "айәт" язылышын кабул иткәннәр. Бу сүзнең гарәпчә күплек формасы "Гарәпчә—татарча—русча алынмалар сүзлеге"ндә "айат" рәвешендә бирелә. Болар, әлбәттә, бер-берсенә комачауларга мөмкин, ләкин шулай да татарчада "айәт" язылышын кабул итү кулай. Бер уңайдан "ривайәт", "хикәйәт", "әкийәт" язылышына кучу турында да уйларга була. Алланың рәхмәте инеп, латин хоруфаты кертелгәнне көтеп ятмыйк, хәрәкәттә—бәрәкәт, дигән.

Мәсәлән, металлны нәфис эшкәртүгә кагылган бер мәкаләне алыйк *(422 бит)*. Анда без "басма" (штамповка? тиснение?), "кырлау" (огранка? инкрустация? әдепләү, кайма тоту?), "чоку" (чеканка?), "уемлау" (гравировка?) кебек бер төркем терминнарны очратабыз. Күрәбез ки, терминнар татарчада бик якынча бирелгәннәр, мәгънәләре томанлы, сүзлекнең русчасыннан башка аларны аңлап бетереп тә булмый.

Әйтик, нигә штамплау яки калыплау сүзеннән куркырга? Ә "басма" термины конкрет бу очракта русчада да "тиснение"гә тәңгәл, һәм аны шул мәгънәдә кулланырга иде. "Басма" сүзе һәм юка металл табакларга рельефлы бизәкләр басу ысулы руска татардан кергән дип уйларга нигез бар. Мәсәлән, руслар чиркәүдәге көмеш әйберләрне басменный дип атаганнар, иконаны бизи торган юка көмеш каплама (кыса) да басма дип йөртелгән. Вл. Даль сүзлегенә теркәлгән басман сүзе (патша сарае яки казна ипие) дә шушы "басма" сүзеннән булырга тиеш. М. Фасмер бу ипигә келәймә басылган булгандыр дип фараз итә.

Гравировка ысулы да "уемлау" да "уемлау" (миндә "уеплау" формасы теркәлгән булган, бәлки, ялгышканмындыр?) гына түгел, чөнки бизәкләр калкытып эшләнергә дә мөмкин, электр (гальваник, Каюм Насыйрида—"галфания") ысулы да бар. Гомумән, терминологиябездә, халыкчан "уемлау" яки "уеплау" сүзен саклаган хәлдә, "гравер", "гравюра", "граверлау" сүзләрен дә ташлап булмас дип уйлыйм.

Сүзлектә кулланылган "кырлау" терминын исә ювелирлык эшендәге "огранка"га калдырыйк, чөнки инкрустация дип аңлаганда да металл эшкәртүгә аның туры мөнәсәбәте юк. Өстәвенә ул кул эшендә әдепләү, кайма тоту, тирәләү мәгънәсендәге термин буларак бик билгеле. Телчеләр русча "чеканка" сүзенең төрки "чүкү" сүзеннән алынган булуын дәлилиләр. Асылда "чоку", "чокчыну", "чуку" һәм кайбер башка фигыльләр дә шул тамырдан. Сүз бара торган очракта да "чүкү" сүзен кулланырга ярар иде (ләкин "чекинка монет" акча сугу, әлбәттә). Тимерчеләр арасында "таптау" сүзе дә йөри, ул күбрәк "ковка"га туры килә дип беләм. Әлеге мәкаләдә шуны куллану урынлы булыр иде.

Шушы ук мәкаләдә "каш кую" термины очрый, ә аның металл эшкәртүгә (хәтта "нәфисе"нә дә) һичбер катнашы юк, ул—зәргәрлек (ювелирлык) термины һәм Сүзлекнең русча вариантында бу урында телгә дә алынмый. Сүз уңаеннан йөзектәге

"каш" сүзенең төркиләрдә сихер ташы булып йөргән борынгы "каш" (нефрит) мәгъданы белән генетик бәйләнешенә игътибар итик. Татар хатыннарының "каштау" дигән баш киеме атамасында да күз өстендәге каш турында сүз бармый, бәлки аның энже-җәүһәрләр, тәнкәләр белән бизәлгән булуы күздә тотыла.

"Кырлау" сүзе аерым да теркәлгән һәм аның мәгънәсе инкрустация дип күрсәтелгән. Шулай да монда Сүзлекнең русча версиясендә очраган татарча "корлау" сүзе торырга тиеш түгелме икән? Ул чагында "асылташлар белән корлау"ны, акылга муафыйк рәвештә, асылташлар кую, кору, төзү-тезү мәгънәсендә дип аңлап булыр иде. Бер иске сүзлектә кор- тамырыннан ясалган корыну фигылен дә очратканым бар, аның мәгънәсе—тезелешү, сафка креп басу. Ихтимал, жепкыр дигән сүзнең дә асыл язылышы "жепкор" булыр ("чыбык челтәр кору"?). Корылма, коргы, корама (!) һәм кургаш (!) сүзләре дә ана кардәш. Соңгыларының мәгънәсе чыннан да "инкрустация" алымын искә төшерә. Р. Әхмәтьянов борынгы төрки телдә корга сүзенең "металл эретеп ямау" мәгънәсендә булганлыгын искәртә. Борынгылар инкрустация вакытында кургаш белән ябыштыру (беркетү) ысулын кулланганнар дип уйлау табигый.

Күрәбез ки, бу мәсьәлә шактый тирәнгә алып керә һәм, адашып ук калмас өчен, аны борынгы төрки-татар тел белгечләренә тапшыру хәерле. Тик шунысы ачык: халыкара инкрустация терминын тәмам читкә тибәрү акланмый. Хәлбуки, бүгенге терминологиядә бер мөһим юнәлеш барлык халыклар өчен уртак информацион кырны баету һәм эшкәртү булырга тиеш. Бу кырда (басуда, бакчада) миллилек һәм бәйнәлмиләл юнәлешләре тыгыз үрелеп барса гына уңышка ирешәчәкбез, җимеш алачакбыз.

Әлеге мәкаләдә "металл эретү" сүзе формаль яктан дөрес булса да, монда "металл кою" сүзе кулайрак дияр идем, чөнки "эретү" сүзе металлны югары температурада каты хәлдән сыек хәлгә китерү мәгънәсенә генә тарта, ә "кою" сүзендә нәрсәне дә булса "эретеп чыгару", "агызып алу", "житештерү" мәгънәсе дә төсмерләнә.

Шулай да Сүзлектәге "су электр станциясе" бераз гаҗәпләндерә. Һич югы терминның бер сүзе татарча булсын дигәннәрме? Гидроэлектр станциясе термины аңлаешлырак түгелмени? "Гидравлика", "гидрант" кебек сүзләр телдә тамыр җибәргән һәм үзләшеп беткән бит. Ә менә язылышка килсәк, бәлки һидро дип яза башларга да вакыт җиткәндер (һидроген, һидравлика һ. б.). Ә бәлки Һенрих Һейне, Һитлер кебек язылышларны да канунлаштырырга ярыйдыр инде (Мәскәүдәге Дәүләт Думасы башбаштаклары якабыздан эләктергәләгәнче).

Энциклопедик сүзлектә "Вильгелем (Рубрук)" язылышын күргәч тә сәерсенеп китәсең. Бу да транскрипциянең бер уңышсыз мисалы инде. Монда татар өчен нечкәлек билгесенең дә, ахырда килеп кысылган "е" хәрефенең дә кирәге чамалы (бусы "башкортлык" була).

"Татар энциклопедия сүзлеге"нә ярым-йортылы "...бол" (туп, мяч) сүзенең ни өчен теркәлүен аңлый алмадым. Ул миңа бу сүзлектә очраклы бер курьёз сыман гына күренде. Русчасында мондый "...бол" юк, ул лингвистик сүзлекләргә яисә "Чит тел сүзләре лөгате", "Спорт сүзлеге" кебек белешмаләргә генә керергә мөмкин.

Шушында мәкаләмә нокта куйсам да ярар төсле, ләкин киләчәктә "Татар энциклопедия сүзлеге"ндәге яки тулаем "Татар энциклопедиясе"ндәге күпсанлы һәм уңышлы неологизмнарны берәмтекләп тикшерүче һәм гомумиләштерүче иренмәс җан табылса, туган телебез, фәнни терминологиябез үсеше өчен көчле этәргеч булыр иде дигән фикеремне тагын бер тапкыр кабатлап әйтәсем килә. Объективлык Сүзлегебезнең бу өлкәдәге күркәм казанышларын аерым тикшерүне таләп итә.

Энциклопедиябезнең яңа томнары чыкканын көтеп калабыз.

Беләсезме, бәйрәмне куанып көтә белү—үзе бер бәхет бит ул!

•

*Хәтер*

## Фәнис Яруллин

# СИРӘГӘЯ БАРА АККОШЛАР

Шундый шәхесләр була—алар белән артык еш аралашмыйсың, ләкин һәр очрашу онытылмаслык булып күңелгә сеңеп кала. Мондый күрешүләрдә җаннарның бер-берсенә ныграк тартылуын, күңеленнең баюын, яшәү мәгънәсенә тирәнрәк төшенә баруыңны аңлыйсың. Эчеңдә кайнаган уй-фикерләрнең башкаларның да җанын борчуын тою араларны якынайта.

Композитор Фасил Әхмәтов шундый шәхесләрнең берсе иде. Без аның белән башта телефон аша аралаша идек. Каяндыр бер очрашудан кайткач ул миңа болай дип шалтыратты:

—Карале, Фәнис, мине нишләптер синең белән бутыйлар. Күп кенә урыннарда: "Син Фәнис Яруллин түгелме?"—дип сорыйлар. Мин аларга: "Шагыйрь белән композитор җаннары бертуган инде алар. Шуңа күрә бутыйсыздыр",—дим.

—Әйе, дөрес әйткәнсең,—дип килешәм Фасил белән.—Син үзеңнең хисләреңне, кичерешләреңне музыка аша белдерәсең, ә мин шигъри юлларга салам.

—Анысы шулай,—ди Фасил,—кешенең күзенә иң беренче синең тышкы кыяфәтең күренә бит. Мин таяк белән көчкә-көчкә генә йөргәч, бу Фәнис Яруллин түгелме икән, дип уйлыйлардыр.

—Минем таяк белән дә йөри алмаганны белмәүчеләрнең генә башына шундый уй килергә мөмкин,—дим.

—Кеше сине хыялында тудыра, үзең беләсең, хыялда туган образ һәрвакыт чынбарлыктан матуррак була. Мондый кыяфәтем белән сәхнәгә чыгып басып, мин бит аларның хыялларын гына җимерәм.

—Алай ук кимсетмә әле үзеңне. Кай җирең кешенекеннән ким? Кызлар да гашыйк буладыр әле үзеңә?

—Анысы шулай,—ди Фасил һәм үзенең балачакта лапас өстенә менеп тальян гармунда уйнавын сөйләп китә.—Үзебезнең лапас түбәсе минем өчен беренче сәхнә булды,—ди ул.

Телефон аша танышып, дуслашып беткәч, язмыш безне хастаханәдә очраштырды. 1984 елның кышында бөерләрем бик каты ялкынсыну нәтиҗәсендә минем температурам кырык градустан да югарырак күтәрелеп китте һәм хатыным Нурсөя белән безне элек "спецклиника" дип йөртелгән хастаханәгә салдылар. Заманы өчен ул хастаханә иң әйбәтләрдән санала һәм анда күренекле шәхесләрне генә салалар иде. Безгә аерым палата бирделәр. Дәвалый башладылар. Авырудан бераз күзләр ачыла төшкәч, аш-су өләшүче Эльмира ханым: "Сездән өстәге катта композитор Фасил Әхмәтов ята",—дигән хәбәр җиткерде. Кичке ашларны ашау белән Нурсөяне Фасил янына менгереп җибәрдем. Озак та үтмәде, Нурсөя Фасил Әхмәтовны җитәкләп палатага төште. Фасил кыска буйлы, саргылт чәчле, мөлаем кыяфәтле кеше икән. Беренче күрешкәндә үк күптәнге танышлар кебек чын күңелдән сөйләшеп киттек. Палаталар эссе булганлыктан, мин күлмәксез генә ята идем. Кабыргалар тирене төртеп чыгардай, беләк тә юанрак салам хәтле генә. Фасилнең минем ябыклыкка исе китмәде.

—Чишенеп ташласам, минем дә синнән артык җирем юк инде,—диде ул.

—Димәк, белеп охшаталар,—дидем, аның шаяру катыш әйткән сүзләрен искә төшереп.

—Эш ябыклыктамыни?—диде ул.—Аю чаклы ирләрнең сукыр тычкан хәтле эшләре дә булмаудан кемгә файда? Без синең белән гигантлар!

—Гигант булмасак та, кәрлә түгел,  
Эшләгән эш безнең җитәрлек.

Халык безне үзенен иннәрендә
Киләчәккә бара күтәреп,—

дидем Фасилгә. Ул әлеге шигъри юлларга бик канәгать булды. Күзләрендә хәтта яшь күренеп китте кебек.

—Дөрес әйтәсен, дустым,—диде ул.—Халык теләсә кемне иннәренә менгерергә ашыкмый.

Фасил кичерешләргә бирелеп бераз басып торды һәм шунда гына кәгазьгә төреп тоткан кучтәнәчен исенә төшерде.

—Менә моны алып куй әле, Нурсөя,—дип төргәген хатыныма суздь.—Хатын килгән иде, анын кучтәнәче бу. Чәй эчәрсез.—Һәм ниндидер рухи талчыгу сизепме—урындыкка утырды.

Төргәктә чәк-чәк икән. "О-о чәк-чәк!—дидем мин,—болай булгач чәйне бергәләп эчәбез инде".

Нурсөя электр чәйнеген чыжлатып җибәрде. Банкада бал бар иде, аны чыгарып утыртты. Тиз арада чәй әзерләнде. Фасил шунда өстәлгә күнелсез генә карап:

—Өйдә булса, чәй янында мәе дә булыр иде,—дип көрсенеп алды.

—Мәен дә табарбыз,—дидем мин. Әмма Фасил минем сүзләрне шаяртуга гына юрап, көлемсерәп куйды.—Каяле, Нурсөя, теге явызны чыгар әле,—дидем мин.

—Нинди явыз?

Нурсөя дә мине анлап житкермәде. Ә хикмәт шунда иде: тәнемдәге яраларым ачылмасын өчен, һәркөнне тәнне сөртергә мина камфара кушылган спирт бирәләр иде. "Камфара исеннән мина аллергия була",—дигәч, чиста спирт бирә башладылар. Көненә 30-40 грамм чамасы иде бугай ул. Күрәсен, саклабрак тотканбыздыр, чөнки ул спирт кибетләрдә юк, ә аптекаларда рецепт белән генә сатыла иде. Өйгә укол ясарга килә торган шәфкать туташлары да аны былбыл төкерегедәй саклап кына тоталар. Шуна күрә, сөртенергә дип биргән спиртны әз-әзләп жыя килгәнбездер. Мин Нурсөягә шул спирт хакында ымладым. Ул бездә йөз граммнар тирәсе жыелган иде.

—Менә бу чиста спирт дип атала,—дидем бераз мактанып. Фасил спирт салынган савытны иснәп карады.

—Чынлап та, Фәнис туган, монардан спирт исе килә. Без аны болай итик әле.

Фасил стаканга өстәлдәге графиннан бераз су салды һәм дару шешәсенә жыелып килгән спиртны стаканга бушатты.

—Су кушкач күбрәк күренә, эчәргә жинелрәк була ул,—дип сөйләнә-сөйләнә, Нурсөя белән алар табын әзерләделәр.

Бөтенесе әзер булгач:

—Әйдә, малай, жиффәрик әле. Ату монда минем эч көртлый башлаган иде. Үзегез беләсез, минем хатын врач бит, мондый нәрсәләрне больницага кертү турында авыз да ачтырмый,—диде Фасил һәм су кушылган спиртны эчеп куйды. Мин дә бу мәсьәләдә бик изгеләрдән түгел идем, бөерләр турында онытып, Фасилга иярдем. Ничектер күнелләр күтәрелеп китте, Фасил:

—Шушы шайтан суына күнегеп беттек, малай. Юкса аны эчми дә була. Әмма берәрсенә кунакка баргач, өстәлләрендә кукраеп "акбаш" утырмаса, кәеф китә башлый. Урыс безне үз гадәтләренә өйрәтеп бетерде инде.

—Урыс аны безнен авызыбызга көчләп салмый бит.

—Көчләп салса, бәлки баш тартыр, киреләнер идек. Менә шул көчләмәве белән көчле ул безне. Нәрсә алсан да "ю", бәйрәмдә—шатлыктан, кайгы килсә—кайгыдан, хәтта бер шагыйрьнен шигыренә көй язсан да шушынын белән билгеләп үтә башладык бит.

Фасил белән ул кичне шактый озак сөйләшеп утырдык. Бераздан ул:

—Карале, малай, син монда тик кенә ятмыйсындыр, шигырьләр дәфтәренне биреп тор әле, бәлки берәрсенә жыр язып булыр,—диде.

Минем шигырьләр дәфтәрем үземдә иде. Ни хикмәттер: бик каты температура белән ятканда минем башка бер-бер артлы шигырь юллары килә башлый. Әлбәттә, аларда эзлеклелек булмаска мөмкин. Шигъри образлар ярсыган акыл күзәнәкләрендә төрле формалар алып күз алдында биешә башлыйлар. Фантазия акыл ярларыннан чыга. Жанда хисләр өермәсе барлыкка килә. Шушы өермә сине чынбарлыктан

югарырак күтәрә. Тән кызышуы белән хисләр дулкыны бәрелешүдән анда көтелмәгән фикерләр уяна. Фикерләрем югалмасын өчен аларны Нурсөягә әйтеп, дәфтәргә яздырып куям. Ә инде бераз хәл кергәч, шушы шигъри детальләрне бер формага салам. Киеренке халәттә фикерләр бер фокуска туплана, күрәсең, язып куйгач ярыйсы гына әсәр туганлыгы күренә. Иҗатның ничек туганын әйтүе дә кыен. Организм авыру белән көрәшеп ятканда, бәлки, тәндәге мона кадәр йоклаган күзәнәкләр уянып китеп, аңга, акылга ниндидер тәэсир ясыйдыр. Ләкин мондый халәт һәрвакыт авырганда гына булмый. Тән сау-сәламәт чакта ниндидер ассоциацияләр нәтиҗәсендәме, йөрәктә хис һәм кичерешләр давылы кузгала. Баш мие икеләтә-өчләтә кызурак эшли башлый һәм, болындагы чәчәкләр өстеннән җилләр сыйпап киткән кебек, дулкынлану кичерәсен. Шул дулкынлану, хисләрдән бәргәләнү шигырь юлларына күчә. Билгеле, хастаханәләргә кергәндә дә шигырь дәфтәремне үземнән калдырмыйм. Кайвакыт хастаханәләрдә шигырьләр күбрәк тә языла. Бу юлы да шулай булды. Һәм Фасил сорагач шигырь дәфтәремне аңа биреп чыгардым.

Икенче көнне иртән ул минем "Кем елый соң?" дигән шигыремне яттан сөйләп палатага төште. Без аны бүлдермичә тыңладык.

Тукта, тукта, кем елый соң,
Тетрәндереп күнелне?
Әтисез, иписез үткән
Балачагым түгелме?

Тукта, тукта, кем елый соң,
Бәгырьне кисеп-кисеп?
Рәнжетелгән яшьлегемме
Тора һаман да үксеп?

Тукта, тукта, кем елый соң,
Ишетәм нинди өннәр?
Җирне тырнап елыймы әллә
Заяга үткән көннәр?

Хәтер дигән учагымның
Җил актара көлләрен.
Көл астыннан саркып чыга
Күзе яшьле көннәрем.

Бу шигырь хастаханәдә ятканда язылган иде булса кирәк. Дәфтәремә аның язылу елы 1984 дип куелган. Бәлки ул Фасил белән очрашыр алдыннан гына язылган булгандыр.

Фасил шигырьне сөйләп бетергәч беразга тын калдык.

—Хәтерең шәп икән синең,—дидем тынлыкны бозып.

—Соң, Фәнис туган, монда бит син минем турыда язгансың. Бу кичерешләр гомер буе минем җанда йөри. Син аларны минем күңелдән суырып алгансың. Бер укуда ук хәтергә сеңде шигырең. Хәтта бу шигырьне син түгел, үзем язган кебек тоела башлады. Мин моңа әле музыка язачакмын. Шигырь шигырь инде ул, җыр булып яңгыраса, күпләрнең җанын актарачак әле ул.

Фасил сүзендә торды, хастаханәдән чыгып күпмедер вакыт үткәч, ул миңа телефоннан шалтыратты:

—Фәнис дус, колагыңа телефон трубкасын кысыбрак тот, хәзер мин сиңа бер җыр җырлыйм,—диде дә пианинода уйнап "Кем елый соң?"ны җырлый башлады. Җырның көе шигырь образын ача торган, кискен, шул ук вакытта оптимистик интонацияләргә дә бай иде. Сентименталь кеше булмасам да, күздән яшьләр чыгып китте. Сугыштан соңгы ачлык, хәерчелек, черек бәрәңгене төеп кәлҗемә ашаган чаклар искә төште.

Җырны тыңлап бетергәч, икебез дә телефон трубкасына еш-еш сулап, шактый вакыт сүзсез тордык. Бераздан Фасил:

—Беләсеңме, Фәнис дус, бу җырны Хәйдәр Бигичевка бирәм мин. Аның тавышына бата бу.

Фасил Әхмәтов бу жырны озакка сузмыйча Хәйдәр Бигичевка бирде. Күпмедер вакытлар үткәч Хәйдәр Бигичевка шалтыратып, әлеге жыр турында фикерен сорадым.

—Шәп жыр,—диде Хәйдәр,—мин моны, һичшиксез, радиога яздырачакмын.

Кайчан бу жыр радиодан яңгырар икән дип көтеп яши башладым. Ләкин жыр Хәйдәрдә "батты". Мин анарга бернича кабат жыр язмышын сорап шалтыратып карадым. Ул берсендә:

—Жыр бик катлаулы, озак өйрәнергә кирәк. Ләкин сез борчылмагыз, әкрен-әкрен өйрәнә торам мин аны,—дигән иде. Икенче шалтыратуымда:

—Радиога алып барган идем, яздырып булмады әле, тавышның карлыкканрак чагы булды,—дип аклангандай итте.

Бу жыр шулай тавышсыз-тынсыз гына "үлде" ахры дип уйлап йөри башладым. Хәйдәр Бигичевка да шалтыратмадым. Бер жырның жырлануы-жырланмавы минем өчен бик үк әһәмиятле түгел иде. Ләкин Фасил аны "үзенеке" итте: очрашуларда сөйләп йөри башлады. Хәтердә әле, ана Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге биргәч, Тукай һәйкәле каршындагы мөнбәргә аны чакырдылар. Ул сыңар таягына таянып, салмак адымнар белән микрофон янына килде. Гадәттә, яңа лауреатлар иң беренче сүзне бу зур бүләкне бирүчеләргә рәхмәт әйтүдән башлыйлар иде. Фасил артык сүз әйтеп тормастан:

—Бүген мин сезгә Фәнис Яруллинның бер шигырен укып бирәм. Ул шигырьгә күпләребезнең язмышы сыйган,—дип "Кем елый сон?"ны укып китте. Халык тын да алмый тыңлады. Әйе, Фасил бу шигырьне тәмам үзенеке итте.

—Бервакыт Балтачка очрашуга баргач, төн кунарга шагыйрь һәм хакимият башлыгы алып кайтты,—дип сөйләгән иде Фасил.—Гарифжаннарда төн буе шигърият һәм жыр турында сөйләштек. Йокы онытылды. Соңыннан мин ишек бусагасына утырдым да "Кем елый"ны сөйли башладым. Өй эчендәгеләр тын калды. Ә минем күзләрдән яшь ага, һич туктатып булмый. Шулай, Фәнис дус, ул шигыреңне кая барсам да сөйләми кайтмыйм. Кызганыч, Хәйдәр аны һаман радиога яздыра алмый.

Бераздан Фасил аны нотасы белән "Казан утлары" журналына илтеп бирде. Жыр журнал тышлыгының өченче битендә басылып чыкты. Бервакыт үзебезнең бакчада Мөхәммәт Мәһдиев (ул безнең бакча күршесе иде):

—Фәнис, бүген "Казан утлары"ның ярты елда басылган әсәрләрен тикшерү булды. Мин шунда үз чыгышымда: "Иң уңышлы әсәр—Ф. Яруллинның "Кем елый сон?" дигән жыры. Мондый әсәр ун елга бер генә туа ала, дидем. Музыкасын ишеткән булмагач, анысы хакында әйтүе кыен. Ләкин шигыре шәп,—дигән иде. Бу хакта ул үзенең бер мәкаләсендә язып та чыкты.

Мөхәммәт абыйдан мактау сүзе ишетү бүләк алу белән бер иде. Ә жыр барыбер яңгырады. 1995 елда мина Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирделәр. Бүләк бирү турында Президент указы Г. Тукайның туган көнендә газеталарда басылса да, аның дипломын һәм күкрәккә кадап йөртә торган билгесен шактый соң тапшырдылар. Ул 1995 елның көзендә М. Жәлил исемендәге опера һәм балет театрында булды. Мен кешелек зал шыгрым тулы. Артистларның да данлыклылары чакырылган. Бүләк бирүнең тантаналы өлеше беткәч концерт башланды. Менә сәхнәгә Хәйдәр Бигичевны чакырдылар. Ул: "Бүген мин сезгә Фасил абый Әхмәтовның Фәнис Яруллин шигыренә язган яңа жырын алып килдем. Жыр "Кем елый сон?" дип атала",—дип үзенең көчле тенор тавышы белән жырлый башлады. Жыр минем өчен озын бер гомер иде. Жырны халык зур игътибар белән тыңлады. Хәйдәр Бигичевның тетрәндергеч тавышы залдагы тамашачыларны гүяки бербөтен итте. Жыр тәмамлангач та халык аңына килә алмый торды. Бераздан соң гына, бомба шартлагандай, көчле кул чабулар башланды. Мин сәхнәдә идем, жыр тәмамлануга кулларына чәчәк бәйләме тоткан ике кыз сикереп торды. Кызларның берсе чәчәген мина бирде, икенчесе алгы рәттә утыручы, бу минутта бәхетле мизгелләр кичерүче Фасил Әхмәтовка сузды. Фасил аның чәчәкләрен урыныннан торып кабул итте. Чибәр кыз аның яңагыннан үбеп алгач, күңеле тагын да йомшара төштеме, күзләрен сөртеп алды. Бу кичәне телевидение дә төшереп алды, ләкин аны бер генә мәртәбә күрсәттеләр. Телевидениедән ул кичәнең язмасын сорап караган идем: "Андый ижат кичәләрен без бер генә тапкыр күрсәтәбез, аннары язманы сөрттерәбез",—диделәр. Шуннан соң да ни өчендер Хәйдәр Бигичев

бу жырны радиога яздырырга вакыт тапмады. Жыр, бер очыштан соң янадан галәмгә чыга алмаган космик корабль кебек, Фасил Әхмәтовның 60 яшьлек юбилеена чыккан китабына керде дә янадан тынып калды.

Бу жырга озаграк тукталдым, укучым гафу итәр. Мин бит әле Фасил Әхмәтов белән хастаханәдә ятуым турында яза башлаган идем. Әйе, ул безнең палатага һәр кичне кереп йөрде. Бер кичне ул Нурсөяне минем караватка утыртып, каршыбызга басып "Соңгы сулышыма кадәр" дигән шигыремне яттан сөйләп бирде. Аның хәтере бик шәп иде. Шул хакта әйткәч ул: "Мин берәр шигырьгә көй язарга уйласам, башта ул шигырьне ятлыйм. Шигырь юлларын кабатлап йөри торгач көй туа",—диде.

Ни өчендер Фасилгә шигырьнең исеме ошамады. "Ташлама мине, ташлама" дип атады ул аны. "Жыр өчен "Соңгы сулышыма кадәр", дигән исем бармый",—диде.

—Бу шигыренә көй күңелдә туа башлады инде. Ләкин пианино кирәк. Һич югы гармун. Музыкаль интонацияләрнең ничек яңгыраганын ишетми торып сүзләр белән музыканың бер-берләренә ярашу-ярашмавын аңлавы кыен. Жыр бит ул кияү белән кәләш кебек: алар арасында мәхәббәт булырга тиеш.—Ул күңелендә туып килүче көйне бераз "шыңгырдап" күрсәтте. Ләкин, үзе әйтмешли "кияү белән кәләш" арасында мәхәббәт җепләре бик үк күренми иде әле.

Билгеле, Фасилдә жырлау сәләте чамалы иде, ләкин үзе язган көйләрне жырлап, жыр турында фикер уята алырлык жырлый, шигырьгә язган көенә карата нииндидер килешмәүчәнлек белдерсән, шул урынга кат-кат басым ясап сине ышандыра иде. Кайвакыт без аның белән бәхәскә дә керә идек. Мин: "Жырның нигезе шигырь, шигырьсез жыр булмый",—дим. Ул: "Шигырь көйдән башка канатсыз кош кына",—ди. Безнең бәхәсебез: башта йомырка булганмы, тавыкмы, дигән кебегрәк төс ала.

—Иң беренче шигърият!—дим мин, сүземне бирмичә.

—Юк,—ди Фасил.—Кешеләр сөйләшә башлаганчы ук нииндидер көйләр көйләгән. Көй шигърияттән башка да яши ала.

Шулай бәхәсләшәбез, ләкин һәркем үз фикерендә кала.

Хастаханәдән чыгып күпмедер вакыт үткәч, Фасил "Ташлама мине" шигыренә музыка язды һәм гадәттәгечә телефон трубкасын пианино өстенә куеп миңа жырын тыңлатты. Жыр матур, ләкин шигырьнең композициясе үзгәргән иде. Укучы ул үзгәрешне тулырак күз алдына китерсен өчен жыр текстын тулысынча китереп үтәм.

Ташлама мине, ташлама,
Гел минем жанда уян:
Актык көнемә кадәрле
Ташлама мине, Хыял.

Ташлама мине, ташлама,
Ымсындыр мине, йөгерт:
Мәңге күземне йомганчы
Ташлама мине, Өмет.

Ташлама мине, ташлама,
Рәхәт син барны тою:
Йөрәгем соң кат типкәнче
Ташлама мине, Сөю.

Ташлама мине, ташлама,
Гел тор сафлыгын чәчеп,
Соңгы сулышыма кадәр
Ташлама мине, Яшьлек.

1984 елда язылган бу шигырь Фасил музыкасы белән тиз арада халыкка таралды. Аны беренче булып радиодан Люция Хәсәнова башкарды. Люциянең тавышы лиризмга бай һәм ул аңа үз мелизмнарын кертеп жырлады. Ләкин шигырьнең:

"Ташлама мине, ташлама,
Ымсындыр мине, йөгерт:

Мәңге күземне йомганчы
Ташлама мине, Өмет",—

дигән строфасы төшереп калдырылган иде. Мин Фасилгә: "Нигә төшереп калдырдың, ул төшеп калгач әсәрдәге эзлеклелек югала бит",—дидем. Фасил: "Худсоветта "ташламалар" артыкка китә дип, бу куплетны "ташлаттырдылар",—диде.—Ләкин минемчә дә синең бу куплетың артык. Жыр өчен "йөгерт" дигән сүз бармый". Фасил сүзендә хаклык бар иде, әлбәттә.

Әйе, совет чорында "худсовет" дигән нәрсә бар иде. Жырның текстын сүтеп, берәр сүзгә бәйләнергә жай эзлиләр. Музыкасын "худсовет"ка кергән композиторлар, шигырен шундагы шагыйрьләр, музыкаль редакция работниклары хәл итә иде. Жырың аларга ошамаса, ул радио архивында батып үлә иде. Әле бит жырны ин башта жырчы сайлап ала, әгәр жыр жырчыга ошый икән, композитор үз жырын аның тавышына туры китереп, әсәрен кабат эшләп чыга.

Лирик чигенеш озынгарак китте, сүзем Фасил Әхмәтовның минем шигыремә язган жыры турында иде. "Жырга әйләнгәч шигырьнең композициясе үзгәргән",—дидем. Фасил "Жырның башы тамашачыны беренче сүзләрдән үк үзенә алып кереп китсә генә аны кызыксынып тыңлыйлар",—диде.

Без бу мәсьәләдә шактый бәхәсләштек. Һәркем үз фикерендә калды. Фасил үзе белән килешмәгәнгә мина үпкәләп тә йөрде бугай. Менә бервакыт "Ташлама"ны Фердинанд Сәләхов жырлый башлады. Люция Хәсәнова башкаруында лиризм, нечкәлек, йомшаклык өстенлек итсә, Фердинанд Сәләховныкында күтәренкелек күбрәк. Фердинанд "ташлама" сүзенә ныграк басым ясаса, Люция исә шигъри образдагы "сөю", "яшьлек" кебек төп фикерне белдерүче сүзләргә игътибарын күбрәк юнәлтә. Фердинанд жырлавында оптимизм, Люциянекендә эчкә яшерелгән сагыш бар иде.

Бу ике жырдан соң Фасил белән араларыбыз тагын да якыная төште. Без инде аның белән берәр зуррак әсәр язарга планнар кора башладык. Фасил Әхмәтов белән бер үк йортта М. Жәлил исемендәге опера һәм балет театрының баш режиссеры Валерий Раку яши икән. Көннәрдән бер көнне мина Валерий Раку шалтыратты: "Безне татар әсәрләре куймауда гаеплиләр. Менә без шул тәнкыйтькә колак салып, авторлар белән мөнәсәбәткә керергә уйладык. Берәр музыкаль комедиягә либретто кирәк иде. Яза алмассызмы? Дөрес, бездә Нияз Даутов вакытыннан ук ята торган бер либретто бар. Ләкин аны бу килеш куярлык түгел. Бәлки шуны карап чыгарсыз, ул автор белән бергәләп эшләсәгез дә риза. Ул профессиональ язучы түгел. Ә безгә бу эшнең остасы кирәк",—диде Раку.

—Берәр сюжет башка килсә, мин сезгә хәбәр итәрмен,—дидем һәм уйлана башладым. Төрле жанрларда эшләсәм дә, музыкаль комедия либреттосы язып караган юк иде.

Безнең татар сәнгатендә озак еллар барган М. Фәйзинең "Башмагым"ын укып чыктым. Китапханәдән "Йөз либретто" дигән китап кайтарттым. Тик бу китап әллә ни файдалы булып чыкмады. Анда либреттоларның кыскача сюжеты гына язылган икән. Сюжетларда әсәрнең эчке структурасы, композициянең нинди формада үстерелеше күрсәтелмәгән иде. М. Жәлилнең опера өчен язылган барлык либреттоларын укып чыктым.

Озак вакыт әһәмиятен югалтмый торган вакыйга кирәк иде. Ниһаять, башка бер фикер килде. Ул сабантуй темасы булырга тиеш. Сабантуйда жыр-биюләр, кызыклы хәлләр булып тора. Конфликтны шушы нигездә корырга булдым.

В. Ракуга хәбәр иттем. Композиторлардан Фасил Әхмәтов белән Ренат Еникеевны да чакырдым. В. Раку опера һәм балет театрының әдәби бүлек мөдире Рәмзия Такташ һәм Таубе фамилияле бер режиссер белән килде. Алар килгәндә Фасил Әхмәтов белән Ренат Еникеев бездә утыралар иде инде. Бераз аны-моны сөйләшеп алганнан соң, язылачак либреттом белән таныштыра башладым. Сюжет болай иде: авылда бер чибәр кыз бар, аңа өч егет гыйшык тотып йөри, ләкин кызның сөйгән егете бар. Әмма ул шәһәргә китеп барган. Кызның егете белән кавышуына өмете өзелә башлаган. Авыл егетләре сабантуй көне алдыннан кызны урамда урап алып: "Йә берәребезгә кияүгә чыгасың, йә сине сабантуй көнне урлыйбыз",—диләр. Кыз сабантуйда батыр калучыга чыгарга ризалык бирә. Әмма һаман әле егете кайтып төшәр дип өмет итә. Аның шәһәргә китеп барган егете атаклы көрәшче, көрәшер өчен генә булса да кайтыр дигән уй жылыта кызның күңелен. Сабантуйда өч егетнең

берсе дә батыр кала алмый. Батыр калучы өлкән яшьтәге кеше булып чыга.

Сюжет әнә шундый күп борылышлы, кызыклы вакыйгаларга бай иде. Язылачак либреттоның эчтәлеге һәммәсенә ошады.

—Давай, тиз арада яза башла,—диде Валерий Раку.—Бөтенләй язып бетергәнне көтмә. Бер пәрдәсен язу белән безне чакыр. Укырбыз, фикерләшербез.

Аннары ул Фасилгә борылып:

—Музыкасын син язарсың дип уйлыйм,—диде.

—Мин бит инде сездә куелмый яткан либреттога биш-алты ария язган идем. Шуларны файдаланырга мөмкин. Арияләрне Фәнис мин язган музыка кисәкләренә сыйдырырлык итеп яза алыр, анысына ышанам,—диде Фасил.—Бер шәп кенә увертюра язып җибәрсәм, спектакльнең яртысы әзер диярлек була.

Булачак әсәребезнең уңышлы чыгуы өчен бер "ярты"ны бушатканнан соң кунаклар таралышты. Икенче көнне үк эшкә тотындым. Әсәр шактый җиңел барды. Фасилга кайбер арияләрне телефон аша әйтеп торып яздырдым. Ул музыкасының ритмикасына туры китерер өчен кайбер арияләрне кабат-кабат эшләтте. Бернинә атна дигәндә либреттоның беренче пәрдәсе әзер иде инде. Тагын В. Ракуны чакырдым. Бу юлы да режиссер Таубе килгән, хәтта аларга СССРның халык артисты Азат Аббасов та ияргән иде. Әсәрнең язылган кадәресен укып һәр җөмләне русчага тәрҗемә итә-итә телләр әйләнмәс хәлгә килде. Татарча язылган либреттоны бөтен нечкәлекләре белән "на ходу" гына тәрҗемә итү җиңел түгел иде. Безнең традицияләрне рәтләп белмәгән, сабантуйларны ниндидер спорт ярышлары белән чагыштырып караучы башка милләт кешесе өчен әсәрем бик үк кызыклы тоелмады бугай. Ракуның чырае бозылды.

Эшемне бетергәч җиңел сулап театр карамагына, ягъни театрның әдәби бүлек мөдире Рәмзия Такташ кулына тапшырдым. Атна, айлар көтеп тә театрдан һич бер хәбәр алмагач, театрга шалтыраттым. Валерий Раку: "Мин сезнең әсәрегезне Фасил Әхмәтовка бирдем",—дигәч, Фасилга шалтыраттым. Фасил: "Әйе, Раку аны миңа биргән иде, ләкин минем авырып яткан чак булгач, ул аны башка композиторга бирәм дип, кире алып чыгып китте",—диде. Аптырагач, театрның директоры Рүфәл Мөхәммәтҗановка шалтыраттым. Ул: "Без аны русчага тәрҗемә иттерәбез, хәзер аңа подстрочник ясыйлар, рус режиссерлары татарча материал белән эшли алмыйлар бит",—диде.

Шулай итеп бу комик опера дөньяга чыга алмады. Соңыннан мин аны драмтеатрлар өчен кабат эшләдем һәм ул Г. Камал, К. Тинчурин театрларында куелды. Ләкин ул имгәтелгән, әсәргә яктылык биреп торучы лиризм урынына шарж килеп кергән һәм арияләр дә тиешле югарылыкта башкарылмады. Дөрес, һәр ике театрда әсәр уңышлы барды. Режиссерга рәхмәтемне әйтсәм дә, күңелдә барыбер канәгатьсезлек калды.

Шул чорда китап нәшриятында пьесаларым китап булып басылып ята иде. Шунда кайсыдыр редактор "Сөембикә егет сайлый"ны (бу әсәр шулай дип атала иде) Луиза Батыркаевага биргән. Луиза Батыркаева (Батыр-Болгарый) ул чагында китап нәшриятында музыкаль редактор булып эшли иде. Әсәрне укып чыккан, ошаткан. Аннары безгә килгән, килгән дим, чөнки ул көнне без бакчада булганбыз.

Бу опереттаның дөнья күрә алмавына артык исем китмәде. Язучылык эшендә андый уңышсызлыклар булып тора, башка әсәрләргә тотындым.

Фасил Әхмәтов белән дә ара өзелмәде. Язмыш безне, ни өчендер, гел якынайтырга тырышты. Шулай бервакытны безгә яна туган чебеш кебек кечкенә, ләкин чибәр генә бер кыз килеп керде. Укучылар, студентлар күп килеп йөргәнлектән, моңа аптырамадым. Кыз кыю иде. Ул үзе белән таныштырып: "Мин Гөлнара Тимерҗанова булам. Монда, Казанда музыка училищесының беренче курсында укыйм. Үзем Башкортстаннан",—диде.

—Ничә яшь соң сиңа?—дип сорадым.

—Унбиш тулды инде. Уналтыга чыктым. Тугызынчы классны бетердем дә музыка училищесына килдем.—Ул бераз тын торганнан соң:—Миңа бер җыр кирәк иде,—диде.

—Нинди җыр кирәк соң сиңа? Мин бит композитор түгел, шагыйрь,—дидем.

—Беләм,—диде ул.—Ләкин шигырь булмаса, композитор көй яза алмый бит.—Миңа яраткан егетемә җырлый торган җыр кирәк. Мин ул җырны тик аның өчен генә башкарачакмын.

—Яраткан егетен дә бармыни?

—Бар, нигә булмасын. Без озакламый анын белән өйләнешәчәкбез. Менә шунда туйда жырлаячакмын мин ул жырны.

—Ул егетен кайда соң?

—Авылда.

—Ә син артист булырга жыенасын. Казанга укырга килгәнсен. Өйләнешкәч авылда калырга туры килер бит.

—Юк, калмаем. Мин татар кызы, Казанда жырларга тиеш.

Мин Гөлнараны жырлатып карадым. Анын тавышы лирик сопрано иде. Халык жырларын да матур гына башкара икән. Гөлнара чыгып киту белән күнелемнән анын халәтенә туры килерлек сүзләр эзли башладым. Нәтижәдә менә бу шигырь туды.

Мин синеке, бары синеке,
Шикләренне тарат күнеленнән.
Яшьлегемнен якты таннарында
Тинем итеп сине сайлавыма
Мин үкенмәм, мәнге үкенмәм.

Мин синеке, бары синеке,
Башкалар юк минем уемда.
Күнелләрем назга сусаганда,
Кара төннәр юлда очраганда
Коенамын күзен нурында.

Мин синеке, бары синеке,
Син эчерден сөю моннарын.
Матур гөлләр диеп үрелсәм дә,
Бәхетемә таба йөгерсәм дә,
Сина илтә барлык юлларым.

Гөлнара Тимержанованы чакырып, аңа шигыремне укып күрсәттем. Ул шигырьне бик яратты. "Нәкъ минем күнелдә йөргән сүзләрне язгансыз",—диде һәм шигырьне күчереп алды.

—Хәзер композитор кирәк бит инде мона,—дидем. Гөлнара минем белән килешеп "әйе" дип куйды. Яна гына укырга кергән унбиш-уналты яшьлек кызнын таныш композиторлары югын белә идем, сүзне озакка сузмыйча Фасил Әхмәтовка шалтыраттым:

—Фасил, менә минем янымда бер чибәр кыз утыра. Жырчылыкка укый. Шуна тиз арада гына бер жыр кирәк иде.

—Шигыре бармы сон?

—Шигырен яздым. Хәзер укып күрсәтәм.—Һәм телефоннан шигырьне укыдым.

—Болай ярыйсы күренә—диде Фасил,—әйдә шигырен алсын да безгә килсен. Мин анын тавышын тынлап карармын.

Гөлнарага Фасилнен адресын бирдем. Бу 1991 елда иде.

Берничә сәгатьтән Фасил мина шалтыратты:

—Кызын килде, тавышын тынлап карадым. Моны бар. Халык жырларын да әйбәт жырлый. Ин мөһиме: күптәнге жырларга үз аһәнен кертеп жибәрә. Кайвакытта гади генә мелизм жырны янарта. Бу кызны үстерергә кирәк. Ә синен шигыренә көй язармын дип уйлыйм. Хәзер мин ижат йортына китәргә жыенам. Балки, шунда язып та кайтырмын.

Фасил сүзендә торды, шигырьгә музыка язып кайтты. Бер килгәч аны ноталары белән Гөлнарага тапшырдым. Гөлнара рәхмәт әйтеп чыгып киткәндә: "Өйрәнгәч тә жырынны мина жырлап күрсәт!"—дип калдым.

Шактый вакыт үтте, Гөлнара һаман жырны өйрәнмәде. Бер килгәндә мин анардан: "Жырны кайчан жырлап күрсәтәсен сон инде?—дип сорадым.—Фасил да көтә бит. Син жырны өйрәнеп беткәч, Фасилны кунакка чакырачакмын. Ул үзе дә гел сине сораштырып тора: "Гөлнара жырын әзерләгәч тә мин гармунымны күтәреп сезгә кунакка киләм",—ди".

—Бик авыр җыр булып чыкты әле ул,—диде Гөлнара.—Кайбер ноталарны алып булмый. Тавыш икенчегә күчә.

—Фасилга әйтсәң, бәлки ул аны беразгадиләштереп бирер,—дидем. Гөлнара аны-моны әйтмәде, мин аның бу җырны җырларга ашкынып тормавын сиздем. Күрәсең, егете белән аралары суына башлаган булгандыр һәм бу җырның кирәге калмагандыр.

Яңадан бу җыр турында сүз кузгатмадым. Аны берәр вакыт ишетермен дип тә көтмәдем. 1998 елда Г. Камал театрында минем 60 яшьлек юбилеемны уздырдылар. Иҗат бәйрәмендә катнашырга Гөлнараны да чакырдым. Ул инде музыка училищесыннан соң консерватория тәмамлаган, танылып килүче җырчы иде. Һәм мин аңа яңадан да бик күп җырлар яздым. Минем җырларны җырлап ул 2001 елда "Алтын барс" бүләгенә лаек булды. Хәзер аның репертуарында минем шигырьләргә язылган унбиш җыр бар. 60 яшьлек юбилей кичәсендә инде ул "Мин синеке, бары синеке" дигән җырны җырлады. Залда бәйрәм рухы хөкем сөргәнгәме, Гөлнара әйбәт җырладымы—тамашачы җырны яратты. Мондый кичәләрдә теге яки бу җырның ничек кабул ителүе залның рухи атмосферасыннан да тора. Гөлнарага чәчәкләр менгерүчеләр дә булды. Ул бер бәйләм чәчәген миңа, икенчесен тамашачылар арасында утыручы Фасилгә төшерде. Икенче көнне Фасил миңа шалтыратып: "Карале, Фәнис, безнең җыр ярыйсы килеп чыккан бит",—диде.

—Әйе,—дип килештем мин.—Җырның уңышлы чыгуында Гөлнараның да өлеше бар инде. Яшь, чибәр җырчы. Моңарчы әле сәхнәләрдә күренмәгән диярлек. Тамашачыны туйдырып бетергән артист түгел.

—Анысы бар,—диде Фасил,—озак киелгән киемнән туйган кебек, көн саен йә сәхнәдән, йә телевизордан күренеп яки радиодан ишетелеп торган җырчылар туйдыра шул. Халыкка яңалык кирәк. Ә безнең артистларның кайберләре "комы коелып" беткәнче сәхнәдән төшәргә теләми. Шуның белән ул үзенең элек яулаган даның үтерә.

Фасил белән мондый темаларга элек тә сөйләшкәли идек. Бервакыт ул хәтта болай дигән иде: "Без ул яктан бәхетле. Икебез дә авыру кешеләр. Ә иҗатларыбыз—Аллага шөкер. Үзебездән алдан үлмәстер, шәт. Минем "Аккошларым" гына ни тора!"

Ул Равил Фәйзуллин шигыренә язган бу җырын бик ярата һәм аның белән горурлана. "Минем ике җырым булса да яшәр әле",—ди иде.

—Икенче җырың?—дип сорадым.

—"Таң йолдызы",—диде ул.—Минем хатынның исеме Йолдыз бит. Шушы җырны язып үземә караттым мин аны. Югыйсә минем кебек көчкә өстерәлеп йөргән кешегә кем чыгар иде.

—Алай димә...

Без һәркайсыбыз үз язмышларыбызны уйлап тын калдык. Бераздан Фасил:

—Минем хатын Баулыдан бит, син шуны беләсеңме?

—Йолдызың белән якташлар икәнбез, шуны моңарчы әйткәнең дә булмады.

—Әйтсәм ни булыр иде? Син дә бит Нурсөяңнең Мари республикасыннан икәнен әйтмәдең. Мин башкалардан гына ишеттем.

Без хатыннарыбыз турында сөйләшеп киттек.

—Ярый әле синең Нурсөяң, минем Йолдызым кебек хатын-кызлар бар. Без фәлән нәрсә яздык, дип мактанырга яратабыз. Ә бит алар булмаса, безнең иҗат та булмас иде,—диде Фасил һәм ул: "Үзем гел сезгә киләм, ә сезне үзебезгә алып барган юк. Хәзер менә минем "Запорожец" белән чыгып китәр идек, салган баштан рульгә утырырга ярамый. Үзем генә булганда утыргалыйм инде, анысы яшеренбатырын түгел. Ә кеше белән ярамый. Берәр көнне улым Азат килеп алыр әле.

Әмма кунакка барырга туры килмәде. Шулай да улы Азат белән таныштык. 1994 елда нефтьчеләр ярдәме белән минем өч томлык сайланма әсәрләрем чыккан иде. Спонсорлар чыгарган китапка гонорар түләнми икән. Гонорар урынына китапларымны бирделәр. Аларны сатарга кирәк. Эшне ничек башларга белми торганда, Балтачтан Вагыйз Сәләхов дигән бер дустым килеп төште. Бездәге китап өемнәрен күргәч ул:

—Безгә китерегез, китапларыгызның бөтенесен бер сәгатьтә үзем сатып бирәм,—диде. Вагыйзнең бераз арттырыбрак сөйләгәнен белсәк тә, бер җае чыккач, барырга

булдык. Балтач халкының киң күңелле, кунакчыл икәнен белә идек. Чөнки 1972 елда алар мина, армиядә имгәнеп кайткан кеше буларак, "Запорожец" машинасы биргәннәр иде. Нәкъ шул елны Вагыйз мәдәният институтының режиссерлык бүлегенә керергә имтихан бирергә килгән иде. Бер ай буе безнең идәндә тәгәритәгәри имтиханнарга әзерләнде. Белем ягы сайрак булса да, сөйләшергә оста иде. Соңгы имтиханын биреп кайткач: "Рәхмәт инде тиктормас телемә. Белгәнне дә, белмәгәнне дә сөйләдем. Профессорлар мине туктатмакчы була, ә мин сөйлим дә сөйлим. "Житте, житте, "бишле" куябыз",—дигәч кенә тукталдым. Пеләш башлы профессорларга: "Мин Чапшар егете, исегездә тотыгыз",—дип чыгып киттем",—дип көлдереп, киткән чакта үзләренә кунакка чакырган иде.

Көз ул елны жылы килде. Безнең барыр урын юк. Тоттык та киттек Балтачка. Вагыйз Чапшар дигән кечкенә генә авылда клуб мөдире булып эшли икән. Безне бик жылы каршы алдылар. Вагыйз тиз арада клубка халыкны жыеп, очрашу оештырды. Безне очраганы-бере кунакка чакыра башлады. Аларда бер атна кунак булдык, мунчалар кердек. Без барган елны Вагыйзнең жингәсе Салисә бәбәй табарга жыена иде. "Кыз тапсам—Нурсөя, малай булса—Фәнис кушабыз, Алла боерса",—дип калганнар иде. Салисә ханым кыз тапты һәм ана Нурсөя дип исем куштылар.

Вагыйз безгә, без аларга баргалап тордык. Мәдәният институтын бетергәннән соң Вагыйзне Балтач район мәдәният йортына директор итеп куйдылар. Вагыйз өйләнеп жибәрде, район үзәгендә йорт салып башка чыкты.

Вагыйзләрнең яна йортларын да күргән юк иде, китаплар төяп Балтачка барырга булдык. Бер сөйләшүдә бу турыда Фасил Әхмәтовка әйткән идем, ул: "Минем Азат сезгә ярдәм итәр. Ул машинаны әйбәт йөртә",—диде.

Безгә бер ел элек кенә нефтьчеләр "Жигули" бүләк иткәннәр иде. Машинаны тутырып китаплар төядек. 800 данә иде булса кирәк. Ул томнарның һәрберсе ярты кило. Әле шуның өстенә үзебез өч кеше. Әченә кереп утыргач машинабыз сыгылып төште. Китапларны да калдырасы килми. Машинаның арты жиргә тиям-тиям дип бара. Азат: "Шундый шәп машинаны әрәм итәбез",—дип безгә бераз үпкә белдерде.

Исән-имин Балтачка барып життек. Вагыйзләргә кердек. Ул безне администрация бинасына алып китте. Хакимият башлыгы ул чакта Марат Әхмәтов иде. Безнең янга тиз-тиз атлап Марат Әхмәтовның урынбасары Гарифжан Мөхәммәтшин белән ул чактагы мәдәният министры урынбасары Мөжип Низамиев килеп чыктылар. Исәнләштек, күрештек, нинди максат белән йөрүебезне әйттек. Гарифжан Мөхәммәтшин үзе дә шагыйрь кеше, китап чыгару һәм аны халыкка житкерү кыенлыкларын белә. Ул безгә ярдәм итешергә булды: "Биш йөз китапны администрация сатып алыр. Ләкин әле генә түләргә акча юк. Китапларыгызны китапханәләргә, мәктәпләргә саткач, акчасын үзем китерермен",—дип биш йөз китапны алып калды. Машинага да, үзебезгә дә жинел булып китте.

Безнең бәхетебезгә, Балтачта укытучыларның август кинәшмәсе бара икән. Без килгәнне ишеткән укытучылар машинабызны сырып алдылар. Ул көнне йөздән артык автограф язарга туры килде. Фасилның улы Азат, чынлап та, машинаны әйбәт йөртә икән. Әллә нинди чокырлы-чакырлы юлларда да батмыйча, ике көн дигәндә 800 дән артыграк китапны сатып бетереп кайттык. "Балтач халкы китап ярата",—дигән иде Вагыйз, сүзе дөрес булып чыкты.

Юлдан кайткач Фасилга шалтыраттым.

—Мондый уңышны "юмый" калырга ярамый инде, бер килеп чыгам әле,—диде ул. Һәм, көннәрдән бер көнне Азат аны безгә китереп китте. Фасил минем шигырьләргә язган жырларының ноталарын да алып килгән иде."Әле үзең ишетмәгән жырың да бар монда",—диде ул һәм тальянын сузып бер көй уйнап күрсәтте:—"Синең "Бирмә мине беркемгә дә" дигән шигыреңә яздым мин моны. Берничә жырчыга жырлатып карадым, образны ачып бетерә алмыйлар. Аннары "Бирмә хәтта үлемгә" дигән сүзгә бәйләнәләр. Имеш, жырга үлем сүзе керергә тиеш түгел. Клара Хәйретдинова балки жырлар. Ул жырны яратып алып калган иде".

Күпмедер вакыт үткәч Клара Хәйретдинова башкаруында бу жыр радиодан ишетелә башлады.

Хәзер йөздән артык жырымны жырчылар жырлап йөри. Ләкин, жырга мәхәббәтем һәм күпмедер жырлау сәләтем булуга карамастан, мин үз шигырьләремә язылган

көйләрне отып кала алмыйм. Чөнки алар минем эчке халәтемә туры килеп бетми.

Бу сүзләр Фасил Әхмәтовның иҗатын кечерәйтеп күрсәтү өчен түгеллеген укучы аңлыйдыр, дип уйлыйм. Фасил, гомумән, җырга бик таләпчән карый иде. Кайбер очракларда фикерләр аерымлыгы булгаласа да, гомумән алганда, без аның белән җинел аңлаша идек. Гел рухи якынлык сизеп яшәдек. Безнең әле аның белән эшлисе эшләр, корган планнар күп иде. Ләкин ул бер көнне миңа: "Фәнис дус, мине Әлмәткә чакыралар. Ике бүлмәле фатир бирәбез, эшләр өчен шартлар тудырабыз, диләр. Нишләргә икән?"—дип шалтыратты.

—Әлмәт Казан түгел инде ул. Анда, кечкенә шәһәрдә, җаның кысанлык тоймасмы соң?—дидем.

—Теләсә кайчан Казанга кайтып килергә машина бирәбез, дип вәгъдә итәләр. Бер уйласаң, Казанда да кысан безгә. Дөньяга чыгарырлык иҗатыбыз бар. Ләкин күп вакыт безне күрмиләр. Без өч бүлмәле кечкенә фатирда бишәү яшәп ятабыз: малай, килен, оныкһәм хатын белән без. Үзең беләсең, минем хатын табиб, аңа кинәшкә яки ярдәм сорап килүчеләр никадәр. Үземне әйтмим дә инде: көнenә ничә шагыйрь, ничә җырчы килә. Музыка бит ул сукыр тычкан түгел, кечкенә генә чокырга сыймый. Бәлки иркен урында фикерләр дә иркенлек алыр. Юкса кысага кысылып барам кебек,—диде Фасил.

—Үзенә кара инде,—дидем.—Ләкин мин шушы Казанның төтенле һавасын суламасам, яза алмыйм. Монда бит ниндидер иҗади атмосфера. Син миңа бер җыр язуга аны җырчыларга тыңлатып карый аласың, фикер алышасың.

—Каядыр күчәсе килә минем,—диде ул көрсенгәндәй итеп.—Үземнең иҗатымнан да канәгать түгел. Әлмәттә балалар белән эшләрсең, диләр. Үзең белгәнне балаларга өйрәтеп калдыру да начар түгел бит.

—Начар түгел, ләкин балалар монда да бар бит. Консерваториядә дә укыттың. Ялгышмасам, әле һаман берничә малайны үз өеңә китереп музыка серләренә төшендерәсең бугай.

—Әйе, сәләтле малайлар алар. Ләкин, үзең беләсең, Казанда сәләтне ачарга мөмкинлекләр бар, ә бәләкәй шәһәрләрдә, авылларын әйтеп тормыйм инде, күпме талант ачыла алмый кала. Бәлки мин анда Фасил Әхмәтов мәктәбе ачып җибәрермен.

—Алайса планнарың зурдан икән. Шәп эш булачак бу. Анда Ринат Галиев ярдәм итми калмас сиңа.

Ринат Галиев ул чагында "Татнефть"нең генераль директоры иде. Ул милләтне үстерү, талантларны дөньяга чыгару өчен җанын-тәнен кызганмый торган кеше. "Рухият" фонды ачып, нефть чыга торган төбәкләрдәге язучыларның китапларын бастырып чыгару, кайбер талантлы балаларны консерваториягә кертергә ярдәм итеп, аларга уку дәвамында стипендияләр түләп тору, ел саен яшь талантларны Казанга җыеп фестивальләр үткәрү кебек эшләрне ул башлап җибәрде. Фасилны Әлмәткә чакыручы да ул иде.

—Иҗат кешеләренә Әлмәттә бер йорт төзиләр икән. Шул бетүгә китәм инде,—дип йөри иде Фасил.

Ләкин...

Ләкин көннәрдән бер көнне Идел буендагы бакчасында Фасилның йөрәге тотып, больницага да барып житә алмыйча вафат булуы турында хәбәр килде. Үз иҗаты турында гына түгел, милләтебезнең яшь талантларын эзләп табып, дөньяга чыгару турында кайгыртып йөргән зур шәхес арабыздан китеп барды.

Фасил Әхмәтов кебекләрнең иҗаты милләтне милләт итүче, татарның барлыгын, талантлы халык икәнен дөньяга белдерүче иҗат. Ләкин һаман бер сүзне кабатларга кала: талантлы кешеләргә яшәү авыррак. Алар үзләренә зур миссия йөкләнгәнен яхшы аңлыйлар. Шушы миссияләрен үтәү өчен бөтен көчләрен куялар һәм очышта үлгән кошлар кебек кинәт, биектә калалар.

Зур талант иясенә багышланган бу язмамны Фасилның вафатыннан соң иҗат ителгән шигырем белән тәмамлыйм.

Миңа син дә китеп бардың, Фасил,
Киткән "Аккошлар"ың артыннан.
Ул аккошлар синең пакь җаныңны
Саклап барыр җилдән-салкыннан.

Якын иттек без гел бер-беребезне,
Аралашмасак та бик артык.
Җаннарыбыз безнен кардәш иде,
Шул кардәшлек торды гел тартып.

Зарланышып ала идек кайчак
Озак-озак итеп телефоннан.
Трубканны куеп роялена
Бер көй уйный идең син соннан.

Әйтә идең: "Шәп чыккан бит, малай,
Музыкада бу бит—яналык.
Чукынып китсен, хәер, яналыгы,
Ничек анда синен тазалык?

Язасынмы һаман? Язасындыр.
Үземә дә бу эш бик таныш.
Тик "тегендә" генә булыр ахры
Синен белән мина тукталыш.

Без бөекләр... Юк, юк каршы килмә,
Без бит моны яхшы беләбез.
Яраларны яшереп бәйли-бәйли,
Карурманнан җырлап киләбез.

Бездән чыкмый сыкрау авазлары,
Безнен тавыш һаман көр әле.
Мин уйнармын сина яна бер көй,
Такси ал да мина кил әле.

Хәер, килмә, үзем барам сина,
Эләктерәмен дә бер "ярты".
"Генераллар" булып утырырбыз,
Сонга калсак—күктә Ай якты".

...Шулай диеп шалтырата идең,
Уенын-чынын кушып гел бергә.
Вакыт күп тә, гомер кыска икән
Кунак-кунак булып йөрергә.

Ашыга-ашыга китеп бардын, Фасил,
Киткән "Аккошлар"ын эзеннән.
Аккошларнын ап-ак каурыйлары
Кабрен өсләренә сибелгән.

Фасилнын арабыздан китүенә дә алты елдан артык вакыт үтте. Ә "Аккошлар"ы һаман оча, "Тан йолдызы" калка, ләкин күнелдән сагыш кына китми. Олы шәхесләребезне кинрәк дөньяга чыгара алмавыбызга күнел рәнжи.

# Татарстан Республикасы Президенты Указы

## Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген бирү эшчәнлеген оештыруны камилләштерү, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә дәүләт бүләгенең әһәмиятен арттыру, иҗади эшчәнлекне стимуллаштыру максатында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге җәмгыять тарафыннан киң танылган, илебез мәдәниятен һәм милли мәдәниятне үстерүгә зур өлеш керткән, югары профессиональ осталыгы белән аерылып торган, үзенчәлекле автор стиленә ия булган аеруча күренекле әдәбият һәм сәнгать әсәрләре, шулай ук сәнгать һәм әдәбият белеме өлкәләренә караган күренекле фәнни тикшеренүләр өчен бирелә дип билгеләргә.

Ел саен һәркайсы 300 мең сум күләмендә булган Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге өч дәүләт бүләген бирергә.

2. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Комиссия турында Нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Комиссия составын расларга (3 нче кушымта).

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген бирү һәм түләү белән бәйле чыгымнарны финанслау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бүлүне тәэмин итәргә;

үзенең элек чыгарган хокукый актларын әлеге Указга туры китерергә;

әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка чаралар күрергә.

6. Әлеге Указ рәсми төстә басылып чыккан көннән көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **М. Ш. ШӘЙМИЕВ**
*Казан, Кремль*
*2004 ел, 31 декабрь*

*Татарстан Республикасы Президентының*
*2004 елның 31 декабрендәге 824нче Указына*
*1 нче кушымта*

## Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында НИГЕЗЛӘМӘ

1. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге җәмгыять тарафыннан киң танылган, илебез мәдәниятен һәм милли мәдәниятне үстерүгә зур өлеш керткән, югары профессиональ осталыгы, яңалыгы һәм оригинальлеге белән аерылып торган, үзенчәлекле автор стиленә ия булган, аеруча

күренекле әдәбият һәм сәнгать әсәрләре (сынлы сәнгать, музыка, театр, эстрада-цирк, кино сәнгате әсәрләре, архитектура һәм шәһәр төзелеше), шулай ук сәнгать һәм әдәбият белеме өлкәләренә караган күренекле фәнни тикшеренүләр өчен бирелә.

2. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә бирелә.

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында Татарстан Республикасы Президенты Указы Габдулла Тукайның туган көненә (26 апрельгә) басылып чыга.

3. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган затларга "Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты" исеме бирелә, акчалата бүләк, диплом, мактаулы лауреат билгесе һәм әлеге билгенең таныклыгы тапшырыла.

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты билгесе, СССРның Ленин һәм Дәүләт бүләге, Россия Федерациясе Дәүләт бүләге лауреатларының мактаулы билгеләреннән соң, күкрәкнең уң ягында йөртелә.

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан тантаналы шартларда тапшырыла.

4. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге персональ характерда һәм, кагыйдә буларак, бер кешегә генә бирелә. Теге яки бу казанышка ирешүдә берничә зат хәлиткеч роль уйнаганда, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге әлеге бүләкне дәгъва иткән коллективка да бирелергә мөмкин, ләкин монда коллектив сигез кешедән дә артык булмаска тиеш. Бу очракта Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге дипломы, мактаулы билге һәм таныклык лауреатларның һәркайсына тапшырыла, ә акчалата бүләк түбәндәгечә бүленә:

өч кешедән торган авторлар коллективында коллектив җитәкчесенә бүләк акчаның яртысы бирелә, ә икенче яртысы калган ике кеше арасында тигез итеп бүленә;

авторлар икәү булганда акчалата бүләк алар арасында тигез итеп бүленә;

коллектив дүрт һәм аннан да күбрәк кешедән торганда коллектив җитәкчесенә акчалата бүләкнең өчтән бер өлеше бирелә, ә өчтән ике өлеше коллективның калган әгъзалары арасында бүленә;

авторлар коллективы җитәкчене күрсәтмәгән очракта акчалата бүләк коллективның барлык әгъзалары арасында тигез итеп бүленә.

Аерым очракларда, аеруча мөһим һәм яңа казанышларга ирешкәндә, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреатларга икенче мәртәбә дә бирелергә мөмкин.

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге вафат булганнан соң да бирелергә мөмкин. Вафат булганнан соң яисә үлгәч бүләкләнгән лауреатның дипломы һәм мактаулы билгесе истәлек итеп гаиләсенә бирелә яисә гаиләсендә калдырыла, ә акчалата бүләк Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мирас рәвешендә тапшырыла.

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителүчеләр арасында бүләккә лаек кешеләр булмаганда яисә аларның саны ел саен бирелә торган Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре саныннан кимрәк булганда, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре бирелми яки кимрәк күләмдә бирелә.

5. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә мәдәният һәм сәнгатьне үстерүгә керткән өлеше әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән шартларга туры килгән зат тәкъдим ителергә мөмкин.

6. Әсәрләрне һәм хезмәтләрне Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим итү Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының башка министрлыклары һәм ведомстволары, Татарстан Республикасының иҗат берлекләре – Татарстан Республикасы Архитекторлар берлеге, Татарстан Республикасы Композиторлар берлеге, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, Татарстан Республикасы Театр эшлеклеләре берлеге, Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге, Татарстан Республикасының билгеләнгән тәртиптә төзелгән башка иҗат берлекләре, шулай ук предприятиеләр, фәнни учреждениеләр, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре, югары уку йортлары, җәмәгать оешмалары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Хезмәтләр

коллегияләр, президиумнар, идарәләр, сәнгать һәм гыйльми советлар утырышларында, хезмәт коллективлары җыелышларында күрсәтелә. Хезмәтләргә бәя бирү, сәнгать процессында аларның урынын билгеләү, бүләккә тәкъдим ителә торган һәр кандидатның иҗади өлешен ачыклау югары таләпчәнлек шартларында, киң җәмәгатьчелек катнашында һәм хәбәрдарлык шартларында узарга тиеш.

Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары, шулай ук мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре үзләренең тәкъдимнәрен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы аша, предприятиеләр, фәнни учреждениеләр, югары уку йортлары, җәмәгать берләшмәләре – тәкъдим ителгән хезмәтләрнең һәм әсәрләрнең асылына туры килгән юнәлешләр буенча, Татарстан Республикасының иҗат берлекләре аша кертәләр.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының тиешле министрлыклары һәм ведомстволары, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре җитәкчеләрен чакырып, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары, шулай ук мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре тарафыннан тәкъдим ителгән хезмәтләрне һәм әсәрләрне башлап тикшерүне оештыра.

Татарстан Республикасы иҗат берлеге, берлекнең теләге булган барлык әгъзаларын чакырып, предприятиеләр, фәнни учреждениеләр, югары уку йортлары, җәмәгать берләшмәләре тарафыннан тәкъдим ителгән хезмәтләр һәм әсәрләр хакында фикер алышу оештырырга, аның нәтиҗәләре буенча тәкъдим ителә торган хезмәтләрне һәм әсәрләрне хуплау яисә хупламау хакында карар кабул итәргә хокуклы. Татарстан Республикасы иҗат берлегенең фикере Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә хезмәтләр һәм әсәрләр күрсәтү хакында тәкъдимнәрне караганда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Комиссия тарафыннан исәпкә алына.

7. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә хезмәтләр һәм әсәрләр күрсәтү хакында тәкъдимнәр Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Комиссиягә һәр елның 15 февраленә кадәр кертелә. Аларның эшләрне кабул итү срогы чыкканга кадәр бер елдан да соңга калмыйча халык алдында башкарылган, басылып чыккан, күрсәтелгән, төзелеп беткән һәм файдалануга тапшырылган булуы шарт.

8. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләренә кандидатлар күрсәткәндә түбәндәге документлар һәм материаллар тапшырыла:

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә кандидат (кандидатлар) күрсәтү хакында гарызнамә;

Татарстан Республикасының иҗат берлеге яисә тиешле коллегиаль идарә органына ия башка оешма тәкъдим иткән очракта әлеге кандидатны (кандидатларны) күрсәтү турында коллегиаль орган карары;

хезмәтнең тасвирламасы;

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителә торган хезмәт;

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителгән хезмәтнең һәр авторы тарафыннан кертелгән иҗади өлеш хакында белешмә, анкета мәгълүматлары (кадрларны исәпкә алу кәгазе);

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителә торган кандидатның (кандидатларның) авторлык эшләре белән бәйле рәвештә аеруча мөһим моментларны ассызыклаучы өстәмә материаллар (фотосурәтләр, сызымнар, аудио- һәм видеоязмалар, репродукцияләр һәм башкалар) бүләккә тәкъдим итүчеләрнең теләге белән җибәрелә.

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә материаллар һәм документлар кертү белән бәйле оештыру-техник мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләнә.

9. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә хезмәтләр һәм әсәрләр тәкъдим итү хакында тәкъдимнәр тиешле материаллар һәм документлар белән бергә Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Комиссия тарафыннан карала.

10. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителгән әсәрләр һәм хезмәтләр матбугатта, телевидение һәм радио

тапшыруларында, җәмәгатьчелек җыелышларында, хезмәт һәм уку йортлары коллективларында, гыйльми, сәнгать, редакция-нәшрият советларында, иҗат һәм башка җәмәгать оешмаларында төрле яклап һәм киң рәвештә тикшерелә. Тикшерү белән бәйле материаллар, бәяләмәләр, тәкъдимнәр Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссиягә җибәрелә һәм алар Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителгән кандидатураны тикшергәндә исәпкә алыналар.

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Комиссия утырышларын уздырганда спектакльләрне, концерт программаларын, кино- һәм телефильмнар, сынлы сәнгать әсәрләре күргәзмәләрен карауны һәм тыңлауны оештыру Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына һәм Татарстан Республикасының "Татмедиа" массакүләм коммуникацияләр агентлыгына йөкләнә.

11. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Комиссия Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителгән әсәрләрне һәм хезмәтләрне карау йомгаклары буенча Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә кандидатларны билгели һәм Татарстан Республикасы Президентына Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген бирү хакында указга кул кую буенча тиешле тәкъдимнәр кертә.

*Татарстан Республикасы Президентының*
*2004 елның 31 декабрендәге 824нче Указына*
*2 нче кушымта*

## Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Комиссия турында НИГЕЗЛӘМӘ

1. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Комиссия (текст буенча алга таба – Комиссия) Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президентына тәкъдимнәр әзерләүгә кагылышлы мәсьәләләрне карау максатында оештырыла.

Комиссия составын Татарстан Республикасы Президенты раслый. Комиссия составына вазыйфасы буенча Татарстан Республикасы мәдәният министры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле һәм Татарстан Республикасы иҗат берлекләре җитәкчеләре, шулай ук башка затлар керә.

Комиссия рәисе булып Татарстан Республикасы Президенты тора.

2. Комиссия Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителә торган әсәрләрне һәм хезмәтләрне карый, карау йомгаклары буенча кандидатларны Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә кандидат итеп күрсәтү хакында карар кабул итә.

3. Составының өчтән ике өлеше катнашканда Комиссия утырышлары вәкаләтле санала.

Татарстан Республикасының Дәүләт бүләгенә Комиссия әгъзасының әсәре тәкъдим ителгән очракта аның авторы, үз кандидатурасын теркәгән мизгелдән башлап Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген бирү турында Татарстан Республикасы Президенты Указы басылып чыкканга кадәр, Комиссия эшендә катнашмый.

4. Һәр хезмәтне яклап утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының кимендә

дүрттән өч өлеше тавыш биргән очракта Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә кандидатлар күрсәтү хакында Комиссия тарафыннан карар кабул ителгән дип санала.

Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

5. Комиссиянең оештыру-документ, мәгълүмат һәм матди-техник эшчәнлеген тәэмин итү Татарстан Республикасы Президенты Аппараты һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

*Татарстан Республикасы Президентының*
*2004 елның 31 декабрендәге 824 нче Указына*
*3 нче кушымта*

## Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Комиссия СОСТАВЫ

**Шәймиев М. Ш.** Татарстан Республикасы Президенты (Комиссия рәисе);

**Вәлиева З. Р.** Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары (Комиссия рәисе урынбасары);

**Абзгильдин А. А.** Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге рәисе (килешү буенча);

**Галимуллин Ф. Г.** Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе (килешү буенча);

**Кәлимуллин Р. Ф.** Татарстан Республикасы Композиторлар берлеге рәисе (килешү буенча);

**Миңнуллин Т. А.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, драматург (килешү буенча);

**Ратникова Р. А.** Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары (килешү буенча);

**Сәйфуллин И. Ф.** Татарстан Республикасы Архитекторлар берлеге идарәсе рәисе (килешү буенча);

**Славутский А. Я.** В.И.Качалов исемендәге Казан рус академия Зур драма театры баш режиссеры (килешү буенча);

**Сөнгатуллина З. Д.** М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры артисты, Казан дәүләт консерваториясе профессоры (килешү буенча);

**Тажетдинов Р. А.** Татарстан Республикасы Театр эшлеклеләре берлеге идарәсе рәисе (килешү буенча);

**Тарханов И. Г.** Татарстан Республикасы мәдәният министры;

**Терентьев А. М.** Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының җәмәгатьчелек белән элемтә һәм милләтара мөнәсәбәтләр бүлеге мөдире;

**Хәсәнов М. Х.** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Президенты;

**Шутиков А. И.** Татарстан Республикасы халык уен кораллары дәүләт оркестрының сәнгать җитәкчесе (килешү буенча).

Гыйлем-Фән

# Адлер Тимергалин

## МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***КЕРӘШЕННӘР*** — Православие диненә күчкән, ягъни чукындырылган татарлар ("крещен"-*чукындырылган* дигән рус сүзеннән). Чукынуны татарда тагын *төртенү* дип тә әйтәләр. *Төртенмеш, чукынмыш*-чукындырылган, ягъни "керәшен" дигән сүз була. Бу сүзләр татар арасында тискәре төсмерле мәгънәгә ия. Чуаш һәм мари телләрендә дә таңгал яңгырашлы *керәшен* — "чукынган татар кешесе". Үз керәшеннәрен дә бу күрше халыклар шулай атаганнар (татар теле тәэсирендә). Чит илләрдә керәшеннәрне "baptized", ягъни "чукындырыл-ганнар" дип атыйлар *(М.Глухов)*. Тагы шуны да әйтергә кирәк, христиан төркиләр VII гасырдан ук билгеле, әмма алар "керәшен" дип аталмаган *(Р.Әхмәтьянов)*.

Үзатамалары да — керәшен, кайбер төркемнәре үзләрен нагайбәкләр дип йөртәләр. Чуаш һәм мари телләрендә дә таңгал яңгырашлы *керәшен* — "чукынган татар кешесе". Үз керәшеннәрен дә бу күрше халыклар шулай атаганнар (татар теле тәэсирендә).

Аерым тикшеренүчеләр, мәсәлән, М.Глухов, "керәшен" этнонимының килеп чыгышын *керчин* (санскр. *кер*-тау+кыт. *чин*-кеше) сүзенә кайтарып калдырмакчы. М.Глухов фикеренчә, бу сүз — татар кабиләләренең берсе исәпләнгән кераитларның үзатамасы һәм, ихтимал, керәшеннәр шул халыкның варислары булыр. М.Глуховның "фикри гимраннары" сүзләрнең формаль охшашлыгына гына корылган һәм "этимология бовина" (нигезсез, буш, "үгез" этимологиясе) дигән нәрсәнең ачык бер үрнәге генә. (Хәер, үзенең 2002 елның мартында русча газиттә басылган "Народ в народе" исемле кечкенә язмасында ул "керәшен" сүзенең "сөннәтләнгән" "крещеный" сүзе булуын тагын танырга мәҗбүр.)

Керәшеннәрдә рус-христиан исемнәре кайчагында танымаслык дәрәҗәдә үзгәреш кичерә, бозыла, ләкин рәсми документларда башлыча рус язылышы кулланыла.

Мөселманнарның православие диненә күчүенә мисалларны болгар чорыннан ук табарга мөмкин. Мәсәлән, Киев кенәзе Владимир 990 елда Идел Болгарстанына үзенең христиан вәгазьчесен җибәрә. Шушы вакытта дүрт болгар кенәзе христианлык кабул итеп, Владимирга барып баш игәннәр. (Дөрес, Никон елъязмасындагы бу хәбәр галимнәрне сагайта — ул сәяси максатларны күздә тотып уйлап чыгарылган булырга да мөмкин.)

Кайбер чыганакларга караганда, Мамайның бер улы, православиегә күчеп, соңыннан хәтта чиркәү изгеләре исәбенә кертелгән.

Н.А.Спасскийның "Очерки по родиноведению" китабында *(Казан, 1910)* Болгар чорында мөселманлыктан христиан диненә күчкән Авраамий дигән болгар кешесе турында сөйләнә. Ул, шөгыле буенча сәүдәгәр, Суздаль Русенең Владимир шәһәрендә булган һәм, күрәсең, шунда чукынган. Русь белән Болгар йорты арасында сугыш башлангач, Биләргә кайткан һәм халык арасында христианлыкны пропагандалый башлаган. Ватандашлары аның кире мөселманлыкка дүнүен таләп иткәннәр, башта үгетләп караганнар, аннары кул-аякларын өзеп газаплап үтергәннәр. Бу хәл 1229 елның 1 апрелендә булган. 1230 елда Суздаль Русе белән Болгар йорты арасында солых төзелгәч, Авраамийның җәсәден Владимир шәһәренә алып килеп тантаналы шартларда монастырьга куйганнар һәм православныйлар бүгенгә кадәр аны изге дип саныйлар.

Казан ханлыгы чорында ук Кама алдының үзәк һәм көньяк өлешләрендә керәшен авыллары булган һәм аларның күбесендә иске мөселман зиратларында XIII-XVI гасырларга караган каберташлар табылган.

Әле Казан ханлыгы егылганчы ук Мәскәүгә йөз тоткан аерым татар морзалары

*Дәвамы. Башы журналыбызның 2004 елгы 1нче саныннан башлана.*

христиан динен кабул иткән булалар. 1556 елда Казанда Мәскәүгә каршы күтәрелгән "фетнәне" бастыруда шушы керәшеннәрнең катнашканлыгы мәгълүм. 1557 елда алар Лаеш шәһәре тирәсенә күчереп утыртылганнар.

Татар хәтерендә Явыз Иван чоры аеруча уелып калган. Һәм бу рус елъязмалары белән дә раслана. Никон күчермәләре дип атала торган рус елъязмасында Казан егылганнан соң 1552-57 елларда кенәз Андрей Курбский һәм кенәз Семен Микулинский (воеводалар Петр Морозов һәм Иван Шереметьев) җитәкләгән рус гаскәрләренең Казан арты төбәгендә һәм Кама буенда яшәгән татарларны кырып бетерүе турында сөйләнә. Бу вакытта 250 татар авылыннан көл генә калган. 1556 елда әсир төшкән татар ир-атларын кылычтан үткәрәләр, 20000 нән артык татар хатынын көчлиләр һәм коллыкка саталар. *(Әхмәт Сәхапов, "Гаяз Исхакый һәм XX гасыр татар әдәбияты".)* Буш калган җирләргә рус крәстиәннәрен күчереп утырталар. "Татар җирләрендә алпавытлардан Урта Алатта Реутовлар, Пекеньнар, Кече Отарда Христофорлар, Ивановлар, Аночиннар, Каймарда Энгельгардт, Геркен, Перцев, Шушарда Циолковский, Мейснерлар, Урматта Де Траверзе һәм башка бик күпләр тамыр җәя" *(тарихчы Г.Фәйзрахманов).*

Бер ривайәттә Явыз Иван заманында Казанда өч бертуган морза яшәгәнлеге һәм шуларның икесе—Исхак белән Нырсуның чукындырылуы, аннары шушы ике бертуганның күп кенә кардәшләрен христианлыкка дүндерүләре турында сөйләнә.

И.А.Износков Кече Нырсы дигән авылны түбәндәгечә сыйфатлый: "Кече Нырсы, икенче төрле Тау иле. Ул Нугай юлы өстенә утырган. Авыл зиратында беркем тарафыннан өйрәнелмәгән татарча язулы борынгы таш бар. Халкының бер өлеше чукындырылган. Ләкин халыкның күп өлеше озак та тормый кире мөселманлыкка кайткан. Авылдагы (1893 ел) 48 хуҗалыкта 172 ир-ат һәм 181 хатын-кыз яшәгән. Шуның өстенә анда әле мөселманлыкка кире кайтырга әзер торган керәшен татарлары да (21 ир-ат һәм 19 хатын-кыз) булган."

Билгеле булганча, Казан тәхетенә 1549 елда өч яшьлек Үтәмеш Гәрәй утыртыла, ә аның әнисе Сөембикә регент итеп билгеләнә. 1551 елда Үтәмеш Гәрәй тәхеттән төшерелеп, әнисе белән бергә Рәсәйгә озатыла һәм 1553 елда чукындырылып, Александр исеме белән атала. Үтәмеш Гәрәй-Александр 1566 елда вафат булган һәм Мәскәү кремлендәге Архангел чиркәвендә җирләнгән.

Әйткәнебезчә, татарны чукындыру һәм төбәкне христианлаштыру сәясәте Казан ханлыгы егылгач ук башлана. 1555 елда Казанда епархия оештырылып, гадәттән тыш киң вәкаләтләр бирелгән архиепископ Гурий Руготин (1500 еллар-1563, 4 декабрь) аңа баш итеп билгеләнә. Аның белән бергә Герман һәм Варсонофий исемле архимандритлар килә, соңгысы яшь чагында ханнарда әсирлектә ятып, татар телен һәм "сарацин грамотасы"н өйрәнгән була. Чит ил тарихчысы Я.Пеленский фикеренчә, 1564 елда беренче рус китабы "Апостол"ның басылып чыгуы да чукындырылган мөселманнарны укыту өчен дини әдәбият кирәк булуына бәйле булган.

Чиркәү тарихчысы А.Можайский үзенең "Изложение хода миссионерского дела по просвещению казанских инородцев с 1552 по 1867 гг." дигән китабында *(М.,1880)* төбәкне христианлаштыруның максаты турында түбәндәгеләрне язган: "Казанны тәмам җиңү өчен русларга Казан төбәгендәге башка каүм халыкларын әхлакый яктан да җиңәргә-рухият кылычы ярдәмендә, ягъни Алла сүзе белән, иман белән, христиан православиесе белән җиңәргә кирәк иде; шул чагында гына Казан "бусурманнары" чын мәгънәсендә һәм рухи яктан җиңеләчәкләр һәм рус христиан дәүләтенең тугрылыклы коллары булып китәчәкләр иде."

Казанны алу белән үк төбәктә монастырьлар оеша башлый. 1552 елда Елантау монастыре (русча чыганакларда: *Зилантовский*), 1556 елда Казан Спас-Преображенский монастыре төзелә. Шул ук вакытта Казан шәһәренә Ислам нуры бирепторган мәчетләр җир белән тигезләнә, яисә биналары төрле хуҗалык максатлары өчен файдаланылып мәсхәрә ителә. Ул мәчетләрнең исемнәре генә кала: Хан мәчете, Мөрәли мәчете, Колшәриф мәчете...

XVI гасыр ахырында Казан шәһәре чикләреннән куылган мөселманнар ук атымы җирдә генә мәчет төзи башлагач, ул вакыттагы митрополит Гермоген Явыз Иванның улы Федор патшага шикаятен җиткерә. 1593 елгы указында Федор патша: "Сез татар мәчетләрен туздырырга боерсагыз һәм киләчәктә татарларны үзбашка гына мәчет

торгызудан тыйсагыз, ә инде булган мәчетләрне бетерергә боерсагыз иде." — дигән фәрман бирә. Шул ук вакытта Федор патша Гермогенга яңа чукындырылганнарны чукынмаганнардан аерып, аерым бистәгә күчерергә, ә карышканнарны, мөселманлыкка кире кайтканнарны "зинданга ябарга, суктырырга, богау салырга һәм чылбырларга" боера.

Иван IV заманында ук көчләп христиан диненә күчерелгән татарларның ерак оныклары XVIII гасыр урталарына да "тәре галәмәте" ("крестное знамение") ясап чукына белмәгәннәр, һәм чиркәү әһелләре моңа бик пошынганнар, дөньяви хакимиятләргә бу мәсьәләдә ярдәм сорап мөрәҗәгать иткәннәр.

1713 елның 3 ноябрендә Петр I биләмәләрендә православие динендәге кешеләре булган татар алпавытларының ярты ел эчендә чукынуларын таләп иткән "исемле фәрман" ("именной указ") чыгара. Буйсынмаган алпавытларның биләмәсе, чуралары һәм крәстиәннәре белән бергә, патша карамагына күчәргә тиеш була. Бу вакытка 2000 татар алпавытыннан 100 кеше христианлыкка күчкән, калганнары ясаклылар исемлегенә теркәлеп, үзләренең морзалык өстенлекләрен җуйганнар һәм сәүдә эше белән шөгыльләнә башлаганнар. 1719 елга кадәр Казан губернасындагы чукындырылган халыклар арасында татарлар 13 322 кеше булган, шуннан соң узган 12 ел эчендә исә боларга тагы 1 995 кеше өстәлгән. Бер үк вакытта кире процесс та барган: 1721 елда, мәсәлән, керәшен татарлар, чукындырылган чуашлар һәм башка халыклар массакүләм төстә мөселманлыкка яки мәҗүсилекләренә кире кайтканнар. Бу хәл патша хөкүмәтен, әлбәттә, борчуга төшергән һәм 1731 елда Зөя монастыре каршында яңа комиссия төзегәннәр. 1738 елда бу комиссия Казанга күчерелә һәм "Яңа керәшеннәр конторасы" дип атала башлый. "Каратун" дип яманаты чыккан Лука Канашевич нәкъ менә шушы вакытта Казанга архиепископ итеп билгеләнә. Казан өязендә аңа әлеге контораның башлыгы архимандрит Сильвестр Гловатский ярдәм итә.

"1720, 1740, 1745, 1750 елгы патша указлары нигезендә чукындырылган татарларга авылның иң уңдырышлы җирләре, урман-болыннары, балыклы күлләре бирелә. Бу махсус рәвештә, матди мәнфәгатьләрне өстен куеп, христиан диненә "ирекле" рәвештә күчүчеләр төркемен булдыру өчен эшләнә." *(Фәрит Йосыпов.)*

Гомумән, Идел буе халыкларын көчләп чукындыру тарихы канлы һәм фаҗигале сәхифәләр белән тулы. 1743 елда протоиерей Г.Давыдов хәрби команда ияртеп Чуел өязенең Кошки-Чураш авылына килгәч, чуаш крәстиәннәре чукынудан баш тартып, "төнлә белән агач сәнәкләр, күсәкләр, чабагачлар күтәреп, юлбасарларча һөҗүм иткәннәр һәм аны, протопопны, чабагач белән кыйнаганнар, православие иманын һәм изге тәрене аты-юлы белән сүккәннәр." Монда бүгенге укучыны елмаерга мәҗбүр итә торган факт шул: 1741 елда ук инде Чар өязе марилары бу миссионерны, хәрби командасы белән бергә, ызбада яндырырга омтылыш ясаганнар һәм моның сәбәбе көчләп чукындыруда гына түгел, бәлки чукынган өчен тиешле бүләкне биреп җиткермәүдә булган икән...

Чуашстанда төбәкне өйрәнү музее коллекциясендә рәссам Н.К.Сверчковның XVIII гасырда чуашларны көчләп чукындыру күренеше сурәтләнгән картинасы саклана. Асылда анда бөтен Идел буе халыкларының тарихи фаҗигасе чагыла дияргә мөмкин.

Христиан руханиларына татарлар арасында миссионерлык эше алып барырга ярдәм итү өчен төрле "методик кулланмалар" төзелә. Шундый кулланмаларның берсе Тубыл һәм Себер митрополиты Антоний Стаховский тарафыннан төзелеп, татарчага тәрҗемә ителгән. Аның кульязма экземплярлы Петербургта Салтыков-Щедрин исемендәге китапханәнең кульязмалар бүлегендә саклана *(Титул битендә: "Книга сообращений сарацынов к вере христианской, переведена преосвященством митрополитом Тобольским и Сибирским Антонием Стаховским, 1726 года" — "Татарларны мәсихия иманына дундурмәк хакында Тобол вә Себер Антоний Стаховский дигән мокатдәс митрополиты илә нәкыл идулмеш китабы. 1726 сәнә.")*

Казандагы "Яңа керәшеннәр конторасы" өчен Хөкүмәт һәм Синод төзегән инструкциядә, мәсәлән, түбәндәгеләр әйтелгән: "...барлык яңа керәшеннәргә чиркәүгә йөрү мәҗбүри; әгәр кем дә кем Мөхәммәд иманын тотуын дәвам итә икән, штраф салырга; яңа керәшеннәрне руслар арасына яки русларны яңа керәшеннәр арасына күчереп утыртырга; (гади) керәшеннәргә бакыр тәре, күлмәк, тула кафтан, бүрек, бияләй, оекбаш белән чарык бирергә; аксөяк керәшеннәргә үзе теләгән төскә манылган кафтан,

чарык урынына күнитек, хатын-кызга башлык, киндер күлмәкләр бирергә; ир-атка 1 сум 50 тиен, яшь егетләргә 1 әр сум, малайларга 50 шәр тиен, хатыннарга һәм 12 яшьтән өлкәнрәк кызларга 1 әр сум, 12 яшькә җитмәгән кыз балаларга 50 тиен акча өләшергә; баеракларга йорт өчен берәр икона бирергә; башка диндәгеләрне рус теленә өйрәтү өчен Казанда, Алабугада, Цивильскида (Чуелда), Царевококшайскида 4 мәктәп ачарга..."

Казан миссионерлары "үз ихтыярлары" белән чукынырга риза булган татарлар өчен хурлыклы "үтенеч" сүзләре уйлап чыгарганнар. Үтенеч императрица исеменә багышланырга һәм "ихтыяри" бәндә үзенең адресын күрсәтергә тиеш булган. "История Татарии в документах и материалах" (Мәскәү, 1937) китабында үтенечнең тексты китерелә (русча): "Мин, электә Мөхәммәд канунында торганым хәлдә, хәзер рухани...(Фрол, Иван, Тихон) аша Мөхәммәднең Алладан җибәрелмәгәнлеген һәм беркайчан да аның илчесе булмаганлыгын мөкәммәл рәвештә белдем. Ул иң оятсыз һәм ялганчы пәйгамбәр һәм антихристларның әлгәре; шулай ук аның кануны Коръән дә ялган вә Аллага каршы; шушы белгәннәрем буенча мин ялган пәйгамбәр Мөхәммәдтән вә аның Коръәненнән ваз кичәм һәм аларны каһәрлим. Ошбу ялган пәйгамбәр Мөхәммәд үзенең Аллага каршы тәгълиматында хәсис сүзләр сөйли [*русча оригиналда:* "блядословит"]. Ә христиан законы иң дөресе һәм Аллага яраклысы. Иисус Христос чын илаһи алладыр. Мин адәмнәрне коткара торган христиан иманын кабул кылырга һәм үлгәнче шуңарда калырга телим".

Башка диндәгеләрне көчләп православиегә дүндерү еш кына фаҗигале төс алган һәм Исламга каршы көрәш белән үрелеп барган. Малмыж өязе Түнтәр авылы мулласы Гали Сәйфуллинны берничә мәҗүси мордва крәстиәнен мөселманлыкка дүндергәне өчен губерна идарәсе фәрманы белән авылдашлары каршында чишендереп таяк белән суктырганнар. Христианлыгын ташлап, Исламны кабул иткән һәм сөннәтләнгән Исаев фамилияле бер казак турындагы мәсьәләне хәтта 1740 елның 2 июнендә Министрлар кабинеты утырышында тикшергәннәр һәм аны үлем җәзасына хөкем итү турында указ чыгарганнар.

Татар арасында Исламны таратучы Идрис Зөл-Мөхәммәд углы Хафизның (1645-1710 еллар тирәсе) шәкерте, Ших-Касим бине Ибраһим дигән кеше керәшеннәрне "христианлыктан кире Исламга дүнәргә" үгетләп йөрүе белән таныла. М.Глухов керәшеннәрнең аны "Касимовский Ибрай" дип йөртүләре турында яза.

Югарыда телгә алынган дин тарихчысы А.Можаровский Казандагы Яңа керәшеннәр конторасының эшчәнлегендә "көтелмәгән минуслар" таба: "Яңа керәшеннәр конторасының эшчәнлеге тискәре яктан да тәэсир итте,—дип яза ул, ачынып.—Ул инородецларның һәм яңа керәшеннәрнең күңелен Пугачевны хуплап каршылауга әзерләде".

"Пугачев килеп чыгу белән яңа чукындырылган инородецлар, аңа тагылып, беренче эш итеп руханилардан үч алырга тотынганнар. *Барлык* инородец авылларында руханиларны кыйнаганнар яисә асып үтергәннәр,"—дип өсти шул ук автор.

Мондый чуалышларның чуаш авылларында аеруча көчле булганлыгын әйтеп китәргә кирәк.

1750 елда яңа керәшеннәрнең бер төркеме синодка үтенеч язып, архиерей Лука тарафыннан ирексезләп чукындырылулары, бу вакытта үзләренең шашар дәрәҗәдә булганлыклары турында хәбәр иткәннәр.

Тарих сәхифәләрен актарганда чын мәгънәсендә фаҗигале хәбәрләргә юлыгасың.

1866 елның 6 июнендә Олы Сулабаш авылында Акулина Павлова исемле керәшен хатыны вафат була. Авыл халкы да, шулай ук күрше Шепшенк авылыныкылар да Алат өязе идарәсенә мәрхүмәне мөселманча җирләргә рөхсәт сорап мөрәҗәгать итәләр. 12 июнь көнне пристав җирле старостадан Сулабаш һәм Шепшенк авылының керәшен татарлары мәрхүмәне христиан йоласы буенча күмәргә мөмкинлек бирмиләр, мәет яткан өй янына җыйнаулашып килеп, мәет янына берәүне дә җибәрмиләр дигән шикаять алгач, Сулабаш авылына барып, мәрхүмәнең ире Максим Федоровка (татарча исем-фамилиясе Ишимъяр Ишимов) мәетне Алат авылына илтеп күмәргә тиешлеген әйтә. Ишимов исә моннан баш тарта, үзләренең христиан иманын ташлауларын һәм Ислам дине тотуларын, мәрхүмәне христианча җирләргә биргәнче шушында, ишегалдында үләчәген әйтә. Пристав Соловцево авылыннан килгән пүнәтәйләргә мәетне алып Алат

авылына илтергә куша, әмма шунда керәшеннәр мәет куелган чокыр өстендәге такталарга яталар…

Авылга хәрби команда җибәреләә һәм тикшерү комиссиясе эшли башлый. Нәтиҗәдә Олы Сулабаш авылы крәстиәне Максим Федоров (Ишимъяр Ишимов), Яков Алексеев (Тимергали Халитов), Шепшенк авылыннан Матвей Данилов (Хәйбулла Халитов), Максим Васильев (Гайнетдин Монасыпов), Василий Васильев (Ибәтулла Моксинов), Нурма авылыннан: Антон Николаев (Хәмидулла Хәйбуллин), Яков Гаврилов (Хәмидулла Гайнуллин), Семен Иванов (Гали Фәйзуллин) һәм Олы Сулабаш авылы татар хатыннарыннан Федосья Семенова (Бибимәдинә Тахтарова), Акулина Семенова (Бибилатифа Халитова), Ирина Иванова (Бибифатыйма Халитова) хакимиятләргә буйсынмауда гаепләнәләр һәм төрмәгә ябылалар.

XIX гасырның икенче яртысында Кама буе керәшеннәрендә таралган "Җапар бәете" ("Җәгъфәр бәете") Казан губернасының Лаеш һәм Мамадыш өязләрендә яңа керәшеннәрнең бер өлеше, православиедән баш тартып, кабат мөселманлыкка кайткач, аларга каршы Казан вице-губернаторы Розов җибәргән җәза экспедициясенең (1866) кансызлыклары турында сөйли.

"Акулина бәете" исә Акулина / Хәдичә белән мөселман егете Җамалетдинның шәхси фаҗигасе турында. Бәеттә соңгырак заманда – 1902 елда булган вакыйгалар тасвир ителә. Ахырда егет белән кыз барыбер кавышалар: "Хәдичә белән Җамали бергә гомер иткәннәр, Котырган этләрдән качып, Урал буйлап киткәннәр".

Көчләп чукындырылган татарларның тетрәндергеч фаҗигасе Гаяз Исхакыйның реаль тормыштан алып язылган "Зөләйха" исемле пьесасында тасвир ителә. Бер "мөселман керәшен карчыгының" Гаяз Исхакыйга бер кием чабата бүләк итеп җибәргәнлеге билгеле. Самими карчыкның эчке кичерешләрен һәм фаҗигасен аермачык күрсәтә торган бүләк бу.

Шәһит Әхмәдиев 1917 елда шушы "Зөләйха" пьесасының сәхнәгә куелу уңае белән язылган мәкаләсендә халык хәтерендә калган хәлләр турында түбәндәгеләрне яза: "Рус хөкүмәтенең элегрәк заманда зурларымызны мунчаларда төтеннәргә тончыктырып, каты суыкларда ялангач йөретеп, кызган тимерләргә бастырып чукындырырга тырышуы һәм кызларны русларга өләшүе, балаларны төрле рус авылларына һәм монастырьларына таратуы хакында әле бабайларымыз да бик ачык итеп сөйлиләр иде."

Шушы ук әсәргә нисбәтле рәвештә тәнкыйтьче Г.Кәрам мондый гомуми фикергә килә: "Киләчәктә татар вә төрек балалары үзләренең бабаларының Русиядә нинди куркыныч гасырларда яшәдекләрен вә алардагы сәлабәте диниянең дәрәҗәи куәтен күреп хәйратлар эчендә калачаклардыр."

Керәшеннәр арасында авылларда йөреп тегү тегүчеләр күп булган. Мөселманнар белән аралашырга туры килгәнгә, керәшен тегүчеләр еш кына христианлыктан кире мөселманлыкка күчкәннәр (бу фактка, мәсәлән, Н.А.Спасский игътибар итә).

Иманын сатмаган мөселманнар матди кыенлыкларга дучар ителгән. Сенатның 1747 ел 11 март фәрманы белән, Зөя өязендә чукындырылган 130 822 татар, чуаш, чирмеш һәм мордва өчен салымны чукынмыйча калган башка 241 338 кешедән алырга, шуның өстәвенә керәшен татарлардан һ.б. лардан рекрут алмаска һәм аларга башка төрле җиңеллекләр бирергә кушыла.

XIX гасырда гамәлгә кергән "Җинаять һәм төзәтү җәзалары турында уложение"дә православиедән чигенгән өчен "милеккә хуҗа булу хокукларыннан мәхрүм итү" (185 маддә), шулай ук вакытлыча башка җиргә күчерү кебек чаралар каралган. Әгәр дә керәшен татар үз гаиләсе әгъзаларының православиедән читләшүен булдырмас өчен чара күрми икән, аны 3 көннән алып 3 айга кадәр ябылуда тотканнар (192 маддә). Првославиедән чигенергә котырткан өчен каты җәзалар күргәннәр ("барлык хокуклардан һәм мөлкәтеннән мәхрүм итү, 8 дән алып 10 елга кадәр каторга эшләренә сөрү"-184 һәм 71 нче маддәләр).

Казан хәрби губернаторы Пущинның Хакимлек итүче Сенатка язган бер рапортында 1778-1779 елларда Казанда 25 чукындырылган башкорт яшәве турында мәгълүмат бар.

*Дәвамы киләсе санда*

# *Хатлардан юллар*

* * *

Кадерле редакция!

"Казан утлары" журналының быелгы беренче номерын кулыма алдым да сөенечле хисләр кичердем. Аллага шөкер, әле шушындый журналыбыз бар, ул исән, ул даими чыгып килә, тиражы да тотрыклы икән, дип куйдым. Ә инде андагы әсәрләрне, үткен язмаларны укыгач, эчтәлеге белән ныклап танышкач гап-гади сөенечем күңел бәйрәменә әйләнде. Чөнки төрле сәбәпләр аркасында журналдан аерылып торырга туры килгән иде. Ә хәзер менә бик яхшы иске танышымны, хәер, танышымны гына түгел, җан дустымны, ахирәтемне очраткандай булдым. Язмалар берсеннән-берсе тирән эчтәлекле, аларда бүгенге көндә татар җанын кыйнаган үткен мәсьәләләр күтәрелә. Язучы Флүс Латыйфиның "Юбилей уңае илә уйланулар" дигән баш мәкаләсендә әйтелгәннәр белән килешми мөмкин түгел, бүген безгә милли аңны, милли рухны үстерү кайчан да булмаганча иң мөһим бер эш булып тоела миңа. Шул күзлектән караганда, журнал үзе үк милли рухны, милли аңны тәрбияләүче үзе бер университет икән ләбаса! Афәрин, туганнар! Киләчәктә дә юлыгыздан тайпылмагыз, бөтен дөньяны колачлап килүче глобализм, милләтсезлек, тәрбиясезлек, гадәтйоласызлык диңгезендә дөрес юл күрсәтүче маяк булып калыгыз.

Шул җәһәттән чыгып караганда, Мөнир Абдуллинның «Уйна дустым, гармуныңны» мәкаләсе дә игътибарны җәлеп итә. Бу уен коралы, аерым алганда, тальян гармун халкыбызның байтак еллар буе милли уен коралы булып саналды. Татарны, татар авылын тальяннан башка күз алдына да китереп булмый иде бит. Дөрес, мин хәзер дә бөтен музыка тальянда башкарылсын дип әйтергә җыенмыйм, скрипкасы да, курае да, барабан вә торбасы да булсын, хәзер модага кергән һәм «япон тактасы» дип йөртелүче электрон уен кораллары да кирәк. Ләкин аларда нәрсә башкарасың бит. Кайчагында мин замана музыкасын тыңлап, татарчамы соң әле бу, дип аптырап та куям. Димәк, бөтен хикмәт, тормышыбыздагы шикелле үк, музыкада да милли рухны, борынгыдан килүче милли яңгырашны саклап кала белүдә. Безнең татар телендә сәнгать һәм, аерым алганда, музыкага багышланган махсус басмаларыбыз юк, шунлыктан, бар карап торганыбыз «Казан утлары». Сәнгатьнең бу төрләренә дә игътибарны арттырасы бар кебек тоела миңа. Дөрес, журнал–язучылар мәҗмугасы. Ләкин, бик тырышсаң, андый язмаларны да сыйдырып булыр иде.

Тагын язучы һәм галим Адлер ага Тимергалинга аерым рәхмәтемне җиткерегез. Аның "Миллият сүзлеге" тулы бер фәнни-тикшеренү институты да башкарып чыга алмаслык титаник хезмәт. Мин халкыбызның сүзлек байлыгын, аерым гыйбарәләрнең төбендә нинди тирән мәгънә ятканлыгын күреп, чын мәгънәсендә тетрәнү кичердем. Һәм тел җәһәтеннән, һәм тарихи мәгълүматка байлык ягыннан бәяләп бетергесез кыйммәтле хезмәт икән ул. Хәзер ул мәкаләләрне кисеп алып, аерым папкага җыеп барам. Ул китап булып чыкканчы әле ничә еллар үтәр, ә мин инде бүген үк шул сүзлеккә ия була барам. Бер генә үтенечем бар, сүзлекне алай вакламагыз, күбрәк, күләмлерәк итеп урнаштырыгыз әле, зинһар! Юкса, болай кече телгә дә йокмый калган шикелле бит. Шундыйрак эчтәлекле, тарихыбызны, йолаларыбызның асылын аңлаткан язмалар күбрәк булса да комачау итмәс. Без бит хәзер надан бер кавемга әйләнеп барабыз бугай. Кулымнан килсә, мин "Казан утлары" журналын һәр татар гаиләсенә яздыруны мәҗбүри итеп куяр идем. "Казан утлары"н белмәгән, укымаган кеше чын татар була алмыйдыр кебек тоела миңа.

Артык кискенрәк әйтелгән җирләр булса, гафу итегез. Болар журналны тагын да яхшырак итү теләгеннән үзеннән-үзе килеп чыкты кебек.

Ихтирам белән, Диләрә ФАТЫЙХОВА,<br>Мөслим.

* * *

Мин журналны 80 еллардан бирле алдырып килəм. Ул елларда Үзбəкстандагы бер районда, "Ленин юлы" колхозында яши идем. Əле менə Рауль Мирхəйдəровның "Карга короле" дигəн романын укыгач шул еллар искə төште, чөнки автор Үзбəкстан мохитын, ул еллардагы хəллəрне шулкадəр белеп, аңлап яза ки, яшьлегемə кире кайткан кебек булдым. Барысын да кичерергə туры килде безгə. Мамык җыюда да катнаштык, түрəлəрнең череп баюын, ярлы халыкның һаман хəерчелəнүен дə күреп тордык. Власть өчен, байлык өчен көрəш нилəр генə эшлəтми. Баксаң, хəзер Рəсəйдə дə шул хəл бит.

Бер мəзəк искə төште əле. Бер хатыннан сорыйлар икəн, "Ничек яшисең?" дип, тегесе "БАМдагы кебек,–дип җавап биргəн.–Больница–аптека–магазин,–дигəн.–Шул сихерле бокрадан чыгып булмый". Без дə шул анекдоттагы кебек сихерле бокрага элəктек бугай. Көн саен бəялəр арта, квартирга түлəү, газга, электрга түлəү, азык-төлек хаклары… Əйтеп бетерерлек түгел. Пенсияне биш-алты процентка күтəргəн кебек итəлəр, ə бəялəр чүпрə кебек күперə. Дөресрəге, күпертəлəр. Юкса без бит нефть, газ өстендə яшибез. Рəсəй шуларны сатып миллионнарча доллар акча җыя, ə без хəерче хəлендə.

"Карга короле" романын укыган кешелəр анда тасвирланган хəллəргə хəтта ышанмаска мөмкиннəр, əмма без белəбез, барысы да шулай иде. Инде хəзер Россиядə дə шулай түгелмени?! Романдагы исем-фамилиялəрне, сурəтлəнгəн шəһəр-авыллар исемен алыштырсаң, нəкъ бүгенге Россия килə дə чыга. Ул олигархлар, миллиардер-миллионерлар күктəн төшмəгəн ич. Ул əсəрне бастырып чыгарган өчен бик зур рəхмəт Сезгə. Килəчəктə дə Рауль Мирхəйдəров əсəрлəрен бастырып чыгарырсыз, дип өметлəнəм.

**Н. Г. ЛАТЫЙПОВА,**
*Оренбург өлкəсе,*
*Орск шəһəре.*

---

# КИЛƏСЕ САНДА УКЫГЫЗ:

Апрель ае халкыбызның сөекле шагыйре Габдулла Тукай туган ай. Шəһəрлəрдə һəм авылларда, татар яшəгəн һəр төбəктə шигырь бəйрəмнəре уздыруның да нəкъ шул айга туры килүе очраклы түгел.

«Казан утлары» журналы да бөек шагыйрьнең туган көнен үзенчə зурлап билгелəп үтəргə ниятли. Аерым алганда, бу санда Габдулла Тукай турында татар һəм башка бик күп миллəт язучылары, фикер иялəре əйткəн канатлы сүзлəр китерелə. Алар арасында **Сибгат Хəким, Нəҗар Нəҗми,** үзбəк шагыйре **Гафур Голəм,** казакъ язучысы **Мохтар Ауэзов,** əзəрбайҗан шагыйре **Сөлəйман Рөстəм,** итальян шагыйре **Җерманетто** һəм башкаларның фикерлəре бар.

Журналда узган ел уздырылган пьесалар конкурсында беренче урынны алган əсəр– **Зөлфəт Хəкимнең** «Телсез күке» драмасы, шагыйрə һəм прозаик **Шамил Маннаповның** кыска хикəялəре белəн танышырга мөмкин булачак.

Поэзия сөючелəрне күренекле шагыйрьлəрдəн Габдулла Тукай исемендəге Дəүлəт премиясе лауреаты **Роберт Əхмəтҗанов** һəм **Рөстəм Мингалимовның** яңа əсəрлəре белəн очрашулар көтə.

«Əдəби тəнкыйть» рубрикасында **Алсу Шəмсутованың** «Бүгенге драматургия герое» дигəн мəкалəсе һəм Казан университеты профессоры, тəнкыйтьче **Дания Заһидуллинаның** соңгы еллар татар əдəбиятында романтизм күренешен анализлаган күлəмле хезмəте тəкъдим ителə.

Журналда шулай ук тормышыбызның үткен проблемаларын күтəргəн публицистик язмалар, иҗтимагый-мəдəни тормышыбыз яңалыклары белəн дə танышырга мөмкин.

# БАЛАЧАК ХАТИРӘСЕ

Абдулла Әхмәт дигәч тә минем хәтергә, нишләптер, инде бик еракта торып калган балачак елларым килеп төшә.

...Илленче еллар уртасы иде булса кирәк... Кышның зәмһәрир суык чагы. Мөслим урамнарындагы колач җиткесез мәһабәт тирәкләрне бәс сарган. (Сүз уңаеннан гына әйтеп үтәм, безнең якларда тупыл дип йөртелүче бу агачларны соңгы елларда кисеп бетерделәр, шуннан соң Мөслим үзенең балачак хәтеремә уелып калган бер матурлыгын югалтты кебек. Хәер, сүзем ул хакта түгел иде бит әле. Яңадан балачак Мөслименә кайтыйк булмаса). Әнә, урамнарда сирәк-мирәк күренүче атларның өстеннән бу күтәрелә, морҗалардан чыккан сыек төтен алкаланып-алкаланып күккә үрли. Утыз градустан арткан мондый суыкта урамда киләп сарып йөрүчеләр сирәк, чыкканнары да кайсы атлап, кайсы йөгереп дигәндәй, тизрәк өенә кайтып керергә ашыга. Әйе, төкергән төкерегең җиргә төшкәнче бозга әйләнә торган кыш чиләсе бу! Нәкъ менә шундый көннәрнең берсендә урамнан-урамга, өйдән-өйгә, мәктәптән-мәктәпкә бер хәбәр йөрде: Мөслимгә язучылар килеп төшкән! Чын, тере язучылар имеш! Моңа кадәр, мин белгән-күргән елларда мондый хәлнең булганы юк иде әле. Язучы безнең өчен ул вакытта ниндидер тылсымлы бер зат, дөньяда чынлап та барлыгын бары тик китаплардан гына укып белә торган мифик җан иясе булып тоемлана иде. Һәм ул чор өчен бу гаҗәп тә түгел. Әле кешенең рухи дөньясын телевидение дигән монстр колачлап алмаган, кино дигәнең дә РДК дип йөртелүче клубта көненә бер генә тапкыр күрсәтелә, анысына безне кертмиләр, балалар сеанслары дигәннәре исә атнага бер генә тапкыр була. Дөньяны танып-белергә, әйләнә-тирәндә ни-нәрсә барлыгын, ерак илләрдәге яшьтәшләрең тормышын, кайдадыр бик еракта яшәп ятучы адәми затларның ничек, ни рәвешле гомер кичерүен, аларның уй-хыялларын, мавыгушөгыльләрен белим дисәң, ярый әле китап бар. Белгәнебез, табынганыбыз—китап! Ул чакларда китап безнең өчен кинොны да, телевизорны да, театрны да, музейны да, хәзер әйтеп бетергесез күп башка төрле клуб вә мавыгуларны да алыштыра иде.

Китап булмаган өй сирәк. Хәтеремә шунысы да сеңеп калган, безнең өйдә китапка аерым бер хөрмәт, ихтирам хөкем сөрә иде. Түшәмнең уртасыннан узган матчаның буеннан-буена кадакланган озын тактада, ягъни шүрлектә урын алганнары бигрәк тә. Аларын әнкәй акка кызыл төсне аркылыга суккан борынгы киндер тастымалларга төреп саклый. Аларына безнең кул җитми. Хәер, җитсә дә, без аңларлык түгел, алары гарәп хәрефләрендә. Көрән төстәге күнгә алтын хәрефләр белән “Ленин”, “Сталин” дип басылган калын томнар да шунда саклана. Бөтен нәрсәгә борынын тыгарга яратучы бала-чага, ягъни безнең кул җитмәсен дип, махсус рәвештә шулай өскә куелганнар алар.

Һәм менә шундый китапларны язучылар безгә, боргаланып аккан Ык елгасының сул як ярына сыенган гап-гади Мөслим авылына килеп төшсен әле! Килүчеләре дә берәү генә түгел, өчәү булып чыкты. Без йотылып укыган “Бәхет орлыклары” дигән фантастик повесть авторы Атилла Расих, шигырьләрен яттан өйрәнгән Гали Хуҗиев белән бергә балалар өчен дистәләрчә хикәяләр, пьесалар иҗат иткән Абдулла Әхмәт иде алар. Мәктәптә үткән беренче очрашуда кыенсынып калуыбызны, укытучыларның: “Сорауларыгыз бармы? Булса бирегез, язучы абыйларыгыз рәхәтләнеп җавап бирер”,—дигән үтенечен карамастан, залдагы балаларның тавыш-тынсыз утыруын да аңларга була. Безнең өчен кул җиткесез бөек кешеләр иде шул алар. Шулай булгач, кыенсынмыйча аларга ничек сорау бирәсең?! Безнең арыш ипие белән кабыклы бәрәңге ашап туймаган авызларыбыздан нинди мәгънәле сүз чыксын! “Абый, бу хикәяңне кайчан яздың?” яисә “Ничек яздың?” дип сорап булмый бит инде. Сораулар ул абыйларның үзләре шикелле үк олпат, тирән мәгънәле, саллы булырга тиеш кебек тоела иде безгә. Ләкин беренче очрашу гына шулай басынкылык белән үтте дә бугай. Тагын балалар китапханәсендә һәм өлкәннәрнекендә дә булды ул, кичен исә бөтен Мөслим халкы, олысы-кечесе, яше-карты дигәндәй, клубка җыелды. Инде ул вакытта ук шигырь язып, әдәбият түгәрәкләренә йөреп, “мәктәп шагыйрьләре” дигән олы исем тагылган без фәкыйрьләрегез—мәктәптән ике-өч бала—аларның берсен дә калдырмадык. Баксаң, язучылар да безнең шикелле

гади кешеләр икән ләбаса! Мәктәптә бирергә кыймый утырган сорауларыбыз да аларга аңлаешлы һәм кызык икән бит! Тормыш юлларын да, теге яки бу әсәрне ничек язулары хакында да бәйнә-бәйнә сөйләделәр, шигырьләрен, хикәяләрен укыдылар. Абдулла Әхмәт абый исә мәзәкләр сөйләп кинәндерде. Хәер, шулай булмый мөмкин дә булмагандыр. Абдулла Әхмәт халык иҗатын туплап, китап итеп чыгаруда иң актив эшләгән әдипләрдән иде.

Очрашу беткәч тә әле язучылар белән аерылышасы килмичә изаландык. Классташларым белән без аларны Мөслим үзәгендәге кунак йортына—"Дом заезжих" дип вывеска кадакланган алты почмаклы гади авыл йортына кадәр озата бардык. Хәер, алар моны үзләре сизмәде дә бугай. Чөнки бер ун метрга арткарак калып иярдек без аларга.

Инде менә ярты гасырга якын вакыт узган, әмма шушы вакыйга минем хәтеремә бөтен ваклыклары белән уелып калган. Үз гомеремдә беренче тапкыр тере язучы күрүем иде ул. Хәзер шул еллар биеклегеннән торып карыйм да уйлап куям: ул чор язучылары бәхетле булган икән. Ләкин… алар гына да түгел, хәтта ул чор укучылары да. Матди яктан ярлырак, хәерчерәк яшәсәләр дә, аларда галиҗәнаб китапка тартылу, аны иҗат иткән әдипләрне хөрмәтләү шулкадәр тирән һәм ихластан булган ки, бүгенге буыннарга көнләшергә һәм кызыгып искә төшерергә генә кала.

Ә искә төшерергә кирәк. Кемдер искә төшергәндә, сагынганда язучы әле безнең арабызда, иҗаты халык хәтерендә дигән сүз дә ул. Шөкер, искә алыр, сагыныр әдипләребез күп.

Шуларның берсе, һичшиксез, балалар язучысы һәм фольклорчы Абдулла Әхмәт булыр.

Абдулла Әхмәт (Абдулла Сафиулла улы Әхмәтов) тумышы белән бүгенге көндә инде татар чишмәсенең тамырлары корый башлаган яклардан. Ул 1905 елның 25 мартында хәзерге Курган өлкәсенең Притобольный районы Звериный авылында урта хәлле игенчеләр гаиләсендә дөньяга килә. Авыл мәктәбендә башлангыч белем алгач, соңрак махсус курслар тәмамлап, 1922-1923 елларда Чиләбе өлкәсенең Олы Солтан авылы балалар йортында тәрбияче, аннары үз авылларында уку йорты мөдире булып эшли. Шул вакытларда ул Уралда чыга торган "Социализм юлы" газетасына хәбәрләр яза башлый. 1925 елда партия-совет мәктәбен тәмамлаганнан соң, яшь хәбәрчене Свердловск шәһәрендә татар телендә чыга торган "Сабан һәм чүкеч" газетасы редакциясенә эшкә чакыралар. Журналистлык хезмәте белән бергә ул әдәби хезмәт белән дә шөгыльләнә, бер-бер артлы аның очерклары, кыска хикәяләре басыла, инде 1931 елда Мәскәүнең "Центриздат" нәшриятында "Кара баганалар" исемле беренче китабы дөнья күрә.

1932 елда А. Әхмәт Казанга күчеп килә, Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый һәм Икенче бөтендөнья сугышы башланганчы "Совет әдәбияты" (хәзерге "Казан утлары") журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр, аннары Казан химия-технология техникумында һәм музыка мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли, әдәби иҗат белән актив шөгыльләнә, пьесалар яза, аның "Үги кыз" пьесасы Татар дәүләт академия театрында сәхнәләштерелә.

Сугыш башлангач, А. Әхмәт фронтка китә, ике ел буе алгы сызыкта гади солдат булып сугыша, яраланып, госпитальдә дәваланып чыккач, яңадан алгы сызыкка кайта һәм сугышның ахырына кадәр татар телендә чыгучы "Алга, дошман өстенә!" исемле фронт газетасы редакциясендә эшли, бик күп очерклар һәм хикәяләр яза.

1946 елда армиядән кайткач, А. Әхмәт башта Татарстан китап нәшриятында яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе мөдире (1946-1951), аннары "Пионер" (хәзерге "Ялкын") журналының җаваплы редакторы булып эшли.

А. Әхмәтнең сугыштан соңгы иҗаты проза һәм драматургия жанрларының һәр икесендә нәтиҗәле эшләве белән характерлы, аның бер-бер артлы китаплары чыгып тора, пьесалары Татар дәүләт академия театрында, Уфа, Свердловск, Бөгелмә театрларында уйнала.

Шулай да, А. Әхмәт калдырган әдәби мирасның күп өлеше балалар өчен язылган әсәрләрдән гыйбарәт. Ул—ике дистәгә якын китап авторы.

А. Әхмәт татар халык иҗаты әсәрләрен туплау, әдәби эшкәртү һәм матбугатка әзерләп чыгару буенча да ифрат күп эш башкара. 1938 елда ул, фольклорчы Хәмит Ярми белән берлектә, "Халык иҗаты" исемле гаять зур күләмле һәм этрафлы җыентык бастырып чыгара. Аның тарафыннан төзелгән һәм кат-кат басылган "Хуҗа Насретдин мәзәкләре", "Мәкальләр", "Табышмак әйтәм—табыгыз" дигән җыентыклар да киң җәмәгатьчелек тарафыннан уңай бәя алды, алар бүген дә халык авыз иҗаты белән кызыксынучыларга киң мәгълүмат бирә.

А. Әхмәт 1976 елның 28 октябрендә Казанда вафат булды.

**Ф. ЛАТЫЙПОВ**

*Котлыйбыз!*

## Мәгъсүм Гәрәевкә 70 яшь



Мәгъсүм Гәрәев публицистика өлкәсендә актив иҗат итүче каләмдәшләребездән. Ул 1935 елның 7 февралендә Питрәч районының Шәле авылында мөгаллимнәр гаиләсендә туган. 1953 елда Шәле урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт педагогия институтының физика-математика факультетында югары белем ала.

Журналистика өлкәсендә беренче чыныгуларын Мәгъсүм Гәрәев Татарстан радиокомитетында башлап җибәрә. 1967 елдан ул "Социалистик Татарстан" (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасының сәнгать бүлегендә, житмешенче еллар башында—Татарстан журналистлар берлегенең баш консультанты, 1991 елдан яңа ачылган "Татарстан хәбәрләре" газетасының икътисад бүлеге мөхәррире, соңгы елларда "Шәһри Казан" газетасының, хәзерге вакытта "Чаян" журналының әдәбият-сәнгать бүлекләрендә мөхәррир булып эшли.

Татар халкының күренекле вәкилләре—космос фәне өлкәсендәге хезмәтләре белән дөньяны шаулаткан академик Роальд Сәгъдиев, аның энесе, шулай ук академик Ренат Сәгъдиев, генерал һәм кардиохирург Рәсим һәр Ренат Акчуриннар, авиаконструктор А. И. Микоян, атаклы математик М. А. Лаврентьев, композитор София Гобәйдуллина, балет сәнгатенең атаклы осталары Рудольф Нуриев һәм Ирек Мөхәммәтовлар турындагы очерк-язмалары аның каләм хезмәте җимеше.

Мәгъсүм Гәрәев әдәбиятыбыз һәм сәнгатебезнең күренекле шәхесләренә багышланган иҗат портретлары тудыруда да актив эшли. Алар арасында Гомәр Бәширов, Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, Рөстәм Яхин, Александр Ключарев, Сара Садыйкова, Илһам Шакиров, Зилә Сөнгатуллина һ. б. багышланган язмалар бар.

Аның очерклары һәм публицистик мәкаләләре республика газеталарында, "Казан утлары", "Татарстан", "Сөембикә", "Ялкын" журналларында дөнья күрде. Шул җөмләдән, 1995 елда Мәгъсүм Гәрәевнең "Казан утлары" журналында Гариф Ахунов белән бергә иҗат ителгән "Арча җиренең ачык китабы" дигән документаль повесте басылып чыкты. Авторлар бу әсәрдә тулы бер районның күмәк портретын тудыруга ирештеләр. Повесть матбугатта уңай бәя алды.

Татарстан китап нәшриятында бүгенге заман геройлары хакында чыккан җыентыкларда М. Гәрәевнең очерклары һәрчак басыла килде. Алар арасыннан: "Күмәч кыры", "Бер уч бодай", "Каһарман", "Ерактагы якын көндәш" кебек язмаларны күрсәтеп үтәргә мөмкин.

2004 елда язучының "Мин, Чуен Гәрәй малае..." исемле җыентыгы дөнья күрде. Җыентыкка кергән кыска-кыска бәяннар язучы биографиясенең бер өлеше. Язучы аларда үз чорының вакыйгаларына, шәхесләренә карата уй-фикерләрен белдерә, мөнәсәбәтләрен ачыклый.

1998 елдан Мәгъсүм Гәрәев Язучылар берлеге әгъзасы.

**Танылган журналист, язучы Мәгъсүм Гәрәев бу көннәрдә олуг юбилеен бәйрәм итә. Аны ихластан тәбрик итәбез, саулык-сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары телибез.**

## Рафис Гыйззәтуллинга 50 яшь



Хикәяче, публицист Рафис Әхмәт улы Гыйззәтуллин 1955 елның 8 мартында Татарстанның Сарман районы Урта Кәшер авылында туган. 1972 елда Иске Кәшер урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетына имтихан тота. 1977 елда татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты белгечлеге буенча укуын тәмамлап, студент чагыннан ук хезмәттәшлек итә башлаган "Татарстан яшьләре" газетасына эшкә урнаша. Шуннан бирле аның тормыш һәм хезмәт юлы нигездә Казан каласы һәм Казан көндәлек матбугаты белән бәйле. 1978—1979 елларда Свердлау, Ижау һәм Тоцки якларында мәжбүри гаскәри хезмәт мөддәтен тутырып кайтканнан соң, ул әүвәл берникадәр вакыт "Ялкын" журналында, аннары озак еллар "Социалистик Татарстан" (хәзерге "Ватаным Татарстан") газетасы редакциясендә хәбәрче, өлкән хәбәрче, бүлек мөдире вазифаларын башкара. 1994 елның гыйнварыннан Р. Гыйззәтуллин "Татар-информ" агентлыгының баш мөхәррире хезмәтендә.

Әле мәктәптә укыган елларында ук каләм тибрәтә башлаган Р. Гыйззәтуллин, үзенчәлекле язучы-хикәяче буларак, республиканың "Ватаным Татарстан", "Идел", "Казан утлары", "Чаян" көндәлек басмаларында һәм Мәскәүнең "Пионер" журналы, "Российская газета"сы битләрендә басылган һәм, башлыча, балалар, яшүсмерләр тормышына багышланып, кеше характерларын психологик планда ачып бирүгә корылган җыйнак сюжетлы, халыкчан образларга бай сыгылма телле хикәяләре һәм үткен фикерле публицистик мәкаләләре белән таныла. Ул—хикәяләре, лирик парчалары, нәсерләре, юморескалары тупланган "Очучы буласым килә" (1984), "Урман юлы" (1987), "Көтелмәгән сорау" (1990), "Кырау" (1996), "Багалмада кунакта" (1996), "Төнге яңгыр" (2002) дигән китаплар авторы.

Рафис Гыйззәтуллин—1981 елдан СССР журналистлары берлеге һәм 1989 елдан Язучылар берлеге әгъзасы. Матбугатта ирешкән уңышлары өчен 1993 елда аңа "Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре" дигән мактаулы исем бирелде.

**Әдхәт Синугылның тууына 70 ел**

# СӘЙЯХ ШАГЫЙРЬНЕҢ СӘЙЯР ГОМЕРЕ...

Бу мәкаләне каләмдәшемнең нәкъ менә дөньядан киткән көннәрендә язам булып чыкты: әйе, узган елның 14 гыйнварында, һич көтмәгәндә, соңгы яшәү урыны Симферопольдән Казанга килеп, иҗат һәм җәмәгать эшләре белән янып, дуслары белән аралашып, сөенеп йөргәндә, Язучылар берлеге бинасында өзелде аның гомере. Сәйях шагыйрьнең сәйяр гомеренең фаҗигале, әмма иҗат кешесе өчен табигый азагы диясем килә минем.

1935 елның 15 мартында Башкортостанның Эстәрлебаш районы Куганакбаш авылында туып, яшьтән ятим калып, бабасы, туганнары химаясендә үскән (бу— пәйгамбәрләр һәм шагыйрьләр язмышы, мөгаен!...), урта мәктәптән соң армия хезмәтен узгач, үзе дә укытучы, район газетасы хезмәткәре булган яшь шагыйрь егетне арытабан, әлбәттә, Казан тарта (Г. Ибраһимов, Г. Алпаров, И. Рәмиев кебек мәшһүр әдипләр, галимнәр чыккан төбәк бит!), татар әдәби мәркәзе чакыра... Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә без бергә укыдык— Хатип Миңнегулов, Әдхәт, мин...—барыбыз да авыл балалары, фәкыйрь шәкертләр... Әмма Әдхәт Синугыл—арабызда иң пөхтә, ыспай егет иде. Акчасы да бар—ул көнтөн тәрҗемә итә, Африка, Азия халыкларына "азатлык яулаша"—бу шагыйрьләрне радиодан яңгырата иде. (Соңрак аның "Уянган Африка", "Вьетнам җинә" исемле тәрҗемә китаплары да басылды.) Бу—континентлар аша сәяхәт һәм сәйярлек безгә— лирик замандашларына—бик үк ошап та җитми иде.

Соныннан аңладык: бу—аның үз халкыбыз азатлыгы юлларын күзаллавы, эзләнүләре дә икән! Ә үз иҗатына, шигъри дөньясын табуга юлы шактый озакурау булды аның. Университеттан соң Пермь һәм Сарман якларында укытты ул; китап нәшриятында редактор, филармониянең әдәби бүлек мөдире булып эшләде. Аннары, әле студент чагында ук Кавказ, Кырым, Урта Азия республикаларына омтылган йөрәге аны кырымтатар халкы белән бәйләде: кардәш халкыбыздан әдип Шамил Алядин кызы Ләйләгә өйләнеп, ул озакка, күп елларга Ташкент якларына күчте. Сәйяр җаны, Мәҗнүн йөрәге Ләйләсе артыннан алып китте, диикме? Юк, изелгән халыклар, көрәш, милли азатлык юлына керде ул... Соңрак, Кырымга күчеп кайтырга юл ачылгач, гаиләсе белән Симферопольгә кайтты, ахыргача шунда яшәде. Шәрекъ дөньясы, борынгы төрки әдәбиятлар белән ныклап танышу да шунда башланды, мөгаен. Соңрак ул Й. Баласагунының "Котадгу белик" әсәреннән бүлекләрне, Ибне Синаның шигырь белән язылган "Тыйбб белеме" китабын, Кырым шагыйрьләрен һәм халык җырларын—маңәләрне тәрҗемә итеп бастырды; атаклы "Кырым сонетлары"н (А. Мицкевичны!) да татарча яңгыратуга иреште һ. б. Иң мөһиме: элек садә, бертөслерәк калыплар һәм сурәтләр белән башлаган шагыйрь Көнчыгыш шигъри күкләрендә сәйярлек кылгач, борынгы формаларда—фәрд, дүртьюллык һ. б. төгәл, сыналган төрки үлчәүләрдә язды, элекке традицияләрне хәтерләрдә яңартты, дия алабыз. "Ватаным Татарстан" газетасының, "Татар-Информ" агентлыгының һәм "Азатлык радиосының Урта Азиядәге үз хәбәрчесе булып эшләү дәверендә (туксанынчы елларда) ул Казанда төрле форумнарда, милли конгрессларда Ташкент, Кырымнан делегат булып катнашты, диаспора турында чыгышлар ясады, халык тарихы, милли аң турында мәкаләләр бастырды—кыскасы, милләтпәрвәр булып та танылды.

1982 елдан СССР һәм Татарстан Язучылары берлеге әгъзасы иде.

Китапларыннан—нәниләр өчен “Чалгы жыры”, “Ник елыйсың, күрчагым”, кырымтатар телендәге “Яшьлек һәйкәле”, соңгы елларда Казанда дөнья күргән “Көньяк гөлләре”, “Ефәк кәрваннар”, “Иман гасыры” исемендәге жыентыкларны әйтеп китәсем килә. Ижаты турында С. Хәким, Н. Нәжми, Г. Афзал, А. Хәлим әйткән фикерләр, хатлар, сабакташы Х. Миннегуловның әтрафлы мәкаләсе өчен сөенече зур иде.

Егерменче йөз ахыры татар шагыйренең—газаплы эзләнүләр аша Ил-ватан, туган тел өчен яшәүнең катлаулы юлында янып узган бер фидакарь гомере булып гәүдәләнә ул минем уйда. Әйе, сәйях шагыйрьнең сәйяр гомере булып...

**Рәдиф ГАТАУЛЛИН.**

---

**Хәниф Хөснуллинның тууына 70 ел**

# ҮЗГӘ БЕР ТЫЙНАКЛЫК ХАС ИДЕ

Сабыр табигатьле, язган һәр сүзенә үтә жаваплылык тоеп ижат итүче, шәхси тормышында да ижатына хас үзгә бер тыйнаклык белән гомер кичергән бер шагыйрь иде Хәниф Хөснуллин. Хәер, “иде” дию дөрес булып бетмәс—аның байтак шигырьләре, жырлары шигырь-жыр сөючеләр күнелендә һаман яши әле.

Хәниф Хөснуллин—тумышы белән Кама аръягы кешесе, төгәлрәк әйткәндә Түбән Кама районының Шәнгәлче авылында 1935 елда туа ул. Гомеренең төп өлеше дә шул яклар белән бәйле. Үз вакытында Казан педагогия институтын тәмамлагач, Түбән Кама, Минзәлә, Чаллы төбәкләрендә китапханәче, укытучы, журналист, мәктәп директоры вазифаларын башкара. Нинди генә хезмәттә булмасын, ул үзенең дөньялыктагы төп эшен ижат дип санады. Хәниф Хөснуллин татар шигърияtenә 60 елларда килеп, шигърияттә Равил Фәйзуллиннар буыны дип йөртелгән шагыйрьләр белән бергә аралашып ижат итте. Аның “Исәнмесез!”, “Алтын тояк”, “Дөньяның матур жире” китаплары—шул чор ядкарьләре.

80 еллар уртасында Хәниф Хөснуллин ижатын танып, А. Гыйләжев, Р. Харис, Р. Мөхәммәдиев, Р. Хисмәтуллин кебек әдипләр ана ышаныч белдереп, тәкъдимнамәләр бирделәр, һәм ул 1985 елда СССР Язучылар Союзы әгъзасы булды.

Хәниф Хөснуллин күпсанлы лирик шигырьләр, жырлар һәм берничә поэма авторы. Ижатының төп мотивлары: сугыш авырлыгын үз жилкәләрендә күтәргән фидакарьләргә ихтирам, газиз аналарыбызга мәхәббәт, Яшәешнең нигезен тәшкил иткән игенче, төзүче хезмәтләренә хөрмәт, сөю-мәхәббәт хисләренә дан... Ул балалар өчен дә унышлы шигырьләр ижат итте, тәржемә өлкәсендә дә матур үрнәкләр калдырды.

Хәниф Хөснуллин 1994 елда вафат булды.

*Latin imlasında uqu künekmələre*

* * *

Tatar telendə qullanılğan bik küp ğərəp həm farsı süzlərenen Kənçığış tellərdə də şul uq məğnədə yərüe ul süzlərne xalıqara süzlər dip atarğa nigez birə. Şunnan çığıp, tatar telendə ike tərkem xalıqara süzlər turında səylərgə məmkin: berençese—Yevropa sivilizatsiəse aşa kilep kergən xalıqara süzlər, ikençese—Kənçığış sivilizatsiəse aşa kilep kergən xalıqara süzlər, yəğni farsı həm ğərəp alınmaları.

Tatar tele həm ğəmumən tatar ile territorial' yaqtan in caylı cirdə urnaşqan bulğan: tatar ile dənyadağı ike zur sivilizatsiənen, yəğni Kənçığıştan borınğı iran-ğərəp, ə Kənbatıştan sonğaraq Yevropa sivilizatsiəse kilep oçraşqan urında bulğan. Tatar xalqı bu sivilizatsiələrnen ikesen də tartınmıyça üzləştergən. Həm, əytergə kirək, başqa tərki xalıqlar arasında Yevropa sivilizatsiəse in berençe bulıp tatarlarğa kilep kergən. Tatarlar monnan yəz yıllar elek ük inde Rossiədə ekonomika həm kul'tura cəhətennən in alğa kitkən millətkə əwerelgən. Bu xəl, üz çiratında, tatar ədəbiatının həm sənğətenen Yevropa kul'turasının ürnəge belən üseşenə, tatar telenen, başqa tərki tellərgə qarağanda, irtərək fənni yaqtan eşlənə başlawına, tatar leksikografiəse barlıqqa kilügə səbəpçe bulğan.

**Cəlil KİEKBAYEV,**
*başqort tel ğalime, professor.*
1966 yıl.

* * *

Adəm uğlının wəcüde eçrə bel,
Ber tılsım, ber əlğəcib irer bu tel.
Ul tılsım açqıçı berlə açılır,
Bəs ni kilsə başqa, bel, teldin kiler,
Adəmigə nə ni qilsa, tel qılır.

**MƏXAMMADYAR,**
*borınğı tatar şağire.*
XVI ğasır.

* * *

Uz ana telem–minem əçen matur, in tamle tel;
Üz telem–üz əyberem bulğan əçen yarata künel.
Şul ana tele belən min məqsudımnı anlatam;
Şul anam tele belən "balam" dilər atam-anam.
Şul tel arqılı iman, uqu, yazunı ügrənəm;
Şul tel arqılı uqıp-belep bulırmın çın adəm.
Min bala çaqtuq "əti-əni" didem şul tel belən,
Həm də ənkəm də mina "bəbkəm" digən şul tel belən.

Əle də şul tel belən uqim, yazam həm səyləşəm,
Şul tatar tele belən kəylim berər kəy kəyləsəm.
Hərwaqıt şul tel belən yazğan matur kitap uqim,
Hərwaqıt şul tel belən tarix uqim, xisap uqim.

**Məcit ĞAFURİ**

* * *

Eş təcribəsendə min üz uylarımnı, kiçereşləremne aŋlatuda, geroylarıymnıŋ xarakterın həm xərəkətləren surətləwdə telneŋ iksez-çiksez məmkinleklərə barlığın tirənten təşenə bardım. Kompozitor əçen muzıyka qorallarınıŋ tawışı, xudojnik əçen buyawlarnıŋ tərle təse sənğət əsəre tudıru əçen nindi kiŋ məmkinleklər birsələr, ədəbi əsər əçen süz baylığınıŋ role şunnan da kim tügel. Sınlı sənğət əsərendə qoyaşnı yəşel təskə buyap surətləw niçek qırğıy, yatışsız bulıp toyılsa, xikəyə həm romanda süzlərne urınsız qullanu da əsərne şulay uq boza… Xalıq belən aralaşu, xalıq ədəbiatın cıyu arqasında bez əsərlərebezneŋ telen bayıtu belən bergə, cıynaq həm anıq itep yazarğa da əyrənəçəkbez. "Süzlərdə–qısan, fikerlərdə–irken" itep yazu ostalığına başqaça ireşep bulmıy.

**Qawi NƏCMİ**

## MƏQƏLLƏR HƏM ƏYTEMNƏR

*Awız yozaq, tel tozaq.*

*Awıznı pıçaq açmıy, tel aça.*

*Awırtqan cirdən qul kitmi,*
*Səygan cirdən tel kitmi.*

*Altıda belgən ana teleŋ altmışta onıtılmas.*

*Ana balanı ike qat tudıra:*
*Ber qat–tən birep, ikence qat–tel birep!*

*Ananıŋ balağa birgən iŋ zur büləge–tel.*

*Anam birgən tuğan tel, atam birgən qoral tel.*

*Ana tele ber bulır.*

*Bit kurke küz, tel kurke süz.*

*Denemnan dunərm, telemnan dunmam.*

*Ədəp başı–tel.*

*Əytkənnan tel qalmas.*

*Canı sawnıŋ tele, yumartnıŋ qulı tik tormas.*

*İle barnıŋ tele bar.*

*«Казан утлары» архивыннан*



*Шагыйрь Хәсән Туфан Тукай һәйкәле янында—Шигырь бәйрәмендә. 1965 ел, апрель.*



*Академик Мирза Мәхмүтов. 2004 ел, декабрь.*



*Халык язучысы Аяз Гыйләҗев хатыны Нәкыя ханым белән. 1998 ел, январь.*



*Казан университетының тарих-филология факультетын 1950 елда тәмамлаган бер төркем. Рәсемдә—язучылардан: (сулдан уңга): галим Ибраһим Нуруллин, тәрҗемәче Фәния Гайнанова, галим Рашат Гайнанов, Мәхмүт Әхмәтҗанов, Мәҗит Рафиков һәм озак еллар мөгаллимлек иткән укытучылар: Бәрирә Хафизова, Энҗе Камалова, Айзирәк Кәримова, Мәсалия Гәрәева. 1975 ел, июль.*



*Газинур Морат Пермь өлкәсенең Барда районы тирәсендәге Тол елгасы буенда. СССР Язучылар союзы оештырган әдәбият көннәре истәлеге. 1988 ел. Июнь.*



*Шагыйрь Илдар Юзеев һәм язучы Габдрахман Минский журналист Минвәгыйз Зәйнетдинов белән Түбән Кама төзелешләре мәйданында. 1969 ел. Октябрь.*

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## СИМВОЛЛАР ТЕРКӘҮ ҮТТЕ

27 январьда ТР Президенты Минтимер Шәймиевнең РФ Президенты каршында эшләп килүче Геральдика советы рәисе—РФ дәүләт герольдмейстеры Георгий Вилинбахов белән очрашуында катнашучылар тарихи вакыйга шаһиты булдылар. Президентка Татарстан Республикасы дәүләт символларын Россия Федерациясе Дәүләт геральдика реестрына кертү турында таныклык тапшырылды.

"Бүгенге вакыйга—республика дәүләт символларын РФ Дәүләт геральдика реестрына кертү—гаять зур вакыйга",—диде М. Шәймиев.

Республика символларының гаять катлаулы чорда, үзгәртеп коруның беренче елларында, элек-электән җыелып килгән проблемаларның барысы да өскә калкып чыккан бер мәлдә эшләнеп кабул ителгәнлеге сер түгел. Шуңа да карамастан, Татарстан бу чорны исәнимин үтеп, ил үсешенә үзеннән бәяләп бетергесез өлеш кертә алды. ТР Президенты фикеренчә, моңа ирешүнең төп сәбәбе—республика үз хокукларын тормышка ашыруны дәгъвалаганда һәрчак Россиянең бөтенлеген үзәккә куеп килде. "Татарстан халкының, тынычлыкны саклап калып, үсешнең яңа юлына чыгуга зирәклеге җитте. Бу җәһәттән республикабызда яшәүчеләрнең интеллектуаль дәрәҗәсе—күп гасырлар дәвамында җыелып килгән байлык зур роль уйнады. Без моның белән горурланабыз, шуңа күрә ул чагында кабул ителгән республика символлары—Татарстанның дәүләтчелек символлары ул дип исәплибез",—дип ассызыклады М. Шәймиев.

РФ Президенты каршындагы Геральдика советы рәисенең сүзләре дә Татарстан Президенты фикеренә аваздаш булып яңгырады. "Геральдика символикасына карата мөнәсәбәт үзебез яши торган җиргә мөнәсәбәт кебек булырга тиеш. Бөтен җәмгыятебез шуның белән сугарылган тәкъдирдә, без, милли идеябез бар, дип әйтә алабыз",—дип искәртте Г. Вилинбахов.

Татарстан Республикасы дәүләт символларын Россия Федерациясенең Геральдика реестрына кертү турында таныклык тапшыру тантанасында ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Ә. Гобәйдуллин, Премьер-министр урынбасары З. Вәлиева, Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары Ю. Камалтынов һәм Р. Ратникова, республиканың әйдәп баручы министрлыклар һәм ведомстволары җитәкчеләре, ТР Дәүләт Советы депутатлары, шулай ук РФ Президенты каршындагы Геральдика советы вәкилләре катнашты.

## ЖУРНАЛИСТЛАР БӘЙРӘМЕ

"Гаммәви мәгълүмат чаралары—җәмгыять эшчәнлеген тәэмин итү институтларының берсе". Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева Россия Матбугаты көне уңаеннан республиканың массакүләм гаммәви чаралары җитәкчеләре һәм федераль басмаларның үз хәбәрчеләре өчен "Татмедиа" агентлыгында уздырылган тантанада әнә шулай диде.

З. Вәлиева Татарстан Президенты һәм Хөкүмәт исеменнән журналистларны Россия Матбугаты көне белән котлап, республика гаммәви мәгълүмат чаралары эшчәнлегенең һәрвакыт югары дәрәҗәдә булуын, аларга Россиянең башка төбәкләрендә дә безгә тигезләшергә омтылуларын билгеләп үтте. "Яңа шартлар безнең алга шактый катлаулы бурычлар куя. Басмалар инвестицияләр җәлеп итә алсын өчен житди тырышлык таләп ителә. Редакцияләрнең күп кенә бурычларны мөстәкыйль хәл кылырга омтылуы сөендерә",—диде ул. З. Вәлиева республика журналистларына алга таба да Россия матбугаты лидерлары булып калуларын теләде.

Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова үз чыгышында илдәге дәүләт хакимияте структурасын үзгәртүгә бәйле житди үзгәрешләр турында әйтте.

"Татмедиа" гаммәви коммуникацияләр агентлыгы чын мәгънәсендә журналистлар йортына, үзләре өчен иң

мөһим мәсьәләләрне хәл кылу урынына әйләнергә тиеш",—диде агентлыкның генераль директоры Марат Моратов.

### МИНИСТР БЕЛӘН ОЧРАШУ

Төркия Республикасы Дәүләт министры Бәшәр Аталай, Төркия Хөкүмәте йортында Татарстанның массакүләм матбугат чаралары житәкчеләре белән очрашуы вакытында, Төркия һәм Татарстан арасындагы мөнәсәбәтләрне үстерергә кирәк, дип белдерде. Очрашу Төркия Республикасының әйдәп баручы массакүләм матбугат чаралары һәм медиа-холдинглар эшчәнлеге белән танышу максатыннан республика матбугат чаралары житәкчеләре өчен "Татмедиа" тарафыннан оештырылган иде.

Төркия Республикасы Дәүләт министры Бәшәр Аталай Төркиянең массакүләм матбугат чараларының милли системасы, Төркия матбугатында сүз ирекe, аның юнәлешләре турында сөйләде. Үз чиратында Татарстанның матбугат чаралары эшчәнлеге белән дә кызыксынды. Әңгәмә барышында Төркиядә татарларга карата җылы мөнәсәбәт булуын да ассызыклап үтте ул. "Без бер тамырдан бит",—диде министр.

Очрашуда шулай ук Казанның меңьеллыгы темасы да күтәрелде. Министр Төркиянең әлеге мөһим вакыйгага әзерлек чараларында катнашырга әзер икәнлеген белдерде. Бәшәр Аталай, әлеге бәйрәмгә чакыру алса, килергә теләгән дә белдерде.

### МЕҢЬЕЛЛЫКНЫ—МАРТТА УК

Мәскәүнең төбәк татар милли-мәдәни автономиясе Казанның меңьеллыгына багышланган зур бәйрәм программасына әзерлек эшләрен башлап җибәрде.

Проектның авторы һәм генераль продюсеры—Налифәр Якупова. Ул тормышның төрле өлкәләрендә: фән, мәдәният, сәнгать, мәгариф, спорт һ. б. өлкәләрдә үзен күрсәтә алган татар халкының танылган вәкилләрен бергә җыюны тәкъдим итте. Оештыру комитеты бәйрәм очрашуын үткәрү урынын һәм вакытын да билгеләде: ул 14 мартта "Россия" концерт залында үтәчәк. Әлеге проектта Роальд Сәгъдиевнең, Рәшит Сөнәев, бертуган Нигъмәтуллиннар, Мәхмүт Гәрәев, Ренат Акчурин, Ринат Ибраһимов, Фоат Мансуров, Суфия Гобәйдуллина, Алмаз Монасыйпов, Ирек Мөхәммәтов, Фәрит Сәйфел-Мөлеков, Шамил Тарпищев, Марат Сафин, Алинә Кабаева, Әминә Зарипова, Ләйсән Үтәшева, Яна Батыршина, Галимә Шөгерова, Ринат Дасаев, Зиннәтулла Билалетдинов, Ралиф Сафин, Фикрәт Табеев, Алсу, Земфира, Сергей Шәкүров, Марат Башаров, Чулпан Хаматова һәм башкаларның катнашуы күздә тотыла.

### МИЛЛИ КИТАПХАНӘГӘ 140 ЕЛ

24 январьда Татарстан Республикасының Милли китапханәсе оешуга 140 ел тулды. Хәзерге вакытта монда 3 миллион 200 меңнән артык төрле китаплар тупланган, шул исәптә татар телендәге китаплар саны—98 мең, чит телләрдә—78 мең. Ел саен китапханәдән файдаланучылар саны 60 мең кешедән артып китә.

Ул—Казан шәһәре җәмәгать китапханәсе буларак 1865 елда ачылган. Башлангыч китаплар җыелмасын күренекле библиофил һәм туган якны өйрәнүче Иван Второвның шәхси тупланмасы тәшкил иткән. Аның 1908 китабы була. Иван Второв үлгәч, улы әтисенең китапларын Казан шәһәренә бүләк итеп биргән. Бары ике дистә ел узгач кына, шактый каршылыкларны җиңеп, Казанда китапханә оештырыла. 1906 елда исә биредә мөселманнар өчен махсус бүлек ачыла. Озакламый ул Россия мөселманнарының мәгърифәт үзәгенә әйләнә. Инкыйлаб китапханәгә йогынты ясамыйча калмый, әлбәттә. Башта ул—үзәк губерна, аннары үзәк шәһәр китапханәсе дип атала. 1920 елда аны В. И. Ленин исеме белән атыйлар. Йөз еллык юбилее елында ул фәнни китапханә статусы алды.

1991 елда китапханә тарихында яна үзгәрешләр башланды. Шул елның 5 ноябрендә милли мәдәният, милләтара аралашу үзәгенә әйләндерү максатыннан, аңа Милли китапханә исеме бирелде. Хәзер ул татар мәдәниятен таныту, татар китабын һәм республикабыз турындагы әдәбиятны туплау, саклау, тарату мәсьәләләре белән ныклап шөгыльләнә.

### ГЕРБЛЫ ҺӘМ ФЛАГЛЫ КАЗАН

Казан шәһәр Советының XXI сессиясендә депутатлар башкала символларын—герб һәм флаг үрнәкләрен кабул итте.

Әлеге билге проектлары Россия һәм Татарстан Президентлары каршындагы Геральдика советларының тикшерү-экспертизасын узды.

Аннан алынган бәяләмә буенча, башкала символлары геральдика кануннарына тулысынча җавап бирә.

Казан элек тә гербы булган. Ул 1781 елда кабул ителгән. Бүгенге герб та шуңа нигезләнгән. Ул кара аждаһа рәвешендәге сурәттән һәм тарихи Казан бүре-

геннән гыйбарәт. Башкала әләмендә дә аждаһа рәсеме урын алган, әмма ул бүрексез.

Әлеге билгеләр хәзергә компьютерда эшләнгән рәвештә тәкъдим ителде. Тиздән алар осталар тарафыннан кулдан эшләнәчәк.

## ОЕШМАГА ЧИРЕК ГАСЫР

1980 елда, Татарстан Язучылар берлегенең бер өлеше буларак, Чаллы Язучылар бүлеге ачылды. Аны оештыруда Республика җитәкчелегенең, бигрәк тә, ул елларда Чаллы төбәге башлыгы булып эшләгән Рәис Беляевнең һәм Татарстан Язучылар берлегенең шул чор рәисе Гариф Ахуновның роле зур булды.

25 ел эчендә Чаллы язучылар оешмасы зур бер әдәби-мәдәни үзәккә әверелде. Бу төбәктә яшәүче язучыларның йөзләрчә китаплары чыкты, әдәби журнал булдырылды, халык арасында меңнәрчә очрашу-кичәләр уздырылды... Бүгенге көндә оешма байтак дистә (утызга якыны Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы) язучыларны берләштерә (үз вакытында Чаллыда К. Сибгатуллин, Э. Касыймов, Г. Кашапов, Я. Игәнәй, Р. Хисмәтуллин кебек күренекле язучылар яшәде). Хәзерге вакытта татар әдәбияты үсешенә сизелерлек өлеш кертеп килүче А. Хәлим, Ф. Әмәк, Ф. Бәйрәмова, В. Имамов, Р. Бәшәр кебек язучыларыбыз бу шәһәрдә яшәп иҗат итә.

3-4 февраль көннәрендә оешманың 25 еллыгы уңае белән Чаллыда зур әдәби-мәдәни чаралар үткәрелде. С. Садыйкова исемендәге Концерт залына чакырылган кунаклар, шәһәр җәмәгатьчелеге, күпсанлы әдәбият сөючеләр җыйналды. Кичәне Чаллы Язучылар оешмасы җитәкчесе Вахит Имамов ачып җибәрде. Аннан соң шәһәр администрациясе башлыгы урынбасары Фәйрүзә Мостафина чыгыш ясады, тантанада катнашучыларны котлады. Үз нәүбәтендә чакырылган кунаклар—Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, драматург Туфан Миңнуллин, шагыйрь Разил Вәлиев, драматург Ризван Хәмид (соңгы икесе 80 елларда Чаллы Язучылар оешмасының җитәкчесе булып эшләде), шагыйрь Роберт Миңнуллин һәм башкалар чыгыш ясап, Чаллы язучылар оешмасы эшчәнлеге турында сөйләделәр. Юбилей уңае белән күрше республикалардан—Башкортстан, Удмуртиядән дә вәкилләр килгән иде, алар да язучыларыбыз, гомумән татар әдәбияты турында үз сүзләрен әйттеләр. Кунаклар һәм Чаллы язучылары, төркемнәргә бүленеп, Чаллы шәһәренең югары уку йортларында, мәктәпләрендә булдылар, күпсанлы коллективлар белән очраштылар.

Чаллы язучылар оешмасының юбилей тантаналарында "Казан утлары" вәкилләре—баш мөхәррир Равил Фәйзуллин, баш мөхәррир урынбасары Флүс Латыйфи катнаштылар, юбилей кичәсендә һәм очрашуларда чыгышлар ясадылар.

## КОНКУРС ДӘВАМ ИТӘ

Мәгълүм булганча, инде бишенче ел "Идел" яшьләр үзәге һәм Татарстан Язучылар берлеге яшь язучыларның "Иделем акчарлагы" дигән конкурс игълан итеп килә. Ул быел да дәвам итәчәк. Әдәби әсәрләр 2005 елның 1 августына кадәр кабул ителә. Сайлап алу нәтиҗәсен жюри әгъзалары сентябрь аенда белдерәчәк. Финалга чыккан яшь язучыларга "Чишмәкәй" лагеренда үтәчәк "Иделем акчарлагы" конкурсының йомгаклау өлешенә чакыру җибәрелә. Анда конкурсантлар иҗат остаханәләрендә белем эсти, кызыклы викториналарда, күренекле шәхесләр белән очрашуларда катнаша.

Иҗат әсәрләре проза, поэзия һәм драма жанрлары буенча кабул ителә. Шунысын да искәртик: быелгы конкурста проза һәм драма әсәрләре иҗат итүчеләргә аерым игътибар ителәчәк.

Конкурста 3-4 әдәби әсәр белән дә катнашырга мөмкин. Алар татар телендә һәм компьютерда җыелган булырга тиеш. Катнашучыларның яше—14 тән 30га кадәр. Конкурста Татарстан Республикасында гына түгел, чит төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез дә катнаша ала. Хат юллаганда үзегез турында кыскача белешмә, төгәл адрес һәм хәбәрләшү өчен телефон номерын күрсәтү кирәк. Әсәрләрегезне түбәндәге адрес буенча җибәрегез:

420107, Казан шәһәре, Санкт-Петербург (Свердлов) урамы, 12 йорт. "Идел" яшьләр үзәге.

## ХАЛЫК ЯЗУЧЫСЫН ХӨРМӘТЛӘП

Халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнең 75 еллыгы уңаеннан әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан байтак игелекле гамәлләр башкарылды. Шәриф Камал музеенда "Кеше китә—җыры кала" дигән исем белән әдәби кичә үткәрелде. Анда күренекле язучылар, артистлар, язучы иҗатын ихтирам итүче укучылар җыелган иде. Татарстан китап нәшрияты да юбилей уңаеннан укучыларга күркәм бүләк әзерләде: "Мөхәммәт Мәһдиев" дип аталган альбом-китапны бастырып чыгарды. Истәлекләрдән, фотосурәтләрдән гыйбарәт бу китапны төзүче—әдипнең кызы Гәүһәр Мәһдие-

ва. Январь ахырында Арчала, язучының туган авылы Гөберчәктә, укыган авылы Сикертәндә искә алу кичәләре булып узды. Очрашу кичәләрендә Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, язучылар—Т. Галиуллин, М. Әмирханов, Г. Гыйльманов, А. Әхмәдуллин, Т. Нәҗмиев, Х. Ибраһим, Акъегет (Р. Фәйзуллин), В. Нуриевлар катнашты. Бу чараларда шулай ук әдипнең хатыны Лилия ханым Мәһдиева, Гөберчәк музеен оештыруда күп хезмәт куйган Ф. Дәминова һәм башкалар катнашты.

### МАМАДЫШТА ШӘЙХИ МАННУР КӨННӘРЕ

Күренекле шагыйрь, прозаик һәм тәрҗемәче Шәйхи Маннурның тууына 100 ел тулды. Шушы унайдан 14-15 гыйнварьда Мамадыш районында юбилей тантаналары үткәрелде. Бәйрәм чараларында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин житәкчелегендәге зур делегация катнашты. Кунаклар арасында Казаннан танылган каләм әһелләре Ренат Харис, Вакыйф Нуруллин, Зиннур Мансуров, Резеда Вәлиева, Шаһинур Мостафин, Марат Закир, журналистлар Люция Фаршатова, Земфира Гыйльметдинова, Чаллыдан Вахит Имамов, Факил Сафин, Рәис Шаһи бар иде. Юбилей тантаналарында шулай ук әдипнең кызы Миләүшә Маннурова, аларның башка туганнары, Татарстан мәдәният министры урынбасары Илфак Ибраһимов, Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакиров, Тулбайдагы музей-китапханә проектын эшләүдә һәм аны гамәлгә ашыруда күп көч куйган музей белгече Дания Баһаветдинова, "Мәгариф" нәшриятының бүлек мөдире Талия Шакирова, жырчы Мингол Галиев, тальянчы Әгъмәл Шәрәфетдинов, Мамадыш төбәгендә яшәп иҗат итүче шагыйрьләр Рафаил Газизов, Вахит Галиев, Вәрис Гали, Гарәфи Әгъләмов, Сәяф Шәйхи һ. б.лар катнашты.

Беренче көнне район мәдәният йортында Ш. Маннурның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды. Анда кунакларның сәламләү сүзләре, әдипнең шигырьләренә язылган җырлар яңгырады, тамашачыларга аерым әсәрләр буенча сәхнәләштерелгән күренешләр тәкъдим ителде. Юбилей чаралары кысаларында район мәктәпләрендә Ш. Маннурга багышлап язылган иң яхшы инша, шигырь һәм хатка конкурс үткәрелгән иде. Тантаналы кичәдә әлеге бәйгенең җиңүчеләренә диплом һәм бүләкләр тапшырылды.

Икенче көнне иртән район үзәгендә Ш. Маннур һәйкәленә чәчәкләр салу мәрәсиме булды. Аннары кунаклар язучының туган авылы Тулбайга юл тоттылар. Биредә әдипнең каберен зиярәт кылганнан соң, бәйрәмдә катнашучылар музей-китапханә янында Ш. Маннур бюстын (Б. Урманче эше) ачу шаһите булдылар, аннары төзекләндерелгән музей-китапханә белән таныштылар.

Олыяз авылы мәдәният йортында үткәрелгән тантаналы кичәдә ел саен бирелеп барыла торган Ш. Маннур исемендәге бүләкнең быелгы лауреатлары игълан ителде. Татарстан Язучылар берлеге идарәсе һәм Мамадыш районы хакимияте карары белән әлеге премия Ш. Маннур мемориал музей-китапханәсе, "Агымсу" әдәби-иҗат берләшмәсе, Урта Кирмән мәктәбе һәм мәдәният йорты, "Чулпан" агрофирмасының "Таң" кооперативы һәм "Янарыш" кооперативы товарлыклы-сөтчелек фермасы коллективларына бирелде.

### КАЗАН ХӨРМӘТЕНӘ ТӘҢКӘЛӘР

Россия Үзәк банкы быелның июнь аенда "Казанга нигез салуның 1000 еллыгы" исемле юбилей сериясенә керүче мен ярым саф алтын һәм ун мен көмеш тәнкә чыгарырга җыена. 150 данә итеп ясалырга тиешле иң кыйммәтле тәнкәнең хакы—10 мен сум, авырлыгы—1 килограмм. Шулардан кала 7,78 грамм авырлыктагы 50 сумлык мен ярым тәнкә чыгарылачак. Аларның барысы да 999 нчы пробалы алтыннан коелырга тиеш. 100 сумлык бер килограмм авырлыктагы 500 тәнкә көмештән ясалачак. Шулай ук берсе 31 граммлы, 3 сум торган 10 мен көмеш тәнкә дә чыгарылачак.

### "ДАСТАН"—СТУДЕНТЛАР БАСМАСЫ

Татар дәүләт гуманитар институтының тарих, татар теле һәм көнчыгыш телләр факультеты студентлары тарафыннан нәшер ителә торган "Дастан" дигән газетасының беренче саны дөнья күрде.

Ун биттән торган, студентлар тормышын, аларның эшчәнлеген һәм иҗатын яктыртучы газетаның әлеге санында институт ректоры Васил Гайфуллин белән әңгәмә бирелгән. Анда ректор башкарылган эшләргә йомгак ясый, барлык студентлар һәм укытучылар өчен дә җитди мәсьәлә саналган яна бина төзелү һәм яңа факультетлар ачылу хакында мәгълүмат бирә. "Быел, ди ул, "Татэнерго"ның элеккеге бинасына күчүне планлаштырабыз, соңрак исә Г. Камал театры каршында төзелүче зур һәм мәһабәт өр-яңа бина безнеке булачак. Киләчәктә милли университет статусын алачак институтыбызның факультетлар саны да күбәер. Тарих факультеты үзе берничә бүлектән торачак, анда музей

эшчәнлеген һәм татар халкы тарихын өйрәнү бүлекләре булачак. Инглиз теле факультеты да инглиз-испан һәм инглиз-татар бүлекләреннән торачак. Шулай ук журналистика, әдәбиятчылар факультетларын ачу да күздә тотыла. Әдәбиятчылар факультетында тәнкыйтьчеләр, сценарий язучылар әзерләнәчәк. Аерым рәвештә информатика, икътисад, дәүләт һәм муниципаль идарә итү, хокук һәм халыкара мөнәсәбәтләр, мәдәният, этнография, политология, менеджмент һәм туризм факультетлары ачылачак",—диде Васил Гайфуллин әлеге әңгәмәсендә.

### МУЗЕЙ АРТЫР

"Казан Кремле" тыюлыгы житәкчесе урынбасары Нияз Халитов Санкт-Петербургта булып кайтты. Ул анда "Эрмитаж" житәкчелеге белән әлеге данлыклы музей бүлеген Казанда булдыру хакында эшлекле сөйләшүләр алып барды. "Казан" дип аталган Эрмитаж үзәге Казан Кремле жирлегендәге элеккеге юнкерлар училищесының өченче катында урын алачак. Шунсы да мәгълүм булсын: Эрмитажның бүлекләре әлегә Амстердамда, Лондонда һәм Лас-Вегаста гына. Ә бездәгесе музейның Россиядәге тәүге бүлеге булачак.

### "ТИМЕР БОРЧАК" ПРЕМЬЕРАСЫ

10 февральдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Равил Бохараев әсәре буенча куелган "Тимер борчак" (режиссеры—Рамил Фазлыев) премьерасы күрсәтелде. Балалар өчен язылган әлеге әсәр узган ел "Яңа татар пьесасы" конкурсында өченче урынны алган иде. Автор әсәрен рус телендә, шигъри формада язган. Пьесаны татарчага Хәлим Жәләй тәрҗемә иткән.

"Тимер борчак" Г. Тукай, К. Насыйри әкиятләренә нигезләнеп язылган. Төп рольләрне Н. Ихсанова, Р. Әхмәтжанов, И. Баһманов кебек күренекле артистлар башкара.

### ЖИҺАНГИРГА БАГЫШЛАНА

Россиянең күренекле актеры һәм режиссеры Сергей Бодров тарихта зур эз калдырган Чыңгыз хан турында фильм төшерә башлады. Фильм иң зур халыкара проектлар рәтенә керә. Анда Россия, Монголия, Казакъстан, Алмания, Франция һәм Кытай актерлары һәм кинематографчылары катнаша. Аны төшерүгә 10-12 миллион сум акча каралган. Беренче тасма Монголия далаларында төшерелә башлаячак.

### МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ ТУРЫНДА ФИЛЬМНАР

БТК Башкарма комитеты дөньяга сибелгән милләттәшләребезнең үткәне, бүгенгесе турындагы "Татар авазы" дигән фильмнар сериясен әзерләүне башлап жибәргән иде. Аның беренчесе—Мордовиядә гомер итүче татарларга багышланганы "Татарстан—яңа гасыр" телевидениесе аша тамашачыларга күрсәтелде дә инде.

Икенче фильм Удмуртиядә яшәүче милләттәшләребез тормышына багышланган. Иҗат төркеме монтаж эшләрен тәмамлады, фильм тиздән тамашачылар хөкеменә тапшырылачак.

### ЯҢА БЕЛЕШМӘ

"Заман" нәшриятында Татарстан Милли музее инициативасы белән "Казан музейлары" дигән белешмә-юл күрсәткече дөнья күрде. Казанның 1000 еллыгына багышланган әлеге белешмәдә төрле елларда башкалада ачылган музейларның тарихы, аларның бүгенге эшчәнлеге турында мәгълүмат тупланган. Жыентык 5 бүлектән тора, барлыгы 84 музей турындагы язма урын алган. Кушымта рәвешендәге бүлектә музейларның бүгенге адреслары да күрсәтелгән.

*

### *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казан кызы Ләйсән. ***Н. Васильева рәсеме.***

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы-публицист **Венера Якупова.**

# ЯҢА КИТАПЛАР




**Мәхәббәтнамә.** Поэмалар, дастаннар, шигырьләр.—Казан: "Мәгариф" нәшр., 2005. —320 б. Тиражы—3000 данә.

Әле монарчы бер үк китапта параллель рәвештә бер үк текстларның татарча һәм башкортча басылганы юк иде шикелле. Татар кешесе башкорт китабын, башкорт—татар китабын, әгәр ул туган телен яхшы белсә, рәхәтләнеп укый ала. Китап бу җәһәттән үзенә күрә бер яңалык... Бу уртак җыентыкка Идел-Урал төбәгендә яшәүче өч йөздән артык шагыйрьнең мәхәббәт дип аталган бөек хискә багышланган шигырьләре тупланган.

Китап Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең кыскача кереш сүз-юлламасы белән ачыла. Анда мондый сүзләр бар: "Сөю-сәгадәт белән мөлдерәмә әлеге үзенчәлекле китап—Агыйделләр, Чулман-Иделләр аша үрелеп кул биреп күрешү фалы—уртак моңнарыбызга һәйкәл, ана телләребезгә хөрмәт, туганлыгыбызны ныгыту билгесе булсын".

Китапның төзүчеләре: Г. Котоева (Уфа), Р. Корбан (Казан), С. Шәрипов (Уфа).




Фәрит Хатипов. **Мөлкәтебезне барлаганда**: иҗат портретлары, тәнкыйди-теоретик мәкаләләр.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.—272 б.—Тиражы—2000 данә.

Әдәбият белгече, галим Фәрит Хатиповның бу китабында әдәби мөлкәтебезгә бүгенге караш яктыртыла: совет чорында язылган күренекле роман-повестьларыбыз яңача анализлана. Китапта Ә. Еники, Н. Фәттах турында иҗат портретлары урнаштырылган. Анда шулай ук Ф. Хөсни, Г. Бәширов, С. Баттал, А. Гыйләҗев, Р. Батулла, М. Хуҗин әсәрләренең сәнгатьчә үзенчәлекләре, иҗат серләре бәян ителә. Яңа рухтагы теоретик мәкаләләр тәкъдим ителә.

Китапның мөхәррире—Ф. Хафизов, рәссамы—Э. Егоров.

Индекс 73210



Венера Якупова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)